www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

Бу санда

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Туган телгә мәдхия. *Шигырь.* ...3

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Бердәм милләт мәңге яшәр! *Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе Ринат ЗАКИРОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе.* ...4

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Һиҗрәт. *Тарихи роман.* ...14
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Еракларга җилде болытлар. *Шигырьләр.* ...84
Дамир ГЫЙСМЕТДИН. Асылташ. *Сатирик маҗара.* ...88
Ирек САБИРОВ. Яшәсен иде халкым... *Шигырьләр.* ...104
Бу – минем тарихи кыйммәтем! *(Роберт МИҢНУЛЛИН, Айдар ХӘЛИМ, Равил РАХМАНИ, Нәҗибә САФИНА, Рашат НИЗАМИ, Рәниф ШӘРИПОВ, Ленар ШӘЕХ шигырьләре).* ...154

*100нче бит:* Ирек САБИРОВ. Ана теле сүзлеге. ...100

ИСТӘЛЕКЛӘР

Индус ТАҺИРОВ. Азатлык юлында. ...110
Рәфикъ ЮНЫС. Татар күге якты, бик якты! ...115
Гөлгенә КӘРИМОВА. «Менә шундый Зәйнәб инде мин...» ...116

МӨХӘРРИР СОРАУ БИРӘ

Рухың саумы, Милләтем? *Рамил ХАННАНОВ әзерләде.* ...130

ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ

Зәки ВӘЛИДИ ТУГАН. Хатирәләр. ...139
Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Самара татарлары һәм замана фольклоры. ...148

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Юксыну. ...160

ТАРИХ

Мостафа ӨНӘР. Тарихтагы татар сурәте турында язмалар. ...165

СӘНГАТЬ

Рабит БАТУЛЛА. Тулганай тотылганда. ...172
Асия ЮНЫСОВА. Юллар һәм җырлар. ...177

*Укучыларыбыз иҗаты:* Гыйззәтулла ХӘСӘН. Алтыннан да асыл телем. *Шигырьләр.* ...184

*Шаян сәхифә.* Уены-чыны бергә. Зәки ВӘЛИДИ ТУГАН хатирәләреннән өземтәләр ...187

«Казан утлары» архивыннан. ...108
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер)**.**

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
✆: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.06.2017, график буенча 30.06.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1557. Тираж 4950.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел

Лена
Шагыйрьҗан

# ТУГАН ТЕЛГӘ МӘДХИЯ

Әй син, телем, туган телем,
тамыр телем.
Җир астыннан тарих серен
табыр телем...
Әй син, телем, рәхәт телем,
авыр телем.
Телне тешләп канатырлык
сабыр телем...
Синең беләң рәхмәт укыйм,
теләк телим.
Җырга салып сине, милли
көйләр көйлим.
Табындагы икмәгем күк
телем-телем,
Табынам сиңа,
синсез бер тәм
тоймас телем...
Әй син, телем, айлы төнем,
якты көнем.
Әремнәрдән әче, балдан
татлы телем.
Сине саклап калыр өчен
күпме белем
кирәклеген аңладым мин,
белдем бүген...
Әткәм-әнкәм мирасы син
миңа күчкән.
Чишмә үзе сусаганда,
сине эчкән...
Алдым сине,
күчтең төбем-тамырыма,
күчтең күзәнәкләремә,
карыныма.
Кердең аңга, яттың җанга,
сеңдең канга.
Һәр гөл белә үз исемен
син кушканга.
Җиһандагы һәрбер җисем,
һәрбер матдә,
Исемем бар, дип, гүя сиңа
рәхмәт әйтә.
Әй син телем, батыр телем,
горур телем.
Җирдә йолдыз булып балкып
торыр телем.
Халкым теле, хак телем син,
йөрәк телем.
Киләчәгем өчен мәңге
кирәк телем!

# БЕРДӘМ МИЛЛӘТ МӘҢГЕ ЯШӘР!

*Журналыбызның бу саны халкыбыз тарихында булачак мөһим вакыйгага багышлана. Август аенда Казанда дөньяның 40 иленнән милләттәшләребез Бөтендөнья татар конгрессының VI съездына җыелачак.*

*Без шул уңайдан Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе* ***Ринат Зиннур улы ЗАКИРОВ*** *белән булган әңгәмәне тәкъдим итәбез.*



***– Хөрмәтле Ринат әфәнде! Быел Бөтендөнья татар конгрессы оешуга 25 ел тула. Ул үзенең август аенда узачак VI съездына әзерләнә. Шушы уңайдан Конгрессның оешу сәбәпләре һәм аның тарихы турында кыскача сөйләп китсәгез иде.***

– Әйе, Бөтендөнья татар конгрессының 25 еллык юбилее хикмәтле рәвештә 1917 ел вакыйгаларының 100 еллыгына туры килә. Мин монда бик зур символик мәгънә күрәм. Революция чорында халкыбыз көчле милли күтәрелеш кичерә. 25 ел элек тә шулай булды, ирекkә сусаган халык урамнарга чыкты, мәйданнарны тутырды. Моның сәбәпләре бик тә аңлаешлы, татар кешесе ул азатлык җилләренә гаять сизгер, илдә барган демократик үзгәрешләрне нечкә тоемлый.

Узып киткән XX гасыр татар халкы өчен гаять мөһим чор булды. Нәкъ шушы чор башында, XIX йөздән яңа гасырга күчкәндә, татар халкы заманча милләт булып формалаша һәм көчле мәдәни күтәрелеш кичерә. Татар тормышына, язгы ташкын кебек, яңа күренешләр бәреп керә: яңа әдәбият, милли матбугат, профессиональ театр һәм музыка сәнгатьләре; милли мәгариф системасында җәдитчелек хәрәкәте барлыкка килә. Милләт мәйданында яшь, көчле әдипләр пәйда була: Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Габдрәшит Ибраһимов һәм башка бик күпләр. Илнең катлаулы шартларында татар үзен иҗтимагый-сәяси тормышта да сынатмый. Әйтик, Бөтенрусия мөселманнарының I съезды 1905 елның 15 августында бик маҗаралы рәвештә уза. Аның делегатлары Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында, саклану чарасы буларак, «Густав Струве» пароходына төялеп, Идел буйлап сәяхәткә чыгып китәләр һәм шунда милләт язмышы турында җитди сөйләшүләр алып баралар. Соңыннан татар халкы вәкилләре, Русия Дәүләт Думасына сайланып, үзләрен әзерлекле сәясәтчеләр итеп күрсәтәләр. Ә Садри Максуди илнең парламентында хәтта мөселман фракциясен дә җитәкли.

Менә шулай, туктаусыз хәрәкәттә булган халкыбыз 1917 елга килеп керә. Февраль инкыйлабыннан соң, ул елның язында Казан урамнарында «Без бу азатлыкны 300 ел көттек» дигән шигарь астында туктаусыз татар митинглары уза. Нәкъ шул елда татар җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән өч гомумрусия мөселман съезды уздырыла. Ә 1917 елның җәендә Казан шәһәрендә Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарияте игълан ителә. Моны, һичшиксез, татар дәүләтчелеген торгызуга тәүге адым дип карарга кирәк. Ул чорда сәяси мәйданга татарның бик көчле сәясәтчеләре һәм җәмәгать эшлеклеләре чыга: Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Ильяс Алкин, Галимҗан Шәрәф, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Ризаэтдин Фәхретдин,

Мирсәет Солтангалиев һ.б. Һичшиксез, татар халкының шушындый көчле хәрәкәте, милли дәүләт корырга омтылышы яшь совет хөкүмәтен 1920 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын булдыру турында карар чыгарырга мәҗбүр итә. Бу мөһим вакыйганың 100 еллыгын Татарстан зурлап билгеләп үтәргә җыена, моның өчен махсус хөкүмәт комиссиясе дә төзелде инде.

Әйе, совет чоры татар халкы тормышына зур үзгәрешләр китерә, әйтик, милли мәгариф дөньяви нигезгә баса, диннән читләшә. Илдә барган индустриализация шаукымы татарларны шәһәрләргә күпләп күчәргә мәҗбүр итә. Совет хакимияте бик күпләргә югары белем алу мөмкинлеге бирә. Милли әдәбият һәм мәдәният яңа совет идеологиясе нигезенә күчерелә, әмма миллилек сыйфатларын җуймый. Татар мәдәниятендә яңа жанрлар барлыкка килә: опера, балет сәнгатьләре, симфоник һәм камера музыкалары. Милли матбугат татар телендәге радио һәм телевидение тапшырулары белән тулыландырыла. Болар, һичшиксез, милләт үсешен тасвирлый. Әмма, минемчә, совет чорының тискәре күренешләре турында әйтмәсәк, дөрес булмас. Сталин репрессияләре аркасында меңләгән зыялыларыбыз, дин әһелләре, авылның тырыш кешеләре корбан ителә. Татар телен ике тапкыр әлифба алыштырырга мәҗбүр итәләр, ә моның максаты билгеле: халыкны бай милли мирастан читләштерү, ассимиляция юлына кертеп җибәрү. Шунысын да әйтергә кирәк: совет автономиясе кысалары милләт үсешен шактый чикләде. Моны татар җәмәгатьчелеге һәрвакыт әйтеп килде. Чикләүләрнең иң авыры татар халкының бердәм милли тормышын тыю булды. Совет чорында татар тормышы ТАССР кысаларына кертеп бикләнгән иде, ә бу инде илдә яшәүче миллионлаган татарны һич тә канәгатьләндерә алмады.

Шуңа да, илдә демократик үзгәрешләр башлангач, татар кул кушырып утырмады, янә милли хәрәкәткә күтәрелде, аның төп таләбе Татарстанны союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрү иде. Нәтиҗәдә, 1990 елның 30 августында Татарстан Республикасы мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителде. Шул көннән татар халкының яңа дәүләтчелеге башланды дисәк, ялгыш булмас.

Кайвакыт, «Нәрсә бирде соң безгә Суверенитет декларациясе?» дигән сорау ишетергә туры килә. Минем ул сорауга җавабым бер: Татарстанның мөстәкыйльлеге халкыбызга горурлык хисен, үз-үзеңне ихтирам итү тойгысын кайтарды. Чыннан да, шушы чорда татар кешесе җилкәсен турайтты, башын горур тотып йөри башлады, аның әлегә хәтле басылып килгән көче, егәре ачылды.

Әгәр бүген Татарстан Республикасы илебезнең иң алдынгы төбәкләренең берсе икән, бу бит күктән төшмәгән, бу – халкыбызның тырышлыгы, канатланып эшләү нәтиҗәсе. Психология күзлегеннән караганда, кешенең күңеле ул бик нечкә нәрсә. Төшенке күңел белән яшәп аска гына тәгәрәп була, ә күтәренке рух, канатлы хыял кешеләрне күкләргә күтәрә, зур уңышларга ирештерә.

Бүгенге Татарстанны 25 ел элекке халәте белән чагыштырып та булмый. Кешенең табигате шундый ки: ул яхшыга тиз күнегә, тормыш гел шулай барган дип уйлый башлый. Казан уртасында таралып утырган хәрабәләрне, халык кысылып төялгән шәһәр транспортын, интегеп Кама аркылы паромда йөргәннәрне, авылларның юлсыз, газсыз интеккәнен яхшы хәтерлим мин. Ә бүген Казанны да, җөмһүриятебезнең шәһәр-авылларын да танырлык түгел инде. Меңләгән гаилә иске-җимерек торактан яңа җайлы фатирларга күченде. Казан халкы җилдереп метрода йөри. Авылларыбызга юллар, газ, су керде. Болар авыл кешесенең тормышын, яшәү рәвешен тамырдан үзгәртте. Кама, Идел, Казансу, Нократ елгалары аша салынган яңа күперләр ерак араларны якынайтты. Бу үзгәрешләр Татарстанның икътисади үсешенә дә көчле этәргеч булды.

Шулай итеп, еллар үткәч, Дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең республикага нинди мөмкинлекләр ачканын бик яхшы күрәбез. Без ул кыю адымның нинди нәтиҗәләргә китергәнен әле бер яктан гына ачып бирдек. Икенче ягы исә халкыбыз өчен тагын да мөһимрәк. Татарстанның яңа дәүләтчелеге милли хәрәкәтне дә яңа баскычка күтәрде. 1992 елның җәендә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең фәрманы белән Казанда Бөтендөнья татар конгрессының I съезды җыелды. Халкыбыз бу чараны үзенең олуг вакыйгасы һәм чын бәйрәме сыйфатында кабул итте. Ул корылтайның күтәренке рухы күпләрнең күңелендә әле дә

саклана. Конгресс Башкарма комитетының беренче рәисе итеп күренекле галим, тарих фәннәре докторы, академик Индус Таһиров сайланды һәм ул аны 10 ел дәвамында җитәкләп килде.

Инде хәзер, Бөтендөнья татар конгрессының 25 ел дәверендә үткән юлын күзалласак, күңелдә горурлык хисе туа. Уйлап карагыз, безнең халыкара оешмабыз бүген Русиянең 70 төбәгендәге һәм дөньяның 40 илендәге 500гә якын татар җәмгыятен берләштерә. Алар тырышлыгы белән һәр җирдә татар тормышы кайнап тора һәм милләттәшләребезнең Татарстан белән бәйләнешләре елдан-ел ныгый, үсә. Ә бу инде дөньяга сибелгән 7,5 миллионлы татар халкының уртак милли тормышы бар дигән сүз.

***– Бүген татар дөньясы һәм милли оешмалар алдында нинди бурычлар тора, нинди максатлар куела?***

– Максатыбыз бер – татар милләтен саклау һәм яшәтү, аның мәгарифен-мәдәниятен үстерү. Милләт тормышында торгынлык булырга тиеш түгел, ата-бабаларыбыз, өлкән буын безгә бай рухи һәм мәдәни мирас калдырган, безнең алардан чигенергә һич хакыбыз юк.

Әмма иске казанышлар, элеккеге уңышлар белән генә яшәп булмый, безгә киләчәк турында да уйланырга кирәк, ә монда борчылырлык нәрсәләр бар. Бүген милли мәгариф һәм мәдәният өчен кадрлар әзерләү мәсьәләсе алдыбызга бөтен кискенлеге белән килеп басты. Әгәр татар үзенең мәгарифе-мәдәнияте турында үзе кайгыртмаса, башкалар аларны һич кайгыртмас. Әйтик, әлегә кадәр безнең татар әдәбияты талантларга беркайчан кытлык кичермәде, яңадан-яңа әдипләр, сүз осталары халкыбызның күңеленә ятышлы әсәрләр иҗат итеп килде. Һичшиксез, без моның өчен милли мәгарифкә, фидакарь укытучыларыбызга рәхмәт әйтергә тиеш. Туган телдә укыган Муса Җәлил, Әмирхан Еники, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин һәм бик күп башкалар әдәбият мәйданына чыгып каләм тибрәтте. Кызганыч ки, бүген бу инеш саегып бара, чөнки милли мәгариф системабыз шактый авырлыклар кичерә, моны танырга кирәк. Ә бит бу кыенлыклар әдәбият өлкәсенә генә кагылмый, әлеге проблемалар театр, музыка, эстрада сәнгатьләрен дә уратып узмый. Әгәр без милли кадрлар, артистлар, режиссёрлар, дирижёрлар, композиторлар, башкаручылар әзерләүгә игътибарны арттырмасак, мәдәният дәрьясы да саегачак. Уйлап карагыз, 20-30 ел элек безнең симфония, опера, балет өлкәсендә иҗат итүче композиторларыбыз ике дистәгә якын булса, бүген аларның саны 4-5 исем белән генә чикләнә. Заманында татар музыкасын үстерү нияте белән оештырылган Татарстан Дәүләт симфоник оркестры да бүген милли әсәрләрдән читләште.

Кызганыч, кайбер кешеләр милли мәдәниятне фольклор дәрәҗәсендә генә күрә. Дөрес, анысы да кирәк, әмма югары мәдәниятең булмый икән, димәк, заманча милләт булуың да шик астына куела. Республикада музыкаль театр булмавы да сәнгатебез үсешенә кире йогынты ясый. Безнең Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры бинасы ел әйләнәсендә күп вакыт буш тора, чөнки аның труппасы яртышар ел чит илләрдә гастрольдә йөри. Нигә шул вакытта сәхнәгә татар музыкаль спектакльләрен чыгармаска? Ә хәзергә безнең яшь талантлы артист-җырчыларыбыз мондый спектакльләрне консерваториянең укыту студиясендә генә куярга мәҗбүр. Мондый ярым үзешчән спектакльләргә дә халык бик теләп йөри, әмма алары да бик сирәк куела. Кыскасы, без милли мәдәниятебезне бар көчебез белән сакларга һәм үстерергә тиеш.

***– Конгрессның милли мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеге турында әйтеп китсәгез иде.***

– Мөстәкыйльлек юлына басу барлык тармакларда республика үсешенә киң мөмкинлекләр ачты. Мәгариф өлкәсендә бу аеруча нык сизелде. Шул ук 90нчы елларда Казанда, Чаллыда, җөмһүриятебезнең башка шәһәрләре һәм район үзәкләрендә дистәләгән татар гимназияләре, татар-төрек лицейлары ачылды, халык бик теләп ул мәктәпләргә балаларын укырга бирә башлады. Моны аңлап була, чөнки татар мәктәпләре үзләренең тәртибе, җылы мөнәсәбәтләре, тәрбияви уңышлары белән



*Бөтенроссия Сабан туе. Чиләбе. 2012 ел*



*Бөтенроссия дин әһелләренең VI форумы. Казан. 2016 ел*



*II Европа Сабан туенда. Сулдан уңга: Жанетта Миңнуллина (Лондон), Гөлназ Шәйхи (Казан), Рамил һәм Ленара Кутиевлар (Казан), Равил һәм Фәүзия Хадиуллиннар. Таллинн. Берлин. 2015 ел*

һәрвакыт аерылып торалар. Минемчә, бу халкыбызның иң матур сыйфатларыннан, бала сөючәнлегеннән килә.Ул гына да түгел, 90нчы елларда Татарстанның югары уку йортлары да татар теленә йөз белән борылды. Казан дәүләт университетында татар факультеты ачылды, башкалабызда Татар гуманитар институты эшли башлады, бай тарихы булган Казан педагогика институты Татар гуманитар-педагогика университеты итеп үзгәртелде, башка югары уку йортларында да төрле белгечлекләр буенча татарча уку төркемнәре булдырылды. Ул елларда татар җәмәгатьчелеге дә читтә тормады, төрле үзешчән мәгариф оешмалары һәр мәктәп эшчәнлеген контрольдә тотты.

Кызганыч, тора-бара милли мәгарифкә мөнәсәбәт үзгәрде. Бигрәк тә бу Дәүләт Думасы тарафыннан 309нчы номерлы Закон кабул ителгәч, нык сизелә башлады. Ул канун мәгарифнең федераль стандартларыннан милли компонентны төшереп калдырды. Укыту стандартларында милли компонент булмагач, төбәкләрдә туган тел дәресләре кимеде, күп җирләрдә аны факультатив (димәк, теләгән кешеләргә генә) рәвештә генә укыта башладылар. Шуның өстенә, күп төбәкләрдә «оптимизация» дигән сылтау белән татар мәктәпләрен яптылар яисә урыс теленә күчерделәр. Мәктәпләргә Бердәм дәүләт имтиханын кертү дә милли мәгарифкә зур зыян салды, чөнки аны туган телдә тапшыру тыелды.

Бөтендөнья татар конгрессы каршында мәгариф комиссиясе эшләп килә, җәмәгатьчелек вәкилләре татар мәктәпләре эшчәнлеген даими рәвештә тикшереп тора. Мин үзем дә, Конгресс җитәкчесе буларак та, Татарстан Югары Советы депутаты буларак та, кая гына барсам да, андагы татар мәктәпләрен карап чыгарга тырышам.Таныргa кирәк, аларның төрлесе бар, бик яхшы эшли торганнары да, күз буяуга корылганнары да. Әле күптән түгел миңа Арча районының Шушмабаш урта мәктәбендә булырга туры килде. Менә бу инде чын милли уку йорты! Анда бөтен фәннәр фәкать татар телендә генә укытыла, балаларның, өлкән сыйныф укучыларының күзләре янып тора. Алар белән аралашу чын күңел бәйрәме булды, шулхәтле белемле, тапкыр, тәрбияле матур балалар, күз генә тимәсен! Барлык мәктәпләребез дә шундый булсын дип җан атарга кирәк безгә хәзер!

Тагын бер нәрсә турында аерып әйтәсем килә. Узган елларда республиканың мәгариф җитәкчеләре еш алышынып торды, бу һич тә файдага булмады. Кызганыч ки, мәгариф өлкәсенә күз буяу ысуллары үтеп керде, ә болар тәрбия эшенә бик зур зыян китерә. Ниһаять, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгын Энгель Фәттахов җитәкләде һәм ул җиң сызганып эшкә кереште. Бүген мәгариф өлкәсендә күзгә күренерлек уңай үзгәрешләр бар. Мәгариф министрлыгы төбәкләрдә эшли торган татар теле укытучыларының корылтайларын даими уздыра башлады, татар теленнән халыкара олимпиадалар үткәрелә, анда меңләгән укучы катнаша (хәтта чит илләрдән дә), шулай ук Интернетта «Ана теле» дип аталган дистанцион онлайн мәктәбе эшләп килә һәм бу мәктәптә берьюлы 10 мең кеше татар телен өйрәнә.

Әмма борчыган әйберләр дә юк түгел. Минемчә, Казанда эшләп килгән махсус педагогика югары уку йортын федераль университетка кушу зур хата булды. Федераль университетны тәмамлаучылар мәктәпкә эшкә бармый, аларның карашлары һәм максатлары башка. Ә бүген республика мәктәпләрендә, бигрәк тә татарлар күпләп яшәгән Русия төбәкләрендә, укытучы кадрларга кытлык үзен нык сиздерә. Шул сәбәпле, минем фикеремчә, Казанда ашыгыч рәвештә педагогика югары уку йортын яңадан торгызырга кирәк.

Татар мәгарифе ул бит әле милли кадрлар, әдәбият-мәдәният әһелләрен әзерләү генә түгел, ә, беренче чиратта, шушы бай мәдәниятне кулланучы укучыларны, тамашачыларны тәрбияләү дә. Әгәр безнең йөзләгән язучыларыбыз, шагыйрьләребез бар икән, аларның бит укучылары да булырга тиеш. Милли театрларыбыз, сәнгатькәрләребез иҗат иткән спектакльләр, концерт-тамашаларны караучы булмаса, бу бит инде һич акларлык нәрсә түгел. Тамашачыларны тәрбияләү дә милли мәгариф эше.

***– Бөтендөнья татар конгрессының эш ысуллары, аларның үзенчәлекләре турында әйтеп китсәгез иде.***

– Без күптән инде үзебезнең эшчәнлектә халкыбызның төрле катламнары белән

хезмәттәшлекне төп ысул итеп алдык. Әйтик, бүген Бөтендөнья татар конгрессы кысаларында хатын-кызлар, яшьләр, дин әһелләре, укытучылар, авыл эшмәкәрләре, галимнәр, төбәк тарихчылары хәрәкәтләре эшләп килә, аларның илкүләм оешмалары да бар. «Ак калфак» халыкара татар хатын-кызлары оешмасы үзенең форумнарын ел саен уздыра, анда татар гаиләсе, хатын-кызларның җәмгыятьтә тоткан урыны, милли традицияләр, гореф-гадәтләр, хәтта татарның аш-су осталыгы турында да җитди сөйләшүләр бара. Әйе, татар гаиләсенә дә бүген ярдәм кирәк, миллилек бит ул, беренче чиратта, гаиләдә тәрбияләнә. Демография мәсьәләсе дә кискенләште. Хатын-кызларыбыз укымышлы-белемле, бүген аларның җәмгыятьтә тоткан урыннары бик тә мөһим. Мәгарифтә, сәламәтлек саклауда эшләүчеләрнең күпчелек өлеше нәкъ менә хатын-кызлар. Шуңа күрә алар өйдә бала карап кына утыра алмый. Әмма һәр татар гаиләсендә ким дигәндә өч бала тәрбияләнсә, без татар халкының демографик хәлен нык яхшырта алыр идек.

Тагын бер үзенчәлекле күренеш турында әйтәсем килә. Татар халкының гасырлардан килгән аш-су традицияләре бар, алар милли мәдәниятебезнең аерылгысыз өлеше дип әйтсәм, ялгыш булмас. Менә шуларны истә тотып, күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессы, төрле төбәкләрдән милләт кызларын җыеп, Әтнә районында һәм Казанда татар ризыкларын пешерү буенча «мастер-класс» дип аталган кулинария сабакларын уздырды. 100дән артык кеше татарның аш-су әзерләү серләрен өйрәнде. Мондый эшнең нәтиҗәсе булмый калмас, әлбәттә.

Конгресс яшьләр хәрәкәте белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Безнең Башкарма комитетта махсус яшьләр бүлеге эшләп килә, аның җитәкчесе Тәбрис Яруллин шул ук вакытта Бөтендөнья татар яшьләре форумы дип аталган халыкара оешманың да рәисе. Ике елга бер Казанда зур күләмле Татар яшьләре форумы җыела, былтыр аның җиденчесендә 750 кеше катнашты. Бу эш безнең 2004 елда башланды, һәм, әйтергә кирәк, һәр чираттагы җыенга берсеннән-берсе әзерлекле милләт егетләре һәм кызлары килә. Мин яшьләребезнең шулхәтле милли җанлы булуларын күреп сокланам. Ул форумнарда яшьләр төрле секцияләргә бүленеп эшли, анда милли һәм тарихи үзаң тәрбияләү турында да, татарның төрле төбәкләрдәге тарихи ядкарьләре турында да, заманча технологияләр турында да җитди сөйләшүләр һәм бәхәсләр бара. Татар яшьләре Татарстан белән, аның тарихи урыннары белән таныша. Яшьләребез өметле, аларны милләт язмышы борчый икән, бу – табигый күренеш.

Сер түгел, безнең максатыбыз – төрле төбәкләрдә яшәүче татар яшьләрен бер-берсе белән таныштыру, дуслаштыру, аларны уртак проектлар белән мавыктыру. Яшьлек бит әле ул – хисләр, тойгылар кайнап ташып торган чор, гаилә кору нияте белән яшәү. Шулай татар яшьләре форумнарында танышып гаилә корган егетләр һәм кызлар бар. Монысы безнең өчен аеруча куанычлы, бу яшьләр бит милләтебезнең киләчәге. Татар гаиләләре арткан саен, милләтебезнең киләчәге дә өметлерәк.

Яшьләр турында сүз чыккач, тагын бер уртак эшебезне аерып әйтәсем килә. Менә инде ничәмә еллар Татарстанда читтә яшәүче милләттәшләрне республика югары уку йортларына максатлы урыннарга җәлеп итү оештырыла. Шушы проект нигезендә һәр елны читтәге яшь милләттәшләр Татарстан югары уку йортларына кабул ителә. Алар төрле белгечлекләр буенча укый, без бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты, татар тарихы буенча белем алуны хуплыйбыз. Нинди генә белгечлек буенча укысалар да, алар биш ел дәвамында туган телне һәм милли мәдәниятне үзләштерә ала, монысы да бик мөһим.

Бу нисбәттән соңгы 10 елда Кытайда яшәүче татар балаларының Казанда югары белем алулары турында да әйтеп китү урынлы булыр. Бүгенге көндә 70 кеше Казанда укый, ә 10 елда аларның саны 120 гә җитте. Укып чыкканнарның кайберләре Татарстан белән Кытай арасындагы икътисади бәйләнешләрне булдыру эше белән шөгыльләнә, икенчеләре үзләре яшәгән шәһәрләрдә хезмәт куя, татар милли оешмаларына ярдәм итә. Бөтендөнья татар конгрессы әлеге проектны тормышка ашыруда актив катнаша, Татарстан хөкүмәте, Мәгариф һәм фән министрлыгы, югары уку йортлары белән тыгыз элемтәдә эшли.

Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең тагын бер мөһим юнәлеше – ул дин әһелләре белән тыгыз хезмәттәшлек. Танырга кирәк, бүгенге катлаулы дөньяда

милләтебезнең иң ышанычлы терәге булып Ислам дине тора, шигем юк, ул киләчәктә дә шулай булачак. Халкыбызның иң асыл сыйфатлары динебез аша тәрбияләнгән. Шуңа да Конгресс инде дистә еллар дини оешмалар белән уртак эшчәнлек кора. Һәр елны меңләгән дин әһелләренең Казанга җыелуы, аларның Болгар җыеннарында катнашулары милләтебезнең матур традициясенә әверелеп бара. Болар, бер яктан, дин әһелләренең бердәмлеген булдыруга хезмәт итсә, икенче яктан, аларның милли тормышта катнашуына ярдәм. Шушы нисбәттән Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан Диния нәзарәте һәм Русия ислам университеты белән даими рәвештә хезмәттәшлек итә. Бу хезмәттәшлек күркәм нәтиҗәләргә дә китерә. Күптән түгел Татарстан Диния нәзарәте үзенең киңәйтелгән пленумында республика мәчетләрендә җомга вәгазьләрен фәкать татар телендә уку таләбен кабул итте. Бу, һичшиксез, дин өлкәсендә туган телебезне саклау буенча җитди бер адым.

Халкыбыз алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе – ул татар авылларын саклау һәм яшәтү. Милләтебезнең чишмә башы – татар авылы. Анда милли мохит, туган телебез, динебез, халкыбызның гасырлардан килгән гореф-гадәтләре, традицияләре сакланган. Әмма бүген авыл тормышына кагылышлы борчулы мәсьәләләр дә байтак. Авыл картая, яшьләр шәһәргә күчү ягын карый, илдәге икътисади үзгәрешләр авыл хуҗалыгын яңа базар шартларына яраклашырга мәҗбүр итә. Ә бу һич тә җиңел эш түгел. Әмма илдә бик тә шәп хәлдәге татар авыллары бар, аларның даны бөтен Рәсәйгә тарала. Без шундый авылларны барлап, алар белән тыгыз элемтә урнаштырдык. Баксаң, ул авылларның уңышларында бер сер бар икән – күпчелек халык анда эшмәкәрлек кәсебен үзләштергән: кемдер теплицаларда яшелчә үстерә; кемдер мал асрый, ит-сөт җитештерә; кемдер шушы продукцияне эшкәртеп, кулланучыларга озата; кемдер сату эше белән шөгыльләнә. Шулай итеп, бу авыллар базар шартларына яраклашкан, табыш ала башлаган. Конгресс бу тәҗрибәне өйрәнеп, аны бөтен татар авылларына таратырга кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Шушы максаттан без 2012 елның язында I Бөтенрусия татар авыллары эшмәкәрләре җыены уздырдык. Ул шул хәтле уңышлы үтте ки, төрле төбәкләрдән һәм республика районнарыннан килгән эшмәкәрләр авылларына рухланып, канатланып кайтып киттеләр. Бу эштә безгә Татарстан хөкүмәте дә бик зур ярдәм күрсәтә. Әлеге зур проект бик үзенчәлекле башланып китте. 2010 елның җәендә Конгресс тырышлыгы белән Самара өлкәсенең Гали авылында I Бөтенрусия авыл Сабан туе уздырылды. Ул бәйрәмгә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Русия Хөкүмәте вице-премьеры Александр Жуков, Самара өлкәсе губернаторы Владимир Артяков килделәр. Алар Гали авылы тормышы белән якыннан таныштылар.

Гали авылының уңышларын күргәч, Президент Рөстәм Миңнеханов Татарстанның Авыл хуҗалыгы министрлыгына «Республика районнарында 1000 гаилә фермасын булдырырга» дигән күрсәтмә бирде. Бу проект инде тормышка ашырылды да.

Быел без VI Бөтенрусия авыл эшмәкәрләре җыенын уздырдык. Бу – иң уңышлы проектларыбызның берсе, авыл эшмәкәрләре әлеге чарада бик теләп катнаша.Уңышлы татар авыллары тәҗрибәсе шуны күрсәтә: бүгенге авыл эшмәкәрлеккә таянып кына яши ала. Әйтергә кирәк, андый татар авыллары саны Рәсәй җирлегендә аз түгел. Шунысы кызык: аларда тагын бер закончалык күзгә чалына: уңышлы авылларда дин көчле, халык күпсанлы мәчетләр тота, балалар гаиләдә тиешле әхлак тәрбиясе ала, эш сөючән булып үсә.

Гомумән, эш сөючәнлек – ул халкыбызның иң күркәм сыйфатларының берсе, татар кешесе гомер-гомергә үз көнен үзе күргән. Мөмкинлекләр чыккан саен, халкыбызда эшмәкәрләр катламы барлыкка килгән, алар тырышлыгы белән милли капитал тупланган һәм ул милләт үсешенә хезмәт иткән. Атаклы татар сәүдәгәрләре Хөсәеновлар, Рәмиевләр, Кәримовлар, Акчуриннар, Яушевлар һәм башкалар үз хисапларына мәчет-мәдрәсәләр, нәшрият-басмаханәләр тотканнар. Меңләгән китап, газета-журнал чыгарганнар. Шулай итеп, алар ярдәме белән татар халкы хаклы рәвештә Русия илендә иң укымышлы, мәдәниятле халык дигән абруй казанган.

Аяныч ки, совет чоры халкыбызның эшмәкәрләр катламын юкка чыгара, шуның белән милли үсешкә зур зыян сала. Әмма илдә икътисади үзгәрешләр башлангач, базар шартларында, татар халкының эшмәкәрләр катламы яңадан үсеп чыкты. Бүген

татар эшмәкәрләре милли тормышка нык ярдәм итә. Аларның матди булышлыгы белән Сабантуйлар, сәнгать фестивальләре, иҗади бәйгеләр уздырыла, туган телне өйрәнү буенча якшәмбе мәктәпләре эшли, мәчетләр салына, төрле басмалар нәшер ителә.

Халкыбыз тарихы бай, тирән тамырлы. Ата-бабаларыбыз шанлы дәүләтләр тоткан, дөнья тарихына, цивилизацияләр үсешенә лаеклы өлеш керткән. Татарстан дәүләтчелеге үсеше белән бәйле үзгәрешләр тарихыбызны өйрәнү өлкәсендә дә яңа мөмкинлекләр ачты. Татарстан Фәннәр академиясе каршында эшләп килүче Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты «Татар тарихы» дип аталган 7 томлы фундаменталь хезмәт бастырып чыгарды. Бу хезмәтне башкаруда бик күп Татарстан, Русия һәм чит ил галимнәре катнашты. Ул хезмәт киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде.

Әмма бу татар тарихы өлкәсендә барган эзләнүләрнең бер өлеше генә әле. Бүген меңләгән милләттәшләребез үзләре яшәгән төбәкләр, авыллар тарихын мавыгып өйрәнә, нәсел шәҗәрәләре өлкәсендә тирән эзләнүләр алып бара. Моның нәтиҗәсе буларак, татар авыллары һәм төбәкләре тарихына багышланган меңнән артык хезмәт басылып чыкты. Шулай итеп, соңгы елларда татар төбәк тарихчылары хәрәкәте барлыкка килде. Алар инде үзләренең III җыенын уздырды (бер тапкыр – Уфада, ике тапкыр – Казанда). Соңгысында төбәк тарихчылары илкүләм оешмаларын кордылар һәм шушы темага багышланган махсус журнал чыгарырга карар кылдылар.

Шунысын да әйтергә кирәк: Рәсәй киңлекләрендә татар тарихы белән бәйле ядкарьләр байтак. Аларның иң танылганнары: Алтын Урда дәүләтенең борынгы башкаласы Үкәк (хәзер Саратов өлкәсендә) һәм Себер ханлыгының башкаласы Искер, анысы Төмән өлкәсе аша уза торган Иртыш елгасы буенда. Бүген татар җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән әлеге тарихи урыннарда археологик эзләнүләр бара, алар тарихына багышланган фәнни конференцияләр уздырыла.

Төбәк тарихчылары хәрәкәте Бөтендөнья татар конгрессы канаты астында эшләп килә. Конгресс бу хәрәкәткә аеруча игътибар бирә, чөнки тарихны өйрәнү ул милли үзаңны булдыруда иң мөһим урынны алып тора.

***– Ринат әфәнде, Бөтендөнья татар конгрессының халыкара эшчәнлеге турында да әйтеп китсәгез иде. Татар диаспорасы нинди хәлдә?***

– Әйе, татар дөньясы ул Татарстан һәм Русия дәүләте белән генә чикләнми, безнең 2 миллион чамасы милләттәшебез дөньяның төрле илләрендә яшәп ята. Татар кешесе кайсы илдә генә яшәмәсен, ул тырышып эшли, күркәм сыйфатлар үрнәге булып тора, шуның белән абруй казана. Шул ук Финляндия татарларын гына алыйк, аларның үз илләрендә дәрәҗәләре бик югары. Берничә ел элек ул вакыттагы Финляндия Президенты Тарья Халлонен: «Без татарларыбыз белән горурланабыз», – дип әйтте. Гомумән, Финляндиянең һәр яңа сайланган Президенты андагы «Исламия» татар җәмгыяте белән танышуны үзенең бурычы итеп күрә. Җәмгыятьнең биш катлы бинасы Хельсинки уртасында урнашкан, анда мәчет бүлмәләре дә, тамаша залы да, уку класслары да, аш-су пешерү җайланмалары да – барысы да бар. Бирεдә төрле мәдәни чаралар, дини бәйрәмнәр, милләт әһелләре белән очрашулар уза. Ул гына да түгел, алар ел саен милләт балалары өчен табигать кочагында җәйге лагерьлар уздыра, анда башка илләрдән дә татар балалары килә. Финляндия татарларының үзешчән сәнгать осталары да, спорт командалары да бар, алар төрле ярышларда катнашып, җиңүләргә ирешә. Мәгълүм ки, Финляндия – Европа Берлеге әгъзасы. Шушы мөмкинлектән файдаланып, Финляндия татарлары туган телебезне Европа Берлеге милли азчылыклары телләре исемлегенә кертүгә ирештеләр. Бу – зур уңыш, чөнки Европа Берлеге милли азчылыкларның телләрен, мәдәниятләрен саклауга зур әһәмият бирә. Моның өчен махсус грантлар системасы эшләп килә, төрле проектлар тормышка ашырыла. Мисал өчен, Литва татарлары шушы проектлар нигезендә Европа Берлеге хисабына ике милли-мәдәни үзәк бинасы салуга иреште: берсе – Кырык татар авылында, икенчесе – Вильнюс янындагы Немежис бистәсендә.

Литва, Польша, Беларусь татарлары – халкыбызның бик үзенчәлекле өлеше ул. Аларның тарихы да бик кызыклы. Бу җирләргә татарларны алты гасыр элек Алтын

Урда дәүләтеннән Литва гаскәрләрендә хезмәт итәргә чакырганнар. Шул вакыттан Литва, Польша, Беларусь җирләрендә татарлар укмашып яши башлый. Аларның төп һөнәре хәрби хезмәт була. Татарларны батыр хезмәтләре өчен бигрәк тә Польша дәүләтендә хөрмәт итәләр. 2010 елда Польшаның Гданьск шәһәрендә атлы татар сугышчысына һәйкәл куйдылар. Аның ачылышында илнең ул вакыттагы Президенты Бронислав Комаровский да чыгыш ясады, бу – милләтебезгә бик зур хөрмәт һәм дәрәҗә.

Элек-электән татар халкы Төркия дәүләтен һәм аның халкын якын күрде. Тарихтан мәгълүм ки, узган гасырларда ук татар мөһаҗирләре Төркия дәүләтендә сыену урыны тапкан. Ул гына да түгел, күп кенә татар зыялылары Төркиянең күренекле дәүләт эшлеклеләре, фән, мәдәният, бизнес әһелләре булып киткән. Монда Йосыф Акчура, Садри Максуди, Әхмәтвәли Мәңгәр, Габделбарый Баттал, Әхмәт Тимер, Зәки Вәлиди һәм башка исемнәрне атап була. Бүгенге милләттәшләребез дә сынатмый, Әнкарада, Истанбулда һәм Искешәһәрдә татар мәдәнияте җәмгыятьләре эшләп килә. Ел саен бу шәһәрләрдә Сабантуй уздырыла. Әнкара татар мәдәнияте оешмасы турында аерым әйтәсем килә. Төркия башкаласында татар милли-мәдәни үзәге матур бинада. Ул бина урнашкан урам Габдулла Тукай исемен йөртә, һәм анда бөек татар шагыйренә һәйкәл дә куелган. Күптән түгел Әнкара татар мәдәнияте оешмасы үзенең 50 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Бик көчле татар җәмгыятьләре Америка Кушма Штатларында эшләп килә. Аларның берсе – Нью-Йорк каласында, икенчесе – Калифорния штатының Сан-Франциско шәһәрендә. Алар да даими рәвештә Сабантуйлар, дини бәйрәмнәр, уртак чаралар уздыралар. Калифорниягә килгән татарлар тарихы гаять кызыклы. Алар Сан-Франциско шәһәрендә тора башлагач, атаклы «Пан Америкэн» исемле авиация ширкәтенә эшкә урнашалар. Ике-өч ай узгач, боларны ширкәт җитәкчеләре чакыртып ала да мондый сорау бирә: «Сез нинди милләт кешеләре, кайдан килдегез?» Милләттәшләр «без – татарлар» дип җавап бирә. Шунда ширкәт җитәкчеләре: «Әгәр сезнең тагын башка татарларыгыз булса, аларны монда алып килегез, без андый кешеләрне бик теләп эшкә алыр идек», – дигән үтенечләрен җиткерә. Татар милләтенең абруе менә шулай тырыш хезмәт белән булдырыла.

Безнең бик көчле татар җәмгыяте Австралиянең Аделаида шәһәрендә эшләп килә. Нигездә, болар Кытай карамагында булган Шәркый Төркестаннан (Шенҗан-Уйгыр автоном районы) күченеп килгән мөһаҗирләр. Болар арасында бизнеста уңган кешеләр шактый. Алар буш урында башлап, татар мәхәлләсе абруен үзләренең тырыш хезмәтләре белән нык кына күтәрәләр. Бүген татар мәхәлләсенең мәчетләре дә, Мәдәният үзәге дә бар. Австралия татарлары Татарстан белән тыгыз бәйләнештә. Моннан кияүләр, кәләшләр табалар, гаилә коралар. Австралия дәүләтенә килеп урнашу шартлары бик кырыс, әмма татарларга биредә уңай карыйлар. Әйтик, Австралия карамагында булган Тасмания утравында урнашу мөмкинлеген мөселман халыклары арасыннан фәкать татарларга гына бирәләр.

Советлар Союзы таркалгач, татар халкының шактый өлеше Урта Азия һәм Казакъстан дәүләтләрендә яшәп калды. Анда якынча миллионнан артык милләттәшебез бар. Советлар заманында Үзбәкстанда 750 мең татар исәпләнә иде, минемчә, алар бүген дә элеккедән ким түгелдер. Безнең өчен Үзбәкстан татарларының милли тормышы, аларның Татарстан белән даими бәйләнешләре бик мөһим. Монда үзбәк халкының татарларга карата җылы мөнәсәбәте нык сизелә. Ә бу, һичшиксез, ике халыкның туганнарча дуслыгы, Үзбәкстан белән Татарстан арасында тыгыз һәм файдалы бәйләнешләр урнаштыруга хезмәт итә.

Казакъстанда да милләттәшләребезгә карата бик җылы мөнәсәбәт яшәп килә. Алар арасында танылган галимнәр, сәнгать, спорт осталары бар. Казакъстанда, аның һәр өлкәсендә дәүләт дәрәҗәсендә Сабантуй бәйрәмнәре уздырыла. Әле шушы көннәрдә генә Казакъстан башкаласы Астананың бер урамына Казан ханбикәсе Сөембикә исемен бирделәр. Шулай ук биредә Габдулла Тукайга һәм Муса Җәлилгә һәйкәлләр куелган. Кыскасы, Казакъстанда татар тормышы бик уңышлы бара һәм бу ике халыкның туганлык мөнәсәбәтләренә хезмәт итә.

Урта Азия дәүләтләре турында сүз чыккач, Кыргызстан һәм Таҗикстанда да татар җәмгыятьләре уңышлы гына эшләп килә, алар Татарстан һәм Конгресс белән тыгыз элемтәдә яши.


Бүген күп кенә Европа илләрендә яңа татар эмиграциясе барлыкка килде. Чикләр ачылгач, татар милләтеннән булган яшь белгечләр үзләренә кызыклы эш табалар, төрле илләрдә урнашалар. Алар бик көчле, белемле шәхесләр, араларында галимнәр дә, топ-менеджерлар да, банк хезмәткәрләре дә, сәнгать әһелләре дә бар. Шул ук вакытта алар бик милли җанлы инсаннар, бер-берсен табып, татар җәмгыятьләре оештыралар, төрле мәдәни чаралар уздыралар. Бүген Сабантуй бәйрәмнәре Европаның 20гә якын илендә уза. Европа тормышы бик үзенчәлекле, анда чикләр ачык, шуннан файдаланып, милләттәшләр бер-берсенә кунакка йөри, уртак мәдәни чаралар уздыра. Тора-бара мондый хезмәттәшлек яңа нәтиҗәләргә китерде. 2014 елда Европа Берлегендәге дәүләтләрдә яшәүче милләттәшләр, Бельгия башкаласы Брюссельда җыелып, «Европа татарлары альянсы» дип аталган яңа оешма кордылар. Моның оештыру җыелышы Европа парламенты бинасында узды һәм оешма Бельгия Юстиция министрлыгы тарафыннан теркәлде. Оешма шунда ук актив эшли башлады, әйтик, быелтыр алар Европа Берлегендә «Милли азчылыклар елын» уздыру тәкъдиме белән чыктылар. Һәм Европа Берлеге җитәкчелеге бу тәкъдимне кабул итте, киләсе 2018 ел «Милли азчылыклар елы» дип игълан ителде. Гомумән, «Европа татарлары альянсы»н булдыру – ул гомуммилли хәрәкәтнең зур уңышы. Монда да милләттәшләребезгә зур мөмкинлекләр ачыла.

Кайберәүләрдән «Конгресс нишләп чит илләрдәге татарларга шулхәтле игътибар бирә соң?» дигән сорау да ишетергә туры килә. Минемчә, бу сәясәтне, милләт мәнфәгатьләрен аңламаудан килә. Илнең бер халкында да (урыслардан кала) татарныкы кебек зур, көчле диаспора юк. Дөресен әйткәндә, мондый күренеш дөньяда татар факторы барлыкны раслый. Ә бу инде Татарстанга да зур мөмкинлекләр ача. Илнең бер генә төбәге дә халыкара мәйданда җөмһүриятебез кебек киң колачлы эшчәнлек алып бармый, дөресен әйткәндә, аларның мондый ихтыяҗлары да юк. Ә Татарстанның һәм татар халкының мондый ихтыяҗларын федераль хакимият тә таный. Күреп торабыз, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кая гына барса да, андагы татар җәмәгатьчелеге белән очраша, милләттәшләрнең тормышы белән кызыксына. Игътибар итсәгез, ул очрашуларда Русия илчеләре һәм югары кимәлдәге дипломатлар катнаша.

Президентның милләттәшләр белән очрашулары бик кызыклы һәм эчтәлекле үтә. Монда яшь буын татар эмиграциясе турында сүз чыккан иде инде. Былтыр Канадада бик кызыклы очрашулар булды. Биредә Монреаль һәм Торонто шәһәрләрендә татар җәмгыятьләре эшли. Татарстан Президентының Торонто каласына килүе турында ишеткәч, бик күп милләттәшләр бөтен Канададан әлеге шәһәргә җыелганнар иде. Бу очрашу шыгрым тулы залда узды, Президент белән очрашуга яшь гаиләләр балаларын җитәкләп килгәннәр, ә алар матур итеп татарча сөйләшә. Бу бит Татарстанга, аның Президентына теләктәшлек белдерү. Очрашуда Русия илчесе дә катнашты, әлбәттә инде, бу хакта мәгълүмат федераль хакимияткә дә ирештерелә, монысы да татар факторын күрсәтә. Минемчә, бүгенге катлаулы шартларда Русия җитәкчелеге дә Татарстанга халыкара мәйданда хәрәкәт итәргә мөмкинлекләр ача, чөнки республиканың төрле илләр белән икътисади хезмәттәшлеге, һичшиксез, илнең үсешенә ярдәм итә.

Бөтендөнья татар конгрессының 25 еллык дәверендәге төп казанышы – ул татар халкының бердәм милләт булып яши башлавы. XXI гасырга без көчле милләт булып, ныклы адымнар белән кердек. Татар халкы тормышында яңа чор башланды, ул яңа технологияләр, компьютерлар, интернет челтәре белән бәйле. Бу яңарыш чоры туган телебезне саклауга һәм үстерүгә яңа мөмкинлекләр ача. Һәр татар кешесе әлеге мөмкинлекләрдән файдаланырга әзер булырга тиеш. Без бергә, бердәм милләт булып, киләчәккә атлыйбыз. Юлыбыз уңышлы булсын!

*Әңгәмәдәш* – **Илфак ИБРАҺИМОВ.**



Фәүзия
Бәйрәмова

# ҺИҖРӘТ

ТАРИХИ РОМАН

**«Йә – китәбез, йә – үләбез!»**

Мөхәммәтҗан карт ничә көннәр буе җанына урын таба алмый, әле карурманнарга чыгып китә, әле күл буена барып утыра, әле атын җигеп, Тарага юл ала... Кая барса да, күңелендә, телендә бер сүз – «һиҗрәт», илдән китү, дин-ислам хакына туган яклар белән мәңгегә бәхилләшү. Электән мулла кеше буларак, иманга куркыныч янаганда, һиҗрәтнең мәҗбүрият икәнлеген ул белә, әмма шушында тамыр җибәргән, нигез корган, гаилә тоткан ир-ат буларак, аның тота-каба гына кубарылып чыгып китәсе дә килми. Олыгайган көндә анда аларны ни көтә, газеталардан күренгәнчә, Төркиянең үзендә дә әллә ниләр булып ята, яшьләр хакимиятне дер селкетә, ирек даулыйлар. Дөрес, анда мөселманнарга дин тотарга ирек бар, әмма заманалар үзгәреп, аларда да Рәсәй илендәге кебек булмасмы – монысын беркем дә әйтә алмый...

Мөхәммәтҗан картның бөтен туганнары һиҗрәткә әзерләнә, инде сатыласы маллар очсыз бәягә сатылган, анда баргач яшәп китәргә бераз мая тупланган, кешеләрдә сәфәр дәрте, юл мәшәкате... Аларны инде бер нәрсә белән дә үгетләп, ниятләреннән кире кайтарып булмый. Мөхәммәтҗан картны иң борчыганы – тумыштан телсез-чукрак кызы Хөснибикәнең дә, иренә ияреп, күз күрмәгән җирләргә чыгып китәргә җыенуы. Җитмәсә, авырлы да. Яшьтән анадан ятим калган, әле үзе дә балалыктан чыгып җитмәгән бу бичаракай ул чит-ят җирләрдә газап чикмәсме, ким-хур булып йөрмәсме – ата кешенең йөрәген менә шул уйлар да телгәли... Шул ук вакытта үзе дә алар белән ерак юлга кузгалырга җыенмый, әниләре баладан үлеп киткәч, итәк тулы ятим белән калды, хәзер шуларны кеше итәсе, аякка бастырасы бар. Монда ул һәр куакны, һәр агачны, һәр кошны, һәр җанварны белә, үзе исән чагында балаларын ач итмәсен дә белә, ә менә чит-ят илдә аны нәрсә көтеп тора – әйтә алмый...

Менә бүген дә ул, Тулпар атын җигеп, өяз каласы Тарага юл алды. Анда качып кына Габдрәшит хаҗи кайткан, дигән сүзләр йөри, Мөхәммәтҗан карт аның белән очрашырга дип махсус бара. Габдрәшит хаҗи – тирә-юньдә иң күренекле, иң укымышлы кеше, иң гайрәтле, туры сүзле хәзрәт. Атасы ягыннан

---

Фәүзия БӘЙРӘМОВА – *язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе; Гаяз Исхакый һәм Һади Атласи исемендәге премияләр лауреаты. «Кырык сырт», «Күчем хан», «Соңгы туранчы» һ.б. иллегә якын китап авторы. Чаллы шәһәрендә яши.*

– җиде буын ахуннар, дин әһелләре, бохаралы, анасы ягыннан – гайрәтле мишәр һәм себер татарлары токымыннан. Яшьтән ятим калып, Аллаһ ярдәме белән Мәккә-Мәдинәләрдә белем алган, Коръәнне яттан белгән, Тара мәчетендә имам булган, мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, хәтта ки бөтен Рәсәй мөселманнарының казые булган абруйлы кеше! Халык аны хөрмәт итә, сүзенә ышана, ул әйткәнне эшли иде. Һәм шушы кеше, туган якларына кайтып, авылдан-авылга йөреп, халыкка дөнья хәлләрен сөйли башлады, Рәсәйне бик куркыныч чорлар көткәнен аңлатты, мәчетләр ябылачак, манаралар киселәчәк, муллалар атып үтереләчәк, дин бетереләчәк, диде. Халык телсез калды, болай да гасырлар буе бу илдә җәһәннәм газаплары күргән татарларны инде милләт буларак, инде мөселман буларак юкка чыгу көтә иде. Исән калу өчен бары бер генә юл бар, ул – бу Аллаһ каргаган илдән китү, дин-ислам хакына һиҗрәт кылу иде...

Югыйсә, алар заманында бу җирләргә ислам динен тарату, дәгъват кылу өчен килгәннәр иде бит! Себердә яшәп яткан җирле халыкларның ислам диненнән шактый ерак торуларын ишетеп, бирегә әле хан заманнарында ук Бохара якларыннан күренекле дин әһелләре – сәедләр һәм шәехләр, укымышлы галимнәр килде. Дөрес, себер татарларының бер өлеше инде бик борынгы чорлардан – Багдад хәлифәте заманнарыннан, соңрак Үзбәк хан вакытларыннан ук ислам динен кабул иткән булганнар, әмма мәҗүсилектә калганнары да бар икән. Һәм гасырлар буе, бигрәк тә Күчем хан заманнарында Себердә ислам динен тарату өчен Бохара тарафларыннан дәгъватчы-миссионерлар килеп торды, Мөхәммәтҗан картның нәсел башы да шуннан. Картларның сөйләүләре буенча, алар бераз соңрак килгән, Әвәсбакы шәехнең Фәйзи шык, Алим шык, Ашкы шык, Баба шык улларыннан киткән зур нәсел ул, шуңа күрә, Тарадан башлап, шушы Яланкүл, Аубаткан, Үләнкүл, Рәчәп авылларының яртысы – Шиховлар фамилиясен йөртә. Мөхәммәтҗан картның үзенең дә фамилиясе Шихов, ә авыл халкы аларны йә шыклар дип, йә бохарилар дип атый. Шыклар – шәехләр дигәнне, ә бохари-бохаралы – Бохара тарафыннан килүчеләр дигәнне аңлата.

Ә Бохара тарафыннан, дине бер булса да, милләте буенча төрле кешеләр килгән – монда Алтын Урданың затлы татарлары да, зәңгәр күзле, ак йөзле таҗиклар да, кап-кара Африка мөселманнары – гарәпләр дә, халык телендә сартлар дип йөртелгән үзбәкләр дә булган. Соңрак алар барысы да бер исем – бохаралы дип йөртелә башлаган, дистә меңнәрчә себер татарлары арасында таралып, алар белән аралашып-кушылып яшәп киткәннәр, әмма беркайчан да үзләренең кемлекләрен онытмаганнар. Мөхәммәтҗан карт та җиде буынны гына түгел, кырык буын бабаларын белә, аларның бу дөньяга кайлардан таралганын да яхшы белә. Анда кәҗә тиресенә гарәпчә язылган, уклауга чорналган мең еллык нәсел шәҗәрәсе саклана, һәм ул Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташа.

Әйе, Мөхәммәтҗанның атасы – Мөхәммәтрәхим, аның атасы – Сөецбакы, аның атасы – Мөхәммәтрәхим, аның атасы – Мырза шык, аның атасы – Фәйзи шык, ә ул – Әвәсбакының улы, бу – кырыгынчы буын. Ә нәсел башы Мөхәммәд галәйһиссәламнең кызы Фатыйма һәм аның балаларыннан китә, шәҗәрәгә шулай дип язылган. Шуңа күрә, нинди авыр елларда да, алар пәйгамбәр нәселе дәвамчылары булуларын онытмадылар, ислам хакына шушы җиргә ябышып яттылар, Себернең кара урманнарын ислам нуры белән нурландырдылар. Һәм нинди авыр вакытларда да, аерым кешеләр китсә дә, алар ил белән кубарылып һиҗрәткә китү турында уйламадылар, үзләрен Ходай тарафыннан шушы җирләргә ислам таратырга җибәрелгән илчеләр дип аңладылар, шушы фикергә гомер буе тугры булып калдылар. Һәм менә өммәт алдына, милләт алдына, бөтен җитдилеге белән, котылгысызлыгы белән һиҗрәт мәсьәләсе килеп басты...

Әйе, бу һиҗрәт дигәннәре авылларны гына түгел, гаиләләрне дә икегә бүлде

– берәүләр «йә – китәбез, йә – үләбез», диделәр, икенчеләр аларны кузгалмаска үгетләде, мондагы тормышның да уңай якларын табарга тырыштылар. Ике якта да хаклык бар иде. Һиҗрәт турында сүз, дин-ислам хакына Госманлы иленә – Төркиягә күчеп китү мәсьәләсе Идел-Уралда гына түгел, Себердә дә күтәрелеп-күтәрелеп ала, илдәге хәлләргә карап, халыкның да кәефе үзгәреп тора. Себер татар авылларында дин Казан якларындагы кебек көчле булмаса да, монда да иман хакына җир читенә китәргә әзер торучылар бар, бигрәк тә бохаралы дип йөртелгән аксөяк нәселләр нык торалар иде. Дөрес, моңа кадәр патша хакимияте аларга артык каты кагылмады, аз санлы катлам, дип, бохаралылардан хәтта гаскәргә дә алмадылар, укымышлы бу татарлар җирле халык белән түрәләр арасында арадашчы булып торды. Әмма заманалар үзгәрә, ханнар вакытында ук Себергә ислам динен таратырга килгән бохаралы мөселманнарның да баш очында кара болытлар куера, ил өстенә шомлы афәт киләсен алар җаннары-тәннәре белән тоялар иде...

«Һиҗрәт», «һиҗрәт», дисәләр дә, дин-ислам хакына бөтен нәселең, хәтта ки авылың белән кубарылып, туып-үскән җирләреңне мәңгегә калдырып, бер белмәгән якларга чыгып китәргә күпләр әзер түгел иде. Шуңа күрә бу мәсьәлә сузылды, сүз куерды, бергәләп китә алмагач, кайберәүләр аерым-аерым да һиҗрәткә дип Төркиягә чыгып киттеләр, әмма төп халык һаман нидер көтте, өмет итте. Китик, диючеләр дә, калыйк, диючеләр дә ул арада тәмам шомарып, чарланып беттеләр, ике яктан да берсеннән-берсе дәһшәтле дәлилләр китерелде, гади халык тәмам гаҗиз булды. Әмма соңгы елларда Рәсәйдә барган шомлы үзгәрешләр, мөселманнарны эзәрлекләүләр, кулга алулар, төрмәләргә утыртулар һиҗрәт яклыларны көчәйтте. «Монда калсак, безне дә шушы хәл көтә», дип, алар авылдан-авылга йөреп, мәчет-мәдрәсәләрдә чыгышлар ясадылар. Өяз башкаласы Тарада исә һиҗрәткә кузгалырга теләүче себер татарларының исемлекләре төзелде, патшага прошение-гаризалар язылды, инде юл хәстәрләре күрелә башлады.

Халыкның ашыга-ашыга туган җирләрен ташлап китәргә җыенуының төп сәбәбе булып чукындыру куркынычы тора иде. Себер урыслар тарафыннан яулап алынганнан бирле, менә инде берничә гасыр буе, җирле халыкларны көчләп чукындырулар беркайчан да туктап тормады. Биредә әлмисактан бирле яшәгән иштәк-остяк-вогуллар, себер татарлары, кыргыз-кайсаклар авылы-авылы белән дә, аерым-аерым да чиркәүләргә куып кертелде, чукынырга теләмәгәннәр төрмәләргә, монастырьларга ябылды, мәңгегә каторгага сөрелде. Көчләп чукындырылган җирле халыкның бер өлеше әкренләп урыска әйләнде, берничә буында үзенең асыл телен дә, изге динен дә, кемлеген дә онытты, әмма каракучкыл йөзләре, кысык күзләре аларның урыс түгеллеген кычкырып тора иде. Һәр патша килгән саен үз тәртибен кертте, чукындыру да бер көчәеп, бер йомшарып торды, әмма беркайчан да ахыргача туктамады.

Башка җирле халыкларны урыс диненә куып кертү тизрәк барса да, попларга себер татарлары белән шактый озак изаланырга туры килде. Алар арасына асылташлар булып сибелгән бохаралылар һәм казан татарлары дин-ислам өчен үләргә дә әзер иделәр, алар бу иманны себер татарларына да кертә алдылар. Шуңа күрә урыс поплары чукындырып киткәннән соң да, себер татарларының бер өлеше барыбер качып кына ислам динен тотты, түрендә икона булса, сандыгында Коръәне ятты, муенында мәҗбүриләп асылган калай тәре булса да, күлмәк изүендә изге сүрәләр язылган бөтие яшерелгән иде. Әмма бу хәл ачылган очракта аларны төрмә көтә, хәтта каторгага сөргән очраклар да була. Урыс поплары бигрәк тә унсигезенче гасыр башларында нык котыра, башкисәр Ермак һәм Явыз Иван чукындырып бетерә алмаган себер татарларын ят дингә күндерүне Пётр патша һәм аның патшабикә кызлары, христиан дине әһелләре, архимандритлар, митрополитлар дәвам итә. Губерна һәм епархия үзәге булган

Тубылда чиркәү суды оештырыла, анда менә шушы «яшерен мөселманнар«га җәза бирү белән шөгыльләнәләр, шул рәвешле, йөзләрчә, хәтта меңнәрчә себер татарын яңадан исламга кайткан өчен җәзалыйлар. Урыс дин әһелләре һәм хәрбиләре, патша хакимияте белән берләшеп, чукынырга теләмәгән татарларны тереләй утларда яндырудан башлап, мәңгелек сөргеннәргә хәтле сөрәләр, аларның затлы нәселләрен юк итәләр... Себердәге барлык мәчетләр дә диярлек ут төртеп яндырыла, мәктәп-мәдрәсәләр җимертелә, чукынмаган татарлар үз авылларыннан куыла, исән калганнары чукынган милләттәшләре өчен дә салым түли, рекрут бирә башлыйлар.

Бу коточкыч хәлләрне Тарада, Иртыш-Ишим буендагы татар авылларында да яхшы хәтерлиләр, чөнки ул хәлләр аларның туганнары, якыннары белән дә булды бит! Шуңа күрә, тагы чукындыру сүзе чыга икән, аңа җавап итеп, һиҗрәткә чакыру яңгырады, милләт фаҗигасенә тиң Гөлбостан авылы тарихы сөйләнде. Ул авыл Иртыш елгасы буенда, Ишим тамагында урнашкан, бик борынгы, хан заманнарыннан калган сала, дөресрәге, элеккеге кала була. Хәзер аның урынында «Керәшен кыры» дип аталган бушлык, тоташ каберлекләр... Гөлбостан халкы борын-борыннан үзенең затлылыгы, шыклар-шәехләр нәселеннән укымышлы бохаралылар яшәве белән аерылып торган, төп халкы исә саргат кабиләсеннән себер татарлары булган.

Алар Ермакка каршы да арыслан кебек сугышалар, бирелмиләр, патша гаскәрләре дә аларны тиз генә буйсындыра алмый, ә менә урыс поплары шушы борынгы ханнар авылының башына җитә. Чукындыруга алар тиз генә бирешмиләр, тәре күтәреп килгән урыс попларының да кайберләрен алдалап, кайберләрен куркытып, кайберләрен сатып алып кире боралар. Әмма алар тирәсендәге тимер кыршау кысылганнан-кысыла бара, бу тирәдә алардан башка чукынмаган татар авылы калмый, инде чират Гөлбостанга да җитә. Башта авылның аксакалларын, шәех-муллаларын урлап, Тубыл төрмәсенә ябып, канга батырып кыйныйлар, аларга нахак ялалар ягалар, христиан динен кабул итмәсәләр, үлем белән яныйлар. Нәтиҗәдә, бу аксакалларның бер өлеше төрмәдә юкка чыга, бер өлеше, муеннарына тәре асып, авылга әйләнеп кайта. Нәфрәт белән үзләренең йөзләренә төкергән авылдашларына алар болай ди: «Без җанны саклап калу өчен тәреләрен астык, чөнки Коръәндә дә гомерне саклап калу өчен динеңне яшерергә мөмкин, диелгән. Әмма без күңелебез белән барыбер мөселман булып калдык, тормышыбызда да мөселманлыкны алып барырбыз. Урыс поплары авылга килгәндә, аларча булырбыз, алар киткәч, үзебезчә – татарча-мөселманча яшәрбез». Һәм шулай яши башлыйлар да – поплар Гөлбостанга килгәндә – икона һәм тәре, алар китү белән – намазлык һәм түбәтәй... Әмма бу уен озакка бармый, поплар килеп, авылның чукынган һәм чукынмаганнарын аера башлыйлар, имеш, пакь христианнар «поганый басурманнар» белән бергә яшәргә тиеш түгел икән, димәк, мөселман-татарлар туган авылларын ташлап китәргә тиеш булалар. Гөлбостанда мәчет тә тыела, тиз арада чиркәү салып куялар, Казан ягыннан килгән керәшен татарын анда поп итеп билгелиләр. Ә ул һәр кешене күзәтеп, теркәп, билгеләп бара, чиркәүгә йөрүләр, бала тугач, чукындыру һәм язып куюлар, кеше үлгәч, аны христиан гадәте буенча күмүләр аның өстендә була. Шушыларны аз гына бозсаң да, авылга атлы казаклар килеп җитә, тагы яткырып суктырулар, тагы судлар, тагы төрмәләр...

Шушы куылулардан, эзәрлекләүләрдән, суд һәм төрмәләрдән тәмам алҗыган, бу хәлдән һичнинди чыгу юлы тапмаган себер татарлары аянычлы язмышлары белән килешә башлыйлар. Кемнәрдер – авылын ташлап сукбайга әйләнмәс өчен, кемнәрдер – калган гомерен төрмәдә уздырмас өчен ыңгырашып булса да поп әйткәннәр белән ризалаша... Дөрес, караңгы төннәрдә авылдан чыгып качып, кара

урманнар, төпсез сазлыклар аша кыпчак далаларына барып җитүчеләр, аның аша Бохарага юл тотучылар да була. Хәтта дин-ислам хакына Төркия, гарәп илләренә һиҗрәт кылучылар булганын да әйтәләр, әмма бөтен халык ул юлга баса алмый, күпләр туган авылларында кала һәм яшәр өчен чукынырга мәҗбүр була. Әмма патша хакимияте аларны чукынгач та тынычлыкта калдырмый – бу татарлар яшереп үз диннәрен тотып ятмасыннар өчен, яңа фәрманын чыгара. Бу фәрман буенча, чукынган җирле халык вәкилләре үз милләттәшләре белән гаилә кормаска, бары тик православ урыслар белән генә өйләнешергә, кияүгә чыгарга тиеш булалар. Моның белән патша хакимияте берничә мәкерле максатын тормышка ашыра – җирле халыкларны, шул исәптән, себер татарларын да ана теле мохитеннән аера, аларның берничә буында урыска әйләнүенә юл ача. Икенчедән, элеккечә качып үз диннәрен тотуга, исламча яшәүгә барлык юлларны да яба. Шушы хәбәрләрне алгач, Гөлбостанның мәҗбүри чукынган татарлары катгый карарга киләләр – моннан соң беркемгә дә кияүгә чыкмаска һәм өйләнмәскә!

«Без гомеребезне саклап калу өчен кяфер динен алырга мәҗбүр булдык, үлем куркынычы астында муеныбызга тәре астык. Моның өчен Аллаһтан көне-төне кичерү сорыйбыз, без күңелләребез белән барыбер мөселман булып калдык... Инде бездән соң килгән буыннар боларны онытыр, урыслар белән гаилә корып яшәп, урыска әйләнер, кяфер булыр... Шуңа күрә, үзебездән кяфер нәсел калдырмас өчен, васыять итеп әйтәбез – ир балаларыбыз беркайчан да өйләнмәсен, кыз балаларыбыз беркайчан да кияүгә чыкмасын! Бу – безнең аманәт, васыятебез, соңгы догабыз...»

Һәм шулай була да – Гөлбостан авылы егетләре өйләнми, кызлары кияүгә чыкмый картая, үзләреннән кяфер нәсел калдырмыйча, әлеге авыл халкы әкренләп зиратка күчеп бетә... Хәзер ул урын «Керәшен кыры» дип атала... Әлбәттә, бу хәбәр бөтен Себергә тарала, татарлар аны елый-елый тыңлыйлар, башкаларга да тараталар. Халык инде соңгы чиккә килеп җиткәч, мәчетләр беткәч, мөселманнарга кара урманнарда да урын калмагач, бохаралы Алим Шихов исемле кешене Петербургка, патшабикәнең үзе янына җибәрәләр. Пәһлеван кыяфәтле, тавышыннан диварлар дерелдәгән, аяк атлавыннан идәннәр сыгылып торган Алим шыкны патшабикә Елизавета Петровна кабул итә. Үз каршында баһадир кыяфәтле, башы түшәмгә тигән, өстенә затлы киемнәр кигән татар ир-атын күргәч, ул, шаяртган булып:

– Сездә, Сибириядә, бөтен татарлар да шушындый богатырь-баһадирмы? – дип сораган.

Алим шык та югалып калмаган, мыек астыннан гына елмаеп:

– Әйе, нәкъ шулай, патшабикә галиҗәнапләре, татарлар барысы да шундый, әмма мин алар арасында әле иң бәләкәе, – дип җавап биргән.

Әлбәттә, Алим шәехнең төп сүзе себер татарларының аянычлы язмышы турында булган, һәм төп таләбе – динебезгә тимәскә, халыкны салымнар белән бумаска, татар җирләренә урысларны күчереп утыртмаска! Әлбәттә, бу таләпләрнең барысы да үтәлмәгәндер, әмма патша хакимияте дә вакыты-вакыты белән татар бугазыннан кулын ычкындырып торган, чөнки җирдә эшләргә дә кеше кирәк булган.

Инде бу шомлы көннәр тәмам артта калды, заманалар үзгәрде, чукындырулар да яңадан әйләнеп кайтмас, дип торганда гына, дөньялар тагы болгана башлый, Себер өстенә тагы чукындыру шомлыгы тарала... Бу инде егерменче гасырның башлары була... Көтмәгәндә, Тубылда яңа чукындыру үзәге ачып куялар, аны «Противомусульманская миссия» дип атыйлар, ягъни, ул турыдан-туры мөселманнарга каршы эшләргә тиеш була. 1900 елның 15 февралендә Синод указы белән ачылган бу карагруһ оешма, бөтен Себергә, бигрәк тә, ислам диненә ябышып яткан татар авылларына таралып, халык арасында христиан динен «кодалый» башлыйлар. Әлеге мәкерле гамәлләренә алар бик нык әзерлек белән

тотыналар – башта себер татарлары өчен аларның үз телләрендә сүзлекләр һәм китаплар чыгаралар, аларны язуда һәм таратуда Казаннан махсус җибәрелгән керәшен татарлары нык булыша. Бу китапларның барысы да диярлек ислам динен түбәнәйтүгә, христиан динен күтәрүгә юнәлтелгән була. Миссионерлар турыдан-туры Коръәнгә мөрәҗәгать итеп, аның сүзләрен-аятьләрен бозып, халыкка изге китапны үзләренчә аңлата башлыйлар. Шулай ук себертатар телендә Мөхәммәд пәйгамбәрне хурлаган китаплар да дөнья күрә. Ефрем Елисеев исемле поп-миссионер, керәшен татары, мөселманнарга каршы көрәштә бөтен игътибарын мәктәп-мәдрәсәләргә юнәлдерә, аларда бары тик урысча укытып һәм христиан дине дәресләре кертеп кенә татарларны җиңәргә мөмкин, дигән нәтиҗә ясый.

Патша хөкүмәте моны тиз ишетеп ала... Һәм патша хөкүмәте шушы юнәлештә чаралар да күрә башлый. Гасырлар буе барган көчләп чукындырудан соң әле яңа аякка басып килгән татар милләтен мәктәп-мәдрәсәләре аша кабат чукындырырга уйлый. 1905 елның маенда империя хөкүмәте әлеге мәсьәлә буенча махсус киңәшмә җыя, анда татар әлифбасын урысныкына алыштыру, мәктәп-мәдрәсәләрдә мәҗбүри урыс телен кертү, балаларны урыс рухында тәрбияләү мәсьәләләре карала. Бер елдан, ягъни 1906 елның мартында бу кагыйдәләр аерым җыентык булып басылып чыга һәм аларны үтәү мәҗбүри булып тора. Милләт моңа каршы күтәрелә, бу хәлләрне яңа чукындыру, дип атый, хакимият исә каршы чыккан татарларны җәзалау юлына баса. Милләтнең күренекле уллары тагы төрмәләргә ябыла, алар чыгарган газеталар ябыла, мәктәп-мәдрәсәләренә йозак салына...

### «Чират безгә дә килеп җитте...»

Бу хәлләр ерак Себергә дә килеп җитә...

Мәчет-мәдрәсәләрдә тентүләр уздырыла, алардан йөге-йөге белән дини китаплар алып чыгыла, мулла-мөгаллимнәрне берәм-берәм Тара һәм Тубыл төрмәләренә ябып куюлар башлана. Бу хәлләргә ризасызлык күрсәтүчеләрнең үзләрен күзәтү астына алалар, калага алып китеп, полициягә ябып куярга да күп сорамыйлар. Патшаның дин иреге турындагы фәрманыннан соң бераз тынычланган халыкның йөрәгенә тагы шом керә, ул арада Тарадан да берсеннән-берсе куркыныч хәбәрләр килеп ишетелә. Имеш, себер татарларының иң күренекле кешесе Габдрәшит хәзрәтне Петербургта кулга алганнар икән, газеталарын суд белән япканнар, үзен крепостька бикләп куйганнар ди. Югыйсә, ул бу көннәр киләсен халыкка әллә кайчан аңлаткан иде, кайткан-киткән саен себер татарларын мәчетләргә җыеп, бу илдә мөселманнарга беркайчан да ирек булмаячагын сөйләгән иде бит! Һиҗрәт мәсьәләсен дә бу якларда беренче булып ул күтәрде, иманны саклап калу өчен исламга ирек булган урынга күчеп китәргә кирәк, диде. Бөтен дөньяны әйләнеп чыкканнан соң, якташлары өчен иң кулай андый урын дип Төркияне тапты, хәтта аның патшасы белән дә сөйләшеп-килешеп кайткан, диделәр.

Мөхәммәтҗан карт үзе дә хәтерли әле аның Аубаткан, Яланкүл авылларына килеп, мәчет-мәдрәсәләрдә халык белән очрашып йөрүләрен. Бу төбәктә генә түгел, бөтен Себерендә Габдрәшит хаҗи кебек гыйлем иясе юктыр, мөгаен, ә аның сөйләү, ышандыру көче турында инде әйтеп тә торасы юк. Аның белән бер тапкыр очрашкан һәм чыгышын тыңлаган кеше алга таба инде Габдрәшит хаҗиның тарафдары булып китә, аның сүзеннән чыкмый. Ул Мөхәммәтҗан карттан бераз яшьрәк, әмма зур гыйлеме, халык арасында абруе, сүз һәм гамәленең бер булуы аны барысыннан да олы һәм өстен куя. Һәм ышандыра, һәм үз артыннан алып китә...

Һиҗрәт белән дә шулай булды – ни авыр елларда да авылга ябышып яткан себер татарлары, бохарилар Габдрәшит хаҗины тыңлагач, алыштырып куйган кебек булдылар, әйтерсең лә аларның өченче яшерен күзләре ачылды. Алар үзләренең тормышларына, узган тарихларына бөтенләй башкача карый башладылар. Ул көчләп чукындыру хурлыклары, ул атлы казакларның авылларга атылып кереп, буйсынмаган халыкны яткырып камчы белән ярулары, кулаякларга богау салып, сөргенгә сөрелүләр... Милләт, яраларын ялап, кара урманнарга кереп качты, төпсез сазлыкларга барып сыенды, адәм баласы яши алмаслык урыннарда тормыш итә башлады... Габдрәшит хаҗи менә шуларның барысын да яңадан милләтнең исенә төшерде, бүген дә аларның хокуксыз хәлдә яшәүләрен әйтте, алда исә тагы да куркыныч хәлләр көткәнен кисәтте.

– Бу илдә иң хокуксыз халык без, ягъни, мөселманнар, татарлар, – дип сөйләгән иде ул. – Ни дин-ислам ягыннан, ни милли нисбәттә безгә урыслар белән тигез хокуклар каралмаган, киресенчә, һәрдаим түбәнсетү, һәрдаим кимсетү һәм читкә этәрү бара... Бу илдә урысча имтихан бирмәсәң, муллалыкка указ да ала алмыйсың. Алга таба барлык халыкка шул таләп куелачак, моның өчен инде менә ничә еллар мәктәп-мәдрәсәләребездә урысча укытырга күчәргә мәҗбүр итәләр. Без хәзергә бирешмибез, әмма андый әмерләре бар. Изге Коръән хәрефләрен урысныкына алыштырып, укытуны алар теленә күчерсәк, тора-бара милләт тә шул кавемгә әйләнәчәк бит, Аллаһ сакласын! Алар артында – дәүләт, жандармерия, атлы казаклар, гаскәр, инде ниһаять, тәре аскан поплары тора... Безнең артта – бөек тарихыбыз һәм үз дәүләтебезне югалту сәбәпле, шушындый аянычлы хәлгә төшкән бәхетсез милләтебез тора... Эшләр болай барса, алда безне милләт буларак бетү, юкка чыгу көтә... Нишлик, туганнар?

Яланкүл мәчетенә җыелган ир-атлар тынсыз калды, авыр эштән изелеп, әле аларның беркайчан да болай төбенә төшеп уйланганнары, мондый катлаулы сорауларга җавап эзләгәннәре юк иде. Әле ул вакытта Хөҗҗәт мулла да авылда иде, Габдрәшит хәзрәткә ул җавап бирергә җөрьәт итте:

– Хәзрәт, – дип башлады ул салмак кына. – Авылда яшәсәк тә, без сез язганнарны укып барабыз, чыгарган матбагагызны Тарага да барып алабыз, бу тирәдә алдыручылар да бар... Ил белән шушы хәл икәнен дә беләбез, әмма дә ләкин безнең хәлебез – Себер мөселманнарының хәле аерата авыр, без беткәнче урыс арасында яшибез... Бөтен тирә-якта урыс авыллары, анда дуңгызы, хәмере, хәрамы – барысы да бар. Попларның әрсезлеге турында инде әйтеп тә тормыйм – тәреләрен күтәреп, өйдән-өйгә йөриләр, әллә нәрсәләр вәгъдә итәләр, динебезне сүгәләр, пычраталар... Аз гына каршы әйтсәң, артларыннан бастырып атлы казаклары килеп җитә, юк кына нәрсәләргә бәйләнеп, ир-атларыбызны Тара төрмәсенә алып барып ябалар, анда аларны куркытып һәм янап, тагы эшкәртәләр... Шул төрмәләрдән муеннарына тәре асып кайтучылар да күренә башлады, нишләсен, мәңгегә кәтер китмәс өчен чукынырсың да! Әстәгъфируллаһ! Аның авырлыкларына түзәрсең, менә шул чукындыру куркынычы һаман өстебездә тора бит... Халык та хәзер элеккеге түгел, һәркем үз җаен карый. Иманны саклау өчен, динебезне, телебезне, үзебезне саклап калу өчен бер генә юл кала инде, теге вакытта сез әйткәнчә, һиҗрәт, моннан башны алып китү...

Хөҗҗәт мулла күптәннән инде моннан китү тарафдары иде, Хаҗ кылу нияте белән берничә тапкыр Мәккә-Мәдинәләрдә булып, барышлый-кайтышлый айлар буе госманлы Төркиясендә яшәгән, һиҗрәт эшләрен белешкән кеше. Бер баруында ул госманлы хөкүмәтенә һиҗрәт мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итә, аңа: «Әгәр күмәк рәвештә һиҗрәт кылырга телисез икән, ул чагында үзегезнең хөкүмәтегездән рөхсәт кәгазе алып килегез, югыйсә, документсыз килеп, авыр хәлдә калырсыз, безнең дәүләтебезне дә кыен хәлгә куярсыз», диләр. Ягъни,

аерым-аерым һиҗрәт кылган кешеләргә госманлы иленә килеп урнашу җиңелрәк булса да, инде йөзәрләгән, хәтта меңәрләгән мөселман кубарылып чыккач, Төркия дә, Рәсәй дә рәсмилеккә күчәләр – мөһаҗирләрдән документ таләп итәләр. Патша хакимияте Идел-Уралдан һәм хәтта ки ерак Себерләрдән туган илләрен ташлап чыгып киткән мөселман-татарларга башта каршылык күрсәтмәсә дә, инде авылы-авылы белән, йөзәрләп-меңәрләп китә башлагач, инде моңа чит илләрдә дә игътибар итә башлагач, бу хәлләргә нокта куярга булды – сораган документларын бирмичә, еллар буе йөртте. Шуңа күрә дә бу һиҗрәт мәсьәләсе Себердә елларга сузылды, китәсе кешеләр аерым-аерым китте, авыллар белән кузгалырга һаман рөхсәт булмады. Ул арада, халыкны котыртып йөри, дип, Хөҗҗәт мулланы да төрмәгә утыртып куйдылар, аңа да төрлечә янап-куркытып карадылар, әмма ул нык торды, төрмәдән котылам, дип, тәреләрен дә асмады, һиҗрәт дигән ниятеннән дә кире кайтмады, хәзер дә әнә шул хакта сөйли.

– Дөрес әйтәсең, Хөҗҗәт мулла, – дип аны хуплады Габдрәшит хәзрәт. – Ул чукындыру дигәненең туктап торганы да булмады... Илебезне-җиребезне урыс басып алганнан бирле, меңнәрчә-меңнәрчә милләттәшебез кяфер диненә күчәргә мәҗбүр булды. Бөтен мәчет-мәдрәсәләребез полиция күзәтүе астында, мөфти-муллаларны да урыс хөкүмәте билгели. Безгә үз хакыйкый тарихыбызны белү тыелган, үз дәүләтчелегебез дип авыз да ачарга ярамый. Ә заманында дистәләгән дәүләт тоткан халык булганбыз бит югыйсә! Үз дәүләтең булмагач, кяфер дәүләтендә алар билгеләгән тәртип белән яшәргә мәҗбүрбез. Ә аларның төп максаты – урыс булмаган бөтен халыкларны әкренләп чукындырып бетерү һәм урыска әйләндерү. Явыз Иван заманында да шул булды, Пётр да шул юл белән барды, хәзергеләре дә алардан ким түгел. «Бу хәтле кысуга болар чыдый алмас, диннәреннән чыгарлар, милләтләрен онытырлар, безнең кебек булырлар», дип уйлый булыр явыз кяфер... Инде гасырлар барышында күпме милләттәшебезне алар казанына салдык. Чират хәзер безгә дә килеп җитте...

Җыелган халык тагы аһ итеп куйды, тагы узгандагы авыр хәлләр, керәшен кырына әйләнгән татар авыллары күз алдына килде. Әмма мәчеткә җыелган халыкның барысы да китү ягында түгел иде, хәтта ки моңа каршы эшләп йөрүчеләр дә бар иде. Алар, ярдәм көткәндәй, Мөхәммәтҗан карт ягына борылып карадылар, чөнки Тара кунагына каршы ул гына сүз әйтергә мөмкин иде. Һәм шулай булды да.

– Шулаен ул шулай да, әмма яшибез бит әле, хәзрәт, – дип сүзен башлап җибәрде Мөхәммәтҗан карт, бу фикергә каршы булуын тавышына чыгарып. – Мәчетләребез эшләп тора, өебездән килеп куып чыгаручы юк, күрше авыл урыслары белән дә тату яшибез... Сугыш заманы түгел, ачлык түгел, нигә әле булмаган хәлләр өчен алдан хәвефләнеп, бөтен авыл белән кубарылып чыгып китәргә? Гаепкә алма, Габдрәшит хаҗи, мин элек тә каршы идем туган җирләрне ташлап чыгып китәргә, хәзер дә каршы...

– Каршы булсаң, китмәссең, кем сине мәҗбүр итә? – дип, аңа каршы чыкты Юанбаш Мөхәммәди. – Киткән кеше китә, калганы кала, бернинди мәҗбүриләү юк... Әмма син башкаларны котыртып йөрмә инде, Мөхәммәтҗан әкә! Без Аллаһ ризалыгы өчен, иман хакына шундый зур юлга кузгалабыз. Нәсел-нәсәбебезне исламда саклап калу өчен һиҗрәт кылабыз. Исламга ирек булган җиргә – Исланбулга китәбез, Аллаһ теләсә! Госманлы иленә, хәлифәткә, мөселман кардәшләребез янына барабыз! Бу юлда без таш яуса да түзәчәкбез! Ә менә монда калып, нәселебезнең урыслашуы, кяфергә әйләнүе белән беркайчан ризалашмаячакбыз!

Халык гөрли башлады, үзара бәхәсләшүләр, сүз көрәштерүләр китте. Халык тагы икегә аерылды, берәүләр «Китәбез!» диде, икенчеләре «Калабыз!» дип

күкрәк какты. Инде кемнең нәрсә әйткәнен аңламас хәлгә килгәндә, мәчет диварларын Габдрәшит хәзрәтнең йөрәк түреннән чыккан авазы тетрәндерде, ул мөнбәргә басып, Коръән укый иде:

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим!

Иннә-лләзиинә тәвәффәәһүмүл-мәләәәикәтү заалимиии әңфүсиһим каалуу фиимә күңтүм каалуу күннәә мүстәдгәфиинә фил-ард...»

– Белмәгәннәрегезгә татарчасын аңлатам, Коръәннең «Нисә» сүрәсе, 97нче аять: «Дин өчен һиҗрәт итү лязем булып та, һиҗрәт итмичә, үзләренә золым кылган кешеләрнең рухларын алучы газап фәрештәләре әйтерләр: «Ни булды сезгә, динегез бик зәгыйфь?» – дип. Ул кешеләр әйтерләр: «Без кяферләр кулында гаҗиз булдык, шул сәбәпле динебездә күп кимчелекләр кылдык», – дип. Газап фәрештәләре әйтте: «Әя Аллаһ җире сезгә киң иде түгелме? Сезгә дин иркен урынга күчеп китү лязем иде, ник күчмәдегез?» – дип. Күчәргә мөмкинлекләре була торып та, дин өчен күчмәгән кешеләрнең урыны җәһәннәм, ул җәһәннәм нинди яман урындыр». Бу Коръәндә язылган, җәмәгать, Аллаһ сүзләре, Аллаһ әмере! Бүгенге көндә ислам динен иркен тота торган урыннар бар, ул – госманлы җирләре, алар килегез, дип торалар. Әлбәттә, тормыш башлап җибәрү анда да җиңел генә булмас, әмма монда калып кяфер булганчы, ислам илендә фәкыйрь булуың мең артык!

Хәзрәтнең шушы сүзләреннән соң, халык тынып калды, хәтта ки куркыныч, шомлы булып китте. Китәргә мөмкинлек булып та китмәсәң, теге дөньяда җәһәннәм көтә икән бит! Кара урманнарда аюлар белән бил алышкан, диңгездәй күлләрдә балыклар белән узышкан, Себер күкләрендә бөркет булып очкан, агачтан-агачка киек-каплан булып сикергән татар ирләре Коръән сүзе каршында баш иде... Аллаһы Тәгаләнең җәһәннәм белән кисәтүе алдында тез чүкте...

Бу дәһшәтле тынлыкны тагы Мөхәммәтҗан карт бозды, ул да Коръән сүзе белән башлады:

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим!

Илләл-мүстәдгәфиинә минәр-риҗәәли вән-нисәәәи вәл-вилдәәни ләә йәстәтыйгүүнә хииләтәү вә ләә йәһтәдүүнә сәбиил».

– Мин дә белмәгәннәргә татарчасын аңлатам, Коръәннең «Нисә» – «Хатыннар» сүрәсенең 98-99нче аятьләре: «Мәгәр күчәргә көче җитмәгән зәгыйфь ирләргә, хатыннарга һәм балаларга күчмәгән өчен җәһәннәм газабы булмас, алар торган җайларында кяфер кулыннан котылырга хәйлә тапмасалар, яки күчеп китәргә ничек тә көчләре җитмәсә. Бу гозерле кешеләрне Аллаһуның гафу итүе бик өметледер, Аллаһ гафу итүче, ярлыкаучы булды», дип тә әйтелгән әле монда... Ягъни, карт-корыга, хатын-кызларга, бала-чагага кяфер арасыннан күчеп китмәгән өчен җәһәннәм газабы юк, Габдрәшит хаҗи! Ә монда ярты авыл шундыйлардан тора, кая алар белән андый билгесез юлга чыгарга?!

Габдрәшит хаҗи аның белән бәхәскә кермәде, Коръән-хафиз буларак, андый аятьләр барын ул яхшы белә иде, әмма бәхәсләшеп, ил картын уңайсыз хәлгә куярга теләмәде. Мөхәммәтҗан карт – тирә-юньдә билгеле шәхес, дин дисәң – дине бар, кулы алтын, белмәгән эше юк, әле үзе шагыйрь-чичән дә, теленнән гөл коела... Себерне, аның кырыс һәм матур табигатен аның кебек өзелеп яратучы, һәр җан иясенең, һәр бөҗәкнең телен-көен белүче тагы бармы икән? Ул Себердән китсә дә, читтә яши алмас иде, тышавын өзгән чаптар ат кебек, туган якларына җәяүләп булса да кайтып егылыр иде... Аны һиҗрәткә чакырудан мәгънә юк, әмма башкаларның башын әйләндермәсә, яхшырак булыр иде...

Хәзрәтнең уйларын сизгәндәй, сүзгә Хөҗҗәт хаҗи кушылды.

– Соң, Мөхәммәтҗан әкә, ул сүрәнең тагы дәвамы бар бит әле: «Бер мөэмин Аллаһ юлында, дин өчен һиҗрәт итсә, барган җаенда диндә вә тормышта

киңлекне һәм яхшы мөселманнарны табар. Бер мөэмин Аллаһ юлына, расүле янына китмәк өчен өеннән юлга чыкса, соңра юлда аңа үлем ирешсә, дөреслектә аның әҗере Аллаһ хозурында сабит булды. Аллаһ мөһаҗир хәлендә үлгән мөэминнәрнең әүвәлдә булган гөнаһларын ярлыкаучы һәм рәхмәт кылучы булды», диелгән анда. Һиҗрәт кылган мөселманнар Аллаһның саклавында һәм яклавында булачаклар, син әйткән картлар, балалар, хатын-кызлар да... Шуңа күрә, син Аллаһ ризалыгы өчен, аның җәннәтләренә өмет итеп, шушындый зур юлга чыгарга ниятләгән кешеләрне кирегә үгетләмә инде, Аллаһ әмеренә каршы барма, Аның ачуына дучар булма...

Бу сүзләрдән соң артык бәхәс булмады, әмма һәркем үз фикерендә калды. Мөхәммәтҗан карт та, йөрерләр-йөрерләр дә, туктарлар, басылырлар, дип уйлады, китүчеләргә документлар бирелмәүне дә яхшыга юрады. Ул арада Хөҗҗәт хаҗи да Хаҗга киткән җиреннән Төркиядә урнашып калды, монда башка кайтмады. Әмма аның эшен биредә шул Юанбаш Мөхәммәди Шихов башкара, бик акыллы, зирәк булганга, аны шулай «Юанбаш» дип йөртәләр. Ул үз тирәсенә бер төркем туплый, анда Давыт Шихов, Әбнәзир Князев, Абханнан Әхмәдиев, Вәли Зыятдинов була, алар Яланкүл, Аубаткан, Кумыслы, Үләнкүл, Каракүл, Чабаклы, Койгалы, Кошкүл, Чарналы авылларында йөреп, халык белән эшлиләр. Юанбаш Мөхәммәди исә күбрәк Тара, Тубыл белән эш йөртә, һиҗрәткә җыенганнарның документлары артыннан берничә тапкыр үзе Петербургка хәтле бара. Авыл старостасы Вәли Зыятдиновны, халыкны китәргә котырта, дип, җиде айга Тара төрмәсенә тыгып куялар, шуннан соң һиҗрәтчеләр яшерен эш алып бара башлыйлар. Тарада дуслары ярдәмендә, Вәли Зыятдинов мәңгелек сөргеннән котыла, төрмә аның һиҗрәткә китү теләген тагы да ныгыта.

Әйе, эшләр Мөхәммәтҗан карт уйлаганча булмады – бу көннәрдә яңа хәбәр килде – Юанбаш Мөхәммәди башкаладан һиҗрәт өчен кирәкле документларын әзерләп кайткан, гаеттән соң юлга кузгаласылар икән. Бу хәбәр Мөхәммәтҗан картны иярдән бәреп төшергән кебек булды, ул шунда ук авыру кызы Хөснибикә турында уйлады, бернигә карамый китәргә әзерләнгән ир һәм кыз туганнары, аларның балалары күз алдына килде. Китәләр... Бөтен нәсел-ыру, бөтен туган-тумача, бөтен авыл белән күз күрмәгән, колак ишетмәгән госманлы иленә китәргә җыеналар... Анда аларны кем көтеп торсын?! Кемгә кирәк булыр алар – Себер мөһаҗирләре, урман-дала татарлары? Кем кара көзгә, салкын кышка каршы шушындый озын юлга чыга?! Яшь балалар, авырлы хатыннар, үләргә торган картлар белән?! Себер бит бу, аларның яртысы юлда үлеп бетәчәк! Юк, бу эшне ничек тә туктатырга кирәк, туктатса, моны Габдрәшит хаҗи гына туктатырга мөмкин, чөнки бар эш шуннан башланды. Мөхәммәтҗан карт үзе аның белән аерым очрашыр, халык хәтле халыкны куркыныч астына куярга ярамаганын әйтер. Инде бик китәселәре килә икән, әнә, башта ир-атлар китеп урнашсын, аннан гаиләләрен дә алдырырлар. Сугыш-мазар юк, берсе дә ач-ялангач түгел, өйләрдән килеп куып чыгаручы юк, ничек инде ирекле баштан шушы җәннәттәй җирләрне ташлап китәргә мөмкин?!

## Аккош каргышы

...Мөхәммәтҗан карт атның дилбегәсен үзенә тартыбрак куйды, юртак адымнарын әкренәйтте, хуҗасының ни теләгәнен аңлады ахры. Әйе, Тара шактый ерак булса да, Мөхәммәтҗан картның ашыгасы килми иде, бүген барыбер анда барып җитәрлек түгел, юлдагы берәр татар авылына кереп кунасы булыр. Шагыйрь җанлы кеше өчен моннан да зур хозурлык, моннан да бәхетле мизгелләр була аламы соң?! Соңгы вакытларда эш, дип, тормыш, дип, баш күтәреп карарга да вакыт булмаган, инде игеннәр урылган, амбарлар кышкы азык белән тулган, мал

чалырга әле иртә, бер күкрәк тутырып, ял-сахра һаваларын да суларга була... Ул һиҗрәт белән дә күпме җанны ашарга мөмкин, ярар, киткәне китәр, калганы калыр, Мөхәммәтҗан карт үзе ике аягының берсен дә ул тарафка атламаячак. Тик менә... Һаман шул газиз балакай, зәгыйфь колынкай – Хөснибикәсе үзәкне өзә шул... Ире Салих, китәбез булгач китәбез, ди, ә хатынына ул хуҗа, ул ничек әйтсә, шулай булачак, уч төбендә генә үстергән ата сүзе үтми хәзер...

Хуҗасының уйга бирелгәнен сизеп, Тулпар ат адымнарын әкренәйтте, озын муенын борып, юл читендәге үләннәрне чемченеп бара башлады. Чемченсен, аңа да ял кирәк, нәселле юртак булса да, аңа да авыл җирендә хуҗасы белән бергә җигелеп тартырга туры килә. Авыл җирендә шунсыз булмый, шуңа күрә дә ир-ат инде ул, бергә янәшә өстерәсәң генә тормыш бара... Менә Мөхәммәтҗан карт та заманында мәдрәсәләр тәмамлаган, имамлык иткән, балалар укытып йөргән укымышлы бер кеше иде. Артык туры сүзле булуы, үз фикереннән кайтмавы өчен ул да кайберәүләргә ярап бетмәде, төрле гаеп табып, аны да читкә этәреп куйдылар. Ишле гаиләне, авыл тормышын да тәсбих тартып утырып кына алып барып булмый иде, шуңа күрә, китапларын читкә куеп, тормыш арбасына җигелергә туры килде. Игенен дә чәчте ул, иңенә мылтык асып, ауга да йөрде, абзар тутырып, малын да асрады, гаиләсен, бер-бер артлы туып торган балаларын ач-ялангач итмәде. Авыл халкыннан аермалы буларак, әле тимер эше белән дә шөгыльләнде, тимер йорты-мастерскоенда ул төзәтмәгән, ул ясап карамаган нәрсә калмады. Гомер буе матурлыкка омтылды Мөхәммәтҗан карт, гомер буе әллә нинди хыяллар белән яшәде, болын чәчәкләренә охшатып, тимердән чәчкәләр койды, күлдәге аккошларны ясап куйды, капка-коймаларны чәчәкләп-бизәкләп бетерде... Озакка сузылган кышкы салкын төннәрдә аның өендә җәй матурлыгы яшәде, ул үзе чыгарган шигырьләре, җырлары белән бу матурлыкка җан өрде, шушы тормышыннан бер ямь тапты...

Әмма өзелеп сөйгән яры, гомер иткән хатыны бала тапканда кинәт кенә үлеп киткәч, аның да кояшы сүнде, тормышының яме бетте... Бу фаҗига моннан ун еллар элек булды, ул чагында әле балалар да кечерәк иде, алар – анасыз, Мөхәммәтҗан үзе пар канатсыз калды... Ир башы белән үксеп-үксеп елады ул, Тайрасының киемнәрен күкрәгенә кысып, аннан сеңеп калган исләрдән иләсләнде, саташкандай, үзалдына сөйләнеп йөри башлады. Юк, саташмады ул, ә Тайрасы-Таһирәсе турында кырык көн буе шигырь чыгарды, аны мөнәҗәт итеп әйтеп йөрде. Монысын да гаеп итүчеләр булды, имеш, мулла башы белән, дога кыласы урында, шигырь әйтеп йөри... Юк, догасын да кылды ул, күзләре яшь, күңеле моң белән мөлдерәп тулганда, мөнәҗәтен дә әйтте. Шул хәсрәтле көннәрен исенә төшереп, Мөхәммәтҗан карт Шәм-Шәрифкәй көенә салмак кына җыр сузып җибәрде:

Карның агындай тәннәрең,
Багалмадай иде йөзкәең.
Кара кашым, карлыгачым,
Моңлы карый иде күзләрең.
Чәч толымыңда чулпыларың,
Чыңлаган күк тоела колакта.
Энҗе-мәрвәт муенсаңны
Үбеп-үбеп алам аулакта.
Көмеш беләзегеңне тагып
Йөргән кебек тоеласың.

Көләч йөзле, бәгырькәем,
Күз алдымнан таясың.
Төннәр буе утырамын
Шәмдәлләрдә шәм ягып.
Зәгъфрандай саргаеп,
Кара япан ябынып.
Тәкъдиремдә язылгандыр –
Сыктап-сыктап яшәрмен.
Тимер өем эчләрендә
Ялгыз гомер кичәрмен...

Юртак ат, хуҗасының моңга сабышканын тоеп, үлән киртләвеннән туктады да, башын күтәреп, аңа карап тора башлады... Алар инде бергә картаеп киләләр, Тулпар да хуҗасының кайчан кайгырганын, кайчан шатланганын

тавышыннан сизә, ул моңаеп җырлый башласа, үзенең дә күзләреннән эре-эре яшь тамчылары тәгәрәп төшә... Бу юлы да шулай булды – урман-дала уртасында ялгыз татар ире сулкылдап җырлый, аның җан дустына әйләнгән аты тын гына елый иде... Мөхәммәтҗан карт, юртагының башын кочып, аңа йөзен яшереп, үзе дә сүзсез генә елады... Инде Тайрасын гына түгел, баласын – телсез-чукрак Хөснибикәсен дә мәңгелеккә югалтасын ата йөрәге белән сизенеп, аты белән бергә кушылып елады ул урман юлында...

Баш очында үзәк өзгеч аһылдаган тавышлар ишетеп, Мөхәммәтҗан карт күтәрелеп карады – зәңгәр күкне урталай телеп, кыйбла якка таба аккошлар китеп бара иде... Юк, алар кычкырмыйлар, бары тик сулкылдап-аһылдап кына куялар, бу шундый кошлар иде... Аккошлар... Алар да китә... Һиҗрәтчеләр кебек, кыйбла тарафка китә... Әмма алар кайту өчен китә, язларын шушы күлләрне тутырып, оя ясау, нәсел калдыру өчен барыбер Себергә әйләнеп кайта алар. Шул чакта Мөхәммәтҗан картның йөрәге «жу» итеп китте, бер – диңгездәй җәйрәп яткан күлләргә, бер шул күлләрне ташлап китеп барган аккошларга карады һәм тагы йөрәк ярасы исенә төште – «Аккош каргышы!» Аның нәселендә аккош каргышы бар бит, бөтен авыл шулай сөйли, үзенең язмышы да шул хакта искәртә...

Яланкүл авылы тирәсендә күлләр бик күп – аларның диңгездәй зурлары да, җыйнак кына булганнары да, бик тирән-төпсезләре дә, тозлы-төчеләре дә бар. Аларның исемнәре дә җырлап тора – Рәчәп, Кошкүл, Еланкүл, Кәккүк, Акпава, Чуар, Мәрәткүл, Куртайлы-Дениз, Кумыслы, Мәүлет күл, Ырыслы... Менә шул Ырыслы күлдән башланды инде аның гаилә фаҗигасе... Бу күлнең ярларын камыш баскан, һәм анда һәр язда аккошлар кайтып, оя кора, бала чыгара, чөнки камыш арасында аларга тынычрак, күрәсең. Әмма алар бу камышлы күлгә башка кош-кортны якын китермиләр, адашып килеп кергән йорт казларын да канатлары белән кыйнап куып чыгаралар, хәтта аларның муеннарын канат белән чабып өзгән вакытлары да булды. Күлгә якын яшәгән Мөхәммәтҗан картның да йорт казлары ничә ел рәттән шулай кырылды, һич түзәр хәл калмады. Һәм бер елны ул бу әрсез аккошларны бераз өркетергә, акылга утыртырга уйлады.

Тайрасының Хөснибикә белән авырлы елы иде. Җәен тагы Ырыслы күлдә аккошлар һәм йорт казларының сугышы башланды. Мөхәммәтҗан, ау мылтыгын алып, күл ягына юнәлде, исәбе – аккошларны куркыту, йорт казларына күлдә йөзәргә ирек бирү иде. Күлдә йорт казлары күренү белән, аккошлар, канатларын киң җәеп, аларга ташландылар, яман ысылдап, сәер сулкылдап һәм аһылдап, канатканчы чукый, шапылдатып кыйный башладылар, күл өстенә дә аккошлар көтүе җыелды. Алар шулай берләшеп үз ояларын, андагы нәни кошчыкларын саклыйлар иде. Күз алдында казларын аккошлардан талатып үтертмәс өчен, Мөхәммәтҗан гөрселдәтеп күккә атып җибәрде, бу тавыштан аккошларның кайсы күккә күтәрелде, кайсы камышлар арасына кереп качты. Мөхәммәтҗан аккош атам дип атмады, бары тик кисәтергә, куркытырга гына теләде, әмма ул аткач, бер аккош, канатларын күкрәгенә кысып, Мөхәммәтҗанның аяк астына килеп төште... Аның канат астыннан ак мамыгына кан бәреп чыккан, ул аккошның бар гәүдәсенә таралып бара иде...

Әле җаны да чыгып өлгермәгән аккошны Мөхәммәтҗан канатларыннан күтәреп кулына алды, гафу үтенгәндәй, күзләренә карады, аннан, күкрәгенә кысып, өйләренә алып кайтып китте. Ул юл буе нindидер авыр җинаять эшләгән кеше кебек кайтты, юлда очраган авылдашларына да күтәрелеп карамады, ә алар аның артыннан башларын чайкап, гаепләп калдылар. Татар авылларында беркайчан да аккош атмадылар, үзләре ачлы-туклы булганда да, аларга нindидер изге, пакь кошларга караган кебек карыйлар иде, шуңа күрә алар Яланкүлгә дә һәр язда беренчеләрдән булып очып кайтып җитәләр иде.

Һәм менә Мөхәммәтҗан аккош аткан, үз башына язык-гөнаһ алган, моның ахыры хәерле бетмәс, дип сөйләнделәр авылда. Иренең үле аккош күтәреп кайтып кергәнен күргәч, Таһирә дә тынсыз калды, күзләренә яшь бәреп чыкты, аннан алъяпкычына капланып, тыела алмыйча елый башлады.

– Гөнаһысын кая куярбыз, нәселебезгә аккош каргышы төшүе бар бит, нишләдең син?! – дип өзгәләнде ул.

Мөхәммәтҗан аны юатып та карады, син авырлы бит, болай борчылып, балага зыян килмәсен, дип, тынычландырырга тырышты. Тайраның тынып-моңаеп калганын күргәч, аккошны алып, тизрәк өйдән чыгып китте. Күл буе да тынып-шомланып калган иде, ник бер аккош, ник бер йорт казы күренсен! Һавада әле дары исе дә таралып өлгермәгән кебек, җирдә исә атылган аккошның ак каурыйлары аунап ята, мамыгы җилдә очып йөри... Мөхәммәтҗан үле аккошны шул җиргә куеп калдырды, ул яр читеннән ерак түгел, камышлар тирәсендә иде. Нигә алай эшләде – үзе дә аңламады, пары күрсен, дип уйладымы – белми. Икенче көнне иртән күл буена килеп караганда, атылган аккош анда юк иде инде, суга таба кан таплары гына тамып-тамып калган, озын камышларга мамык йоны уралган иде... Аккошлар бөтенләй күренми, ә күлгә йорт казлары хуҗа булып өлгергән иде...

Ә көз көне, аккошлар җылы якка киткәндә, Тайра Хөснибикәне тапты. Нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, аккошлар авыл өстендә кат-кат әйләнделәр, аларның сулкылдаган-аһылдаган тавышлары белән күл буйлары тулды. Соңыннан билгеле булды – бер аккош җылы якка китмичә, Ырыслы күлендә калган икән, башкалары аны чакырып шулай өзгәләнгәннәр. Китмәде ул аккош җылы якларга, күл боз белән капланганчы, парын эзләп ялгыз йөзде, аһылдап-сулкылдап, авыл өстендә әйләнде, аның хәсрәте урман-далаларга сыймады. Аның белән бергә, авыл халкы аһ-зар итте, парын атып үтергән Мөхәммәтҗанны гаепләделәр, үз оялары да шулай тузгымасын, дип курыктылар... Инде елга-күлләр боз белән каплангач, инде җир өстен ак кар каплагач, ялгыз аккош күкнең иң биек ноктасына күтәрелде дә, канатларын күкрәгенә кушырып, түбәнгә томырылды... Җирдә ул ак кар белән бергә кушылды, бары тик күкрәгеннән бәреп чыккан кан табы гына монда аккош ятканын белдереп тора иде... Аның гәүдәсе пары белән янәшә ята иде...

Бераз үсә төшкәч, Хөснибикәнең тумыштан телсез-чукрак икәнлеге беленде, ул, аккош тавышы чыгарып, сулкылдый-аһылдый гына ала иде... «Аккош каргышы!» дип аһ итте Тайра, баласының телсез-чукрак булуын белүгә. Авыл халкы исә «Мөхәммәтҗан мулланың баласы аккош тавышлы булып туган, аһылдый-сулкылдый гына ала икән, атасы аккош атып зур языклы булганга, баласы шундый туды», дип сөйләделәр. Мөхәммәтҗан исә Аллаһ алдында да, баласы алдында да үзен зур гөнаһлы исәпләде, шул вакыттан муллалыгын ташлады, ат кебек кара эшкә җигелде.

Ә аккошлар шактый еллар яңадан Яланкүл авылы күлләренә кайтмадылар, аларның да нәсел хәтеренә бу фаҗига кан белән язылган иде. Ә менә Тайра баладан үлеп ятканда, язгы ямьле көннәрнең берсендә, авыл өстендә тагы аккошлар күренде. Алар Яланкүл өстендә кат-кат әйләнделәр, әйтерсең лә үзләренә төшеп оя корыр өчен камышлы күл эзлиләр иде... Тайрасы-җан кисәге, нидер әйтергә теләгәндәй, киң итеп ачып куйган тәрәзәгә текәлде, мәрмәрдәй ак йөзеннән күз яшьләре тәгәрәп төште. «Кайттылар... – диде ул, җиңел сулап. – Мине алырга кайттылар... Каргышларын кире алырга кайттылар...» Кул хәрәкәте белән, ул кызы Хөснибикәне үз янына чакырып китерде, аны йөзе белән ачык тәрәзәгә таба борды. Ә анда, зәңгәр күкне тутырып, аккошлар оча иде, әйтерсең лә җан биреп яткан үз тиңнәре белән бәхилләшәләр, аһылдап-сулкылдап кичерү сорыйлар... Аларга кушылып, телсез Хөснибикә аһылдый, очып китәрдәй булып,

кулларын күккә таба суза, ятим каласын сизенгәндәй, бөтен гәүдәсе белән сулкылдый, елый иде... Аккошлар яңадан Ырыслы күлгә төшеп утырганда, Таһирә җан бирде, парын мәңгегә ятим калдырып, бу дөньядан китеп барды...

Шул вакытлардан күңеленә әллә нинди бетмәс сары сагыш кереп оялады Мөхәммәтҗанның, ул аккош моңына әйләнеп, әле шигырь, әле мөнәҗәт булып бәреп чыкты, җырлатты һәм елатты. Мөхәммәтҗан Тара базарында гаҗәеп бер уен коралы – скрипка күреп әсәрләнеп кайтты, ат кылыннан тарттырып, эрбет агачын киптереп, ул да шундый уен коралы ясап карады – көй чыкты! Башта ул анда яшереп кенә тимер өендә уйнады, аннан күл буйларына, урман араларына да чыгып китә башлады, авыл халкы аны бөтенләй җиңеләйгәнгә санады... Ә Мөхәммәтҗан аккош көен уйный иде, мәңгелек мәхәббәт һәм мәңгелек ялгызлык турында сөйли, үз парына тугрылыгын аңлата иде... Бу көен ул күл буендагы аккошларга да барып уйнады, аккош кебек телсез кызына да тыңлатты, менә хәзер дә атында әкрен генә шуны көйләп бара...

Бәнем ялгышларым җиттеме икән –
Ялгыз аккош авыл-лай күгендә?
Аккош каргышлары төштеме икән –
Парсыз калдым гомерем-ләй көзендә...
Кичерсәнә, Раббым, кичерсәнә,
Коткар нәселемне каргыштан.
Сакла нәселемне ул ялгыштан –
Аккошлардин калган язмыштан...

...Тулпар ат җыр көенә әкрен генә кыр юлы буйлап Тарага таба атлый... Аның бу җырны инде күп тапкырлар ишеткәне бар, хуҗасы юлга чыккан саен, ялгыз калган саен шуны көйли. Хәзер караңгы төшеп, берәр җирдә кунарга тукталганчы, шулай барачаклар – җырлап һәм елап, елап һәм җырлап... Моны хәтта ки җыр дип тә әйтеп булмый, ул – күңелнең ыңгырашуы, бәндәнең ялгыз калып, үз-үзе белән сөйләшүе, үкенече һәм тәүбәсе, заяга үтеп барган гомеренә нәтиҗә ясавы... Себер урманнары, карагай-каеннары, поши-бүреләре, күлләрдә чуртан-җәеннәре, сазлыкларда бака-еланнары, күкләрдә аккош-бөркетләре белән бер татар картының җырын тыңлыйлар иде... Ул җыр Себер урманнары кебек иксез-чиксез, елга-күлләр кебек тирән-төпсез, дала җиле кебек җитез иде, ул көй зәңгәр күкләрдә аккош канатлары белән язылып, җирдә бәндәләр күңеленә мәңгегә сеңгән иде... Һәм бу җыр әле, мөһаҗирләр көе булып, алар белән бергә ерак Төркияләргә китәчәк, анда туган илләреннән мәңгегә аерылган татарларның йөрәк сагышы булып, тау-ташларга уралачак, әманәт итеп, буыннан-буынга тапшырылачак, бер гасырдан соң, яңадан Себер туфракларына кайтып егылачак әле... Әмма моның өчен йөз еллык мөһаҗирләр юлын үтәргә, йөз ел буе туган яктан аерылу сагышын йөрәкләрдә күтәреп йөртергә туры киләчәк... Һәм бу мөкатдәс тел, бу аккош моңы, бу мәңгелек иман изге әманәт булып гомер буе сакланачак...

## Габдрәшит хаҗи янында

Тарага икенче көнне генә килеп керделәр...

Озын юлда төрлесен уйлады Мөхәммәтҗан карт, Яланкүлдәге кайнарлыгы бераз басыла төште, һиҗрәт мәсьәләсен дә төрле яктан килеп бәяләде. Ул үзе анда китмәячәк инде, бу турыда сүз дә була алмый, Тайрасының, ата-аналарының каберләрен калдырып, гомер буе бөртекләп җыйган йорт-җирне пыран-заран китереп, балалары белән билгесезлеккә чыгып китә алмый ул. Ә менә кызы Хөснибикә... Ул бик кызганыч, үзәкләрне өзә шул гарип баланың язмышы... Үзенең

балалары нинди булып туар, ире риза булып яшәрме телсез-чукрак хатын белән? Әле монда, ни булса да, ярдәмгә ашыгырга карт атасы бар, анда кем янына килер, кем хәлләрен белер? Хәер, Мөхәммәтҗан картның ике кыз туганы һәм энесе дә, балалары белән, шушы һиҗрәт кәрванына кушылырга уйлыйлар, аларның инде хәл ителгән. Анда баргач та, Хөснибикәсен ташламаслар, инша Аллаһ! Алай да, инде бер юлга чыккач, Габдрәшит хаҗига хәлне аңлатып карарга кирәк, бәлки башлап йөрүчеләргә әйтер, Хөснибикәләр гаиләсен калырга үгетли алырлар?

Теге вакытта Яланкүл мәчетендә Габдрәшит хаҗига каршы төшеп тә ялгыш эшләде ахры ул... Кеше алдында кирәкмәс иде, имеш, Коръәнне Мөхәммәтҗан карт та белә... Габдрәшит хаҗи исә ил алдында аның йөзен ертмады, каршы төшмәде, әмма үз фикереннән дә кире кайтмады. Мөхәммәтҗан карт та үз фикереннән кире кайтмады анысы. Тәмам башы катты аның бу һиҗрәт белән...

Әнә шундый икеле-микеле уйлар белән Тарага килеп кергәндә, өйлә туры үтеп киткән иде инде, Мөхәммәтҗан карт атын мәчет ягына атлатты, намазын да укып алыр, Габдрәшит хаҗины да шунда күрермен дип уйлады. Башлыча ике катлы агач йортлардан торган Тара шәһәре аны көзге ярминкәләре, кайнап торган базарлары, урамда очып йөргән сары яфраклары белән каршы алды. Аның Тарага элегрәк тә килгәләгәне булды, биредә татарлар шактый яши, бохаралы мөселманнарның да төп яшәү урыннары шушында. Биредә ике мәчет бар, чиркәүләрнең саны хисапсыз. Заманында Күчем ханның җәйге ыстаны булган һәм Ялым-Тора дип аталган бу шәһәрне себер татарлары хәзер дә Тора, дип кенә йөртәләр. Урыслар исә аны басып алып, 1594 елда биредә хәрби кәлгә төзеп куялар, тора-бара ул бөтен Себерне яулап алырга бер үзәк була. Тара өчен сугышлар әле Күчем хан үлгәч тә озак дәвам итә, аның балалары һәм оныклары бу шәһәрне генә түгел, бөтен Себерне кире кайтару өчен көрәшеп карыйлар, әмма урысларны җиңә алмыйлар.

Тара бөтенләе белән урыслар кулына күчкәч тә, татарлар биредә юкка чыкмыйлар, шул ук бохарилар каладан аз гына читтәрәк – тау асты бистәсендә оешып яши башлыйлар. Бик яхшы сәүдәгәрләр һәм оста арадашчылар булганга, җирле халыклар белән ике арада эш алып бару өчен, патша хөкүмәте аларга тими, тия башласалар, алар Петербургка илчеләр юллыйлар һәм мәсьәләне үз файдаларына хәл итеп кайталар. Алим шык та шулай заманында патшабикә янына барып, халыкны бөтенләй чукындырып бетерүдән саклап калган иде... Аннан соң да төрле хәлләр булды, бохаралылар да ышанычтан чыга башлады, чөнки алар урыс хакимияте өчен барыбер мөселманнар, барыбер татарлар иде. Габдрәшит хаҗи дөрес әйтә – алар татарларны чукындырып бетермичә туктамаячаклар. Татарлар да тик ятмый – кулларына аз гына акча кердеме – урыс арасында мәчет-мәдрәсә төзеп куялар, балаларын укыталар, һөнәр бирәләр, үрчиләр! Тарада беренче мәчет-мәдрәсәләрне дә шул Габдрәшит хаҗиның бабалары салды бит, әле ул Пётр патша заманында ук булды. Шул гасыр азагында шәһәрдә беренче таш мәчет салынды, түбәсен калай белән яптылар, анысын инде данлыклы Айтукә байлар эшләде. Мөхәммәтҗан карт хәзер менә шул таш мәчеткә бара, ул һаман эшләп тора...

Аны күрергә дип тәгаенләп килсә дә, Габдрәшит хаҗи мәчеттә булмады. Мөхәммәтҗан карт намазларын укыды да, инде кайда яшәгәнен сораштырып, өенә барырмын, дип торганда, бер яшь татар килеп, аңа булышырга алынды. Ябык кына кыяфәтле, бер күзенә ак төшкән бу кеше үзен сәер тота, туктаусыз як-ягына карана иде. Ул Аубаткан авылыннан булып, Исмәгыйль исемле икән, хәзер Тарада яши ди, Мөхәммәтҗан картны да белә булып чыкты. Мөхәммәтҗан карт аңа үзенең гозерен әйтте, Габдрәшит хаҗины эзләп килүен җиткерде. Яңа танышы як-ягына каранды, аннан сер итеп кенә әйткәндәй, пышылдап куйды:

– Хәзрәт Питердән качып кайткан бит, ул мәчет тирәсендә бик күренеп йөрми хәзер, анда-санда гына кергәләп чыга...

– Алай икән, – диде Мөхәммәтҗан карт, авыр сулап. – Мин аны күрергә дип ат җигеп Яланкүлдән үк килгән идем бит... Килешеп бетмәсә дә, өенә бармыйча булмас инде, киңәшәсе нәрсәләрем бар иде...

Яшь кеше аның янына ук килеп утырды.

– Авылда бер-бер яман нәрсә юктыр бит, агай? – диде ул, кызыксынып.

– Яман гынамы, энекәш, яман гынамы?! Бетә авыл, безнеке дә, сезнеке дә... Бөтенесе һиҗрәткә дип кузгалган, тыеп-туктатыр хәл юк...

– Габдрәшит хаҗига әйтүдән мәгънә юк моны, агай, – диде яңа танышы, бик белдекле кыяфәттә. – Ул үзе аларны котыртып йөри бит... Аны тыңлый күрмәгез! Иярә күрмәгез, харап булырсыз! Панисламист, пантюркист бит ул! Хөкүмәт дошманы, күзәтү астында ул хәзер, сак булыгыз!

Шул чакта Мөхәммәтҗан карт аңлап алды – бу шома егет Габдрәшит хаҗига каршы кеше иде ахрысы, тел төбеннән шул аңлашыла. Үзе дә артыграгын әйтеп ташлады ахры, инде хәзрәткә зыяны-фәләне тия күрмәсен...

– Ярар, энекәш, мин китим әле алайса, – диде ул, авыр гына күтәрелеп. – Юл кешесенең юлда булуы яхшы.

Яшь татар аңа ярдәм итәргә теләп иелде, шул чакта Мөхәммәтҗан карт аның изүендә нидер ялтырап китүен күрде, тимер чылбырга «тавык тәпие» тагылган иде!

Мөхәммәтҗан карт, корт чаккандай, сикереп торды, чепи күз белән саубуллашып та тормыйча, тизрәк мәчеттән чыгып китте. Ошамады аңа бу егет, әллә нинди шымчы кыяфәтле бәндә, әллә муенында тәресе дә бар инде, әллә күзенә генә күрендеме... Ни булса да, яныннан тизрәк китүең хәерле. Мөгаен, мәчеткә кем кергән-чыкканны тиешле җирләргә җиткереп барадыр... Аллам сакласын, Габдрәшит хаҗига зыяны тия күрмәсен... Атына утырып, мәчет тыкрыгыннан борылуга, каршына очраган татарлардан Габдрәшит хаҗиның кайда торуын сорады. Аның өе якында гына булып чыкты, ул карагай агачыннан салынган җыйнак кына йортта яши икән, каршысында бакчасы да бар. Ишек шакылдаткан тавышка өйдән буй җиткән егет чыкты, каршында олы яшьтәге татар ирен күргәч, аны шунда ук эчкә үтәргә чакырды. Мөхәммәтҗан карт егет артыннан эчкә үтте, алар китаплар белән тулы якты бер бүлмәгә килеп керделәр, аның түрендә, Коръән укып, Габдрәшит хаҗи үзе утыра иде. Ул да бераз олыгаеп киткән кебек, йөзе дә арыган-алҗыганга охшаган, соңгы вакытта тормыш аны да нык басты шул... Баштанаяк актан киенгән, мәһабәт гәүдәле, ак сакаллы бу кеше Хозыр-Ильясның үзенә охшаган, аннан нур һәм көч-кодрәт бөркелеп тора иде...

Кул биреп, кочаклашып күрештеләр, утырып, дога кылдылар. Кайбер фикер каршылыклары булса да, Габдрәшит хаҗи кунагына нык куанды, якын туганы кебек, түр башына утыртты. Капка төбендә аты калганлыгын белеп, улына аны ишегалдына кертеп куярга, алдына ашарга салырга кушты, егет ашыгып чыгып китте. Ул арада икенче бүлмәдән ирләрнең үзләренә дә ашарга чыгардылар, әнисе белән үсмер кыз алар янына тәмле-төмлесен ташып кына тордылар. Өстәлгә кайнар ашы да, салкынча ите дә, җиләк-җимеше дә, сөтле чәе дә чыкты, ирләр ашаган арада сүз дә башлап җибәрделәр.

– Син, Габдрәшит хаҗи, мине кичер инде, теге вакытта Яланкүл мәчетендә сүзеңә каршы төштем... Минә хәзер дә шул мәсьәлә буенча килдем әле...

– Әллә үзең дә китәргә җыенасыңмы, Мөхәммәтҗан мелла? – диде Габдрәшит хаҗи, гаҗәпләнеп һәм серле елмаеп.

– Юк, хәзрәт, мин андый олы юлга чыга алмыйм, – диде Мөхәммәтҗан карт, кырт кистереп. – Син, бәлки, беләсеңдер, Тайрам үлгәч, балаларны ятим итеп булмый,

дип, мин туганнан-туганыма өйләндем... Бер-бер артлы тагы балалар туды... Әмма алар барысы да телсез-чукрак булып тудылар... Әниләре үзе дә шундыйрак... Менә шул ничә гарип-горабаны төяп, мин ничек билгесез юлга чыгып китим? Монда мин һәр үләнне, һәр киекне беләм, гаиләмне ач итмәм, анда нишләрмен? Син миннән яшьрәк, әмма мин алтмышка җитеп киләм бит инде, ак сакаллы бабай!

– Йә, куй, Мөхәммәтҗан әкә, син әле егетләргә биргесез! – дип, хуҗа аны бүлдерде. – Сине урмандагы аюга каршы коры кул белән барган, аның белән бил алышкан, сыртына салып, авылга алып кайткан, дип сөйлиләр бит...

– Анысы аның яшь чакта булды бит инде, – дип кул селтәде Мөхәммәтҗан карт, әмма үзенең күңеле булды, күзләре янып, хәрәкәтләре җиңеләеп китте. – Аюларны күп ектык без, хәзрәт, бүреләрне күп суктык... Ә хәзер тормыш басты, Тайрамның вакытсыз китүе, балаларымның зәгыйфь булып тууы да күңелне төшерде... Мин әле кайчан гына җир җимертеп, ун авылны бер итеп йөри торган кеше идем бит! Ярар, анысын куеп торыйк, сиңа килүемнең сәбәбе бик җитди, Габдрәшит хаҗи, шул теге вакытта кузгаткан сүз инде... Телсез-чукрак кызым Хөснибикә өчен бик борчылам, җитмәсә авырлы, бик зәгыйфь, йомшак бала, мондый юлны күтәрә алмас ул... Ире беркемне тыңламый, үзе дә китә, хатынын да өстери... Бәлки, син әйтсәң, калып торырлар иде, баласын табып, бераз тернәкләнгәч, үзләре хәл итәрләр иде тагын... Бу һиҗрәткә җыенучылар арасында карт-корылар, яшь балалар күп, аларны бер белмәгән-күрмәгән җиргә, кышкы юлга ничек чыгарып җибәрәсең? Әллә китәргә теләгән ирләр үзләре генә китсеннәрме башта, дим? Шул турыда киңәшергә дип, ат җигеп, махсус килдем синең яныңа...

Габдрәшит хаҗи җавап бирергә ашыкмады. Кече яктан хатынын чакырып, тагы кайнар чәй китерттерде. Ул арада ат бәйләргә чыгып киткән уллары да кереп, алар янына килеп утырды.

– Мин үзем дә иртәгә таң белән озын юлга кузгалырга торам, Мөхәммәтҗан әкә, – дип башлады Габдрәшит хаҗи, сүзне еракτанрак урап. – Гаиләмне Казанга илтеп куям, аннан, җай чыккач, Истанбулга алдырырмын, инша Аллаһ! Бәлки, минем хәлләрне ишеткәнсеңдер – үзем дә жандармнардан качып йөрим, чөнки мәхкәмә төрмәгә ябарга дип карар чыгарды...

Мөхәммәтҗан карт уңайсызланып куйды, менә бит, башта кешенең хәлен сорамыйча, үзенекен сөйли башлады! Һай шул авыл акылын, әйтерсең лә аның кайгысы гына кайгы, аның эше генә эш! Ә менә шундый гыйлем иясе төрмәгә хөкем ителеп, качып йөрергә мәҗбүр икән бит... Хәер, Тара мәчетендәге теге чепи күз нидер сөйләп маташкан иде бит, качып йөри, дигән иде... Димәк, белеп сөйләгән икән...

– Син тагы кичер инде мине, хәзрәт, – дип, ул икенче тапкыр гафу үтенде. – Хәлеңне сорамыйча, үземнекен сөйли башладым, синеке минекеннән дә авыррак булып чыкты...

– Без барыбыз да бер хәлдә, Мөхәммәтҗан әкә, – дип дәвам итте Габдрәшит хаҗи. – Без үз илебездә качак хәлендә, теләсә кайчан тотып, зинданга ябарга мөмкиннәр... Ул гасырлар буе шулай булды, алга таба әле тагы да куркыныч булачак, эшләр шуңа таба бара. Мин теге вакытта мәчеттә әйтеп бетермәдем, чөнки анда да озын колаклар булырга мөмкин, бу илдә әле канлы инкыйлаблар көтелә... Бишенче елгы халык күтәрелешеннән алар бик курыкты, хәзер рәттән – урысын-татарын, украинын-ләхен, җәбрәен-мөселманын төрмәләргә утырта башладылар. Авыз ачып бер сүз әйтергә ярамый, син хөкүмәткә, патша галиҗәнапләренә каршы икән, дип, килеп алып китәләр һәм ябып та куялар. Газеталар ябылды, думалар куып таратылды, инде чират мәчет-мәдрәсәләргә дә җитеп килә...

– Анысына ук бармаслар инде, хәзрәт, мәчет-мәдрәсәләрнең тыны да чыкмый бит, ак патшага дога кылып утыралар, – дип, тагы бераз каршы төште Мөхәммәтҗан карт.

– Синеке дә дөрес, ак патшага дога кылган урыннар да күп, – дип, моңсу гына елмаеп куйды Габдрәшит хаҗи. – Бәлки, башта аларына тимәсләр дә, әмма чират барысына да җитәчәк – тарих шуны күрсәтә... Татарда хәзер шуларны күрүчеләр, чын тарихны язучылар, халыкка аңлатучылар күренә башлады. Цензорлар гына бу дөреслекне сызып бетерә алмыйлар, татарның күзләре ачылып килә – менә нәрсәдән курка ул карагруһлар! Менә нәрсә өчен милли матбагабызны, дини уку йортларыбызны юк итәргә телиләр һәм шул кара эшкә тотындылар да инде!

Сөйләшү шактый озакка сузылды, сүзгә уллары да катнашып китте, ул Мөнир-Әхмәт исемле икән, үсмер кызлары Фәүзия атлы булып чыкты. Менә алар да туып-үскән урыннарыннан кубарылып чыгып китәргә җыеналар икән, иртәгә иртүк юлга кузгаласылар ди. Шул исенә төшкәч, Мөхәммәтҗан карт тагы үз мәсьәләсенә күчте, аннан кузгалырга уйлады.

– Безгә нишләргә соң, хәзрәт? – диде ул, читкә-чатка кереп тормыйча. – Халык икегә бүленде бит, бөтен авыл купты, әле мондый хәлнең булганы юк иде, кыямәт диярсең...

– Китәргә ниятләгән кешеләрне туктату дөрес булмас, Мөхәммәтҗан әкә, – диде Габдрәшит хаҗи. – Һиҗрәт бит ул, иманны, динне саклап калу өчен, Аллаһ ризалыгы өчен дингә ирек булган урынга күчеп китү... Госманлы дәүләте, килегез, дип тора, еллар буе артыннан йөреп, тиешле документлар алынды, юлга чыгуның көне-сәгате билгеләнде – ураза гаетеннән соң, дип торалар... Дөрес, юл мәшәкате җиңел булмас, кышка каршы бит. Патша хөкүмәте махсус шулай сузды, кирәкле кәгазьләрне кышка таба юлга чыга торган итеп бирде. Мөгаен, шуннан куркып, туктап калырлар, дип уйлаганнардыр. Инде тагы да сузсак, юллар бөтенләй ябылырга мөмкин, чөнки дөньяда зур сугышлар, фаҗигаләр көтелә, китсәк, хәзер китеп калабыз, аннан капкалар ябылачак.

Бу сүзләрдән соң Мөхәммәтҗан картка да куркыныч булып китте, чөнки Габдрәшит хаҗиның буш сүз сөйләмәгәнен ул яхшы белә иде. Бөтен дөньяны әйләнеп чыккан, ничәмә-ничә тапкыр Мәккә-Мәдинәләрдә булган, Төркиядә һәм Япониядә патшалар белән кара-каршы утырып сөйләшкән, монда да ничәмә-ничә газет-журналлар чыгарган, сәяси фиркаләр төзеп йөргән, мөфти-казый дәрәҗәсенә кадәр ирешкән, төрмәләрен дә күргән Габдрәшит хаҗи бит ул! Ул белми сөйләмәс, начар киңәш бирмәс. Әмма, әмма Мөхәммәтҗан картның да үз кайгысы кайгы бит, ничек шул зәгыйфь баласын йөрәгеннән өзеп чит-ят җирләргә чыгарып җибәрсен ул?!

Аның борчулы уйларын сизгәндәй, Габдрәшит хаҗи үзе яңадан бу сөйләшүгә әйләнеп кайтты.

– Кызың өчен дә бик борчылма, Мөхәммәтҗан әкә, – диде ул. – Бәлки, менә шушы телсез-чукрак кызыңнан туган нәсел синең бердәнбер догачыларың булыр әле, Аллаһ белүче! Монда калганнарда дин кайгысы булмаячак, баш кайгысы булачак, бәндәләр исән калу турында гына уйлаячаклар, әмма күпләр харап булыр... Сугышлар, ачлык, төрмәләр, бер гаепсез кешеләрне, бигрәк тә, дин тотучыларны үтерүләр – аларның иге-чиге булмаячак, Мөхәммәтҗан әкә... Бу илдә гасырлар буе күргән газапларыбыз әлеге фаҗигаләр алдында кечкенә булып калачак...

Габдрәшит хаҗи кыйбла якка ачып куелган тәрәзәгә карап сөйли дә сөйли, әйтерсең лә анда күк мөнбәренә куелган китапны укый, бәндәләрне шул хакта кисәтә... Зур укымышлы, мәһабәт гәүдәле, сакалы агарып килә торган бу ил картының сүзләренә ышанмау мөмкин түгел... Мөхәммәтҗан картның да күңелендә бер генә уй бөтерелә башлады – киткәннәр котыла, калганнар тотыла икән... Язмыш аларны, бугазларыннан эләктереп алып, кара гүргә салмакчы була икән... Ярый да әле анда иман кәлимәсе белән, мөселман булган хәлеңдә күчсәң, андый болганчык заманда барысы да онытыла бит!

– Аллага тапшырдык инде, хәзрәт, ни булса да ил белән күрербез... Киңәшкисәтүләрең өчен зур рәхмәт, ни булса да, Аллаһ язган булыр! Әйткәнемчә, мин үзем китмим, нишлисен һәркем үзе хәл итәр. Бер генә үтенечем бар – кызымны... Хөснибикәмне ярдәмеңнән, догаңнан ташлама...

– Хөснибикәңне синең догаларың саклар, Мөхәммәтҗан әкә! Дөньяда иң зур дога – атаның баласына догасы. Бик кайгырма, ут йотма, баштарак авыр булса да, янында синең кыз һәм ир туганнарың да булачак бит, ярты авыл анда булачак! Аллага тапшырып, тәвәккәлләргә кирәк, безнең бабаларыбыз дин-ислам хакына җылы якларны Себергә алыштырганнар, ә монда – киресенчә – боз салкыныннан кояш нурына таба китә бит кешеләр! Ислам нурына таба! Моннан да зур бәхет була аламы?!

Бу сүзләрдән соң Мөхәммәтҗан картның да күңеле тынычланып китте, ул күңеленнән генә Хөснибикәсенә фатихасын бирде. Инде кузгалырга дип торганда, Яланкүлдән Юанбаш Мөхәммәди һәм тагы берничә ир-ат килеп керде. Мөхәммәтҗан картның мондалыгын алар ишегалдындагы юртак атыннан ук белгәннәр иде, шуңа күрә аптырамадылар. Ә менә аның тыныч кына чәй эчеп утыруын күреп гаҗәпкә калдылар, Мөхәммәтҗан карт Яланкүлдәге кебек нәгъра ормый, шауламый, язмышы белән килешкән кебек күренә... Габдрәшит хаҗи янында башка төрле була да алмыйсың, ул – теләсә кемне ышандыра, үз артыннан алып китә торган шәхес, һиҗрәткә төп каршы кеше Мөхәммәтҗан карт та, әнә, икенче кешегә әйләнгән...

Тагы кул биреп күрешүләр, кочаклашулар, хәл белешүләр китте, тагы өстәлгә сый-хөрмәт чыкты, вакыт сузылды да сузылды. Юанбаш Мөхәммәдиләр Габдрәшит хаҗиның иртәгә китәсен белгәннәр дә тагы шул һиҗрәт турында киңәшергә, документларны күрсәтергә дип килгәннәр. Юлга кузгалуны ноябрь уртасы, декабрь башы дип тәгаенләделәр, ул вакытта ураза да беткән булачак, юлларга кар да төшәр, әле аның Умба-Омскиена чаклы да ике йөз чакрымнан артык ара бит. Умбада кайда тукталырга, нинди поездга алдан заказ бирергә – барысы турында да киңәштеләр, җаваплы кешеләрне билгеләделәр. Ә Истанбулда аларны Габдрәшит хаҗи үзе каршы алачак, анда инде барысы да сөйләшеп куелган, мөһаҗирләрнең килгәннәрен генә көтәләр ди...

Шушы сөйләшүләрдән соң, ирләрнең күңелләре күтәрелеп китте, Мөхәммәтҗан карттан кала, барысы да госманлы мәмләкәте белән хозурлана башлады, аның турында күбрәк беләселәре килеп, Габдрәшит хаҗидан Төркиядәге хәзерге вазгыять турында сораштырдылар, ул бик теләп җавап бирде.

– Госманлы иле дә кайный, җәмәгать... Анда да алда зур үзгәрешләр көтелә, чөнки яшьләр искечә яшәргә теләмиләр, хөкүмәт алдына көн дә яңа таләпләр куялар... Истанбулда бихисап газета-журналлар чыга, кем нәрсә теләсә – шуны яза, кем нәрсә теләсә – шуны сөйли... Хакимият кайда да үз-үзен яклый – анда да күп кенә яшь сәясәтчеләрне төрмәләргә утырттылар, илдән кудылар...

– Соң, анда да шул хәл булгач, нигә туган илне госманлыга алыштырырга соң? – дип сораганын сизми дә калды Мөхәммәтҗан карт.

Башкалар да куркып, сагаеп калдылар, алар шул төрмәләрдән качып, бу илдән китәләр бит инде, баксаң, анда да шул ук хәл икән!

– Әйе, анда да шул ук хәл, – диде Габдрәшит хаҗи, аларның уйларын сизгәндәй. – Әмма анда дингә тимиләр, мәчет-мәдрәсәләрне япмыйлар, муллаларны төрмәгә утыртмыйлар, синнән урыс-кяфер ясарга тырышмыйлар... Хәзергә шулай, алдагысын бер Аллаһ белә...

Җыелган халык җиңел сулап куйды, иң мөһиме – дингә тимиләр икән! Алар шул дин-ислам хакына гына шушы озын юлга – мәңгелек юлга кузгала бит... Шушы туып-үскән якларыннан, Себернең карлы-буранлы кышларыннан, мең

төрле сайрар кошларыннан, якын туганнардан, ата-бабаларның каберләреннән аерыла бит! Аларның бу моңсу уйларын сизгәндәй, Габдрәшит хаҗи тагы дәвам итте:

– Төрекләр уку-укытуга бик зур игътибар бирә башладылар, гарәпкә генә ябышып ятмыйлар, чит телләр өйрәнәләр, французча белү бик модада, – диде ул. – Балаларыгызны теләсә кайсы уку йортларында укыту мөмкин булачак, аларга зур дөньяга юллар ачылачак, инша Аллаһ! Төрек халкы бик тырыш, җиргә ябышып ята, анда бар нәрсә үсә – карбызы да, әфлисуны-йөземе дә, җәннәт ризыклары булган инҗире, зәйтүне дә...

– Арпа-бодай бармы соң, анда да бәрәңге утырталармы? – дип сорап куйды бер авыл агае.

– Иген дә чәчәләр, яшелчә-җимешен, бәрәңгесен дә утырталар... Дөрес, анда һәр тарафта үз ризыгы, Шам тарафында, ягъни эссе якларда, Анадалада инҗир-йөзем, армут-анар кебек затлы җимешләр тиз өлгерсә, рум тарафында, Конья тирәләрендә салкынча була, анда иген игәләр, яшелчә үстерәләр.

– Безгә соңгысы яхшырак икән, – дип сүзгә кушылды Юанбаш Мөхәммәди. – Безгә, Себер халкына, салкынчарак җир кирәк, хәзрәт... Безнең халык андый эссегә күнекмәгән, авыр булыр... Хөкүмәт белән сөйләшкәндә, шул рум тарафы дигән урынны тәгаенләсәң иде...

– Үзем дә шулайрак уйлап торам, – диде Габдрәшит хаҗи. – Бик борынгы, бик тарихи урыннар ул Конья тирәләре, төрекләрнең изгеләштерә торган җирләре... Аларның беренче дәүләтләре, башкалалары да шунда булган... Анда бөек акыл иясе Мәүлана хәзрәтләре җирләнгән, мәчете-мәдрәсәсенә хәтле саклана. Дөрес, Коньяның үзендә зур сулар юк, әмма бераз арырак китсәң, суы да, яшеллеге дә бар. Казан татарлары исә Искешәһәр тирәсенә урнашканнар, баргач, үзегез барысын да карап, йөреп чыгарсыз, бер урында тукталырбыз, инша Аллаһ!

Икенде вакыты кереп килә иде, барысы да рәхмәт әйтеп, урыннарыннан кузгалды, намазны янәшәдәге мәчеткә кереп укырга булдылар. Намаздан соң Габдрәшит хаҗи үзендә калырга тәкъдим итсә дә, аларның иртәгә иртүк ерак юлга чыгасыларын уйлап, Мөхәммәтҗан карт та, Юанбаш Мөхәммәди һәм аның белән килүчеләр дә рәхмәт әйтеп баш тарттылар. Ул кичне юлга кузгалмадылар, мәчет янәшәсендәге мәдрәсәгә кереп кундылар. Габдрәшит хаҗи әле анда кереп тә алар белән шактый сөйләшеп утырды, ахшам, ястү намазларын да бергәләп укыдылар. Шулчак Мөхәммәтҗан карт үзен мәчеттә каршылаган Аубаткан кешесенең гел Габдрәшит хаҗи артыннан тагылып, күзәтеп йөрүен шәйләде, бу хакта хәзрәтнең үзенә дә әйтте. Габдрәшит хаҗи үзе дә моңа игътибар иткән булган икән, шуңа күрә өйдәге кебек артыгын сөйләмәде, аларга да саграк булырга кушты. Шуны гына көткәндәй, Юанбаш Мөхәммәди ук кебек атылып чепи күз янына барды, авыл турылыгы белән, ярып та салды:

– Син нәрсә, чепи Исмай, һаман безгә тагылып йөрисең? – диде ул, аны зур гәүдәсе белән бер читкә кысрыклап. – Синең турыда төрле сүзләр йөри бит, тәти егет! Теге йорттагы абзыйлар тирәсендә дә күргәлиләр ди сине...

Исмай ябык гәүдәсе белән аның көрәктәй куллары астыннан чыгып ычкынмакчы булды, үзе нидер мыгырданды, ризасызлык күрсәтте.

– Кара аны, егет, – диде Юанбаш Мөхәммәди, бала башыдай йодрыкларын аның борын төбендә уйнатып. – Кара аны, Габдрәшит хаҗиның башыннан бер генә бөртек чәче төшсә дә, үз башың белән җавап бирәсең! Ишеттеңме, аңладыңмы?

Аубаткан Исмай аның кулыннан ычкынып китте, һәм шул чагында аяк астына чыңгылдап нидер килеп төште. Барысы да лампа яктысында шуңа текәлделәр, Исмайның аяк астында җиз тәре ялкылдап ята иде...

– Менә эш нәрсәдә икән... – дип куйды Юанбаш Мөхәммәди. Аннан,

җирәнгәндәй, тәрене аягы белән тибеп җибәрде. – Бар, исән чакта ычкын моннан, югыйсә, болдыр баскычына асып куям үзеңне, хәшәрәт...

Исмай мүкәләп тәресен эзләп тапты, аны тиз генә куенына яшерде һәм, артына да борылып карамыйча, ашыга-ашыга чыгып китте.

Бу хәлдән барысы да аңга килә алмый тордылар, беренче булып сүзне Мөхәммәтҗан карт башлады.

– Харап булган егет, динен саткан, кяфер булган, – диде ул, авыр сулап.

– Яшьтән шушы Тарада, урыс арасында бөтерелде ул, – дип дәвам итте Юанбаш Мөхәммәди. – Югыйсә, атасы Габдрахман абзый да начар кеше түгел иде бит... Гомер буе үз хезмәте белән көн күрде. Ә менә улын кулдан ычкындырган, Исмәгыйльдән Иванга әйләнгән егет, адәм хурлыгы...

Моңа кадәр бу хәлләрне авыр сулап, дәшми генә күзәткән Габдрәшит хаҗи да сүзгә кушылды:

– Бер татар баласының үз иреге белән муенына тәре тагуында барыбызның да гаеп бар, җәмәгать, – диде ул. – Димәк ки, милләт белән, халык белән эшләп бетермәгәнбез... Хәзер бит теге заманнар түгел, муенга тәрене көчләп асмыйлар. Димәк ки, егетне ышандыра алганнар, үз диннәренә аударганнар... Бәлки, ниндидер куркытулар, янаулар да булгандыр, бәлки, закон каршында ниндидер гаебе бардыр, шуннан котылу өчен бу юлга баргандыр... Аллаһу әгълам, Аллаһ белүче. Алда әле мондый хәлләр күп булачак... Менә шуңа күрә, иманны саклап калу өчен, һиҗрәткә кузгала инде халык.

Икенче көнне мәчеттә иртәнге намазны укыгач, һәркем үз юлына кузгалды – Габдрәшит хаҗиның гаиләсе – Казан ягына, Яланкүлләр – авыл тарафына... Аубаткан кешесе аларны чат башыннан борылганчы карап калды, аннары ашыга-ашыга полиция идарәсенә, жандармериягә юнәлде, аның үз эше иде... Тиздән авылда, тагы берничә елдан шушы Тарада, мәхкәмәдә бу бәндә белән кабат очрашасыларын Габдрәшит хаҗи да, Мөхәммәтҗан карт та уйларына да кертә алмыйлар иде...

## Туганнар белән соңгы табын

...Ул елның уразасы көз аена туры килде, әллә туган якларда соңгы ураза булганга, әллә көннәр шулай сагыштай сары торганга, халык аны үзенә бер бирелгәнлек белән тотты. Авыл халкының бер өлеше биш вакыт намаз укымыйча, җомга намазларына гына йөрсә дә, уразаны монда беркем дә калдырмый, кемдер Алладан куркып, кемдер кеше сүзеннән оялып тота... Яланкүлдә дә шулай – рамазан аенда бөтен авыл белән бергә сәхәргә торалар, бөтен авыл белән бергә кичен авыз ачалар... Ул авыз ачтырулар быел бигрәк тә үзәк өзгеч булды – әллә бәйрәм, әллә бәхилләшү, хушлашу – соңгы тапкыр бергә булган мәҗлесләр кебек иде алар. Туган-тумачалар, бер оч-урам халкы шулай бер-берләренә йөрештеләр, бүләкләр бирештеләр, бер-берләренә иң җылы, иң кадерле сүзләрен әйтеп калырга тырыштылар. Һиҗрәткә каршы эшләүчеләр дә бу айда тынып торды, чөнки инде буласы булган, китүчеләрнең документлары кулларында, мал-мөлкәт сатылган, барысы да гаеттән соң олы юлга кузгалуны көтәләр...

Мөхәммәтҗан карт та бу айда гел кызы Хөснибикә белән бергә булырга тырышты – йә ифтарга, дигән булып, үзенә чакырды, йә бүләк-санакларын күтәреп, кияве өенә барып җитте. Кияве Салих элек бабасының тормышларына артык кысылып йөрүен, кызын калырга үгетләвен өнәп бетермәсә дә, ураза вакытында аларга сүз әйтмәде, ул да ата белән кызның соңгы күрешүләре икәнен яхшы аңлый иде. Ә Хөснибикә әле үзе балалар кебек, иренең бераз ирек бирүен сизүгә, чакырмыйча да атасы йортына чыгып йөгерә, аның белән

җитәкләшеп, Ырыслы күл буена чыгып китә, яшь колынчык кебек, сары яфраклар өстенә ятып ауный, әйтерсең лә туган якның бөтен исен-тәмен тәненә-җанына сеңдереп калырга тырыша...

Хөснибикә кечкенәдән әтисенең иң яраткан кызы булып үсте, бәлки, моңа баланың телсез-чукрак булуы, шуның белән башкалардан аерылып торуы сәбәпче булгандыр. Әнисе дә аны үлгәнче кулларыннан төшермәде, авырлы чакта да Хөснибикәсен җаныннан артык күреп яратты, бар көчен, җылысын, бар мәхәббәтен аңа бирде. Хөснибикә үзе дә яраттыра торган бала иде шул! Ул түгелергә торган яшькелт зур күзләр, дисеңме, ул мәрмәр кебек ак йөз, ап-ак тән, ул карлыгач канатыдай елкылдап торган озын кара чәчләр... Хәер, аның анасы Таһирә дә нәкъ шундый иде бит – авылда гына түгел, бөтен Себерендә иң гүзәл бичә! Дөрес, ул бохаралы түгел, җирле себер татарларыннан, аларның да әле иң борынгы кабиләләреннән – саргатлардан. Себер гомер-бакый алар кулында булган, бик гаярь-гайрәтле, сугышчан, югары мәдәнияткә ия халык булган алар. Нигездә, Ишимнең Иртышка коя торган тамагында яшәгән бу саргат татарларын беркайчан да көч белән җиңә алмаганнар, ә хәйлә һәм мәкер белән тозакка керткәннәр. Керәшен кыры – шул бөек кабиләнең юкка чыгуына бер фаҗигаи мисал бит инде...

Менә шул саргат кызы Таһирәне Ишим-Тамак якларыннан кодалап алып кайткан иде Мөхәммәтҗан. Тара-Тубыл юлы өстендәге бу борынгы кала аша үтеп барганда, мулла өендә күргән иде ул аны. Янәшәдәге Олы Бүрән авылыннан, ятим бала, диделәр. Инде олыгаеп барган, «карт егет» хисабында йөргән Мөхәммәтҗан күрде дә бу кыз баланы, тынсыз-хушсыз калды – ул аның гомер буе эзләгәне һәм көткәне иде... Әйтеп-сөйләп бетергесез тышкы матурлыгы өстенә, аның көмеш нур сибеп торган йөзе, нәни генә ап-ак куллары, фәрештәдәй тыйнаклыгы Мөхәммәтҗанны бер күрүдә гашыйк итте. Ул, тәвәккәлләп, кызны хатынлыкка сорады. Мулла хәзрәтләре аның туган тиешлесе икән, ул, әлбәттә, Яланкул имамының теләгенә каршы килмәде, никахлар укып, кызны биреп тә җибәрделәр. Яхшы җиргә, мөселман-татарлар арасына, мулла йортына килен булып төшә, дип куанып та калдылар әле... Мөхәммәтҗан калымны мулдан бирде, ул бу урман гүзәле өчен бар байлыгын бирергә әзер иде. Ә Таһирәсенең, ятимәкәйнең, әллә ни бирнәсе дә юк иде – бер төенчек чүпрәк-чапрак инде шунда. Аның каравы беләгендәге борынгы көмеш беләзеге дөнья бәясенә торырлык затлы һәм сирәк хәзинә иде!

Фирүзә ташлар белән бизәлгән ул көмеш беләзек Таһирәгә мәрхүм әнисеннән калган булган, ә аның нәселе Саргат солтанга барып чыга. Ул исә теге шомлы елларда ук башкисәр Ермакка каршы сугышта шәһит киткән, каласы туздырылган һәм яндырылган, гаиләсе исә кара урманнарга качып кына исән калган. Ире үлгәч, хатыны Тукбикә халыкны басып алучыларга каршы яуга күтәргән, әмма урыс ядрәсе аны Иртыш елгасы буйларында куып тоткан, су эчендә юк иткән... Тукбикә турында себер татарларында бик борынгы җырбәетләр дә саклана, үзе дә шушы нәселдән булган Таһирәсе дә аны белә иде.

Алыста ла йирдән башын алган
Иртыш суы шаулап агатыр.
Шаулап та гына аккан суныңтайын
Күземдән канлы йәш таматыр.
Агач үсте Себер йиренә,
Урыс килде татар иленә.

Күрәлмадым синең буйларыңда,
Колач ташлап, Тукбикәм йөзгәнен.
Аккош канатыдай ак җанына
Явыз урыс мылтыгын төзәгәнен.
Урман басты Себер йирләрен,
Кяфер алды татар йирләрен...

Әйе, Себердә бу бәетне һаман да әйтәләр, ә менә Хөснибикәсе әнисе кебек аны моңлы итеп башкара алмый шул инде, тәкъдир аны тавышсыз иткән. Ә менә Таһирәсе кулындагы көмеш беләзекне Саргат солтанбикәсеннән калган мирас,

дип сөйлиләр иде, ул аны үлгәндә дә салмады... Хәзер ул беләзек Хөснибикә кызында, ичмаса, ерак илләрдә анасының төсе итеп кияр, колынкай...

Мөхәммәтҗан карт, сагышлы уйларына бирелеп, өйгә кызы Хөснибикә кергәнен сизми дә калды. Ул аңа сокланып та, кызганып та озак карап торды – нәкъ әнисе инде бу бала, нәкъ аның Яланкүлгә килен булып төшкән вакытындагы кебек. Күлдәй яшькелт күзләрен камыштай озын керфекләре чорнап алган, ак мәрмәр йөзендә нindider илаһи нур балкый, елмайганда исә күк капуслары ачылган кебек була... Телсез-чукрак булса да, авылда аңа кызыгып караучы егетләр шактый иде, кияүне исә кыз түгел, аның атасы Мөхәммәтҗан үзе сайлады, Хөснибикәнең кемгә кияүгә чыгасын ул хәл итте. Һәм менә шул Салих хәзер аның фәрештәдәй баласын җир читенә алып китеп бара...

Мөхәммәтҗан картны тагы авыр уйлар басты, тагы шул һиҗрәт, кызыннан, туганнарыннан аерылу хәсрәте җанын изде. Хөснибикә дә аның уйларын сизгәндәй, карт атасының күкрәгенә башын куйды, күзеннән энҗе яшьләре тәгәрәп төште... Ул күңеле белән атасының борчылганын күптән сизенә, ире белән шул хакта ачуланышканнарын да хәтерли, сүзләрен ишетмәгәч, бу борчылуның сәбәпләрен белми... Әмма ул күрә, сизә – аның тормышында нидер үзгәрергә тора, бу үзгәреш аңа гына түгел, күп кешеләргә кагыла, чөнки ярты авыл урыныннан купкан, һаман нидер җыялар, саталар, нәрсәгәдер әзерләнәләр. Ире Салих та малтуарны сатып, төенчекләрне төйнәп куйды, Хөснибикәнең сорау белән мөлдерәп тулган карашына кулын селтәп кенә җавап бирә. Әтисе аңлатырга тырыша, алар кечкенәдән кул хәрәкәтләре белән сөйләшергә өйрәнделәр, әмма ул да аңлатып бетерә алмый, ниндидер ерак юлны күрсәтә... Тик Хөснибикә ул юлның кая алып барганын белми, ул урман юлларын күзен йомып та таба, күрше авылларга үзе генә барып кайта ала, әмма аннан да ерактa дөнья барын белми...

Ул арада икенде намазы вакыты җитте, Мөхәммәтҗан карт камәт төшереп намазга басты. Хөснибикә дә әтисе артына килеп басты, чөнки әле әнисе исән вакытта ук аны намазга өйрәтеп калдырган иде. Телсез-чукрак кызының бик сизгер, һәр хәрәкәтне кабатлап баруын күреп, Таһирә аңа гарәп хәрефләрен язып өйрәтә башлады, иреннәрен бөрә-бөрә, аларның әйтелешен аңлатырга тырышты. Башта Мөхәммәтҗан моңа каршы булды, телсез-чукрак кеше, хәрефләрнең әйтелешен ишетмәгәч, аларны үз теле белән кабатлый алмагач, берни дә килеп чыкмас дип уйлады. Әмма кечкенә кызчык әнисенең һәр хәрәкәтен, бармак очларының, иреннәренең, йөз сызыкларының һәр тибрәнешен карап, йотып, сеңдереп барды, аһылдый-уһылдый аның артыннан кабатлады. Иртәнге һәм төнге намазлардан кала, ул әнисе янына басып, аның бар хәрәкәтләрен кабатлады, намазлыгына ябышып ятты... Аның ничек укыганын, нәрсә укыганын бер Аллаһ кына белә, әмма телсез-чукрак баланың, нәни кулларын күккә күтәреп дога кылуын күргәндә, олылар да елый иде...

Әнисе үлгәч, Хөснибикә намазны атасы артына басып укый башлады, ул эш белән мавыгып онытылып китсә, кызы аны кулыннан тартып намазлык янына алып килә иде. Үсә төшкәч, Хөснибикә олылар белән ураза тота башлады, әнә быел да, авырлы булуына карамастан, уразага кергән. Бүген Мөхәммәтҗан карт аны һәм һиҗрәткә җыенган кыз туганнарын ифтарга – авыз ачарга чакырды, бәлки, бу соңгы мәҗлесләре дә булыр, дип, тагы күңеле тулды. Икенде намазы бетеп, бераз вакыт узуга, өйгә бер төркем хатын-кызлар килеп керде, алар абыйлары белән шау-гөр килеп, кочаклашып күрештеләр, ахшамга кадәр бераз сөйләшеп алырга булдылар.

– И, газиз кыз кардәшләрем, бәлки, бу безнең бергәләп соңгы утыруыбыздыр, олы юлга кузгалыр алдыннан сезгә әйтер сүзләрем бар, – дип башлады Мөхәммәтҗан карт.

Сеңелләре Мәхсүрә белән Мансура аңа якынрак килеп утырдылар, Мәхсүрәнең үсмер кызы Зөлбану Хөснибикә белән бераз читтәрәк урнаштылар. Элегрәк абыйлары һиҗрәт турында ишетергә дә теләмәгәч, бу хакта әле кыз туганнары белән җитди сөйләшүнең булганы да юк иде. Әмма соңгы вакытта Мөхәммәтҗан карт та тәкъдирдә язылган белән килеште кебек, һиҗрәткә каршы сөйләгәне ишетелми башлады. Бер караганда, абыйларын да аңларга була – гарип кызы, барлык туганнары гаиләләре белән кубарылып, мәңгегә туган якларны ташлап китәләр бит... Себер татарларында туганлык җепләре бик көчле, аның язылмаган катгый кануннары да бар. Абыйлары Мөхәммәтҗан – хәзер аларга ата урынына калган кеше, ягъни, аның сүзе закон булырга тиеш. Әмма Мәхсүрә белән Мансураның ирләре дә бар бит әле, һәм соңгы сүзне барыбер алар әйтә. Ә алар, китәбез, диделәр. Ә энеләре Сахибзадә үзе хәл итте китәсен, беркем белән киңәшеп тормады.

– Сезгә кызым Хөснибикәне әманәт итеп тапшырам, – дип сүзен дәвам итте Мөхәммәтҗан карт. – Аның хәлен үзегез беләсез – кеше ишеткәнне ишетми, кирәген аңлатып сөйли алмый... Монда без аның белән аралашырга өйрәнгән идек инде, анда балакаема бик авыр булачак... Кияү дә аның хәлен аңлап бетми әле, матурлыгына, тыйнаклыгына карап өйләнде... Анда баргач, карашы үзгәрмәсме, балам чит җирдә ятим калмасмы – менә шул уйлар өзгәли минем үзәгемне...

– Алай бик бетеренмә, абый, – диде Мәхсүрә, аны юатып. – Ялгызы чыгып китми бит – янында ире бар, без барыбыз да анда... Әнә Зөлбану да аның белән бик яхшы аңлаша бит! Алар монда да гел бергә булдылар, анда да аерылмаслар, Аллаһ теләсә!

Барысы да борылып Хөснибикә белән Зөлбануга карадылар, алар исә, дөньяларын онытып, үзләре генә белгән хәрәкәтләр телендә мәш килеп сөйләшеп утыралар иде. Мөхәммәтҗан карт та, беренче тапкыр күргәндәй, сеңлесенең кызына текәлде – ул коеп куйган Хөснибикә иде! Шундый ук зифа буй, ак йөз, шундый ук зур яшькелт күзләр... Охшаса да охшар икән туган туганга! Әле бер-берләрен аңлыйлар да икән бит, кайчан, каян өйрәнеп өлгергән бу Зөлбану балакай Хөснибикәнең телсезләр телен?

Мөхәммәтҗан карт шулай дип сораганын сизми дә калды. Зөлбануның озынча ак йөзе алсуланып чыкты, олылар сүзенә кушылырга уңайсызланып, кыска гына җавап бирде:

– Туганым бит ул минем, әкә, – диде ул. – Без бит бергә үстек, аннан күреп өйрәндем инде...

Мөхәммәтҗан картка бераз җиңел булып китте. Юк, аның туганнары Хөснибикәне беркайчан да ташламаслар, Аллаһ теләсә!

– Рәхмәт, кызым, туганлыкны аңлыйсың икән, мәңге шулай булыгыз! Соңгы сулышыгызга кадәр бер-берегезне ташламагыз, бу – минем сезгә васыятем, әманәтем! Монда без күп идек, һәр авыл саен туган-тумачаны табарга була... Анда сез аз, чит кавемнәр арасында, аларның холык-фигыльләрен белмисез... Нәрсә генә булса да, дөньялар кайсы якка үзгәрсә дә, сез үзгәрмәгез – бер-берегезгә таяныгыз, бер-берегезне сатмагыз, бер-берегезне саклагыз һәм яклагыз!

– Үзең дә тәвәккәлләмисеңме соң, абый? – дип сорады сеңлесе Мәхсүрә, аның йомшаруын сизеп. – Син бит безгә атабыз урынында калган кеше, анда да барыбызны бер канат астында җыеп тотар идең...

Кыз туганының шулай олылап дәшүенә Мөхәммәтҗан картның күңеле булды.

– Рәхмәт, кардәшем, мин хәзер дә сезнең өчен олы абый урынында да, ата урынында да, – диде ул. – Теләсә кайсы вакытта яныма кайтып сыена аласыз – үзем үлгәндә дә сезне яшәтер өчен тырышырмын... Мин китмим инде, монда калам... Үз өемдә, үз нигеземдә, үз илемдә калам... Ни күрсәм дә, шушында күрермен... Өй

тулы менә бу сабыйларыма монда нәселне дәвам итәргә язган, күрәсең... Җиңгәгез дә авыру, үзегез күреп торасыз, балаларда да шаукымы бар... Олыгайган көнемдә итәк тулы бала, шөкер Аллаһка! Безгә монда яшәргә җиңелрәк булачак, Аллаһы Тәгалә шуларны аякка бастырырлык хәерле гомер бирсен инде.

Әйе, Мөхәммәтҗан картны моннан кузгатырлык көч юк иде инде... Читтә яши дә алмас иде ул, шушы карлы-бозлы Себерен сагынып саргаер иде... Ул әйтерсең лә табигатьнең үзеннән үсеп чыккан кебек – карагайдай нык бәдән, төз буй-сын, аюдай көч, бүредәй үткенлек, тиендәй җитезлек, сандугачтай моң – барысы да бер кешедә тупланган. Шушыларны үзе белән ала алганда гына, аны урыныннан кузгатып булыр иде, бөтен Себерне – кышын-язын, җәен-көзен моннан күчергәндә генә, Мөхәммәтҗан карт китәргә ризалашыр иде...

Ул арада ахшам якынлашты, лампага ут элделәр, өй эче яктырып китте. Мөхәммәтҗан карт янәшәдәге мәчеткә юнәлде, Хөҗҗәт мулла киткәннән бирле, биредә намазларны ул укыта иде. Өйдә калган хатын-кызлар исә кече якта авыз ачарга ризык әзерли башладылар, хәер, җиңгәләренең инде көндездән үк барысы да әзер иде. Өстәлне зур якка куйдылар, кунаклар өчен генә дип тоткан бар тәмле-томлы чыкты, барысы да сабыр гына азанны көтә башлады. Көзге кояш урман артына кереп яшеренгәч, мәчет манарасыннан моңлы азан тавышы яңгырады, аны бүген Мөхәммәтҗан карт үзе әйтте. Хатын-кызлар кайсы берничә йотым су, кайсы хөрмә-җимешләр белән авыз ачтылар да, дога кылып, ахшам намазына бастылар. Хөснибикә белән Зөлбану намазны янәшә басып укыдылар, Хөснибикәнең туган нигезендә бу соңгы намазы иде... Әллә шуны сизенепме, тезләнеп сәҗдә кылганда, күз яшьләре намазлык өстенә тамды, ул бөтен җаны-тәне белән Аллаһтан үзе өчен дә, туасы баласы өчен дә, карт атасы өчен дә хәерлесен сорады...

Кичке ашка утырырга Мөхәммәтҗан картны көттеләр, ә ул бер төркем ир-ат белән кайтып керде. Мәчеттәге ахшам намазыннан бирегә ифтар мәҗлесенә энесе Сахибзадә, сеңелләренең ирләре, кияве Салих та килгән, Мөхәммәтҗан карт бик кыстагач, Юанбаш Мөхәммәди дә ияреп кайткан иде. Алар шулай бер төркем килеп кергәч, ирләргә тиз генә аерым өстәл куелды, өстәлгә тагы яңа ризыклар чыга башлады. Себер татарларының иң яраткан ризыгы өйрәдән башка мондый мәҗлесләрне күз алдына да китереп булмый, сөякле ит шулпасына киледә төелгән арпа салып пешерелә ул милли аш. Өйрәгә өстәп, өстәлгә табак-табак ат ите куела, аннан тирән эчле бәлеш чыга, көзләрен ул ярма һәм кабактан булса, кышларын инде, эре мал суйгач, ит бәлешләре пешә... Бүген дә әнә ифтар табыны пәрәмәчләрдән тау кебек өелеп тора. Аның өстенә катыгы-каймагы, балы-мае, урман җимешләре – мәмрәп торган мүк җиләкләре – торна күзе, кура-карлыганнары – барысы да көннәр буе Аллаһ ризалыгы өчен ураза тотканнарга сый-нигъмәт...

Табын янында да сүз һиҗрәт турында барды, чөнки инде ураза бетеп бара, гаеттән соң олы юлга кузгалырга торалар иде. Бәхетләренә, быел көз дә бик матур, коры килде, туктаусыз яңгырлары белән интектермәде, югыйсә, яңгыр яуса, монда авыл араларында аякланып йөри торган түгел. Инде коры, җылы көннәр артта калып, аяк асларын катыра да башлады, күлләрне боз элпәсе каплады, урманнарны ак бәс сарды... Әле бу кичтә әнә кар да төшкәли башлаган, бәлки, олы сәфәргә кузгалганчы, чана юллары да төшәр, ул чакта җиңелрәк булыр иде... Юанбаш Мөхәммәдинең әйтүенчә, Умбага кадәр атлар белән барачаклар, йөкләр-төенчекләр белән, алтмыш-җитмеш олау кирәк булачак. Олы юлга чыккач, Яланкүлләргә күрше-тирә авыллар да кушылачак, алар белән дә сөйләшенгән. Ә Умбыда аларны Мәтин бай көтеп тора, мең кеше булса да ашатам, үземдә тотам, чөнки алар Аллаһ мөсафирлары, дигән, рәхмәт яугыры! Һиҗрәтчеләр мең үк булмаса

да, аның яртысы булыр, документлар шуның кадәр кешегә әзерләнгән. Аннан Умбага аларны алырга Барнаулдан махсус поезд киләчәк, ул Одессага кадәр алып барып җиткерәчәк икән. Аннан соң инде һиҗрәтчеләр диңгездә пароход белән Истанбулга китәчәкләр икән, анда аларны көтеп торачаклар ди...

Сөйләшкәндә шулай җиңел генә тоелса да, бу сәфәрнең авыр буласын барысы да аңлый иде. Кыш көне, балалар, карт-карчыклар, авырлы хатыннар белән күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә чыгып китә бит алар... Мәңгегә, бөтенләйгә, дип чыгып китә... Юлда да, анда баргач та, төрле хәлләр булырга мөмкин, үлем-җитемнәргә дә әзер булып торырга кирәк. Иң мөһиме – бу бөек кузгалышның, бу мәңгелек китүнең Аллаһ ризалыгы өчен, иманны саклап калу өчен һиҗрәт икәнен онытмаска, шуның хакына барысына да түзәргә, сабыр итәргә... Алар шулай дип бер-берсен юатты, бер-берсен дәртләндерде һәм тынычландырырга тырышты, әмма йөрәкләрендә инде юлга кузгалмас борын ниндидер моң һәм шом бар иде…

Инде ашка дога кылып, мәчеткә тәравих намазына керер вакыт җитте. Шул чакта урам якта ниндидер чит тавышлар ишетеп, барысы да сискәнеп китте – киләсе кеше килгән, инде таралыр вакыт җиткәндә, көзге кара төндә кемнәр шулай йөрергә мөмкин? Ул арада каты итеп ишек дөбердәттеләр, керергә рөхсәт тә сорап тормыйча, ниндидер чит-ят кешеләр өйгә бәреп керде. Бишмәтләрендәге ялтыр төймәләрдән һәм башларындагы текә кәпәчләреннән аларның гади кешеләр булмыйча, хөкүмәт эшендәгеләр, полиция-жандармериядән килгәннәре күренеп тора иде. Алар арасында бер генә таныш кеше бар – Аубаткан Исмай. Көтелмәгән кунакларны күргәч, ризыкка дип сузылган куллар кире төште, һиҗрәт дип ачылган телләр тешләнде, барысы да, шомланып, бу хәлләрнең ахырын көтте. Йорт хуҗасы буларак, Мөхәммәтҗан карт алгарак чыкты һәм, татар гадәте буенча, өенә бәреп керүчеләрне табынга чакырды, әмма аның сүзләрен Аубаткан Исмаеннан башка беркем аңламады.

– Ашау кайгысы түгел монда, әкә, – дип, барысы өчен дә җавап бирде ул. – Үзегез күреп торасыз, болар – Тарадан килгән хөкүмәт кешеләре, полицайлар… Аларның тикмәгә йөрмәгәннәрен дә яхшы беләсез… Безнең кулыбызда Мөхәммәди Шиховны кулга алырга, дигән боерык бар. Аны алырга дип килдек, ә ул монда булып чыкты. Хәзер өенә барып, үзе алдында тентү уздырабыз һәм аны Тарага алып китәбез…

Аубаткан Исмайның бу сүзләре барысын да телсез калдырды. Нинди Тара, нинди кулга алу, нинди тентү? Юанбаш Мөхәммәдинең ни гаебе бар? Һиҗрәтне өзү өчен эшләнгән этлек түгелме икән бу? Ник дисәң, бөтен документлар анда бит, бөтен эшне ул оештыра, башкалар ияреп йөрүчеләр генә… Күбесенең башыннан шундый уйлар сызылып үтте, Мөхәммәтҗан карт түзмәде, бу сорауны Аубаткан Исмайның үзенә дә бирде.

– Шулай итеп, һиҗрәт сәфәрен өзәргә булдыңмы, энем? – диде ул, Исмайның каршысына ук килеп. – Барып чыкмас, Аллаһтан язылган икән, китәр алар, син генә туктатып кала алмассың…

– Соң, Мөхәммәтҗан әкә, син үзең дә каршы идең бит ул нәрсәгә?! Теге вакытта мәчеттә, бетәбез, бетәбез шул һиҗрәт белән, дигән идең! Нәрсә, сине дә сатып алдылармы бу корткычлар?

– Син, Исмайдан урыс Иванга әйләнгән мөртәт, сүзләреңне чамалап сөйлә! – дип, Юанбаш Мөхәммәди аның өстенә очып кунды. Аларның арасына, кылычларын чыңгылдатып, полицай урыслар килеп керде. Ул арада Юанбаш Мөхәммәдинең бүрәнәдәй беләкләренә богау да салып куйдылар. Бу хәлдән барысы да шашып калды. Тарадан килгән полицайлар башлыгы Юанбаш Мөхәммәдинең борынына кәгазь кисәге төртте.

– Сез патша галиҗәнапләренә каршы коткы таратуда, империянең нигезен җимерергә тырышуда гаепләнәсез, – диде ул, русчалатып.

Аубаткан Исмай аны татарчага тәрҗемә итәргә тотынды.

– Татарга тылмач кирәкми, дәшмә, надан! – дип кычкырды аңа Юанбаш Мөхәммәди. – Мин – Пётрларда патша хөкүмәте белән сөйләшүләр алып барган кеше! Үземне-үзем якларлык көчем дә, гыйлемем дә бар!

Аннан ул урыс полицаена борылды да, урысчалатып:

– Мин кайда патшага каршы сөйләп йөргән инде, анысын да белик! – диде.

Сүзгә тагы Аубаткан Исмай килеп кушылды.

– Оныттыңмыни, теге вакытта, Тарада мәчеттә сөйләгәнеңне? Безгә монда ирек юк, солтан җиренә китәргә кирәк, дидең! Татарларны бөтен җирдә кысалар, урыслар басып алганнан бирле көчләп чукындыралар, алар безне урыс ясамыйча тукталмаячаклар, дидең!

– Нәрсә, дөрес түгелмени? – дип, сүзгә Мөхәммәтҗан карт та кушылды. – Менә мин дә нәкъ шулай дип әйтәм, алайса, мине дә кулга алыгыз! Син, энем, Мөхәммәдидән үч аласың, теге вакытта муеныңдагы тәреңне тартып өзгән өчен! Анда барып әләкләгәнсең. Хәзер һиҗрәтне өзәргә тырышасың – барып чыкмас, мөртәт керәшен!

– Син, әкә, кайчаннан бирле һиҗрәт яклы соң әле? Авылда моңа иң каршы кеше син идең бит, оныттыңмыни?! Әллә үзең дә шулар арбасына утырып чыгып китәргә җыенасыңмы?

– Әйе, мин каршы идем, дөрес әйтәсең. Менә шушы гарип балам хакына, аларны илдән җибәрәсем килмәде… Ә хәзер – барыгыз, бу Алланың каһәре суккан илдән башыгызны алып качыгыз, дим! Чөнки монда калсаң, теләсә кайсы вакытта менә шушы хәл булачак – рөхсәтсез өеңә килеп керәчәкләр, кулыңа богау салачаклар, зинданга ыргытачаклар… Әле, синеке кебек, муеныңа тәре дә асарга мөмкиннәр… Китегез, балакайларым, качыгыз бу илдән, иманны, үзегезне, нәселне саклап калыгыз – миннән сезгә хәер-фатыйха!

Тара урысларына татарларның бу талашлары кирәкми иде – Юанбаш Мөхәммәдине, төрткәли-төрткәли, өйдән алып чыгып киттеләр. Аубаткан Исмай да тизрәк алар артыннан җилдертте, монда калса, Яланкүл ир-атлары аны өзгәләп ташларга мөмкиннәр иде. Өй эче, яу чыккандай, тынып, бушанып калды. Ифтар мәҗлесе өзелгән иде. Әмма иң куркынычы, Юанбаш Мөхәммәди кулга алынгач, һиҗрәт сәфәре дә өзелергә мөмкин иде… Ирләр иртәгә үк Тарага барырга, өяз түрәләре белән сөйләшергә, дигән фикергә килеп, башларын иеп, өйләренә таралдылар. Мөхәммәтҗан картның кызы, туганнары белән соңгы мәҗлесе шулай догасыз тәмамланды… Һәм бу илнең үзен дә озак елларга догасыз, имансыз, динсез, бәхетсез чорлар көтә иде…

## Татарларны төрмәдән коткару

Иртән билгеле булды – Юанбаш Мөхәммәди белән бергә, төнлә авылдан тагы берничә ир-атны кулга алып, конвой белән Тарага алып киткәннәр икән. Аларның барысын да хөкүмәткә каршы сөйләгән өчен, Рәсәйне яманлап, төрекләрне мактаган өчен гаеплиләр, ди. Имеш, халыкны Истанбулга, төрек иленә көчләп китәргә котырталар икән. Имеш, монда калсалар, аларны чукындырачаклар, урыс ясаячаклар икән...

Ничә еллардан бирле һиҗрәткә дип җыенган, соңгы вакытта инде мал-мөлкәтләрен дә сатып бетергән, бүген-иртәгә юлга кузгалырга торган халык аптырашта калды. Ничек инде ул, кулда Питерның үзеннән рөхсәт кәгазьләре була торып, шулай каршы чыгарга, һиҗрәт өчен төрмәгә утыртырга мөмкин?

Җитмәсә, ураза вакытында? Әле мондый хәлнең авылда булганы юк иде! Төнлә килеп, авыз ачып, намаз укып утырган җиреңнән өстерәп алып чыгып китсеннәр инде! Нәрсә, алар кеше үтергәнме, кеше талаганмы, хөкүмәтне бәреп төшерергә чакырганмы?! Әйе, алар хөкүмәтнең мөселман-татарларга каршы алып барган эшләреннән риза түгел, чукындыруга да каршы, урыс булырга да теләмиләр. Шул сәбәпле, туган җирләрен ташлап китәләр дә инде – иманны саклап, мөселман-татар булып калыр өчен җир читенә чыгып китәләр...

Авыл халкының моңарчы һиҗрәткә каршы булганнары да аларның хәлләренә кереп, ярдәм итә башладылар. Иң беренче эш итеп авылның үткенрәк ир-атларын Тарага юлладылар, алар анда өяз түрәләре белән сөйләшергә, кулга алынганнарга ярдәм итәргә тиешләр иде. Бик барам, дисә дә, Мөхәммәтҗан картны авылда калдырдылар, хәзер барысы өчен дә ул җаваплы иде. Кызы Хөснибикә хәсрәте дә бер кырыйдарак калды, чөнки сүз милләт хәсрәте, халык кайгысы турында бара иде... Ни генә булса да, һиҗрәтне өзмәскә, кулларында рөхсәт кәгазе булганнарга гаеттән соң әзер булып торырга кушылды. Биш-алты авылдан олаулар әзерләү башланды, моңа җаваплы кешеләр билгеләнде, бөтен халык шушы тормыш белән яши башлады...

Ул арада Тара татарлары да тик ятмады, милләтнең бөтен өске катламы – муллалар һәм ахуннар, байлар һәм сәүдәгәрләр, шәкертләр һәм һөнәрчеләр калыкты. Күренекле Айтүкә байлар Питерга, хәтта патшаның үзенә кеше юллаган, диделәр, бик күп акча түләп, адвокат та яллаганнар, ди. Ә Айтыкиннар тотынса, алар болай гына туктамый инде, бөтен шәһәрне тотып торучы, ярты дөнья белән сәүдә итүче атаклы байлар бит алар! Җитмәсә, ураза вакытында Яланкүл татарларын кулга алганнарын ишетеп, тирә-як авыллардан да Тарага кешеләр килә башлады, шәһәр мәчете һәм мәдрәсә шундый юлаучылар белән тулды.

«Бүген аларны, иртәгә безне килеп алырлармы? – дип кайнады халык. – Салымын түлибез, солдатын бирәбез, инде мал йөртергә, иген чәчәргә урын калмады, барысын алып бетерделәр, хәзер иманыбызга ябыштылармы? Бездән керәшен кыры ясамакчы булалармы? Барып чыкмас! Үлсәк үләбез, әмма мөселман-татар булып калабыз!»

Бу хәлләрне полиция бүлегендә дә шомланып күзәттеләр, охранка шымчысы Исмай-Иван исә өенә кереп бикләнде, чөнки урамда күрсәләр, татарлар аны өзгәләп ташларга мөмкин иде... Мондагы хәлләр турында хәбәр губерна үзәге Тубылга да барып ишетелгән булып чыкты, өяз начальнигына аннан телеграмма килеп төште. Баксаң, Тара татарлары инде Петербургка барып җиткәннәр, госманлыга китәргә рөхсәт биргән патша чиновниклары янында булганнар, бу хакта Истанбулга да хәбәр итеп өлгергәннәр икән. Ә бу – халыкара гауга дигән сүз! Җитмәсә, шәһәр тулы сөргенгә сөрелгән революционерлар, араларында кызыл байрак болгап йөрүчеләр дә бар, алар күтәреп кенә алачак бу каршылыкны... Өяз начальнигы үзе дә чукынган татар Исмай-Иван сүзе белән бу ыгы-зыгыга кереп батуына үкенә башлады, китсеннәр иде шунда, Төркиягә түгел, хет җәһәннәменә!

Өяз начальнигы, карт урыс, бүлмәсенә становой приставны чакыртты, чөнки бу тоткын татарлар аның карамагында, алар белән алга таба нишлисен дә шушы полиция башлыгы белән сөйләшергә-киңәшергә кирәк иде.

– Йә, нишлибез бу тоткын татарларың белән? – дип башлады ул сүзен, бүлмәсенә полиция башлыгы килеп керү белән. – Менә, Тубылдан, губернаторның үзеннән телеграмма бар, татарлар безнең өстән жалу белән Питерга хәтле барып җиткәннәр... Имеш, без монда Төркиягә китәргә теләүчеләрне законсыз кулга алганбыз икән... Хәзер Тубылда да, Питерда да бездән җавап көтәләр.

– Соң, Иван Иваныч, ул татарларның хөкүмәткә каршы сөйләп йөрүләре дә дөрес бит инде! Безнең яшерен шымчыбыз Исмай-Иван аларның артларыннан тагылып йөреп, барысын да үзе ишеткән!

– Бер сатлык татар сүзе белән генә без берни дә эшли алмыйбыз! Эш мәхкәмәгә барып җитсә, алар җиңәргә мөмкин... Үзең беләсең, монда аларның тамырлар тирән, бер Айтикиннары гына да бөтен Себерне кулда тота. Үлән арасындагы елан кебек эш итәләр ул татарлар... Юлларында торсаң, чагып алулары да бар.

Әйе, татарлар арасында Айтүкә байлар, дип йөртелгән бу нәсел Себернең иң атаклы кешеләре иде. Алар да чыгышлары белән бохарилар булып, нәселләре Күчем ханга ук барып тоташа, Динали сәетнең оныклары булып торалар, ягъни пәйгамбәрләр токымыннан. Инде алар монда ныклы тамыр җибәргәннәр, сәүдә белән Кытайларга хәтле барып җиткән кешеләр иде. Аталары Нияс Айтикин әле узган гасырда ук Тарада күн заводы, кибетләр тоткан, 1нче гильдия купец булган, Омск-Коканд кәрван юлын ачкан атаклы кеше. Аның уллары Абдулфәттах, Рәхмәтулла, Насретдин, Нәҗметдин исә тагы да еракка – Көнбатыш Европага сәүдә кәрваннары озаталар, Иртышта аларның «Работник» һәм «Тара» дип аталган үз пароходлары йөзеп йөри, ә Тарада исә зур-зур йортлары, пыяла заводлары, ризык һәм кием кибетләре бар. Айтүкә байлар шәһәр казнасына да бик зур өлеш кертәләр, ә аларның хәйриячелек эшчәнлеге турында инде әйтеп тә торасы юк – юмартлар, халыкны урыска-татарга аермыйлар! Һәм менә шушы кешеләр хәзер һиҗрәтчеләр ягына басты, әнә, патша түрәләренең үзләренә барып җиткәннәр!

– Айтикиннарның бу эшкә кушылулары начар булды, әлбәттә, – дип сүзгә кушылды полиция башлыгы. – Югыйсә, мәхкәмә өчен бөтенесе әзер иде... Хөкүмәтнең яшерен күрсәтмәсе барын да беләсең бит, Иван Иваныч, күпләп аларны моннан җибәрмәскә кушылган.

Монысын өяз начальнигы үзе дә белә иде, әмма аның шәһәрдә тавыш та чыгарасы килми. Ул полиция башлыгының губернатор тарафыннан билгеләп куелуын да яхшы белә, ә аның тел төбе – бу татарларны төрмәдә черетү. Аларны якларга тырышуын сизсә, өяз начальнигының да башына җитүе мөмкин, чөнки ул турыдан-туры Тубыл белән эш йөртә. Әмма бу эшләр Тарада зур тавыш кузгатачак, һай, давыл кубачак монда! Дөнья читендә, кара урманнар уртасында урнашкан кебек булса да, үзенең баш бирмәве һәм бунтлары белән танылган кала әле ул Тара! Пётр патшаның әмерләренә буйсынмыйча, аны антихрист дип игълан итеп, йөзәрләп үз-үзләрен яндырып үтергән раскольникларның нәселе, иске урыс динен тотучылар яши әле монда! Һәм меңләгән сәяси тоткын биредә сөргендә ята, шәһәр шырпы кабызмасаң да гөлт итеп кабынырга тора... Инде хәзер бу татарлары аяк астында бутала! Становой пристав та дөрес әйтә – аларны моннан җибәрергә ярамый, яшерен кәнсәләриянең әмере шундый.

– Чөнки алар биредә төп салым түләүчеләр, рекрут бирүчеләр, шәһәр халкын ашатучылар дип санала, – диде өяз начальнигы. – Үзең беләсең, мондагы урыс авылларыннан әллә ни көтеп булмый, Тарада да спирт заводыннан башка берниебез юк. Татарлар моннан күпләп китә башласа, шәһәрне эш белән тотып торучы Айтикиннарың да калмас, аны ашатып торучы авыл татарлары да калмас... Менә кайсы ягы да бар бит әле аның!

– Айтикиннар бу эшкә нык комачау итәчәкләр, – дип дәвам итте полиция башлыгы. – Алар патшаның үзеннән көмеш медаль алган кешеләр бит, элемтәләре бик саллы! Җитмәсә, аларның сукно фабрикаларында Рәсәй хәрбиләре өчен кием тегәләр, таныш-белешләре бик күп! Айтикиннар хәзер бу татарларны яклар өчен бөтен каналларны кулланачак, Иван Иваныч! Әмма безгә дә чигенергә ярамый, монда кем хуҗа икәнне күрсәтергә кирәк ул татарвага!

Сөйләшүдән шул аңлашылды: мәхкәмә өчен дәлилләр җитеп бетмәсә дә, бу татарларны төрмәдән чыгарырга ярамый иде. Һәм ул һиҗрәт дигәннәрен өзәргә кирәк, чөнки патша хөкүмәтенең яшерен әмере буенча, илдән күпләп күчеп китү тыелган. Алар читтә Рәсәй дәүләтенә карата кире фикер тудырырга мөмкиннәр, монда калганнарны да шуңа өндәргә, патша хөкүмәтенә каршы баш күтәрергә котыртырга мөмкиннәр. Димәк ки, һиҗрәтне өзү өчен, Яланкүлдән, Кумыслыдан, Аубатканнан, Черналыдан һәм тагы якын-тирә авыллардан ир-атларны кулга алырга кирәк булачак, алардан башка хатын-кызлары юлга кузгалмаячак, татарларда шундый тәртип. Себердә генә түгел, бөтен Рәсәйгә яңгырарлык эш кузгатырга кирәк булачак – бу татарларны пантюркизмда, панисламизмда гаепләргә, аларны госманлы шпионнары дип игълан итәргә, иң мөһиме – аларны хәлифәт төзергә омтылуда гаепләргә! Әмма моны ышандырырлык итеп эшләргә кирәк, араларыннан Исмай-Иван кебек йомшакларын чүпләп табарга, аларны мәңгелек каторга белән куркытырга һәм шушы гаепне үз өсләренә алдырырга... Яшерен охранканың моңа зур тәҗрибәсе бар иде, полиция башлыгы бу зур эштә Тубылдан да ярдәм чакырачагына ышандырды. Инде бөтенесе килешенеп бетте, дигәндә, ишек артында ниндидер шау-шу ишетелде, өяз начальнигы бүлмәсенә бер төркем кеше килеп керде. Бу – татарлар, аның да әле иң атаманнары – данлыклы Айтикиннар иде!

Өяз башлыгы аларны күптән белә һәм бу татар байлары белән яхшы мөнәсәбәттә булырга тырыша иде. Сәбәбе – аларның шәһәргә файдадан башка зыяннары тигәне юк! Киресенчә, шушы татар сәүдәгәрләре аркасында гына Тара дөньяга чыга, дөнья белән аралаша, Европадан Кытайга хәтле сәүдә юллары шушы Айтикиннар сәбәпле Тарага да кагылып үтә. Алар – шәһәрнең мактаулы әгъзалары, 1нче гильдия купецлар, Тарада гомумкитапханәгә хәтле алар үз акчаларына ачтылар! Моңа кадәр Айтикиннар өяз башлыгын һичкайчан юк-бар белән борчымадылар, ә менә бу юлы аның йөрәге кысылып куйды – җүнлегә түгел боларның кинәт килеп керүе, дип уйлады. Барысы белән дә кул биреп күрешкәч, ул аларга утырырга тәкъдим итте, ишек төбендәге хезмәткәренә кунакларга чәй китерергә кушты.

– Борчылмагыз, Иван Иваныч, без уразада, – диде Айтикиннарның өлкәннәреннән булганы, саф рус телендә. – Һәм эшебез дә бик ашыгыч һәм бик мөһим...

Ул өяз башлыгы алдына үзе белән алып кергән кәгазьләрне чыгарып салды. Тегесе аны караган арада, тагы сүзен дәвам итте:

– Полиция башлыгының да монда булуы яхшы булды әле, чөнки бу мәсьәлә икегезгә дә кагыла. Менә адвокатыбыз, ул яңа гына Питердан кайтып төште, бик мөһим хәбәр белән кайтты...

Полиция башлыгы эшнең нәрсәдә икәнен инде үзе дә чамалый башлаган иде – кулга алынган Яланкүл татарлары артыннан йөри болар! Кыяфәтләре бик җитди, үз-үзләренә ышанып сөйлиләр, ниндидер кәгазьләр күтәреп килгәннәр. Ә ничек киенгәннәр – патша сараена килгәннәрмени! Өсләрендә затлы сюртуклар, аларның кесәләреннән алтын чылбырлары асылынып тора, аякларында елкылдап торган чит ил ботинкалары, ә башларында – кара бәрхет татар түбәтәе! Менә шул түбәтәйләре һәм пөхтә сакал-мыеклары гына аларның татарлыгын күрсәтеп тора, ә калганы – барысы да Европача! Аларның кече энеләре һәм уллары хәзер шул Европа тарафлары белән – Алмания, Италияләр белән генә эш йөртәләр икән, ә Финляндия белән Балтыйк буе илләреннән кайтып кергәннәре дә юк, дип сөйлиләр. Кирәк икән, бөтен Европаны күтәрәчәк алар, Рәсәйдә татарларны кысалар, дип, дөньяны сасытачаклар... Полиция башлыгы офтанып куйды, бу татарлар белән бәйләнүенең ахыры җүнле бетмәсен аңлады.

Аның уйларын сизгәндәй, Айтикиннарның өлкәне тагы телгә килде:

– Һиҗрәткә җыенган татарларны кулга алу дөрес эш булмады, – диде ул. – Моның шулай икәнлеген, шөкер, Питерда да аңладылар. Менә бу белешмә шул хакта.

– Әмма алар патша галиҗәнапләренә каршы сөйләделәр, Рәсәйне хурладылар, халыкны хөкүмәткә каршы котырттылар! – дип, аңа каршы төште полиция башлыгы. – Бездә шаһитлар да, дәлилләр дә җитәрлек...

– Әмма алар һиҗрәткә рөхсәт бирелгән көннән бу ил ватандашлары булып саналмыйлар, – дип, аңа җавап бирде Айтикиннарның адвокаты. – Алар җиде ел буе шушы рөхсәт артыннан йөрделәр, ниһаять, аны алдылар, госманлы илендә бу татарларның киләсен беләләр һәм көтеп торалар... Хәзер аларны тоткарлыйсыз икән – халыкара конфликт чыгачак, бу хәбәр инде Истанбул газеталарында басылган!

Өяз башлыгы тирләп чыкты, мундиры бугазын буа башлады, ул үзенең бу татарлар белән бик авыр хәлдә калганын аңлады. Бер яктан – җибәрмәскә, дигән яшерен әмер, икенче яктан – тотмагыз, җибәрегез, дигән ачыктан-ачык күрсәтмә... Кайсын тыңларга? Аларга суд була калса да, дәлилләр бик йомшак, боларны җиңәрлек түгел... Ул, җавап көткәндәй, полиция башлыгына карады, анысы инде дәшмәде, чөнки әйтер сүзе калмаган иде... Айтикиннарның кечесе сүзгә кушылды:

– Иван Иваныч, без моңа кадәр сезнең белән тату яшәдек, үзегез беләсез, шәһәргә кулдан килгәнчә ярдәм иттек, – диде ул. – Инде эшләр мондыйга киткән икән, безнең дә сезгә карата мөнәсәбәт үзгәрәчәк бит, безнең дә моннан китеп баруыбыз бар... Бу татарлар төрмәгә утыртылып, һиҗрәт сәфәрләре өзелсә, без барыбыз да өстебезгә зур гөнаһ алган булабыз... Иван Иваныч, барыбыз өчен дә Аллаһ бер, барыбыз да шушы салкын Себердә җан асрыйбыз... Үзегез беләсез, татарлар дин өчен бик куркалар, чөнки узган тарихларда төрлесен күрдек... Тагы шул көннәр килер дип борчылалар. Алар бары тик иманны саклап калу өчен генә шушы авыр юлга чыга, тотмагыз аларны, алмагыз өстегезгә зур гөнаһ!

– Ә Себерне кем тотар, кем иген игәр, кем мал асрар, барыбыз да моннан качып бетсәк? – Өяз башлыгы шулай дип әйтүен сизми дә калды.

– Анысы өчен дә борчылмагыз, әнә Идел буйларыннан йөзләгән татар гаиләләре бу якларга күченә башлады бит... Үзегез беләсез, авыллар гына түгел, урман аланнары да килгән татарлар белән тулды, урнаштырып бетерә алмыйбыз, алар да безнең өстә.

Бу сүзләрдә дә дөреслек бар иде – соңгы елларда Идел-Уралдан бик күп гаиләләр монда күчте, җирсезлектән, хокуксызлыктан тилмереп, туган якларын шушы салкын Себергә алыштырдылар. Бер караганда, патша хакимияте берни дә югалтмый кебек – болары китсә, бушлыкны күчеп килгән казан татарлары тутырачак, эшләргә, салым түләргә кеше булачак... Өяз башлыгы инде бер карарга килгән иде – кулында Питердан кайткан рөхсәт кәгазе бар, суд өчен дәлилләр йомшак, җитмәсә, бу токтын татарлар өчен нинди кешеләр аның каршына баш иеп килгән! Димәк, чыгарырга аларны ябылган җирләреннән, теләсә кая китсеннәр, хәзер аларны тотар көч юк иде...

– Ярый, килештек, миңа хөкүмәт кәгазе закон, – диде ул, полиция башлыгына карап. – Чыгар үзләрен зинданнан, биреп җибәр боларга... Калганын үзләре карарлар... Ә сез кергәләп йөрегез, Рәхмәтулла Ниязович! Менә шәһәрдә яңа больница салырга кирәк, ә рәт юк инде, каян булсын!

– Больницаны үз өстебезгә алабыз, Иван Иваныч! Халык өчен бит! Ә бу карарыгыз өчен зур рәхмәт! Гает бәйрәменә өйләренә кайтсыннар бу мөселманнар, юлга әзерләнсеннәр...

Куллар бирешеп, кочаклашып аерылыштылар. Айтикиннар ишек төбендә

затлы төлке туннарын киделәр, урамда үзләрен көтеп торган сиртмәле фаэтоннарга утырып, пар атлар белән полиция бинасына таба юнәлделәр. Алар анда шатлыклы хәбәр белән бара – Яланкүл татарлары зинданнан чыгачак, һәм һиҗрәткә юллар ачылган иде... Өяз башлыгы, карт урыс, аларны тәрәзәдән башын чайкап карап калды – бу татарлар бер-берләре өчен утка керергә дә әзер иде! Кара син аны, дөньяның нинди зур байлары, олы башларын кече итеп, зинданда яткан шул авыл татарлары өчен сорарга килгәннәр бит! Питерларга хәтле барып җиткәннәр! Һәм үз дигәннәрен эшләделәр – Себер тарихында беренче тапкыр йөзләгән татар хәзер дин өчен чит илгә күчеп китәчәк... Моның яхшымы-яманмы икәнен өяз башлыгы хәзергә үзе дә аңлап бетерми, әмма бу хәлләрдән соң аның да күңеленә шом керде. Татарлар шулай кубарылып китә икән, димәк, нидер сизенәләр, дөньяда ниндидер зур үзгәрешләр булырга тора... Сәясәт дөньясы да тыныч түгел – казан кебек кайный, көн дә террор, кеше үтерүләр, инкыйлабка чакырулар... Тара-Тубыл төрмәләре әнә шул революционерлар белән тулган, алар өчен Алла да юк, мулла да юк, поп та юк... Бәлки, бу татарлар шушы хәлләрне сизенеп, алдан аяк киенәләрдер, инде ут капкан бу җирләрдән качып-күчеп китәләрдер? Бу сорауга өяз башлыгының җавабы юк, ә җавап тапканда, ул инде үзе дә төрмәдә булачак иде...

Полиция башлыгы исә тыкрыклар буйлап, җәяүләп кенә эш урынына ашыкты, ул шушы татарларны җиңә алмаганына гарьләнде, алар сүзенең өстен чыгуына кимсенде. Әмма өяз башлыгында да хаклык бар – бер Исмай-Иван сүзе белән генә аларны төрмәгә утырту авыр булачак, шуңа күрә бу юлы бәйләнмәвең хәерле. Ә вакыт киләчәк әле, киләчәк, урысның телен дә, динен дә кабул итәрсез, рәхмәт әйтә-әйтә, нәселегезгә, куеныгызга кертәчәксез. Моның шулай буласына полиция башлыгы шикләнми, чөнки Себерне басып алучылар нәселеннән бит ул! Ата-бабаларының юкка кан түкмәгәннәрен белә, һәм ул үзе дә бу җирләрнең бер карышын да, беркемгә дә бирмәячәк, шул исәптән, бу татарвага да!

Айтүкә байлар зинданда яткан Яланкүл тоткыннарын туп-туры үзләренә алып кайттылар. Ураза вакыты, көн кичкә авышып бара, шушында авыз ачып, намазларын укып, үзләрендә кунып китәргә тәкъдим ясадылар. «Сез – Аллаһ мөсафирлары, сезләрне кунак итү безнең өчен мәртәбә», диделәр алар. Айтикиннар бөтен зур нәселләре белән шәһәрнең тау астындагы Татар бистәсендә үзләре зур бер утрау булып яшәп яталар икән. Ерак түгел Иртыш елгасы, аңа коючы Аркар, елгаларның кырый-кырыйлары инде кар-боз белән капланган. Шәһәргә терәлеп кара урман шаулый, башлары күккә тигән карагайлар, эрбет агачлары җилдә чайкала... Табигатьтә инде кыш башланган, инде ничә көннән бирле талгын гына йомшак ак кар ява, ул юлларны, кырларны, урман-болыннарны каплап киткән. Яланкүл татарлары үзләре Тара төрмәсендә ятканда, табигатьтә берничә көн эчендә булган үзгәрешләргә таң калдылар, моңа сөенделәр. Әмма иң зур сөенеч, могҗизага тиң яңалык, ул, әлбәттә, төрмәдән исән-имин котылулары, һиҗрәтнең өзелмәве иде. Моның өчен алар Айтүкә байларга кат-кат рәхмәтләрен әйттеләр.

– Без сәбәпче генә, бу Аллаһның рәхмәте, – дип җавап бирде Айтүкә байлар. – Башта без дә сезнең авылларыгыз белән һиҗрәткә кузгалуыгызга аптырабрак караган идек, чөнки монда да яшәргә була... Әмма соңгы еллардагы хәлләр, дәүләт думасын куып таратулар, Тубыл-Тара зинданнарының тоткыннар белән тулуы, бирегә сөргенгә сөрелгән революционерларның көннән-көн артуы уйландыра башлады... Бу хәлләр хәерле бетмәс кебек, бу илдә ниндидер зур тетрәнүләр булырга охшаган... Габдрәшит хәзрәт тә шулай дип әйткән иде. «Үз дәүләтебез булса, болай дөнья буйлап каңгырып йөрмәс идек, кяфер законы белән түгел, үзебезнең тәртип белән яшәр идек», дигән иде... Хак сүзләр.

Әмма дөньялар бик нык үзгәрәчәк. Без бит дөнья буйлап йөрибез һәм моны бик яхшы сизәбез... Әмма без кузгала алмыйбыз инде – үзебез олыгайдык, балалар монда ияләшкән. Башлаган эшләребез дә көн дә биредә булуны таләп итә – Умбада, Кызылъярда, Павлодарда, Верныйда да завод-фабрикаларыбыз бар, аларның эшен өзә алмыйбыз.

Яланкүл татарлары арасында иң абруйлысы Юанбаш Мөхәммәди иде, Айтүкә байларга җавапны да ул бирде.

– Тоткынлыктагы дин кардәшләрегезгә шулай эчкерсез ярдәм иткән өчен Аллаһ үзегезгә дә ике дөньяның һидәятен насыйп итсен, – дип башлады ул сүзен, бераз рәсмирәк төстә. Аннан гадирәк, авыл теленә күчте. – Инде дә борчылган идек безнең аркада һиҗрәт сәфәре өзелә икән дип! Юк, үзебез өчен алай кайгырмадык, халык бездән башка бу олы эшне башкарып чыга алырмы, дип борчылдык... Зинданда көннәр буе тоткан уразаларыбыз, төннәр буе укыган тәһәҗҗүд намазларыбыз, кылган догаларыбыз кабул булды, Аллага шөкер, Хак Тәгалә ярдәмгә сезне җибәрде! Инде авылда халык та сөенер, гает бәйрәменә кайтып та җитәрбез, иншa Аллаһ!

Авыз ачканда да сүз юл, һиҗрәт мәшәкатьләре турында барды, киңәшләшү намаздан соң да дәвам итте. Шул хәтле кешегә Умбага барырга алтмыш-җитмеш кенә олау җитмәс, дигән фикергә килделәр, әле бит һәркем үзе белән күтәрә алган кадәр кирәк-ярагын да алачак. Шуңа күрә Айтүкә байлар олаулар санын йөзгә җиткерергә киңәш итте, калганнарын Тарадан үзләре бирергә килештеләр.

– Атлар бездән булыр, – диде алар. – Олаучылар гаеттән соң Яланкүлгә барып кунар, икенче көнне юлга чыгарга җайлырак булыр... Умбага барып җиткәнче юлда татар-казакъ авылларында төн кунарсыз, алары белән дә алдан сөйләшербез. Умбада Мәтин бай белән сөйләштек, ул сезнең барыгызны да үзенә алачак, анда сыймаганнарыгыз минем Умбадагы өйләремдә торырсыз, без Мәтин бай белән янәшә генә яшибез. Поезд чыгымнарын да бүлешеп күтәрербез, дип торабыз, аның буенча инде эшләр бара... Аз булса да хәлегезне җиңеләйтәсе килә инде, кардәшләр!

Яланкүл татарлары Айтүкә байларның сүзләрен авызларын ачып тыңладылар. Алар төрмәдә ятканда да милләттә күпме эш барган икән, күпме кеше аларга сиздерми-күрсәтми генә ярдәм итәргә алынган! Моны Аллаһ рәхмәте дими, тагы ни дип әйтәсең! Димәк, Аллаһы Тәгалә бу һиҗрәттән риза, шуңа күрә юлларын да ача, яхшы кешеләрне сәбәпче итә... Инде тәвәккәлләргә, бу юлда ниләр генә булса да, сабыр итәргә, Аллаһ ризалыгы өчен түзәргә кирәк булачак. Халык төрле, араларында икеле-микеleләре дә бар, инде ничек тә фетнә чыгармаска, бу сәфәрнең ни дәрәҗәдә җитдилеген гел исләренә төшереп торырга туры киләчәк. Ә моны бары тик ислам дине, Коръән нигезендә генә аңлатып булачак.

## Олы сәфәр алдыннан

Икенче көнне таң беленгәнче сәхәр ашап, иртә намазыннан соң, Айтүкә байлар биргән яхшы атларга утырып, яланкүлләләр кышкы юлга кузгалды. Күңелләр күтәренке, көн искиткеч матур, инде чана юлы да төшкән, атлар ап-ак урман-кырлар өстеннән очып барган кебек кенә җилдерәләр иде. Ә кар һаман әкрен генә ява да ява, җир өстенә бәрәкәт булып ява, күңелләргә дога булып иңә, җаннарны тынычландыра иде... Җилдәй искән шәп атлар белән авыз ачкан вакытка, кичке ахшам намазына Яланкүлгә кайтып җиттеләр. Юанбаш Мөхәммәдиләрнең төрмәдән котылып кайтулары турында хәбәр шунда ук бөтен авылга таралды, авыз ачу белән, халык мәчеткә җыела башлады. Бүген уразаның

соңгы көне, тәравих намазы булмаячак, әмма ирләр төнге намаз алдыннан тагы бер җыелып киңәшергә булдылар, чөнки вакыт аз калып бара иде. Хатын-кызлар исә бәйрәм мунчалары яктылар, иртәгесе көн өчен пешеренделәр, китәселәр исә тагы бер кат төенчекләрен барлады, юлга хәзерләнде.

...Ураза гаетенә җыелган халык мәчеткә генә сыймады, урамда ак кар өстенә җәймә җәеп, намаз укучылар да күп булды. Монда тәртибе шундый иде: бер генә ир-ат та өйдә утырып калмый, гает намазында катнаша, сәдакасын бирә, вәгазь тыңлый. Бүген дә шулай булды, гает бәйрәме бүген бигрәк тә үзәк өзгеч булды, чөнки бу туган авылда, туган илдә соңгы гает иде... Бу – бәхилләшү гаете иде, моның шулай икәнен китүчеләр дә, калучылар да яхшы аңлады. Элек капма-каршы торулар, бәхәсләр булса да, мәңгелеккә аерылуны аңлау аларны килештерде. Бүген намазда Мөхәммәтҗан карт имамлык итте, вәгазьне дә ул сөйләде.

– Җәмәгать, авылдашларым, кардәшләрем, менә без бүген соңгы тапкыр бергәләп гает намазы укырга җыйналдык, – дип башлады ул сүзен. – Иртәгә иртәнге намаздан соң һиҗрәтчеләр, Аллага тапшырып, ерак юлга кузгалачаклар, җыелу шушы мәчет янында булачак... Үзегез шаһит – без башта бу сәфәргә каршы идек, әмма Аллаһтан шулай язган, күрәсең, аларны беркем туктата алмады, хәтта төрмәләрдән дә алар исән-имин котыла алдылар. Инде бу мәсьәлә ахыргача хәл ителгән, патшадан башлап, өяз түрәләренә хәтле рөхсәтләрен биргәннәр, инде бездән дә бер хәер-фатыйха, җәмәгать! «Бисмилләһи тәвәккәлтү галәлләһи вә хаулә вә лә куәтә иллә билләһи» – «Барлык эшләребезне Аллаһка тапшырабыз, Аллаһ куәте-көченнән башка гайре көч юктыр». Бу Аллаһ мөсафирлары ниятләгән җирләренә исән-имин барып җитеп, шул туфракларда тамыр җибәрсеннәр иде. Амин! Болар бары тик Аллаһ ризалыгы өчен, иманны, динебезне саклап калу өчен, туган яклардан мәңгегә аерылып, күз күрмәгән җирләргә китеп баралар, аларга догада булыйк! Бәхиллегебезне бирик, элеккеге ачуланышуларны онытыйк! Инде киткәннәргә дә әйтер сүзем бар. Юлда да, анда баргач та төрле хәлләр булыр, Аллаһ ризалыгы өчен, Аның хакына түзегез, сабыр итегез! Сез иманны саклау өчен, җәннәт өмет итеп, шушы юлга кузгаласыз, алда үзегезне ни көткәнен белмисез... Ни булса да, Аллаһка таяныгыз, бер-берегезне ташламагыз, бер-берегезгә терәк булыгыз. Безнең бохари ата-бабаларыбыз дин-ислам хакына шушы Себер җирләренә һиҗрәт кылганнар, кара урманнарда яшәүче халыкка иман нуры таратканнар. Сез исә ислам иленә китәсез, тоташы белән мөселманнар яшәгән, мөселманнар идарә иткән җирләргә һиҗрәт кыласыз. Анда барысы да булыр, инша Аллаһ – дин тотарга ирек тә булыр, мәчет-мәдрәсәләр дә эшләп торыр, көчләп чукындыру куркынычы да булмас... Салкын Себердән аермалы җылы табигать булыр, җәннәт җимешләренә тиң ризыклар булыр, анда барысы да булыр, әмма анда туган җир, туганнар гына булмас... Без булмабыз... Димәк, тәкъдирдә шулай язылган булган. Моның белән килешергә кирәк. Үзәкләрегезне туган якларны, туганнарны сагыну өзгәләр, елап күзләрегез сукыраер, төшләрегезгә шушы ак карлар, шаулап утырган карагай урманнары керер, туган илгә җәяүләп йөгереп кайтыр хәлгә килерсез – әмма түзегез, бу сезгә Аллаһның сынавы булыр. Аның әҗерен ике дөньяда да күрерсез, бу дөньяда – иманлы нәсел белән, ахирәт көнендә – җәннәт бүләге белән… Инде сез дә безгә, бирердә кяфер арасында калган кардәшләрегезгә, догада булыгыз, бу дөньяда насыйп булмаса, ахирәт көнендә җәннәтләрдә бергә булырга язсын, дип Аллаһтан сорыйк!

Мөхәммәтҗан карт бу сүзләрне елый-елый сөйләде, аңа кушылып, гаеткә җыелган халык та елый иде... Сукса тимер өзәрлек, басса бакыр сытарлык әзмәвер ирләр, аю-бүреләрне коры кул белән тотып, сыртларына салган татар ирләре, алда торган мәңгелек аерылуны бөтен йөрәкләре белән тоеп, сүзсез генә елыйлар иде... И, бәхетсез милләт, үз дәүләтең булса, син шулай каңгырып дөнья

буйлап йөрер идеңме, чукындырудан качып, кара урманнарга, сазлык араларына таралыр идеңме? Инде телсез-динсез каласыңны аңлап, бөтен нәселең белән кубарылып, туган якларны ташлап китәр идеңме? Анда сине ни көтә? Син кем кадерлесе анда? Моны барысы да аңлый иде, һәм моңа барысы да әзер иде...

Халык гает намазыннан таралгач та, һиҗрәт өчен җаваплы ир-атлар әле мәчеттә калдылар, иртәгә башланачак сәфәрне тагы бер кат барлап-тикшереп чыктылар. Юлга чыгачак бөтен гаиләләрнең исемлеге төзелде, һәр олауга бер җаваплы кеше билгеләнде, ә бөтен төркемнең башлыгы итеп Тайяр улы Тәһсинне куйдылар, чөнки Умба-Омски юлын иң яхшы белүче ул иде. Һәр ат чанасына кышкы киемнәрдән биш-алты гына кеше утырырлык иде, ә әйберләр, сандык-төенчекләр өчен артта аерым олаулар билгеләнде. Атларның үзләренә дигән азык та аерым олауларга төялде. Китүчеләргә үзләре белән әйберләрне күп алмаска киңәш ителде, әмма хатын-кызлар тегү машиналарыннан, ә ирләр һөнәрчелек коралларыннан аерылмаска булдылар, чөнки киләчәктә аларны шулар ашатачак иде.

Юлда кереп кунасы татар-казакъ авыллары инде алдан билгеләнгән, сөйләшенгән иде, төннәрен шунда туктап, атларны ял иттерергә булдылар. Ерак юл өчен бөтенләй ризыксыз да булмый, анық бозылмый торганнарын – казылык, каклаган һәм тозлаган ит, бавырсак, кипкән икмәк алырга дип киңәш ителде. Инде намаз мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк иде. Авылдан кузгалган вакыттан башлап, Истанбулга барып җиткәнче алар мөсафир саналалар иде һәм намазларны да дин рөхсәт иткәнчә, кыскартып, сәфәр намазы итеп укырга килештеләр. Намаз вакытлары җиткәнне төркемгә азан әйтеп белдерергә булдылар, мөмкинлек булганда, намазны җәмәгать белән, андый шартлар булмаса, олауларда утырган җирдән укырга дигән фикергә киленде. Инде тәһарәт мәсьәләсенә килгәндә, юлда гел су булмас, дин рөхсәт иткәнчә, тәэммүм алырга килештеләр, моның өчен һәркем үзе белән зур булмаган таш-кирпеч кисәге алырга тиеш иде.

Мөхәммәтҗан карт үзе дә олаулар белән Умбага кадәр озата барырга булды, ул юлда дин эшләренә дә җавап бирер, Хөснибикәсенә дә күз-колак булыр... Бүген ул Коръән ашына кияүләренә чакырулы, өенә кайтып, гаиләсе белән бәйрәм чәен эчәр дә Хөснибикәсе янына китәр... Аласы әйберләрен алганмы, юлда ашарына ризыгын салганмы, җылы өс-башларын әзерләгәнме – ата кеше үзе күзәтәчәк, үзе хәстәрләячәк. Инде ул тәкъдире белән килеште, ичмасам, соңгы көннәрдә булса да баласына кулыннан килгәнчә ярдәм итеп калсын...

Бүген Яланкүлдә аерата ямьле һәм ыгы-зыгылы иде...

Авыл кайнап тора, капкалар ачыла да ябыла, берәүләр, кочак-кочак әйбер күтәреп, урамның икенче башына ашыга, икенчеләре калган мал-туарны кемнәргәдер урнаштыра... Кышкы авыл өстенә коймак исе, итле бәлеш исе таралган, бүген бар халык ураза бәйрәмен бәйрәм итә, кунакка йөрешә, бүләк бирешә... Яңа яуган ап-ак кар исе кичтән яккан кара мунча исе белән кушыла, кемнәрдер олы юлга чыгар алдыннан бүген дә иркенләп юынып ала, халык әле бүгенгә көндәлек авыл тормышы белән яши. Ә иртәгә барысы да үзгәрәчәк. Чаналарга менеп утырганнан башлап, икенче тормыш, башка яшәү шартлары башланачак... Моны барысы да белә, әмма ничек буласын чамалыйлар гына, котылгысыз тәвәккәллек өстенә кешеләрнең йөрәкләрендә бераз хәвеф һәм шом да бар... Ничек булыр? Ахырга чаклы түзәрләрме? Түзә алмыйча, берәр җирдә өзелмәсләрме? Һәркем күңеленнән шул сорауларга да җавап эзли иде...

Ә балаларның бер нәрсәдә кайгылары юк, алар Яланкүл урамнарын тутырып, соңгы тапкыр агач чаналарда шуалар, аякларына киң агачтан ясалган аучы чаңгылары киеп, урман юлыннан җилдерәләр... Иртәгә бу балалар да ата-аналары белән ерак юлга кузгалачаклар – урмансыз, карсыз, чаңгы-чанасыз җирләргә... Әмма татар балалары әле боларны белми, алар бу ак карлар, бу кара урманнар,

бу Себер табигате бөтен җирдә дә бар, дип уйлый һәм шуның белән бәхетлеләр... Кара, Зөлбану белән Хөснибикә дә шул балалар арасында бит, хәер, алар үзләре дә әле балалыктан чыгып җитмәгән шул! Әмма инде аларның йөзләрендә елмаю булса да, күзләрендә әллә нинди моң, аерылу сагышы, алар, гүя, туган җирләре белән мәңгелеккә бәхилләшергә дип соңгы тапкыр урамга уйнарга чыкканнар...

Мөхәммәтҗан карт алар янына килде, Зөлбану белән Хөснибикәнең кар атышып уйнавын елмаеп карап торды. Ул арада капка астыннан шуып чыгып, Пүрехан да килеп җитте. Пүрехан – Хөснибикәнең көчек чагыннан карап үстергән бүре-эте, аны Мөхәммәтҗан карт урмандагы ау алачыгыннан табып алып кайткан иде. Бияләй кадәр генә иде әле ул вакытта, бер аягы яралы иде, ишегалдында малайлар белән бергә үсте. Бүре затыннан булгач, Мөхәммәтҗан карт башта аннан шикләнгән иде, кире урманга җибәрергә дә уйлады, әмма Пүрехан һәрвакыт йөгереп өйгә кайтты. Бәлки, бер аякка гарип булуы сәбәпле, урманга түгел, кешеләр янына сыенгандыр, ул анда барыбер ачтан үләр иде. Хөснибикә белән алар бигрәк тә дуслашты, чөнки башка балалар Пүреханга кычкырсалар да, Хөснибикә аһылдап аның башыннан гына сыйпый иде. Шулай итеп, Пүрехан Мөхәммәтҗан картларда яшәп калды, ә Хөснибикә кияүгә чыккач, берничә көн җир тырнап елады, бу хәлгә түзә алмыйча, ул аны кияве йортына илтеп куярга мәҗбүр булды. Менә хәзер дә ул Хөснибикәнең артыннан тагылып йөри, иртәгә нишләр – белгән хәл юк. Иртәгә чылбырга бәйләп куймый булмас үзен, югыйсә, Хөснибикәдән калмаячак ул...

Өйгә кергәч, ул бу хакта кияве Салихка да әйтте, Пүреханны иртәдән чылбырга бәйләп куярга кушты. Бу йортта да юлга чыгарга барысы да әзер иде, кода-кодагыйлар китми-китүен, алар да, Мөхәммәтҗан карт кебек, уллары белән килененең һиҗрәткә китүенә каршы булдылар. Әмма Салихны үгетләп кенә кире күндерә торган түгел иде, әллә нинди эчке бер ашкыну белән җыенды ул бу сәфәргә... Адәм баласын тәкъдире йөртә шул инде, димәк, эчәр сулары, ашар ризыклары анда булган, шулар тарткан... Алай да, кунаклар җыелганчы, Мөхәммәтҗан карт киявенә бераз үгет-нәсихәт бирергә булды.

– Башта бик каршы булсам да, инде китүегез белән килештем, кияү, – диде ул. – Үзең беләсең – Хөснибикәмне йөрәгемнән өзеп алып чит җирләргә җибәрәм... Мин бит монда аңа ата урынында да, ана урынында да идем. Ул бит әле балалыктан да чыгып бетмәгән, колынкаем, әнә, Зөлбану кардәше белән кар атып уйнап йөри... Син аңа каты кагылма инде, кияү, хәленә кер. Ул бит кая, нәрсәгә киткәнен дә белми, бездән мәңгегә аерыласын да аңламый, сагынудан саргайса да, моны беркемгә әйтә алмас...

Мөхәммәтҗан картның күзләренә яшь бәреп чыкты, ул аны күлмәк җиңе белән сөртеп алды. Атаның ничек баласы өчен йөрәге өзгәләнгәнен кияве дә сизде, чөнки Себер ирләре юкка-барга еламый иде...

– Борчылма, бабай, үзем исән чагында Хөснибикәнең башыннан чәч бөртеге дә төшмәс, күз яше таммас, мин аны тормыштан да, кешеләрдән дә рәнҗеттермәм, Алла теләсә! – диде ул. – Инде баласын исән-имин таба күрсен, икесен бергә карап үстерермен. Үзебез урнашып алгач, сезне дә чакыртырбыз, бергә-бергә гомер итәрбез әле, бабай!

Киявенең бу сүзләреннән Мөхәммәтҗан картның күңеле күтәрелеп китте. Әйе шул, нигә әле ул һаман дөнья беткән кебек кара кайгыга батып утыра? Хөснибикә бер ялгызы чыгып китми бит, янында әзмәвердәй ире бар, ярты авыл, туган-тумача шунда булачак... Дөньяныкын белеп булмый, Аллаһ насыйп итсә, бәлки әле үзе дә ул якларны бер әйләнер... Хаҗга да юлны шул Истанбул аша диләр бит, балаларын бераз аякка бастыргач, андый нияте дә бар Мөхәммәтҗан картның... Шуңа күрә исән чакта бер-береңне тереләй күмәргә кирәкми, бер

Аллага тапшырырга кирәк, дип уйлады ул. Бәйрәм табыны янында Коръән укып, кызы белән киявенә фатихасын бирде, аларга хәерле сәфәрләр, хәерле-имин тормыш теләде, үзләреннән соң иманлы нәсел калдырсыннар, дип, озаклап дога кылды. Ата кешенең баласына догасы кабул булмыймы соң инде? Кабул булыр, инша Аллаһ, әмма моның өчен җир йөзендә үк тереләй сират күперләре кичәргә туры килүе дә бар шул... Һәм ул шулай була да...

## «Бәхил булыгыз, туганнар!»

Икенче көнне иртә намазыннан соң Яланкүл мәчете янына бөтен авыл җыелды – китәселәре дә, каласылары да, ир-атлар да, хатын-кызлар да шунда агылды. Кышкы көннең сүрән таңы йөрәкләргә бетмәс сагыш салды, күңелләрне моңландырды, тәннәрне оетты, хәрәкәтләрне салмакландырды... Әйтерсең лә китүчеләр дә, калучылар да бергә булу вакытын шулай аз булса да сузарга телиләр, аерылышу мизгелләрен җаннары белән туктатырга омтылалар иде... Әмма кышкы көн кыска, барыр юл озак, кайчан да бер кузгалырга кирәк... Тарадан Айтүкә байлар җибәргән олаулар инде кичтән үк авылга килеп кунганнар иде, Чабаклы һәм Үләнкүлләр, Чарналы һәм Каракүлләр, Кошкүл һәм Койгалылар һиҗрәт кәрванына олы юлда килеп кушылачаклар, ә янәшәдәге Аубаткан белән Кумыслы мөһаҗирләре авыл башында көтеп торалар.

Китүчеләр барысы да җылы итеп киенгән – өсләрендә кайры тун, аякларында киез итек, ирләрнең башларында тире бүрек, хатын-кызларда – мамык шәлләр... Зур төенчекләр арттагы олауларга салынган, янда – юлда ашыйсы ризык, күкрәкләрдә – Коръән китабы... Калган барысы да кала...

Җыелган халык алдында Мөхәммәтҗан карт Коръән укып фатихасын бирде, аннан соң һиҗрәтчеләр башлыгы Юанбаш Мөхәммәди сүз алды.

– Авылдашлар, менә без китәбез инде, хәзер юлга кузгалабыз, – диде ул авырлык белән, бугазына килеп терәлгән төерне йота алмыйча. – Бәхил булыгыз, бергә яшәгәндә каты сүзләр әйткән булсак, кичерегез, безгә ачу тотмагыз... Без дин-ислам хакына туган җирләребезне ташлап китәргә мәҗбүр булабыз, курыкмыйча ислам динен тотарга телибез, нәселебезнең дә мөселман булуын телибез... Безнең өчен борчылмагыз, без Аллаһ юлында, Аллаһ ризалыгы өчен шушы юлга чыгабыз, ни күрсәк тә түзәрбез... Без сезнең өчен куркабыз, бу кяфер арасында калып, урыска әйләнүегездән куркабыз, авылларыбызның керәшен кырына әйләнүеннән куркабыз. Әмма безнең, кара урманнарда күмелеп калган бер уч себер татарының, бохариларның бу кяфер илен җиңәрлек көчебез юк. Шуңа күрә үзебез китәбез... Ни булса да, бер-беребезгә догада булыйк, кем арасында, нинди заманда яшәсәк тә, мөселман булып, үзебез булып калыйк! Ә хәзер, олау башлары, атларыгызга утырыгыз, гаиләләрегезне төягез, юлга кузгалабыз...

Мәчет каршындагы халык дулкындай тибрәлеп куйды, аннан авыл өстенә үзәк өзгеч моң булып, бәхилләшү авазы булып, тәкъбир тавышы таралды:

Аллаһу әкбар, Аллаһу әкбар,
Ләә иләһә иллә Аллаһу,
Үә Аллаһу әкбар үә лилләһил хәмдү.
Аллаһу әкбар, Аллаһу әкбар,
Ләә иләһә иллә Аллаһу,
Үә Аллаһу әкбар үә лилләһил хәмдү.

Бу аваз, авыл өстенә генә сыймыйча, кара урманнарга хәтле барып җитте, кайгы булып, карагайларга килеп уралды, кар каплаган кырлар-болыннар өстенә ятып сулкылдады, бозлы күлләргә сарылып елады... Аһ ул татарның

тәкъбире, ил-дин өчен соңгы сугышка кергән милләт каһарманнарының үлем күзенә карап әйткән тәкъбире! Чукынмаган өчен тереләй утларда яндырылган татар ирләренең һәм хатын-кызларының ялкын телләре арасыннан ыңгырашып әйткән соңгы тәкъбире! Чукындыру өчен бозлы суларга куып кертелгән, монастырьларга ябылган татарларның су төбеннән, тимер читлекләрдән яңгыраган соңгы тәкъбире! Дин-милләт дигән өчен тимер чылбырларга бәйләп гомерлек каторгага сөрелгән татарларның җан авазы, мәңгелеккә бәхилләшүе, дин-милләт өчен көрәшергә соңгы әманәтләре дә бит ул – татар тәкъбире! Моны шушы фаҗигаләрнең барысын да кичергән милләт кенә аңлый ала... Һәм менә шул соңгы тәкъбир хәзер Себер күгендә, Яланкүл авылы өстендә яңгырый... Бәхил булыгыз, туганнар!!! Бәхил булыгыз...

Хатын-кызлар бу изге аваздан күз яшьләрен тыя алмый кочаклашып елаша башладылар, бер-берләренә соңгы сүзләрен әйттеләр, бирәсе күчтәнәчләрен бирделәр. Мөхәммәтҗан карт кияве белән кызын Тулпар атын җигеп үзе озатырга булды, аларны кадерләп чана түренә кертеп утыртты, дилбегәне дә үзе тотты. Ул чана төбенә кичтән мул итеп кипкән печән түшәде, өстенә йомшак җәймә җәйде, кызына таяныбрак барырга кечкенә мендәрчеген дә салырга онытмады. Кызы Хөснибикә авырлы булганга, ул чанага башкаларны утыртмады, һәрхәлдә һәр олауга дүрт-биш кеше утырту каралган булса да. Хөснибикә дә әтисе үзе теккән җыйнак төлке туннан, үзе бәйләгән йомшак мамык шәлдән, ак киез каталардан курчак кебек, чана түрендә утыра. Хөснибикәдән кала, барысы да кая барганнарын һәм ни өчен илдән киткәннәрен белсәләр дә, аның телсез-чукрак балакае әле һаман берни аңламый, зур яшел күзләрендә бераз курку да, кызыксыну да сизелә... Әмма янында ире һәм атасы булгач, ул барыбер тыныч, Зөлбану да әнә әти-әниләре белән күрше олауда, тик алар нигәдер бик моңсулар...

## Һиҗрәт кәрваны

Ул арада олаулар Умба ягына таба, кыйбла якка карап тезелделәр, һиҗрәт кәрванының бер башы Ырыслы күл буенда, икенче башы Ям кугы дип аталган нарат урманына кадәр сузылган иде. Һавада Тайяр Тәһсиненең «Кузгалдык, җәмәгать! Аллага тапшырдык!» дигән сүзләре яңгырады, һиҗрәт кәрваны кузгалып китте... Авыл башында бу кәрванга Кумыслы һәм Аубатканнан килгән олаулар да кушылды, олы юлга таба башка авыллардан да атлы чаналар чыгып килә иде. Яланкүл халкы авыл башына хәтле мөһаҗирләрне елый-елый озата барды, хуҗаларыннан аерылган этләр дә олаулар артыннан һау-һаулап бераз чабып бардылар да, арып һәм аптырап, туктап калдылар. Гомер буе Тара белән Умба арасында ямщик булып йөргән Айтүкә бай олаучылары һиҗрәт кәрванын җай гына кыйбла тарафка таба алып киттеләр, инде Яланкүл авылы да ак томаннар артында күздән югалды...

Мөһаҗирләр шул чагында гына нәрсә югалтуларын аңладылар, юк, бу туган авылны гына күздән югалту түгел иде, бу – кендек каны тамган җирләрне, эчкән сулары белән канга сеңгән милли хәтерне, кемлегеңне дә югалтуның башы иде... Иман хакына, үз теләгең белән, үз-үзеңнән, үткәннәреңнән, яратканнарыңнан баш тарту иде... Бу югалтулар ачысына бары тик ныклы иман калканы белән генә каршы торырга, үзеңә дә юкка чыкмаска мөмкин иде...

«Хушыгыз, инде бөтенләйгә хуш-бәхил булыгыз, Туба, Мәртен, Чумарт атауларында киерелеп печән чапкан болыннар, инде сез татар мөһаҗирләренең төшләрендә генә шау чәчәктә утырырсыз... Хушыгыз, Ям кугы, Куртайлы, Койгалы урманнарында аю атып, бүре сугып, җиләк җыеп, эрбет коеп узган заманнар, хәзер монда без булмабыз инде... Хушыгыз, Яланкүлне чорнап

алган зәңгәр күлләр – Рәҗәп һәм Каук күлләре, Мәүлет һәм Каргакүл, һәр елны аккошлар кайта торган Ырыскүл, йөрәк тамырларыбызда шушы күлләр суының шифа-дәрманын алып китәбез... Без гомер буе, соңгы сулышыбызны алганчы, туган якның исен-төсен, кышкы саф салкыннарын, язгы дәртле тамчыларын, җәйге җылы туфракларын, көзге сары яфракларын күңелебездә саклarбыз, шушы сагыну-җирсү хисен балаларыбызга, нәселебезгә дә тапшырып калдырырбыз... Хуш, туган җир, бәхил бул, безгә рәнҗеп калма...»

Соңыннан бу аерылу сагышы моң булып татар мөһаҗирләренең җырбәетләренә күчәр, Төркиянең чүл-далаларында яңгырар:

Карлыгачлар очмас карурмандин,
Кара кошлар очып барайды.
Башмагым төшмәс ят җирләргә
Башкынаем китеп барайды.
Карлыгачлар үтмәс кара таудин
Мөһаҗирләр үтеп барайды...

Кара урман башын, әй, кар алган,
Яшь йөрәгем башын сар алган.
Яшь башым белән яшь йөрәгем
Кайгы-хәсрәт өчен яралган.

Иртән лә торып тышка чыксам,
Ай туган ла җиргә, көн туган.
Күрербез Ходайның язганын,
Туып-үскән җирдән лә кем туйган...

Шулчак, барысын да сискәндереп, йөрәкләрне ярып, кышкы көнне урталай телеп, бер сәер аваз яңгырады. Ул кеше елавын да, бүре улавын да хәтерләтә иде, бу тавыштан тәннәр чымырдый, каннар өши, тыннар буыла иде... Бу дәһшәтле һәм шул ук вакытта гаять кызганыч, әрнүле тавыштан атлар барган җирләреннән шып итеп туктап калды, Тара йөкчеләре эшне аңлап алып, ау мылтыкларына ябыштылар – аларны арттан бүре куа килә иде. Әйе, озын тимер чылбырына уралып, гарип арт аягын карлы юлдан сөйрәп, гәүдәсен әле алга атып бәреп, әле йомгак кебек тәгәрәп китеп, һиҗрәт олавы артыннан Пүрехан чаба иде... Качкан, тимер чылбырын өзеп, агач казыгын чәйнәп чыгып качкан Пүрехан Яланкүлдән, ул менә хәзер балачактан бергә үскән Хөснибикә артыннан йөгерә, күккә карап улый-улый, җиргә ятып елый-елый, яшел күзле адәм баласы артыннан йөгерә ул...

– Тимәгез, атмагыз, бу бит Пүрехан! – дип кычкырып җибәрде Мөхәммәтҗан карт. – Безнең арттан килә ул, чылбырын өзеп качкан, бәгырь...

Ул арада Пүрехан йөгереп килгән уңайга Хөснибикә утырган чанага сикерде, бәс каплаган борынын аның киез итегенә төртеп, әллә табу сөенеченнән, әллә тагы югалту кайгысыннан, өзгәләнеп-үксеп шыңшый башлады. Хөснибикә дә таянып торган җиреннән сикереп торды, Пүреханның башыннан кочып алды, алар үзләре генә белгән-аңлаган телдә нидер сөйләшәләр иде. Пүреханның да, Хөснибикәнең дә яшел күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп төште, телсез кыз белән телсез җанварның сагыш-хәсрәтләре диңгез булып түгелде...

– Ярар, кызым, җибәр Пүреханны, кайтсын өйгә, – дип, Мөхәммәтҗан карт Пүреханны чанадан төшерергә тырышты, әмма ул куган саен яңадан сикереп менде.

Хөснибикә дә, атасын тыңлап, кул хәрәкәтләре белән, аһылдый-аһылдый, Пүреханга китәргә кушты, әмма бүре-эт аны да тыңламады, башын иеп, гарип

аягын сөйрәп, чана артыннан баруын дәвам итте, артыннан, шалтырап, тимер чылбыры ияреп килә иде... Һәм Пүрехан егылып үлгәнче Хөснибикә утырган чана артыннан барачак иде... Ирләр белән киңәшкәннән соң, Пүреханны да Умбага кадәр үзләре белән алырга булдылар, аннан олау белән кире әйләнеп кайтыр, диделәр. Һәм юл буе шулай булды – Пүрехан әле олаулар янәшәсеннән юыртты, әле кызганып, Мөхәммәтҗан карт аны чанасына алды, ә туктаган авылларда Пүреханны тагы чылбырга бәйләп куйдылар, ни әйтсәң дә, бүре затыннан бит, дип уйладылар.

Юл шулай алдан сөйләшенгәнчә дәвам итте – төнгә татар-казакъ авылларында кунарга тукталдылар, көндезләрен исә такыр кышкы юлдан шәп кенә җилдерделәр. Намаз вакытлары җиткәндә, Мөхәммәтҗан карт, чанасына басып, кычкырып азан әйтте, шарты булганда, бергәләп, җәмәгать намазы итеп, туктап тормаганда, аерым-аерым укыдылар. Шулай итеп, бер атна дигәндә Умбага килеп җиттеләр, алдан сөйләшенгәнчә, туп-туры Мәтин байларга киттеләр. Айтүкә байларның уллары да шушы тирәләрдә генә тора икән, халыкның бер өлешен алар да үзләренә алды. Умбада туганнары, якын таныш-белешләре булганнар аларга китте, мәчеткә барып сыенучылар да булды. Әйберләрне бушатып, олаулар кире Тарага һәм Яланкүлгә, башка авылларга кайтып китте, бары тик Мөхәммәтҗан карт кына, мөһаҗирләр поезды килгәнче, Умбада калды.

Татар мөһаҗирләре башта Умба-Омскины күргәч, куркыбрак та калды, чөнки аларның күпчелеге беркайчан да туган авылларыннан читкә чыкмаган, дөнья күрмәгән, шуңа күрә бу таш кала бераз өркетә иде. Юанбаш Мөхәммәдиләр поезд мәшәкатьләре артыннан йөргән арада, мөһаҗирләр әкрен-әкрен генә шәһәргә чыгып, кирәк-яракларын алгалый башладылар. Йөреп кайткан бере исе-акылы китеп сөйләде – ул урамнарының озынлыгы, ул базарларында кешенең һәм әйбернең күплеге, ул күз явын алырлык матур таш йортлар, чат саен алтын тәреләрен ялтыратып утыручы чиркәүләр, алардан калышырга теләмичә, бер-бер артлы күтәрелеп чыккан мәчетләр дисеңме... Яланкүл ирләренең кайберләре Тарада булганы бар иде, аларның артык исе китмәде, әмма Тара – агач шәһәр, ә монда – тоташ таш, дип тел шартлаттылар. Мөхәммәтҗан карт та кызы һәм кияве белән Умба урамнарын әйләнеп кайтырга булды, бер уңайдан, таш мәчетне дә карап чыгармын, дип уйлады. Туктаган урында, Мәтин байларда Пүреханны бәйләп калдырырга уйласалар да, ул баш бирмәде, ырылдап, сыртын кабартты, күзләреннән ут чәчте. Аны да шул чылбырыннан тотып, үзләре белән шәһәргә алып чыгарга мәҗбүр булдылар.

Умба, чыннан да, зур таш кала булып чыкты. Мөхәммәтҗан карт үзе урыс хәрефләрен әллә ни белми, кияве Салих Тарада бераз өйрәнгән булып чыкты, бергәләп, урамнардагы язуларны укып бардылар. Монда Себер губернаторы сарае да, ул яши торган курчак өе кебек йорт та бар икән, ул театрлар, китапханәләр, чиркәүләрне инде әйтеп тә торасы юк – әллә каян кукраеп утыралар. Тимер юл вокзалын да барып карадылар – анда халык кырмыска кебек кайнап тора иде, ә поездлар ике яктан да ажгырып килеп чыгалар да, дөбердәп, борын төбеңдә туктыйлар. Бу хәлләрне күреп, Хөснибикә курка калды, чытырдатып иренең кулына ябышты. Пүрехан булып Пүрехан да, төтенгә батып утырган тимер аждаһаларны күреп, койрыгын кысты, Мөхәммәтҗан картның аякларына елышты. Ә халык Пүреханның үзеннән курыкты, чылбырга бәйләнгән әллә эт, әллә бүрене күреп, урысы-татары, үзбәге-казагы читкәрәк ашыкты, кырын-кырын карап, яннарыннан үтеп китте...

Мөхәммәтҗан картның бу таш урамнан эзләгәне – мәчет иде, һәм ул аны тапты. Яшел манаралы, алтын гөмбәзле, шактый зур гына бер таш мәчет булып

чыкты ул. Әле янында килгән-киткән өчен кәрвансарай кебек озын агач йорты да бар икән, мөһаҗирләрдән дә берничә кеше шунда барып урнашкан икән. Пүрехан белән мәчеткә кереп булмаганга, Хөснибикәне анның белән урамда калдырып, Мөхәммәтҗан карт белән кияве кереп намаз укып чыктылар, анда җыелган казакълар белән бераз сөйләшеп утырдылар. Аларның һиҗрәткә кузгалган себер татарлары икәнлекләрен белгәч, казакълар кунакка кыстый башлады, юл сәдакасы дип, хәер бирде, Аллаһ мөсафирларының догаларын алып калырга тырышты. Дала казакълары дин тотуда алай каты булмасалар да, Аллаһтан куркалар, җае чыккан саен, Аллаһ ризалыгы өчен яхшылык эшләп калырга тырышалар иде. Алар Мөхәммәтҗан картка ияреп, мөһаҗирләр туктаган Мәтин байларга, Айтикиннарга да бардылар, көн саен куен-сарыгын чалып, мөһаҗирләрне туендырдылар. Хәер, Умбада яшәүче татарлар да, Тара ягыннан Истанбулга һиҗрәт сәфәренә чыккан милләттәшләре турында ишетеп, алар янына агыла башлады, һәркем мөһаҗирләргә ярдәм итеп, савап эшләп калырга тырышты.

Ун көнләп Умбада паровоз көтеп ятканнан соң, ниһаять, Барнаулдан мөһаҗирләр өчен махсус эшелон килде. Ул унике вагоннан булып, шуның унбере – юлаучылар өчен, уникенчесе мәчет һәм йөкләр өчен билгеләнгән иде. Вагоннарга исә туган туган белән, авыл авыл белән урнашырга тырышты, аларның да исемлеге алдан төзеп куелган иде. Мөһаҗирләрне озатырга бик күп татарлар килгән иде, әйтерсең лә бөтен Умба кубып чыккан! Һәркемнең кулында китүчеләргә күчтәнәч-бүләк, һәркем иман өчен изге юлга чыккан һиҗрәтчеләрнең догасын алып калырга тырыша... Вагоннар янында хушлашу ыгы-зыгысы, бәхилләшү һәм рәхмәт әйтешүләр башланды, гомерләрендә беренче тапкыр поездга утырган авыл халкына һәркем кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты. Ул арада ябалак-ябалак кар ява башлады, китүчеләрнең күз яшьләре белән буталып, сагышлы йөзләрендә эреп таралды, туган якның соңгы сәламе булып, артларыннан киемнәренә ябышып керде...

Мөхәммәтҗан карт кызы белән киявен вагонга үзе кертеп урнаштырды, алар анның кыз туганнары һәм Сахибзадә энесе, аларның балалары белән бергә иде. Инде Умбадагы тормышына бераз ияләнә төшкән, атасының һәм иренең янында булуына тынычланган Хөснибикә, бу ыгы-зыгыны күреп, тагы хәвефләнә калды. Ишетмәгәч, ул моның сәбәбен аңламады, сөйләшә алмагач, кая барабыз, дип сорау да бирә алмады. Анның күңелендә борчу, күзләрендә курку иде. Әтисе, Пүреханны өстерәп, вагоннан чыга башлагач, ул анның артыннан омтылды, әмма ире аны җибәрмәде, беләкләреннән кысып тотты. Хөснибикә поезд тәрәзәсенә капланды, урамда карт атасын күреп, тагы бер тапкыр анның янына талпынды. Шул чакта поезд каты итеп тартылып куйды, Хөснибикә чайкалып китте, соңгы тапкыр томырылып атасына карады, нидер белдерергә теләп, кулларын күтәрде, күкрәгеннән аһылдаган аваз бәреп чыкты... Эшелон кузгалып китте... Ә кышкы күктән әллә эре кар бөртекләре, әллә яралы аккошның ак каурыйлары коела иде... Әйтерсең лә салкын Себер шулай итеп үзенең ятим балалары белән бәхилләшә иде... Әйтерсең лә Мөхәммәтҗан карт нәселен аккош язмышлары, аккош каргышлары куа килә иде...

Бәнем ялгышларым җиттеме икән –
Ялгыз аккош авыл-лай күгендә?
Аккош каргышлары төштеме икән –
Парсыз калдым гомерем-ләй көзендә...
Кичерсәнә, Раббым, кичерсәнә,
Коткар нәселемне каргыштан.
Сакла нәселемне ул ялгыштан –
Аккошлардин калган язмыштан...

Хөснибикәнең тимер читлектә китеп баруын күргәч, Пүрехан башта улап күккә сикерде, аннан Мөхәммәтҗан картны өстерәп, поезд артыннан чаба башлады. Бу үзәк өзгеч күренеш иде – чылбырга бәйләнгән Пүрехан бәгырьләрне актарып, сулкылдый-сулкылдый улады, ә баласын мәңгегә югалткан Мөхәммәтҗан карт, үксеп-үксеп елый-елый, аның артыннан йөгерде... Аның хәле бетте, аяклары тотмый башлады, куллары оеп чыкты, ул үзен өстерәп диярлек йөгергән Пүреханны тыя алмасын аңлады, чылбырны ычкындырды да җиргә тезләнде, ак кар өстенә егылды... Пүрехан атылган ук кебек котырынып чабып китте, артыннан озын чылбыры сөйрәлде. Пүрехан эшелон артыннан күмелгәнче йөгерде, тимер юл буйлап ул әле тагы озак аксый-аксый чапты, аннан кырт кына урман ягына борылды да, күккә карап, тагы озак итеп улап торды. Куркыныч, шомлы, шул ук вакытта сагышлы-рәнҗүле дә иде бу тавыш... Аның кеше заты, бигрәк тә яшел күзле, тавышсыз кыз бала белән мәңгегә бәхилләшүе иде... Пүрехан Мөхәммәтҗан карт янына кире әйләнеп кайтмады... Бары тик соңыннан Яланкүл авылы тирәсендә төннәрен ялгыз бүре улавын куркып тыңладылар, иртәләрен аның гарип аяк эзләре буенча Пүрехан икәнлеген белделәр, әмма ул кешеләр янына яңадан әйләнеп кайтмады... Ул адәми затларның бу аерылу хыянәтен аңлый да, кабул итә дә алмады...

Мөхәммәтҗан карт, Тулпарына утырып, Яланкүлгә бер атнадан соң, ялгызы кайтып керде. Ул сөйләшмәскә, көлмәскә әйләнде, намазларын укыгач, кулына үзе ясаган скрипкасын ала да тимер өенә кереп бикләнә. Анда елый-елый, Сак-Сок көенә, инде телсез кызы Хөснибикәгә багышлап, бәет әйтә, бәет чыгара иде...

Мәзлүмәм идең, җаным-кызкаем,
Мөсафир кылдың үзеңне, назкаем.
Үгетли алмадык, ятып калмадың,
Олаулар китте тезелеп кыйбладин.

Һуштан ауганчы безләр сыктадык,
Кайгы-сагыштан бергәләп сыкрандык.
Күрешә алмабыз Сак белән Соктай,
Сөйләшә алмабыз су белән уттай.

Бәхетең ачылсын инде, балакай,
Ерак илләрдә калдың, колынкай.
Кошлар җиткерсен бәнем сәламем,
Кулда калтырый каурый каләмем.

Хәтфә бишмәтем туя кимәдем,
Газиз кызымны туя күрмәдем.
Маллар табылыр, башың сау булса,
Кайгың таралыр, бәхетең ачылса...

Ә ул бәхет ачылачак иде, ачылачак! Әмма моның өчен актарылып аккан диңгез суларын кичәргә, кеше менә алмаган биек таулар аша үтәргә, чүлләрдә пешәргә, җилләрдә өшергә, бер сынык икмәккә, бер йотым суга тилмерергә, иң якыннарын мәңгегә югалтырга, кеше почмакларында бәрелеп-сугылып йөрергә – Аллаһ биргән бөтен сынауларны да үтәргә туры киләчәк иде... Хәзергә моны Себердә калган Мөхәммәтҗан карт та, Төркиягә һиҗрәткә киткән Хөснибикә дә белмиләр иде...

## Һиҗрәт эшелоны

Киттеләр...

Менә бу юлы чынлап киттеләр инде...

Әле Яланкүлдән чыгып киткәндә, Умба белән ике арадагы карлы юллар буйлап барганда, шау-гөр килеп, Умбада, Мәтин байларда кунак булып ятканда, бу әле чын мәгънәсендә китү булмаган икән. Барыбер үз илең, аякка нык басып торган үз җирең, тирә-якта үз халкың иде, ә хәзер бу тимер арбада дыңгырдап билгесезлеккә очасың, кая барганыңны да белмисең... Авыл халкының күпчелеге поездга беренче тапкыр утыруы иде, башта куркудан авыз да ача алмадылар, бер-берләренә сыенып, тын гына утырдылар. Аннан бераз ияләшә төштеләр, хатын-кызлар вагон тәрәзәләренә капланды, ирләр киңәш-табыш итте, юл хәстәрләрен күрделәр, балаларга да җан керде, алар вагон буйлап йөгерешә башлады. Бары тик Хөснибикә генә, өнсез калып, бер почмакта утыра, Умба вокзалындагы хәлләрдән соң ул һаман аңына килә алмый иде...

Һиҗрәт эшелоны ачы төтеннәр чыгарып кузгалып киткәч, Хөснибикә читлектәге кош кебек бәргәләнде, Пүрехан белән атасының янәшә йөгергәнен күреп, алар янына сикереп төшәргә омтылды, әмма ире аның беләгеннән кысып тоткан иде. Менә Пүрехан чылбырыннан ычкынды, сикереп-тәгәрәп диярлек бар көченә поезд артыннан ыргылды, Хөснибикәнең газиз атасы, тун чабуларына уралып, юлда егылып калды. Атасын тыны белән тартып алырлык булып, Хөснибикә вагон тәрәзәсенә капланды, сәер авазлар чыгарып, сулкылдады-аһылдады, әмма аны беркем дә аңламады, һәркемнең үз кайгысы иде. Инде Умба да, бүредән алып үстергән Пүрехан да, телсез-чукрак Хөснибикәнең карт атасы Мөхәммәтҗан да бик еракта, ак томаннар артында калдылар. Һәм Хөснибикәнең үзәген өзеп, бәгырен телеп, бер уй үтте, бу – аерылышу иде... Бу – атасы, туган авылы, анасының кабере, узган тормыш белән мәңгегә аерылышу иде. Һәм ул аларны инде беркайчан да күрмәячәк иде...

Башкалар ичмасам кая барганнарын, ни өчен барганнарын беләләр, ә ул, ишетмәгәч, сөйләшә алмагач, берни аңламый, кайгыдан кычкырып елый да алмый, өнсез калып, бер почмакта утыра. Юк, утырмый, әйтерсең лә, балачактагы кебек, су төбенә төшеп китте, күл төбенә төшеп ятты. Ул чакта аны, тешләре белән күлмәк итәгеннән өстерәп, күл төбеннән Пүрехан алып чыккан иде. Ә хәзер Пүрехан да юк, атасы да ак кар өстендә егылып калды, тимер арба, чайкала-чайкала, аны алардан аерып алып китеп бара... Хөснибикә, чарасызланып, тагы вагон тәрәзәсеннән тышка карады, ә анда кар каплап киткән ала-кола дала, анда-монда тырпаеп утырган камыш сабаклары гына күзгә чалынып кала, урыны-урыны белән бәс сарган агачлар да күренеп китә... Авыллар да юк, Яланкүл дә юк, Яланкүл янындагы эрбет-карагай урманнары да, хәтта күлләр дә юк... Ап-ак дала, шул ап-ак даладан язмышына таба һиҗрәт кәрваны чаба, йөзләгән татар, дин-ислам хакына, туган-үскән җирләрен калдырып, билгесез илләргә китеп бара...

Кемнеңдер йомшак кына орынуыннан, Хөснибикә сискәнеп китте, борылып караса, елмаеп басып торган Зөлбану кардәшен күреп, уянып киткәндәй булды. Зөлбануның нур чәчеп торган йөзе, ярату һәм кызгану белән тулган зур яшькелт күзләре Хөснибикәне яңадан бу дөньяга кайтарды, үзенә тартып торган күл төбе әллә кайда – еракта калды, аның белән бәйле хатирәләр дә таралып, артка чигенде. Әйе, Хөснибикә Яланкүлдә түгел иде, аккошлар оя корган Ырыскүл дә түгел бу, һәм ул да күл суында түгел, үзен алып китеп барган тимер арбада чайкала... Әмма ул монда үзе генә түгел бит, әнә ире Салих нәрсәләрнедер урнаштырып, барлап йөри, вакыты-вакыты белән, борчылып, Хөснибикә ягына карап ала. Әнә әтисенең кыз туганнары Мәхсүрә һәм Мансура апалары, энесе Сахипзадә әкә, менә янында

елмаеп Зөлбану басып тора... Ярты авыл монда икән бит, ул ялгыз түгел, әмма әтисе генә юк, үз туганнары гына юк, алар анда калдылар...

Хөснибикә кул хәрәкәтләре белән Зөлбанудан шулар турында сорады, ни өчен биредә әтисенең һәм туганнарының юклыгын, үзләренең кая барганын белергә теләде. Зөлбану да үзе белгәнчә аңлатырга тырышты, бер күккә, бер җиргә төртеп күрсәтте, Аллаһ, иман, диде, шуның хакына чит җирләргә күчеп китүләрен әйтте. Аның кул хәрәкәтләреннән күренгәнчә, бара торган җирләре бик ерак икән, әмма бик матур ди, анда җәен-кышын җимешләр үсеп утыра, былбыллар сайрап тора ди, Себердәге кара урманнар урынына җәннәт бакчалары шаулый ди... Боларны азмы-күпме аңлагач, Хөснибикә тагы уйга калды, нигә шундый матур, рәхәт урынга аның әтисе һәм туганнары күчми икән соң? Аның әтисе бит дөньяның иң акыллы кешесе, барасы җирләре алай яхшы булгач, ул да анда китәр иде, Себернең ак карын кочаклап, егылып ятып калмас иде... Әмма Хөснибикә болар турында Зөлбануга аңлатып тормады, чөнки бу сорауларга барыбер аның да җавабы булмас иде. Зөлбану белән аралашып алгач, ул барыбер бераз тынычланды, ул арада янына Мәхсүрә һәм Мансура апалары да килеп җитте, кул астында булган нәрсәләр белән тамак ялгап алдылар, озын юлга яраклашу-җайлашу хәстәрен күрә башладылар. Әйтмәсәләр дә, һәркемнең уй-хәсрәте үзе белән иде, һәркем авылда иң якыннарын калдырып киткән, ни әйтсәң дә, җаннарның яртысы анда өзелеп калган иде... Хатын-кызлар яшеренеп кенә сызланды-елады, ирләр, үз хәлләрен күрсәтмәс өчен, эш тапкан булып, вагон араларында әрле-бирле килде, бала-чага, мондый кысынкылыктан һәм тарлыктан гаҗиз булып, тәрәзәләргә сарылды, алар хыялларында булса да ак дала буйлап тәгәрәделәр, билгесез язмышлары каршына йөгерделәр...

Кышкы көн кыска, ул арада өйлә намазы вакыты да килеп җитте, сәфәрдә булгач, аны икенде белән бергә кушып укырга булдылар. Ирләр уникенче вагонга юнәлде, карт-корылар, хатын-кызлар һәм балалар хәзергә үз вагоннарында калды, шунда укырга булдылар. Уникенче вагонның кырый-кырыйларына сандык-әрҗәләр өелгән иде, уртасы исә буш, юлчылар өчен махсус шулай көйләнгән. Хатын-кызлар башта барып, аны тәртипкә китереп, юып чыктылар, идәннәргә үзләре тукыган паласлар җәелде, җылы булсын өчен, астына киез дә салып калдырылды. Уникенче вагон шунда ук ямьләнеп китте, Яланкүл мәчетенә охшап калды. Бу юлы намазда Юанбаш Мөхәммәдине имам итеп билгеләделәр, аннан чиратлап имамлык итәргә булдылар. Инде туган авыллардан чykканнан бирле намазлар кыскартылып, сәфәр намазы итеп укыла иде, өйлә белән икендене, ахшам белән ястүне дә бергә кушып укыдылар, бу юлчылар өчен бик җайлы булды. «Вакыт иркен булганда, бәлки, барысын да тулысынча укырга кирәктер?» диючеләргә белемлерәк кешеләр: «Бу – Аллаһның мөсафирларга бүләге, бүләкне кабул итмәү рәхмәтсезлек булыр иде», дип җавап бирделәр. Бу юлы да өйлә белән икенде бергә укылды, аннан соң ирләр, таралышмыйча, бераз киңәшеп алырга булдылар.

– Җәмәгать, инде урнаштык, исән-имин кузгалып киттек, Аллаһ ниятләгән урыннарыбызга сау-сәламәт барып җитәргә насыйп итсен! – дип башлады сүзен Төхфәтулла улы Мөхәммәди Юанбаш. – Юлыбыз әле шактый озын, атнадан артык барасы. Миндә тәкъдим бар – хатын-кызлар үзләре аерым вагоннарда барсыннар, ирләр – аерым. Чөнки күрәм, хатын-кызларыбыз чит ирләрдән бик уңайсызланалар, киенә-чишенә дә алмыйлар, ятып торырга да кыенсыналар. Әйдәгез, бу вакытта гаиләләребездән аерылып торыйк, кирәк тапсагыз, әнә, ишек төбендә очрашыгыз, тукталышларда хәл итәсе нәрсәләрне хәл итегез. Кыз балалар әниләре белән калыр, малайлар – әтиләре белән. Әгәр

дә ки вагонда гел туганнар һәм мәхрәмнәр генә икән, ул чагында бергә дә мөмкин, әмма вагон тутырырлык туган-тумача юктыр дип беләм.

Ирләр гөрләшеп алдылар, алар үзләре дә чит хатын-кызлар белән бер вагоннарда барырга уңайсызланалар, бу турыда ничек сүз башларга гына белмиләр иде. Рәхмәт Юанбаш Мөхәммәдигә, хәлләренә керде, шулай итәсе булыр, диештеләр. Кулга каләм тотып, ак кәгазьгә язып, вагоннарны бүлештеләр, һәр вагонга бер җаваплы кеше билгеләделәр. Яшьрәкләргә дә эш табылды – алар станцияләрдә поезддан төшеп, халыкка ашарга-эчәргә алып менәргә тиешләр, моның өчен һәркемне йөгертеп булмый. Тукталышларда бигрәк тә сак булырга кушылды – беркем рөхсәтсез беркая китәргә тиеш түгел, аяк язарга ишек төбенә генә чыгып басасы, бу бигрәк тә хатын-кызларга һәм балаларга кагыла. Инде атна-ун көн шактый озак вакыт, аны бушка уздырырга ярамас, намаздан соң – ирләр, намаз араларында хатын-кызлар, балалар, уникенче вагонга җыелып, вәгазь тыңларга, дәресләр алырга дип киңәшелде.

– Синнән сорыйм әле, Мөхәммәди әкә, күңелемдә калмасын – бер һиҗрәткә дип юлга чыккач, кире кайтырга ярыймы?

Бу сорауны Хөснибикәнең ире Салих бирде, барысы да аптырап аның ягына борылып карады.

– Ни өчен шулай дип әйтәм, чөнки үзегез күрәсез, хатыным Хөснибикә бик газаплана, корсагындагы баласына зыян килмәсен, дим. Ул бит башкалар кебек түгел, берни белми, кая барганын, нигә атасын, туганнарын, авылны ташлап чыгып киткәнне аңламый, шуңа күрә бик сызлана, мескенем... Үзегез беләсез, каенатай аны җибәрергә теләмәде, мин каты торганга гына бу юлга кузгалдык. Аларның Умбада йөрәк өзгеч аерылышулары җаныма тынгылык бирми, үземне гел гаепле кебек хис итәм. Күңелемә шик килде... Тора алырбызмы икән без анда, бөтенләй чит-ят илләрдә? Барыбыз да саргаеп үлмәбезме икән?

Кайберәүләр мондыйрак сорауларны инде Умбада ук бирә башлаганнар иде, хәтта Аубаткан һәм Яланкүлдән берничә гаилә Умбадан кире авылларына да кайтып китте. Нишлисең, һәркем үзе хәл итә, беркемне дә мәҗбүриләү юк. Юл җиңел түгел, әле анда ни көткәнен дә беркем белми, шуңа күрә икеләнүчеләр дә күренә башлады. Әмма һиҗрәт – икеле-микеле уйный торган нәрсә түгел, бу – бик җитди эш, бары тик Аллаһ ризалыгы өчен, дин-ислам хакына башкарыла торган гамәл. Күңелгә шик кергән икән, аны бары тик дин-исламга таянып кына аңлатырга һәм таратырга мөмкин. Төхфәтулла улы Мөхәммәди шулай эшләде дә.

– Һиҗрәт нияте белән бер юлга кузгалгач, кайтып-китеп йөрүләр юк инде ул, Салих энем, – диде ул. – Әлбәттә, ярты юлдан борылып кайтып китәргә дә була, Умбада кайберәүләр шулай эшләде дә, аларның шул вакыттан инде һиҗрәтләре өзелде... Барып урнашкач, кайтып-килеп ике арада йөрсәң дә, ул инде һиҗрәт булмый, үзеңә җайлыны эзләп йөрү була. Без бит Аллаһ ризалыгы өчен, динебезне саклап калу өчен шундый авыр юлга кузгалдык, менә шушы иман хакына барысына да түзәргә тиешбез. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһиссәламне искә төшерегез, һиҗрәт бит аннан башланган! Мәккә кяферләренең җәберләүләренә түзә алмыйча, дин-исламны саклау һәм тарату өчен, илле өч яшендә туган җирен, якыннарын калдырып, Ясрибкә, ягъни хәзерге Мәдинә шәһәренә күчеп китәргә мәҗбүр була. Дөрес, аңа кадәр ул аз санлы Мәккә мөселманнарын, үлем-җәбердән саклап калу өчен, яшерен генә башта Хәбәшстанга, аннан Мәдинәгә күчерттергән була. Әле безнең арттан куа чыгучы, эзәрлекләүче юк, ә Мәккә мөшрикләре пәйгамбәребезнең дә, аңа ияргән мөселманнарның да теңкәләренә тигәннәр, эзәрлекләгәннәр, төрлечә кимсеткәннәр, үз ялган диннәренә аударырга тырышканнар. Пәйгамбәребез Кәгъбәтуллада намаз укып утырганда, ул сәҗдәгә киткәч, аның өстенә тизәкле тирес тә ташлаганнар, ләгыйньнәр! Бу

явызлар хәтта ки сөекле пәйгамбәребезне үтерергә ниятлиләр, план коралар, әмма Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аша аңа бу хакта җиткерә, кяфер-мөшрикләр аны үтерә алмыйлар. Сәфәр аеның егерме җиденче көнендә пәйгамбәребез хәзрәти Әбү Бәкер белән бергә, Мәккәдән Мәдинәгә күчәргә ниятләп, юлга кузгалалар. Мәккә мөшрикләре пәйгамбәребезне өендә таба алмагач, артларыннан куа чыгалар, ниятләре – юлда тотып үтерү була. Юлчылар исә ул вакытта Мәвер тавында бер куышка кереп яшеренәләр, Аллаһ әмере белән, бу тау тишеген шунда ук үрмәкүч пәрәвез белән чорнап ала, күгәрченнәр оя кора һәм күкәй сала... Бу Аллаһның бер хикмәте, рәхмәте була инде... Куа килүчеләр тау куышына килеп җиткәч, аларның аяк тавышларын ишетеп, Әбү Бәкер бик нык курка, хәзер тотып алып, сөекле пәйгамбәребезне үтерерләр инде, дип кайгыра. Моны күреп, Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа әйтә, «Син кайгырма, Аллаһ безнең белән», ди. Нәкъ шулай була да – куа килүчеләр пәрәвез сарган тау тишеген күреп, монда күптән кеше аяк басмаган икән, дип, борылып китеп баралар. Пәйгамбәребез өч көн, өч төн шушы тау куышында гыйбадәттә үткәрә, Рабигул-әүвәл аеның беренче дүшәмбесендә аннан чыгып, Мәдинә тарафына юнәлә. Моны ишетеп, Мәккә мөшрикләре аны тагы куа чыгалар, әмма Аллаһы Тәгалә үзенең сөекле пәйгамбәрен явызлар җәберенә бирми, алар Әбү Бәкер белән исән-имин Мәдинәгә килеп җитәләр. Ә Мәдинә халкы пәйгамбәребезне урамнарга чыгып, бик сөенеп каршы ала, һәркем аны үзенең кунагы итәргә хыяллана. Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылган башка мөселманнарны да Мәдинә халкы үз туганнарыдай якын күрә, йорт-җирен, ризыгын бирә, ислам динен Мәккәдәге кебек, яшермичә, ачыктан-ачык тотарга шартлар тудыра. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салаллаһу галәйһиссәлам Мәдинәгә күчеп килү белән, биредә тиз арада ислам дине тарала башлый, беренче ислам дәүләте дә монда төзелә, соңыннан мөселманнар Мәккәгә барып та аны сугышсыз яулап алалар. Менә үзегез уйлап карагыз инде, әгәр пәйгамбәребез һәм башка мөселманнар Мәккәдә калган булсалар, аларның язмышы ничек булыр иде? Дин-исламның язмышы ничек булыр иде? Дөрес, Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребезне дә, динебезне дә саклар иде, әмма тагы күпме газаплар күрер иде алар? Димәк, һиҗрәт әмере аларга Аллаһтан булган, безгә дә бу уйларны Аллаһ күңелебезгә салды, шуңа күрә, мондый җаваплы юлга чыккач, икеләнмик инде, туганнар!

Ир-атларның бер өлеше бу хәлләр турында ишетеп белсә дә, күпчелек халык Юанбаш Мөхәммәди сөйләгәннәрне авыз ачып тыңлады. Әйе, бер караганда, аларның хәлләре әле Аллага шөкер, арттан куа килүчеләр юк, эссе чүлләрдә дөягә атланып та үтмиләр бу юлларны, тимер атларда гаиләләре белән җилдерәләр... Анда да ярдәм итәрләр, инша Аллаһ, мөселманнар янына баралар бит, Мәдинәдәге ансарлар кебек, аларны да ташламаслар... Ә менә бер баргач, яңадан илгә кайтып-килү мәсьәләсендә кайберәүләрендә барыбер сораулар калды. Салих тагы шул сорауны күтәрде:

– Мөхәммәди әкә, пәйгамбәребез соңыннан Мәккәгә кайткан түгелме соң, безгә Тара мәчетендә шулайрак сөйләгәннәр иде, – диде.

– Әйе, Мөхәммәд галәйһиссәлам Мәккәгә килгән, әмма ул Хаҗ кылу өчен генә анда барган, соңыннан Мәдинәгә кайтып киткән, – дип җавап бирде Юанбаш Мөхәммәди. – Ул бит үлүен дә Мәдинә шәһәрендә үлгән, шунда күмелгән дә... Күрәсезме, хәтта ул да, инде Мәккә халкы иман китергәч тә, аларны гафу иткәч тә, яңадан анда кайтмаган, чөнки ул Мәдинәгә һиҗрәт нияте белән, дин-ислам хакына күчеп киткән булган һәм шунда калган да... Безгә дә пәйгамбәребез сөннәтен тотарга кирәк. Әлбәттә, дөньяда төрле хәлләр булырга мөмкин, Умбадагы кебек, кире борылучылар да булуы бар, әмма ул чагында алар һиҗрәт савабыннан мәхрүм кала инде...

Шулай сөйләшеп, вәгазьләшеп утырып, ахшам җиткәнне дә сизмичә

калганнар, азан әйтеп, камәт төшереп, тиз генә намазга бастылар. Намаздан соң, алдан сөйләшенгәнчә, вагоннарда урыннарны алыштылар – ирләр ирләр белән, хатын-кызлар үзләре аерым урнашты, балалар да шулай бүленде. Таң алдыннан исә беренче зур станциягә – Кызылъяр-Петропавелга килеп җиттеләр, эшелон монда шактый гына торасы икән, ир-атлар төшеп, аяк язып алырга, һава суларга булдылар. Хатын-кызлар исә, башта куркыбрак торсалар да, паровоз озак тора, дигәч, ирләре янына төшеп, бер-берләренә азык һәм кирәк-яракларны бирештеләр, үзара киңәшеп тә алдылар. Ул арада балалар да батыраеп, берәм-берәм баскычлардан сикерешеп төшә башладылар, ата-аналары аларны каравылларга ашыкты, шулай итеп, һиҗрәт составы тирәсендә йөзләгән кеше җыелган мәйдан барлыкка килде.

Аларны күреп, әллә кайчаннан биредә яшәүче казакълар һәм татарлар йөгереп килеп җитте, алар Тара татарларының дин-ислам хакына госманлы иленә китеп барулары турында инде ишеткәннәр иде, һәркем бу мөһаҗирләрне күреп калырга ашыкты. Казакълар – бик юмарт, ихлас халык, алар шунда ук итен-маен, күчтәнәчләрен күтәреп килеп җиттеләр, аны сөенә-сөенә, Аллаһ ризалыгы өчен, дип, китүчеләргә тарата башладылар, аларның хәер-фатыйхасын, догаларын алып калырга тырыштылар. Бер-берләрен моңа кадәр күрмәгән-белмәгән кешеләр кочаклашып күрештеләр, елап аерылыштылар, чөнки гасырлар буе бергә яшәп, алар инде туганлашып беткәннәр иде... Һиҗрәткә китеп барган татарларны Себер урманнары гына түгел, кар каплаган казакъ далалары да, шушы далаларның чын хуҗасы булган казакъ халкы да бәхиллеген биреп, елап озатып калды... Әмма татарларның авылы-авылы белән кубарылып, туган илләрен ташлап китеп барулары дала казакъларының күңеленә шом салды. Татарлар, бигрәк тә бөтен урман-дала халкына гыйлем биргән укымышлы бохарилар юкка гына болай кузгалмаслар, димәк, илдә ниндидер афәтләр көтелә, дип уйлады алар. Үзләренең олылары, укымышлы муллалары белән дә бу хакта киңәшеп карадылар. «Ил өстенә кызыл кыргын килә», диде Тараз якларында яшәүче бер акыл иясе, ягъни, кызыл террор, әмма моңа кадәр әле нәкъ ун ел вакыт бар иде...

Һиҗрәт эшелоны, Кызылъярдан акрын гына кузгалып, Курган-Чиләбе якларына юл алды, аннан соң Урал таулары, Уфа-Самарлар булыр, алардан соң – Рәзән-Мәскәүләр, ә Мәскәүдән – Хаҗибәйле-Одесса, Кара диңгез аша – Истанбул... Юл әле бик ерак, ул әле башлана гына, шуңа күрә, иманга зәгыйфьлек китермичә, саулыкны саклап, шушы тәртипләргә өйрәнеп һәм түзеп, барасы да барасы... Вагон араларында интегеп йөрмәс өчен, Кызылъярда туктап торганда ук, хатын-кызлар һәм балалар уникенче вагонга керделәр, Зәйнәп абыстай аларга бераз үгет-нәсихәт биреп алырга булды. Хөснибикә белән Зөлбану да биредә иде, Хөснибикә ишетмәсә дә, башкалардан аерылып каласы килмәде. Балалар исә бу кадәр иркенлектән башта аптырап калдылар, аннан идәнгә җәелгән келәмнәр өстенә ятып, тәгәри-уйный башладылар. Алар шулай бераз кан тараткач, Зәйнәп абыстай барысын да каршына тезеп утыртты, әниләре дә балалары янына чүмәште. Яшьрәк кызлар, баласыз киленчәкләр аерымрак утырды, һәркемнең үз ишләре белән күбрәк аралашасы килә иде.

– Менә озын юлга чыкканнан бирле беренче тапкыр шулай үзебез генә иркенләп җыйнала алдык, Аллаһка мең шөкер! – дип башлап китте Зәйнәп абыстай сүзен. – Үзегез беләсез, хатын-кыз таифәсенең ирләргә белдерергә уңайсызлана торган нечкә яклары да бар, андый вакытта, бер-беребез белән киңәшик, ярдәм итешик... Безгә әле барып урнашканчы ирләребез белән аерым яшәргә туры киләчәк, моңа да ияләнергә кирәк. Ашау-эчү мәсьәләләрен һәр вагонда уртак хәл итәрбез, кемдә нәрсә бар – бүлешербез. Тәһарәткә су бар,

әмма зурлап юынулар урынга барып җиткәч, тәмам урнашкач кына булачак, анысына да әзер булып торыгыз. Юлда чисталыкны саклау бик мөһим, Аллам сакласын, авырып китсәк, монда өебез түгел, кул астында әллә нәрсә юк...

Шулчак Таһирә апа дип йөртелгән Кумыслы хатыны сүзгә кушылды:

– Мин үзем белән барысын да алдым, Зәйнәп абыстай, – диде ул. – Китәбез, дип, җәй буе дару үләннәре җыеп киптердем, салкын тигәннән дә күп, ә эч киткәннән һәм катканнан агач кайрыларын төеп әзерләдем, төнәтмәләрем дә бар... Пешкән-янганнан төрле майлар да алдым. Алар барысы да үзем белән, төенчегемә сыймаганнары менә бу әрҗәләрдә.

– Бик яхшы булган, Таһирә апа, – диде Зәйнәп абыстай. – Син алайса авыруларның янына килгәннәрен көтеп торма инде, һәр көн иртә-кич хатын-кыз вагоннарын әйләнеп, урап чык... Үләннәреңне дә үзең белән ал. Кем ютәлли, кем чирли, кем уттай яна – барысын да тикшереп-белеп тор, бигрәк тә балаларны кара... Сез дә бер-берегезгә күз-колак булыгыз, хатыннар, чирегезне яшермәгез, чөнки урыны-вакыты андый түгел. Балалар дигәннән, монысын инде аналарына әйтәм – нык карагыз аларны. Сикереп-уйнап имгәнә күрмәсеннәр, гарип калмасыннар. Бигрәк тә станцияләрдә балаларыгызны кулыгыздан ычкындырмагыз, урамга чыксагыз, җылы итеп киенеп чыгыгыз. Каты чир-зәхмәт аркасында һиҗрәтегез дә өзелүе бар, Аллам сакласын!

Хатын-кызлар гөжләшеп алдылар, бу хәтле озак әзерлекләр белән, бу кадәр авырлыклар белән башланган сәфәрнең шулай өзелүен берәү дә теләми иде. Әйе, юл бик җитди, җаваплы, әмма билгеле бер тәртип белән яшәсәң, ашау-эчү, чисталык кагыйдәләрен сакласаң, исән-имин барып җителер, инша Аллаһ! Әнә Зәйнәп абыстай да шуларны раслый, моның өстенә, икеле-микеле уйлардан да арынырга, Аллаһка тәвәккәллек кылырга куша. Зәйнәп абыстай үзе белән Коръән китабын да алган икән, хатын-кызлар бераз тынычлангач, матур-моңлы тавыш белән укый башлады. Хатын-кызларның күбесе дини белемле иде, алар абыстай артыннан пышылдап кына кабатлап бардылар, вагон-мәчет илаһи бер нур белән тулды... Аннан Зәйнәп абыстай балалардан белгән аять-сүрәләрне укытты, алар аерым-аерым да, бергәләп тә җырлый-җырлый, суза-көйли, тәгәрмәч тавышларын да уздырып, урамда улаган буран тавышларын да күмеп, Коръән укыдылар... Бу мизгелләрдә инде еракта калып барган туган авыллар да, әле барып җитмәгән төрек иле дә, артта калган авырлыклар, алда көткән билгесезлекләр дә алар өчен юк иде... Һиҗрәт эшелонының уникенче вагонында, туң җир белән салкын күкне тоташтырып, изге Коръән аятьләре яңгырый, мөһаҗирләр исә илаһи нур эчендә йөзәләр иде...

Зәйнәп абыстайның бик оста сүз остасы, чичән икәнен дә белгән балалар аннан әкият сөйләвен дә сорый башладылар. Яланкүлдә вакытта, җәйләрен, малларны көтүдән каршы алганда, ул авыл балаларын күл буена җыеп, матур-матур хикәятләр, борынгыда булып үткән хәлләрне сөйли иде. Күпме буын балалар Зәйнәп абыстайның әкиятләрен тыңлап үсте. Хәер, аларны әкият дип тә әйтеп булмый, барлык вакыйгалар да шушы тирәләрдә булган, дип ышанып тыңлыйлар иде балалар. Ул бөтен Себер белән идарә иткән ханнар-солтаннар дисеңме, ил-җирләр өчен барган каты сугышлар, аягүрә үлгән батыр каһарманнар дисеңме, дошманга бирелмичә, манаралардан ташланган ханбикәләр дисеңме – тәннәр чымырдап торырлык, гомер онытылырлык түгел! Зәйнәп абыстайның шуларны сөйли башлаганын көтеп, балалар идәнгә җәйлап сузылып яттылар, олыраклар аның тирәсенә якынрак килеп утырды, чичәнә хикәятен башлады...

– Борын-борын заманнарда түгел, әле безнең бабайларның бабайлары заманында, Себернең патшасы Күчем хан булган... Карттәйләр сөйлиләр иде

– аның җирләре Алтайдан Урал тауларына кадәр җәелгән, котыптан кыпчак далаларына кадәр сузылган... Бу тирәдәге бөтен халыклар – иштәге-нугае, кыргыз-кайсагы аңа буйсынган, татарлар кул астында булган, Күчем хан аларның берсен дә рәнҗетмәгән. Динебезне ныгытыр өчен, Бохарадан ярдәмчеләр чакырткан, ислам динен таратырга Себергә йөзләгән мөселман килгән.

Себер җире киң икән, Күчем хан шундый ир икән,
Себер-йортта бер икән, милләтенә тиң икән,
Ирекле кеше ул булып, илне тотар ир икән!
Күчем хан илдә бер икән, ир сыртланы ир икән,
Милләтенең баласы – татарына тиң икән!

– Халкыбыз бай яшәгән, дәүләтебез нык булган, урманнарда киек, суларда балык гөжләп торган, хан бар кешене дә тигез күргән. Әмма Урал аръягындагы төкле урыслар бу җирләрне, бу байлыкны бездән тартып алырга теләгәннәр, кяфер патшасы Себергә үзенең яугирләрен җибәргән. Алар кеше үтерә торган утлы таяклар белән килгәннәр, безнекеләрдә ук та җәя, сөңге дә кылыч кына булган... Борынгыларның бәет-мөнәҗәтләрендә бу хакта менә ничек әйтелә:

Себер-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Күчем хан әйткән көн килде,
Чыңгызның куйган хан тагы
Кан тагы булып әверелде,
Татар иле камалды.

– Башта Йармак дигән канэчкеч атаманнары башкалабыз Искәрне басып алган, ул тирәдәге халыкны баш өсләрендә кылыч тотып көчләп чукындырган, чукынмаганнарны үтергән. Күчем хан яугирләре Искәрне камап алган, урыслар анда ачтан кырыла башлагач, Йармак аннан чыгып качарга омтылган, Күчем хан аны куып җитеп үтергән. «Эткә эт үлеме!» дигән. Әмма урыслар барыбер Күчем ханга, татарларга тыныч яшәргә ирек бирмәгәннәр, Себер өстенә яу артыннан яу җибәргәннәр. Урыслар килгән бер җиргә кәлгә салып куеп, аны утлы корал белән саклый башлаганнар, якын-тирә авылларны талаганнар, үзләренә буйсындырганнар. Безнең Торада да элек Күчем ханның ыстаны булган, ул җәйләрен биредә яшәгән, әмма урыслар аны да басып алганнар. Күчем хан ун-унбиш ел буе кулына кылыч тотып бу басып алучылар белән сугышкан, картайган, сукырайган, әмма урысларга үз теләге белән бирелмәгән, иманын сатмаган. Ул соңрак безнең Иртыш буйларыннан Уба елгасы буйларына чигенергә мәҗбүр булган, аның шәһәрләре анда да булган. Инде кяферләрдән еракта, Бараба далаларында бераз тын алыйм, көч җыйыйм, дип уйлаганда, урыс яугирләре аның җәйге ыстанына таң алдыннан, көтмәгәндә һөҗүм итеп, утлы таякларыннан бар халыкны диярлек кырып салалар, үтерәләр. Бу канлы сугышта Күчем хан каты яралана, аны яугирләре һәм уллары Убаның теге ягына алып чыгып китәләр, ә исән калган гаиләсен, балаларын, хатыннарын, киленчәкләрен урыслар әсир итеп алалар һәм башкалаларына алып китеп чукындыралар. Күчем хан каты ялалардан үлә, улларына, нәселенә кяферләрне Себердән කууны әманәт итеп әйтеп калдыра, ислам динен һәм милләтебезне васыять итә.

Каршына урыс килгәч, алдында үлем күргәч,
Анда әйтте Күчем хан:

– Үлем белән куркытмаң, курка торган уем юк!
Үлем туры килә икән, котыла торган буем юк!
Илем өчен илсенеп, җирем өчен җирсенеп,
Көрәшкәнне милләтем аңладымы – белалмам!
Аңламаса халыгым, аңлатмастан үлалмам!

– Бабайларның сөйләве буенча, Күчем ханның уллары һәм оныклары, ул үлгәч тә әле, бик озак еллар урысларга каршы сугышалар, ләкин аларны җиңә алмыйлар. Алар да безгә дәүләтне, динне һәм милләтне васыять итеп бу дөньядан китә... Татарлар Себердә яңадан дәүләтне торгыза алмыйлар, әмма динне һәм милләтне шушы көнгә хәтле саклап яшиләр. Дөрес, динебезгә, динебез аша милләтебезгә күп һөҗүмнәр булды, халкыбызның бер өлеше көчләп чукындырылды һәм урыска әйләнде, хәзер менә калганнарын да шул хәл көтә... Безнең аларны җиңәрлек көчебез юк, шуңа күрә үзебез китәбез... Иманны саклап калу өчен, урыска әйләнмәс өчен, туган җирләребезне калдырып, дөнья читенә чыгып киттек, оланнар... Бу тарихны, бу дастанны беркайчан да онытмагыз, кайда гына яшәсәгез дә, аны нәселегезгә тапшырыгыз. Әйе, без – дин-ислам хакына ерак илләргә һиҗрәт кылучы мөселманнар, әмма шул ук вакытта без әлмисактан бирле Себердә яшәгән, биредә дәүләтләр тоткан һәм аларны югалткан бөек һәм фаҗигале язмышлы халык – татарлар да... Менә шушы ике нәрсәне онытмасагыз – дин һәм милләт – аларга гомер буе тугры булсагыз, тагы ханлы да, данлы да булырбыз, Аллаһ теләсә!

Себер иле киң икән, татарның гөле икән,
Пәйгамбәрләр заманыннан намазлы җире икән,
Милләтенең сөйләме дә былбыллар теле икән,
Себер шундый ил икән!
Татарына тиң икән...
Котыплардан кыпчаккача тәхет тоткан җир икән!
Дәүләт тоткан ил икән!
Күчем хан шундый ир икән –
Татар өчен сугышта арысланга тиң икән!

Зәйнәп абыстай бүген «Күчем хан» дастанын бигрәк тә йөрәкләргә үтәрлек итеп әйтте, бу аның илдән китүчеләргә васыяте кебек тә яңгырады. Әйе, олы як кая барса да, кайда яшәсә дә, үзләренең кем икәнлекләрен, кайлардан килүен беркайчан да онытмаячак, үлгәнче истә тотачак... Ул гынамы, – алар Себер елгаларындагы җәелеп аккан язгы ташуларны, актарылып өскә чыккан боз тауларын, язын авыл өстен тутырып очкан аккошларны, җәйге йомшак җилләрне, авыл урамнарын иңләп кайткан мал көтүләрен, сандугачлы таңнарын, көзге урманнарның, үзәк өзеп, моңлы шаулавын, сазлык-әрәмәләрдә тәгәрәп үскән мүк җиләкләрен, бөрлегәннәрне, кыйблага карап сузылган кышкы чана юлларын, шул юллар буенча мәңгелеккә китеп барган чакларын – алар мәңге онытмаячак! Юк, юк, юк... онытмаячак... Ә менә яшьләр, алардан соң туган, алар бу дөньядан киткәч туган буын – хәтерләрме боларны? Дөньяның читендә, кара урманнар арасында, котып тарафында Себер дигән җир барын, анда ятим булып калган туган авылларын, һаман шунда яшәп яткан милләттәшләрен, кан кардәшләрен хәтерләрләрме, белерләрме, онытмасалармы алар?

Зәйнәп абыстай вагон идәненә тезелешеп утырган балаларга, аларның тынып калган аналарына карады. «Менә бу балаларның кем булып үсүләре, тарихи хәтерне ни дәрәҗәдә саклаулары аналарыннан да торачак, – дип уйлады ул. – Димәк, күбрәк алар белән эшләргә, аларга аңлатырга кирәк булачак. Дини илгә баралар, дин болай да булыр, инша Аллаһ, ә менә телне, милли

тарихны һәм мәдәниятне, үз ризыкларыбызны һәм киемнәребезне, татарга гына хас һөнәрләрне чит-ятлар арасында саклап калу шактый авыр булачак... Картнә-әбиләр, әни-инәләр бу гөнаһсыз сабыйларны ничек тәрбияләр – алар шундый булачак. Балаларның да исләренә һәрвакыт ана теленең матурлыгын, байлыгын, кирәклеген искә төшереп тору лазем...»

## Һиҗрәт шаһите

Баралар...

Татар тарихыдай чиксез кыпчак далаларын, милләт хәсрәтедәй төпсез Себер елгаларын кичеп, инде Урал тауларына кереп баралар...

Гомерләрендә дә тау күрмәгән себер татарлары, шомланып һәм сокланып, юлларында мәгърур басып калган таш-кыяларга текәләләр... Үзләренең дә заман башларында шушы биек таулардан төшкән Тау Ирләре икәнлекләрен белмиләр алар... Нух пәйгамбәр көймәсе белән шушы Урал-Җаек тауларыннан төшеп, көнчыгыштагы урман-далаларга, көнбатыштагы үзән-кырларга таралган бөек төрки-татар кавеме хәзер инде тауларын танымый... Инде аларны да җиде ятка калдырып, илдән китеп баралар... Инде үзенең дәһшәтле таулары белән Миасс, Злотоуст станцияләре артта калды, алда Уфа – татар шәһәре, диделәр, анда эшелон шактый торасы икән.

Һиҗрәт эшелоны Урал таулары аша үткәндә, Хөснибикәләр вагонында баручы олы яшьтәге Кумыслы хатынының авырып киткәне билгеле булды. Аның авырганлыгын Таһирә апа ачыклады, чөнки ул һәр көн иртә-кич хатын-кыз вагоннарын йөреп чыга, берәрсе аз гына авырый башласа да, аны карый, үләннәре белән дәвалый, аякка бастыра иде. Ә менә Кумыслы хатыны Мәрфуга белән әллә нәрсә булды, дарулар да ярдәм итмәде, күзгә күренеп сүнде, хәле начарайганнан-начарая барды. Хатыннар аның янына барып, баш очында «Ясин» дә укыдылар, өшкерделәр дә, төрле төнәтмәләр дә биреп карадылар – файдасы тимәде. Уфага җитәр алдыннан, ул кул хәрәкәтләре белән Зәйнәп абыстайны үз янына чакырып алды, аңа ияреп, башкалар да Мәрфуга яткан урынга җыелдылар. Ул ярылып кипкән иреннәрен көч-хәл белән ачып, аларга соңгы сүзләрен, соңгы теләген әйтеп калырга ашыкты:

– Мин китәм инде... Аллаһ янына китәм... Үз өемә кайтам... Мине юлда ташлап калдырмагыз... Мөселманча күмегез... Соңгы әманәтем шул... Үлемтек-кәфенлекләрем үзем белән... Мин аларны юлга алып чыккан идем... Һиҗрәтем өзелә инде... Шул үкенеч...

Мәрфуга хәле бетеп, күзләрен йомды, ут булып янган битләре өстеннән тозлы күз яшьләре тәгәрәп төште. Янына балалары җыелды, кайсыдыр тагы Коръән укый башлады. Ул туктаган арада, Зәйнәп абыстай Мәрфуганың ак яулыклы башыннан сыйпап, үз догаларын укыды, тагы өшкереп карады...

– Һиҗрәтең өзелмәс, туганым, борчылма... Юлга һиҗрәт нияте белән чыккач, савабы да һиҗрәт өчен булыр, инша Аллаһ!

Мәрфуганың керфекләре тетрәп куйды, ул күзләрен ачты, беренче һәм соңгы тапкыр күргәндәй, янында басып торган хатын-кызларга карады. Кайда ул, кая бара? Аста ярсып тәгәрмәчләр дөберди, барган уңайга, идән-түшәмнәр чайкала, тәрәзгә юеш кар бөртекләре килеп сыланалар да, күмер төтене белән кушылып, каралып агып төшәләр... Әйтерсең лә табигать үзе бу татар хатынын соңгы юлга кара күз яшьләре белән елап озата... Юк, бу бит Кумыслы күл өсләреннән шулай кара карлыгачлар очып уйнаклый, әйтерсең лә зур давыл, яңгыр буласын хәбәр итәләр...

– Кумыслы... күл... буйларында...

«Саташа, бичара, һаман шул Кумыслы күл, туган авылы белән саташа», дип уйлады үлеп барган Мәрфуганы чорнап алган хатыннар. Ә ул саташмый иде, аның, мәңгелек өенә киткәндә, үзе белән Кумыслы күл буйларында үскән үләннәрнең исен, суының тәмен алып китәсе килә иде... Әмма исәннәр моны аңлыймы соң?!

Мәрфуга хәлсез куллары белән баш очына ишарәләп күрсәтте. Ул яткан кайнар мендәрне бераз күтәреп карадылар, аннан төенчеге белән үлемтекләре һәм... төргәктә кипкән үләннәр һәм туфрак белән кечкенә шешәдә су килеп чыкты. Болар – Мәрфуга белән Кумыслыдан һиҗрәткә китеп барган туган туфрак һәм берничә йотым су иде... Төргәкне Мәрфуганың еш-еш күтәрелгән күкрәгенә куйдылар, ул аннан калтыранган бармаклары белән кипкән үләннәрне алды, аларны битләренә китерде, тирән итеп бер иснәде, талгын бер рәхәтлек кичереп, елмаеп куйды...

Саташа, бичара, һаман Кумыслы күл буйларында үскән үләннәр белән саташа, дип уйладылар аны саклап торган хатыннар. Ә ул саташмый иде, ул туган туфрагы белән тагы бер тапкыр бәхилләшә иде... Моны аңлап, хатыннар нәни шешәдәге Кумыслы суын инде китеп барган Мәрфуганың уттай иреннәренә тидерделәр, ул җиңел сулап куйды, әйтерсең лә шуны гына көтеп яткан, шуны гына теләгән... Суның соңгы тамчыларын ул йота алмады, алар ирен читеннән үлемтек төенчегенә тәгәрәп төште... Мәрфуга очып китәргә теләгән коштай талпынып-тартынып куйды, терсәкләренә таянып, яткан җиреннән бераз күтәрелә төште һәм, җиңел сулап:

– Әшһәду әлләә иләәһә илләллааһу үә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ, – дип шәһәдәт кәлимәсен әйтте һәм тынычланып, урынына сеңде... Кумыслы хатыны Мәрфуга беренче һиҗрәт шәһите булды...

Мәрфуга шулай тыныч кына, язмышы белән килешеп, бу дөньядан китеп барды, калганнар исә бары тик бер сорауга җавап эзләделәр – мәет белән нишләргә? Монда аны юып та, күмеп тә булмый, димәк, бу эшләрне алдагы станциядә эшләргә туры киләчәк. Әмма паровоз бу хәтле вакыт аларны көтеп тормаячак бит, ирен, балаларын да мәет күмү өчен анда калдырып булмый, алар соңыннан һиҗрәткә кушыла алмаячаклар. Димәк, мәетне Уфада калдырырга туры килә, әмма кемгә? Бу хакта эшелон башлыгына да җиткерделәр, ул да мәсьәләне Уфада хәл итәргә киңәш итте. Нәрсә генә булса да, мәет вагонда калдырыла алмый иде.

Уфага килеп туктау белән, урысча бераз яхшырак белгән ир-атлар станция начальнигына юнәлделәр, хәлне аңлатып бирделәр. Олы яшьтәге урыс кешесенең мондый хәлләр белән очраштыргалаганы булган, ул аларга бу тирәдә яшәүче татарларны эзләп табарга һәм мәетне күмәр өчен шуларга биреп калдырырга киңәш итте. Вокзал янында гына татарлар яши икән, эзләп табып, хәлне аңлаттылар, үзләренең Себердән бөтен состав белән госманлыга һиҗрәткә китеп баруларын, юлда олы яшьтәге бер хатынның үлүен, аны биредә мөселманча күмәргә кирәклеген әйттеләр. Әмма паровоз аларны көтеп тормаячак, шуңа күрә, Аллаһ ризалыгы өчен, мәетне күмәргә алып калуларын сорадылар, кәфенлекләре дә, хәер-сәдакалары да барлыгын белдерделәр.

Бераз киңәш-табыш итешкәч, барысы да җыелып тагы вокзалга киттеләр, Уфа татарлары үзләре белән мәет салырга кабык колашасын, кирәк-яракларын алдылар. Ирләр җыелып Мәрфуга яткан вагонга керделәр, бу вакытта хатын-кызлар урамга чыгып торды, ярдәм итәргә якыннары гына калды. Мәрфуганы үлемтек төенчеге белән бергә күтәреп колашага салдылар, калган әйберләрен иренә, балаларына бирделәр. Мәетне күтәреп урамга чыккач, мөһаҗирләр аның янына җыелышты, барысы да тын гына һиҗрәт шәһидәсе белән бәхилләште... Ул арада, монда мин дә бар әле, дигәндәй, ачы итеп паровоз кычкыртып

җибәрде, вокзал өстенә кара төтен таралды, аның ачысы бу юлы күзләргә генә түгел, йөрәкләргә дә үтеп керде... Бу – кыйблага таба карап очкан, нурга таба йөгергән бер юлдашларыннан инде мәңгелеккә аерылу иде...

Паровоз тагы сузып кычкыртып җибәрде, вагоннар сискәнеп тартылып куйдылар, ул арада Мәрфуганың мәетен күтәреп алып киттеләр. Моны күреп, балалары һәм хатын-кызлар елаша башладылар, ирләр тәкъбир әйтергә тотындылар. Уфаның карлы урамнарына Себер мөһаҗирләренең бәхилләшү авазы булып тәкъбир яңгырады, ул Мәрфуганы күздән югалганчы озата барды, баш очында эленеп торды...

## Киттеләр...

Тагы кузгалып киттеләр...

Һиҗрәт юлында беренче шәһитләрен биреп, инде юлда ук һәрнәрсәгә әзер булып, язмышның күзенә туры карап, алар тагы кузгалып киттеләр... Алда – кар каплаган авыллар һәм шәһәрләр – Самар, Рузаевка, Рәзән, Мәскәү... Аннан – Хаҗибәйле-Одесса... Ары таба – Кара диңгез аша – Истанбул, госманлы иле, мөселманнар җире... Әмма аңа кадәр әле күпме барырга, юлда тагы күпме шәһитләр бирергә туры киләчәк аларга! Ә хәзергә алар бара – тәкъдирләренә буйсынып, киләчәккә зур өмет белән, әмма эчләре тулы сагыш-моң белән, Себер мөһаҗирләре һиҗрәткә китеп бара... ... Хөснибикә дә инде бу тимер арбадагы тормышына күнегә башлады. Ире белән тукталышларда, урамда очрашалар, уникенче вагондагы мәчеткә барган-кайтканда да күрешкәлиләр. Инде Салих та тынычланган, кире кайтып китү турында уйламый да, сорамый да... Үз вагоннарында да, мәчеттә дә көне буе вәгазьләр, дәресләр бара, Салих аларда гомер буе яшәп тә моңарчы белмәгәннәрен белде. Авылда мал арасында ятып, җәй буе озын кышка утын-печән әзерләп, кышлык азык булдырып, аның дөнья турында уйларга да вакыты юк иде. Ә дөнья әнә нинди зур икән бит – инде ничә көн баралар, әле Рәсәй җирләренең дә теге башына барып җитә алганнары юк. Монда төрле халык җыелган, шактый укымышлылар да бар, менә шуларның әйтүенчә, бу җирләр борынгыда барысы да татарларныкы булган икән. Себере дә, Уралы да, Самары да, менә хәзер үтеп китеп бара торган мишәр яклары да татарлар кулында булган. Башта Явыз Иван дигән патша, аннан башкалары бу җирләрне татар канын түгеп басып алган, үзләрен кол иткән... «Ә нигә татарлар бу җирләрне яңадан сугышып тартып алмыйлар икән?» Бу сорау Салихның башында юл буе бөтерелде, ул аны Юанбаш Мөхәммәдигә бирмичә булдыра алмады.

– Мөхәммәди әкә, тагы бер сорау тынгы бирми миңа – бу безнең җирләр икән, ни өчен без, татарлар, аннан китәргә тиеш соң? Иманым камил, беркем дә сөенеп ташлап китмәде бит туган җирләрне, һәрберебезнең жаны елый... Нигә без китәргә тиеш соң моннан, ә алар түгел?

– Кемнәр – алар?

– Кемнәр, дип, безне басып алучылар инде... Бәс, бу безнең җирләр икән, бәс, монда безнең дәүләтләребез булган икән, ул заманнарда иркенләп үз динебезне тотканбыз икән, нигә хәзер дә без шуны эшли алмыйбыз соң? Нигә без китәргә тиеш моннан?!

Юанбаш Мөхәммәди бу яшь себер татарына бераз тын гына карап торды. Сорау бик гади тоелса да, бик җитди иде, аңа орды-бәрде генә җавап бирсәң, күңелендә шик калуы бар. Ирләрчә туры сорауга ирләрчә туры җавап та кирәк булачак.

– Әйе, Салих энем, син дөрес әйтәсең, моннан без түгел, алар китәргә тиеш иде... Әмма китмәячәкләр, чөнки алар бу җирләрне сугышып, кан коеп яулап

алдылар... Әйе, безнең канны коеп, гөрләп яшәп яткан татар дәүләтләрен юк итеп, алар татар җирләрен басып алдылар, һәм кылыч, һәм тәре тотып, үз тәртипләрен урнаштырдылар. Безнең халык гасырлар буе аларга каршы көрәште, җиңелгәннән соң да тиз генә бирешмәде, яу артыннан яуга кузгалды... Күчем ханның оныклары Урал аръягына чыгып, анда яшәүче татар-башкортларны, мишәрләрне патша хөкүмәтенә каршы сугышларга күтәрделәр... Казан, Идел-Урал-Себер кулдан киткәч тә, татарлар ике йөз ел буе баскыннарга баш бирмиләр, буйсынмыйлар, ирек өчен көрәшәләр. Шушы юлда бик күп каһарман ирләр корбан була.

– Без аларга ата-бабаларыбызның җирләрен калдырып китәбез бит, кол ителгән милләтебезне ташлап китәбез! Без үзебезнең җаннарыбызны, иманыбызны саклыйбыз, дип чит-ят илләргә китәбез, әмма бөтен милләт китә алмый бит! Алар нишләр? Нигә соң шундый зур, бөек тарихлы милләттә татарны яңадан дәүләтле итәрлек кешеләр табылмый? Ярар, без инде кара халык, авылда мал-туардан башка нәрсә белмибез, әмма Казан-Уфа-Төмән-Таралар бар бит әле, аларда яшәүче укыган татарлар бар, нигә күтәрми алар халыкны дәүләт өчен көрәшкә?

– Сорауны дөрес куясың, энем, әйткәнемчә, булган татарның андый ир-егетләре, мондый күтәрелешләр ике йөз ел буе дәвам иткән. Әмма татар хәзер шушы коллык шартларында башын күтәрмичә генә исән калуның юлларын эзли башлады, чөнки баш күтәрүнең үлем икәнен яхшы белә... Милләткә хәзер исән калырга кирәк, әмма Габдрәшит хаҗи әйткәнчә, үз дәүләте булмаган милләт иртәме-соңмы барыбер юк була, көчлеләр тарафыннан йотыла... Менә шуңа күрә без китеп барабыз инде...

– Әмма анда да безнең үз дәүләтебез булмаячак бит, без кайда да килгән-килмешәк булачакбыз!

– Әйе, дөрес әйтәсең – безнең анда да үз дәүләтебез булмаячак... Без төрекләр гасырлар буе төзегән һәм саклаган ислам дәүләтенә барып сыенабыз... Анда безнең динебезгә тимәячәкләр, иманыбыз зәгыйфьләнмәс. Бары тик шуның өчен генә без шушы авыр юлга чыктык, Салих энем, Аллаһ барыбызга да сабырлыклар бирсен!

Халыкның күңелсезләнгәнен күреп, Зәйнәп абыстай аларга тагы үгет-нәсихәтләрен бирде, барыбыз да Аллаһ кулында, тәкъдиребездә ни язылган булса, шул булыр, әҗәлдән качып котылу мөмкин түгел, диде. Таһирә апа исә вагонны җиллэтергә, мәет яткан урын-җирләрне читкәрәк алып куярга кушты, яшь киленчәкләр шунда ук эшкә керештеләр. Хөснибикә дә аларга кушылырга булды, күз яшьләрен сөртте дә тиз генә урыныннан сикереп торды, әмма эчендәге сәер хәрәкәттән куркып, яңадан урынына утырды. Аның күзләре зур булып ачылган, йөзендә курку да, гаҗәпләнү дә чагыла, үзе куллары белән эчен тоткан иде. Хатыннарга булышып йөргән Зөлбану моны күреп, Хөснибикә янына йөгереп килде, янына утырып, ул да кулларын аның инде беленебрәк торган корсагына куйды.

– Тибә, Хөснибикәнең бәбие тибә башлады! – дип, ул бөтен вагонга кычкырып җибәрде.

Алар янына Мәхсүрә белән Мансура йөгереп килде, башкалар да җыелышты, вагон җанланып китте.

– Менә бит, тере җан аннан да хәбәр бирә! – дип сөенештеләр. – Сабыйга җан керде! Фәрештәләр Аллаһ әмере белән аңа җан иңдерде! Менә бит, берәү үлә, берәү туа, дөнья шулай яратылган инде ул... Инде бәхетле сабый булсын, фәрештәләр хәерле язмыш иңдергән булсыннар...

Зөлбану кул ишарәләре белән Хөснибикәгә боларның барысын да аңлатты. Хөснибикә башта нигәдер оялды, кызарып чыкты, аннан йөзенә елмаю таралды, бу аның юлга чыкканнан бирле беренче елмаюы иде. Аның баласы

тибенә, хәбәр сала бит! «Син хәзер минем өчен дә җаваплы, үзеңне нык тот, әни!» – ди бит... Әни, ди, инәй, ди, балакаем... Елама, син миңа кирәк, бик кирәк, ди... Бу минутта бөтен вагонында, юк, бөтен эшелонда Хөснибикәдән дә бәхетле кеше юк иде, аның бу шатлыкны ире белән дә бүлешәсе килде. Яшь кызлар күрше вагонга Салихтан сөенче алырга йөгерделәр, аннан Хөснибикә ире белән тамбурга чыгып, бик озак бер-берләренә сыенып, янәшә басып тордылар... Ә ике арада аларның туачак балалары, нәсел дәвамчысы гайрәт белән тибенә, шул рәвешле, дөньяга аваз сала иде... Ә һиҗрәт паровозы ак карлар арасыннан аларның киләчәгенә таба томырылып чаба иде...

## Одессада кораб көтү

...Одесса татар мөһаҗирләрен җил-яңгырлар белән каршы алды...

Аларның диңгез буендагы бу шәһәргә тизрәк барып җитәсе килгән иде, әмма һиҗрәт паровозы дөбердәп Одесса вокзалына килеп туктагач, каушап-куркып ук калдылар. Мөһаҗирләр бу тимер арбага инде ияләнгәннәр иде, аның тәртибен-җаен беләләр, ятарга урыннары, ашарга ризыклары, намаз укырга мәчетләре бар иде. Ә монда кая барырлар? Бу бит Себердәге Умба түгел, монда татарның Мәтин байлары юк иде... Җитмәсә, урамда юеш, монда кышның эзе дә юк, ә алар җылы киемнәрдән, киез итекләрдән, кайры туннардан... Әмма озак уйлап торырга вакыт юк, составны бушатырга кушалар, сандык-төенчекләрне җиргә төшерергә кирәк. Юанбаш Мөхәммәди тагы вагоннан-вагонга очып диярлек йөри башлады, аңа Зыятдин улы Вәли, Күчемнекеләр-Князевлар, Салих, хатын-кызлардан Таһирә һәм Зәйнәп абыстайлар ярдәмгә килде. Аякларга читек-кәвешләрне алып киделәр, өстәге калын киемнәр дә салынып, төргәкләргә тутырылды, төенчеләр артса да, йөрергә җиңел булып китте. Хатын-кызларны һәм балаларны, әйберләр белән бергә, вокзал мәйданына бастырдылар, шуннан кузгалмаска куштылар. Ирләр ике арада йөгереп, әйберләрне бушатты, хатын-кызлар малларны һәм балаларны саклап торды.

Ул арада вокзал каршындагы мәйданга яхшы атлар җигелгән берничә бөркәүле арба килеп туктады, алардан чалма-чапаннар кигән олы яшьтәге дин әһеле һәм башына кырпау бүрек кигән бай кыяфәтле ир-ат чыкты, артларыннан тагы берничә кеше күренде. Аларның татар икәнлекләре йөзләренә язылган иде, әмма себерләргә охшамаган, аксыл йөзле, эре гәүдәле, аурупа кыяфәтле татарлар иде алар. Бу татарлар туп-туры вокзал читендә зур төркем булып басып торучылар янына килделәр, мөселманча, татарча сәлам бирделәр, кайдан килүләрен сорадылар. Хатын-кызлар башта куркып-каушап калдылар, аннан үз авылларының исемнәрен әйтә башладылар. Ул арада төркем янына Юанбаш Мөхәммәди үзе дә килеп җитте, сәлам алыштылар, бер-берләре белән таныштырдылар.

– Без Габдрәшит хаҗиның соравы буенча, Сибириядән килгән мөһаҗирләрне каршы алырга килдек, – дип сүзен башлады чалма-чапан кигән дин әһеле. – Мин шушы шәһәрнең мулласы булам, атым – Ибраһим, фамилиям – Адикаев. Бу әфәндебез шәһәребезнең мәртәбәле кешесе Хөсәен бай, зур сәүдәгәр... Әйе, Габдрәшит хаҗи сезне каршы алып, кунакханәгә урнаштыруны үтенде, без инде урыннар белешеп куйдык.

Габдрәшит хаҗиның исемен ишеткәч, мөһаҗирләр сөенеп куйды, менә бит, аны монда да беләләр икән! Аның исеменнән ярдәм итәргә торучылар монда да бар икән! Көтүләре белән урамда калмыйлар икән болай булгач...

– Без мөсафирларга шулай ярдәмгә килгәнегез өчен сезгә Аллаһның рәхмәтләре яусын, – дип, барысы өчен дә Юанбаш Мөхәммәди җавап бирде. – Мин Төхфәтулла улы Мөхәммәди булам, шушы һиҗрәт төркеменең өлкәне,

җаваплысы, ягъни... Безгә ярдәм бик кирәк булачак, хәзрәт, чөнки монда һичкемне белмибез, кайда кунарга, кайдан Истанбулга пароходка утырып китәргә – әле берсе дә хәл ителмәгән... Үзегез күрәсез – халык күп, озын юлда килеп, авыручылар, хәтта үлем очрагы да булды... Тагы юлга кузгалганчы, кешеләрне бераз ял иттерәсе иде, күрәсез, олылар, балалар да күп бит...

Моңарчы сүзгә катнашмыйчарак торган Хөсәен бай әңгәмәгә кушылды:

– Алайса, болай итәрбез, Мөхәммәди туган, – диде ул. – Моннан ерак түгел хаҗилар өчен махсус салынган Кәрван-Сарай бар, без аны Хаҗиханә дип тә йөртәбез. Ул бик зур, өч меңләп кеше сыярлык, үзенең мәчете, ашханәсе, мунчасы, кирәк булса, хастаханәсе дә бар. Без сезнең өчен шуны белешкән идек. Әле пароход тиз генә булмас, дөрес, ул да белешенгән, әмма сезнең үзегезгә аерым кирәк, шуңа күрә бераз көтәргә туры килер. Әйберләрегезне ташырга хәзер атлы-арбалар килеп җитәр, халык шул якка таба җәяүләп тә бара тора ала, Хаҗиханә моннан ерак түгел. Менә бу егетләр юлны күрсәтер, анда очрашырбыз, калганнарын шунда иркенләп сөйләшербез.

Хөсәен байның бу сүзләрен күктән төшкән бәхет итеп кабул иттеләр, чөнки алар бөтенләй чит-ят җирдә ярдәм итүчеләр булыр дип башларына да китермәделәр. Ул арада эшелоннан әйберләрне ташып бетерделәр, аларны әллә кайдан гына килеп чыккан атлы-арбаларга төяделәр, халык исә үзләрен озата барган җирле татарлар артыннан ияреп китте. Аяк астында чыптырдаган суларны күреп, тирә-юньдә шаулап үсеп утырган ямь-яшел сәер агачларга карап, алар гаҗәпкә калганнар иде... Кайда монда кыш, кайда монда Себердәге ап-ак кар-бураннар, кайда чыршы-наратлар, башлары күккә тигән карагайлар? Аларның монда берсе дә юк, кешеләр дә Себердәге кебек түгел, бик җиңел киенгәннәр, үзләре каядыр ашыгалар, яннан бәрелеп диярлек китәләр... Ул арада шәһәр халкы да бу сәер кешеләргә игътибар итә башлады, – башларында җон бүрекләр, күбесенең өсләрендә җылы туннар, аякларында да әллә нәрсәләр – кемнәр соң болар? Чегәннәр, дияр идең – чегәннәр болай киенми, алар җиңелчә йөрергә ярата, хаҗилар, дияр идең – бала-чагалар, хатын-кызлар күп, ә Хаҗга, гадәттә, Одесса аша ир-атлар гына китә. Шәһәр халкы аларны әнә шундый шикле һәм аптыраулы караш белән озатып калды, бары тик соңыннан гына аларның Истанбулга күчеп китеп баручы себер татарлары икәнлекләрен белделәр.

Кәрван-Сарай дигәннәре, чыннан да, бик зур, рәт-рәт тезелеп киткән таш биналардан торган үзе бер кала булып чыкты. Рәсәй мөселманнары Хаҗга Одесса аша бара, башта пароход белән Кара диңгездән Истанбулга, аннан тагы су юлы белән Җиддәгә китәләр икән. Одессада алар өчен шушы гаять зур Хаҗиханә салынган, ул ел әйләнәсе хаҗиларга хезмәт итә, олы Хаҗдан тыш, гомрәгә дә гел барып торалар икән. Шулай ук Истанбулга сәүдә белән йөрүчеләр, шәкертләр һәм эш адәмнәре дә шушы Хаҗиханәдә тукталырга тырышалар, чөнки ул вокзалга да, пристаньга да якын, үзендә яшәү өчен бөтен шартлар бар, диделәр. Шулай дип әйтсәләр дә, Хаҗиханә гаиләләр өчен каралмаган иде, аерым бүлмәләр алырга Себер мөһаҗирләренең матди мөмкинлекләре дә чамалы иде, шуңа күрә тагы, эшелондагы кебек, зур-зур бүлмәләргә хатын-кызлар – хатын-кызлар белән, ирләр исә үз ишләре белән урнашты. Барысы да монда озак тоткарланмабыз, пароход белән тиз арада Истанбулга китеп барырбыз, дип уйлады. Әмма аларга Одессаның дымлы, юеш һавасын сулап, ягылмаган салкын таш биналарда туңып, Хаҗиханәдә шактый озак ятарга туры килде...

Килгән көнне үк Хөсәен бай мөһаҗирләрнең өлкәннәрен үзенә кунакка дәштерде, алар арасында Юанбаш Мөхәммәди, Зыятдин улы Вәли, Күчемнекеләр дә бар иде, яшь булса да, Салихны да алдылар. Хөсәен бай шәһәр уртасында ике катлы таш йортта яши икән, уллары Хәсән белән Абдулла да гаиләләре белән

янәшәдә генә яшиләр булып чыкты. Бу татар байлары Пенза ягы мишәрләре булып, бөтен Одессаны диярлек ит-май белән тәэмин итәләр икән, улларының унбиштән артык ит кибете бар, диделәр. Аталары Хөсәен Истанбул белән сәүдә эшләре алып барган, бераз олыгайгач, бу эшне улларына тапшырган, әмма төрекләр белән араларын өзмәгән. Себер татарлары килеп, аш янына утыргач та, сүз шул госманлы иле турында булды, аны Хөсәен бай үзе башлады.

– Бик тынгысыз вакытта юлга кузгалгансыз икән, туганнар, – дип башлады ул сүзен. – Истанбулда бер дә тыныч түгел хәзер – халык солтанга каршы күтәрелә... Солтан Абдулхәмит тә бик каты тора – төрмәләр яшь милләтчеләр, укымышлы төрекләр белән тулган... Госманлы кулыннан берәм-берәм хәлифәт җирләре китә, аларга аурупалылар ябырылды. Монда ил эчендә шундый хәлләр, ни белән бетәр – бер Аллаһ белә... Аларда хәзер чит кеше кайгысы юк, үзләренекен кая куярга белмиләр.

Боларны ишетеп, мөһаҗирләр телсез калды, хәтта ашаудан туктадылар, әмма каршы бер сүз дә әйтә алмадылар, чөнки алар аңлarлык нәрсә түгел иде бу. Кунакларның ни хәлдә калганын күреп, сүзгә Ибраһим мулла катнашты.

– Син кунакларны алай куркытма әле, Хөсәен туган, – диде ул. – Алар инде ниятләп шушы авыр юлга чыккан, монда кадәр килеп җиткәннәр... Истанбулда төрекләр үзара сугыша, дип, алар инде кире борыла алмый. Документлары кулларында, аннан кил, дип торалар, Габдрәшит хәзрәт үзе ярдәм итәргә алынган, шәт, урамда калмаслар, инша Аллаһ!

– Әйе, мин Габдрәшит хаҗины күрдем анда, ул хөкүмәт кешеләре белән бу мөһаҗирләр турында сөйләшкән-килешкән, элегрәк хәтта солтанның үзе белән дә очрашкан булган. Әмма заманалар үзгәрде, госманлыда вазгыять бөтенләй башка... Авыр хәлдә калмасыннар, дип, кисәтеп әйтеп куям, кая барганнарын бераз чамаласыннар.

– Әмма, Хөсәен кардәш, госманлыда солтан-вәзирләрдән кала, халык та бар бит әле, алар бик дини, кунакчыл, һиҗрәт кебек изге юлга чыккан мөселманнарны авыр хәлдә калдырмаслар, инша Аллаһ!

– Әйе, анысы да бар – төрекләр Аллаһ юлындагы инсаннар, ихласлар һәм ярдәмчәннәр, алар солтан-пашаларга карап тормаслар, кулдан килгәнне эшләрләр... Әмма алар арасында да төрлесе бар – төрекне төп башына утыртырга һәрдаим әзер торган әрмәние, һаман Византияне кире торгызырга өметләнеп йөргән рум-греклары, бөтен сәүдәне-банкларны, акча капчыгын үз кулларында тоткан елгыр яһүдиләре, беркемгә буйсынмыйча, үзләренчә яшәп яткан көрдләре... Һәркем бу болганчык суда үз балыгын тота. Киңәшем шул: татар туганнар аларның берсенә дә ышанмагыз, бер Аллаһка таяныгыз да ихлас мөселманнарга сыеныгыз. Үзебезнең татарлар да бар анда, алар ерак авылларга таралып урнашкан, хәлләрен алай җиңел димәс идем, әмма госманлыда тамыр җибәрделәр инде. Алар янына да барып карагыз, киңәш-табыш итегез...

– Безнең үзебезнең дә шундыйрак исәп бар иде – элегрәк күчкән татарларны эзләп табып, алар белән киңәшергә, – дип сүзгә кушылды Юанбаш Мөхәммәди. – Без – авыл халкы, гомеребез буе шунда яшәгән, шәһәр тормышы безнең өчен ят нәрсә, авыр булачак... Аннан, үзегез беләсез, без бит гомер буе салкын Себердә яшәгән халык, ә госманлыда бик эссе, диләр, хәтта кыш та булмый икән! Безгә андыйга ияләнү бик авыр булачак, шуңа күрә ул илнең салкынрак урынын эзләп, шунда урнашырга туры киләчәк. Андый җирләр бардыр бит төрек илендә?

Хөсәен байның моңа кадәр сүзгә катнашмыйча утырган уллары Хәсән белән Абдулла бер-берләренә карап, елмаеп куйдылар. Алар госманлыда еш булалар, бу илнең төрле почмакларын күргән кешеләр, аның турында барысыннан да яхшырак беләләр иде. Яшьләр Төркияне ярата, анда барган сәяси хәлләргә,

үзара ыгы-зыгыларга да куркып карамыйлар, киресенчә, шулай булырга тиеш, дип табалар иде.

– Төрек илендә һәр шәй бар, – дип, Хәсән мөһаҗирләр соравына җавап бирде. – Төньягында – кара урманнар һәм Кара диңгез, көньягында – җәннәт җимешләре һәм Ак диңгез, уртада – Мәрмәр диңгез, рум тарафында – Эгей диңгезе... Истанбулны икегә бүлеп, ике диңгезне тоташтырып, Бугаз сузылып яткан... Су дисәң – суы бар, тау дисәң – тавы, илнең уртасында – Анадулуда – иген кырлары, җимеш бакчалары, тоз күлләре... Әмма әти хак әйтте – госманлы иле бүген зур тетрәнүләр кичерә, яшь төрекләр искечә яшәргә теләмиләр, алар солтан басымы астыннан чыгып, үз Ана Ясаклары, ягъни Конституция буенча яшәүне таләп итәләр. Бу дөрес тә булыр иде, чөнки халык бераз булса да ирек өмет итә, яшь төрек зыялылары шуның өчен көрәшә. Әмма без сезгә ул эшләргә катнашмаска тәкъдим итәр идек, хәзер Төркиядә сәясәткә катнашу, солтанга, хакимияткә каршы эшләү – туп-туры төрмәгә илтеп тыга. Хәер, сезгә моны сөйләп торасы юк, монда да шул ук хәл бит инде! Бердәнбер аерма – анда хәзергә дингә кагылмыйлар, мондагы кебек, дин өчен төрмәгә утыртмыйлар...

– Әмма мондагылар әләкләсәләр, утырталар да, тотып та бирәләр, улым, – дип, аның сүзенә каршы төште Хөсәен бай. – Оныттыңмыни, моннан берничә ел элек Габдрәшит хаҗины, урыс хөкүмәте әләге һәм таләбе белән, башта Истанбулда кулга алдылар, аннан монда тотып җибәрделәр, Одесса төрмәсенә утыртып куйдылар... Артыннан үзебез күпме йөрдек бит, бөтен шәһәр мөселманнары аны яклап купты... Рәсәйдән күпме телеграммнар килде! Халык тавышыннан куркып кына хәзрәтне төрмәдән чыгардылар. Рәсәй сорый, дип, Габдрәшит хаҗи кебек акыл иясен дә урысларга тотып бирде төрек солтаны... Тукай абзагыз нәрсә дигән әле, улым, «Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион!» дигәнме? Шәп әйткән, дөрес әйткән!

– Гаҗәпләнмәгез, Истанбулга безнең аша баручы шәкертләр бирегә Казаннан бар яңалыкны җиткереп торалар, Тукай шигырьләре дә тиз килеп җитә, – диде Хәсән. – Чыннан да, шагыйрь шәп әйткән, дөрес әйткән, өздереп «Китмибез!» дигән:

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
– Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! – диләр.
Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.
Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар – шул иске камчы, башкалык – тик фәсләре!
Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!
...................
Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (гыйззе вә җәл).

Себер урманнарына татар шагыйренең бу шигырьләре килеп җиткәне юк иде, мөһаҗирләр аны тетрәнеп тыңладылар... Бу Тукай дигәннәре нәкъ Яланкүлдәге Мөхәммәтҗан карт кебек сөйли иде. Ул да бит бу һиҗрәткә күпме каршы төште, күпме дәлилләр китерде, күпме ялварды, аннан инде тәкъдиргә буйсынды, авыру кызын һәм туганнарын үзе фатихасын биреп озатып калды. Инде илдән кубарылып чыгып киттеләр, инде монда хәтле килеп җиттеләр, инде алда ни көтсә дә, кире борылу юк... Моны мөһаҗирләр дә, аларны кунак итүчеләр дә яхшы аңлый иде, шуңа күрә, йөрәк яралардай сүзләрдән ераграк булырга тырыштылар. Алай да, Салихның йөрәгенә ук булып килеп кадалды

бу сүзләр – «Китмибез без!» Аның күзләре ачылып киткәндәй булды, үзе юлга чыкканнан бирле эзләгән сорауларга җавап тапты. Әйе, ахрысы, каенатай хаклы булган – китәргә кирәкмәгән аларга... Алдагы авырлыклардан куркудан түгел, ә илне, туган җирләрне шул кяферләргә ташлап киткәнгә җаны янды Салихның. Әйе, һиҗрәт изге, әмма үз илеңдә, үз җиреңдә динең өчен көрәшү, иман хакына җиһад тагы да саваплы һәм кирәкле эш булган булыр иде... Тик хәзер бу турыда уйларга да, сөйләшергә дә соң инде.

Табын янында сүз үз җаена дәвам итте, токмачлы аштан соң, өстәлгә табак-табак ит китерделәр, аннан бәлеше, җимешле чәе чыкты. Юлдан килгәннәрнең инде Умбадан бирле кайнар ризык ашаганнары юк иде, алар күбрәк токмачлы ит шулпасын якын иттеләр, чит җирләрдән китерелгән җиләк-җимешләргә бераз ятсынып карадылар. Ул арада Хөсәен байның кече улы Абдулла да сүзгә катнашты.

– Менә бу җәннәт җимешләре барысы да Истанбулдан китерелгән – йөземе, анары, алма-армуты, карбыз-кавыннары, әфлисуны-бананы, – диде ул, өстәл тулы җиләк-җимешкә күрсәтеп. – Ел әйләнәсе анда бөтен нәрсә үсә, бигрәк тә – эссе якларында... Әмма сезгә анда авыр булыр, шуңа күрә, Габдрәшит хаҗи белән киңәшеп, илнең уртасынарак урнашырга тырышыгыз. Үзегездәге кебек, иген игәрлек, мал асрарлык булсын. Салкынчарак булган, инеше-су агып торган урынны табарга кирәк, ә су булган урында яшеллек тә бар... Инде тәвәккәлләп шушы юлга чыккансыз икән, нык торыгыз, андагы татарлар белән дә, безнең белән дә элемтәдә булыгыз. Сез – Аллаһ юлындагы кешеләр, без дә кулыбыздан килгәнчә ярдәм итәрбез, инша Аллаһ!

Аннан соң сүз Кара диңгез аша булачак соңгы сәфәргә күчте. Бу хакта сөйләшүләр инде күптән, мөһаҗирләр бирегә килеп җиткәнче башланса да, һаман ачыкланып бетмәгән нәрсәләр күп икән әле. Себер мөһаҗирләрен Одесса портында туктаган төрле пароходларга бүлгәләп утыртып җибәреп булмый, ә аерым кораб бик кыйммәткә төшә һәм шактый көтәргә туры киләчәк. Әмма һич башка чара юк, диңгез аша җәяүләп чыгып китеп булмый, торырга урыннары бар – көтәрләр. Пароход чыгымнарының бер өлешен Хөсәен байлар да күтәрешергә булды, әмма алар да тулаем түли алмыйлар иде. Инде бу Кәрван-Сарайда торганнарына да зур рәхмәтләр әйтеп, Себер кунаклары таралышты, аларны торган урыннарына кадәр яхшы атларда илтеп куйдылар. Шулай итеп, мөһаҗирләрнең Одессада мөсафирлыклары башланды... Хаҗиханәдә бикләнеп ятмас өчен, алар әкренләп шәһәргә чыга башладылар, башта куркып, якын-тирәдә генә йөрделәр, аннан диңгезгә хәтле барып җиттеләр. Бу таш кала аларны таң калдырды...

Әйе, Одессаның шаккатырлыгы бар иде, ул инде Умба-Омски гына түгел! Инде кыш кереп килсә дә, ямь-яшел булып утырган агачлар дисеңме, өчәр-дүртәр катлы сырлы-бизәкле таш йортлар дисеңме, ул чуен күперләр, алар буенча дагаларыннан ут чәчеп чапкан көяз атлар, аларда кәпрәеп утырган эшләпәле ирләр дисеңме... Умбада боларның берсе дә юк иде... Дөрес, анда да, монда да чат саен чиркәүләр, кибетләр, базары, театрлары бар, әмма Одессаныкы бөтен яктан да бай һәм келпеп тора! Ул Пассаж дигән кибетләренә керсәң, адаша торган, ул Дума дигәннәре хан сарае кебек, ул китапханәләре, кереп ашый торган рестораннары – исең-акылың китәрлек... Әмма Себердән килгән мөһаҗирләрне иң шаккатырганы, әлбәттә, диңгез булды, аларның мондый зур суны гомерләрендә дә күргәннәре юк иде. Әле бу диңгезнең култыгы гына, дисәләр дә, аның очы-кырые күренми иде, ә яр буйлары эреле-ваклы пароходлар, көймәләр, җилкәнле җаеклар белән тулган, ничек бер-берләренә бәрелешмиләрдер! Алар да менә шушы корабларның берсенә утырып, шушы төпсез дәрьяга кереп китәчәкләр бит инде – бу аларны куркыта да, ымсындыра да иде. Биредә себер татарларын иң гаҗәпләндергәне яр буендагы бик биек баскыч булды, аның басмалары ике йөзгә

якын, диделәр, югарыга ниндидер тимер тартмаларда төшеп-менеп йөриләр. Мөһаҗирләр аңа утырырга курыктылар, кырыйдан гына карап тордылар. Диңгез эчендәге маякка да алар аптырап карап тордылар, ул чиркәү каланчасыннан да биек һәм кичләрен утлары янып тора иде...

Урамнарда йөргәндә, биредәге халыкка да игътибар иттеләр, алар бик төрле, чуар иде. Умбадагы кебек, урысча киенеп, урысча сөйләшеп йөрүчеләрне дә күрде алар, телләре аңлашылмаган кешеләр дә шактый иде, аларын яһүдиләр, диделәр, бу халык монда күп яши икән. Әмма иң гаҗәбе – сөйләшүләре татарчага охшаган, киемнәре дә урысныкы түгел, әмма себер халкыннан шактый аерылып торган кешеләрне дә очратты алар Одесса урамнарында. Боларын кырым татарлары, диделәр, алар да монда шактый икән. Хөсәен байның сөйләвенчә, Одесса элек татар шәһәре булган, ул Хаҗибәйле, дип йөртелгән. Монда хәтта төрек хәрбиләренең кәлгәсе дә булган. Әмма Әби патша заманында шәһәрне урыслар басып ала, бу сугыш вакытында бик күп татарларны һәм төрекләрне үтерәләр, җирле халыкның бер өлеше качып котыла. Еллар үткәч, кырым татарлары тагы туган җирләренә җыела башлый, аларга казан татарлары, Пенза ягыннан мишәр-татарлар да килеп кушыла, шулай итеп, көчле генә мөселман җәмгыяте барлыкка килә. Алар тиз арада биредә мәчет салалар, мәдрәсә-мәктәп ачалар, мөселман-татар зираты булдыралар. Татарларның биредә төп кәсепләре – сәүдә һәм, моңа өстәп, Одесса аша хаҗиларны җибәреп-каршы алып тору да алар өстендә икән.

Себер мөһаҗирләре бирегә килгәндә, көн шактый яңгырлы һәм дымлы булса да, тора-бара кояш чыгып, бераз җылытып җибәрде, татарлар да җиңелчә генә киенеп, салкын Хаҗиханәдән урамнарга ашыктылар. Шәһәр бүген аеруча ямьле һәм купшы күренә иде, урам тулы матур итеп киенгән кешеләр, бөтен җирдә гөрләп эшләп торган кибетләр, янәшәдән генә җылы пар бөркеп чабып узган җигүле атлар... Болар барысы да Одессага бәйрәм төсе кертә, күңелләрне күтәреп җибәрә иде. Гомер буе авылда бикләнеп ятып, алар шушындый илләр-җирләр барлыгын да белмәгәннәр бит! Одесса шушындый булганны, әле Истанбул ниндидер, аны да сөйләп бетерә алмыйлар бит!

Салих белән Хөснибикә дә, җиңелчә матур киемнәрен киеп, Зөлбануны да үзләре белән алып, шәһәр карарга чыктылар. Хөснибикә өстенә чиккән затлы бәрхет камзулын киде, башына энҗеле калфагын эләктерде, ак ефәк шәлен ябынды, аягында әтисе Тара базарыннан алып кайткан каюлы читекләр иде. Муенындагы энҗе-мәрҗәннәре, беләгендәге фирүзә кашлы беләзеге аны кино афишаларындагы шәрык гүзәле кебек күрсәтә иде. Әллә шуңамы, үткән-сүткән борылып-борылып аңа карый, кырым татарлары исә сәлам биреп китәләр, аларга җавапны Салих кайтара... Зөлбану да апасыннан калышмаган, Яланкүлдән алып чыккан бөтен затлы киемнәрен кигән, алар болын чәчкәләре кебек, әллә кайдан нур чәчеп торалар. Икесенең дә ак мәрмәрдәй йөзләре, зур яшькелт күзләре, талчыбыктай төз сыннары бу татар кызларының затлы нәселдән икәнлеген күрсәтеп тора иде. Тик Хөснибикә генә инде шактый түгәрәкләнеп килә, гәүдәсен киң камзулы астына яшерсә дә, аның хәрәкәтләре инде Зөлбануныкы кебек түгел, сак һәм әкрен. Салих та Хөснибикәсен күз карасыдай саклый, кулыннан ычкындырмый, тавышсыз ханбикәсен керфек сирпүеннән үк аңлый...

Менә алар тагы диңгез буена килеп бастылар, ул шомлы да, серле дә, матур да иде... Хәзергә көннәр җылы тора, шуңа күрә диңгез дә тыныч, җилле көннәрдә исә аның янына килергә куркыныч. Бөтен яр буе эреле-ваклы көймәләр белән тулы, ак төтеннәр чыгарып, зур-зур пароходлар да килеп туктый. Пристань белән ике арада йөк төягән арбачылар чабыша, кешеләр ашыга, мөһаҗирләр

моңа кадәр гомерләрендә дә күрмәгән әллә нинди машиналар, техника эшләп тора. Әмма аларны иң кызыксындырганы – менә шушы зур кораблар, чөнки үзләре дә тиздән шуларга утырып, Төркиягә китәчәкләр... Бу хәл бераз куркыта, шул ук вакытта моннан тизрәк китү теләге дә көчле. Ә дәрьяның очы-кырые юк, әле моны «култык» кына, диләр, ә диңгез үзе бөтенләй дә иксез-чиксез икән... Төбенә дә төшеп җитеп булмый, ди, бу сиңа Яланкүлдәге Ырыслы күл генә түгел инде, Аллам сакласын!

– Җизни, бу көймәгә без барыбыз да ничек сыярбыз икән? – дип сорап куйды Зөлбану диңгезгә текәлеп карап торган Салихтан.

– Әллә ничә катлы ул, балдыз, аның әле астында да зур-зур бүлемнәр бар, – дип җавап бирде аңа Салих, чөнки аның Тарада Иртыш буенча йөзгән пароходларны күргәне бар иде.

– Ә ул ничек батмый икән, бигрәк куркыныч бит!

– Ул шулай төзелгән инде, аның су астында да бер зур өлеше бар әле, батырмыйча күтәреп тора торган... Диңгездә давыл булмаса, куркыныч түгел, ә менә җил-давыл котырганда, чыннан да, Аллам сакласын инде! Әлегә көннәр әйбәт тора, әмма кайчан кузгаласы һаман билгеле түгел. Декабрь азагында монда да суытып җибәрә, көчле җилләр була, диләр, ничек тә шуңа кадәр китеп каласы иде, балдыз...

Хөснибикә аларның нәрсә турында сөйләгәннәрен ишетмәсә дә, йөзләрендәге борчуны күреп, сүзнең алда торган сәфәр турында икәнен аңлады. Ул, гомумән, кешенең йөзеннән, иреннәреннән, күз карашыннан бик күп нәрсәләрне төшенә иде, әмма сөйләшә алмагач, аңлата да алмый иде. Хөснибикә сизә – алар шушы зур су буенча еракка китеп барачаклар, әмма янында ире һәм туганнары булгач, ул инде бераз тынычланды, элеккеге кебек өзгәләнми. Тик үзен Умбада ак кар өстенә тезләнеп озатып калган карт атасын, чылбырын өзеп, поезд артыннан чапкан Пүреханны ул һаман оныта алмый... Ни өчен алардан, авылыннан аерып алып, шушы диңгез буена китереп бастырганнарын да аңлый алмый ул. Әмма үзе өчен дә, туачак баласы өчен дә өр-яңа тормыш башланганын, үткәннәргә инде юлларның ябык булуын бөтен йөрәге белән тоя...

Ул арада диңгез ягыннан нindидер салкынча җил исеп алды, су өстеннән шадра дулкыннар йөзеп узды. Җил тиз арада көчәйде, әллә диңгез суын, әллә яңгыр тамчыларын йөзләргә китереп сылый башлады. Салих җиңелчә генә киенгән Хөснибикәсен үзенә табарак тартып куйды, диңгездән читкәрәк алып китте. Зөлбану да алар артыннан ашыкты, чөнки җил көчәйгәннән-көчәя бара, яр буендагы агачларны да дер селкетә иде.

– Кайтыйк булмаса, монда җил-давыл кузгалырга тора ахрысы, – диде Салих, Хөснибикәне кулларыннан җитәкләп. Хөснибикәнең куллары боз кебек салкын иде, үзе җиңелчә генә калтырый, җил-давылдан сакларга теләгәндәй, карындагы сабыен камзул итәге белән капларга тырыша... Әмма диңгез җиле бөтен җиргә үтеп керә, җелекләргә төшә, аннан бары тик качып котылырга гына мөмкин...

Алар йөгерә-атлый Хаҗиханә ягына ашыктылар, яр буендагы кешеләр дә бик тиз таралып бетте, урамнар бушап калды. Шәһәр өстенә диңгез тарафыннан җил-давыл килә иде, судагы кечерәк көймәләр йомычка кебек бата-калка башлады, зур пароходлар да салмак кына арлы-бирле чайкалдылар, яр буена таба йөгерешеп килгән дулкыннарга каршы басарга мәҗбүр булдылар... Монда бөтенесе дә бик тиз үзгәрә икән – әле генә чалт аяз кояшлы көн иде, ә хәзер диңгез дулый, әллә яңгыр ява, әллә кар төшә, һава шунда ук салкынайтты, җил сөякләргә хәтле үтеп керә башлады. Шәһәр карарга чыккан мөһаҗирләр төрле яктан Хаҗиханәгә ашыктылар, чөнки аларның беркайчан да мондый хәлне күргәннәре юк иде. Ай ахырында һавалар бозыла, дигәннәр иде, бозыла башлавы шушы икән...

Һәм ашыга-ашыга, чыланып Хаҗиханәгә кайтып җиткәч, аларга яңа хәбәр әйттеләр – Истанбулдан аларны алырга паром дигән йөк көймәсе юлга чыккан, берничә көннән монда буласы икән... Алар бу хәбәргә шатланырга да, кайгырырга да белмәделәр. Шатланырлар иде – урамда эт чыкмаслык көн, җил-давыл котыра, шундый вакытта ничек диңгезгә чыкмак кирәк? Кайгырырлар иде – алар менә инде ун көнләп шушы шәһәрдә, салкын таш бинада ята, инде чирләүчеләр дә бар, барысы да моннан тизрәк китү турында хыялланды, инде китү хәбәре килгәч, ничек борчылмак кирәк? Инде аларга дигән кораб юлда, бу көннәрдә бар әйберләрне әзерләп, тиздән соңгы сәфәргә... Соңгы сәфәргә, шушы диңгез дигән дәрьяларын исән-имин кичсәләр, аннан соң Истанбул, аннан соң һиҗрәттә яңа тормыш башланыр, инша Аллаһ! Һәркем бу көннәрдә әйберләрен барлады, юлга әзерләнде, киңәшеп, җылырак киемнәрне янга алырга булдылар, чөнки диңгездә бик салкын була, диделәр. Ирләр исә соңгы тапкыр Одесса кибетләреннән юлга кирәк-ярак алды, хатын-кызлар да, бинадагы боз салкынына түзә алмыйча, урамга чыгып-чыгып керде. Күпләр исә, авыллардан киеп чыккан туннарына төренеп, намаз-гыйбадәттә утырды, һәркем Аллаһтан бу соңгы сәфәрнең хәерле булуын теләп догалар кылды, теләкләр теләде, ә кемнәрдер өчен чыннан да соңгы сәфәр буласын әле беркем дә белми иде...

Урамда исә җил-давыл бер тынды, бер көчәйде, хәтта аяк астындагы суларны да туңдырып-катырып җибәрде. Себердәге кебек ап-ак карлар булмаса да, хәтта монда да кыш сулышы сизелә иде. Мөһаҗирләр яңадан кайры туннарын, тире бүрекләрен киеп куйдылар, ераккарак яшерелгән киез итекләр дә яңадан чыкты. Шуңа карамастан, халык өшеде, туктаусыз исеп торган салкын диңгез җиленнән эчләренә суык төште, аларның хәтта Себердә дә болай туңганнары юк иде. Мөһаҗирләр арасында мондый юеш һәм салкын һавадан авыручылар артты, Таһирә апа тагы үлән-төнәтмәләрен күтәреп, Хаҗиханә бүлмәләре буйлап йөри башлады. Бу көннәрдә Хөснибикә дә кәефсезләнде, тәне әле боз, әле ут булды, ул үзенең авырый башлаганын сизенде, әмма бу хакта әйтә алмады, атасы кидереп җибәргән тунына төренеп, салкын урын өстенә менеп ятты... Юлга чыгар алдыннан, Хөснибикә авырып киткән иде... Хаҗиханәнең үз хастаханәсе бар иде, аннан табиб килеп, Хөснибикәне карады һәм кичекмәстән больницага салырга кирәклеген әйтте. Ул чагында Салихның да, Хөснибикәнең дә һиҗрәте өзеләчәк иде.

Бу хәбәрне ишетеп, мәчеттән Ибраһим мулла белән хатыны Әминә абыстай килеп җитте, алар Хөснибикәне өшкереп тә карадылар, үзләре белән алып килгән нindидер әчкелт дарулар да бирделәр, әмма аның хәле яхшырмады. Бүлмәдәге боз салкынлыгын тоеп, Әминә абыстай эшнең нәрсәдә икәнен аңлады, Хөснибикәне олы юлга чыкканчы үзләренә алып кайтып китәргә теләде. Бу хакта иренә дә әйтте.

– Бу бала монда тиз генә терелә алмаячак, өйгә, җылыга алып кайтыйк без аны, аның эченә салкын төшкән, – диде Ибраһим мулла.

Хөснибикәнең ире Салих һәм мөһаҗирләр җитәкчесе Юанбаш Мөхәммәди белән киңәшеп һәм килешеп, Хөснибикәне Ибраһим муллаларга алып кайтып киттеләр. Ибраһим мулла Хаҗиханәдән ерак түгел, җыйнак кына үз өйләре белән яши икән, йорт янында бакчалары, мунчалары, каралты-куралары да бар, авылдагы кебек көн күреп яталар... Алар икесе дә инде олы яшьтә булып, балалары аерым яши икән, мулла белән абыстайның да күп вакыты мәчеттә һәм аш мәҗлесләрендә үтә. Авыру Хөснибикәне алып кайткач, абыстай күп вакытын аны дәвалауга бирде, аны аерым бүлмәгә урнаштырды, үз баласы кебек юындырып, киемнәрен алыштырды, төрле йорт ашлары пешерде, өшкерде... Инде айдан артык җылы өй, кайнар аш күрмәгән Хөснибикә күзгә

күренеп тернәкләнде, битләре алсуланды, күзләренә нур кайтты... Аның бәхетенә, мөһаҗирләрне алырга килгән паром да, диңгездә давыл булу сәбәпле, берничә көнгә Одессада тоткарланды, юлга чыкмады.

Үзенең балалары күптән үсеп-таралып беткән Әминә абыстай Себердән килгән бу телсез кыз баланы аерата якын итте, авырлы килеш шундый ерак юлга чыкканын кызганды. Хөснибикәнең ире Салихтан сорашып, ул аның әнисе үлгән булуын, әтисенең инде карт икәнен, телсез-чукрак кызын һиҗрәткә бер дә җибәрәсе килмәвен белде. Әле җитмәсә, авырлы да бит! Юлда нишләр ул, анда баргач, ничек ияләнер, ул бит башкалар кебек сау-сәламәт түгел! Шул телсез-чукрак килеш тә, авыру һәм авырлы була торып та Хөснибикәнең бер генә намазын да калдырмавы Әминә абыстайның бөтенләй күңелен нечкәртте, аны яныннан җибәрәсе килмәде. Ул кайсыдыр ягы белән Әминә абыстайның яшьли үлгән кызына да охшаган иде. Балачакта ук ана җылысыннан аерылган Хөснибикә дә йомшак күңелле, йомшак куллы, олы яшьтәге бу хатынны бик якын итте, үз анасыдай күрде. Алар бергәләп намаз укыдылар, Хөснибикә бераз терелгәч, кул арасына да керә башлады, Әминә абыстай аның аш-суга да бик оста икәнен күрде.

Бу хакта ул иренә дә әйтте, Хөснибикәне ире белән монда калдырсак та яхшы булыр иде, анда аңа бик авыр булачак бит, диде. Салих белән Хөснибикәнең төпле, ныклы иманлы, тырыш яшьләр булуына Ибраһим мулла үзе дә игътибар иткән иде, әмма Аллаһ юлында һиҗрәткә чыккан кешеләргә калыгыз, дип әйтергә аның теле әйләнмәде. Алай да, Салих хатыны янына килгәч, ул сүзне читтәнрәк башлап карарга булды.

– Хатының авырлы, үзе авыру да, шушы хәлдә аны ерак юлга алып чыгу дөрес булырмы икән, энем? – диде ул. – Әминә абыстаең аны монда калдырып торырга куша... Әлбәттә, шәһәрдә сиңа да эш табылыр иде, күреп торабыз, тырыш кешеләр сез...

Салих хәзрәттән мондый сүз көтмәгән иде, башта аптырап калды, дәшмичә шактый уйланып торды. Бәлки, Аллаһы Тәгалә аларга илдә калырга шушы соңгы мөмкинлекне бирәдер? Бәлки, шушы чит-ят җирләрдә калыргадыр, аннан авылга кайтырлар? Ә анда ни йөз белән кайтып кермәк кирәк? Шушы һиҗрәт өчен авылда күпме сүз булды, инде нинди авыр юл үттеләр, соңгы сәфәр генә калды, инде монда хәтле килеп җиткәч, ничек баш тартасың? Аллаһ ни әйтер, юлдашлары моны ничек кабул итәр? Дөрес, Хөснибикәнең хәле алай ук яхшы түгел, әмма мөһаҗирләр арасында салкын тиеп авыручылар шактый, бигрәк тә хатын-кызлар һәм балалар арасында, әмма берсе дә кире борылырга уйламый.

– Бу тәкъдимегезгә рәхмәт, хәзрәт, Хөснибикәмне үз балагыз кебек карадыгыз, анысына да зур рәхмәт... Әмма инде монда кадәр килеп җиткәч, юлдашлардан аерылып калуны, һиҗрәт сәфәребезнең өзелүен күңел кабул итә алмый... Баштарак уйларга кирәк булган да бит, хәзер соң инде. Без бит Аллаһ ризалыгы өчен дип шушы юлга чыктык...

– Аңлыйм, улым, бик аңлыйм, әмма синең хатының башкалар кебек түгел – авыру, авырлы, җитмәсә, ишетми дә, сөйләшә дә алмый... Аңа бигрәк тә авыр булыр дип борчылабыз. Баласын тынычлап монда табар, аннан үзегез карарсыз тагы кайда яшәргә...

– Хөснибикә үзе беләме соң моны?

– Юк, синең белән киңәшмичә әйтә алмадык. Хәер, ул бөтенләй ишетмәгәч, без ни теләгәнебезне аңлата да алмаган булыр идек. Син аның белән аңлаша аласың, үзе белән киңәшеп кара әле...

Алар хатын-кызлар янына чыктылар, Салих Хөснибикәсен таный алмыйча сокланып карап торды. Әминә абыстай аңа шәһәр кызларыныкы кебек

яңа затлы күлмәк кидергән, башында да матур яулык, аякларында чиккән чүәкләр... Салихны күргәч, Хөснибикәнең битләре алсуланып китте, ак нәфис кулларын иренә таба сузды, янында хәзрәт булгач, уңайсызланып куйды. Салих хатынының янына утырып, кул хәрәкәтләре белән аңа нидер аңлата башлады. Хөснибикәнең зур яшькелт күзләре гаҗәпләнүдән тагы да ныграк ачылды, ул бер иренә, бер Әминә абыстайга карады. Салих аша Әминә абыстай да сүзгә катнашырга булды.

– Син әле терелеп бетмәдең, кызым, мондый хәлдә юлга чыгу авыр булыр, – диде ул. – Кал монда, балаңны монда табарсың, без сиңа ярдәмче булырбыз... Мөселманнар бит без, татарлар, әлхәмдүлилләһ! Ирең дә монда кала ала, калырга теләмәсә, барып урнашкач, сине кайтып алыр. Син миңа үз кызым кебек якын, әле үзең дә балалыктан чыгып җитмәгәнсең, бик авыр булыр, дип, кызганып әйтәм бу сүзләремне...

Салих кул хәрәкәтләре белән Әминә абыстайның сүзләрен Хөснибикәгә җиткергәч, ул бер тын уйланып утырды, аннан иренә карап, ишарәләр белән аңлата башлады.

– Мин – ир хатыны, ул ничек әйтсә, шулай булыр... Әмма мин туачак балабызны һиҗрәт савабыннан мәхрүм итмәс идем... Ул ислам илендә, мөселманнар арасында туарга һәм яшәргә тиеш... Без шуның өчен илдән кубарылып кузгалдык бит... Ә монда... сез бик яхшы, Аллаһның рәхмәтләре булсын сезгә, әмма монда гел урыслар, кяферләр бит, минем балам да алар кебек булыр, дип куркам...

Телсез-чукрак Хөснибикәнең, әле үзе дә балалыктан чыгып бетмәгән Хөснибикәнең, шушы сүзләреннән барысы да тетрәнеп, тынып калдылар. Әйе, ул ишетмәсә дә, иң кирәген – иман хакына һиҗрәт кылганлыгын аңлаган, ул сөйләшә белмәсә дә, иң кирәген – иман хакына юлын дәвам итәргә кирәклеген белә. Ишеткән-сөйләшә белгәннәргә җаны, йөрәге белән үзенә ни кирәген аңлатты. Моннан соң үгетләп торудан мәгънә юк иде. Салих та әллә нишләп китте, ул соңгы вакытларда гел киресен уйлап йөри башлаган иде, ә Хөснибикәсе иң кирәген әйтте дә бирде: «Туачак балабыз хакына кяфер иленнән китәбез», – диде. Әйе, алар үзләре илдән генә түгел, кайчан да булса бу дөньядан да китеп котылырлар, ә калган балалар, нәсел кем булыр? Кем арасында яшәсә – шул булыр. Моны хәтта бер тапкыр да авылдан чыкмаган телсез-чукрак хатын да аңлаган, ә ул, ир башы белән, әллә нинди вәсвәсәләргә төшеп бетте...

– Ярар, балалар, үзегез беләсез, – диде сүзне йомгаклап Ибраһим мулла. – Без Хөснибикәнең авырлы һәм авыру булганы өчен генә кызганып әйткән идек бу сүзләребезне. Ишегебез һәрчак ачык, Аллаһ мөсафирларына ярдәм итү безнең изге бурычыбыз. Калганын үзегез хәл итегез.

Урамда җил-давыл бераз тынган арада, Хөснибикә дә шактый тернәкләнде, инде аягына басты, китәргә әзерләнә башлады. Ул арада мөһаҗирләрне алырга килгән кораб хуҗалары да диңгезгә чыгарга әзерлекләрен белдергәннәр, иртәгә таң белән юлга кузгаласы, ди. Хөснибикәне җылы итеп киендереп, сиртмәле тарантаска утыртып, диңгез портына Ибраһим мулла белән Әминә абыстай үзләре илтеп куйдылар. Бирегә инде Хаҗиханәдән дә мөһаҗирләр җыела башлаган иде, алар Хөснибикәне күргәч, шатланып, аны кочаклап алдылар, бигрәк тә Зөлбану сөенде, ул апасы монда кала икән, дип, бик курыккан иде. Ирләр әйберләрне ташыдылар, хатын-кызлар төркем-төркем булып аларны саклап торды, бала-чагалар да шул тирәдә генә чуалды, аларның тизрәк бу кораб дигәннәренә кереп утырасы килде...

Көн бераз рәтләнеп киткән кебек тоелса да, диңгез бөтенләй үк тынычланып бетмәгән иде әле, мөгаен, бу айларда ул инде ахыргача тынычлана да алмыйдыр.

Әнә бит каралы-сорылы дулкыннар әллә кайдан гына килеп чыгалар да ярсу бер көч белән яр читенә китереп бәрәләр, һавага су баганалары күтәрелә... Бер дулкын артыннан икенчесе йөгереп килеп кенә җитеп тора, әле бу култык дигәннәрендә шулай, ә ачык диңгезгә чыккач ни булыр? Белгән кешеләр шулай сөйләшә, ә мөһаҗирләр борчылмаска тырыша, кораб хуҗасы юлга кузгала икән, белеп эшлидер, диләр. Инде монда хәтле килеп җиткәч, диңгез аша Истанбулга бер-ике көндә ничек тә барып җитәрбез, түзәрбез, дип үз-үзләрен юаталар. Ә диңгез һаман нәрсәгәдер ачуланып кайный, мырлый, җырлый, әллә нинди ят тавышлар чыгара, тагы әллә нәрсәләр вәгъдә итеп, юеш йодрыгын селки, мөһаҗирләрне куркытырга тели...

Мөһаҗирләрне озатырга Хөсәен бай да уллары белән килгән иде, тагы күп кенә татарлар, мөселманнар да пристаньга җыелды. Һәрберсе нидер күтәреп килгән, китүчеләргә үзенең киңәшен һәм кучтәнәчләрен бирә, дога кыла... Инде мондагы халык белән танышып-дуслашып беткән мөһаҗирләр дә, туганнары белән аерылгандай, аларны кочаклап елыйлар, дога кылалар... Диңгезнең бу ягында, бу ярында яшәүче татарлар – алар туган илдә күргән-белгән соңгы татарлар, шуңа күрә аерылышу да бик хәсрәтле-сагышлы... Озата килүчеләр белән саубуллашып, паром-корабка утыра башладылар. Хөснибикә дә инде үз туганы кебек якынаеп өлгергән Әминә абыстай белән кочаклашып саубуллашты, ишарәләр белән аңа рәхмәтләрен әйтте. Салих та Ибраһим мулла белән саубуллашып, Хөснибикәне кулларыннан җитәкләде һәм алар, мөһаҗирләр төркеменә кушылып, тар баскычлардан күтәрелделәр. Аннан соң Салих Хөснибикәне апалары кулына тапшырып, үзе Юанбаш Мөхәммәдигә ярдәм итәргә китте, чөнки халыкны урнаштырырга кирәк иде. Бу кораб дигәннәре йөк ташый торган гаҗәеп зур паром булып чыкты, чөнки бу кадәр халыкны гадәти пароходларга сыйдыру мөмкин түгел, мөһаҗирләрнең аны сатып алырга акчалары да җитмәс иде...

Ә халык керде дә керде, инде астагы зур-зур бүлемнәр дә кеше белән шыплап тулды, өскә, баскыч асларына, бөтен буш урыннарга әйберләрен куйдылар һәм үзләре урнаштылар, берничә көнгә ничек тә түзәрбез, дип, үз-үзләрен юаттылар. Монда инде ирләргә-хатыннарга аерылып торырга мөмкинлек юк иде, һәркем үз гаиләсе, үз туганнары, үз авылдашлары белән бер тирәдә урнашырга тырышты. Хөснибикә дә Зөлбанулар белән бергә булды, ә Салих исә һаман Юанбаш Мөхәммәдиләргә булышып, әйберләрне урнаштырып йөрде. Менә халык бөтен бүлемнәргә шыплап тулды, монда хәтта кыймылдарлык та урын калмады, алар кисмәктәге балыкларны хәтерләтәләр иде. Шунда ук эссе булып китте, салкыннан куркып киенгән кышкы киемнәр тагы салынды, һава җитми башлады. Ул арада кораб, торбасыннан аклы-көрән төтеннәр чыгарып, сузып кычкыртып җибәрде, шалдыр-шолдыр китереп тимер чылбырларны җыйдылар, баскычны күтәрделәр һәм чайкала-чайкала кузгалып та киттеләр.

## Соңгы сәфәр

Гомерләрендә беренче тапкыр корабка утырып диңгезгә чыккан татар мөһаҗирләре баштарак кыймылдарга да куркып бардылар, аннан, бу хәлгә дә килешеп, ияләнә төштеләр. Ир-атлар хәтта батыраеп китеп, өске катка да менеп карады, намаз уку урыннарын җайладылар, һәркемне яңадан барлап-тикшереп чыктылар, барысы да көймәдә иде. Әмма култыкны үтеп, ачык диңгезгә чыккач, кораб сизелерлек итеп айкала-чайкала башлады, көчәя барган җил аны әле бер якка, әле икенче якка бәрде, әйтерсең лә таудан-тауга сикерәләр иде. Кешеләрнең кулларындагы пешкән йомыркалары тәгәрәп китте, авызларына китергән сулары чайпалып түгелде, тотынмыйчарак барганнары бер-берләренең өсләренә аудылар.

Бу хәлдән балалар чырылдап елап җибәрде, хатын-кызлар пыш-пыш килеп дога кылды, ирләр исә, тотына-тотына, өске катка менеп киттеләр, кораб белән ни булганын ачыкларга уйладылар. Ә кораб белән берни булмаган иде, бары тик диңгездә җил көчәеп бара һәм тагы давыл чыгу куркынычы бар, шуңа күрә татар мөһаҗирләрен төягән йөк көймәсе дә шулай алпан-тилпән чайкала иде...

– Аллага тапшырдык, туганнар, исән-имин шушы дәрьяны кичәргә насыйп итсен инде! – диде Юанбаш Мөхәммәди. – Бик давыллап тора, хатыннарыгызга, балаларыгызга әйтегез – өскә менмәсеннәр... Бу хәлне күреп, куркырлар, җил очырып алып китүе дә бар, Аллам сакласын!

Ә өстә, чыннан да, җил улап тора иде, тагы әллә кайдан гына килеп, яңгыры башланды, ул төшә-төшешкә катып бозга әйләнә, инә кебек чәнчеп йөзгә бәрә, күзләрне томалый иде. Диңгезгә эчкәрәк кергән саен, давыл көчәя барды, тау-тау дулкыннар кораб өстенә ыжгырып киләләр дә палубага ябырылалар, тотынмыйча басып торсаң, үзләре белән алып төшеп китүләре дә бар. Кораб исә гәүдәсен тота алмыйча калтырана, дулкын китереп бәргән саен, сискәнгәндәй, сикереп китә, әле бер якка янтаеп куя, әле икенче якка авып диярлек бетә... Бу хәлне күреп, ирләр дә куркып калды, тизрәк аска төшеп киттеләр, анда исә аларны идән буенча тәгәрәп йөргән балалары, аларга чытырдап ябышкан хатыннары көтеп тора иде. Нәрсә бу?! Нигә бу кораб дигәннәре шулай болгый, аякка басарга да ирек бирми, идәнгә сылый соң? Балалар коса, хатын-кызлар елый, төенчекләре, ризыклары кайсы-кайда тәгәрәп ята... Кайда монда ашау, кайда монда йоклау, хәтта намазны да күпләр утырган килеш кенә укыдылар, чөнки аякка басу мөмкин түгел иде...

Салих Хөснибикәсен кысып тотты, кочагыннан чыгармады, дулкын кайсы яктан китереп бәрсә дә, аларны бер-берләреннән аера алмады, идән буйлап та бергә тәгәрәделәр. Икесе дә үзләре өчен түгел, карындагы бала өчен борчылдылар, аның сирәк-мирәк тибенеп куюына да сөенеп, үз хәлләрен онyттылар, сабыр иттеләр. Әмма беркем дә диңгез юлының болай ук куркыныч һәм авыр буласын күз алдына да китермәгән иде... Тышта яман тавыш белән диңгез үкерә, эчтәге мөһаҗирләр кайсы ятып, кайсы тезләнеп, кайсы утырып Аллаһка ялвара, балалары хакына бу афәттән исән калдыруны сорый... Корабтагы бөтен тимер-агач корылмалар соң чиккә җитеп, шартлап сынардай булып шатырдый башлады, өстә кемнәрдер йөгереште, аста кемнәрдер җан ачысы белән кычкырып җибәрде:

– Батабыз, бетәбез бит!!! Нишлик?! Шушында җан бирү өчен юлга чыктыкмы икәнни, Раббым?!

Аубаткан авылыннан яшь кенә хатын, баласын күкрәгенә кысып, үкереп елый иде... Ә баласы, дүрт-биш яшьләрдәге малай, камыр кебек анасының кулына салынып төшкән, йөзендә җан әсәре юк, хәтта сулыш алганы да сизелми... Алар янына Зәйнәп абыстай белән Таһирә апа шуышып диярлек килделәр, хатынның кулыннан авыру баланы алдылар, ә ул инде суынып беткән иде...

– Үлгән, балакай, киткән, җаны очкан, – диде Зәйнәп абыстай, баланың өстенә иелеп. – Иннә лилләһи вә иннәә иләйһи раааҗигуун! Аллаһтан килдек, Аллаһ каршына китәбез... Сабыр ит, Гафифә кызым...

Аубаткан хатыны шунда гына аңына килде, бу сүзләргә ышанмыйча, бер баласына, бер Зәйнәп абыстайга карады, аннан: «Улым, Абдулла, улым, Абдулла, ач күзеңне!» – дип өзгәләнде. Башкалар да үз хәлләрен онытып, яшь ана башына килгән олы хәсрәттән шашып калдылар. Юлда авырулар булса да, Кумыслы хатыны Мәрфуга үлгәннән соң, әле беркемнең дә башына мондый кайгы-хәсрәт килмәгән иде. Инде күпме юл үтеп, инде ниятләгән җиргә барып җитәбез, дип торганда, тагы бер хәсрәт, тагы бер мәет! Инде монысы диңгез шәһите! Бәлки, аларның барысын да шушы хәл көтәдер?

Аубаткан хатыны үле баласын күкрәгенә кысып, үксеп-үксеп елый башлады, янына ашыгып ире килеп җитте. Аның да хатынын юатырлык сүзләре юк иде, ул да бердәнбер улын, кичә генә йөгереп уйнап йөргән баласын югалткан иде, ул да баласы өстенә капланып, сулкылдап елый иде... Ирләр киңәш-табышка җыелдылар, баланы күмәргә кирәк иде, әмма кайда, ничек итеп? Тирә-якта диңгез актарыла, әле коры җиргә ерак, ә мәетне каядыр куярга кирәк. Кораб хуҗасы белән дә киңәшеп, мөселман гадәтен дә искә алып, баланы кәфенләп, җеназа укып, диңгезгә ташларга булдылар, белгән кешеләр, тәртибе шундый, диделәр. Инде ата-анасына шуны җиткерергә, халыкка ни өчен шулай эшләгәннәрен аңлатырга кирәк иде.

– Туганнар, ни эшләмәк кирәк, күрәсез – арабызда тагы бер мәет бар, – дип сүзен башлады Юанбаш Мөхәммәди. – Аллаһы Тәгалә юлдашларыбыз Гайнетдин белән Гафифәнең бердәнбер улларын үз янына алды... Димәк, баланың тәкъдиренә үзе туганчы ук шулай язылган булган... Ата-ана өчен авыр кайгы, әмма бернишләп булмый, тәкъдирне үзгәртә алмыйбыз... Аллаһтан сезнең өчен сабырлык сорыйбыз... Инша Аллаһ, сабыйның урыны җәннәттә булыр, һиҗрәт шәһитләреннән булыр, сезгә дә җәннәт капкаларын ачар... Инде баланы җеназа укып, күмәргә кирәк, әмма без диңгез уртасында, димәк ки, без аны суга гына тапшыра алабыз... Кораб капитаны да шулай ди, хәтта Мәккәгә барырга чыккан хаҗилар да, диңгездә үлсә, аларны җеназа укып, диңгезгә ташлыйлар икән... Безгә дә шулай итәргә туры киләчәк.

Бу сүзләрне ишеткәч, халык тынсыз калды, алар мондый хәл булыр дип күз алларына да китермәгәннәр иде. Димәк, монда үлә калсалар, аларны да шушы язмыш көтә? Кәфенлеккә төреп, диңгезгә ыргыту көтә?! Аларның хәтта каберләре дә булмаячакмыни инде?

Халыкның дулкынлана башлавын күреп, Юанбаш Мөхәммәди тагы сүз башлады:

– Туганнар, без нинди юлга чыкканыбызны белеп чыктык, – диде ул. – Аллаһ ризалыгы өчен, туган җирләребезне калдырып, һиҗрәткә кузгалдык. Бу озын һәм авыр юлда теләсә кайсыбызның җанын Газраил килеп алырга мөмкин иде. Бу инде бездән тормый... Алай да без бирегә хәтле исән-имин килеп җитә алдык, әмма барыбызның да язмышы кыл өстендә... Без хәзер корабыбыз белән котырган диңгез өстендә йомычка кебек бөтереләбез, сәфәребезнең ахыры ни белән бетәр – белмибез... Аллаһ безне менә шушындый без белмәгән һәм күрмәгән авырлыклары белән сыный... Инде барыбызга да көне-төне гыйбадәт кылып, Аллаһтан сорарга кирәк – һиҗрәт юлыбызда бу сабый корбаны соңгысы булсын иде! Үзебезгә бу бәладән исән-имин котылып, җиргә аяк басарга насыйп итсен иде! Шул хакта дога кылыйк! Ә баланы югарыга алып менеп юарбыз, кәфенләрбез, җеназа укырбыз һәм Аллаһка тапшырырбыз.

Абдулланың мәетен анасы кулыннан сак кына алдылар да атасына тапшырдылар. Баланы төрергә кәфенлек кирәк иде, берничә кеше үз кәфенлеген сузды, кешеләр юлга барысына да әзер булып чыкканнар икән. Ирләр өскә менеп китте, Зәйнәп абыстай белән Таһирә апа баласының үлеменә һаман ышанмаган Гафифәне кочакларына алдылар, ана кешенең бу хәлләрне күрмәве хәерлерәк иде... Ирләр исә арлы-бирле чайкалып торган юеш палубада, идәнгә яткырып, нәни Абдулланы юдылар, кәфенләделәр, баш очына басып, җеназа намазы укыдылар, аннан бисмилла әйтеп, диңгезгә ташладылар... Боларны эшләгәндә, олы ирләр дә сүзсез елады, алар гына түгел, бу хәлләрдән күпне күргән Кара диңгез үзе дә ярсып елый, бәргәләнә иде... Абдулланың ап-ак кәфенгә төрелгән нәни гәүдәсе, диңгез өстендәге акчарлак кебек, актарылып кайнаган суга барып төште... Кара дулкыннар аны шунда ук үз араларына

суырып алдылар, бала мәете бата-чума бераз су өстендә талпынды да, күздән югалды, юкка чыкты. Мондый хәлдән тетрәнгән ирләр дә аска, гаиләләре янына төштеләр, кораб, кара дәрьяның кара суларын ерып, кара төнгә кереп бара иде...

Хөснибикә тирә-ягындагы тавышны, диңгез үкерүен, хатын-кызларның һәм балаларның елауларын ишетмәсә дә, барысын да күреп торды – корабка бәла килгән иде... Күрше авыл хатынының терекөмеш кебек бердәнбер балалары үлгән, аны ир-атлар өскә алып менеп киттеләр... Аннан соң ни булганын Хөснибикә аңламады, әмма йөрәге белән шомланып сизенде – баланың мәете корабтан юкка чыкты. Ул карынындагы үз баласын куллары белән кысып тотты, сабый анасының җылысын тоеп, тибенеп-тибенеп алды, Хөснибикә тынычланып китте. Ире Салих та кулларын аның корсагына куйды, карындагы сабый аңа да тибенеп җавап бирде. Ир белән хатын, бер-берләренә сыенып, караңгы корабта шушы бәхеттән дә яктылык табып, уй-хыялларында киләчәкләренә таба йөзәләр иде...

Төнлә давыл бераз басылды ахры, ул чаклы болгамый башлады. Көне буе идәндә бәргәләнгән, үлем фаҗигасен күргән, тәннәре һәм җаннары арыган-талчыккан мөһаҗирләр кайда ятсалар, шундук изрәп йокыга киттеләр. Алар төшләрендә Себернең ап-ак карларын, шул карларда уелып калган җәнлек эзләрен, артларыннан томырылып чабып килгән тугры атларын, авыл өстеннән туп-туры күтәрелгән морҗа төтеннәрен, шул төтен белән бергә бар дөньяга таралган ризык исләрен, себеркеле мунча парларын, боз каплаган күлләрне, бәкедән су алган хатын-кызларны, мәчетләрдән кайтып килгән ак сакаллы картларны күрделәр... Алар моңсу гына туган илдән китеп баручыларга карыйлар, сагынудан саргаюларын әйтәләр, мөһаҗирләр белән мәңгегә бәхилләшәләр, ахирәт көнендә күрешергә өмет итәләр иде...

Хөснибикә исә төшендә балачагын күрде...

Әле әнисе дә исән вакыт икән, алар Ырыслы күл буенда йөриләр, әтиләре дә шунда... Ә күл өстендә ниндидер сәер кошлар бөтерелә, болар аккошлар түгел икән, чөнки алар хәзер монда килми, башка җирдә оя коралар... Бу кошлар бераз кечерәк һәм ап-ак, диңгез акчарлаклары кебек... Менә кошларның берсе, очып барган җиреннән, күлгә егылып төште, башкалары исә авыл өстеннән бер әйләнделәр дә кыйблага таба очып киттеләр... Суга егылып төшкән кош та алар артыннан йөзә башлады, кинәт ул кичә үлгән малайга әйләнде, кулларын сузып, башка кошлар артыннан йөгерде... Менә ул Хөснибикә янына килеп җитте, кулларын сузып, аны су буена өстерәде, ә анда... кәфенлеккә төрелгән бала мәете йөзеп килә иде...

Хөснибикә сискәнеп уянып китте, әкрен генә Салихны да уятты. Аның башы әйләнә, күңеле болгана иде, ул иреннән өскә, һавага алып чыгарга сорады. Алар изрәп йоклап яткан кешеләргә басмаска тырышып, караңгыда текә баскычтан өскә үрмәләделәр. Төнлә давыл бераз басылган, диңгез өсте дә тына төшкән, таң әле атып кына килә иде. Иркенлектән файдаланып, ире белән бергәләп иртәнге намазны укыдылар, аннан бераз диңгезгә карап, саф һава сулап тордылар. Шул чак Хөснибикәнең таң алдыннан күргән төше исенә төште, чөнки диңгез өстендә дә нәкъ шундый кошлар очып йөри иде... Аннан ул нидер сизенеп, аска карады, ә анда, кораб койрыгы артыннан, ак кәфенлеккә төрелгән бала гәүдәсе йөзеп килә иде...

Хөснибикә иренең беләгенә чытырдатып ябышты, куллары белән диңгезгә төртеп күрсәтте. Бала мәетен Салих та күрде, «Абдулла!» дип пышылдады ул, коты алынып. Әйе, кичә суга ташлаган бала мәете дулкыннар арасында бата-калка, кораб артыннан йөзеп килә иде... Салих белән Хөснибикә җитәкләшеп аска йөгерделәр, кешеләрнең күбесе инде йокыдан уянган, кайсы намаз укый, кайсы тирә-юнен тәртипкә китерә иде. Алар котлары чыккан Салих белән

Хөснибикәгә аптырап карадылар, ни булганын аңламадылар. «Абдулла!» – диде Салих, диңгез ягына кулы белән күрсәтеп. Халыкның бер өлеше өскә ашыкты, Абдулланың әти-әнисе дә алар арасында иде. Кораб артыннан йөзеп килгән Абдулланы шунда ук күрделәр, аның өстендә акчарлаклар бөтерелә, алар аны әллә саклап килә, әллә үз вакытларын көтә – аңлап булмый иде...

– Улым! – Диңгез өстен үзәк өзгеч тавыш телеп үтте, бу – Абдулланың әнисе Гафифә шулай ачыргаланып кычкыра иде. – Улым! Балам! Балам!!!

Гафифәне тизрәк читкә алып киттеләр, чөнки ул рәшәткәгә күкрәге белән капланган, бер-ике талпынса, үзе дә диңгезгә очып барып төшәргә мөмкин иде. Хатыннар кочаклап алып, аны юата башладылар, баланың атасына исә үзенә ярдәм кирәк иде. Ул диңгез белән палубаны аерып торган тимер рәшәткәгә сыгылып төшкән, улын йөрәге белән тартып алырлык булып, кулларын аңа сузган, үзе туктаусыз, «балам, балам», дип кабатлый... Диңгез өстендә ачыргаланып акчарлаклар елый, кораб идәненә тезләнеп, бердәнбер балаларын үз куллары белән диңгезгә салган ата-ана елый, алар артыннан, аерылып калырга теләмичә, Абдулланың ак кәфенгә төрелгән нәни гәүдәсе йөзеп килә... Бала әле шактый вакыт шулай бата-калка кораб артыннан йөзеп барды, аннан диңгезнең соры дулкыннары аны соңгы тапкыр өскә күтәрделәр дә, акылдан шашарлык хәлгә килгән ата-анасына соңгы тапкыр күрсәтеп, үз куеннарына алдылар. Абдулланы озата килгән акчарлаклар да күздән югалды, палубадагы кешеләр дә, салкынга түзә алмыйча, берәм-берәм аска төшеп китте, бары тик тимер рәшәткәгә капланып, ата белән ана басып калды... Алар һаман нәни Абдулланың гәүдәсе су өстендә күренер, дип көтәләр иде... Ә ул башка күренмәде, кара дәрья илсез-җирсез бер татар баласын үз кочагына алды...

Ә аста халык тын калып, озак кына сөйләшмичә утырды. Мондый дәһшәтле, шомлы, куркыныч хәлне аларның гомерләрендә дә күргәннәре юк иде. Әле кайчан гына йөгереп йөргән газиз балаң күз алдында җан бирсен дә, аны үз кулларың белән суга ташла әле! Һәм шул бала дәрьяда батмыйча, кораб артыннан ияреп килсен әле – акылыңнан шашарсың! Бу юлда аларның һәрберсен шушы хәл көтәргә мөмкин бит! Менә нәрсә икән ул һиҗрәт – ул һәр мизгелдә үлем белән очрашу, су төпләренә китү, дигән сүз дә икән әле! Җәннәткә юл шушы җирдәге тәмуглар аша да үтә икән!

Халыкның күңелсезләнеп калуын, пошаманга төшүен күреп, Юанбаш Мөхәммәди сүз башлады:

– Монда үзебездә дә гаеп бар, җәмәгать, мәетне суга салганда, авыррак әйбер бәйләргә кирәк булган, – диде ул. – Күрәсез, ул батмаган, су өстенә калкып чыккан... Дулкынга ияреп, арттан йөзеп килгән... Ата-анасына авыр инде бу хәлләрне күрү, Аллаһ сабырлыклар бирсен... Мондый хәлләр бер безнең башка гына төшмәгән, хәтта пәйгамбәрләр башына да килгән. Юныс пәйгамбәр кыйссасын хәтерләсәгез, аны хәтта диңгездә зур балык йота, ул балык карынында да Аллаһка дога кылуын ташламый. «Лә иләһә иллә әнтә, субханәкә инни күнтү минәз-залимин», дип дога кыла, ягъни, «Синнән башка илаһ юк, Син пакь булучы Зат, дөреслектә мин золым кылучылардан булдым», дип Аллаһка ялвара. Ни өчен Юныс галәйһиссәлам үзен шулай дип атый, чөнки ул иман китермәгән кавемен ташлап китә, ә кавеме, күзенә үлем газабы күренгәч, иман китерә, Аллаһ алардан газабын кире ала... Әйткәнемчә, Юныс пәйгамбәр Аллаһ рөхсәтеннән башка халкын ташлый, әле җитмәсә, аларга рәнҗеп дога кыла, менә шулар өчен Аллаһ аның үзенә җәза бирә. Әгәр Юныс пәйгамбәр балык карынында тәүбә итмәгән булса, Аллаһка гыйбадәт кылмаган булса, кыямәт көнгә хәтле шунда калган булыр иде... Коръәннең «Нун» сүрәсендә бу хакта болай әйтелә: «Чыда Раббыңның хөкеменә һәм кяферләрнең каршылык


күрсәтүләренә, вә балык юлдашы Юныс кеби булма. Ул Юныс балык эчендә тарлыкта Раббысына мөрәҗәгать итте, ялварды эченә кайгы тулган хәлдә. Әгәр ул Юныска балык эчендә Раббысыннан нигъмәт ирешмәгән булса иде, әлбәттә, балык эченнән чыгарылып, агачсыз вә үләнсез булган сәхрага хур итеп ташланыр иде. Ул Юнысны Раббысы ихтыяр кылды, яңадан вәхи иңдереп, пәйгамбәрлеген дәвам иттерде, дәхи аны изгеләрдән кылды». Күрәсез, Аллаһ хәтта үзенең сөекле пәйгамбәрләренә дә ялгыш-хаталары өчен нинди җәзалар биргән, ә без, гади халык, җаһиллектән әле чыгып та җитмәгән кавем, ни көтик? Шуңа күрә төрле көфер уйларга бирелмик, кардәшләрем, һиҗрәтебезнең савабын киметмик, Аллаһның җәзасына тарымыйк. Нишлисең, мондый озын һәм авыр юлда төрлесе булырга мөмкин, без әле дә күпчелектә монда кадәр исән-имин килеп җиттек. Инде күп калмады, сабыр итик! Әнә, күрәсез, диңгез дә бераз тынычланды, хәзер алай болгамый. Сабыр итик, авылдашлар, юлдашлар, күбенә түздек, инде азына түзик... Аллаһ ризалыгы өчен, түзик... Бу барыбыз өчен дә зур сынау...

Юанбаш Мөхәммәдинең бу сүзләреннән соң корабта тынлык урнашты. Һәркем үзенекен уйлады, һәркем эченнән генә тәүбә итте, дога кылды... «Инде пәйгамбәрләр башына да шундый авырлыклар килгән икән, без ничек бер авырлык күрмичә җәннәт өмет итик?» дип уйлады алар. Һиҗрәт бит ул күрше авылга гына барып кайту түгел, яки теге яки бу нәрсә ошамый, дип, урын алыштыру түгел. Һиҗрәт – Аллаһ ризалыгы өчен, иманыңны саклау өчен, дин тотарга ирек булган урынга күчеп китү... Шушы юлда сабыр итү, сыналу, барысына да түзү... Хәтта үлем-китемгә дә, чөнки Аллаһ бирә – Аллаһ ала...

Юанбаш Мөхәммәдинең бу сүзләреннән соң Салих тагы уйга калды. «Аллаһы Тәгалә Юныс пәйгамбәрне кавемен рөхсәтсез ташлап киткән өчен шулай каты җәзалаган, ә без дә туган халкыбызны, туып-үскән җирләрне ташлап китеп барабыз бит, – дип уйлады ул. – Үзебезнең җаннарыбызны, иманыбызны саклау өчен, без халкыбыздан, илебездән мәңгегә аерылдык... Ә алар нишләр? Анда калган милләт нишләр? Бөтен халык кубарылып чыгып китә алмый бит, димәк, без аларны дошман кулына калдырып киттек? Бер яктан, һиҗрәт – савап, икенче яктан, халкыңны дошман арасында калдыру гөнаһ та булырга мөмкин бит әле... Һәм моңа җәза да булуы мөмкин... Раббым, кичер без гөнаһлы бәндәләреңне, ниятебез изге иде, инде бу эшләрнең ахырын да хәерле кыл! Мөселманнар арасына исән-имин барып урнашып, үзебездән соң иманлы нәсел калдырырга насыйп ит!»

Диңгез бераз тынычланганга, ирләр өйлә һәм икенде намазын иркенләп өстә укыдылар, хатын-кызлар да бераз тынычланды, кулларына тәсбих тотып, белгән догаларын укырга утырдылар. Юл никадәр авыр булса да, үлем һәм авырулардан торса да, инде килеп җитәбез, инде аз гына калды, дигән өмет барысын салкында да җылыта, бөтенләй аумаска көч бирә иде... Әйе, инде ерак калмады, арыган һәм тилмергән сабыйларны йөрәккә кысып, тагы бераз түзәргә... Ә анда, диңгезнең аръягында – Истанбул, мөселман өммәтен үзенә җыйган Исламбул, аларның булачак Ана Ватаннары, туачак балаларының, оныкларының Ата Йорты, нәселнең нигезе хәзер син булачаксың, Төрек Иле, Төркия! Җылы күңелең белән кабул ит салкын Себерләрдән иман хакына сиңа күченгән себер татарларын, заманында бөек милләт булган кавемнең илсез-җирсез, дәүләтсез калган ятим балаларын! Алар сиңа өмет белән килә, карлы-бозларны күкрәкләре белән ерып, коллык чылбырларын тешләре белән өзеп, алар сиңа дога белән килә, Төркия! Кабул ит татар мөһаҗирләрен...

*Беренче китап тәмам.*



Рим
Идиятуллин

# ЕРАКЛАРГА ҖИЛДЕ БОЛЫТЛАР

## Хастаханәдә туган уйлар...

*Утырдым ла көймәнең, һай, түренә,*
*Карадым ла агымсулар төбенә,*
*Су төпкәйләрендә һичбер кара юк,*
*Хак язганны күрми чара юк!*

**1**

Дәһриләр җырын җырлый-җырлый
Җилсәк тә без калтыр арбада,
Әйләндек лә гомер азагында
Атка печән салмас муллага.

Эшкә түгел, ашка йөрү генә –
Калды нибарысы шул шөгыль;
Үләргә дә риза булыр идем,
Картаюны белсә хөр күңел.

**2**

Нәрсә үлем? – Коты сүнгән йортка
Ачылмаслык йозак эләсе;
Ә калдырсаң нәсел агачы,
Бикләнмичә торыр keлəce.

Хафаларга төшмә, калыр эшне
Түгел аны очлап бетәсе;
Баш очыңа килеп берәрсе
Чүксә тезен – дөнья бәһасе...

**3**

Берәү килә, берәү китә, юк бәла, –
Җир үз күчәрендә әйләнә;
Ике гасыр Күкне күзләсәм дә,
Ниләр барын белмим галәмдә.

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) – *шагыйрь; «Хәерле иртә», «Хәерле көн», «Хәерле кич» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Уфада яши.*

Игелекле Җирем! – Таптым урын
Печтек кенә гамәл кылып та;
Серем сыйды да бит, сыеныр җир
Табылырмы чиксез бушлыкта?..

**4**

Аягүрә яна чал урманнар,
Йөзе кибеп үлә елгалар,
Әйтегезче, дөньяларда хозур
Табигатьтән башка ни ямь бар?!

Их,
Ничекләр соң, ничек янәдән
Кайтарырга җир-су, ил котын?
Мәңге яшәр булып, терек суын
Уртлый алсам әгәр бер йотым,
Кайтарыр да идем кабаттин.
Ай-һай гамьсезләндең син, кешем?!

**5**

Язмыш дәрьялары, ай, болганчык,
Хәтәр чоңгыллары күренми;
Тәкъдиреңә ни язганны Ходам
Алдан укырларга ник бирми?!
Аһ, бирми.

Күрәчәгем күз алдымда торса,
Бер елганы кабат кичмәс идем,
Якын килмәс идем утларга,
Чиккән гомеремә шөкер итеп,
Аягымда чакта авар идем.
Юк шул! –
Бу хыялны әҗәл башкара...

**6**

Кемне сорашсаң да: «Китте», – диеп
Сөйли якташ гамьсез бер төстә;
Язмыш белән күпме көрәшсәң дә,
Булмый җиңеп, кала ул өстә.

Гомер – көрешү дә хушлашу ич,
Ник көтәргә әле искәрмә?!
Сөен! – Җан иректә, яшәп ятам
Майлы ботка кимереп кенә...

**7**

Тормыш дигән диңгез кичә-кичә,
Шатлык бетә, кайгы өелә;
Ни теләсәң телә, кәкшән картка
Озын гомер генә теләмә!

Мәңге яшәгән соң кем генә?!
Диңгез кара, төшсәң төбенә.
И игенчем! Кара ипиеңне
Ашадым мин тәмләп, гел мактап;
Чара тапсам, йөземнәрдән туеп,
Шул икмәкне иснәр өчен генә
Качып кайтыр идем оҗмахтан.

## Дөньялар кая барыр?

Дөнья миннән башланмаган,
Дөньясы миндә бетмәс.
…Ник ярылып кычкыра соң,
Кич тәмле шулпа буласын
Кикригенә дә элмичә,
Таңны уяткан әтәч?

Ни җитми төн карасында
Өздереп сайрар кошка?
Син җырлы җаннардан өйрән, –
Һәр туар көн олы бәйрәм
Икәнлеген белә ич ул;
Их, моңлы гомер кыска.

…Сандугач моңын тыңладым,
Көттем ал таң туганын;
Ә яшәп һич тә туймадым.
Кабер ташымнан да авыр
Бер соравым сезгә калыр:
Дөньялар кая барыр?

## Хәерле төн

…Айны болыт йотты. Төн күзендә
Җемелдәшә көзге яфраклар;
Сунарга да чыгар вакыт җитте:
Хәерле төн телим  шагыйрьләргә!
Хәерсезе сезгә, караклар!

Шагыйрьләр дә, караклар да, әйе,
Икесе дә бер үк нәселдән;
Кичер, Ходам! Мин дә бур һөнәрен
Үзләштердем үсмер яшемнән.

Юк, алмыймын гөнаһ үз өстемә:
Өелеп ятмагае! – Чит-ятның
Кечтек энәсенә тимәдем;
Мәгәр, кеше күрмәгәндә, күктән
Алтын сүзләр урлыйм төннәрен.

Чуар төскә кергән язмышларның
Чуалчыклы  җебен сүтә-сүтә,
Саплыймын да каләм кашына,
Җан җылыткыч шигъри кием тегәм
Җирдә яшәгәннең барсына.

Бу тәңгәлдә мин ялгызак түгел,
Чал табигать – тиңсез көндәшче:
«Һәрбер күзәнәгем – тере шигырь,
Син шымып тор, шагыйрь!» – димәкче.

Һич белдермим үпкә табигатькә, –
Игезәк ич изге шөгыльләр;
Шуңа да мин ихлас теләк юллыйм:
Хәерле төн сезгә, кешеләрем!
Хәерле төн, хаклы шагыйрьләр!

## Бер сурәт

Дөньяда күп гыйбрәтле сурәт:
Күктә – болыт, җирдә – гашыйклар.
Салкын күз яшьләрен коймый гына
Тукталган да калган болытлар.

Көпә-көндез урам уртасында
Кочаклаша түзмәс гашыйклар;
Сөю-сәгадәтне санламасаң,
Үч кайтармый калмас болытлар.

Сөрмә тарткан кашын җыерды да
Бәрде җиргә бозын болытлар;
Кая качар урын табалмагач,
Шәрәләнеп калды гашыйклар.

Арынгачтын йөктән, җилне җигеп,
Еракларга җилде болытлар;
Мәхәббәтне хәзер бар галәмгә
Күрсәтергә кыймый гашыйклар.

***

Гомер кичү беләсезме нәрсә?
Ачы әрем үскән кола яланда
Язмыш белән икәү качыш уйнау,
Әҗәл бер мизгелгә күзен йомганда.

***

Киләчәккә кайтыр исәбем бар,
Иярләсә җилне уй-җилкән;
Юк, мин анда оҗмах эзләп йөрмәм,
Кош сайравын тыңлаучылар булса,
Тукай исән торса, шул җиткән,
Шул җиткән!



Дамир
Гыйсметдин

# АСЫЛТАШ

САТИРИК МАҖАРА

Мәгълүм ки, һәр авылда теләсә нинди техниканы сүтеп җыючы, аның эшләү тәртибен аңлардай талантлы адәм бар. Техника җене кагылган андый инсаннар конструкторларның башына да кермәгән ысулларны кулланып, якын кешеләренең тормышларын бераз гына булса да үзгәртә һәм җиңеләйтә алганнар. Аларны халык инженерлары, урысча әйтсәк – кулибиннар дип тә атаганнар. Шундыйларның берсе – һәр тишеккә борынын тыгып, үтә кызыксынып гомер итүче Зиннур бабай. Ул үзе, ничектер сүтеп-җыештырып ясаган детектор радиосын тыңлап, имеш, әйткән булган: «Ярман безгә яу белән килергә охшаган. Тиздән сугыш булыр ахрысы...» – дигән. Чын тарих соңрак авыл күрәзәчесенең әйтүен тулысынча раслаган-раславын. Ләкин баштагы мәлендә сәяси фаразлау Зиннурга бик кыйммәткә төшкән. Радиоалгыч ясарлык сәләте булган акыллы агай да вакыйгаларның тиз арада шулхәтле трагик рәвештә килеп чыгуын берничек тә күз алдына китерә алмаган. НКВД хезмәткәрләре бу сәяси фаразлауны коткы тарату дип бәяләп, Зиннур аганы һәм үз куллары белән ясаган «җинаять җиһазларын» конфисковать итеп, бер әрҗәгә җыештырып-төяп, «воронокка» утыртып, тиешле җиргә алып та киткәннәр. Кешеләр сугышта катнашып, орден-медальләр тагып, урам тутырып, гармун тартып кайткан мәлдә, радиосөюче Зиннур агай, чиләнеп, урман кисеп, алты елын «Карлаг» дигән төрмәләрдә черки ашатып, туберкулёз хастасын ияртеп, авылына шым гына кайтып төшкән. Әле, күрше-күлән күрмәсен дип, бакчаларны әллә кайлардан урап, төн караңгылыгына төренеп кенә туган йортының тәрәзәсен шакыган... Әйе, аның аянычлы мисалы әле күп еллар авыл кешеләрен, шомлы бер искәрмә сыман, һәрдаим өркетеп тора иде. Бу җирлектә яшәгән һәркем аңлый инде: озын тел гомерне кыскарта. Әлеге гыйбарәне биредә ана сөте белән дә, тана сөте белән дә кертәләр иде. Кем-кем, ә Тимәш кешесе хәзер урамга чыгып серен җилгә дә сөйләмәс. Җае чыкса-чыкмаса да, теле үтереп кычытса да, ул дәшми калуны хуп күрә. Кинәнеп китеп, хакимиятләрне сүгү теләсә нинди авылда шәйләнгәндер, чөнки яңа сәвит влачы гади кешене санга сукмавы, җәберләве белән дөньяда атказанган. Тик Тимәш халкы җаны-тәне белән яңа влачны күрәлмәсә дә, телен аркылыга тешләп яшәгән. Һәм моны буыннан-буынга сеңдереп калдырган. Әлеге яшәү рәвешен Зиннур аганың оныгы Сабир мыегына бик яхшы чорнап куйган иде. «Күп күрмә, күп сөйләмә!» кагыйдәсен тотып, ул башлап мәктәпне, аннары

Дамир ГЫЙСМЕТДИН (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; «Әйтсәм әйтим», «Атта да, тәртәдә дә», «Өметсез шайтан», «Кая ашыгырга?..» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

сәүдә университетын тәмамлап, үз көнен үзе күрде, бернинди маҗараларга, гадәти булмаган хәлләргә, сәяси уеннарга катнашмый гына, Аллага шөкер, пенсия яшенә килеп төртелде. Лаеш шулпасы эчеп үскән Сабир, инде ниһаять, пенсиягә чыгып, абыстае Гөлчирә, оныклары белән бергә чөкердәшеп, намаз карты булып яшәргә хыялланган мәлдә, дөньялар тагын үзгәреп, катлауланып китте. Менә бүген дә, пенсиядә булуына карамастан, ул ашык-пошык җыенып, ике авылдашы Галимҗан һәм Зөлфекәр белән, Мәскәүгә бәхет эзләп китеп бара.

Поезд белән бу кичтә Мәскәүгә бәхет эзләп китеп барган Тимәш пенсионерларының өчесе дә эшче-крәстиян хакимиятенең «игелеген» ачлытуклы яшьлекләрендә байтак тәмсенгәннәр иде. Шул ук Галимҗанны гына алыйк. Нишләптер илгә ияреп колхозга кермәгән Биктаһир бабасы нәсел-нәсәбәсен шактый авыр сынауларга дучар итте. «Кулак нәселе» дигән мөһер әйтерсең лә бөтен ыруының маңгаена клеймә сыман чәпәп куелган иде. Инде картаеп барган Биктаһир аганың егерме биш сутый бәрәңге бакчасы мәктәпнең спорт мәйданчыгы белән янәшәдә урнашуы гына да кулак агайның күпме гомерен кыскарткандыр. Волейбол тубы, ара-тирә, Биктаһирның бәрәңге бакчасына килеп төшсә – эшләр харап! Биктаһир абзаң әйтерсең лә шуны гына көтеп торган. Ул яшенә карамастан, беренче булып тупны табып ала һәм, «ул миндә» дигәндәй баш өстенә күтәреп, спорт мәйданчыгындагыларга күрсәтә. Аннары буразнадагы тупка баса да дүрт япьле сәнәк белән мәктәп милегенең язмышын шундук хәл итеп куя.

– Мәгез тубыгызны, уйнагыз!..

Әлбәттә, бу усал гамәлнең нигезендә Биктаһир бабайның мәктәп балаларына түгел, ә сәвит влачына тирән нәфрәте яткандыр, мөгаен. Тик кулак бабасының оныгы Галимҗанга шундый дәү әтисе булганга күпме рәнҗеш сүзләре ишетергә туры килде...

***

Мәскәү поездында йоклап баручы команданың тагын бер әгъзасы Зөлфекар Ибраев турында бер-ике кәлимә әйтмичә ярамас. Аның да бабасы үтә кызыксынучан, белемле, туры сүзле кеше булган, диләр. Шулай килеп чыкты ки, өч авылдашның да бабалары тәртә кебек тугры сүзле, нишләптер влач белән уртак тел тапмыйча, үзләренең туксанын туксан итеп, үҗәт адәмнәр булып яшәгәннәр.

Мәгълүм ки, Сәвит хакимияте яңа тормыш коруны җимерүдән башлый. Бердәнбер төзек нәрсә авылда – мәчет-мәдрәсә. Чөнки догада булган диндар кешеләр гыйбадәтханәләрне үз тырышлыгы, хәләл акчасына, зәкятләр, сәдакалар хисабына тәртиптә тотарга тырышканнар. Ә кызыл куштаннар башкача фикер йөрткән: нишләп соң әле бу искелек символы шулай әллә кайдан күренеп, кояш нурларында горур балкып, яңа тормышны мыскыллап торырга тиеш! Зөлфекарның бабасы Байтимер, бисмиллалы кеше буларак, мәчет манарасын кисүгә ачык рәвештә каршы төшә. Намазга баскан саен динсез иблисләргә бәддога укый.

Әлбәттә, балкып торган манараны вәхшиләрчә кисүгә теше-тырнагы белән каршы чыккан Байтимер агайны халык дошманы дигән мөһер чәпәп, алып китәләр...

***

Тимер поезд әрҗәсендә сәяхәт кылган Тимәш пенсионерларын асылда бер нәрсә генә бәйли иде – мәнфәгать! Дөресрәге – акча. Һай ул акча дигәннәре! Мәмләкәтләрне, дөньяның иң затлы кешеләрен дә каршылыкка кертерлек көчкә ия булган, көтелмәгән сугышлар башлап, кан коюларга китергән акча галиҗәнапләре! Бәхетле булуның ставкалары да билгеле. Картаймыш көнендә хатыны Алия белән шул акча аркасында аерылуга барып җиткән халыкара сәүдә флоты матросы Галимҗанның иң татлы хыялы – якын арада баеп китеп, фатир

алу. Үз почмагына ия булу. Ике тапкыр аерылып, өч тапкыр өйләнеп тә бәхетле булалмаган Зөлфекарның төшләренә нишләптер Австралия, дөресрәге Һинд океаны ярларында урнашкан Аделаида шәһәре керә. Ул үзенең белеме, тәрбиясе белән ерак Австралиядә дә югалмас, киресенчә, бәхетле булырга тиеш иде. Зөлфекар белә – ул бу илдә ялгыш, очраклы гына туган. Күктәге көчләр ярдәмендә ул хатаны ничек тә булса төзәтәчәк, әлбәттә. Йә зур акча казанып, йә бер бай татар хатынына өйләнеп, ул соңарып булса да, теләсә ничек, морадына ирешергә тиеш!

Әйтергә кирәк, бу мәсьәләдә чын-чынлап җирдә басып торучы кеше – бәхет эзләүчеләрнең өченчесе – Сабир иде. Ул буш хыял артыннан чабып йөрми, үзенең урынын әйбәт белә. Күктәге йолдызларга үрелми-нитми генә үз көнен үзе күрә. Гомернең кешегә бер генә тапкыр бирелгәнен дә яхшы аңлый ул. Кооператив төзеп, үз көче белән баеп китеп, соңрак салым инспекциясендәге аферистларга эләгеп, тутый кошын кулыннан ычкындырганга, хәзер һәр адымын, һәр гамәлен уйлап, җиде кат үлчәп, бер генә кисәргә тиеш! Мәскәүгә килеп төшүгә үк, ул иске дусты Нургаянга шалтыратыр. Эшкә ашкынып торучы коллективның позитив энергиясен, җегәрен яңадан матур тормыш коруга юнәлтер! Алга!

***

Илле яшьләрендәге Нургаянның күзләре бер дә тик тормады. Гадәттә, андый йөгерек күзләрне психологлар йә түземсез, йә ялганчы кеше дип фаразлыйлар.

– Җегетләр, сезне исән-сау күрүемә бик шатмын! – диде ул, күзләрен төрле якка уйнаткалап. – Хәзер объектка барабыз, сакал биетеп алабыз, ягъни ашап алабыз, ял итәрсез. Иртәгә ударный труд, җегетләр. Алары хакында иртән баш заказчик килгәч, янә бер гәпләшербез... Безнең Тимәштә сөйләшкәннәр барсы да көчендә кала.

Әйтергә кирәк, мондый җылы каршы алу Казан командасына ниндидер шифалы оеткы салгандай булды. Кәефләр әйтерсең лә бер стаканны түнтәреп куйгандай иде. Димәк, әлегә барсы да яхшы! Аларга Сабир авылда җыелганда вәгъдәләрне әзрәк шәрехләгән иде. Ачыклык йөз процент булмаса да, бар, бригаданың әлегә борчылырлык сәбәпләре юк иде. Бер иске «УАЗик»ка төялеп, төзелеш осталары Мәскәү астындагы бер авылга җитеп, иске бүрәнә йортка урнаштылар.

***

Эш кешесенең вакыты бик тиз уза. Бигрәк тә кылган гамәлеңнең нәтиҗәсе күренеп торса. Ә ул, ягъни «кәтиҗ» диварлары һәр көн өскә күтәрелеп, хуҗа абзыйның да кәефен күтәрә, капитализмны үз куллары белән төзүчеләрнең дә күңелләренә дәрт-өмет өсти иде.

Ике ай тирләп-пешеп эшләгәч, төзелеш мәйданының иң хәлиткеч өлешендә эшләр кинәт тукталды. Гадәттә, иртән килеп эш бирә торган иде – Нургаян каядыр юкка чыкты. Кәтиҗнең хуҗасы Сабирның шалтыратуына, смскыларына баштарак илтифат итмәде, ә бер тәүлектән соң үзе шалтыратты. Җегетләр, янәсе, вакытлыча эш туктала. Всем лечь на дно!.. Соңрак сөйләшербез... Потом всё растолкую!

Әлбәттә, мондый форс-мажор хәл акча казанырга килгән Тимәш бригадасының планында юк иде. Шуңа алар аптырашып Сабирга төбәлделәр. Янәсе, аңлат бу хәлләрне!

Дөресен әйткәндә, сакланганны Алла саклар, дип яшәгән Сабир үзе дә бу көтелмәгән хәлләрдән югалып калды.

– Бу эш турында, Тимәштә җыелгач, без болай сөйләшмәгән идек, якташлар, валлаһи!

Берәү дә паникага төшәргә җыенмый, бу хәлəттә нәрсәдер эшләргә кирәк икәнен аңлыйлар иде. Галимҗан: бүгенгә бераз суынып, моны онытып торырбыз, ә иртәгә яңабаштан нәрсәдер уйлап табарбыз, дигән тәкъдим кертте.

Зөлфекар башын чайкап куйды:

– Ай-һай, җегетләр, без әфиристләр белән эш итмибез микән?..

Компаньоннар дәшмәде. Көнбатыштан әллә нинди кара, шомлы болытлар чыкты. Йортка терәлеп торган наратлар шатырдашып, җилдә чайкала башлады. Ярты сәгать үткәндерме-юкмы, күкләр гөрселдәде, бик көчле яшен яшьнәде...

***

Табигать маҗаралары һәркемне дә гаҗәпләндерә, кайберәүләрне сокландыра, кайберен өркетә. Галимҗан намазда булмаса да, мондый чакта эченнән генә белгәннәрен укыштыргалый иде. Мәчет тирәсендә булгалап, сәдакаларыннан да өлеш чыгара иде. Бу Мәскәү өстендәге яшенле яңгырның иртәнгә хәтле котыруын да Галимҗан курку катыш дулкынлану белән кабул итте. «Тикмәгә түгел бу, тикмәгә түгел, әстәгъфирулла!» дип пышылдады.

Җилле-давыллы яңгыр таң алдыннан әкрен генә тынычланып, ниһаять, юнәлешен үзгәртте булса кирәк. Шундый хәвефле төн кичергән тимәшлеләр каударланмый гына ихатага чыктылар.

– Карагыз әле наратларны – биргән кирәкләрен – шырпы кебек башларын сындырып чыккан, ә – анасын сатыйм! – дип сүгенде Зөлфекар.

Читтәрәк, урман кырыенда, Галимҗан бер-ике потлы өч күгелҗем таш күреп алды. Аның йөзе балкып, ниндидер серле нурга күмелде:

– Валлаһи, яшен ташы бит бу! Җегетләр, бу яшен ташы гына түгел! Бу безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан күктән иңдерелгән һәдия! Ура-а, хәерчелектән котылабыз, димәк! Ниһаять! Догаларым кабул булды, йә Раббым!

Зөлфекар балта түтәсе белән күгелҗем ташка сугып карады:

– Нишләп күктән төшсен ул?! Кичә иртән ком карьерыннан Николай «КамАЗ»га салып кайткан иде ич аларны. Ком белән бергә төяп, әлбәттә.

Галимҗан вазгыятьне гадиләштерүгә кискен каршы чыкты:

– Җегетләр! Сез ашыкмагыз... Могҗиза ул миңгә бер тапкыр гына була! Нишләп мин әлеге гамәлне безгә Аллаһы үзе иңдерде дип саныйм. М...мин инде берничә төн рәттән гел шул күкнең бүләге турында төшләр күрдем бит! Теләкләр теләдем. Ник ышанмыйсыз, Зөлфекар, Сабир, ә?!

Беркүпмегә сузылган пауза Галимҗанның юлдашы иде. Ул шулхәтле хисләнеп, дулкынланып, ышандырырлык итеп сөйләде ки, хәтта питон кебек салкын канлы тыныч Зөлфекарның да башындагы кепкасы дымланып чыкты. Җитмәсә, Галимҗан Җир шарына иләкләп-чиләкләп ява торган метеор-кометалар турында шактый хәбәрдар икән бит! Серле вә хикмәтле нәрсә. Адәм баласы бу иксез-чиксез күкләрдән иңгән могҗизаны аңлый алырлык халәттә түгел. Космос дигән нәрсәнең дә чиксез, төпсез икәнен күз алдына китерә алмый ул. Галактикада нинди хәрәкәт, нинди кануннар, нинди шартлаулар, аларның Җир-анабыз белән нинди бәйләнешләрдә булуын бер инсан да төгәл генә фаразлый алмый. Без бу якты дөньяга аңсыз туабыз, шул килеш китеп тә барабыз. Җир шулай яратылган ки, аның өстенә йолдызлар яңгыры булып туктаусыз төрле ташлар ява. Шөкер, алар, космос дигән иләк аша иләнеп, безнең башыбызга кар, яңгыр, боз рәвешендә генә төшә. Зөлфекар түзмәде, Галимҗанның йолдызлар турында мавыктыргыч лекциясен өзеп: «Бу бит, дуслар – Коперник, Галилей бит бу!» – дип куйды.

– Фикерне бутамагыз, – диде Галимҗан катгый тавыш белән һәм йолдыз – метеор темасын дәвам итте. – Әле бит космосның явым-төшемнәрен тотып карау да мөмкин түгел, чөнки бик сирәге генә планетабыз белән бәрелешә. Аларның барысы да диярлек атмосферабызга кергәч янып бетә. Биредә тоташ серлелек.

Андый яшен ташларының үзенең базары да оешкан. Мондый метеоритны, килолап түгел, граммлап кына саталар, башлыча интернет аша әмәллиләр.

Сез, якташларым, теләсә нишлисез, ә мин күкнең бу сәламен бик җитди кабул итәм! Би-ик! Хәер, һәркемнең үз юлы... Ышанмасагыз ышанмыйсыз инде... Түлке монда Николай кебек денсезләрне катнаштыра күрмәгез! Бу саваплы эштә һәммәсе бер дөрес тәртиптә булырга тиеш.

– Димәк, бу – безгә тегеннән килгән посылка! – дип, күккә бармагы белән күрсәтеп шаярткан булды Зөлфекар.

– Монда шаяртулар урыны түгел! – дип кырт кисте Сабир.

Дөресен әйткәндә, Галимҗанның ялкынлы чыгышы, ягъни сүз бөртекләре дымлы, уңдырышлы туфракка төште булса кирәк. Алда әле нәрсә булыр, ә менә метеор дигәне – чынбарлык. Ул әнә реаль, лапас астында ята. Аны каккалап та суккалап карарга мөмкин; телисең икән, тешләп кара, күтәреп бак. Кыскасы, Тимәшнең бер абруйлы әгъзасы күкләрнең хәдиясен ифрат җитди вә өметле һәм иң мөһиме – бик вакытлы иңдерелгән дип кабул итте. Өч кешенең берәүсе болай дип саный икән – бу пүчтәк түгел инде, агай-эне…

Авылдашлар шапырынмаска килештеләр. Бу могҗизалы тормышта нәрсәләр генә булмый, шайтан белсен! Күк җисеме темасын өч кешедән гайре беркем бернәрсә белмәскә тиеш. Үз арабыздан бернинди сүз чыкмаска тиеш. Зөлфекар бөтен эшне тәртипкә салырга тәкъдим итте. Николайдан бер-ике яртыга әлеге ташны тулаем сатып алуны да үз өстенә йөкләде. Берәр белгечне табып, фәнни киңәш алу – беренче гамәлләрдән. Әлбәттә, бу җитди эш идея авторы Галимҗанга тапшырылды. Сабирга төзелеш эшләренең очына чыгарга, расчёт ясауны ахырына хәтле җиткезергә куштылар.

Ниһаять, җил-давыллар, яңгырлар узып китте. Мәшәкатьле төн кичергән команда, сөйләшеп туймаганга күрә, үзләре дә сизмәстән, алда нәрсәләр булыр икән, дигән сорауга дулкынланып җавап эзләде. Әгәр дә мәгәр, Галимҗан әйткәннәр рас килеп, затлы ташка тап булсалар... И-их, нинди әкәмәт булыр иде! Авылдашлар бер-беренә дәшмәсәләр дә, күңелләрендә ниндидер татлы мизгелләр, эйфория кичерәләр иде. Әйтерсең лә алар фантастик, хәзергечә әйтсәк, маҗаралы виртуаль әкияти дөньяга килеп эләктеләр.

Ләкин көндәлек тормыш кайчак мантыйксыз борылышлар ясый, берәр мөгез китереп чыгара. Һәм матур гына бизәлеп килгән рәсемгә көтмәгәндә, галәмәт ямьсез кара буяу тама. Җиде ятып, бер тапкыр төшкә дә керми торган нәрсәләр пәйда була...

Зилзиләле яңгырдан соң, кәтиҗ төзелешенә кинәт кырыс йөзле өч ир заты килеп төште.

Баштарак үзен участковый дип таныштырган капитан яңгырлы төндә күрше йортта аяныч җинаять кылынганлыгын әйтте: җитмеш биш яшендәге пенсионерканы вә аның балигъ булмаган оныгын өч ир кочләмәкче булган. Кайдандыр килеп кәтиҗ төзегән, биредә теркәлүсез яшәгән өч маньяк. Адәм актыкларын яшәгән урыннарында, әлбәттә, табалмаганнар. Алар, мөгаен, тиз генә үз якларына сыпыртканнардыр. Ә менә торган урыннарыннан бәдрәфтән гайре беркая чыгып йөрмәгән Казан пенсионерлары, һич көтмәгәндә, кул астындагы капкынга килеп эләкте. Ниндидер билгесез өч адәм актыгы аркасында! Мич башында яткан җиреңнән себер китәсең бит, валлаһи! Җитмәсә, сан ягыннан да, һөнәрләре, төзелештә регистрациясез эшләүләре белән дә полиция Тимәш егетләрен шундук шик астына алды.

– Менә сиңа геморрой! – диде Галимҗан, сызланып.

Зөлфекар әкрен генә:

– Болар бит безне хәзер алып китәргә дә могут... – дип куркуын белдерде.

Капитан, чит телдә сөйләшкән шабашникларның янына ук килеп:

– А вы кто такие? Грузины... Азики? Вроде нет. Татары что ли?! – дип сорады.

Галимҗан «Әйе!» дип башын селекте.

Әлбәттә, үз гомерендә милиция-полиция белән якынрак танышкан абзый-агайлар хакимиятнең бу тармагын нишләптер үз итеп бетермиләр иде. Баксаң, алар кешенең иминлеген криминалдан саклый. Күкрәгеn бандит пулясы астына куя. Берәр нәрсә булса, «Милиция!» дип разбой салабыз, йә «пожар!» дип кычкырабыз! Шулаен шулай да, гражданнарның шомлы күңеленә полициянең якты вә мәрхәмәтле образы никтер үтеп керәлми. Күпсанлы фактлар, погонлы кешеләрнең дорфалыгы, ямьсез вә рәхимсез гамәлләре аркасында полициянең якын арада гына гражданнарның ихтирамын, хөрмәтен яулап алалмас кебек тоела. Юкса, бердәнбер факт – җинаятьчеләрнең сан ягыннан туры килүе, әлбәттә, очраклы хәл дип кенә бәяләнерлек бер версия иде. Ләкин алар бу фактны беркатлы гына бәяләмәскә җыенганнар булса кирәк. Зөлфекар әйтмешли, җинаятьчеләре нинди – тикшерүчеләре дә шул ук бер чамада.

Кәтиҗ төзүчеләрдән көне буе сорау алдылар. Тиздән төзелешкә хуҗа абзый белән прорабны да алып килделәр. Шул яшендә булса да, көчләнә язган Марфа түтәй үз акылында булып чыкты. Турысын әйткәндә, җинаять корбанының чиста кыяфәте, пөхтә киемнәре яңгырлы төндә булып узган фаҗигагә бөтенләй катышы юк кебек иде. Әле башы тәртиптә, кул-аяклары сау-таза!.. Куркудан котлары алынган Тимәш ирләрен Марфа түтәй яшәгән бүлмәгә берәм-берәм дә, өчесен бергә дә алып керделәр. Нинди генә сораулар белән дөмбәсләмәделәр. Берничә сәгать бимазалагач, тикшерүче, ниһаять, өч ирнең икесен «свободны!» дип бүлмәдән чыгарып җибәрде.

– Этих-то ребят я знаю... Они тут уже два месяца. Всё время работают. Им, чай, не до баловства... Нет, энти – ничего худого не делали! – дип искә төшерде зыян күрүче карчык, протезлы аңкауларын чәпелдәтеп. – Вот третьего я толком не приметила... Может он, может кто другой... Внучка приедет завтра – расскажет...

Зөлфекарның бертуктаусыз арзан сигарет тарта-тарта башы тубалга әйләнгән, әледән-әле аркасыннан салкын тир бәрә иде. Ерак Австралияләргә китеп, җәннәт почмагында яшәргә хыялланган татар кешесенең баш өстеннән бер мизгелдә нинди генә караңгы уйлар, явыз кара сәмруглар очып үтмәгәндер. Көннең икенче яртысында, ниһаять, Зөлфекарның туалет белән төзелеш арасындагы шул вакыт эчендә ураган юлын полиция алибига чутлады. Бигрәк тә җирле котлетлардан соң аның активлашуы барсына да билгеле иде. Кыскасы, Казан ир-егетләре өстендә очкан хәтәр кошлардан соң нindidер мәрхәмәтле фәрештәләр дә канат җәйде. Әмма Марфа түтинең һәм оныгының әлегә ачыкланып бетмәгән серле җинаятькә дучар булуы якын арада беркемгә дә җинаять урынын ташлап китмәскә дигән кисәтүгә кул куярга форсат бирде.

– Картлык көнемдә шул гына җитмәгән иде, анасын сатыйм! – дип сүгенде Галимҗан.

Шулай да лапас астында яткан яшен ташлары Галимҗанга нindidер җылы нур, өмет сибеп тора иде. Үзләре генә калгач, Тимәш ирләре яңадан бу әллә Сириустан, әллә Кызлар йолдызлыгыннан килгән сәлам турында эшлекле сөйләшүне кирәк дип таптылар. Бу ләззәтле темага сөйләшү өч геройның да яшәвендә нindidер өмет – мәгънә тудыра иде. Кем белә, бүген тузанлы тулай торакта ярымтоткын рәвешендә яшәгән буш кесәле авылдашлар иртәгә миллионер булып китсә! Тиз арада бу эшләрдә белем-фикере булган кешене табарга кирәк дигән бердәм уйга килделәр...

Табарга тек табарга, ләкин тикшерүче каккан казыкка өч яшьти дә канун арканы белән бәйләнеп, беркая да китә алмыйлар иде. Хет утырып көл, хет үкереп ела...

Ә теге күктән төшкән хәдия серле сандык кебек үз җаена лапас астында ята бирә. Нинди сюрприз анда? Нинди хикмәт? Чын, зиннәтле асылташмы, әллә комлыкта аунап яткан гипслы известнякмы?!

Төзелеп бетмәгән йорт хуҗалары бу шомлы хәлләрдән соң нишләптер бөтенләй күренми башлады. Ә Галимҗан үзләренә килгән галәм сәламе турында бик ышандырып сөйләде.

– Үзегез уйлап карагыз, җегетләр. Без кемнәр? Әйе, без – галахлар, без – язмыш корбаннары. Без – бичаралар. Без – хәерчеләр! Без галактиканы, космосны бөтенләй аңламыйбыз, без – наданнар! Безнең бернәрсәбез дә юк. Без – гади кешеләр... Димәк, барысын күреп-белеп торган Хак Тәгалә безгә шул өмет билгесен юллаган. Калганы безнең эш. Шапырынмыйча, менә бүгенгесе кебек аяныч хәлләргә эләкмичә генә, яшен ташын анализга тиз арада бирергә кирәк.

Зөлфекар белән Сабир якташларын тын алмыйча тыңладылар. Бу галәм, астрономия өлкәсенә якынрак торган таныш-белешләрен барлаштыргаладылар. Һәм Галимҗан, и, ничәнче кат рәхмәт төшкере, башына кулы белән «леп» итеп сугып куйды.

– Бар бит андый кеше, бар! Казан обсерваториясендә эшли!

– Нүжәли?! Кем?!

Галимҗан, озакка сузмый, кайчандыр йолдызлар белән мавыгып, күк җисемнәре белән саташып-җенләнеп йөргән, күрше Сориленде туган Хәмидулланы искә төшерде. Аның чире заманында миңа да эләккән иде, дип өстәп куйды Галимҗан.

– Хуп-мәйле! – диде Зөлфекар, кесәсеннән телефонын чыгарып.

– Бозауламыйк, тизрәк кыланыйк! Безне бөек эшләр көтә!

Якташлар тагын тынып калдылар. Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итә бит!

Кесә телефоны дигән могҗизаны уйлап тапкан кешенең урынын җәннәтләрдә генә насыйп әйләсәң иде, Раббым. Дөньяның теләсә кайсы почмагыннан шалтырата аласың, секундта үзеңә хәбәр килә, гаҗәеп нәрсә! Ходайның рәхмәте, Хәмидулла исән-имин булып чыкты. Теманы да бик тиз эләктереп алды. Ниндирәк адымнар ясарга дигән киңәшләрен җиткерде. Мондый шок вә стресс тудырган вакыйгаларны гади авыл мужиклары бер кабуда гына чәйнәп йоталмадылар, әлбәттә. Шулай да астрономия белгеченең киңәш-күрсәтмәләрен истә тотып, план кордылар. Иң мөһиме – галәмнән кинәт иңгән метеоритлар хакыйкый булсын иде. Бу теләкне Хәмидулла якташларына җиткезергә кушты. Әйдәгез, Аллаһы Раббыбыздан бергәләшеп әнә шул хакта сорыйк...

Калганы Тимәш егетләренә вак-төяк кебек кенә тоела башлады. Күкнең бүләген күзгә ташланмый торганрак җиргә яшереп, күксел брезент белән каплап куйдылар. Экскаваторчы белән бульдозерчы кызыксына калса, аларга андый ташлар һәрьякта тәгәрәп ята, кирәге – бер тиен, кебегерәк буш фразалар әйтеп, башка темага күчәрләр. Метеорит темасын башкага бору вазифасы Зөлфекарда иде... Төзелештәге чүп-чарны нәчәлство кушуы буенча төяп җибәргәннәр, и – бетте китте – маладис! Ком арасында нәрсә генә аунап ятмыйдыр анда?!

Бу яңгырлы төндә әллә кылынган, әллә кылынмаган серле сексуаль җинаятькә Тимәш мишәрләренең бернинди катнашы булмавын полиция, ниһаять, аңлады булса кирәк. Хокук саклаучылар гамәлдә җинаятьчеләргә карата мөмкин кадәр күбрәк факт казып чыгарырга тырышалар». Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленер», «Без капчыкта ятмый» дигән гыйбарәләр Феликс Дзержинскийның «канатлы афоризмнары» белән янәшә торырлык һәм полиция өчен изге кагыйдәләр.

Шулай да, Галимҗан фикеренчә, «Алмагачы»н җырларга йә «Яблочка»ны биергә иртәрәк иде әле.

Шабашниклар дигән ямьсез статуска ия булган өч ир-егет акчасыз, ашамлыксыз Мәскәү астындагы урманда, ристан рәвешендә, язмышның чираттагы сынавын башларыннан кичерергә мәҗбүр иде. Галимҗан, бу уңайдан, изге Коръәннән: «Аллаһы Тәгалә яраткан балаларына җитди сынаулар җибәрер»,

– дигән сүзләрне искә төшерде. Әкрен генә безнең чал чәчле геройларның зиһене ачылды: үз ирекләре белән шабашкага алынганнарның төзелеш эшләренә ни контрактлары, ни хакимият тарафыннан имзаланган рөхсәт кәгазьләре, лицензияләре һ.б. юк иде. Гомерләренең соңгы чигенә килеп терәлгән бу адәми затлар, үзләренең беркатлылыгы аркасында, чыннан да, бик мөшкел хәлдә иде.

Кем әйтмешли, ир-җегетләр начар һәм бик начар арасында эленеп калды. Кайдан акча табарга да ничек яшәргә? Нәрсә эшләргә?

Төнлә кинәт Нургаянның, әллә вөҗданы уянганга, әллә эшкә полиция тотынганга, телефоннан хәбәре килде. «Җегетләр, кайгырмагыз. Мин сезне япа-ялгыз карурманда калдырмам. Чапай думает. Дайте миңа бер көн. Мин всё решу... Җегетләр, потерпите!»

Бу кыска гына смсканы тишек корабта утырган тимәшлеләр коткару көймәсе сыман кабул иттеләр.

– А как же! – дип телгә килде күкләр белән даими элемтәдә торучы Галимҗан. – Безне Хак Тәгалә шундый авыр хәлдә ташламас! Әнә бит, Нургаян: «Җегетләр, чыдагыз, без сезнең белән!» дип яза... Башкалар да шул ук татлы фикер бишегендә тибрәнсәләр дә, вакытыннан алда кычкырган күкене искә төшереп, дәшми калдылар.

Ул арада тимәшлеләр яшәгән бүлмәнең ишеген шакыдылар. Тагын нинди сюрприз икән, дип пошаманга калган фатирантлар аптырашып бер-беренә карады. Ачтылар. Бусагада тешсез Марфа әби һәм аның кырында һушны алырлык чибәркәй, зәңгәр күзле, кызыл калфак кигән илаһи бер зат басып тора иде. Бу манзара ир-егетләрне аптырашта калдырды. Контрастлы ханымнар исәнләшеп, кереш сүзне кыска тоттылар. «Көчләнгән» әби дәшми генә оныгының сөйләгәнен тыңлап утырды. Ара-тирә башы белән ымлап, «Вот именно», «А как же» дигән ымлыклар белән матур оныгының хикәятен раслап торды.

Кыскасы, Марфа әби бөтенләй көчләнмәгән икән. Шул ук хикмәтле яңгырлы төндә әбинең оныгы мәктәптән өйгә соңрак кайткан. Ә аннан соң әнисе белән әбисенә өч ир миңа бәйләнделәр, каядыр алып китә яздылар, шуңа тоткарландым дигән версияне сөйләгән. Кызның кычкырганын ишеткән кешеләр, янәсе, ярдәмгә килгәннәр.

– Бу вакыйгага безнең нинди катнашыбыз бар? – дигән сорауга әби белән онык беркүпме дәшми тордылар. Аннары онык беренче булып телгә килде:

– Ну что вы, как невзрослые дяди. Вы не понимаете о чём речь?! Попытка к изнасилованию несовершеннолетней. Статья...

Зөлфекар түзмәде:

– Дәлилләр кая?

Чибәр кыз, бер дә уйлап тормый:

– Алар урысча сөйләшмәделәр. То ли узбеки, то ли татары были...

– Вәт, менә бу ичмасам аргумент! – дип көлде Галимҗан. – Это всего лишь сказки про белого бычка! Читали такую?

Эшнең төбен сизеп алган Сабир, дусларына карап:

– Болары да бездән акча саварга килгәннәр... – диде.

– Заявите в полицию! – диде Галимҗан. – Раз такое дело...

Кызый чыгып китәргә дип тора:

– Я думала, что мы договоримся. Вам, конечно, это дороговато станет...

Тимәшлеләр нишләргә белми басып калдылар.

Зөлфекар araларны бөтенләйгә бозарга теләми:

– Урманда йөргән һәр кешене төрмәгә утырталармы? Ә без монда ике айдан артык яшибез, ләкин бер дә урманга барганыбыз юк. Вакытыбыз тар, эшебез кызу... Бәдрәфкә дә йөрергә онытабыз... Кайчак... Так что, поймите нас. Нам по лесам ходить, соснами любоваться – невдосуг, – диде.

Әби белән онык китеп бардылар. Ләкин тимәшлеләрнең кәефләре тәмам кырылган иде.

– Бу нинди әкәмәт?! Нәрсә эшлибез, егетләр? – диде бөтенләй кәефе төшкән Галимҗан.

– Уңга-сулга сибәрлек акчаң булса иде ичмасам! – диде Сабир, гарьләнеп.

Зөлфекар заманананы сүкте. Янәсе, барысына да акча кирәк: анасына, баласына, әбисенә, сәбисенә... Черек ил! Сплошной разврат!..

Шулай итеп, көчле яңгырдан соң тагын ике көн узып китте. Тимәш бригадасы билгесезлектән, эшсезлектән интеккәнгә, бер-берсе белән юк-бар мәсьәлә буенча низагка да кергәләделәр. Рухи төшенкелек аркасында, карап торырга дустанә якташлар, күкерт кебек капылт кабынып китә башладылар. Галимҗан, сабыр төбе – сары алтын, дип, якташлар арасындагы киеренкелекне күп очракта йомшартырга тырышты.

Ләкин вакыт уза торды, ни төзелештә, ни полиция ягыннан, ни метеорит мәсьәләсендә бернинди гамәли үзгәрешләр сизелмәде.

Хәер, сүзендә тимердәй нык торучы Нургаян, берәр атна узгач, офыкта янә пәйда булды. Ул тимәшлеләрнең моң-зарын озак тыңлап тормады:

– Җегетләр, хәлләр шәптән түгел. Шеф бөтенесен ташлап каядыр Кипрга ычкынган. Аны эзлиләр. Кәтиҗ арестован... Акча тю-тю! Мин сезгә юлыгызга берсәк акча таптым... Ычкыналсагыз моннан – ычкыныгыз... Полицайлар сезне болай гына җибәрмәс... Мондый хәлләрне зур акча гына решать итә... Үзегез дә аңлыйсыз!

Нургаянның теле шактый чишелгән иде. Ул халыкара темаларга, илдәге коррупциягә тукталды. Влачны сүкте. Һәрхәлдә тимәшлеләр Нургаянның махмырлы авызыннан бер генә өметле сүз дә ишетмәделәр. Ләкин маҗаралы урманда утырудан гарык булган, кыргыйлаша башлаган адәмнәр биредә калуны да берничек тә теләмиләр иде.

Галимҗан, Нургаяны тыңлап, бригаданың бердәм теләген җиткерде.

– Нургаян дус, син сөйләгән сүзләр безне бик борчый. Без монда ике ай вакытыбызны салдык, күпме көч куеп, йортны күтәрдек. Нәтиҗәдә, шыр хәерче булып кайтып китәргә мәҗбүрбез. Безнең кечкенә үтенечебез бар: инструментларны вокзалга илтергә берәр машина тапсаң иде. Калганнарын хуҗа абзый табылгач сөйләшергә туры килер инде. Монда маҗаралар көтеп утыруның бернинди мәгънәсе юк, билләһи газыйм!

Шул ук кичне Нургаян, беркая да китмәскә дигән күрсәтмәне үз белдеге белән гамәлдән чыгарып, капитализм төзүчеләрне вокзалга Казан поездына илтте. Әлеге вазгыятьтә монысы да тимәшлеләр өчен бик зур ярдәм иде. Ул-бу була калса, без – сине, син безне күрмәдең, дип җавап тотарга килештеләр. Иң мөһиме – утызар килолы өч кисәк метеоритны поезд кондукторына сиздерми генә вагонга кертеп куйдылар. Монда мишәр факторы ярдәм итте. Мәгълүм ки, Казан вокзалында гомер-гомергә мишәр-татарлар хакимлек итә. Ә йөк ташучылар вокзалдагы бөтен ишек-тишекне, кем әйтмешли, һәр этне белә. Аларның берсе проводникны сөйләштереп торган арада, Галимҗан командасы күкләр һәдиясен чит күзләр күрмәслек итеп иплә кенә урнаштырып та куйды.

Поезд туган якка кузгалып киткәч, Зөлфекар түзмәде, әкрен генә такмак әйтә башлады:

Мәскәү – Казан арасы,
Унбиш сәгать барасы.
Әзрәк кенә саласы,
Печтик ашап аласы,
Бераз йоклап аласы.

Ике шәһәр арасында
Йөри татар баласы.
Мәскәү алып киткәнне
Бик тели кайтарасы.
Шактый күп җыелган икән

Ала каргадан аласы.
Матур татарның каласы,
Көчле Мәскәү каласы.
Шуңа Мәскәү ике куллап
Тоткан татар якасын.

***

Галимҗан соңгы көннәрдәге җанкыйнау аркасында хәтта поезд тәгәрмәчләре текелдәвенә дә йоклый алмады. Йокларсың монда: «кругом шестнадцать». Мәскәүләр шымытыр тоттырып җибәрделәр. Метеорит белән дә эшләр суга сәнәк белән язган кебек – эзе бар, ә гамәле юк. Һаман бер урында таптанабыз. Ходаем, асылташ кына без теләгәнчә булып чыксын иде инде... Әйе, без барчабыз да бу яшен ташына инанып, аңа дәү өметләр баглыйбыз. Монда Галимҗанның җилкәсендә зур мәсьүлият ята. Үзе дә инанды, якташларның да башын борды. Әгәр дә метеорит дигәнең юк кына бер чуерташ кисәге – биш тиенлек чичикай кебек нәрсә булып чыкса?.. Юк, Галимҗанның әлеге караңгы фараз уена да керергә тиеш түгел! Ул ахыргача бер фикердә торачак. Алла боерса, безнеңчә булыр! Асылташ!

Тимәшлеләр исән-имин Казанга кайтып төштеләр. Астроном Хәмидулла, бер миллионлы Казанда метеоритлар турында хәбәрдар булган бедәнбер белгеч иде. Аның күк җисемнәре хакында белеме дә, иң мөһиме – бу өлкәдә үзенең дус-ишләре, корпоротив элемтәләре дә байтак иде.

Казан – зур шәһәр, ләкин берәр кызыклы хәбәр булса, ул рәсми каналлар буенча да, сарафан радиосы аша да кирәкле вә кирәкмәгән колакларга бик тиз барып ирешә. Тимәшлеләр кайтып берничә көн ял итәргә өлгермәделәр, кайбер гәҗитләрдә, интернет сайтларда Казан геологик экспедициясе Мәскәү астындагы бер авылда бик зиннәтле метеоритка тап булган дигән сенсация таралды. Әлбәттә, мондый эштә шау-шу бер дә кирәкмәгән нәрсә иде. Һәрхәлдә моны Галимҗан бөтенләй көтмәгән иде. Шуңа да бер уч валидол эчеп, Хәмидуллага шалтыратырга җөрьәт итте.

– Агай-эне Хәмидулла, монда безнең хакта галәмәт тузга язмаган хәбәрләр йөри башлады... Сезнең тирәдән чыккан сүз түгелдер бит?!

Галим кеше бу эшләрдән хәбәрдар иде.

– Юк, Галимҗан ахири, шту син! Моны соң үз арагыздан берәрсе ычкындырмады микән?

– Безнекеләр арасында андыйлар булмас...

Хәмидулла тирән сулап куйды:

– Безнең халык мактанырга ярата инде ул. Бигрәк тә теленә бераз шайтан суы да эләксә... Дустынамы, хатынынамы, күршесенәме – аннары русча әйтәм: далее везде со всеми остановками. Син артык борчылма, Галимҗан якташ: әле бит ташны өйрәнәсе, аңа исем кушасы бар... Болар беркөнлек кенә эш түгел. Менә аннан соң пьесаның иң кызык өлеше башлана. Ә бүген әле борчылырга да, нәтиҗә ясарга да иртәрәк, Галимҗан әфәнде!..

Ләкин Галимҗан андый битараф, тыныч кеше булып тумаган шул. Әле бит күктәге айның Хәмидулла белмәгән икенче ягы да бар. Мәскәүдән рөхсәтсез кайтып китүләр. Андагы полициянең дәгъвалары... Ә җир җимертеп эзләтә башласалар? Һәр чатта: «Игътибар, полиция эзли!» – дигән игъланнар белән фоторәсемнәрен чәпәп куйсалар?.. Менә нинди мәрәкә! Картлык көнеңдә! Мондый вазгыятьтә елганың иң тирән урынына кереп төпкә ятарга һәм бераз көтәргә кирәк! Борчылудан кан басымы шактый күтәрелгән Галимҗан түзмәде, Зөлфекар белән Сабирга шалтыратты: «Җегетләр, кичектермичә гәпләшеп алырга кирәк!» Ял паркында очрашырга килештеләр.

Галимҗан кан басымын уйнаклатып торткан уй-фикерләре белән ачыктан-ачык уртаклашты. Сабир якташының хәленә керебрәк сөйләшсә, Зөлфекар,

киресенчә, сез ситуацияне катлауландырасыз, бер дә юкка паникага биреләсез, алай ярамый дигәнрәк мәгънәдә сукалады. Сабирның кайчандыр курсташы булган, ә хәзер прокуратурада эшләгән Зиннәт дигән дусты бар икән. Һич булмаса аның белән киңәшеп алуны кирәк дип таптылар. Күп белүче, күп күрүче журналистлардан котылу юллары шәйләнмәсә дә, Галимҗан Тимәштә туган Гали бабайның оныгын – Алтанны эзләп карарга вәгъдә бирде. «Каны тартмаса, бәлкем, җаны тартадыр...» Зөлфекарның паникага бирелмәскә дигән кисәтүе дә урынлы, дип, якташлар таралыштылар.

***

Хәмидулла атна-ун көн эчендә метеоритның моңарчы рәсми исемлекләрдә теркәлмәвен ачыклады. Димәк, Тимәш делитантларына метеорит базарында аны ваклап-күпләп сату хыялы белән хушлашырга туры килә. Дөньяда андый мисаллар байтак. Хәмидулла, иманлы кеше, вөҗданлы галим буларак, бу ачы хакыйкатьне берничек тә яшереп калалмый. Тормышка җиңелчәрәк баккан яшьрәк галимнәр бу эшләрне шухыр-мухыр китергәлиләр. Кайчакта әҗерен дә күрәләр. Имештер, көч түгәләр. Ут белән уйныйлар, кәнишне. Күптән түгел Хәмидулланың бер шәкерте, карап торырга акыллы гына егет, Рафис та, шундыйрак уеннарда катнашып, җылы урынын югалта язган иде. Соңрак дусишләр аркылы ниндидер шәхси лабораториядә җайлы эш тапкан, диләр. Хыялый Тимәш пенсионерларына ничек булса да турысын әйтмичә ярамый. Гәрчә гомер буе акча кытлыгыннан интеккән кешеләрнең соңарып булса да тутый кошны эләктерергә хыялланып йөрүен дә аңлап була. Тик ник соң мондый күңелсез хәбәрне алар нәкъ менә Хәмидулла авызыннан ишетергә тиеш?!

Хәер, соңгы арада вакыйгалар бераз кирегә китә башлады кебек. Галимҗан нишләптер Хәмидуллага шалтыратмый хәзер. Ә бит моңа хәтле көненә берничә кат шалтырата иде. Моның сәбәбе дә тиз арада ачыкланды. Бу мөнәсәбәтнең кинәт үзгәрүе астрономның беренче нәтиҗәләре белән бәйле икән. Галимҗан һәм аның иярченнәре Хәмидулланың беренче прогнозын ишеткәч, «буш куык» галимне башкага – булдыклырак белгечкә алыштырырга булганнар. Эшлекле белгеч Хәмидулланың шәкерте Рафис булып чыккан. «Менә кайда икән чикләвек!» Ташның беренче анализларын ниндидер юллар белән кулга төшергән әрсез белгеч тимәшлеләргә бөтенесен эшләп бирергә вәгъдә кылган.

«Алай булса, эшләсеннәр Рафис белән! – дип тынычландырды үзен Хәмидулла. – Ә мин бу китапны ябып куям һәм әлеге гоп-компаниядән ераграк торам...»

Прокурор белән журналист икесе ике буын кешеләре булып чыкты. Хокук саклаучы, тәҗрибәле, дөньяны күргән-белгән кеше буларак, Тимәш пенсионерларын җентекләп тыңлап: «Дөресен әйткәндә, мин андый авантюралардан ерак торыр идем... Әле ул метеоритның тоннасы бер тиен тора торган нәрсә булып чыкса?.. Җитмәсә, Мәскәү астындагы полициянең җинаять эшен ябуы-япмавы да билгесез. Ул фактор да чуваш апарасы кебек калкып чыкса, нишләрсез?»

Зиннәтнең сүзләрен ишеткәч, Галимҗанның кан басымы күтәрелде.

– Менә мин дә бит сезнең белән килешәм, иптәш прокурор. Тутый кош әлегә кулыбызда түгел бит. Тегендә безне болай печтеләр, монда болай сөйлиләр. Кемне тыңларга белмәссең, валлаһи! Сез, безне ташламагыз инде... Без Сабир классташыгыз белән дә килешкән идек. Әйе, без аңлыйбыз, сезнең хезмәт тә бәяләнергә тиеш... Математикада, кем әйтмешли, тапкырлау гына түгел, бүлү дә бар. Яхшы килеп чыкса, Алла боерса, бүлешербез, барыбызга да җитәр...

Зиннәт, уң кулын алга сузып, Галимҗанны кырт туктатты:

– Шту сез, шту!

Бер минут та узмады, хокукчы абзый тиз генә машинасына утырып китеп тә барды. Әлбәттә, шулхәтле халык алдында ришвәт турында ачыктан-ачык сүз куертырга ярыймы соң инде! Ул бит чит-ят күзләргә чалынмый торган яшертен гамәл!

Ә журналист Алтан Бату белән сөйләшү бөтенләй башкача килеп чыкты. Прокурордан аермалы буларак, Алтан бер-ике җөмләдән соң ук вазгыятьне бик тиз ачып салды:

– Җегетләр, сез моның маркетинг ягын яхшылап санадыгызмы? Бу кәҗә белән сарык әкиятендәге кебек булмасын! Монысын, агайлар, мин үз өстемә алам... Каршы килмәсәгез, әлбәттә... Чөнки минем астрономия лабораториясендә белгән кешем бар. Дустым бар дисәң дә була!..

Дөресен әйткәндә, Батуның ни дәрәҗәдә талантлы журналист икәнен гади пенсионерлар аңларга әзер түгел иде. Алар гәҗит-журнал укымыйлар, укысалар да ышанмыйлар иде. Чөнки матбугатны даими карап баручы, тормыш, ягъни чынбарлыкны белгән, чагыштырырга сәләтле булган укучыны хәзер шәм яндырып эзләргә кирәк. Алтан Бату шәһәр гәҗитенең криминал хроника бүлегендә ара-тирә мәкаләләр язуын язгалый иде. Полиция протоколын гади укучы аңларлык хәлгә җиткерү мөмкин булмаганга, Алтан кебек каләм ияләре йә полиция хезмәткәрләреннән, йә таныш-белешләрдән ишетеп, ешрак үз фантазияләрен эшкә җигеп, кимендә атнага бер тапкыр ике битлек текст яза. Ә асылда берсеннән берсе күчереп алалар. Әрсезлек мәсьәләсенә килгәндә, Батуның салым инспекциясе белмәгән оттырышсыз керемнәре дә булып тора иде. Мәгълүм ки, һәр түрә хакында язып була. Йә мактап – очерк, йә хурлап – фельетон. Хәзер Бату кебекләр икесеннән дә акча каералар икән.

Кыскасы, кайдандыр яшен ташын сөйрәп кайткан якташларын Бату бик оста гына тынычландырды һәм вакыйгаларның кыл уртасында үз урынын эләктереп алды. Галимҗан үзенең үт куыгы белән сизенә иде, мондый әрсез усал, мәнфәгатьле кеше ярты юлда туктап калмас. Әлегә хәтле Аллаһы Тәгалә тимәшлеләрнең теләк-рәхмәтләрен ишетеп ярдәм кылып килде. Әлеге эшнең башында кайнаган, сәламәтлеген югалта язган, аңа эчкерсез инанган инсан буларак, Галимҗан да туктап артка чигенмәячәк. Әлбәттә, үзен ул мондый иблис командасында вә уеннарында күрми. Тик Бату бу эшкә катнашуы белән шайтанны чакырды, дип уйлады күкләр белән даими элемтәдә торган Галимҗан.

– Күз күрер, моңарчы ярдәм иткәнне Раббымыз ташламас, – дип тынычландырды үзен марфлут.

Ләкин Мәскәү өлкәсендәге хезмәткәрләр тимәшлеләрнең эшен игътибар белән күзәтеп торалар икән. Бигрәк тә гәҗитләр, телевидение метеорит турында уйдырма артыннан уйдырма тарата башлагач. Полиция, рәхмәт төшкере, Нургаянны һәм аның карун хуҗасын каты гына кысып, Казан пенсионерларына тиешле хәләл акчаларын түләттергәннәр! Кем уйлаган, полициядә реформалар шундый уңай якка борылыр дип. Хәер, биредә сүз реформаларга бик кагылмый, ә күктән бушлай төшкән метеорит турында бара. Тикшерүчеләргә әнә шул күк җисеменә бәйләнгән җепләрне капшап, вазгыятьне контрольдә тоту кирәк иде. Озак та үтми акча казана башлаган Казан астрономнарына җирле полиция да игътибар итте. Кыскасы, белгечләр, экспертлар полиция башлыгының бүлмәсенә җыелдылар. Бер караганда, эчке эшләр күзәтүенең әлеге мәсьәләгә тыкшынуын иртәрәк кенә түгел, урынсыз дип бәяләргә мөмкин иде. Шуңа да сөйләшү дустанә, ихтирамлы рәвештә барды. Алар күбрәк белгечләрне тыңладылар.

– Баштарак без сезне рөхсәтсез китеп баруыгыз өчен җәзага тартмакчы

## АНА ТЕЛЕ СҮЗЛЕГЕ

**Нинди сүзләр кулланусыз
Черем итеп яталар!
Безнеке булса да, безгә
Әйтерсең лә ят алар.
Монда муллык. Сүз китабы –
Бер могҗиза, күрегез!
...Фәкыйрьлектә изалана
Сөйләшү сүзлегебез.
Ни сырхауга дучар иттек
Халкыбызның хәтерен?
Белми татар урамнары
Дәрдемәнд, Тукай телен.
Сикәлтәле юллардамы
Бушап калган йөгебез?
Ике телдә сөйләшсәк тә,
Чында ярты телле без.
Бытылдыйбыз, үзебезне
Белгән кебек хис итеп,
Татарны да мәсхәрәләп,
Урысны да кимсетеп.
Көннәр буе гарип телдә
Аралашабыз бүген;
Төн буе йотлыгып укыйм
Ана телем сүзлеген...**

**Ирек САБИРОВ**

идек! – дип башлады Мәскәү вәкиле... – Закон нигезендә. Тик сезнең икенче эшегездә, ягъни астрономия өлкәсендәге уңышларыгызның җәмгыяви ягын белгәч тукталып калдык... Ә нигә безгә бергәләп эшләмәскә? Ил өчен, халык өчен. Канун кысаларында, әлбәттә...

Тимәшлеләр дәшми утырдылар. Чыгышта төп нотыкны үзен эксперт итеп таныткан Хәмидулланың шәкерте Рафис ясады. Монда ботканы пешерә башлаучы тимәшлеләргә кайбер кызыклы яңалыклар да мәгълүм булды. Бу метеорит тимер катыш таштан гыйбарәт икән. Дөнья базарында аңа бөтенләй кызыксыну юк дияргә була. Һәрхәлдә бүген. Эчке базарда, бәлкем, тора-бара күренер. Тик аны ваклап сату өчен лицензияләр, дистәләгән анализлар ясарга кирәк әле. Бу шактый чыгымнар таләп итә. Әлбәттә, без сезнең ярдәмегез белән эшләрне тизләтә алабыз. Ләкин күпкә түгел...

Бу экспертлар шурасын җыюны журналист Батудан башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел иде.

Аның ялкынлы, патриотик чыгыш ясавы залдагыларны уятып, дәртләндереп җибәрде: «Илдә барган үзгәрешләрне тизләтергә, яшь буынны тәрбияләүгә яңа сулыш өрергә. Ришвәтчелек, коррупция белән аяусыз көрәшергә. Ә полициянең безнең эштә катнашып китүен мин уңай дип бәяләр идем, әфәнделәр! Сез дә тыныч, без дә тыныч йокларбыз... Әлбәттә, без сезнең хакимият башлыгына да кайнар сәламнәребезне, рәхмәтләребезне җиткерәбез!..»

Бу сүзләрдә ялагайлык ярылып ятса да, алдан рәсми кешеләр, аннары гадиләре дә ерактагы губернаторга адреслап кул чаптылар.

Галимҗан, Сабир, Зөлфекар өйләренә җәяү генә кайтырга булдылар. Дөресен әйткәндә, аларның кәефләре төшенке иде.

Галимҗан, уфтанып:

– Шәхсән, мин бу компания белән эшләмәү ягында! – дип кырт кисте.

Сабир, булганына шөкер, дигәндәй дәшми торды. Ә Зөлфекар югарыда, фәлсәфи биеклекләрдә йөзә иде.

– Җегетләр, без картаябыз бугай. Әнә мәйданга нинди шустрый әтәчләр чыга хәзер, күрдегезме?! Галимҗан парктагы буш эскәмияне шәйләп алды:

– Әйдәгез, утырып алыйк әле, дуслар! Никтер соңгы арада йөрәк топкалый башлады...

– Булыр, булыр, мондый хәлләрдән соң! – диде Зөлфекар моңсу гына.

– Зөлфекар, ничек соң анда Аделаида?

– Бер әптәй белән хәбәрләшеп торабыз, нәрсә булыр...

Сабир, хәбәрдар икәнен күрсәтеп:

– Ике ел элек кайтып та киткән иде бит!

– Казангамы?

Галимҗан, якташы өчен сөенеп:

– Менә бит кеше өйләнергә җыена, маладис син, Зөлфекар! Картаймыйсың! Димәк, егәрең, потенциал бар. Хуп, мәйле! – дип, аркасына дусларча какты.

Галимҗан шуннан соң сүзне бераз башка якка борды.

– Дуслар, бу илдә бәхеткә туенып булмас ахрысы... Күктән иңгән малның да рәхәтен күреп булмый. Метеорит дигәнебез әкрен генә безнең кулдан китә кебек. Ераккарак шуыша... Үткен күзле карчыгалар күзәтеп торалар... Һәр адымны. Ә лицензияләр, сертификатлар алу бездә арыслан авызыннан сөяк тартып алу белән бер. Ул арада безгә тау башындагы зиратка...

Зөлфекар түзмәде, Галимҗанны кинәт туктатты:

– Юк, братлар, картлык, әҗәл турында сөйләшмибез! Минем мондый фикерем бар: без метеор белән хата ясадык. Аның бер өлешен үзебезгә кысып калырга иде, шым гына, мыштым гына. Аннары берәр җае чыккач, чит илгә суытырга иде.

– Һай, хитри-митри! Син, Зөлфекар, бездәге таможняны белмисең ахрысы. Алар бөтен тишек-тошыкларны актарып, кирәкмәгән нәрсәне һәрвакыт табалар. Чыгарырсың! Шиш! Ышан миңа: менә бу чәчләрне алар агартты, агай-эне! Мин яхшы беләм, күпме кеше алар аркасында зинданнарда утыра. Ә менә теге яшь этәчләр җаен табарлар... Аларның башы хәзер бик хәтәр эшли.

Әңгәмәне Галимҗан дәвам итте:

– Вәт хәлләр, дускайлар. Яши идек хәерчеләр кебек. Берни белмичә. Ә хәзер күңелгә кереп утырды теге метеор дигән нәрсә. Ни алга, ни артка җибәрми! Нишләргә белмисең!

Әллә күптән күрешмәгәнгә, әллә сөйләшеп туймаганга, якташлар аерылырга теләмәделәр. Һәрберсе, әйтерсең, ачык микрофонга нәрсәдер бик мөһим, үзен борчыганны әйтеп калырга тели иде. Бу юлы якташлар вак-төяк нәрсә турында түгел, милләт, тел, халык турында сүз куерттылар. Тагын тавыш бирмичә сайланган әйдаман Галимҗан телгә килде:

– Бер акыллы кеше әйткәндәй, бездә тавыш күп, ыгы-зыгы – дачурта, ә файдалы гамәл бик аз. Менә безнең таныш-белешләрне генә алыйк. Кайда булса да очрашса, төпченә, казына, аннары киңәш бирә башлый. Игътибар иткәнегез бардыр: безнең халык акыл сатарга ярата. Менә фәләнне эшләргә кирәк, тегесен башкарырга кирәк... Безнең татар кешесе – почтальон рәвешендәрәк. Кайсы кеше гомер буе «кирәк» дигән капчыкларын таратып йөри. Ул капчыклар – проблемалар белән тулы. Шул шөгыльне башкару, ягъни «кирәкне» кемнәргәдер элеп калдыру – безнең татарның иң яраткан төп эше. Ул кирәк капчыгын асып китә дә, үзе тынычланып, кафега кереп йә йөз грамм шайтан суын чиртә, йә сөяркәсе янына барып йоклый. Шуның белән эш бетә дип уйлый.

Зөлфекар да татарны тәнкыйтьләүгә өлешен кертте:

– Кирәк дип йөрүчеләр күп, ә менә гамәлдә җигелеп эшкә керешү, нәрсәне ничек эшләп күрсәтүче сирәк. Тагын безне артка сөйри торган бер ямьсез гадәт бар. Без – мактанчык халык. Минем үземдә дә бар ул чир.

Сүз остасы булмаса да, ирекле микрофон алдында Сабир да милләтнең кимчелекләрен бетерү турында яныпкөеп йөрүен раслады. Әйтергә кирәк, гади генә эшмәкәр килеш тә ул бик укымышлы кеше булып чыкты. Сабирның сүзләренә караганда, бездә күп саннар хикмәтле, еш кына аларга ышанырга да мөмкин түгел. Җитмәсә, шул ялган статистикага, сәясәтчеләрнең мактанчык чыгышларына таянып, бер төркем Мәскәү политтехнологлары, имиджмейкерлары, экспертлары, пиарщиклары Казанның ясалма, чынбарлыкка туры килмәгән, кыйшайтылган образын тудырырга тырышалар. Бу татар халкы өчен бөтенләй ят образ, килешмәгән брендлардан арынсак, без яхшы гына алга китәр идек...

Милләтен яраткан, аның алдынгы, акыллы, белемле булып үсүен күрергә теләгән гади тимәшлеләр, ни күрсәк тә бергә булыйк, дип аерылыша башладылар.

– Җегетләр, минем бүген яраткан оныгым кайта. Иртәгә аңа уналты яшь тула. Бәлкем, кич утырырбыз. Чакырам.

Зөлфекар бу тәкъдимне шундук күтәреп алды:

– Минем күптән гармун уйнаганым юк. Рәхәтләнеп бер җырларбыз.

Шулай итеп, якташлар Галимҗанның дачасында җыелырга булдылар.

– Бер күрешү – үзе бер гомер! – дип нокта куйды Зөлфекар.

Адәм баласы ниятли, планнар кора, хәстәрен күрә, ә Ходай Тәгалә бар нәрсәне үзенчә башкара.

Галимҗан белән оныгы Солтан якташлар, дуслар, туганнар җыенына кичтән үк әзерләнә башлады. Әле вакыт бар – кибетләр эшли. Дачага – электричка белән өч тукталыш. Кичен бабай белән малай төрек дөнәрендә шашлык ясарга дип

ит әзерләп куйдылар. Анысын да бабасы заманында Истанбулдан өйрәнеп кайткан иде. Татарда бит чит илләргә барып гыйбрәт ал дигән акыллы әйтем бар. Галимҗан аны кайчандыр оныгына да өйрәткән иде. Дөнәрдә пешкән итне ашап туялмаслык. Юкка гына таныш бакчачылар ул ризыкны «Галимҗан дөнәре» дип атамыйлар.

Төнлә, көтмәгәндә, көчле яңгыр ява башлады. Дөньяны дер селкетеп күк күкри, яшен яшьни.

Диванда «бисмилла»сын әйтеп утырган дәү әтисе кинәт «Һай!» дип җанөзгеч тавыш белән кычкырды. Солтан шундук бабасына ташланды:

– Бабай! Дәү әти! Нәрсә булды?! Ләкин дәү әтисе берни дә дәшмәде, куллары салкын иде. Үсмер югалып калмады. «Ашыгыч ярдәм» чакыртты. Өйдә башка кеше юк иде.

Солтан үзе белгәнчә массажлар да ясап карады. Ләкин Галимҗанның җанөзгеч авазы, күрәсең, бу якты дөнья белән бөтенләйгә хушлашуы булгандыр. Һәрхәлдә «Ашыгыч ярдәм» табиблары моны раслады.

Чал чәчле доктор мәетне тагын бер кат карагач, әкрен генә әйтеп куйды:

– Йөрәк... – Солтанга борылып: – дәү әтиегезнең йөрәге авырта идеме?

– Соңгы вакытта даруларны учлап эчә иде! – дип җавап бирде Солтан. – Эх, дәү әти, дәү әти! Үсмер онык чыдый алмады – үксеп елап җибәрде. Табиблар Солтанны тынычландырырга тырыштылар, ниндидер таблеткалар бирделәр.

Бу көтелмәгән әҗәл турындагы хәбәр шундый ук көтелмәгән тизлек белән бөтен таныш-белешләргә, туган-тумачаларга таралды. Галимҗан кебек гади кешенең бу дөньядан китеп баруы гадәттән тыш хәл дип бәяләнмәде, әлбәттә. Күктәге кәнсәләрия төгәл эшли: кешеләрнең берсен ала, берсен китерә. Бу – котылгысыз кагыйдә, һәм ул һәркемгә дә кагыла – патшаларга да, сукбайларга да. Ниндидер гәҗит кенә Галимҗанны һәвәскәр астроном, зиннәтле метеор тапкан кеше дип язып чыккан иде.

Полиция, махсус комиссия оештырып, Галимҗанның дачасында тикшерү уздырды. Мәгълүм ки, безнең мәмләкәттә комиссияләр оештыру – бик мөһим гамәл, ләкин аның нәтиҗәләре күпләргә мәгълүм түгел. Чөнки түрәләр шул күпләрнең иминлеге, сәламәтлеге хакында борчыла. Кем әйтмешли, белмәгәннең беләге авыртмый.

Бу үлем-китемдә, гомумән, метеорит белән бәйле әлеге тарихта, Хәмидулланың мәгълүматы һәм белеме бик урынлы булып чыкты. Менә шул абруйлы кеше әйтүенчә, дачада кавын зурлык, күктән төшкән яшен ташы табылган. Иң мөһиме – аны беренчеләрдән булып Галимҗанның оныгы Солтан тапкан. Кирәк бит! Тәүге тикшеренүләр күрсәткәнчә, дөньяда бу иң затлы ташларның берсе икән. Аның бәһасен кычкырып әйтергә дә ярамый. Хәер, бу инде башка маҗаралы вакыйганың дәвамы. Ә безнең тарихка килгәндә, Хәмидулла әфәнде, мәрхүм Галимҗан тапкан ташларны төптән, тагын бер кат тикшереп, аларның бернинди кыйммәткә ия булмавын раслады.

Серле, могҗизалы дөнья бу... Ә йолдызлар, галәм, метеоритлар белән Галимҗан кебек мавыккан кешеләр, һичшиксез, бу җиһанның бер табышмагы...

Мәскәү астыннан мәшәкатьләнеп алып кайткан ташларны якташлары Галимҗанның каберенә куярга булды. Кыска гына матәм чыгышында Зөлфекар сагышлы тавышы белән болай диде:

– Торсыннар, зират өстендә һәйкәл булып! Безнең өчен алар нинди генә асылташ әле! Башкалар да күрсен! Аяк астына гына карап йөрергә гадәтләнгән халык бу дөньяда галәм дигән серле бер могҗиза барын искә алыр. Моның өчен генә дә без дустыбыз Галимҗанга мәңге рәхмәтле...



Ирек
Сабиров

# ЯШӘСЕН ИДЕ ХАЛКЫМ...

## Без киткәч...

Әле дә моңлы һәр көнебез һаман –
Без әлегә исән, карагыз!
Узып бара безнең җырлы заман,
Үзебез дә китеп барабыз.
Без – шигърият сөйгән соңгы буын.
Әйтче, айфон тоткан яшь иптәш:
Кырлай болыннарын, Ашыт суын
Кемнәр җырга салыр без киткәч?
Мәгърур Тукай! Узса да шул гомрең
Ятимлектә, ачлык-салкында,
Аз булса да, яшәп өлгергәнсең
Милләтемнең таза чагында.
Сине ятлап яшәсәк тә әле,
Ерагая инде арабыз:
Безнең дә бит узып бара заман,
Үзебез дә китеп барабыз...

## Теләк

Әлмисактан янәшәдә яшәп,
Чыдап уртак кайгы-сагышка,
Бер-берсенең китапларын укып
Килгән ике халык ызгыша.
Беркем өстен, һичкем түбән түгел,
Беркем түгел кол йә падишаһ;
Борынгыдан бергә иген игеп
Килгән ике халык сугыша.
Мин аларга (ишетсәләр иде!)
Әйтәсемнәр килә ачынып:
Нәрсә җитә Җирдә шат яшәүгә,
Бер-береңә ихлас ачылып!

---

Ирек САБИРОВ (1950) – *шагыйрь; «Манзара», «Аваз», «Апрель» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск (Яман Елга) шәһәрендә яши.*

Дуслар! Яңа тормыш төзибез, дип,
Элеккесен нигә җимерү?
Болай да бит заманыбыз чирле:
Хәерчелек, рухи тилмерү...
Низагларны балаларыбызга,
Оныкларыбызга калдырмыйк,
Гасырлардан килгән туганлыкны
Заман янгынында яндырмыйк!
...Ишетмиләр...

## Үз халкыма сыенам

Күп язганмын ят телләрдә;
Инде әйтәм: «Җитте, – дим, –
Фикер-хисләремне күбрәк
Үз халкыма җиткерим».

Хәер, элек тә каләмем
Язды аңлап бурычны:
Бөеклегенә татарның
Сокландырдым урысны,

Рәхмәт әйттердем үзбәкне,
Көнләштердем яһүдне;
Яңгыраттым, җырга салып,
Сөю дигән бәхетне.

Хәзер исә басып бара
Ят карашлар дөньяны,
Үзгәрә рухы Җиһанның,
Җиле, җыры, иманы;

Килде Җиргә аң чуалган,
Зиһен саташкан заман;
Бүген козгын – күгәрченгә,
Дошман дуска охшаган.

Никтер күңел кителгәндәй,
Нәрсәдер җуйган сыман;
Шуңа өшеп, өмет эзләп,
Мин халкыма сыенам.

Мин сыенам милләтемә –
Ул әүлия, ул әдип!
Сыенам газиз халкыма –
Булсын, җиңсен, үссен дип.

Күршеләр белән сайрашып,
Аңлап белеп кыйбласын,
Телен, динен, йөзен саклап
Яшәсен иде халкым...

## Мөрәҗәгать

Гает көне. Мөселманнар уза.
Урам аша – синең чиркәвең.
Шул мәчеткә барган мөэминнәргә
Сукранасың никтер, чиркәнеп.

Имеш, яратмыйсың азан моңын,
Коръән укучының сөйләмен...
Мин дә әйтер идем җавап итеп,
Әмма тиргәшергә теләмим:

Ызгыш-талаш түгел, гөрләп яшәү –
Бу дөньяда минем миссия.
Синең чиркәү чаңы миңа тими,
Минем азан сиңа ник тия?

Низаг түгел Җирдә безнең максат,
Аңлашу һәм дуслык яклы без.
Әле юкса бу җирләргә безнең
Сезнекеннән күбрәк хакыбыз.

Мәчетемә син күз ташлаганда,
Карашыңда тоям – бозлавык:
Димәк, нәни генә Явыз Иван
Йөрәгеңдә куя кузгалып.

Ичмасам бер: «Нихяль, сосед!» – диген,
Тату күршелеккә юл ачып:
Кызыксынсаң гына – белү туа,
Белгәч кенә була аңлашып.

Мин тумыштан яшим кызыксынып,
Белеп синең рухың-телеңне,
Ә син исә минем рухиятне
Тамчы гына аңлап белдеңме?

Киңәшем бер: арын ачуыңнан,
Шәфкать белән күз сал кыйблага.
Сукрануың – юкка: бетми татар,
Үрчи генә татар дөньяда!

## Булсын иде халкым

Минем инде: «Яшьли үләм», – диеп
Куркасым юк – узды яшь чаклар;
Сүнеп, күптән җилгә очты безнең
Яр буенда яккан учаклар.

Мәңге яшәп булмый бу дөньяда:
Килер бер көн – мин дә китәрмен.
Кем булдым мин Җирдә? – Актарамын
Гомер китабымның битләрен.

Мин тормышны сөйдем. Хәсрәттә дә
Рухым: «Яшим!» – диеп талпынды;
Тик шулай да яшәүдән дә бигрәк
Мин яраттым туган халкымны.

Мин яраттым аның телен, моңын,
Шигърияте булды сердәшем;
Тарихыннан, сыкрап, гыйбрәт алдым,
Җырлап үстем Тукай-Сәйдәшен,

Исән чакларында күреп белдем
Мәшһүр Мөштәриен, Камаен,
Сөйдем кышкы таңда алсу карын,
Якты көзен, гөлле май аен.

Татар галәменә гашыйк булып,
Өммәтемне сөйдем чын-чыннан,
Чөнки телем «Тәфтиләү»не җырлап,
«Мокамай»ны ятлап ачылган.

Мин бәхетле. Тик беләсем килә,
И Хакыйкать! Ачып куандыр:
Бәлки, үземнең дә, күпме яшәп,
Милләтемә файдам булгандыр?

Килер бер көн – мин китәрмен Җирдән,
Болытлардай агып кыйблага;
Тик милләтем берүк калсын иде,
Булсын иде халкым дөньяда.

## Яшәү рәхәт

Яратуым, саф булса да, –
Уен гына, уен гына;
Хыялларым – ният түгел,
Уем гына, уем гына.
Көзен таңда чык балкымый:
Кырау гына, кырау гына;
Чал башымда җавап тумый, –
Сорау гына, сорау гына.

Җавапларны эзлим күктә:
Йолдызларда, тулган айда...
Барчасында – моңсу бушлык.
Тик шулай да, тик шулай да
Күзең, йөзең, җырың – ләззәт
Диңгезендә бер сәяхәт.
Шуңа да шул – дөнья матур,
Яшәү рәхәт, яшәү рәхәт.

## «Татар кызы» бәйгесе

Меңнәр сине басып алкышлады,
Миллионнар күрми үкенде;
Татар бәйрәменнән дер селкенде
Урал төбәкләре ул көнне.
Таҗларыңда балкый – зөбәрҗәтме,
Фирүзәме, алмаз, якутмы?
Карашыңны тойган мизгелемдә
Туктатасым килә вакытны!
Күзләреңдә – галәм серлелеге,
Һәр ишарәң – нәфис, илһамлы...
Дөнья синдә бөтен милләтемнең
Гүзәллеген күреп сокланды.
Таңга калды халык, хис-тойгылар
Ургылыплар торды, ташыплар:
Яшерен-батырын түгел: әйләнәңдә
Төркем-төркем йөрде гашыйклар.
Идел, Чулман, Җаек дулкыннарын
Җыеп тибә микән бу яшь кан?
Тамырларың кайсы Болгар ханы
Нәселенә барып тоташкан?
Хезмәт сөеп, җырлап, дөрләп яши
Татар кызы, халкым баласы;
Милләтемә, димәк, гасырларга
Барасы да әле, барасы...




*Бөтендөнья татар конгрессының II корылтае президиумы. Алгы рәттә (сулдан уңга): Роза Туфитуллова, Рәсим Акчурин, Мортаза Рәхимов, Минтимер Шәймиев, Фәрит Мөхәммәтшин, Индус Таһиров, Рөстәм Миңнеханов, Шәфәгать Тәхәвәтдинов. Казан. 2002 ел*





*Ерак һәм якын чит илләрдән килгән сугыш һәм хезмәт ветераннары. Казан. 2013 ел*




*«Түгәрәк уен» II Бөтенроссия фольклор фестивале. Төмән. 2009 ел*

# АЗАТЛЫК ЮЛЫНДА



Татар Конгрессының барлыкка килүенә 25 ел үтте дә китте. Тарих өчен бу әллә ни күп вакыт түгел. Ләкин аның эченә берсеннән-берсе күләмлерәк вакыйгалар сыйган. Күз алдыбызда диярлек ничәмә-ничә дәүләт таркалды. Мәңгелек дип саналган СССР юкка чыкты, коммунистик идеология чәлпәрәмә килде. Дөньяның төрле почмакларында «аллыгөлле» революцияләр булып үтте.

Шул ук вакытта гасырлар буе югалып торган татар факторының өр-яңадан дөнья мәйданына чыккан, халкыбызның тирән эчтәлекле, горур республикасы пәйда булган еллар иде бу.

Демократия җилләре исә башлауга ук, татар дөньясы яңарыш чорына кереп китте. Яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәдәй, татар яшәгән һәр урында милли оешмаларыбыз барлыкка килде. Аларның иң йогынтылысы Марат Мөлеков җитәкләгән Татар иҗтимагый үзәге иде. Конгресс шушы дулкында республикабызның Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең хәер-фатихасы белән барлыкка килде. Ул аның аякка басуына, эшен җайлап җибәрүенә үзеннән зур өлеш кертте. Парламентыбыз Җитәкчесе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин шулай ук читтә калмады. Конгрессның беренче һәм башка съездларында рәислек итте, эшчәнлегендә актив катнаша килде. Конгресс һәрдаим хөкүмәтебезнең, аның җитәкчесе Мөхәммәт Галләм улы Сабировның да ярдәмен тоеп торды. Хакимият белән халык арасында бердәмлек барлыкка килгән чор иде бу.

Конгресс уставында сайланган Башкарма комитетның, аның бюросының төп бурычы рәвешендә дөньяга сибелеп яшәгән милләттәшләребезне бергә туплап, татар дөньясын хәрәкәткә китерү, телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне ныгыту максаты билгеләнде.

25 кешедән торган Башкарма комитетның рәисе сайланды. *(Индус Таһиров үзе. – Ред.)* Аның урынбасарлары итеп Югары Советның милли мәсьәләләр, фән һәм мәгариф комиссиясе рәисе, шагыйрь Разил Вәлиев (беренче урынбасар), күренекле журналист Римзил Вәлиев һәм «Сөембикә» журналының баш редакторы Роза Туфитуллова сайланды. Аппарат җитәкчесе итеп Лилия Нарбекова, аның ярдәмчесе итеп Тәэминә Биктимерова, аппаратның секретаре итеп Мөҗип Низамиев билгеләнде.

Татар яшәешенең нигезе – гаилә. Чөнки сан һәм сыйфат, тел, лөгать вә әхлак проблемаларын хәл итү гаиләдән башлана. Халкыбызның «кош оясында ни күрсә, очканында шул була» дигән гыйбарәсе үз эченә гасырлар тәҗрибәсен сеңдергән. Гаиләгә адәм баласын әдәпле һәм тәүфыйклы, туган телен белгән шәхес итеп тәрбияләү вазифасы йөкләнгән. Телебезне юкка гына «ана теле» димәгәннәр. Ул кешегә тумыштан ана сөте белән бирелә. Тел ачылу төшенчәсе дә юктан бар булмаган. Бишек җыры, гаиләдәге милли аһәң тел ачылуга юл сала. Гаилә, ата һәм бигрәк тә ана баланың телен матур итеп ачарга бурычлы. Тел ачкычы – аларда. Шул ук вакытта балага халкыбызның гүзәл сыйфатларын, милли горурлык хисләрен, гореф-гадәтләрен сеңдерү дә гаиләнең изге бурычы булып тора.

Менә шушы урында Конгрессның Башкарма комитеты каршында Роза ханым Туфитуллова тырышлыгы белән барлыкка килгән «Ак калфак» җәмгыятенең, аның төрле шәһәрләрдәге бүлекчәләренең, күпсанлы активистларының изге эшләрен күрсәтеп китү дә урынлы булыр. Алар гаиләдә балага милли идеологиянең орлыгын салынырга тиешлеген аңлап эш иттеләр. «Ак калфак» бүген дә шушы зур һәм җаваплы эшне уңышлы гына алып бара.

Милли идеологиянең нигезе тел, мәгариф, мәдәният, дин һәм, гомумән, милли яшәешкә караган бөтен факторлар җыелмасыннан гыйбарәт. Алар арасында бер төп, калган барысыннан да өстен торган милли идея бар. Һәм ул, Мәҗит Гафури сүзләрен куллансак, «һәммә байрактан тора югары». Менә шушы үзәк идея теге яки бу милләтнең тарихтагы, хәзерге дөньядагы һәм киләчәктәге урынын билгеләүгә юнәлдерелгән була. Аның асылы – дәүләт. Чөнки дәүләт милләтнең яшәешенә гарантия тудыра, аның мәңгелеген тәэмин итә. Дәүләтләре юкка чыккач, татарлар инкыйраз куркынычы астында кала. Исән-имин булу өчен, аларның юкка чыккан дәүләтләренә бәрабәр милли яшәешләрен бар итүдән башка чаралары калмый, һәм Октябрь инкыйлабына кадәр милләтебез үз-үзен саклау рәвешен тудыра алды. Беренчедән, ул гореф-гадәтләрен, милли традицияләрен саклардай мөстәкыйль яшәү рәвешенә ия була алды. Икенчедән, үз мөмкинлекләренә көйләнгән үзенчәлекле мәгариф системасын булдырды һәм Россиянең иң укымышлы халкына әверелде. Һәм инде өченчесе: татарлар рус дәүләтендә үз урыннарын билгели алдылар. Алар, күренекле башкорт тарихчысы Б.Х.Юлдашбаев язганча, мисали ислам милләтенә әверелделәр. 1870 елны Сембер шәһәрендә дөнья күргән бер китапта «татары подчинились русским только политически, но не морально», дип язылуы юкка гына түгел. Бу – аларның, сан ягыннан азчылык булуларына да карамастан, Россиянең дәүләти һәм сәяси системасында үз-үзләрен саклап калуларын һәм милләт буларак лаеклы яшәүне тәэмин итә алуларын тану.

1917 елның Октябрь инкыйлабы хәлне тамырдан үзгәртте. Совет чоры тарихта төрлечә бәяләнә. Ул, бер яктан, инкыйразга юл ачкан булса, икенче яктан, 1920 елда Татарстан Республикасының барлыкка килүенә сәбәп булды. Бу республика үзенең асылы белән курчак дәүләтне хәтерләтсә дә, хокуклары һәм мөмкинлекләре белән административ берәмлекләрдән берничек тә аерылып тормаса да, безгә 1990 елның августында дәүләт суверенлыгын игълан итүгә юл ачты.

Бүгенге милли идеологиябезнең нигезендә ике төп өстенлек ята. Аның беренчесе – Татарстанның суверенлыгы, икенчесе – дөнья татарларының республикабыз тирәсендә рухи һәм мөмкин кадәр икътисади берләшүе. Менә бу – һәммә кешегә аңлашырдай гап-гади идеология, һәм ул Бөтендөнья татар конгрессының уставына салынган. Конгресс Башкарма комитеты үз эшчәнлеген шушы ике юнәлештә алып барды. Аның әгъзалары Дәүләт суверенлыгы декларациясен эшләүдә, Федератив Үзәк белән ике яклы Шартнамә төзү хакындагы сөйләшүләрдә, Татарстан Дәүләт Советында законнар төзү һәм кабул итүдә актив катнаштылар. Шулай ук Россиянең милли сәясәте, милли мәдәният турындагы законнарга үзгәреш кертүгә багышланган Дума тыңлауларында принципиаль позициядәге чыгышлар ясадылар. Беренче ун ел эчендә Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә федерация темасына һәм милли проблемаларга багышланган 20дән артык конференция үткәрделәр. Гомумән, Конгрессның беренче унъеллыгында 80 фәнни-гамәли чара үткәрелде. Шуларның 28е төбәкләрдә үтте.

Без Россиянең киләчәген эңгер-меңгергә күчеп, кояшы батып юкка чыгуда түгел, Тукаебыз әйткәнчә, «Хөр мәмләкәт, хөр Русия» булып яшәвендә күрәбез. Заманында татарлар руслар белән бергә Мәскәү дәүләтен юктан бар иттеләр, гасырлар дәвамында аның үсешенә үз өлешләрен кертә килделәр. Россиянең бөтенлеге татарларның бөтенлеген тәэмин итә торган фактор булганлыктан, без аны милләтебезне саклау һәм үстерүнең гарантиясе рәвешендә күрергә телибез. Россиядәге татар факторын бөтен нечкәлекләре белән күзаллау шулай ук бөтен ил өчен мөһим. Моның стабильлек факторы икәнлеген күп төбәк башлыклары таный һәм шуннан чыгып эш итәләр дә. Татарларның исә бөтен Россиягә таратырдай уңай тәҗрибәләре бар.

Россиядәге авылларның юкка чыга баруы барыбызның да күз алдында. Ә менә татар авыллары шундый шартларда да алга бару мисалларын тудыралар. Мин Татарстан, Башкортстанда гына түгел, башка төбәкләрдәге татар авылларының да заман шартларына яраклашып яшәү мисалы тудыра алуларын күз алдында тотам. Чувашстандагы Шыгырдан һәм Тукай, Пенза өлкәсендәге Урта Әләзән, Ульян өлкәсендәге Кулатка районындагы татар авыллары әнә шундыйлардан. Алардагы икътисади һәм рухи тормыш күпләр өчен заманча яшәү өлгесе булырлык. Шушы рәвештәге татар факторы Россия файдасына эшли һәм аны чәчәк аттыруга юл ача.

Шунлыктан бу факторны хәрәкәткә китергәндә, бүгенге татарлыкның нидән гыйбарәт икәнлеген ныклап өйрәнү зарур. Ул исә илдәге халыклар белән аңлашып, дустанә яшәүгә нигезләнгән. Бу, минемчә, игезәкләрне хәтерләткән татар-башкорт мөнәсәбәтләренә дә кагыла. Халыкларыбыз гасырлар буена бер җыр-моң дөньясында, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып яшиләр. Күп еллар буена татар-башкорт мөнәсәбәтләрен күзәтеп, тикшереп килгән Америка профессоры Хафез Малек: «Бу ике халык бер телдә сөйләшә. Әгәр дә аңарда татар сөйләшсә, ул татар теле була, башкорт сөйләшсә, башкорт теле була», дип язды. Күренекле профессор Р.Г.Кузеев күп еллар дәвамында аралашып яшәү нәтиҗәсендә татар-башкорт уртаклыгы барлыкка килде, дигән фикерне фаразлый. Күп булмасалар да, бер колакларына «Син кем?» дип дәшсәң, «башкорт», икенче колакларына иелеп шул ук сорауны бирсәң, «татар», дип җавап бирүчеләр бар. Юкка гына түгел, кайбер төбәкләрдә уртак татар-башкорт җәмгыятьләре яшәп килә. Екатеринбургта яшәүче милләттәшебез Мөнәвир Фәтхетдиновның ике халыкны да сөеп: «Шомыртым, наратларым, Башкортым, Татарларым, яшәгез сез сау-тазалар, бергә булып шат яшәгез, Башкортым, Татарларым»[1], – дигән сүзләре нәкъ безнең омтылышларыбызга тәңгәл килә. Без мөнәсәбәтләребезнең нәкъ шулай булуын телибез. Гади халык гасырлар буена шушы рәвештә аңлашып, дуслашып, бер рухи дөньяда һәм шул ук вакытта бер-берсенең кем икәнлеген аңлап яши. Ә менә кайбер галимнәр хәтта бүгенгәчә мөнәсәбәтләребезне катлауландыра. Алар, беркемнән сорамастан, Татарстанның Актаныш, Минзәлә, Азнакай кебек районнарына килеп, андагы халыкны башкортлыкка күндереп йөри. Имештер, аларның тамырлары башкортныкы, аларны бары татарлаштырганнар гына. Асылда нәкъ киресенчә. Заманында шактый күп татарны башкорт сословиесенә язганлыклары мәгълүм. Мәсәлән, 1719 елны Казан губернаторы Салтыков Сенатка 46841 ясаклы татарның 19932се башкорт сословиесенә язылганлыгын хәбәр иткән. 1730 елны аны алыштырган Волынский әле нибары 20 ел элек – 35, күп булса 40 мең булган башкортларның саны татарлар хисабына 100 меңгә җитте, дип хәбәр иткән.

Соңгы халык исәбен алу нәтиҗәсендә дә Башкортстанда меңләгән татарны башкорт итеп яздылар әнә. Һәм шушы эш, ни кызганыч, бүген дә дәвам итә.

Бу язмамны милләтебез алдында торган кайбер проблемаларга юнәлтмәкче булам. Ә алар шактый. Иң әүвәл бу – милләтебезнең мәңгелегенә юл ачу, аның санын арттыру һәм сыйфатын саклап калу. Икенчесе – шушы максатка ирешүнең төп шарты булганы – Татарстаныбызны чын рәвешендәге алга киткән, чәчәк атып яшәүче республикага әверелдерү. Бу ике бурычны алар бердәм рәвештә яшәсәләр генә тормышка ашырып булачак. Иманым камил, сөт калса, Ватан кайтачак. Яки татар үзе сакланса, аның Ватаны да кайтачак[2]. Сөт – ул милләтебезнең сыйфаты, аның ныклыгы. Татар дөньясы – ул Татарстан һәм Җир шарының төрле якларына сибелеп яшәүче милләттәшләребез. Соңгы 25 елда татарлар акрынлап булса да бер җан, бер тән булып, бер-берсенең сулышын, йөрәк тибешен сизеп, тоеп яши башладылар. Аларның башкаласы – Казан, тарихи ватаннары – Татарстан.

*Без – татарлар!*
*Шушы исем белән*
*Җирдә яшәү үзе бер бәхет.*

Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең шушы шигъри юллары халкыбызның рухи халәтенә туры килә. Аңа милли горурлык хисләре кайта, үз-үзенә ышанычы ныгый.

Әгәр дә мин, Конгресс, аның Башкарма комитеты барлыкка килүнең беренче елларында ук читтә яшәүче милләттәшләребез белән эшләүнең нәтиҗәле механизмын таба алды дисәм, әлләни ялгышмамдыр. Ул да булса, төрле төбәкләрдә аның күчмә утырышларын уздыру. Бу, бер яктан, комитетның башкарган эшләре турында җәмәгатьчелек алдында хисап тоту булса, икенчедән, җирле хакимиятләр белән татар проблемасын уртага салып сөйләшү төсен алды. Шундый утырышларның

[1] Фәтхетдинов М. Гомерлек юлдашларым. – Екатеринбург, 1999. – Б.36.
[2] Дәрдемәнднең «Сөт калыр, Ватан китәр» дигән шигырь юлына ишарә бу. – *Ред.*

беренчесе – үзебезнең Түбән Кама шәһәрендә, икенчесе Екатеринбургта үтте. Анда Башкарма комитет бюросы һәм җирле хакимият белән татар проблемаларын бергәләп хәл итүне билгеләгән килешүгә кул куелды. Без Свердловск өлкәсе губернаторы Эдуард Россельне үзебезнең теләктәшебезгә әверелдереп, бергәләп татар яшәешенә кагылган күп чаралар үткәрдек. Саратов өлкәсе губернаторы Дмитрий Аяцковны да шундый ук теләктәшебезгә әверелдерә алдык. Губернатор булып эшләгән елларында ул татар мәгарифенә бик нык ярдәм итте. Әгәр бүген Саратовтагы татар гимназиясе чәчәк атып яши икән, монда аның да өлеше бар. Шушы рәвештәге эшләр Самара, Сембер өлкәләрендә дә, Санкт-Петербургта, Мәскәүдә, Удмуртия, Мари һәм Чуваш республикарында һәм башка төбәкләрдә дә уңышлы гына башкарыла килде. Аларның җитәкчеләрен шулай ук татар проблемаларына җәлеп итә алдык. Алай гына түгел, Россия Президенты Б.Н.Ельцинның ведомстволарга татарларның милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәтелгән 17 маддәле йөкләмә бирүенә ирешә алдык. Һәм кулдан килгәнчә аларның үтәлешен тикшереп тордык.

Әгәр дә мин Конгресс эшчәнлеген тасвирлаганда күпләгән активистларыбыздан кайберләренең генә булса да исемнәрен атап китмәсәм, бу һич кенә дә гаделлеккә туры килмәс иде. Менә алар. Бу Уфада – мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Рәиф Әмиров, Эдуард Хәмитов, Радик Сибгатов, Бәләбәйдә – Нурмөхәммәт Хөсәенов, Самарада – Азат Надиров, Әминә Шәмсетдинова, Равил Яһудин, Илгиз Колычев, Фаик Фарукшин, Шамил Баһаветдинов, Рифкать Әһлиуллин, Фәхретдин Канюкаев, Ульяновскида – Айрат Ибраһимов, Мордовиядә – Ирек Биккинин, Әстерханда – Ахияр Измайлов, Әнвәр Алмаев, Оренбургта – Зиннур Шакиров, Ирек Үзбәков, Түбән Новгородта – Алимҗан Орлов, Удмуртиядә – Мәсхүт Гаратуев, Саратовта – Фрид Рәшитов, Митәсим Сөләйманов, Мөкатдәс Бибарсов, Зөфәр Хәкимов, эшмәкәр-галим Камил Аблязов, Чувашстанда – Әлбир Крганов, Богырысланда – Гобәйдулла Сафиуллин, Мәскәүдә – Рифкать Галимов, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин, бертуган Рәсим һәм Ринат Акчуриннар, Нур Гарипов, язучы Ямил Мостафин, Санкт-Петербургта – вице-адмирал Марс Искәндәров, Шамил Әхмәтшин...

1998 елның 10 апрелендә 15 сәгать 30 минутта соңгы ике кешенең зур тырышлыгы белән Конгресс Таврический сараенда Бәйсез ДәүләтләрДуслыгы (Содружество Независимых государств) составына күзәтүче рәвешендә кабул ителде.

Ни кызганыч, милли хисләр утында янып яшәгән Марс Искәндәров, Равил Яһудин, Мәсхүт Гаратуев, Ахияр Измайлов, олы һәм мәртәбәле эшләр башкарып, инде мәңгелеккә күчтеләр. Урыннары җәннәттә була күрсен!

Конгресс БДБ илләрендә дә шактый эшләр башкара. Анда, тулы булмаган мәгълүматларга караганда, 4 миллионга якын татар яши. Бу илләрдә башкарылган һәм башкарыла торган эшләр шулай ук күпкырлы. Конгрессның андагы эшчәнлегендә дә җирле хакимият җитәкчеләре актив катнаша. Әйтик, Казакъстан Президенты Нурсолтан Назарбаев татар тормышы белән махсус кызыксынып тора, үткәрелә торган чараларның кайберләрендә үзе дә катнаша. Шымкент, Семипалат төбәкләренең җитәкчеләре дә татар эшләреннән читтә тормыйлар, кирәк вакытта ярдәм кулларын сузалар. Казакъстандагы зур эшләрне барлаганда, һичшиксез, тарихчы галим Гриф Хәйруллинның, профессор, медицина фәннәре докторы Морат Кәримовның исемнәрен аерып күрсәтү урынлы булыр. Гриф Хәйруллин эшчәнлегенең шактый өлеше тарихыбызны өйрәнүгә, фәнни хезмәтләр язуга багышланган булса, Морат Кәримов күп еллар буена Татарстанның Казакъстандагы вәкиле рәвешендә татар-казакъ дуслыгын ныгыту юнәлешендә зур эшләр башкарды.

Ләкин барысы да ал да гөл дип уйлау һич кенә дә дөрес булмас иде.

Соңгы халык исәбен алу нәтиҗәләре үз телләрен белми торган татарларның арта барганлыгын күрсәтә. Телсезлек – милләт бетүгә туп-туры юл. Россия Дәүләт Думасының 309 нчы законны кабул итүе милли мәгарифебезне генә түгел, ә, гомумән, дәүләтчелегебезне торгызуда билгеләнгән стратегик гамәлләребезне какшата. Моның өчен безгә милли горурлыгыбызны иң беренче урынга чыгарып, үткән бай тарихыбызны барлап, аны халык күңеленә сеңдерү кирәк.

Галимнәребез үткән тарихыбызны гәүдәләндерүдә шактый уңышларга иреште.

Зур күләмле хезмәтләр барлыкка килде. Әмма аларны пропагандалау эше түбәннән-түбән, сүлпәннән-сүлпән. Телевидение һәм радио бу өлкәдә тиешле эш алып бармый, дисәм, дөреслектән әллә ни ерак булмамдыр. Ышанасы килми, ләкин миңа кайвакыт кемнәрдер тарихи хәтеребезне махсус рәвештә сүндерүне максат итеп куйган кебек тоела. Ичмасам күршеләребез башкортлардан үрнәк алсак иде. БСТ каналы моны игътибар үзәгендә тота, даими рәвештә тарихи тапшырулар оештыра.

Тарихсыз халыкның киләчәге юк икәнлеген һич кенә дә онытырга ярамый.

Бурычларыбызның иң зурларыннан берсе – яшь буынны тәрбияләү, татар гаиләсенә махсус игътибар бирү. Балага бишектән башлап ук җыр-моңнарыбызны, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне сеңдерү зарур. Әйтик, Чувашстанның Тукай, Лениногорск районының Керкәле авылларындагы кебек. Бу авылларда җәмәгатьчелек балаларны бөтен тулылыгы белән милли рухта тәрбияли. Мәдрәсә, мәктәп, ата-аналар бу эшне бердәм рәвештә алып баралар. Шунлыктан бу авылларда эчүчелек, наркомания кебек күп урыннарга хас булган заман чирләре дә юк. Чувашстанның Шыгырдан, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән, Мордовиянең Белозерье кебек авылларында да шундый ук нәтиҗәле милли тормыш өстенлек итә.

Сер түгел, соңгы елларда шәһәрләрдә балаларны татар мәктәпләренә бирергә теләмәүчеләрнең саны артты. Имештер, бу мәктәпләрдәге балалар рус телен начар үзләштерә, шунлыктан аларның югары уку йортларына керү мөмкинлекләре чикле. Монда дөреслек бөтенләй юк дип әйтеп булмый. Моңа югары уку йортларына керү БДИ (бердәм дәүләт имтиханы) рус телендә генә бирелергә тиешлек тә дәлил булып тора сыман. Ләкин, алай булгач, нигә соң Казандагы 2нче татар гимназиясендә, Саратовның шәһәр уртасындагы татар гимназиясендә беренче сыйныфка керү өчен бер урынга алты кешелек конкурс? Бу гимназияләргә башка милләт балалары да керергә омтыла әле. Ижевск татар гимназиясендә яки Самараның «Яктылык» мәктәбендә дә шул ук хәл. Моның хикмәтен әллә кайдан эзлисе юк. Бу мәктәпләрдә укыту, белем һәм тәрбия бирү дәрәҗәсе тиешле югарылыкка куелган. Аларны тәмамлаучылар өчен теләсә кайсы уку йортының ишеге ачык. Боларда укыган балаларга заман чирләре дә йокмый. Бу мәктәпләрнең эшчәнлеген киң җәмәгатьчелек һәрвакыт күз уңында тота. Татар галимнәре һәм байлары да үз өлешләрен кертә тора. Мондый мәктәпләрне тәмамлаган балалар туган телләрен дә, рус һәм инглиз телләрен дә камил рәвештә үзләштерә. Ләкин алар өчен бүтән телләрне белүнең төп нигезе – туган тел.

Революциягә кадәр Россиядә татарлар үз телләрен саклый белгәннәр. «Сын Отечества» газетасында (1904 елгы 1 июнь саны) тикмәгә генә «мөселманнарның рус йогынтысыннан ерак торуларына аларның мәктәп системасы сәбәпче», дип язылмаган. Инде безгә бүген дә милли мәгариф проблемасын беренче урынга чыгару зарур. Моны тормышка ашыруда дин әһелләребезнең дә ныклы һәм даими катнашы булырга тиеш. Алар мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның мәчетләрдә вәгазь бары тик татар телендә генә укылырга тиеш дигән күрсәтмәсен бөтен тулылыгы белән үтәргә бурычлылар. Һәм шул ук вакытта яшь буын белән эшләүгә, бигрәк тә мәктәпкә игътибарларын бермә-бер арттырырга тиешләр. Татар Конгрессының дин әһелләре белән якынаюы, уртак чаралар үткәрүе иң кирәкле эшләрнең берсе. Болгар җыенын дәүләт органнары белән бергә үткәрүнең традициягә әверелә баруы моңа ачык мисал. Дин дәүләттән аерылган булса да, ул җәмгыятьтән аерылмаган лабаса.

Халкыбызның 1552 елдан башланган иң авыр чорларында аны Ислам дине саклап калган. Аның аркылы Аллаһы Тәгалә милләтебезгә яшәү көче иңдергән. Ят камалышта калса да, чукындыру, руслаштыру сәясәте янаса да, ул бирешмәгән. Чөнки дини тәрбия милли яшәешнең төп сыйфатына әверелгән. Заманында күренекле тарихчы Н.А.Фирсов болай дип язган: «Ни убеждения миссионеров, ни льготы, даруемые правительством за переход к христианству, ни обстоятельства, что им приходилось разоряться от платежа за новокрещёных податей, ни уничтожение их мечетей не действовали на них; огромнейшее их большинство оставалось твёрдыми в вере отцов и дедов, между тем, как живущие рядом с ними язычники почти поголовно крещены».

Дини тәрбия бүген дә актуаль проблемаларыбызның берсе. Шәһәр һәм авылларыбызда мәчетләр торгызылды, аларның яңалары да үсеп чыкты. Кремль

уртасындагы бөтен шәһәргә нур биргән Колшәриф мәчете яки Болгардагы яңа ачылган мәчет үзләре генә дә ни тора! Әйе, мәчетләр күп, ә менә анда йөрүчеләр әллә ни күп түгел. Татарлар төзегән Мәскәү мәчетләрен башка милләт вәкилләре басып алды. Башка шәһәрләрдә дә охшаш проблемалар җитәрлек. Шунысы куандыра: мәчеткә, динебезгә тартылучы яшьләрнең саны арта. Тик менә дин әһелләребез арасындагы таркаулык кына күңелне борчый. Онытмыйк, дини бердәмлек – милли бердәмлекнең асылы ул.

Проблемалар исә күптин-күп, чуктин-чук. Аларны бары тик милли бердәмлек булганда гына хәл итеп була. Бердәмлек, бердәмлек һәм тагын бердәмлек!

Әйе, 25 ел вакыт күз ачып йомганчы диярлек үтте дә китте. Ләкин яшәеш дәвам итә. Хәл итәсе проблемалар һич кенә дә кимеми. Иманым камил, яңа сайланачак Конгрессның күпчелеге яшьләрдән торырга тиеш. Чөнки тарих һәрбер буын алдында үзенә хас булган бурычларны бертуктаусыз куя тора. Бер-берсен алыштырып торган буыннарның бары тик уртак максатлары гына үзгәрми һәм үзгәрергә тиеш тә түгел. Ул – милләт, аның иминлеге, аның азат киләчәге, аның мәңгелеге.

**Индус ТАҺИРОВ**

# ТАТАР КҮГЕ ЯКТЫ, БИК ЯКТЫ!

**Астрофизик Рәшит Гали улы Сүнәев 12 июньдә В.Путин кулыннан Россия Федерациясенең Дәүләт премиясен алды.**

Мәскәү мөһере сугылган «космик премияне» 2000 елны да алган иде ул. Рәсәйнекен генәме әле? Дөнья илләренең 15 премиясе бирелгән аңа (бишесе – АКШныкы), һәм тагын әле 3 халыкара премия иясе дә ул! Россия Фәннәр академиясенең Космик тикшеренүләр институтының баш фәнни хезмәткәре Сүнәев 1999 елдан алып Германиядәге Макс Планк исемендәге җәмгыятьнең Астрофизика институтына да җитәкчелек итә бит әле. Кыскасы, Рәшитебез – дөньяның иң көчле астрофизикларының берсе!

Ә Космик тикшеренүләр институтына кем җитәкчелек иткән дисез? Роальд Зиннур улы Сәгъдиев – 36 яшендә үк, ягъни СССРда иң яшь академик булган дөньякүләм шанлы-данлы татар. Институтка 15 ел җитәкчелек итеп, 1988 елны Америкага китеп баргачтын, аның урынында кем калган дисез? Альберт Әбүбәкер улы Галиев. Ул әле хәзер дә институтның шәрәфле директоры!

Рәшит әфәнде 2012 елның сентябрендә Казанда астрофизика буенча зур халыкара конференция үткәрде. Миңа конференциядә катнашкан милләттәшләребез турында да сөйләде ул (әңгәмәбез журналның 2012 елгы 11нче санында чыкты). Шуннан бер-икешәр кыскартылган җөмлә булса да китерим әле. «Казанда бер бик әйбәт фәнни мәктәп барлыгы сөендерә. Бу – КФУның астрономия кафедрасы мөдире Наил Абдуллович Сәхибуллин мәктәбе». КФУ профессоры Илфан Бикмаев турында: «Сез аңлап җиткерәсез микән: менә биредә, Казанда, югары дөнья кимәлендәге, бөтенесен дә үзе булдыра ала торган гаҗәеп кеше эшли!» «Космик тикшеренүләр институты профессоры Марат Равилович Гыйльфанов... Хәзер ул – дөньякүләм танылган бик көчле галим...» «Ландау исемендәге Теоретик физика институтының сектор мөдире Наил Галимович Иногамов... Дөньяга танылып өлгергән галим... Принстон институтының профессоры Роман Равилович Рафиковны да тыңладык. Докладында гел Иногамовның эшләренә таянды ул...» Илдар Хәбибуллин турында: «...Сүзем бит бәләкәй татар шәһәреннән калкып чыккан 22 генә яшьлек егет турында, аның искиткеч шәп мәкаләләр язуы турында...»

Һәм... Борынгы заманнардан ук башланган бит безнең бу «астрофизик» эш! Сәйф Сараиебыз «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында ни дип язган әнә:

*«Сөһәйлне күрде-йү әйләнде бер тик –*
*Көнәш гирдендә йөргән мисле җир тик».*

Ягъни шагыйребез кызның егет янында бөтерелүен генә түгел, Кояш тартуындагы Җир кебек әйләнүен дә язган! Инде 1394 елда, ягъни моны «ачкан» Коперник белән Галилей әле дөньяга килгәнче үк! Мәкъсуд әл Болгари (XIII гасыр) кебек мөнәҗҗимнәребез (астрономнар) булган бит безнең.

Менә шулай ул, милләттәшләр, «Җир» планетасындагы хәлебез мөшкелрәк булса да, «күктә», шөкер, балкыйбыз әле!

**Рәфикъ ЮНЫС**

# «МЕНӘ ШУНДЫЙ ЗӘЙНӘБ ИНДЕ МИН...»

## ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН ӨЗЕКЛӘР

### Идән юучы чиләгендәге каеннар

Класстагы Костя исемле бер малай белән борчак пешмәде безнең, укуның беренче көннәреннән үк. Әтисе кибет мөдире дә булып эшли иде шикелле, шуңадырмы, бик ирәеп беренче сыйныфтан ук үзен әллә кемгә куймакчы. Русчасы бик яхшы булса да, башка фәннәрдән әллә ни алдыра алмый, язарга, укырга бик озак өйрәнә алмый интекте. Ә үзе русча яхшы сөйләшмәгәннәрдән көлгән була. Тәнәфесләрдә мин булып кыланып та җанны ашый, имеш, мин «бедная татарочка». Минем моның кыланмышларына бер дә «исем китми», башкалар кебек җавапка үртәшмим, ишетмәмешкә, күрмәмешкә сабышам – туган апаның ире, җизнәй шулай өйрәтте. Шуңадырмы, Костяның ачуы тагы да ныграк чыга, һич тә тынычлана алмый, койма ярыгыннан бар узганга өреп торучы эт кебек тота үзен. Әтисе улына кыйммәтле ручкалар, каләмнәр, пеналлар алып бирә – безнең андыйларны күргән дә юк. Чираттагы рәсем дәресенә бик затлы буяулар белән килде бу. Дәрес башланыр алдыннан барчабыз рәсем дәфтәрләрен парта өстенә куйдык. Партадаш кыз минем альбомны ачып, өйгә бирем итеп бирелгән рәсемемне ачып карап, «Здорово, как красиво!» – дип кычкырып җибәрмәсенме. Рәсемнәрне чыннан да матур ясый идем, бу юлы да агачлар чын булып күренсеннәр дип, кич буе бик тырышып утырган идем. Башкалар да безнең парта янына җыелышып минем каеннарымны карый башладылар. Шунда кешеләрне этә-төртә бу да борынын тыгып маташа. Шул арада «Дай, посмотрю!» – дип, минем рәсем дәфтәрен тартып алды да, без аңышканчы, идән юучы онытып калдырган, класс бүлмәсенең почмагында торучы чиләктәге пычрак суга илтеп ыргытты. Аннары: «Извините, не хотел, кто сюда вообще ведро поставил?» – дип, безгә карап авыз ерды. Мин дә аптырап калмадым, ачуымнан атылып барып өстәлендәге өр-яңа буяуларын кабы белән идәнгә төртеп төшереп җибәрдем дә рәхәтләнеп өстенә басып таптадым. Аннары, аңа телемне күрсәтеп, «И я не хотела, извини», – дип, тыныч кына урыныма барып утырдым. Нигә кайгырырга, мин рәсемемне кабаттан да ясый алам бит, дәфтәрем дә биш тиенлек кенә. Ә бунтарь малайга әтисеннән шәп кенә эләкте булса кирәк, миңа бәйләнүеннән туктады. Төрле авырлыкларга каршы торырга өйрәткән тормыш университетының тәүге беренче баскычларыннан ук менә шундый чирканчыклар ала-ала, төрле чыныгулар кичеп менәргә туры килде миңа.

### Озын колаклы шатлык

Биредәге балачагым шатлыклы мизгелләргә дә бай иде. Дус-ишләр, туганнан туган абыйларым, апаларым белән чыр-чу килеп, бар дөньяны онытып, рәхәтләнеп уйнаулар, рәсем ясаулар бары да нәкъ балачактагыча булды. Кечкенә чак хайваннарга, җанварларга да мәхәббәтсез булмый. Җылы якларда гына яши торган бик тә комик кызык хайваннар – ишәкләрнең кыланмышлары искә төшеп, балачак хатирәләрен яңартып, әле бүген дә ирексездән елмаерга мәҗбүр итә. Вак-вак атлап килүләре, озын колаклары, төп-төгәл сәгать саен кычкырып вакытны белдерүләре – барсы, барсы да без сабыйлар өчен, әлбәттә, бик кызык иде. Ни өчен кычкыралар икән алар дигән сорау да гел баштан китмәде, шул сорауга, күпме эзләсәм дә, җавап таба алмадым...

Минем «ахирәт ишәгем» дә бар иде. Уйламаган җирдән дуслашып киттек без аның

*Ахыры. Башы узган санда.*

белән. Мәктәптән кайтып барам, карыйм, өрек агачына ышыкланыбрак кечкенә генә ишәк баласы басып тора, башын аска игән, колаклары шәлперәйгән. Узып барышлый күзендә яшь күреп янына килдем. Тибә күрмәсә ярар иде дип, курка-курка гына муеныннан сыйпыйм. Ә ул, киресенчә, миңа табарак борылып, башта башын иңемә куйды, аннары, кочакла инде дигәндәй, гел бөтенләй елышты. «Ярар, елама, тукта... Әниеңне югалттыңмы әллә? Әйдә, тынычлан...» кебегрәк сүзләр белән аны үземчә юатам, ә ул балаларча иркәләнә, күзләрен мөлдерәтеп туп-туры минем күзләремә бага. Аны күпме генә җәлләсәм дә, гел янында басып торып булмый бит инде, өйгә дә кайтырга кирәк, ашыйсы да килә. Агач кәүсәсенә сөяп куйган букчамны алып, моның белән саубуллаштым да өйгә таба кузгалдым. Карыйм, бу да миңа иярде. Шулай бергәләп сөйләшә-сөйләшә апаларга кайтып җиттек, алар үз йортлары белән торалар. Тиз генә өйгә кереп, ишәк малаеның да карыны ачкандыр дип, сөткә манчылган бер телем ипи алып чыгып ашаттым. Икенче, өченче көнне дә очраттым мин моны, әллә махсус көтеп тора иде инде ул мине шул агач янында көн саен, аңламадым. Мин аны төрлечә сыйлыйм, үз артымнан барырга рөхсәт бирәм, ә ул кайчакта авыр букчамны җилкәсенә дә куйдырттырып бара – миңа «булыша». Мин аңа «Матур» дип исем дә куштым, ишәк булса да нindидер сөйкемлелеге бар. Беркөнне мәктәптән кайтканда күрәм, ике малай моның янында мәш киләләр. Бәләкәйлегеннән файдаланыпмы, моңа атланырга чамалыйлар, чөнки олырак ишәкләр утыртмыйлар бит, чөеп кенә аталар. Мин бу хәлне күрүгә ачыргаланып, ерактан ук: «Что вы делаете, он же ещё маленький!» – дип кычкырам. Таныш тавышны ишетеп, «Матур» да батыраеп китте, малайларның берсенә арт аягы белән нык итеп типте, теге авыртуына түзә алмыйча кычкырып җибәрде. Миннән арттарак бер апа килә икән, ул да кечкенә ишәкне җәберләүчеләргә «Бессовестные!» дип кычкыргач, бу тәртипсезләр тизрәк таю ягын карадылар.

## Чын туганнар

Үзләренең дүрт балалары өстенә мине дә сыендырган, киң күңелле Мәмдүрә апага, Гали җизнәйгә мин гомерем буе рәхмәтле. Тормышлары җиңелдән булмаса да, алар миңа бер генә тапкыр да кырын күз белән карамадылар. Балалары белән дә бертуганнар кебек дус, тату яшәдек, туганлык хисләрен аларга җизнәй белән апа сабый чакта ук бирә белгән, күрәсең. Кыскасы, мин үземне бу гаиләдә чит буларак хис итмәдем, туганны туган итү буенча тәүге дәресләрне дә шушында алдым. Мәмдүрә апа – әниемнең бертуган апасы, аның иң якын сердәше. Алар бер-берсе турында энәсеннән җебенә кадәр беләләр, бер-берсен шулкадәр якын итәләр, яраталар, берсе икенчесе өчен соңгы күлмәген дә бирергә әзер. Әти абыйны алып Сарлыга кайтып киткәч тә, апа иң беренче булып әнигә үзе сүз ката. Мәрҗәнә, акыллым, ди ул, иреңне ялгызын кайтарып җибәреп дөрес эшләмәдең, киткәненә дә шактый инде, ир-ат ир-ат инде ул, шайтан коткысына тиз бирелә алар. Үзе матур, үзе ялгыз булган ирләрне эләктереп алырга әзер хатыннар да аз түгел. Холкы усал булса да,Фазлетдинның күз явын алырлык. Гармунын уйнап, җырлап та җибәрсә... Балалар кызганыч, ике ятим бар бит инде, берсе әтисен, икенчесе исә әнисен күрергә тилмерәләр, инде бу нарасыйны да әтисез калдырмакчы буласызмыни, ди ул минем якка ишарәләп. Гайнетдин абыйны ничәмә еллар тәрбияләп, үз баласы кебек яратып өлгергән, аның язмышы өчен инде Ходай каршында да җаваплы әни дә, үзенең дә бик каты борчылуын, уйларга чумып йөрүен, абыйсыз калган Гайнетдинне сеңлесеннән дә мәхрүм итәргә ярамаганлыгын, кызын да туганы белән бергә әтиләре янында үстерергә теләгәнлеген әйтә. Ләкин уку елы башында мине мәктәптән аерырга теләми, ә кызын ташлап китүне күз алдына да китерә алмый. Мәмдүрә апа бу сөйләшүгә бераздан кабат әйләнеп кайта, монысында үз сүзен җизнәй дә әйтә. «Мәрҗәнә, балдыз, бар кайт ирең янына, Зәйнәбне бездә калдырып тор, ялгыш кына да авыр сүз әйтмәбез, ул безнең күңелләргә бик якын бала, без дә аңа чит түгел. Уку елы тәмамлангач кайтып алырсыз», – дип, мәсьәләне хәл итә дә куя.

Мәмдүрә апа гомер буе мамык җыюда бил бөгә, басу-кырларда җанлылык тынып торганда, үзенә башка шөгыльләр таба, бер эштән дә куркып тормый: дүрт баланы туйдырасы, киендерәсе, кеше итәсе бар. Мин аның үзем укыган мәктәптә идән юып йөргәнен дә хәтерлим. Гали җизнәй – мәчеттә имам, бөтен нәрсәгә үз фикере

булган, киң карашлы, бик тә хөрмәтле кеше. Сугыш еллары белән бәйле тетрәндергеч хатирәләргә дә бай иде аның тормыш китабы. Дошман белән бик каты бәрелешләрдә камалышта калган, тулысынча әсирлеккә алынган Волхов армиясендә хезмәт иткән. Ул чорның үз хакыйкате: пленга алганнармы, төшкәнсеңме, аерма юк – син барыбер сатлык. Үз иленең иминлеге, якыннарының якты киләчәге өчен җанын да бирергә әзер җизнәй мондый хурлыклы ярлык белән яшәргә җыенмый да, теләми дә. Бу хәлдән котылу буенча башында берничә план өлгерә һәм шуның берсен озакка сузмый тормышка ашырырга ниятли: армияне урман аша алып киткәндә ничек булса да качарга! Эчем авырта дип хәйләләп, еш кына куак араларына «йомышын йомышларга» керә башлый, үзенең авырып киткәнлегенә тегеләрне тәмам ышандырып бетерә һәм чираттагы керүендә «озаграк тоткарлана», армия күздән югалгач кына чыгып, бөтен көчен җыеп кире якка йөгерә. Берничә көн юл эзләп, адашып йөргәч, ул якындагы бер авыл кешеләренә юлыга. Бу миһербанлы җаннар аны ашатып, киендереп озаталар. Шул ук вакытта алар аңа үзе турында беркемгә берни сөйләмәскә, бигрәк тә хәрби киемле кешеләрдән ераграк булырга, кайсы армиядә хезмәт иткәнен, гомумән, сугышта, пленда булуын авыз ачып беркемгә дә әйтмәскә, туган ягыннан ераккарак китеп төпләнергә киңәш бирәләр. Туган авылына юлны ул бик озак һәм зур авырлыклар белән үтә: документлар юк, теләсә кайда туктатып, кемлегеңне тикшертеп, ахыр чиктә трибунал чәпәп куярга да мөмкиннәр. Кайтып җиткәч тә төнгә кадәр урманда качып утыра, авыл урамнары кара шәл ябынгач кына арткы бакчалар аша өенә юнәлә. Ә инде таң атып, көн узып, кабаттан төн җиткәч, гаилә бергәләп юлга чыга. Бәхет эзләп түгел, менә-менә эләктерергә әзер булган гаделсез язмыш ыргагыннан мөмкин кадәр ераграк җиргә, колак ишеткән булса да, күз күрмәгән якларга качу уе белән, беркем белән дә саубуллашмый, хушлашмый, бер төенчек кием, бер төенчек юлда капкаларлык азык алып тимер юл станциясенә киләләр. Товар поездында – күмер вагонында яшеренеп Үзбәкстанга юл алалар, Ходай ярдәме белән килеп җиткәч, Красногорскта төпләнәләр. «Тәңрем коткарып калды мине, әсирлеккә төшкән армия солдаты дип атып та үтерерләр иде – еллары шундый иде. Шуңа да гомерем буе Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итәргә сүз бирдем», – дип сөйләгәннәре хәтердә җизнәйнең. Ул мине дә сабыр булырга, шөкер итә, көтә белергә өйрәтте, таңның да төн узгач кына атуын, ләкин шул ук вакытта бәхет өчен көрәшү кирәклеген дә аңлата алды. «Кызым, беләм, сиңа әнисез, әтисез авыр. Ләкин бу – вакытлыча гына бирелгән тормыш сынавы. Иң мөһиме, алар исән-сау һәм сине кайтып алачаклар», – диде ул берсендә. Мин җизнәйне бик яратам, ул алдый белми, бары дөресен генә сөйли, аның әйткәннәре һәрчак уйландыра да. Чыннан да, әнием мине тиздән кайтып алачак бит! Шунда минем күз алдына Гайнетдин абыйның сагышлы йөзе пәйда була. Ул да әнисен сагына бит! Яныңдагылар никадәр яхшы, мәрхәмәтле булмасын, үз әниең үз әниең инде ул, аңа беркем җитми. Моның чыннан да шулай икәнен, абыемның ничәмә еллык эчке кичерешләрен, аның нинди утларда янганын бөтен барлыгым белән үземнең татып каравым түгелме соң бу?! «Абыем, мин сине аңлыйм, мин сине яратам, мин сине тыңлармын, каршы бер генә дә сүз әйтмәм!» – дип кочаклаплар аласым килде аны шул чакта, тик үзе генә янда юк, аралар ерак. Шул мизгелдә күңелемдә бер шәм кабына – абыема карата ниндидер үзгә – тагын да җылырак хисләр уяна...

## Таулар иле яки коммунизм утраучыгы

Красногорск Ташкенттан ерак түгел, нибары илле чакрым ераклыкта. Тянь-Шань тауларының көнбатыш өлешендәге Чаткал сыртлары битендә, ике тау елгасы кушылган, диңгез тигезлегеннән 700 метр биеклектәге җирдә төзегәннәр аны. Таулар зур, кызыл төстәге ташлардан тора. Без биредә яшәгән чакта ул – әле яшь, Мәскәү тәэминатындагы шәһәр тибындагы шахтёрлар бистәсе иде. Уран һәм башка табигый хәзинәләргә бай, статусы буенча ябык бу торак пунктны ул чакта «коммунизм утраучыгы» дип йөртәләр иде. Чөнки монда баштан ук, аңа нигез салганда ук, шахтёрлар, илнең төрле почмагыннан килеп төпләнүче кешеләр өчен барлык уңайлыклар тудырганнар. Яши торган халкы күп түгел, бары ун меңнән артыграк. Ләкин, кечкенәлегенә карамастан, зур кинотеатры, бихисап кеше сыйдырышлы Мәдәният йорты, төрле спорт, мәдәният,

медицина корылмалары бар. Мәктәпләре генә дә унга якын, дөрес, шул исәпкә сәнгать, музыка белемнәрен бирү юнәлештәгеләрен дә кертеп. Кыскасы, заманына күрә ул бик тә уңайлы, төзек шәһәрчек булган. Бистәне чыгуга ясалган күлдә халык рәхәтләнеп ял итә. Кибетләр саны да монда ул чакта ук аз түгел иде, кешеләрнең товарга кытлык кичергәннәрен, чират торып интеккәннәрен хәтерләмим. Киресенчә, башка җирдә юк әйбер монда һәрчак бар иде. Без Сарлыга, әби янына, Башкортстанга туганнарга кунакка кайтканда кучтәнәчкә нәрсә генә алып кайтмыйбыз.

Бистә халкы, әйткәнемчә, нигездә күчмә – шахталарда эшләр өчен, бәхет эзләп килгән кешеләр: руслар, татарлар, немецлар, үзбәкләр. Мәктәпнең икесе генә милли, башкаларында уку рус телендә бара иде.

Истәлекләремне бистәнең, аның тирәлегенең искиткеч матур табигатен сурәтләми, тасвирламый дәвам итсәм, туган ягым һәм балачагым мине дөрес аңламаслар, гафу итмәсләр. Красногорск, язганымча, таулар арасында, дөресрәге, таулыкларда урнашкан. Шул кечкенә тауларга, калкулыкларга менә-төшә йөрдем дә инде мин мәктәпкә. Сине һәр урамда, үзәнлекләрдә өрек, персик, гранат, биек чия – черешня агачлары, куаклары каршылый, озатып кала. Безнең якта үсүче агачлар да шактый монда, әлбәттә. Әллә кайлардан сәлам биреп, елмаеп кәефне күтәрүче, бөтен дөньяны, үзәнлекләрне, болыннарны тутырып үсүче, бу якларны искиткеч гүзәллеккә күмүче ләлә-кызалак, мәк чәчәкләре исә бай, юмарт табигатьнең үзгә бүләкләре. Тоташ кызылга «буялган» болыннар әле дә күз алдымда, күзләрне камаштыручы, зиһеннәрне чуалдыручы бу күренеш хәтерләрдән мәңге җуелмас, юылмас. Офыкта күкләр белән тоташучы, үзе бер серле галәм – биек, мәгърур, бар дөньяга билгеле Тянь-Шань таулары. Аннан инде Кытай чигенә дә ерак калмый. Очы-кырые күренмәгән мамык басуларында кечкенә балалардан алып олы яшьтәге апаларга кадәр зур осталык белән бу якларның ак алтынын – йомшак хәзинәне җыялар. Аны күзәтеп тору үзе бер хозурлык! Хәтер төпкелләремә менә шундый искиткеч гүзәл җир булып уелып калган балачагымның тәүге елларын үз сандыгында саклаучы бистә бу.

Студент елларымда, әле ул вакыт совет чоры, Красногорскка барып, балачагым калган урамнарны, болыннарны, күл тирәләрен кабаттан урадым. Хәзер, белүемчә, бистәдә хәлләр шәптән түгел икән, шахта ябылган, кешеләргә эш юк. Кем ничек көн күрә ала инде. Ирләрнең күбесе таулардагы кызыл ташларны кисеп, сатып яши икән – ягъни легальләштерелмәгән шөгыль белән мәшгуль. Бүген анда башлыча үзбәкләр генә яши, башка милләтнекеләр туксанынчы елларда кайсы кая таралышкан, теге әйтемдәге кебек: «Русские – в Рязань, татары – в Казань!»

## Сарлыма кайттым әле мин

Мәктәпләрдә укулар тәмамлангач, әти килеп мине Сарлыга алып китте. Самолёт белән очсак та, юл бигрәкләр дә ерак, вакыт озак уза тоелды. Тизрәк урам капкасын ачып кереп, ишегалдына мине каршыларга йөгереп чыккан әниемнең чәчемнән сыйпауларыннан эреп китәсе иде... Кайтып җиткәч, әниемнең кочагына чумып, сыенып утыруларым, төш кенә түгел микән бу дип үземне чеметеп карауларым, бергәләп елашканнарыбыз, көлешкәннәребез әле дә хәтеремдә. Мин кайтканчы әти йорт та күтәртеп куйган. Колхоз рәисе эшкә батыр механизаторга җирне дә бик тә гүзәл, матур урыннан – Ык буеннан биргән. Йорт җыйнак кына, гади бер авыл өе булса да, минем өчен аңардан да кадерлерәк, матуррак нигез юк: аның түбәсе астында без бөтенебез бергә! Бергәләшеп мүклисен мүкләп, сылыйсын сылап көзгә кергәнче эшләнәсе эшләрен бетердек. Утын агын да хәстәрләргә кирәк бит – авыл янында урман юк. Ат белән Ыкны кичеп, Башкортстан ягыннан кыш чыгарлык агач ташыйбыз. Җәйнең җылы көннәре инде артта калган, караңгы да тиз төшә, кире юлга кузгалганчы кояш баткан була. Ә кичен су да салкын. Елга агымының зәһәрлеге бөтен күзәнәкләреңә кадәр үтеп кереп өшетә, бер җебеңне дә калдырмый чылата, юешләтә. Авыр, ләкин барыбер күңелле. Бергәләп печән әзерләүләр, көтү көтүләр, бәрәңге бакчаларында эшләүләр – барысы да нык алҗытсалар да, күңелгә нindидер бер рәхәтлек бирәләр иде. Мин эшкә ярарга тырышам, әни яныннан китмим, ул нәрсә эшли, шуңа тотынган булам...

## Ходай боерды

Әэш авылда күп. Бакчабыз да хәйран зур. Алтмыш сутый! Монысы этинең Красногорскка мине алып китәргә әйләнеп кайткач, җизнәйгә сөйләгәненнән хәтердә калган. «Бажай, бар да яхшы, йорт күтәрдек, алтмыш сутый гына бакчабыз бар», – дигән иде. Шунда баһадир этием белән горурланып та куйган идем: йорт кадәр йортны күтәрә алсын әле! Сүзем бакча турында иде бит. Шул болын буе бакча берничәгә бүленгән. Аның иң зурысында, сыер, сарык абзары артындагысында, мине Үзбәкстаннан алып кайтканчы ук бәрәңге утыртканнар. Бәрәңге җиренең очы-кырые күренми. Бераз алгарак китеп, ничек бәрәңге алганны сөйлим әле. Сентябрь урталары иде. Ярдәмгә Башкортстаннан туганнар да кайтты. Ир-атлар казыйлар. Хатын-кызлар, балалар сабакны каккалап, суккалап башта бәрәңгене коябыз, аннары кечкенә өемнәр ясап киптерәбез дә капчыкларга тутырабыз. Әти: «Иртәгә яңгыр булырга охшаган, бүген ничек тә бетерергә кирәк», – дигәч, барысы да тагы да ашыгып эшләргә тотындылар. «Ашарга үзем пешерермен», – дигән кунак апа да өйгә кереп китүне онытты. Әни генә ара-тирә: «Нишләргә инде, кешеләрне дә ашатырга кирәк, бәрәңгене дә бетерәсе бар», – дип куйгалый. Дөрес, иртән ашап эшкә чыкканда, табагы белән кыстыбый һәм бидон тутырып сөт, катык чыгарып куйган иде ул, карыннары ачканнар тамак ялгый-ялгый эшләрләр дип. Алар да ашалып бетте. Әни бик каты борчылса да, мин генә кайгырмыйм, чөнки күптән хәйләсен таптым. Дөресрәге, бөтен кеше алдында әнине шатландырасы, үзем белән горурландырасы килде. Аның бер әйткәне гел колагымда. «Кызым бар бит минем, ярдәмчем, горурлыгым булыр, Алла боерса», – дигән иде ул. Бакчада тиз генә чиләгемне тутырам да, «мин хәзер», дип өйгә йөгерәм. Бер биш тапкыр шулай иткәнмендер. Абый түзмәде, кисәтү ясады. Әни дә сәерсенеп карап ала. Ә мин аларга игътибар итмим, үземнекен эшлим. Беренче керүемдә эшләрнең иң катлаулыларын башкардым. Карават астыннан үзем сыярлык иң зур кәстрүлне тартып чыгардым. Күтәреп булмый икән моны: бигрәк киң, ике тоткычын да берьюлы эләктереп булмый. Күп уйлап торырга вакыт юк, бер колагыннан тотып газ плитәсе янына кадәр сөйрәп алып бардым. Ике урындыкны янәшә куеп, берсенә менеп басып, икенчесенә кәстрүлне тартып менгездем. Аннары бер кулым белән бер тоткасын эләктереп, икенче кулым белән төбеннән алып газ плитәсенең кырыннан шуыштыра-шуыштыра өстенә кадәр күтәреп утырттым. Әни чистартып, әзерләп калдырган тавык та бик зур, аны да көч-хәл белән салдым кәстрүл төбенә. Аннары өсте күмелгәнче дип идәндәге бидоннан чүмечләп су ташыдым. Газ плитәсен кабызганда ярты кап шырпы бетте. Икенче кергәндә, тиз генә бәрәңге әрчедем. Өченче кергәндә, бәрәңгене ашка салдым да, күп итеп – бөтенесенә дә җитсен (!) – камыр бастым. Аны җәям, җәям, җәеп бетерә алмыйм. Куна тактасыннан да чыгып китеп, салынып ук төште. Нигәдер ябешә, ертыла да үзе. Әнинеке алай булмый торган иде, күпме карап торган бар... Ничек итсәм иттем, җәеп бетердем бит. Тизрәк, җайлырак булсын дип абыйның линейкасын алдым да шуңа тери-тери кистем дә чыктым. Калынрак булдылар кебек токмачларым, әнинеке нечкә була торган иде. Ярар, бөтенесенең дә ашыйсы нык килә, тамаклары туяр, тагы чыгасы бар бит әле эшләргә. Урындыкка басып, кәстерүлдән тавык белән бәрәңгеләрне алганда, чак кына урындыгым авып китмәде. Вакытында тураерга өлгердем – иң мөһиме беркайчан да югалып калмаска, үзеңне кулга алырга кирәклекне әнидән ишеткән бар иде. Аннары токмачларны кайнап торган шулпага салдым да йөгердем эшче халыкны ашарга дәшергә. «Керегез!» – дип кычкырам бакча башыннан ук, шатлыгымнан күкләргә очарга җилпенгән кош кебек.Әни куркуыннан кулындагы бәрәңгеле чиләген төшереп җибәрде, ярый әле аягына төшмәде: «Әй Ходаем, нәрсә булды?!» – ди. Башкалар да эшләрен ташлап, сагаеп миңа карыйлар. «Керегез тизрәк, токмачым куера!» диюемә бөтен бәрәңге бакчасы дәррәү көлә башлады. Шулхәтле халыкның берьюлы көлүеннән куркып, якында гына ял итеп утыручы каргалар көтүе кар-кар килеп күккә күтәрелде. Безнекеләрнең хор белән пырхылдавы авылның икенче башына кадәр ишетелде булса кирәк, ерактагырак бакчалардагы бәрәңге алучылар да безнең якка төртеп күрсәтә-күрсәтә нидер сөйләнеп калдылар... Токмачларым бик калын булса да, ашымны барысы да мактый-мактый ашадылар. Тозны гына салырга

онытканмын, анысын һәркем, күпме кирәк, үзе өстәде... Минем түбәм күккә генә тими. Әни шулай да сорамый булдыра алмады: «Кызым, ничек шулай башыңа килде?» – ди. Мин җитди генә: «Алла бабай боерды», – дип җавап бирдем.

## Казлар һәм бәбкәләр яки SOS

Ул җәйне миңа төп, даими эшемне дә ышанып тапшырдылар – Ык буенда каз, үрдәк бәбкәләрен саклау. Бик тә җаваплы вазифа икәнен дә бәйнә-бәйнә аңлаттылар: бәбкәләрнең берсен генә дә җуймаска, үтертмәскә, алар көзгә кадәр көр, матур булып үсеп җитәргә тиешләр. «Кышка кергәч, каз өмәләре уза, аның бөтен күрке казларның күплегендә һәм матурлыгында, кызым», – диде әнием һәм боларның бары да миннән торганын тәгаенләде. «Бигрәк тә каргалардан, тилгәннән сак булырга кирәк», – дип, абыем да зурларча үз киңәшен бирде. Бигрәкләр дә күп белә ул, шуңа да аны һәрчак тыңлыйм. Каз өмәләренең нәрсә икәнен төбенә кадәр аңлап бетермәсәм дә, аның гаҗәеп бер бәйрәм икәнлеген күзаллыйм, әлеге күренешне тизрәк үз күзем белән күрәсем килә. Тик әлегә бәбкәләрем бәбкәләр генә шул, шушы кечкенә томшыкларны каз итеп үстереп җиткерәсе бар! Аларны каравыллап кына утырмыйсың, әлбәттә, шундый ук максат-вазифа белән чирәмлеккә үз кош-кортларын алып төшкән яшьтәшләрем, зуррак, кечерәк кызлар, малайлар белән бар дөньяны онытып төрле уеннар да уйныйбыз, гөр киләбез. Мондый чакта төп ышаныч бәбкәләрнең әнкәләрендә, әткәләрендә: бигрәкләр дә уяу алар, без ярдәмчеләре генә. Берәр куркыныч туа башладымы, гаилә башлыклары шундый итеп ысылдый, канат кага башлыйлар, бирелгән сигналны ишетеп, без дә йөгереп киләбез... Килеп җитеп өлгермәгән чаклар да була. Берсендә иләмсез зур каргалар берьюлы берничә каз бәбкәсен урлап киттеләр. Безнекеләр барысы исән булса да, һавага очып менеп китүче каргалар авызында кечкенә бәбкәләрне күреп, аларны кызганудан елап җибәрдем. Бер бәбкәнең әнкәсе кычкыра-кычкыра, канатларын кага-кага алар артыннан чабып та карады, ләкин очып китә алмады шул... Төш җиткәч, абый әбәд алып килде. Өйдә, өстәл артында утырып ашауга караганда тәмлерәк икән саф һавада, күк гөмбәзе астында тамак ялгаулары...

## Марҗалык белән хушлашу

Шулай итеп, җәй дә узып китте, көз килеп җитте. Абыем Гайнетдин белән мәктәпкә җыенабыз. Мине башта, рус мәктәбеннән соң татар мәктәбендә алдырта алмас дип, кабат беренче сыйныфка гына кертмәкчеләр иде. Әни белән үз сүзебезне нык әйттек, каты тордык, бер генә адым да артка чигенмәдек: «Миңа бит инде сигез яшь, укый, яза, саный беләм! Нигә яңадан беренчеләр белән укып йөрергә тиеш ди мин?! Икенчегә алсагыз-алмасагыз да, икенче класслар белән укыячакмын, беренчеләр янына аягымны да атламаячакмын!» – дидем, үҗәтлегемне күрсәтеп. Аннары: «Мин бит марҗа түгел, татар кызы, сөйләшә дә беләм!» – дип тә өстәп куйдым. Үземне якларга, бирешмәскә өйрәткән иде шул мине Үзбәкстандагы үксез язмышым. Мине икенче сыйныфка кабул иттеләр. Дөрестән дә, җиңел булмады, Красногорскта русчага нинди авырлыклар белән кереп киткән булсам, монда инде, киресенчә, русчадан татарчага күчәр өчен кабат кискен борылыш ясарга, кыскасы, тагы икеләтә тырышырга кирәк. Рус теле, җыр дәресләрендә исә миңа тиңнәр юк. Хезмәт, физкультурада да «бишле» алам. Башка фәннәргә килгәндә, күп нәрсәне татарча аңлап бетермим. Шулай да туган тел күңелемә нигәдер бик газиз.

## Русча да, татарча да, һинд, чех телләрендә дә...

Мәктәптә концертлар оештырылганда, мин үзенә күрә бер табыш. Ник дигәндә, бернинди акцентсыз, тартынмыйча рус җырларын да сузам:

*Солнечный круг,*
*Небо вокруг...*

Шулай ук «Песня Красной шапочки», «Лесной олень»нарны да яратып башкарам.

Бигрәк тә укытучылар яратып кабул итә мондый чыгышларымны. Интернациональ рух көчле булган заман өчен бу бик тә мөһим. Ләкин минем күңел ул чакта ук күбрәк татар җырларына тартыла, грампластинкалардан, радиодан яңгыраган көйләр арасыннан моңлыракларын сайлап алам, әни белән әтинең «репертуарларыннан» да үземә ошаганнарын җыр сандыгыма салып барам. Илдә һинд җырлары популярлаша башлады, мин дә заманадан артка калмыйм, аларын да өйрәнәм. Алай гына да түгел, бераз алгарак та киттем: чех җырлары пластинкасы кулга төшеп, аннан да берничәне алдым. Шулай итеп баетам репертуарымны. Әти башта шәһәргә барып телевизор, аннары инде магнитофон да алып кайткач, эшләр бөтенләй худка китте. Бар булганым белән җыр дөньясына чумдым: *«Җыр канатлары безнең күңелдә...»*

## «Контр»лар була яздык яки акыллылык бәласе

Авылда заман техникалары иң беренчеләрдән булып безнең өйдә пәйда булды. Авыл яшьләренең, малайлар, кызларның җыйнаулашып телевизордан кино карарга килгәннәре дә истә. Кайсыберләре рәхмәттән тыш бакыр акчалар да калдырып китә, кем биш тиен, кем ике тиен. Шулай итеп, чак кына кинозалга да әверелмәде йортыбыз. Анысы ярый. Башларыбызны чак кына төрмәгә дә алып китмәде абыемның радиотехника белән артык җенләнүе. Берзаман ул радиодан төрле дулкыннарны тотып, чит илләрнең «Азатлык» радиосын да тыңлый башлады. Тора-бара безгә дуслары да ияләште, җыйнаулашып тыңлыйлар. Тыелганны үз колагың белән ишетү кызыграк бит. Болар ахыр чиктә бу дулкынны бөтен авыл ишетерлек итеп көйләделәр, тапшыруларны башкалар да тыңласын, имеш. Болай итүләре яхшы булды – һәркем үз өендә тыңласын, радиозал ачып булмас. Менә шулай «Азатлык» Сарлының һәр йортына үтеп керде, инде аны һәркем көтеп ала. Тик колхоз рәисе белән участковый гына бик каты пошаманда, бергәләп баш ваталар: кайсы йорттан җибәрелә икән бу куркыныч дулкыннар? Үзәккә ишетелгәнче ничек тә ачыкларга кирәк. Берсендә Гайнетдин абый дулкыннарны гомум радиочелтәргә тоташтырып йөргәндә, җырлый-җырлый әти кайтып керә, тракторы белән кемнеңдер бакчасын сөргән өчен бик каты сыйлаган булалар аны. Шулай итеп, радиоалгычлардан бөтен Сарлыга башта әти җырлап җибәрә, аннары аңа кушылып «Азатлык» сөйли башлый һәм идән асты радиостанциясенең авылдагы штаб адресы фаш ителә. Абый белән бик каты профилактик әңгәмә уздырыла, әтиләргә штраф салалар, Ходай кушып, эш зурга җибәрелми.

## Югарырак сыйныфларда

Ә йөзәргә мин барыбер өйрәндем. Дус кызым белән, ул да бик әллә ни йөзә белми икән, үҗәтләнә-үҗәтләнә, елганың иң авыр урыннарын сайлыйбыз. Берничә ел су юлын таптап, шактый нык остардык. Үземнән берничә яшькә өлкәнрәк Рүзилә исемле кыз белән инде. Ыкны аркылыга да чыгабыз, агымга каршы да йөзәбез, утрауларны да әйләнеп киләбез. Сашок дигән малай безне батырам дип куркытып йөргән булса, без хәзер аның үзеннән дә шәбрәк йөзәбез. Инде үзе бездән шүрли: безне күрсә, ерактанрак әйләнеп үтә торганга әйләнде. Моңарчы рәнҗеткәннәре өчен җавап кайтарырбыз дип шикләнә булса кирәк.

Мәктәп үзе бер кызык тормыш. Ике катлы бу белем йорты баскычларыннан көненә күпме менеп, күпме төшкәнбездер. Югары каттагы спортзалга йөгерә идек буш вакытларда. Мин физкультура дәресен яратам, ярышларда катнашып, грамоталар да алам. Йөгерү, граната ыргытуларда аеруча мактый иде физкультура укытучысы Фаяз абый. Гомумзачётка ату да керә. Менә анысын булдыра алмыйм, күпме туры төзәргә тырышсам да, «пуля»лар тыңламый. Тир мәктәпнең подвал өлешендә. Фаяз абыйның үзе белән дә төшеп тренировка ясап карыйбыз, юк инде. Күпмедер чиләнгәч, аңладык, күз ерактан начар күрә икән. Йөгерүдә төп көндәшем – Фәния Кәримова, үзебез дуслар да, бүген кем кемне узар, кайсыбыз беренче килер дип көлешәбез, ахырдан сөйләшми йөргән чаклар да була. Ахирәт дустым Тәслия белән беребез озынрак, икенчебез кечерәк буйлы булганга, безне «багана» белән «кәтүк» дип йөртәләр. Агылый белән тагылый кебек идек без, мәктәптә дә, уйнаганда да, зуррак үсеп яшүсмер кызлар булгач

та аерылышмадык, имтиханнарга да бергәләп әзерләндек. Зөфәр белән туебызда минем яктан шаһит тә ул булды. Мәктәпкә аерым гына бару юк, бөтен урамны гөрләтеп барабыз. Егетләребез чын джентльменнар, сумкаларыбызны күтәреп баралар. Рим, Фердинанд, Ленар, Наилләр башка чакларда да ярдәмгә киләбез дип кенә торалар. Югары сыйныфларда күрше авыл егетләреннән дә саклап йөрделәр. Дәресләр беткәч, без, активрак саналучылар, төрле түгәрәкләрдә катнашучылар, күп кенә җәмгыяви йөкләрне дә тартучылар, кайтып китәргә ашыкмыйбыз, яки кичкә таба, өйләребездә эшләр тәмамлангач, кире мәктәптә җыелабыз. Кызлар бергәләп еш кына спортзалда мәш киләбез. Соңыннан минем җырлауны сорыйлар. Мин яраткан көйләремне сузам:

*Кыр казлары артыннан*
*Биеклеккә тартылам...*

Мәктәбебезнең укытучылар коллективы бик көчле. Аларның һәрберсе һәр бала өчен җан ата, борчыла. Без аларны якын итеп, исемнәренә өстәп «абый», «апа» дип дәшәбез. Директор белән завучка гына әтиләре исемен кушып мөрәҗәгать итәбез. Класс җитәкчебез Хәдия апа һәрберебез турында энәсеннән җебенә кадәр белә. Без үзебез дә аның белән серләребезне бүлешәбез, киңәшләшәбез.

## Бигрәк гүзәл Ык буем

Безнең Сарлы җәннәт кебек бик гүзәл җирдә урнашкан. Вакыт тигәндә, дус кызлар, сыйныфташлар белән аның төрле почмакларына юл алабыз, тагы да матуррак урыннарын эзләп табабыз. Авылыбызның буеннан-буена борма-борма су юлы – Ык елгасы озатып кала. Бу матурлык белән туйганчы хозурланыгыз дигәндәй, табигать әнкәбез янәшәдә генә таулардан ансамбль да төзеп куйган. Әтеш тауга менеп Сарлыбызга, аның сөелеп туймас табигатенә тагы бер кат таң калабыз. Аннан Убалы тау, аның тирәсендәге иркен басулар да, Үчәлле буе агачлыгы да, заманында күпләп бур чыгарылган Бур тавы да матур пейзаж тудыралар. Әнә без рәхәтләнеп су керә торган Кара Яр. Ул ярым айга охшаган. «Ай»ның нәкъ урта бер җирендә озынча утрау. Анда су кереп арыган каз-үрдәк тә ял итәргә ярата. Ачылы төбәк тә бик ачык күренә биеклектән. Ул куаклар белән капланган, яз җитүгә үк су эчендә кала, су җәй уртасына кадәр китми. Шуңа да туфрагы сазлык җирләрдәге кебек ачы, дым яратучы үсентеләр өчен менә дигән урын. Без анда карлыган, балан, миләш, бөрлегән, шомырт җыярга да йөрибез. Монысы исә үз эченә берничә аланны сыендырган Бәешле! Ул Сарлыдан берничә чакрым ераклыкта, төньякка китебрәк урнашкан. Аның үз күле дә бар. Карлыган, кара бөрлегән, балан, шомырт үз җимешләрен монда мул бирә. Халык рәхәтләнеп печәнгә дә төшә бу җирләргә, өмәләр ясап күңелле итеп чабалар үләнне. Аучылар кышларын бирегә куян, төлке ауларга йөриләр. Пошилар да очрый аланнарда. Иңгереш болыннарына күз салсаң, анда көтүләр йөри... Гүзәл, бигрәкләр дә гүзәл минем авылым! Мондый чакта ничек инде җырламый түзәсең ди?!


*Үз илемдә ямьле миңа*
*Бәрәңге бакчасы да...*

## Изге Мәрҗәнә яки мәрхәмәтле әнием

Синең әниең гади хатын түгел, ул – изге Мәрҗәнә, шуны онытма, балам, дип бер авыл апасының урамда мине туктатып әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә. Башта мин, сабый бала, бу сүзләрнең мәгънәсен бөтенләй аңламадым, тора-бара күпмедер дәрәҗәдә төшендем. Ә бүген аның тормышын күзаллыйм да әниемнең, чыннан да, бу бөек исемгә лаек икәненә бар булганым белән инанам.

Әти әнине урлап алып кайткан. Беренче гаиләсе таркалгач, алда язып үткәнемчә, ике бала да бергә калмый. Гайнетдин сиңа охшаган дип, хатыны аңа кече абыйны биреп җибәрә. Балага ана тәрбиясе – яңа әни кирәк. Ләкин үги булса да, улына кырын карый торган булмасын. Шундый максат белән әти тирә-юнь авылларны урап

кайтырга ният кыла. Ык елгасының икенче ягында урнашкан Башкорт Урманаендагы бер танышы аңа авылларында бик тә ипле гаиләдә Мәрҗәнә исемле, күңеле мәрҗәнгә тиң шундый берәүнең барлыгын әйтә. «Тик риза булыр микән үзе, – ди ул. – Кемнәр генә яучы җибәрмәде бу йортка, йә әнисе, йә үзе ризалашмады. Яратып көткән егете сугыш кырында ятып калган иде, шуны да оныта алмый диләр. Яше дә бар инде аның, синнән олырак ул. Моңарчы кияүгә чыкмаганны, хәзер генә белмим, ай-һай, уңай җавап ала алырсың микән?! Ләкин күндерә алсаң, balaң өчен аңардан да яхшырак әни таба алмассың. Ак кәгазь кебек аның күңеле...» Әти башка кешеләрдән дә әни турында сораштыра, аның үзен дә читтән генә күзәтә. Баласына әни, үзенә хатын алып кайту максаты белән юлга чыккан ир, чыннан да әнидән дә яхшырагы булмас дип, тимерне кызуында сугарга була: танышыннан урамга чакырттырып чыгара да урлап алып китә. Инде утыз тугызын тутырган, дөньяның әчесен җитәрлек татырга өлгергән әни, нык ачуы килеп, башта качып кайтып китәргә дә уйлый. Ләкин кечкенә Гайнетдиннең күзләре белән очрашкач, йөрәге түрендә бу сабыйга карата җылылык хисләре уяна. «Күзенә карадым да, мин китеп барсам, тагы кемне алып кайтыр микән бу ир балага әни итеп, дип уйладым. Гайнетдин генә тотып калды мине. Үземнән яшь, артык чибәр, олпат гәүдәле Фазлетдиннең, беренчедән, мине яратып торырына да ышанмадым, аннары минем кияүгә чыгу инде уемда да юк иде», – дип, миңа да сөйләгән иде ул чираттагы ачылган, күңел түрендә җыелганнарын актарган мизгелләрнең берсендә.



*8 айлык Зәйнәб әнисе Мәрҗәнә белән*

Әнием тырышлыклары, булганлыклары белән тирә-юньдә дан тоткан гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Зур каралты-куралары, көтүләре белән маллары, умарталары була. Болар өстенә бабай чабыш атлары асрый, шәп нәселле, озын аяклы этләр тота, ауга йөри, аңа сунарчы буларак та тиңнәр табылмый. Колхозлаштыру башлангач, кулаклар дип, аларның бар мөлкәтен тартып алалар, соңгы капчык оннарына хәтле төяп алып чыгып китәләр. Бабайны цемент шахтасына сөрәләр, берничә елдан соң үпкәсенә цемент тузаны тулып, бик каты авырып киткәч, комиссовать итәләр, ул нигезенә кайтып егыла һәм озак та үтми бакыйлыкка китеп бара. Әбигә, балаларына нәрсәләр генә күрергә, кичерергә туры килми ул чорда. Бер уч он табып кереп, шуны су, төрле үләннәр белән бутап, пешереп ашаган чакларын да сөйли иде әни. Аннары сугыш башлана. Ул вакытта әнигә ундүрт яшь була. Унбиш яшьтән аны Ленинград өлкәсендәге торф җиренә эшкә җибәрәләр. Өч ел буе шунда бил бөгә ул. Бөтен авырлыкларга түзеп кенә калмый, әнисе, туганнары турында уйлап йөрәге әрни, аларга ярдәм итү юлларын эзли. Үзеннән кечерәк өч бертуганы өчен икенче әни дә бит әле ул. Паёкка бирелә торган спиртны җыеп барып, аны ситсыга, төрле кирәк-яракка алыштырып, өенә посылкалар җибәрә. Каты салкыннарда да туктамыйча, норма үтиләр. Өенә ул нык бетеренеп кайтып керә. Ләкин тырышлык, гыйлем белән бөтен нәрсәне җиңәргә күнеккән нәсел үзенекен итә, бирешергә ярамый – максат куйсаң, туган якның һәр валчыгы булышыр. Әби белән әни бергәләп гаиләне аякка бастырырга керешәләр. Авылда умарталык ачылачагын ишетеп, әни умарталык курсларын бетерә – әбиләр бит үзләре дә заманында умарта тотканнар. Бал – бөтен авыруларга каршы иң яхшы дәва. Мәрҗәнәсен шул юл белән генә саклап калып булуга инанган ана үз ихаталарында да кабат бу эшне торгызу максаты белән җиң сызганып эшкә тотына. Ихатада кечкенә генә булса да умарталык пәйда була. Гаилә балдан төрле төнәтмәләр ясап, авылның шактый кешесен төрле авырулардан коткарып кала. Киң карашлы әти-әни тәрбиясендә үскән укымышлы, гыйлем әби кызына карап шакката: кара әле, миннән дә күбрәк белә бит бу, Ходай ярдәм итәдер инде үзенә, дип фикер йөртә ул, Мәрҗәнәсенең игелекле гамәлләренә дүрт куллап фатиха бирә. Умарта умарта инде, җелекне колхоз

эше суыра. Сугыштан соң күмәк хуҗалыкны күтәрергә кирәк, анда эш тәүлек буена диярлек сузыла, ир-атның күбесе сугышта үлеп калган, әйләнеп кайтканы да кайсы кулсыз, кайсы аяксыз... Әни колхоз умарталыгында кайнашырга да, башка эшләргә дә өлгерә. Башлы дип хисапчы итеп тә куялар әле үзен. Менә шундый Мәрҗәнә килен булып төшә дә инде ул Азнакай районы Сарлы авылының Фәрхетдиновлар гаиләсенә. Әни үзен әти урлап киткәнче бер төш күргән була. Имеш, аның янына бер кыр казы очып килә дә аннары кечкенә кызга әверелә. Юраучы: «Кияүгә чыгарсың, кыз бала алып кайтырсың», – ди.

Әни Гайнетдин абыйны, җиде яшьлек сабыйны бер күрүдә үк ярата. Моны сизепме, бала да аңа тизияләшә. «Малайлар малайлар инде, кызларга караганда шуграк та булалар. Ләкин, үз әнкәсе булмагач, фикереңне бик тә нык итеп җиткерергә кирәк чагында да, сүзеңне сайлап, чамалап кына әйтәсең, бала күңелен җәрәхәтләүдән дә яманрак нәрсә юк, шуны беркайчан да истән чыгармаска тырыштым», – дип сөйли иде әнием инде үзе картаеп әби булгач. Ул Гайнетдин абыема һәрчак чын әни булырга омтылды, абыем да аңа үз итеп «әнием» дип кенә дәште. Өфедәге олы абый да әбиләргә еш кына кунакка кайткалый иде. Абыемнарның үз әниләренең (ул да Өфедә икенче тапкыр гаилә корган иде) гомере озын булмады, ул Сирин абый хәрби хезмәттә чакта вафат булды. Олы абый армиядән ялга туры безгә кайтты. Гайнетдин абый гына әнисе исән чакта аның белән бер генә тапкыр да очраша-күрешә алмады... Абыем бик күрсәтмәсә дә, мин аның әнисен ничек күрәсе килгәнен, аны сагынганын тоя, аңлый идем. Кайчакта бик боегып, уйга калып йөргәнен ул үзе дә яшерә алмады. Гитарада уйнап, моңланып җырлап утырган чакларында качып кына үземнең елаганнарым да булды. Көчле рухлы абыем булу белән гел горурлана идем. Әнигә дә ул бер генә тапкыр да авыз күтәреп каршы әйтмәде, күңелен җәрәхәтләмәде. Әнием дә язмышы болай да әче булган абыйга беркайчан да әче миләш тоттырмады.

Әни Сарлыда мин белгәннән бирле мәктәптә, күрше-тирә авыллардан килеп йөрүче укучы балалар яши торган интернатта ашарга пешерде. Ул эшкә иртә таңнан чыгып китә иде. Анда йөгергәнче әтигә, безгә дә табын әзерләп калдырырга кирәк бит әле. Әни – бик оста пешекче. Ул безнең як ризыкларын гына әзерләми, бөтенләй таныш түгел ят ашлар белән дә шаккатыра иде авылдашларын. Аның кебек үзбәк халык ашларын да җиренә җиткереп пешерүче юк Сарлыда. Кыскасы, аш-суны төрләндерергә бик тә ярата. Әни барына да җитешә. Балаларының, әтинең өс-башын карарга да, өйне җыештырырга да. Каралты-курада да, маллар янында да эш җитәрлек. Авылыбызда умартачылыкны җәелдереп җибәрүче дә әнием булды. Ул бу шөгыльнең үзенә күрә бер профессоры кебек, аның бөтен нечкәлекләренә кадәр белә. Әнием бал кортларын безне – балаларын яраткан кебек ярата. Аларның теленә хәтле аңлый. Кортлары да аны тыңлыйлар, әнине беркайчан да чакмыйлар. Салкыннарда ул аларны өйгә алып кереп тәрәзәләр куенына җибәрә. Ахырдан кортларын ничектер бик тә җайлы итеп, бик кадерләп кенә учларына алып җыя. Үзе аларга «бәгырьләрем», «матурларым», «баллыларым» кебек матур сүзләр белән дәшә, бар дөньясын онытып кортлары белән сөйләшә! Ул – кортларның дирижёры кебек. Аның алар белән кайнашуы үзе бер сәнгать! Әни үзе белгәннәрен башкалар белән дә бик теләп бүлеште, авылдашларын да умартачылык серләренә өйрәтте, аларга чын мәгънәсендә осталык дәресләре бирде.

Әниебез эшкә батыр булса да, күңеле артык йомшак иде. Миңа әйтәсе сүзен дә беркайчан да каты итеп, кистереп әйтмәде. Шулай итсәң яхшырак булмасмы, диебрәк бирә иде киңәшләрен. Тавыш, моң бирелгән булса да, җырларга бик һәвәс булмады. Әти баянда уйнап җырлаганда да күбрәк уйга батып тыңлады. Мин һөнәр сайлаганда җырчы булуыма каршы да килде әле. Ахырдан, чып-чынлап җырчы булып киткәч, минем өчен куанып бетә алмады. Зөфәрне дә бик яратты ул. Җәйләрен, хәл белергә кайткач, киявен таңда уятып, иртән сауган сөтләргә кадәр эчерә иде.

Әнкәемне яратуым шулкадәр көчле иде, репертуарымда да аналарга, бары тик аңа багышланган җырларым шактый урын алды. Беренче чиратта, ул кичергәннәрне чагылдырган, әниемне тасвирлаган җырларны эзләп таба, сайлап ала идем:

*Су өстендә үскән төнбоектай,*
*Карашларың, әнкәй, ник боек...*

Әнием 84енче яшендә, 2009 елның август аенда, минем туган көннән соң озак та тормый вафат булды. Ул җан биргәндә, кызганычка каршы, без гаиләбез белән Төркиядә ялда идек. Юлга чыкканчы янына кайтып килдек, хәле яхшы иде әле. Тугызынчы дистәсе белән барса да, үз аягында, ихатадагы эшләрне карап, умарталары янында кайнашып, баллар аертып йөрде. Төркиядән көн саен шалтыратам, хәлен белешеп торам, үзебезнең исән-саулыкны җиткерәм. Бер шалтыратуымда, сизәм, тавышы зәгыйфьрәк чыга. Әни, авырыйсыңмы әллә, дим. Суык кына тиде бугай, зарарлы түгел, ди әни. Аның белән сөйләшкәннән соң, шундук абый белән җиңгине җыйдым. Алар пошаманда. Кинәт кенә әллә нәрсә булды, диләр. Икенче көнне дә хәле яхшырмагач, хастаханәгә салырга булдык. Мин телефоннан Азнакайның башлыгы белән сөйләшеп, әнине яхшырак палатага яткырып, шәбрәк карауларын сорадым. Мансур Камаретдинович, рәхмәт яусын, кулыннан килгәннең барын да эшләде. Әни белән телефоннан сөйләшеп торам, ул, балам, борчылма, бар да яхшы булыр, ныклап начараеп китсәм, әйтермен, ди. Мин, болай булмый, кайтып китәргә кирәк, дип уйлыйм, килгәнебезгә дүрт көн узган иде. Ял итү кәефе бөтенләй юк, ул көнне дә үзебезнекеләргә ияреп кенә диңгезгә чыктым. Зөфәр һәм кече улыбыз йөзәргә суга кереп киттеләр, мин исә яр буенда – пляжда калдым. Уйларым гел әни турында. Бер мәлне барлык акылым белән фани дөньямнан нindидер бер бөтенләй башка киңлеккә чумдым. Әни белән ике арада моңарчы булмаган бәйләнеш барлыкка килде. Кабаттан фанилыкка әйләнеп кайтуга, күземә иң беренче булып күктә бик ерактан – минем якка таба бөркет кебек зур кош очып килгәне күренде. Кош канатларын ачык китап кебек киң итеп ачып җилпеп килә. Ул да булмады, якындагы агач ягыннан бер кошчык очып килеп чыкты, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй ачыргаланып, кычкырып баш өстемнән берничә кат әйләнде дә кабат юкка чыкты. Күктәге зур кошым да күренмәде. Минем йөрәгемнән, җанымнан шул мәлдә нәрсәдер өзелеп төште... Әнием, әнием, китеп барасыңмы әллә минем кайтканымны да көтмичә?! Күземнән яшь тамчылары тәгәрәде. Диңгездән Зөфәр белән Фоат чыкканда, мин шундый халәттә идем. «Әни инде исән түгел бугай, аның җаны килеп хушлашты минем белән», – дип үксеп аңлатырга да өлгермәдем, кесә телефоны шалтырады: әнием чыннан да мәңгегә күзен йомган.

*Очып килгәч, булып кош,*
*Әйткәнсеңдер: «Балам, хуш!»*
*Юксынамын, уйлыйм еш,*
*Синсез узар быел кыш.*

*Алып киттең. Хыянәт*
*Иттең миңа ник, җәем?!*
*Хәлең ничек, догалар*
*Көтәсеңдер, әнкәем.*

*Әрнеп елый, үкси күз,*
*Ничек яшим, әйт, синсез?!*
*Кемнәр көтәр өзелеп,*
*Авыр икән әнисез.*
*Ял күрмәдең, белмәдең*
*Җир йөзендә ник бераз?!*
*Оҗмахтамы урының? –*
*Анда, диләр, һәрчак яз.*

*Очып килгәч, булып кош,*
*Әйткәнсеңдер: «Балам, хуш!»*
*Сагнам, әнкәй, уйлыйм еш,*
*Синсез үтә тагы кыш...*
*Юк, юк,*
*Юк, үлмәгән, Әнкәй, югалмаган –*
*Суга гына киткән нибары...*

## Талантлы, матур, кырыс әтиебез

Әти, әтиебез... Мин аны зур итеп «ӘТИЕМ!» дип әйтә алмыйм, ул безнең белән параллель генә барды. Әнием белән яшәсә дә, ул аныкы гына һәм безнеке генә түгел иде. Әти, зинһар, кичер, боларны мин язмый булдыра алмыйм. Хәер, син үзең дә ялгышларыңны аңлап, Ходайдан гафу сорап, гомереңнең соңгы елларында дин юлына бастың. Мине дә дөрес аңла, мин бүген, үзем дә ир хатыны, ике бала анасы, әниемнең кичергәннәрен еллар узган саен тагы да ныграк аңлыйм, үземнең йөрәгем, бар күзәнәгем аша уздырам. Әни сине бәхилләп китте, без дә сине соңгы юлыңа бәхилләп, олылап озаттык. Туганнар белән җыелганда, җылы итеп искә алабыз, шулай ук юксынабыз, сагынабыз. Ләкин әниемнең күргәннәрен оныта алмыйм, гафу ит. Үзбәкстаннан да әни юкка гына мине, җаныннан өзелеп төшкән нарасыен ташлап, балалар ятим булмасын дип кайтып китмәде бит. Ике балаң ятим булу өстенә, чак кына мине дә ятим итмәгәнсең: авылга кайтуга ук башка хатын белән тора башлагансың. Әниебезнең батырлыгы мине, абыемны ятим итмәде, ләкин синең бу чираттагы хатаң җир йөзенә тагы бер үксезне тудырды. Ләлә сеңлем, аның гаебе юк, без кечкенә чакта бергә уйнадык, аралаштык. Ул безгә килеп йөрде, мин аларга бара идем. Бүген дә, Аллага шөкер, туганнар икәнебезне аңлап, багланышларны өзмибез... Әти, әниебез үлеп, төп йортта син берүзең калгач, ул күрше урамнан синең яныңа көн дә килеп, ашарларыңа пешереп, өйне җыештырып, сине – әтиебезне балаларча тәрбияләде, карады. Без аңа моның өчен бик рәхмәтле.

Әти үзе бик матур, олпат гәүдәле ир иде. Ходай аңа талантны бар яклап биргән: сыздырып баянда, Саратов гармунында уйный, оста итеп бии. Матрос биюен биегәндә аңа сокланмый мөмкин түгел. Ул Кырымда, диңгез ярында хезмәт иткән, бу биюне җиренә җиткереп башкара. Шулар өстенә, әтиебез искиткеч матур итеп җырлый. Артист булып китсә, һичшиксез, зур җырчы булыр иде. Аңа күбрәк авыл тематикасы якын булган, күрәсең, еш кына «Авыл» көен суза, аның башка тагын шундый моңлы җырларын яратып тыңлыйбыз. Шаян җырлары да шактый иде. Берсен әле дә искә төшерәм:

*Татарча: «Кая барасың?»,*
*Урысча: «Куда пойдёшь?»*
*Уйларыңны күп уйласаң,*
*Наверно, сума сойдёшь...*

Димәк, әти үзенең тормыш юлы хакында уйлап йөргән, тыштан гына сиздермәгән безгә.

Аңа җыр, биюгә булган сәләтләре нәселдән нәселгә күчеп килеп җиткән. Бабайның әтисе белән әнисе авылдан авылга йөреп җырлаучы чәчән артист булганнар. Әтинең әнисе мөнәҗәтләр әйтә иде, аның матур тавышын тыңлап утырырга ярата идем. Морза нәселе булган Баязит бабай Америкагага дүрт баласы белән китә – уллары белән. Кызларын бер гаиләдә яшереп калдыра. Яхшы вакытка кадәр сакла дип. Раскулачивание еллары. Ачлык еллары. Бабам да яшь чагында җырлаган, миңа аны күрү насыйп булмады, ул сугышның беренче айларында ук һәлак булып чит җирләрдә ятып кала..

Әти һәрчак эшкә дә батыр булды, гомер буе механизатор булып хезмәт куйды. Колхоз эшенә генә бер дә күңеле тартмады аның. Авылда беренчеләрдән булып нефтькә – геофизиклар оешмасына эшкә урнашты. Акчаны да яхшы алды, ләкин эчсә, холкы бик начар иде, андый чакта барыбызга да эләгә, әнине кул күтәреп тә рәнҗеткәләде.

Җырчы булырга фатиханы, алдарак әйткәнемчә, зурлап әти бирде, үсмер чагымда ук ул мине зур җырчы итеп күрде. Бәлки, үзенең чынга ашмаган хыялын минем аша күрергә теләгәндер. Ул миңа үз-үземә ышаныч уятырга ярдәм итте, моның өчен әтигә бүген дә чиксез рәхмәтлемен. Әти шул ук вакытта мин әнием кебек артык йомшак күңелле булмасын дип тә курка иде. Мин җырчы булгач, зур сәхнәләргә менгәч тә, репертуар сайлаганда, ул, җыр-моңга гашыйк кеше, әти буларак үзенең киңәшләрен һәрчак биреп килде. Халыкка нинди җыр кирәген, кайсы җырымны бигрәк тә яратып тыңлауларын иң әүвәл әнием һәм әтием әйтәләр иде.

## Абыйларым, туганнарым

Гайнетдин, Сирин абыйлар кебек бик тә якын туганнарым булуына мин Ходайга чиксез рәхмәтлемен. Язганымча, без кечкенәдән үк бергә үстек, шатлыкларны, кайгыларны бергә бүлештек. Бүген дә шулай. Абыйларым искиткеч талантлылар, җырлыйлар, төрле уен коралларында уйныйлар. Яшүсмер чакта ук вокаль-инструменталь ансамбль оештырып авылны гөрләттеләр. Миңа гына клубка чыгарга рөхсәт бирмәделәр: «Кызлар йөри торган җир түгел, башың яшь, вакыты җиткәч, өлгерерсең!» Аларның җырлаганнарын, уйнаганнарын карыйсым, клуб дигән сәнгать, җыр, моң диңгезенә чумасым, аның казанында кайныйсым килсә дә, олы абыйларга каршы килүне дә булдыра алмыйм. Ярамый! Олы туган – олы туган, аның сүзе һәрчак дөрес. Җырга, моңга һәвәс булсалар да, абыйларым зур сәхнәгә менүне максат итеп куймадылар. Гайнетдин абый, инде белгәнегезчә, кечкенәдән үк техника белән дә җенләнде, радиоалгычлар, телевизорлар сүтеп, җыеп ремонтлады. Башка төрле техниканы да. Кемнең нәрсәсе ватылган – аңардан беләбез: бөтен авыл аңа килә. Бу шөгыльләрнең барысы этидән күчкәндер дип уйлыйм, ул да бит тракторын, техниканы һәрчак үзе ремонтлады, шуңардан рәхәт тапты. Кече абыем туган якта төпләнеп калды, бүген Азнакайда яши. Азнакайга кайткан саен шуларда инде без. Гайнетдин абый үзе дә, Рүзилә җиңги дә, балалары да бик тырышлар, авылдагы йортка да күз-колак булып торалар. Туган нигездә бергәләп гөр киләбез, бакча эшләрен дә күмәкләп башкарабыз. Шулай күңеллерәк. Балалар да аралашып үсә.

Сирин абыйлар Себер якларында яшәделәр. Пенсиягә чыккач, балалары янына Казанга күченделәр. Мөнәвәрә җиңги дә аралашырга бик рәхәт кеше. Кунакка йөрешеп яшибез дию генә аз булыр, Сирин абый безнең иҗат төркеме белән илебезнең төрле почмакларын иңли, җырга мәхәббәт аны да труппабызга китерде.

## Мин – алдынгы сыер савучы

Унынчыдан соң классыбыз белән авылда, фермада эшләргә калдык. Күрше авыл мәктәпләрен тәмамлаучылар да бер ел сыер саудылар, терлек карадылар. Берничә авыл яшьләре үзара йөрешеп, клубларны гөрләтеп, ярыша-ярыша тырышып эшләп, көз, кыш узды, яз җитте. Сыер савучылар бәйгесендә икенче урын алып бүләкләндем. Шуның белән бу һөнәргә нокта куелды. Тулысынча класс белән бер ел колхозда эшләтү, яшьләрне читкә җибәрмәү ул чакта республикабызның барлык районнарында – авылны саклап калу сәясәте кысасында барлыкка килгән матур башлангыч иде. Чөнки әлеге бер еллык хезмәт чорыннан соң шактыеның бәхетне шәһәрдә, читтә табу планнары үзгәрә. Безнең класстан да авылда төпләнеп калучылар аз булмады. Кемдер гади колхозчы һөнәрен сайлады, кемдер читтән торып укырга керде.

## Табибмы, җырчымы?

Ә минем уйда бары Казан – укырга керергә! Кем булырга дигәндә, миндә, Такташ әйтмешли, ике «мин». Җырчы булыргамы, табибмы, тәгаен хәл итә алмыйм. Әни җырлап йөреп кенә тамагыңны туйдыра алырсыңмы икән дип борчыла. Әти белән рус теле укытучысы Роза Фәттаховна, киресенчә, талантыңны җуйма, җыр сине биеккә күтәрәчәк, диләр. Документларымны алып, Казанга юл тоттым. Барып җиткәч, Медицина институтына юнәлдем. Кабул итү комиссиясендә утыручы апа, нindидер справка җитми дип, мине кире борды. Сарлыга кайтып, ул кәгазьне юллап, кабаттан Казанга киттем. Автобуста карыйм: бер таныш кыз. Ул да укырга керергә документлар тапшырырга бара икән – Мәдәният институтына. Янәшә утырып, сөйләшә-сөйләшә башкалага барып җиткәч, мин дә аның белән исеме үк җанга якын булган вуз тирәсендә төшеп калдым. Документларымны кабул иттеләр. Тулай торакта гына урын юк икән. Анысына артык исем китмәде. Медицина институтында укучы авылдашым Римма белән әллә ничә ай элек үк сөйләшеп куелган бит, Казанга килеп төшүгә, туп-туры аның янына барам, дип. Адресы кесәмдә. Кешеләрдән нинди транспортка утырып, кайсы тукталышта төшәсен белешеп, киттем ул яши торган тулай торакны эзләп. Казан бигрәкләр дә зур икән. Зур калаларны моңарчы да күргән бар, шулай булса да, исем китеп барам.

Кечкенә чагымда, Үзбәкстанда яшәгәндә, әни белән дә, аннары туган апам белән дә, бистәбездән ерак булмагач, Ташкентка гел барып йөрдек. Әллә Ташкенттан да зуррак инде бу Казан?! Үзебезнең Сарлы мәктәбе укытучылары Өфегә дә еш алып баралар иде безне, экскурсиягә. Өфедән һичшиксез зуррак! Монда адашу да озак түгелдер... Адресны җуймасам, югалмам – әледән-әле кесәдәге дүрткә бөкләнгән кәгазьне барлыйм. Исән, Аллага шөкер! Тулай торакның ишеген ачып кергәндә, шәһәр урамнарына караңгылык иңә башлаган иде. Әй Ходаем, Римма берүк бүлмәсендә була күрсен! Вахтёр апа, күңелгә шикләр иңдереп, әйләнгеч тимер җайланмасын тормозга куйган, мине кертергә ашыкмый. Паспортымны сорый, кирәкмәс сораулар бирә: кем булам, нинди йомыш, максат белән? Төрмәдә дә шулай кыланмыйлардыр. Мин, иртә таңнан юлга кузгалып, күпме эшләр башкарып, бөтен Казанны гизеп, болай да арыган кыз, түзмәдем: «Нәрсә, апа җаным, Римма Габдрахманова шулхәтле секретный врач булырга укый мәллә?» – дим. Апам башта аңышмыйча, күзен зур итеп ачып миңа бераз карап торды, аннары шаркылдап көлеп җибәрде. «Әй, балам, бездә тәртипләр шундый инде, каян киләсең, арыгансың да бугай», – дип, бөтенләй йомшарып китте. «Азнакайдан ук, дөресе, аннан да ераграк авылдан, бер хәлем дә калмады», – дим инде. «Тукта, хәзер карыйм алайса, бүлмәсендә микән безнең кызыбыз», – дип, ул җөмләсен ахырга кадәр әйтергә дә өлгермәде, мин, аны бүлеп: «Юуук, апа, арысам да, ул хәтле үк түгел инде, бүлмәсенә җитәрлек кенә көчем бар, кайсы якка барырга икәнен генә әйтегез, сезне йөртмәм инде!» – дим. Апа көлүеннән бөгелеп үк төште: «Икенче катта яши, ләкин тулай торактамы, юкмы икәнен монда гына утырып та яхшы беләм», – ди бу, атылып чыккан яшьләрен сөртә-сөртә. «Әллә күзәтү камералары куйганнар инде бүлмәләргә?!» дигән уй йөгереп узды башымнан. Ярый бу сорауны үзенә бирмәдем әле, телемне тыеп кала алдым. «Менә хәзер карыйбыз, бүлмә ачкычы монда микән? Бәхетең бар икән, ачкычлары юк, димәк, бүлмәдә кемдер бар. Икенче катка менеп, сулга борылырсың», – дип, әйләнгеч җайланманы, ниһаять, хәрәкәткә китерде апабыз. Римма, бәхетемә каршы, гомуми кухнядан кичке ашын алып кереп килә иде. Мондый тәмле кыздырылган бәрәңгене беренче тапкыр ашадым. «Тулай торакта бәрәңге үзенчә тәмле ул», – дип көлә Римма. Табыннан торырга өлгермәдек, бүлмәгә авылдашымның төркемдәшләре, дуслары кереп тулды, чәй эчүне бергәләп дәвам иттек. Имтиханнарын бетереп, кем практикага, кем каникулга өенә җыенып, бер-берсе белән киләсе уку елына кадәр хушлашып йөрүләре икән. Берсе шул арада гитара да алып керде, аның җырына башкалар белән мин дә кушылдым. Медицина институтына керергә насыйп булмаса да, табиблыкка кандидат абитуриентлар, студентлар белән менә шулай аралашырга, гөрләшергә язды. Шунда: «Әй, табиблыкка бирәсе калган мәллә документларымны?» – дип әйтеп куйдым. Лилия исемле Казан кызы: «Без бары гади врач булачакбыз, ә син врачларның врачы, җырың, моңың белән яралы җаннарны, барлык чирләрне дәваларга сәләтле, яраларны бернинди скальпельсез төзәтүче табиб булачаксың... Их, синдәге тавыш булсамы миндә!» – дип, барлык икеләнүләремне юкка чыгарды.



*Легендар җырчы Әлфия Авзалова һәм хәләл җефете Зөфәр Билалов белән. Чаллы. 1995 ел*

Мәдәният институтында иҗади бәйгене җиңел уздым. Имтиханнарда тиешле балларны да бары ике фәнне: рус әдәбияты һәм белгечлек буенча сынауны биреп җыйдым. Калган предметларны тапшырып торырга кирәкмәде дә. Кабул итү комиссиясенең төгәл нәтиҗәләре булганны көтеп йөрдек әле аннары. Узганыңны белсәң дә, рәсми документ чыкмыйча – ректорның боерыгына кул куелмыйча, син студент түгел. Институтның стенасына эленгән булачак студентлар исемлегендә үземнең фамилиямне күрү минем өчен иң зур бәхет иде ул көнне. Урраа, Казан, мин синеке, исәнме, яңа тормыш!

*Истәлекләрне кәгазь битенә* **Гөлгенә КӘРИМОВА** *төшерде.*

# РУХЫҢ САУМЫ, МИЛЛӘТЕМ?

***– Татар халкы кайда гына сибелеп яшәми. Заман зилзиләләре аны төрлечә сыный, Чиләбе өлкәсенең бөтен тарихы татар дөньясы белән бәйле. Татарсыз чор беркайчан да булмаган монда, татар җәмгыяте гел яшәп торган. Язмышның бар ачысын татыган, «Чиләбедә чиләнгән» татар рухы бүген саумы?***



**Лена КОЛЕСНИКОВА,**
*Чиләбе өлкәсе татарлары конгрессы*
*Башкарма комитеты рәисе:*

– Татар дөньясын бүген Бөтендөнья татар конгрессыннан башка күз алдына китерүе кыен. Аның Урал татар җәмгыятенең яңарыш хәрәкәтенә йогынтысы да бәя биреп бетергесез.

Әйе, Чиләбе өлкәсенең бөтен тарихы татар дөньясы белән бәйле. Татарсыз чор беркайчан да булмаган монда, татар җәмгыяте гел яшәп торган. Чиләбедә XIX гасырда һәм XX йөз башында сәүдә, сәнәгать өлкәсендә танылган милләттәшләребезнең затлы архитектура үрнәге – сәүдә йортлары әле дә исән. 110-120 ел буе туктаусыз эшләп килгән мәчет һәм милли китапханәбез татарларга «сез – татар, сез – мөселман», дип искәртеп торган фактор булгандыр дип уйлыйм. Татар сәнгате, татар әдәбияты да гасырлар буе милли нур чәчкән. Татар үзешчән сәнгате совет елларында мәдәният йортларында ышык табып эшләп килгән һәм эшләп килә дә. ЧТЗ мәдәният сараенда күп еллар тамашачыларын сөендергән татар театры турында бүгенге көндә дә матур риваятьләр йөри.

Мондагы татар дөньясының тарихи үзәге – Троицк каласы. Исеме рус диненнән алынган булса да, аның урамнарында Тукай, Гафури, Зәйнулла ишан, Шиһабетдин Мәрҗани, Акмулла, Бабич, Габделбари Баттал, Габдрахман Сәгъди, Г.Газиз (Газиз Гобәйдуллин), Атилла Расих, Исхак һәм Исмәгыйль Иляловлар, Гамил Афзал, Сәрвәр Әдһәмова, Миңгали Надрюков, Мохтар Мутин, Сара Садыйкова, Бари Тарханов һәм тагын йөзләрчә танылган татарның эзләре бар.

Магнитогорски каласы – «Бөтенсоюз комсомол төзелеше» булып, илдән сөрелеп җыелган катнаш милләтләр конгломераты рәвешендә формалашса да, татар рухының тагын бер учагы ул. Халкыбызның иң талантлы композиторларының берсе Рафаил Бакировыбызның иҗаты нәкъ менә шунда чәчәк атты. Гамил Афзалны да хәтерли әле бу тимер-корыч шәһәр. Гамил аганың дусты, яшьтәше, шагыйрь Басыйр абый Рәфыйков бүгенге көндә Троицкта яши, әдәби очрашуларда яңа шигырьләрен укый. Мөсәгыйт абый Хәбибуллин да яшьли мондагы металлургия комбинатында берникадәр вакыт токарь булып эшләп киткән. Болар – җирле татар дөньясыннан үсеп чыккан яки формалашуына биредәге татар җәмгыяте йогынты ясаган талантлар.

Милли хәрәкәтнең яңа дулкыны узган гасырның сиксәненче еллары ахырында күтәрелде монда. Ул заманда өлкә милли мәдәният үзәге оешты. Дөнья кайнап торды.

Җир шарындагы татар дөньясының илһамланып, җанланып китүенә 1992 елның июнендә Казанда татар халкының беренче съезды җыелу һәм Бөтендөнья татар конгрессын оештыру турында карар кабул ителү сәбәп булды. Бу безнең Чиләбе өлкәсендәге эшчәнлегебезгә дә яңа көч, яңа күтәрелеш өстәп җибәрде. 1998 елның язында, өлкәбез төбәкләреннән татар делегатлары җыелып, Өлкә татар конгрессы оештырылды. 2002-2003 елларда узган «Чиләбе өлкәсендә Татарстан көннәре» һәм «Татарстанда Чиләбе өлкәсе көннәре» шушы абруйлы җирле Конгрессыбызның өлкә хакимияте һәм Бөтендөнья татар конгрессы белән бергә оештырган чарасы булды.

2009 елда исә, Конгрессның чираттагы съездында, Конгресс башкарма комитетының җитәкчесе дилбегәсен ышанып миңа тапшырдылар.

Төп максатыбыз татар рухын һәр татарның йөрәгенә җиткерү, татар милләтенең гүзәллеген бөтен гаммәви чаралар аша дөньяга киң һәм сокландыргыч итеп күрсәтеп тору, Татарстан, Казан һәм татар яшәгән бүтән төбәкләр белән тыгыз элемтәдә эшләүдән гыйбарәт иде. Бераз алга китеп әйтик: Чиләбе өлкәсе Татар конгрессының бүгенге көндәге уңышлары һәм югары абруе – нәкъ менә Татарстан белән, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты белән бергәләшеп эшләү нәтиҗәсе.

Чиләбедә һәм регионның берничә төбәгендә татар телен укыту курсларын ачып җибәрүдән һәм өлкә күләмендә (Чиләбе өлкәсендәге 43 төбәкнең берсе дә читтә калмый) ел саен уза торган «Җәлил укулары» бәйгесен, Тукай көннәрен оештырудан башлаган идек эшебезне. Тиздән шуңа «Хәзинә» исемле атналык телевизион тапшыруыбыз һәм шулай ук «Хәзинә» дип аталган айлык, 15 мең тираж белән чыга торган газетабыз өстәлде. Хәзер исә безнең тормышка ашырылган, әле дә дәвам иткән проектларны санап чыгу да кыен: «Озын толым», «Бишек җырлары», «Шәҗәрә», «Сабыйлар халык әкиятләрен рәсемгә төшерә» бәйгеләре... Бөтен татар (хәер, татар гына да түгел) кавемен шаккатырып сокландырганы – «Татар кызы» бәйгесе булды, әлбәттә. Берничә дистә татар кызының апрельдән сентябрьгә кадәр җырлау-бию-артистлык осталыгын күрсәтүен, спорт чаралары, авылда каз өмәләре үткәрүен, су ташу, печән эскертләү, өчпочмак, бәлеш һ.б. милли ризыклар әзерләвен, калфак, изү, беләзек чигү, татар теленнән, тарихыннан имтихан тоту һәм тагын күптөрле сынаулар аша үтүен телевидение, газета һәм интернет сайтлары аша бөтен өлкә күзәтеп торды. Бу бәйгенең төп мәгънәсе – примитив чибәрлек конкурсы түгел, ә кызларыбызның сәләтлелеге, рухи күркәмлеге аша милләтебезнең бөеклеген күрсәтү икәнен хәзер күпләр аңлый инде. Соңрак «Татар кызы»на аның сабыйлар варианты – «Нәни энҗеләр» өстәлде, хәзер исә, менә икенче ел рәттән инде, «Татар егете» дә уза.

Мәгълүм ки, «Татар кызы» хәзер Бөтенроссия, хәтта Халыкара конкурс дәрәҗәсенә кадәр үк үсеп җитте.

Татар кинофильмнары фестивале, районнарда берничә милли көрәш заллары ачып җибәрү, һәр ел саен, мәгариф министрлыгы белән берлектә, өлкә татар теле һәм әдәбияты олимпиадалары үткәрү, «Чиләбе өлкәсе татарлары энциклопедиясе» проекты өчен мәгълүмат туплау – болар барысы да Татарстан белән, Бөтендөнья татар конгрессы белән бергә, алар ярдәмендә алып барыла. Татарстан җитәкчеләре – министрлардан башлап Президентка кадәр – бездә еш була, ә Ринат Зиннур улы Закиров һәм БТК Башкарма комитеты әһелләре белән без көн саен элемтәдә.

БТК тәҗрибәсен үзләштерүдән туган тагын бер эш даирәбез – татар авыллары. Коншак, Үзбәгәрәк, Караболак, Арслан, Әптерәк, Әчлекүл, Әмин, Редутово, нугайбәкләр (Фершампенуаз, Париж) авылларына без бүләкләр төяп кенә түгел, ә үзебез дә чын татар рухын тояр өчен, татар һавасын сулау өчен барып йөрибез.

Бүгенге көндә Чиләбенең ике урамы Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемнәрен йөртә. Татар мәдәнияте сыйныфы эшләп килгән 81нче мәктәпкә дә Җәлил исеме бирелде, һәм анда Чулпан апа Җәлилова катнашы белән каһарман шагыйребезнең музеен да ачтык. Шәһәр уртасында, Пушкин урамындагы бакчада, Җәлилгә һәйкәл

дә куелды. Троицкида, Тукаебыз 1912 елда тукталган йортның диварында истәлек тактасы урнаштырдык. Быелгы «Татар кызы» һәм «Татар егете» бәйгеләренең туган якны өйрәнү этабы нәкъ менә Троицк каласында, аның XIX гасыр архитектурасына, мәчетләренә, иске сәүдә йортлары биналарына экскурсия һәм биредәге татар җәмгыятенең тарихына имтихан тоту формасында узды. Троицкиның беренче татар театрлары барлыкка килгән калаларыбызның берсе булуын истә тотып, егетләребез-кызларыбыз Г.Камалның «Беренче театр»ын сәхнәгә куйды. Ул көнне монда булган Г.Кариев исемендәге театр артистлары безнең спектакльгә югары бәя бирде.

Сабан туйлары хәзер, русларның Масленицасы кебек, һәр шәһәрдә-районда ел саен үткәрелә торган бәйрәм булып китте. Бер сыңар татар гына яшәгән урыс авылларында да шаулатып татар бәйрәмнәре уза. Ә менә моннан ике ел элек, БТК тәҗрибәсенә таянып, «Ак калфак» оешмасын булдыргач, һәм бу фидакарь хатын-кызларыбыз өлкәбезнең бөтен татар төбәкләрендә – Чиләбедә һәм Магнитогорскида, Златоустта һәм Миәстә, Копейскида һәм Троицкида, тагын берничә дистә шәһәрдә-авылда остаханәләр үткәреп чыккач, Конгрессыбызның абруе аеруча да үсеп китте кебек.

Соңгы елларда мондагы татар дөньясы җанланып китү генә түгел, шактый киңәйде дә. Күпләр «кем мин?» дип уйлану чорына керде.

Чиләбе өлкәсендәге 200 меңнән артык татар арасында «татар бәхете өчен мин җан атармын», дип торган шәхесләр күп: Ирек Сабиров, Сания Шевченко, Мәхмүт Шәрәфетдинов, Марат Канафин, Луиза Алмаева, Рәсимә Нашарова, Реда Кәбирова, Сәлимә Габидуллина, Валя Заһидуллина, Әлфира Усманова, Дамир Сафин, Искәндәр Шәмсетдинов, Рәүф Гыйззәтуллин, Рөстәм Вәлиев һәм тагын йөзләрчә милләттәшебез – шул токымнан.

Менә шулай, Бөтендөнья татар конгрессы белән бергә без дә алга атлыйбыз. Узган юлыбыз, һичсүзсез, вакыйгаларга һәм уңышларга бай. Әмма эш күп әле. Артыбыздан яшьләр килә, тәҗрибәбезне, уй-фикерләребезне аларга сеңдереп өлгерергә кирәк.

***– Ана телебездә белем һәм тәрбия бирү мәсьәләсе һәр чорда да актуаль һәм четерекле булды. Аеруча да Татарстаннан читтә яшәүче татарлар өчен. Бүген герой-шагыйрь Муса Җәлилне укыткан, тәрбияләгән Оренбург төбәге мәгарифе һәм педагогикасы нинди һава сулый? Милләт яшьләрен ничек үстерәсез?***



**Руслан ЗӘБИРОВ,**
*Оренбург региональ татар милли-мәдәни мохтәрияте рәисе:*

– Оренбург региональ татар милли-мәдәни мохтәриятенең тарихы 1989 елдан башланды, шул вакытта «Оренбург татар иҗтимагый үзәге» барлыкка килде. 1996 елдан ул «Оренбург шәһәре милли-мәдәни автономиясе» исемен йөртә башлады. Шул ук вакытта Оренбург өлкәсендә Орск, Богырыслан, Бозаулык, Сорочинск шәһәрләрендә һәм Татар Каргалысы белән Әсәкәй авылларында җирле татар иҗтимагый оешмалары барлыкка килә башлады.

1999 елда Шәһәр татар автономиясе әгъзалары инициативасы белән, район татар җәмгыяте вәкилләре катнашында «Оренбург региональ татар милли-мәдәни автономиясе (мохтәрияте)» оештырылды. 2013 елда аңа яңа исем бирелде: «Региональ иҗтимагый оешма «Оренбург татар милли-мәдәни автономиясе».

Бүген Оренбург региональ татар милли-мәдәни автономиясе – ул җирле татар милли-мәдәни автономияләреннән һәм иҗтимагый оешмалардан торган челтәр. Өлкәдә Абдуллин, Александровка, Әсәкәй, Матвеевка, Тоз-Түбә районнарында һәм Орск, Богырыслан, Оренбург шәһәрләрендә 8 иҗтимагый оешма эшли.

Оренбург региональ татар милли-мәдәни автономиясенең 25 еллык тарихы бар, аның үз структур бүлекчәләре төп юнәлешләр буенча эшли:

1. Этнокультура (татар) компонентлы мәктәпләрнең директорлары һәм укытучылары берләшмәләре.

2. Татар яшьләре берләшмәсе.

3. «Ак калфак» татар хатын-кызлары берләшмәсе.

4. Хәйриячеләр берләшмәсе.

Иң элек без заманча этнокультуралы (татар) мәгариф системасына игътибар итәбез. Безнең максат – татар теле укытылган мәктәпләрдә белем бирү сыйфатын күтәрү.

Оренбург региональ татар милли-мәдәни мохтарияте өлкәдәге татар этнокультура компонентлы мәктәпләр белән тыгыз бәйләнештә тора. Ел саен аларның директорлары һәм укучыларның ата-аналары белән очрашулар, татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен семинарлар оештырыла. Анда Оренбург өлкәсенең мәгариф, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыклары вәкилләре катнаша. Семинарларның максаты – иң шәп татар теле һәм әдәбияты укытучыларының тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату; инновацион методика алымнары, укыту технологияләре белән танышу.

Шушы көннәрдә Оренбургта «Татар мәгарифе көннәре» уза. Анда Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгыннан да вәкилләр катнаша.

Шулай ук ел дәвамында өлкәнең Региональ мәгарифне үстерү үзәге белән бергә татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен семинар-практикумнар оештырыла. Җирле татар иҗтимагый оешмаларында татар телен өйрәнү клублары эшләп килә. Андый клублар Оренбургта, Әсәкәй һәм Тоз-Түбә районнарында бар.

Һәр елны уза торган чараларның иң күңеллесе – «Җәлил укулары» дип аталган региональ шигырь укучылар конкурсы. Ул якташыбыз, каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көненә багышлана.

Анда 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәр балалар катнаша. Конкурсның тарихы ун ел элек башланды, ә биш ел элек ул региональ статус алды. Ел саен конкурста өлкәнең төрле төбәкләреннән 40тан артык укучы чыгыш ясый. 2016 елда бу чара Җәлилнең туган авылында – Мостафада уздырылды. Конкурста җиңүчеләр дипломнарга һәм акчалата бүләкләргә лаек була. Шулай ук Россиянең атказанган табибы Рамил Әхмәт улы Зәбиров исемендәге премия дә тапшырыла.

Ризаэтдин Фәхретдин әйткән: «Милләтләр югары күтәреләләр, түбән төшәләр, алга китәләр вә артта калалар, хуҗалык итәләр, хезмәтче булып йөриләр; шушы эшләрнең һәрберсендә асыл көч, төп сәбәп – яшьләрдәдер». Оренбургның татар милли-мәдәни автономиясе каршында инде икенче ел Татар яшьләре берләшмәсе эшләп килә. Биредә яшь активистлар җыела. 2016 елда Оренбург яшьләре «Аулак өй» дип аталган берничә чара уздырды. Анда алар татар халкының гореф-гадәтләрен, традицияләрен күрсәтте. Мәсәлән, «Татар туйлары», «Каз өмәсе» һ.б. Яшь активистлар ел дәвамында автономия уздырган чараларда волонтёрлар булып катнашалар. Димәк, киләчәгебез – ышанычлы кулларда.

Мәдәният һәр чорда хәйриячеләр ярдәмендә яшәп килде. Татар милли-мәдәни автономиясе бизнес вәкилләре белән элемтәләрне өзми. Бүген дә безгә автономиянең Хәйриячеләр берләшмәсе акчалата зур ярдәм күрсәтә. Ел дәвамында автономиядә 10-12 чара уза.

Ундүртенче ел рәттән «Ак хисләр» исемле халыкара конкурс-фестиваль оештырыла. Бу конкурс Әсәкәйдә Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре катнашында уза. Чара кысаларында конкурсантларга Татарстан педагоглары җыр һәм бию буенча мастер-класслар бирә. Әсәкәйдә шулай ук «Алтын көз» исемле балалар конкурс-фестивале дә үткәрелә.

Өлкә Сабан туе 2016 елда Әсәкәй районында узды. Шулай ук әлеге татар бәйрәме Тоз-Түбә шәһәрендә дә гөрләп үтте.

Оренбург татар милли-мәдәни автономиясе эшен төрле юнәлешләрдә алып бара. Күп проектлар – планнарда, аларны тиз арада эшкә ашырырга уйлыйбыз. Иң мөһиме – бездә үсешкә, активистларның санын арттырырга бөтен мөмкинлекләр дә бар. Булганны саклыйк, ишәйтик.

***– Әстерхан – бик борынгы, заманында ханлык мәркәзе, төркиләрнең төп сәүдә үзәкләренең берсе булган өлкә. Аны, табигый гүзәллегенә бәйле рәвештә, «Көньяк Венеция», дип тә йөртәләр. Мәскәүдән 1 400 чакрым ераклыкка «качып» сыенган, куенына йөздән артык милләт, үндүрт дини конфессияне сыендырган төбәктә милләттәшләребез үзләрен ничек хис итә?***



**Әнвәр АЛМАЕВ,**

*Әстерхан «Дуслык» татар милли-мәдәни оешмасы рәисе:*

– 1989 елда Әстерханда «Дуслык» татар милли-мәдәни оешмасына нигез салынды. Ул – Әстерхан өлкәсендәге рәсми рәвештә теркәлгән беренче милли оешма.

Оешманың төп максаты – татар милли мәдәниятен торгызу һәм үстерүгә, милли үзенчәлекләрне саклауга, татар милли бәйрәмнәрен, йола һәм гореф-гадәтләрен торгызуга, халыкның культура дәрәҗәсен арттыруга, халкыбызның элекке һәм хәзерге мәдәниятен белүгә нигезләнгән ватанпәрвәрлек хисен һәм югары әхлаклылык тәрбияләүгә ярдәм итү.

«Дуслык» җәмгыяте оешу белән, сиксән елга якын ябылып торган «Идел» татар газетасы 1990 елның августыннан яңадән чыга башлый. Ул мәдәни, әхлакый һәм иҗтимагый проблемаларны яктырта. Әстерхан татарларының тормышы, күренекле шәхесләре хакында яза. Мәктәп укучыларын һәм студентларны татар теленә якынайту максаты белән, «Тукай – минем йөрәгемдә», «Минем гаиләм» һ.б. иҗади бәйгеләр уздыра.

2002 елдан алып бу көнгә кадәр өлкә күләмендә беренче татар милли китапханәсе эшләп килә. Ул, татар авылларының мәктәп китапханәләре белән элемтәдә тора, аларга Казаннан килгән яңа китапларны тапшыра, татарларның иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы истәлекле даталарны билгеләп үтү, олуг татар шәхесләренә, шигърияткә бәйле әдәби һәм мәдәни кичәләр, «түгәрәк өстәл»ләр, китап күргәзмәләре уздыру кебек чаралар башкара. 2002-2005 елларда китапханәдә татар якшәмбе мәктәбе дә эшләп килде.

«Дуслык» татар милли-мәдәни оешмасы эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе булып татар халык бәйрәме Сабантуйны киң форматта уздыру тора. Әстерханда 2008, 2017 елларда Федераль Сабантуй бәйрәме узды. Хәзер бәйрәм 30 меңнән артык кешене җыя. «Нур», «Ялкын» кебек милли ансамбльләр югары дәрәҗәгә күтәрелде. Әстерхан татарлары өчен өлкә һәм Татарстан Республикасыннан килгән артистлар катнашында даими рәвештә төрле чаралар уздырыла.

Оешма каршында берлекнең «Дуслык» яшьләр бүлеге дә эшли. Ул оешма уздырган барлык чараларда да актив катнаша. Төрле кичәләр, мастер-класслар уздыра.


«Дуслык» оешмасы тарафыннан «Ел татарлары» һәм «Татар кызы» кебек проектлар да тормышка ашырыла. 2008 елда беренче тапкыр «Татар теле укытучысы» бәйгесе узды.

Әстерхан өлкәсендә бай тарихлы Татар халык драма театры эшли. Труппа өлкәнең Яшь тамашачылар театры, филармония кебек зур сәхнәләрдә спектакльләр, милли концертлар куя. 1998 елдан театрның репертуары киңәя, ел саен бер-ике яңа спектакль дөнья күрә.

2012 елда оештырылган «Көрәш» федерациясе дә зур нәтиҗәләргә ирешә башлады. Милли көрәш белән яшь буын бик теләп шөгыльләнә. Шулай да «Дуслык» милли татар оешмасының иң зур эшләре – Татарстан Республикасы белән багланышта Тукайга һәм Муса Җәлилгә куелган һәйкәлләр.

Әстерхан татарларына Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының ярдәме бәяләп бетергесез. Шул ук вакытта Әстерхан өлкә Думасындагы татар депутатлары да милли тормышыбызда зур роль уйный.

***– Бай традицияләре, үз-үзен саклау иммунитеты булган татар авылы... Бүген аның язмышы кем кулында? Гомер-гомергә милләтнең зыялы катламының төп өлеше авылларда тәрбияләнгән. Ульяновск өлкәсе татарлары да искәрмә түгелдер... Халкыбызның киләчәген тәрбияләүдә сезнең автономия нинди вазифа башкара?***



**Рамис САФИН,**
*Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясенең Башкарма комитеты рәисе:*

– Соңгы тапкыр халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, безнең Ульяновск өлкәсендә 150 меңнән артык татар кешесе гомер кичерә. Бүген татарлар барлык халыкның 12% ын алып тора. Өлкәбезнең 67 торак пунктында милләттәшләребез күмәкләшеп гомер кичерә. 1998 елда Россиядә иң беренчеләрдән булып өлкә татар милли-мәдәни автономиясе төзелде. Бүгенге көндә Өлкә законнар чыгару җыелышына һәм Шәһәр Думасына 9 кеше депутат булып сайланды. Төрле тармак буенча 14 милләттәшебез – профессор, 105 е фән кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә ия.

Хакимият, мәгариф һәм мәдәният органнарында татар халкының мәнфәгатьләрен Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе яклый. Аның Башкарма комитетында – 105 кеше. Соңгы елларда барлык муниципаль берәмлекләрдә дә милли-мәдәни автономиянең район советлары булдырылды. Алар, җирле район хакимияте белән уртак тел табып, нәтиҗәле эш алып бара.

Озакламый безнең автономия оешканга 20 ел тула. Шуңа күрә бүген ниндидер нәтиҗәләр ясарга да була, алга таба нинди эшләр башкарырга кирәклеге турында да уйланабыз. Мәгариф буенча горурланып сөйләрлек уңышларыбыз бар. 2004 елда Димитровград шәһәрендә татар мәктәбе ачылды. Узган ел аңа Г.Тукай исеме бирелде. Бүген анда укырга теләүчеләрне конкурс нигезендә кабул итү зарурлыгы турында уйланабыз. Мәктәптә урын җитмәгәнлектән, балаларның күбесе башка мәктәпләргә китә. Шунысы сөендерә: әлеге мәктәпне тәмамлаган укучыларның барысы да диярлек Казанда, Самарада, Ульяновскида һәм башка шәһәрләрдәге югары уку йортларына керә.

Гомумән алганда, ун ел элек татар теле өлкә мәктәпләрнең 25-30% ында өйрәнелсә, соңгы елларда ул мәгариф системасының яртысына диярлек үтеп керде. Бүген Ульяновск өлкәсе мәктәпләрендә белем алучы балаларның 50% тан артыгы (ун ел элек 32% иде) ана телен фән буларак яки факультативларда һәм түгәрәкләрдә өйрәнә. Кызганычка каршы, һәр төбәктәге кебек, бездә дә мәктәпләр һәм укучылар, шул исәптән татар милләтеннән булган балалар саны елдан-ел кими бара. Мәктәпләрдә акча бала санына карап бүленеп бирелә башлау да милли мәктәпләргә тискәре йогынты ясады. Шунлыктан, 2006 елда Ульяновск шәһәрендә ачылган татар мәктәбе быел янәшәдәге мәктәп белән берләштерелде. Авырлыклар аша булса да, мәгариф идарәсе белән уртак тел табып, без биредә татар телен дәрес буларак укытуны калдыра алдык. Хәзер бу мәктәптә татар, чуваш һәм мукшы балалары үз ана телләрендә белем ала. Монда һәр милләтнең үз мәдәни үзәге дә булдырылды. Без бүген биредә татар халкы музеена экспонатлар туплыйбыз.

Милли мәгариф системасындагы проблемалар һәм югалту турында сөйләгәндә, Россиянең һәр төбәгендәге кебек, милли тормышта кыенлыклар бездә дә җитәрлек. Гомумән, Татарстаннан читтә яшәүче татарларга бу илдә яшәү, милли мәгариф системасын җайга салу элек тә авыр булган, хәзер дә җиңел түгел, алга таба тагын да катлаулы булачак. Федераль мәгариф министрлыгы тарафыннан милли телләрне укытуны кысу бара. Төбәкләрдәге татар авылларында мәктәпләр ябылу безгә икеләтә авырлык тудыра. Чөнки татар авылында мәктәп ябылгач, андагы балаларны күршедәге рус яисә чуваш авылындагы мәктәпкә автобуслар белән йөртеп укыта башладылар. Ә анда мохит тә, тәрбия дә безнеке түгел инде.

Моннан берничә ел элек, федераль стандартка сылтау итеп, татар авылларында беренче классларда «Әлифба»ны укытмый башлаганнар иде. Безнең өлкәдә Бөтендөнья татар конгрессының күчмә утырышы вакытында без бу хакта Губернаторга җиткердек. Ул моны акылсызлык дип атады һәм мәгариф чиновникларына яңа уку елыннан әлеге хатаны төзәтергә күрсәтмә бирде. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан 500 данә һәм Бөтендөнья татар конгрессыннан 300дән артык «Әлифба» алып кайттык һәм татар авылларына тараттык.

Сер түгел, соңгы 20 елда татарлар яши торган авылларга Казан артистлары килми башлады. Хәзер, бу бушлыкны тутыру максатыннан, ай саен татар автономиясе, Татар мәдәният үзәге артистлары белән бергәләп, «Татар теле һәм сәнгате көннәре» уздыра. Авылдан без концерт куеп, күңел ачып кына кайтмыйбыз, ә милли тормышны җанландыру, андагы проблемалар хакында да сөйләшәбез. Чөнки бу чараларга район башлыкларын, мәдәният һәм мәгариф бүлеге җитәкчеләрен дә чакырабыз. Әле менә шундый чараларның берсе район башлыгы катнашында Павловка районы Татар Шмалагы авылында узды. Андагы китапханәгә татар китаплары соңгы тапкыр моннан 20 ел элек кайткан булган, акча юклыкка сылтау итеп, өлкәбезнең «Өмет» газетасына да язылмый башлаганнар. Сөйләшү барышында район башлыгы чиновникларына бу кимчелекләрне төзәтергә һәм матур әдәбият сатып алу өчен акча бүлеп бирергә кушты.

Моннан тугыз ел элек өлкәбездә ачылган Татар мәдәнияте үзәге дә халкыбызның гореф-гадәтләрен саклауда һәм үстерүдә зур роль уйный. Хәзер биредә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рамилә Сафина җитәкчелегендә 22 кеше (иҗади һәм техник хезмәткәрләр белән) өлкә бюджеты хисабына татар сәнгатенә хезмәт итә. Үзәктәге иҗат коллективларына 5 яшьтән алып 75 яшькә кадәрге үзешчәннәр йөри. Үзәкнең үзешчән сәнгать коллективларына йөрүчеләр саны 200 дән артып китте. Татарстанның атказанган артисты, Ульяновск өлкәсенең атказанган мәдәният хезмәткәре Әлфия Рамазанова җитәкләгән Мәдәни үзәктә балалар иҗатына аеруча зур игътибар бирелә. Гөлнара Вафина һәм Алсу Әлмәтова кебек үз эшенең осталары җитәкләгән музыка төркемнәренә дә сабыйлар яратып йөри. Алар шәһәребездә һәм өлкәбездә уза торган һәр чарада да актив катнаша. Ә узган елда Гөлнараның «Кыңгыраулар» дип аталган балалар төркеме, көнбатыш илләрендә уздырыла торган фестивальдә катнашып, дипломант исеменә лаек булды. Күпсанлы семберлеләр үтенече белән, мәдәният үзәгендә татар театр төркеме ачылу да безнең мәдәни тормышта зур вакыйга булды. Хәзер ел саен районнарда эшләүче татар халык театрлары өчен якташыбыз, Татарстанның атказанган артисты Бари Тарханов исемендәге өлкә театр фестивалендә катнашу зур мәртәбә булып тора.

Мәдәни үзәктә халкыбыз мәгарифенә һәм мәдәниятенә багышланган даими эшләүче һәм яңартылып торучы күргәзмә дә бирегә килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Ә узган ел, мәдният үзәге җитәкчесе Рамилә Сафина инициативасы белән, беренче тапкыр «Сембер сөлгесе» дигән гаҗәеп кызыклы күргәзмә эшләде. Анда авыллардан 80гә якын чигелгән сөлге китерделәр. Алар арасында XIX гасырда тукылганнары да бар иде.

Монда шулай ук өлкәбездә яшәп иҗат итүче рәссамнарыбызның эшләреннән торган күргәзмәләр дә оештырыла. Мәләкәс районы Мукшы Күле авылыннан Россиянең атказанган укытучысы Гыймран Хисмәтулловның «Тормыш мизгелләре» дигән шәхси күргәзмәсе халыкка аеруча ошады. Өлкәбездә тагын бер яңа проектка нигез салынды – беренче тапкыр Яңа Малыклы районында татар гармунчыларының «Уйна, Сембер гармуны!» дигән фестивале уздырылды. Анда 30дан артык гармунчы катнашты. Шунысы сөенечле: бу чарада балалар һәм яшүсмерләр дә зур активлык күрсәтте.

Узган ел, күпсанлы яшьләрнең һәм ата-аналарның үтенечен искә алып, Татар мәдәнияте үзәгендә үзебезнең йолаларыбыз һәм гореф-гадәтләребез нигезендә ЗАГСта язылуны татар телендә оештырдык.

Өлкәбездә уникаль, халыкның 96% татарлар булган Иске Кулаткы районы бар. Биредә 1932 елдан бирле татар телендә «Күмәк көч» газетасы чыга, үзләренең «Яңа

дулкын» дип аталган телеканаллары бар. Авыл мәктәпләрендә балалар татар теле һәм әдәбиятын укыйлар.

Халыкның милли үзаңын уятуда радио, телевидение һәм газеталарның роле әйтеп бетергесез зур. Моннан 28 ел элек өлкә телевидениесендә ул вакыттагы СССРда беренче булып милли булмаган төбәкләрнең берсендә – Ульяновск өлкәсендә татар телендә «Чишмә» һәм чуваш телендә «Ядкарь» дигән тапшырулар эфирга чыга башлады. Төрле сәбәпләр табып, аларны 18 елдан соң яптылар. Әлбәттә, халыкта бу зур ризасызлык тудырды. Шуңа күрә өлкәбезнең Губернаторы Сергей Морозов әлеге тапшыруларны башка каналда өлкә бюджеты хисабына яңадан чыгарырга дигән карарга кул куйды. Бүген әлеге тапшырулар аена ике тапкыр 20шәр минут тамашачыларны милли тормыш белән таныштырып бара. Өлкәбездә 1990 елдан бирле чыгып килүче «Өмет» газетасының да тиражы елдан-ел арта бара. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Исхак Хәлимов җитәкләгән бу редакция базасында соңгы елларда гына борынгы Сембер төбәгендә иҗат итүче татар язучыларының һәм шагыйрьләренең 90 нан артык китабы басылып чыкты. Бу эш бүген дә уңышлы гына дәвам итә. Ә узган ел исә без беренче тапкыр «Сембер-Ульяновск татарлары» дигән энциклопедия бастырып чыгардык. «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең бездә филиалы ачылу да татар тормышына яңа омтылыш бирде. Хәзер бездә узган чаралар турында көнсәгате белән бөтен дөньяда яшәүче милләттәшләребезне таныштыру мөмкинлеге бар. Моның өчен Татарстан Президентына һәм телерадиокомпания җитәкчелегенә зур рәхмәт! Аны Ульяновскида ачу инициативасы белән өлкәбезнең Губернаторы С.И.Морозов үзе чыккан иде, шунлыктан филиалны тоту чыгымнарының да шактый өлешен үзебезнең хөкүмәт үз өстенә алды.

Биш елдан бирле безнең өлкә Губернаторы каршында Милләтләр советы эшли. Анда өлкәбездәге һәр милли оешма җитәкчесе әгъза булып тора. Советның рәисе дә – Губернатор үзе. Өч айга бер тапкыр уза торган киңәшмәдә без, автономия җитәкчеләре, үзебезне борчыган барлык проблемалар хакында да әйтәбез. Барысы да булмаса да, мәсьәләләрнең байтагы иртәме-соңмы чишелеш таба.

2014 елда безнең Ульяновск өлкә татар автономиясен Федераль милли-мәдәни автономиясе Советы «Россиянең иң яхшы татар автономиясе» дип игълан итте һәм акчалата сертификат белән бүләкләде. Билгеле, бу безне тагын да тырышып эшләргә, яңа башлангычларга этәрә.

***– Җөмһүриятебездә милли хәрәкәтнең башлануына 30 еллап вакыт узган. Татарстанга терәлеп торган Чувашстан татарлары да вакыйгалар үзәгендә кайнады. Бүген әлеге төбәк халкынниләр борчый? Нинди максатлар белән яшисез?***



**Фәрит ГЫЙБАТДИНОВ,**
*Чувашстан татарларының милли-мәдәни мохтәрияте рәисе:*

– 2017 елда Чувашстанда татарларның милли яңарыш хәрәкәте башланганга – 30 ел, Татар иҗтимагый үзәге оешканга – 20 ел, милли-мәдәни мохтәрият төзелгәнгә 10 ел тула.

Безнең республикада бүген 36 мең татар яши. Аларның күпчелеге республиканың көньяк-көнчыгыш районнарындагы авылларда гомер итә. Шул ук вакытта шәһәрләрдә дә татар мәхәлләләре актив эшләп килә.

Чувашстандагы татар авылларында татар мәктәпләре, мәчет-мәдрәсәләр халыкка хезмәт күрсәтә. 2016 елда Урмай авылы мәктәбенең 150 еллыгын бик зурлап үткәрдек.

Милләттәшләребезне Республика татар милли-мәдәни автономиясе берләштерә. Аның тырышлыгы белән ике дистә елга якын авыл-шәһәрләрдә Сабантуйлар, төрле милли бәйгеләр, конкурс-фестивальләр, мәдәният хезмәткәрләре өчен укулар

оештырыла. Моннан тыш, Чувашстан татарларының «Мишәр» халык фольклор ансамбле Чувашстанда гына түгел, барлык татар дөньясында дан тота. Шулай ук 25 ел дәвамында төбәкара «Урмай моңы» татар эстрада җыры фестивале Чувашстан татарларын күп җирләргә танытты. Бүген Татарстанның күп кенә танылган җырчылары беренче чирканчыкны шушы бәйге аша алды. Хәзерге көндә Чувашстан татарлары тырышлыгы белән төрки халыкларның «Урмай – Зәлидә», югалган җәүһәрләребезне торгызу максатында, мөнәҗәтләр, дини җырларны үз эченә алган «ART MADHIA» фестивальләре, милли мирасны фәнни яктан өйрәнү максатында, төбәкара «Мирас» фәнни-гамәли конференцияләре уза.

Чувашстан татарларының Казан, Татарстан, Бөтендөнья татар конгрессы белән бәйләнеше бик тыгыз. Татар конгрессы Башкарма комитеты белән Чувашстан татар автономиясе берничә проектны бергәләп алып бара. Татар конгрессы оештырган күп кенә чараларның кунаклары Чувашстанга тәҗрибә алырга даими килеп тора.

Чувашстандагы татарлар бүгенге көндә бердәм. Күп кенә төбәкләр өчен үрнәк булып торалар. Чувашстандагы татарларның мәнфәгате Татарстанның, Бөтендөнья татар конгрессының милли сәясәтенә тулысынча туры килә.

Шулай да күпкырлы эшчәнлегебездә без тарихка азрак урын бирәбез сыман. Бүгенге көнгә кадәр Чувашстандагы татарларның тарихына багышланган саллы гына бер тарихи хезмәтебез дә, тарихны өйрәнүче галимнәребез дә юк. Бу эштә без Казанга гына таяна алабыз.

Шыгырдан, Урмай, Тукай, Чичкан, Бикшик кебек үсеп, зураеп барган авылларыбыз белән беррәттән, проблемалы авылларыбыз да бар. Балалар саны азаю сәбәпле, кечкенәрәк авылларыбызда мәктәпләр ябылды. Шунысы сөендерә: хәзер бу авылларга да яшьләр яңадан кайта башлады. Мәктәпләребезнең яңадан ачылуына да өмет бар. Милли хәрәкәт бу эшләрдә дә әйдәп бара.

Республика күләмендә чыга торган татарча газета, төрле фестивальләр, Сабантуйлар, бәйгеләр, татар дөньясына танылган фәнни конференцияләр, икътисади форумнар, Алтын Урда дәвере мәчет-мәдрәсәләренә охшатып төзелгән яңа гыйбадәт йортлары, авыллар арасында спорт ярышлары – барысы да милли хәрәкәт җимешләре.

1987 елда Урмай һәм Шыгырдан кебек зур татар авылларында картларның яңа мәчетләр төзү идеясе белән чыгуы Чувашстанда татар милли хәрәкәтенә этәргеч биргән иде.

Совет чорында республикада ике мәчет кенә эшләп килсә, хәзер аларның саны 50гә якын. Бу эшне картларыбыз башлап йөрде. Аннары милли яңарыш шаукымы башка өлкәләргә дә үтеп керде.

Тагын бер мәсьәлә калыкты бит әле. Ул – Милләт мәдәнияте йорты оештыру. Милләт мәдәнияте йорты – татарлар өчен яңалык түгел. Бу җәһәттән без Финляндиядәге татарларның «Мәхәллә йорты»н, Австралиядәге татарларның «Милләт йорты»н, Мәскәүдәге Асадуллаев йортын мисал итеп китерергә мөмкин. Әлеге йортның функциясе, беренче чиратта, милли методик үзәк ролен үтәү булса, икенче чиратта милли сәнгатьне, мирасны, мәдәниятне бергә туплау, аны пропагандалау. Шул максатта, анда музейлар оештырыла, әдәби салоннар ачыла, җыелышлар, конференцияләр уздырыла. Әнә Казандагы яһүдиләрнең гыйбадәт йорты – синагога бинасында урнашкан милли үзәк уңышлы гына эшләп килә.

Бүген Чувашстанда яшәүче татарлар милли, дини үсеш, мәдәни мирасны саклау җәһәтеннән шактый зур көч куя. Халкыбыз хәленнән килгәнчә татар мохите тудырырга омтыла, зур планнар корып, милли-дини мәнфәгатьләребезне саклау-яклау юнәлешендә эшли.

**Рамил ХАННАНОВ** *әзерләде.*

*Бөек Октябрь Социалистик Революциясенә быел 100 тула, Башкортстан Мәркәзи Шурасы корылганга да бу ел 100 тулды, атаклы шәхесебез Әхмәтзәки Вәлидигә быел 125 яшь тулган булыр иде, бу өч вакыйганы берләштергән Вәлидинең «Хатирәләр» китабы чыкканга быел 48 ел тула. Шушы өч бөек вакыйганы үз күзләре белән күргән, шушы вакыйгаларны кайнаткан, үзе дә шунда кайнаган сәясәтче, тарихчы-галим, каләм остасы З.Вәлидинең вафатына быел 47 ел тулды. Урыны җәннәттә булсын!*

*Китапны тәрҗемә иткәндә, мин «тюркский, төрки» кәлимәтләре (терминнары) урынына «түрк» сүзен кулландым, чөнки «төрек» сүзе «түрк»тән килеп чыкса да, ул аерым бер милләтне генә күз уңында тота, «түрк» дигәндә, без борынгы ташъязмалардагы бер телдә сөйләүче, бер йолаларда тәрбия алган төрле халыкларны, шул исәптән төрекләрне дә күз уңында тотабыз. Башкорт та, кыргыз да, татар да, төрек үзе дә – т ү р к ләбаса.*

*«Казах», «казакъ», «козак» сүзләре буталмасын өчен, күчмә халык казахлары, үзләре атаганча – «казакъ», Донские, Сибирские, казачьи отряды гаскәриләрен «козаклар» рәвешендә тәрҗемә ителде. Шулай ук казачий полкларда хезмәт итүче татар-башкортлар да «козаклар» дип алынды. Козак – ул милләт түгел, бары тик иҗтимагый катлам гына.*

*«Хатирәләр» Төркиядә төрекчә 1969 елда басыла, урыс телендә 1997 дә, башкорт телендә 1996 елда чыга, инде, ниһаять, бу китапны татарча да укый аласыз. Маҗаралар дөньясына чумасыгыз килсә, тизрәк укый башлагыз!*

**Рабит БАТУЛЛА**



Зәки
Вәлиди Туган

# ХАТИРӘЛӘР*

*Төркестан вә башка Көнчыгыш мөселман түркләренең милли яшәеше һәм культурасы өчен көрәше.*

## Алсүз

Бу хатирәләргә нигез булып яткан кульъязмаларым Төркестаннан Иранга чыгар алдыннан Бохараның Кабул шәһәрендәге илчелеге вә Мөхәммәдабадка китүче сәүдәгәрләр тырышлыгы белән 1923 елның башында чик аша узды. Берничә кыйммәтле документлар якташым Госман Токымбәт тарафыннан шул ук елда Финляндиягә чыгарылды. Төрле юллар белән читкә чыгарылган, шифрлап язылган кәгазьләр һәм документлар. 1943 елда Алманнарга әсир төшкән якташларыбыз белән берлектә бу

* Бу хатирәләремне дөньяга чыгаруда миңа ярдәм иткән сөекле хатыным Назмия Унгар Туганга багышлыйм.

язмалар Берлинда укылды вә алардан аеруча бик күп мәгълүмат алынды. Боларны Берлиндагы бөек илчебез, мәрхүм Саффәт Арикан бәй Төркиягә алып кайтты. 1957 елда Америкада Станфордта «Һоовер Хәрби китапханәсе»ндә сакланган һәм Ф.А.Керенский тарафыннан тупланган урысча чыккан гәзитәләр төпләмәләреннән, бу затның рөхсәте вә китапханә мөдире поляк, проф. В.С.Свораковскийның ярдәме илә киң файдаланылды. Берклей университетыннан мистер Ричард Пиерснең Русияга барып, бөртекләп-кадерләп җыйган Төркестан гәзитәләренең микрофильм тупламаларыннан нык файдаланылды. Бу шәхескә мин миннәтдарлыгымны (канәгать булуымны) әйтергә тиеш идем.

Алынган мәгълүматның дөреслегенә инаныр өчен, бу документлар Габделкадыйр Инан, Кожауглы Госман, Габдулла Таймас вә милләт өчен җантаучы Ширмәхмәт бәк вә кыргыз рәһбәре Парпи Хаҗи кебек көрәшләрдә катнашкан шәхесләргә дә укытылды.

Әсәрнең беренче караламасы 1924 елда Берлинда язылды, әмма кулай нашир табалмадым, шуңа күрә ул соңга калып чыкты. Ниһаять, бер көллият укучысы үзенең эшләп тапкан (җыеп барган) акчасын милли нәшриятка биргән, ләкин үзенең исемен матбугатта чыгармаска кушкан, бу китап аның акчасына чыкты. Китап Көнчыгыш Түрк шивәләре тәэсире илә язылган, нигездә, Төркия төрекчәсе аша күздән кичерү вә басма техникасының уңышлы булуын тәэмин итү кыенлыгын әдип һәм шагыйребез Орхан Шаик Гөк-яй үз өстенә алды. Һәр икесенә дә самими рәхмәтләремне ирештерәмен.

18 февраль, 1967 ел

## Яшьлегем

**Гаиләбез**

Уралларның вә Урта Азиянең соңгы йөз еллыгында бөек сәяси хәрәкәтләрдә, түрк милләтенең бик киң массасының коллыктан котылыш өчен көрәшләрендә рәһбәрлек итәчәгем, икенче яктан милләтләр арасы Шәрекъне өйрәнү мәйданында сүзе үтә торган абруйлы галим булачагым турында башыма да китермәс идем.

Урал тауларының Көньяк тарафында бер яны таулар вә урманнар, башка бер тарафы дала булган бер авылда мал асраучылык, бераз игенчелек вә урман эшләре белән көн күргән башкорт вә татарларның тулысы белән урта гасырда яшәгәннәре кебек, мин дә гади тормышлы, совет колхозы хуҗалыгында михнәт чиккән туганнарым сыман, гап-гади вә карусыз-буйсынучан бер авыл кешесе буларак яшәргә мәҗбүр ителгән булыр идем.

Шуның белән бергә тауда вә җәйләүләрдәге артык гади булып күренгән тормыш итүебез, бигрәк тә, халкыбызның тарихтагы могҗизалары турында бала чагымда ишетә белә идем, хатирәләрдә яшәгән кайтаваз, бу мохиттә яшәгәннәрне һәртөрле маҗараларга алып кереп китәчәк. Түрк вә Ислам галәменең бүгенгесе вә киләчәгенә кагылышлы планнар артына төшәргә мәҗбүр итәчәк. Бу язмам – тормышымның, халкымның эчендә яшәгән тарихи хатирәләрнең бер мантыйкый нәтиҗәсе буларак кабул ителсен. Бу вазгыятьне ачыкламак өчен, укучыларыма беренче карашка һичбер әһәмияте булмаган бәгъзе нечкәлекләрне аңлатуым кирәктер.

Татар, мишәр вә мөселман чувашлардан гыйбарәт булган авылыбызның асылын 30-40 йорттан артмаган хуҗалыклар тәшкил итә иде. Авылыбыз «соклыкай», «унгыт» исемле ике нәселдән тора.

Бу кабиләләр белән бераз танышмак өчен өстәп әйтим, башкортлар һәм башка түрк кабиләләре «з» вә «ч» авазлары урынына «д» вә «с» дип сөйлиләр, алар дүрт төркемгә бүленәләр:

1. Тау башкортлары (Бөрьян, Үсәргән, Тамьян). 2. Ялан (дала) башкортлары (Юрматы, Кудәй, Гайнә, Ирәкте, Янәй, Танып ыруглары). Бу ике төркем Милади елларның башыннан алып Уралларда яшәгән, дип уйланыла. Тау башкортлары «с» урынына «һ» авазын куллана, җәйләү башкортларының күбесе исә «тһ»

дип сөйләшә. Ләкин соңгылары көнбатыш вә төньякта яшәгәннәренең байтагы татарлашып беткән. 3. Өченче төркем исә төрле гасырлар дәвамында Көнчыгыштан килеп башкортларга кушылган кыпчак, каңлы, сувын, уран, кайлы, катай, байлар (баят), кәрәй (кераит), чураш, нугай, кыргыз, мәркит кебек ыруглар төркеменнән гыйбарәттер. Боларның башкортлар арасында урынлашканнары саф башкортча сөйләшә, Көнбатыш тарафларга җирләшкәннәренең күбесе татар теле шивәсе тәэсирендә калган. Бу өч төркем, белгәнебезчә, соңгы йөзьелларда барысы да башкорт гаскәрендә хезмәт итә иде. 4. Дүртенче төркем Көнбатыштан, Болгар вә Казан якларыннан, алары урыс гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителгәч, Башкортстанга күчеп килгән качаклар (яки типтәр, ягъни госманлыча – «дәфтәрле») татарлардан торган мишәр вә мөселман чувашлардыр. Көнбатыштан Казан ханлыгыннан килгән бу качакларны урыслар «Башкиры припущенники», ягъни «уртага алынган башкортлар» дип атаганнар.

Исемнәре аталган бу дүрт төркемнең беренче өчесе ярымкүчмә булып, киң туфракларга вә җәйләүләргә хуҗа иделәр вә алар бер кабиләгә оешкан иде; дүртенче төркем исә, борынгыдан бирле игенчелек белән шөгыльләнүче авыл кешеләре, кабиләнең тарихын, дастаннар вә йолаларны, гореф-гадәтләрне белмиләр иде.

Минем кабиләм «соклы-кайлар» исә өченче төркемдәгеләр булыр. Илле биш елдан бирле тарихчы галим саналганыма күрә, иң аз белгәнем мәүзугъ үз ыруымның тарихыдыр. Агыйдел елгасына коючы Игән ермагының бер тармагы янына урнашкан вә авылыбызның нигезен тәшкил иткән соклы-кай вә унгыт ыруглары 1800 елларда аталарыбыз Көзән вә Бакы хуҗа булган, ике калкулыкта вә Якуб коесы тирәли таралып утырган 12 каралты-курадан гыйбарәт иде. Унсигезенче йөз ел сугышларында болар бик күп югалтуларга дучар булган һәм туфрак кысыр калган, буш калган җирләргә соңыннан 1860 елда, атамның туган елында, патша хөкүмәте бездән тартып алынган җирләргә бик күп «Минзәлә мишәрләре» дип аталган Көнбатыш Башкортстандагы авыл кешеләрен китереп, аерым мәхәллә итеп урнаштыргач, авылыбыз кинәт зураеп киткән. Игән елгасы тармаклары янында утырган Әрмит, Үтәк вә Тугай исемендәге авыллар да XVIII йөз ахырларында башкорт авыллары бик кечкенә булган, Үтәк вә Төкен авыллары, Сәлим Үтәбаевның «Ядигәр» атлы әсәрендә язганына күрә, «Кече табын» кабиләсеннән, имеш. «Әрмит»ләрнең исеме «Әрбит» дип язылганына күрә, кайчандыр Көнбатыш Себер «төмән»нәренә баглы булгандыр дип уйлыйм, аларның кайсы кабиләләргә караганнарын мин белмим. Болар да үз җирләре тартып алынгач, Көнбатыш Башкортстаннан сөрелгән бу күчмә кабиләләргә җир бирелгән икән. Җирләре тартып алынганга күрә, «Көчек Солтан», «Морад Солтан» вә «Солтан Гәрәй» исемендәге баһадирлар идарәсендә, җирләрен кайтару өчен, халык Русиягә каршы баш күтәргән. Безнекеләр, «Көчек Солтан»ны бик хөрмәт иткәннәр, аның идарәсендә Көнчыгышта Табул сулыкларында Әркарагай, Көнчыгыш Уралда Ирәндек вә Чубаркүл дип аталган җирләрдә дә яшәгәннәр, язын эссе чакта Акбиек атлы тауларда җәйләгәннәр. Көчек Солтанның идарәсендәге кешеләр Кәмәлек, Кубань тарафларына күчеп киткән дә урыслар белән сугышып йөргән. Күршебез Катай башкортлары да безнекеләр белән дус булган, фәкать күрше авыллардагы «арлар» бу солтанны кабул итмәгәннәр. Бу арлар бездән кыз алып, кыз бирмәгәннәр; «көчек, эт» дип аталганнарына күрә, ар халкы «сезнең солтаныгыз эт-көчек икән» дип бездән көлә торганнар иде; без дә аларны: «җылан йоткан ар» дип үрти идек. Безнең башка аркадашларыбыз Көнчыгыш Уралдагы «Кучи», «Исмәгыйль» вә «Нугай» авыллары илә Юрматы олысында «Мукач» авылларында да яшиләр иде. Кучи вә Нугай авыллары әүвәлчә авылыбызның Көнчыгышында Игән елгасы буенда «Күчи Йорты» дип аталган җирдә иде, бездән ул тарафка киткәннәр, алар Уралга, Ирәндек тирәләренә күченә, безнекеләр исә үз урыннарында кала. Ләкин арадагы дуслыкны өзмиләр, дәвам итәләр. Акбиек җәйләүләренең Көнчыгыш тарафында «Бетерә» исемле бер елга бар. Тимәс авылына барганда, юл бу елга белән берничә тапкыр кисешә. Моннан 150 еллар элек берәүсе безнең авылдан Күчә авылына киткән ди, икенче берәү Күчәдән

безгә юл тоткан. Икесе дә кыз алырга йөриләр икән. Бу ике төркем, ике килен, юлда очрашкан ди. Бездән киткән килен озын юлда Бетерә елгасы аша хисапсыз кичүләрне кичә-кичә ана йортыннан ераклашкан саен алҗый икән, шуннан бу әйткән: бетерә-бетерә дип сөйлисез, бетмәс бетерә булырмы? дип елый башлаган. Күчәдән килүче килен дә: «Бетерә» елгасы кичүләре бетмәсен иде вә хәзер барачак Игән елгасында аны ниләр көтә икәне турында җылый-җылый җырлый икән: «Бетерәләр бетереп йөрәгем янса, гаҗәп, ялкынын Игән елгасының сулары сүндерерме?» 14 яшемдә чагымга Ирәндектәге Күчи вә Нугай авылларына берничә тапкыр барганым булды, иске дусларым вә апаларымда кунак булган идем, шунда мин без белгән «Мурадым» (Идегәй мирза углы Нурадин)ны язып алдым вә үз риваятьләребезгә өстәп куйган идем. Минем беренче эзләнүләрем-тикшеренүләремнең берсе шушы дастанга кагылышлы. Ул 1911 елда нәшер ителгән беренче мәкаләмдер. Безнең җылкыларыбыз яз башында, борынгы заманнан бирле, күнегелгән гадәт буенча Акбиек җәйләүләренә үз башларына көтүчесез китә торган булганнар. Күчәләрнең дә язның эссе көннәрендә җылкыларын алып, Акбиеккә китү гадәтләре булганлыгы турында алар җырлаган җырларны күчереп бирделәр. Бу җырларда шулай сөйләнә: «Акбиек кеби бер тауны Тәңре безгә бүз тирмә (кәҗә тиресеннән чатыр)лар корып, җәйләмәк өчен бирде. Аның (ияр салынмаган бияләре), тайлары утарга, ягъни бияләрне савар өчен тышаулардан азат булып, араннарда уйнаклап чабып (җылкычыларга) «безне корык кулланмыйча гына тотыгыз» дип үзләре араталарга керә икән. Ягъни мондагы һава (язын) эссе заманнарда бик салкынча булганга тайлар араннарга үзләре кереп, бәйләнмәгән килеш рәхәт чигә торган булганнар.

Бу җәйләү бездән (Көнчыгышта) бәлки йөз чакрым чамасы ераклыкта булгандыр. Ата-бабаларыбыз бер-берсеннән ерак арадагы җәйләү вә кышлакларда яшәгәннәр дә еракларда барган сугышларда һәлак булганнар. Бәгъзеләренең каберләре билгеле. Кайсы мәрхүм турында: ул «Кубаньда үлде», диләр иде. Ул – Төньяк Кавказның Кубань елгасыдыр. Башка бер бабабыз Төмәнгә, Мансилгә китеп, Урал тавының Көнчыгышында Чубаркүл исемле күл тирәсендә калмыклар вә урыслар белән сугышта шәһид китүе турында сөйлиләр иде. Картлардан олы агам Вәли мулла вә уңгытлардан Гүссам ага борынгы дастаннарны күп белә иде. Бу дастаннар Алтын Урда дәверенә кагылышлы шигъри хикәяләр иде (Идегәй, Җирәнчә, Исауглы Әмәт в.б.). Борынгы бабаларыбыздан бу дастаннарны бик яхшы белгән берәү (кабере авылыбыздан өч чакрым ераклыкта урнашкан Карлы бүләк дигән югары җәйләүдә), Аллабирде искә алына, моңа «Аллабирде Нугай» вә каберенә дә «Аллабирде гүре», диләр. Бабаларыбыз арасында озын буйлылар бар иде, дип сөйлиләр иде, Аллабирденең каберен атам ачып карады, чыннан да, гүр иясенең озын буйлы икәнен күреп хәйран калды һәм кабердә кылыч калдыклары да табылды. Аллабирде белән чордаш Нугай бәге нәселеннән Борнак бәк исемле кеше турында хатирәләр бар, Нөгеш елгасы якасында Акбиеккә якын бер җәйләү шуңа (нугай Борнакка) нисбәт ителә. Башка нугай бәкләре Кубань-су ягына күчкәч, бу Борнак илә Аллабирде монда калганнар. Эстәрлетамак шәһәрендәге голамә «Нугай угыллары» бар иде. Алар Нугай мирзалары нәселеннән, имеш. Боларның аталарыннан берсе «Аллабирде» каберлегенә җирләнгән, имеш. Атабызның вә агаларыбызның остазлары шулар икән. Алар безгә кунак булып киләләр иде, дин голамәсе әгъзалары булсалар да, алар хәмергә битараф түгел иде. Көзән угылларыннан булган бишенче буынның берсе Иштуган (шуннан минем нәсел исемем) бездән бик еракта, Кәмәлек дигән урында урысларга каршы сугышта һәлак булган. Авылыбызның әтрафында «Урыс үлгән» вә «Урыс кырылган», «Урыслар тар-мар ителгән җир» кебек атамалы урыннар бар, җир сөргәндә, корал калдыклары да табыла иде.

Боларның бөтенесе дә ыругыбызның башыннан кичкәннәренә кагылышлы риваятьләрдән гыйбарәт булуы минем зиһни өлгерүемә тәэсир иткәндер. Болар күрсәтәдер ки, минем ата-бабаларым күрше авыллардагы башкортлар белән чагыштырганда, хәрәкәтчән, күчеп йөри торган, сугышчан кабилә булган, безнеңчә

«Төбәк» дип аталган анайортыбыз «Игән буе» өлкәсе булуы белән бергә Акбиек җәйләүләре вә Көнчыгыш Башкортстандагы Ирәндек тирәсе дә аларның йортлары саналган, хайваннар илә бу тирәләрдә күчмә тормышта яшәгәннәр; ханнар, бәкләр вә мирзалар җитәкчелегендә Көнбатыш Себердә Мансил, Тубылда, Иркарагай, Көнбатыш Башкортстанда Кәмәлек, Төньяк Кавказда Кубань елгасы арасында булган бөтен сәяси вакыйгаларга катнашканнар; урысларга каршы орышканнары кеби, алар калмыклар белән дә сугышканнар. Күршебездәге кечкенә Калмык авылы халкы аталарыбыз белән берлектә, мөселман булмаган (будда) калмыкларына каршы сугышканнар, шуның нәтиҗәсендә алар хәзерге җирләренә килеп утырганнар. Ләкин өндәрләр (җитәкчеләр) буларак искә алынган кешеләрдән Көчек (Күчүк) Солтанның вә Борнак би, Аллабирде вә Көзән бәкләрнең кем булганнары мәгълүм түгел. Бары тик үсә төшкәч, урысча өйрәнеп, 1912 елда Уфа «Җир чикләү комиссиясе» архивында эшли башлагач кына вә Көнбатыш Себер тарихына кагылышлы русча әдәбият вә «Башкорт шәҗәрәләрен» өйрәнә башлаганнан соң гына, «Күчүк Солтан»ның Көнбатыш Себер ханы мәшһүр Күчем ханның XVII гасырда яшәгән Аблай Солтанның углы «Күчүк Солтан», Борнак вә Аллабирде биләрнең дә XVI йөзьелда яшәгән Нугай биләре булганлыгын, аталарыбызның, Күчүк Солтанның әмерендәге сугышчылары буларак, бу ханзадәләр вә аның кардәше Абага вә Кансуар Солтаннар белән берлектә Көнбатыш Себердә, Әстерхан вә Кубань тарафларында урысларга каршы сугышканнарын, шул сугышларда ганимәткә алынган маллар хисабына яшәүләре, бу ханзадәләрнең җирләре төрле тарафларда булганлыгын белдем. Көчек Солтанның 1663 елда бер башкорт биенә биргән төркчә фәрманы сакланган, ул Башкортстанның Гыйлемнәр академиясе «Тарих материаллары»нда 1943 елда нәшер ителде. Борынгы бабаларыбызның бу ханзадәнең сугышта катнашуы турында Аскар авылында яшәүче Һидаят Суфи атлы затның кулындагы шәҗәрәдә язылган. Борнак белән Аллабирде биләрнең безгә якын Мукас авылында бүген дә исән яшәүче торыннары «Нугай Юрматы»ларның шәҗәрәләре дә 1960 елда Башкортстандагы Гыйльми академиясе тарафыннан матбугатта бастырылды. Күчүк Солтанның 1664 елда урыслар белән сугышларда янында 6400 нугай сугышчысы булганлыгы *(Акты исторические IV, 331)* аңа буйсынган башкортларның «Күчүк хан ничек итеп мөстәкыйль бер дәүләт корса, без дә шулай ук азатлыкны кулга төшерер өчен сугышачакбыз», дигәне *(Дополнения к актам историческим)* урыс чыганакларында язылган. Гыйсъяннарда җитәкчелек иткәннәрдән «Солтан Мурад», бу «Күчүк Солтан»ның углы булып, Кырымга вә Истанбулга китеп, Төрек Солтанын күргән. Дагыстандагы сугышларда урыслар тарафыннан әсир ителеп, үлем җәзасына тартылган. «Солтан Гәрәй» дигәннәре «Күчүк Солтанның углы булып, урыслардан качып яткан заманнарда «Карасакал» вә «Шуна» кушаматларын йөрткән. Авылыбызга исем биргән бөек атабыз «Көзән Карт»ның кай заманнарда яшәгәнлеге билгеле түгел. Бары тик авылыбыз янындагы бер тау гына аның исемен йөртә. Бу Көзәннең торыннарыннан Айдак илә Чуракның Юрматы ыругы Тәлтим 42 би арасында, ягъни алар белән берлектә 1577 елда Эстәрле елгасы башында үзләренең җирләрен Сәет (Каргалы) татарларына сатканлыкларын белдергән антлашма кәгазенең төркчә вә урысча нөсхәләрнең фоторәсемнәре 1956 елда Башкортстанның Гыйлемнәр академиясе тарафыннан «Башкортстан тарихына кагылышлы материаллар» тезмәсендә төркчә дә, урысча да басылып чыкты. Җир вә нәсел шәҗәрәсенә кагылышлы хәбәрләр башка бер документлар арасында да бар иде. Агаларыбызга җитәкчелек кылган солтаннарыбызның исемнәре «Солтан Морад», «Бәхти Гәрәй», «Солтан Гәрәй» соңгы вакытларга чаклы безнең якта балаларга бик тә таныш һәм кадерле исемнәр була килде.

Ыругыбызның асылы Соклы-кай һәм тагын безгә якын Сәнәкле-кәй, Йөрәктау-кай, Таулы-кай төркемнәре кеби Кай яки Кайлы ыруының бер тармагыдыр. Бу ыругның хәзерге җирләребезгә килгәнче үк Көнчыгыш Уралның Ирәндек тирәләрендә

утырганнары риваять ителәдер. Кай (Кайлы) ыруының байтагы Көнбатыш Башкортстанда яши. Исәт елгасы якасындагы «Ялан Катай» вә безгә якын «Урман Катай» пеләмәләре хан заманнарында ук хәрби төркемнәр тәшкил иткән, XVII йөзьел башларыннан бирле тарихта күренгән «Катай кальгасы» («Катайский острог») вә «Кай-город» буларак мәгълүмдер. Авылыбызда башка бер ыруг Уңгыт пеләмәседер; бу кабилә Чыңгыз хан заманында «Ак-татар» исеме белән мәшһүр булган. Кай, Катай кабиләләренең карахитайлар дәверендә табын (кабилә исеме) вә уңгытларның исә моголлар дәверендә башкортларга килеп кушылганын фараз итәм. Катай кабиләсе, нигездә, чыңгызлы Шибан угыллары булганга күрә, Мавәраэннәһерне алганнан соң, аларны «Катай ханнары» дип йөрткәннәр. Бу хәбәрне XVI гасырда яшәгән Алман илчесе Һерберштейн язып калдырган. Атам үз авылының Көнбатышындагы башкорт авылларын бик яхшы белми иде. Бөтен бagланышлары аның Көнчыгыш башкортлары белән иде. Болар – Күчем хан вә угыллары заманында Русияга каршы бер сафта сугышканнарының нәтиҗәседер. Атам мине 14 яшемдә өйләндерде. Җаек елгасы буйларында яшәүче Тәңгәбир башкорты Хаҗи Мәхмәт Якшымбәтовның кызы минем хәләлем булды.

## Гаиләмнең мәдәни багланышлары

Мине әйләндереп алган мохитнең көнкүрешен мәдәният тарафыннан алып бакканда, нәселебездә гыйлемгә яки башка бер фәнгә омтылыш яки безнең нәселдән чыккан мәшһүр шәхесне күрмәссез. Шулай булса да, мәмләкәтебезнең зыялы даирәләре эчендә Соклы-кайларның роле зур. XIX йөзьелнең беренче яртысында олы бабам Вәлид байның өе тирә-якгагы зыялыларның җыелу урыны булган, бу йорт гомум сый мәҗлесләренең мәркәзе вазифаларын үтәгән, башкорт кантоны рәисләре, урыс генераллары, губернаторлар, олы муллалар вә танылган шәхесләр дә бу мәркәздә олы кунак булган. Өебездәге иске кымыз савыты илә бераз искергән келәмнең йорт хуҗасына (алтынчы буын вәкиленә) бер бай тарафыннан бүләк ителгәнлеге турында гел сөйлиләр иде.

**Ата-бабаларымның сугыш турындагы хатирәләре**

Гаиләбездә дуслык мөнәсәбәтләрендә булганнарның күбесе – ата-бабаларыбыз белән берлектә әүвәлге башкорт гаскәрендә хезмәт иткән кешеләрдер. Боларның башында авылыбыздан алты чакрым ераклыкта урнашкан Макар авылыннан Кармыш угылларыдыр, Алакуян авылыннан Качкын бай угыллары килә торган иде. Качкын бай углы Шәмсетдин мулла илә олы агам Вәли мулла урдада (гаскәрдә) баш офицер буларак бергә хезмәт иткән. Кармыш нәселеннән Гомәр хаҗи исемле олы яшьтәге берәү Кантон рәисе иде. Вәли мулланың вә атамның дусты бу гаиләгә якын мөгаллим вә офицерлар безнең милли хәрәкәтебездә вә урдабыз (гаскәребез) дә иң алгы сафларда сугыштылар. Кармыш нәселеннән майор дәрәҗәсендәге Йосыф Карамышев исемендәге бер субай (офицер) чыккан. Халкыбыз Йосыф майорга багышлап җырлар чыгарган, шул җырларны җырлап, үзләре дә ләззәт алып, башкаларга да ләззәт тараткан. Бу җырларның ноталарын Рудаков вә аркадашым, мәрхүм доктор Таган вә профессор Янский Вена каласында Гыйлемнәр академиясе нәшриятында чыгардылар. Хәрби хезмәттә булу сәбәпле, бу гаиләләрдән урысча белүчеләр дә чыкты. Вәли мулла – шундыйлардан. Хәрби хезмәттән алда ул мәдрәсә тәмамлаган. Вәли мулла хәрби хезмәттә булып, Сыр-Дәрья елгасы буйларында хезмәт иткән, атам Дагыстанда хезмәт иткәндә, гарәпчә, фарсыча яхшы өйрәнү форсатын ычкындырмаган. Вәли мулланың гарәпчә-фарсыча язган әсәрләре бар, мин дә, бик яшь булганыма күрә, бары тик Идегәй, Җирәнчә, Иса углы Әмәт кеби төркчә милли-тарихи дастаннарны гына өйрәнә алдым. Атам Кавказда Шәех Шамилнең штабы урнашкан Гуниб авылында хезмәт иткәндә, шәехнең кәтибе (секретаре) Дибр әл-һинди исемле бер галим зат белән таныша, аның белән 1905 инкыйлабына чаклы гарәпчә хатлар алыша. Агамның да, атамның да гарәпчәсе бик яхшы иде. Атамның хәрби хезмәте бетерелгәч, Дагыстанда бер елга

калып, гарәпчә өйрәнүен дәвам итә. Олы агам Вәли янына һәр елны Гомәр Акай исемле бер дагыстанлының килгәне вә агамның угылларына (шул чираттан, Вәли муллага) гарәпчә вә фарсыча дәресләр биргәне мәгълүм.

1860 елга чаклы башкорт гаскәрендә, урыс хәрби бүлекләрендә хезмәт иткән вә хәрби мәктәпләрдә урысча белем алган башкортлар арасында урыс мәдәниятенә тартылыш күренми. Йосыф майор шикелле субайлар хезмәт тышында авылга кайткач, хәрби киемнәрен салып ташлыйлар, урыс музыкасы вә җырлары белән кызыксынмыйлар, үз итмиләр, бию һәм урысча уеннарга катнашмыйлар иде. Кармыш угылларының өйләрендә Көнбатыш вә урыс мәдәниятенә кагылышлы һичнәрсә юк. Өй вә каралты-кураларын бары тик Сыр-Дәрья буйларындагы кебек, Төркестан ысулы белән җиһазлыйлар иде. Совет дәверендә бастырган әсәрләрендә бәгъзе башкорт тарихчылары төркләргә урысның уңай йогынты ясавы турында шапырыналар. Бу бары тик урыс басымы астындагы күренеш кенә. Дөрес, һичшиксез, урыс заман техникасында өстен, ә мәгънәви мәдәният һәм рухи культура ноктасыннан караганда, башка мөселманнар кеби, башкортларның өстенлеге дә гомуми вә катгый бер дөреслектер. Арабызда сатучы яки тимерче-фәлән булып эшләүче урыслар телебезне бик тиз өйрәнеп алалар иде яки аларның балалары исламият йогынтысында яши башлый һәм урыслар тарафыннан тыелган булуга карамастан, Исламны кабул итәләр иде. Урыслар башкортларның тормышын оригиналь рәвештә кабул итүе турында язучылар да бар иде. XIX йөзьел уртасында Орынбур гаскәренең башлыгы, поляк чыгышлы генерал Циолковский да Макар авылында Йосыф майор йортында кунак булган чакта башкорт тормышының оригинальлеге, башкорт музыкасын бик ошатуы турында сөйли һәм башкортларга үз йолаларын сакларга куша. Бер заманнар Төркиядә яшәүче төрек зыялылары да Көнбатыш культурасына табына иде. Төрек зыялыларының берсе Фатих Солтан Мәхмәт Аурупа, аеруча Италия Ренессансына гашыйк булган, имеш. Ләкин бу хакыйкатькә туры килми. Фатих Ислам мәдәниятенең бер асыл вәкиле буларак, Ауропадагыларга өстән карый һәм үз мәдәниятенә гашыйк кеше буларак, аның белән горурланган. XVIII-XIX йөзләрдә урыс культурасының мохите белән теләр-теләмәс элемтәгә кергән башкорт укымышлылары шул ук хәлдә иде, чыгышлары белән Урта Азияле буларак, үз культураларын саклыйлар һәм моның белән горурланалар иде.

**Бохара-Хива муллалары**

Гаиләбез муллалар белән бик күп кайнаша иде. Эстәрлетамактан Нугай нәселле Шәрәфетдин белән Кәмал, Сәйран авылыннан Әпсәләм вә аның углы Бикбулат мулла, Юмагуҗа авылыннан Солтан Гәрәй, Коншак авылыннан Галләм, Эстәрлебаштан Нигъмәтулла белән Зәйнулла, көньяк Урал Муллакай авылыннан Сәет углы Габдулла, Колбактыдан Ханнан вә Троицкидан мәшһүр Зәйнулла Ишан исемлекнең иң башында торалар. Болар – гарәпчә, фарсыча яхшы белүчеләр, диндә галим кешеләр, мәдрәсә тотучылар, китап укучылар, Бохараның Накшбәнди тарикате (җәмгыяте) әгъзалары. Вәли мулла да, атам да надан муллалар белән аралашмаска тырыша иде. Бу шәехләрнең иң галиме Троицкида яшәүче Зәйнулла белән Муллакай Габдулла иде. Бохарада белем алган Габдулла дин гыйлемендә зур абруй казанган, гарәпчә-фарсыча шигырь иҗат итүче олуг остаз иде. Ул – суфыйчылыкта Һиндстандагы Мөҗәддид-и Халиди оешмасының Накышбәнди тарикате әгъзасы. Бу шәхесләрнең мәдрәсәләре дә, мәсәлән, Казан тарафындагы Кышкар вә Түнтәр муллалары вә башкорт илендәге «Ишаннар» исемендәге мәдрәсәләр кебек, Бохара, Хорезм ысуллы мәдрәсәләре. Бу шәхесләр кадимчеләр (фанатик) түгел, алар сәясәт өлкәсеннән дә хәбәрдар, зиһенле адәмнәр иде.

**Гариф Сәйрани белән Хызыр мулла**

Безнең гаиләгә иң нык йогынты ясаган кешеләр Эстәрлетамакта яшәүче Нугай нәселле муллалар булды. Алар үзләрен Кырымнан күчеп килгән Нугай Уйбакты мирза нәселеннән дип саный. Казанлы Курсави, Мәрҗани, Көнбатыш Себерле Чардаклы Хәким кебек галимнәр Бохара белән һәрвакыт элемтәдә тора иде.

Сәясәттә үз карашлары да бар иде. Агам Вәли мулла белән атам да – шуларның мәдрәсәсендә белем алган кешеләр. Болар арасыннан кайбер фикер ияләре дә чыккан, алар математика, тарих фәннәренә җентекле игътибар биргән. Нугаевлар нәселе мәдрәсәләрендә укып чыккан шәхесләребездән күршебездәге Сәйран авылы кешесе, исеме телгә алынган Бикбулат мулланың ир кардәше Гариф Сәйранидыр. Бу зат Корыч авылыннан Катай угылларыннан Низаметдин илә берлектә Нугаевлар мәдрәсәсендә укыган чакта Казанлы Мәрҗанинең исламият турындагы яңа фикерләреннән канатланып, ул заманга күрә, «модерн» төшенчәсен йөрткән «әл-Тарикат әл-мутхла» исемендәге әсәреннән илһам алып, математика вә фәлсәфә белән кызыксына башлый вә бу юлда белемен арттыру максаты белән, узган йөзьелның беренче яртысында Бохарага китә. Әмма бу фәннәрнең артта калганлыгын күреп, аның кәефе кырыла. Минем атама Сәйрани бүләк итеп җибәргән китапның исеме «Гакаид нәсәфи» дип атала, китап эчендә гарәпчә язган хаты да була, бу хатта ул Бохарада фәннәрнең ничек укытылуы турында хәбәр итә. Атам бу хатны татарларның бөек галиме Ризаэтдин Фәхретдингә вә тарихчы Морад Рәмзигә җибәреп, бастырып чыгарды. Гариф шул ук мәгънәдә Бохара мәдрәсәсендәге хәлләрне аңлата: башларына сарылган чалмалары таулар кебек биек, нәфесләре диңгез кебек киң, ләкин наданнар вә нәҗесләр, дип яза ул. Аның бүтән бер гарәпчә хаты Казан тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗанинең әсәрендә басылып чыкты. Бу зат (Гариф Сәйрани) кайнар холыклы дусты Низаметдин белән берлектә фәнни эзләнүләрен дәвам итү максатында тагын Бохарадан Һератка вә Кабулга, аннан Иран юлы белән Багдадка китә, ләкин икесенең дә хыяллары җимерелә, һәр икесе дә 1856 елда хәерчелектә кала һәм сәер шартларда икесе дә вафат була, ихтимал, үзләрен үзләре үтергәндер, дигән фараз яши. Тормышта чын гыйлем эзләгән, иҗтимагый тормышта инкыйлаб (үзгәреш) эстәгән бу ике затның маҗаралар тулы авыр гомере һәм, ниһаять, Бохара, Һерат, Рәй, Багдад кеби дин мәркәзләрендә фикер хәятенең гаять түбәнлегенә шаһит булулары нәтиҗәсендә, хыял-теләкләренең җимерелүе алар өчен олы фаҗига булгандыр, ихтимал.

Авылыбыздан дүрт чакрым ераклыкта Бүҗә авылыннан Хызыр исемле бер имам һәндәсә (геометрия) фәнен бик яхшы белә иде. Атам да аннан һәндәсә буенча белем алган. Бу зат Сәмәркандта Тимерланның торыны атаклы математик Олугбәкнең «Руб-и муҗаеб (астрономикал квадрат)ы» белән чагыштырып, мәчетләрнең кыйбла тарафын тәгаен билгели иде. Ләкин бу замандаш Төркиядә вә Русиядәге математика белән чагыштырганда, якынча гына, уртача гына белем була килде. Бу имам тирә-ягыбыздагы тауларның Үлкән вә Алатауларның биеклеген гап-гади кораллар белән генә хисаплап чыгарган. Хызыр мулла гомеренең соңгы көннәрендә Баҗык исемле авылда имам булып торды, минем урысча өйрәнүмне бик хуплый иде һәм ул минем мөһәндис (инженер) булып китүемне бик тели иде. Аның әҗәленнән соң, мин дә кайбер яңа төзелә торган мәчетләрнең кыйбласын аның ысулы белән билгели идем.

Мин үскән вакытларда Көньяк Урал башкортларына Хива бик көчле йогынты ясый иде. Мәсәлән, туйларда «Хива чапаны» дип аталган кием бүләк итү гадәттә иде. Бездәге кыш көне кия торган, комач белән тышланмаган, сары күннән тегелгән туннар тач Хива-Хорезм рәвешендә, сакал-мыек шәкеле дә Хива-Хорезмдагыларныкы кебек иде. 1929 елда кышын Хорезмда булганымда шуларны күреп шаккаткан идем. Сүзнең кыскасы: атамны камап алган мохит төгәл мәгънәсендә Бохара белән Хорезм мәдәнияте тәэсирендә иде. Халык ярымкүчмә тормыштан бары тик XIX йөзьелда гына аерылган, дөресе, аерылып та бетмәгән иде. Бу мохитнең күзгә ташланып торган мәркәзе бездән җиде чакрым арадагы Көньяк Сәйран авылы, янә шундый ук ераклыктагы Төньяк-Көнчыгыш тарафында булган Макар авылы иде. Ягъни Гариф Сәйрани белән Йосыф майорның авыллары иде. Урыслар империалистик максатлар белән Чин (Кытай), Тибет арасындагы киң мәйданнардагы авылларга барып җитә алганнар. Урал тарафларындагы авылларга бөтенләй игътибар итмәгәннәр. Орынбурда корылган География Җәмгыяте Көньяк Башкортстанның культура учакларыннан бары тик Зыянчураны гына өйрәнде һәм кайбер материалларын

бастырып чыгарса да, ул мәгълүмат безнең тарафларга килеп ирешмәде. Башкортстан вә Татарстанда Сәйран, Шәлче, Япанчы, Сарт Хәсән кеби бәгъзе мәшһүр шәхесләребезне җитештергән яки тарихи байлыклары булган Көнбатыш Төркестанда да Сәйран, Шәлче вә Яфәнес кеби тарихта атаклы мәдәният мәркәзләреннән купкан (күчеп киткән) инсаннарның мәмләкәтебезгә килеп урнашканнарын күрсәтәдер.

**Казан мәктәбенең тәэсирләре**

Авылыбызның төн ягында 15 чакрым ераклыкта урнашкан Үтәк исемле бер авыл бар. Ул авылда башкортлар белән типтәрләр аралаш яши. Авылның имамы Сатлык Кафи иде. Атам шул Кафиның кызы Өммелхәяткә өйләнгән. Өммелхәят минем анам булыр. Атам Өммелхәяткә өйләнеп алгач, күнегелгән мохиттән бераз аермалы башка бер мохиткә кереп китте. Бохара, Хива белән арасын өзеп, Казан белән элемтәгә кереп, башка бер даирәгә якынайды. Үтәк авылыннан борынгыдан бирле абруйлы дини адәмнәр чыккан. Болар арасында 1826 елда вафат булган Кучкар Әмирханы – исеме мәшһүр галим зат. Дагыстанда, Истанбулда, Мисыр вә Һиҗазда белем алган, үзе вә Әхмәтҗан исемле углы (дин гыйлеме өлкәсендәге абруйлы шәхес, ул – Ислам дине фәнендә бәгъзе яңа карашларны алга сөргән зат). Хаждан кайтып килгәндә, Казанда тукталып, бер мәчеттә имам булып шунда кала. Анам тарафыннан туганыбыз тиешле кеше Үтәк авылында мәдрәсә тотучы Үтәгул Габделҗәлил хәзрәт 1859 елда вафат иткән. Хивада Яңа Үргәнеч шәһәрендә белем алган анамның атасы – Сатлык Кафи (үлеме – 1900) Бохарада, Хивада булган вә һәр икесе дә – фарсычаны яхшы өйрәнгән кешеләр. Авылыбызда анамның тәэсире аркасында фарсы мәдәниятенең тәэсире киң җәелгән иде. Мин гарәпчәмне атамнан өйрәндем, анам исә фарсычаны өйрәтте. Казан тарафларында имам булып урнашкан Әмирхан вә аның углы Әхмәтҗан Үтәк авылындагы туганнарын укытыр өчен, Казанга чакыра. Шулай итеп, авылыбызда Казан тарафдарлары күбәеп, Бохара, Хива тарафдарлары азаеп кала, ике мәдәният арасында көндәшлек барлыкка килә. Казан тарафдарлары Үтәк авылыннан чыкмыштыр. Бу хәрәкәтнең башында Сатлык Хәбиб Нәҗҗар иде. Ул мине 11 яшьтә чагымда үз мәдрәсәсенә укырга алган агам булыр. Казанда галим булып өлгергән Мәрҗани, безнең тарафларда аны «Шиһап Хәзрәт» дип йөртәләр, ул Ислам гакыйдәләренә (догмаларына) кагылышлы мәсьәләләрдә кыю фикерләве бик хупланып каршы алынган булса да, тарихка кагылышлы әсәрләре казакъ, башкортлар хакында бу кавемнәрне кимсетебрәк язган гыйбарәләре сәбәпле, һич хөрмәт ителми иде. Шул җәһәттән Хәбиб Нәҗҗарга «Шиһап мулланың ялчысы» буларак карыйлар иде. Мәрҗани гарәп сәяхәтчесе ибн Фадланның шамани «төс» дип аталган пот (фетиш)ларга кагылышлы сүзенә ялгыш аңлатма бирә вә башкортларда ир җенесе (фаллос) культы булганына кагылышлы язмалар бастырганлыктан, гарәпчә бик яхшы белгән Муллакай Габдулла хәзрәт атамның күз алдында Мәрҗанинең «Мостафад әл-Әхбар» исемле әсәрен утка атып яндырган. Мин өлгергән вакытта бу өч кешедән аеры тагын бер башка кемсәләр дә бар иде. Шуларның берсе – Муллагол Диванадыр.

*Төрекчәдән* **Рабит БАТУЛЛА** *тәрҗемә итте.*

*(Дәвамы алдагы саннарда)*

# САМАРА ТАТАРЛАРЫ ҺӘМ ЗАМАНА ФОЛЬКЛОРЫ

Икътисадта, фән-мәгариф һәм мәдәнияттә Россиянең иң эре үзәкләреннән берсе саналган Самара өлкәсе – милләттәшләребез күпләп сыенган урын. Ул – Россиянең татарлар яши торган төбәкләре исемлегендә унынчы урында. Урта Идел территориясенә урнашкан Самараның үзендә генә дә татар милләтеннән булган 40 меңгә якын кеше яши, калада аларның саны руслардан кала икенче урынны били. Самара өлкәсенә мөселман-татарларның әле XVI йөз урталарында ук килеп утырулары хакында тарихи мәгълүматлар саклана. Гүзәл табигатьле бу якларны үз иткән милләттәшләребез биредә ныклап тамыр җәйгән, зур-зур салалар төзегән, бүгенге көндә тулы хокуклы җирле халык булып яшәп ята. Төбәкнең галимнәрне үзенә җәлеп итүенең сере дә нәкъ менә шунда – компактлы яшәүче татарлар белән аралашу аша халкыбызны этнос буларак һәрьяклап өйрәнү мөмкинлеге чиксез зур биредә. Монда, Рәсәй куенындагы Самара өлкәсендә, Татарстанның татар авылларындагы кебек үк рәхәтләнеп татарча аралашып була торган, татарча сөйли, татарча уйлый, татарча эш-гамәл кыла, тормыш алып бара торган милләттәшләребез яши.

Галимнең бурычы – халкыбыз яшәү-тәрәккыятенең кабатланмас чаткыларын, әһәмиятле мизгелләрен билгеләп калу, бөртекләп җыйнау, теркәү, өйрәнү аша мөһим ачышлар ясау, халыкныкын халыкка кире кайтару. Самара татарлары галимнәрне күптәннән кызыксындыра. Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үзенең 75 еллык эшчәнлеге дәвамында татар халкының рухи һәм милли-мәдәни мирасын барлау, туплау һәм өйрәнүгә, гомумән, зур игътибар бирә. Әле алтмышынчы елларда ук бу якларга Институттан Илбарис Надиров, Хуҗи Мәхмүтов, Фатих Урманчеев, Флора Әхмәтова, Халидә Гатина кебек фольклорчы галимнәр, экспедицияләргә чыгып, фактик материаллар туплап алып кайткан, аларны академик басмалар төзегәндә файдаланган, Самара татарларыннан җыелган рухи энҗеләрне милли мирасыбыз буларак бәяләгән. Ярты гасырга якын вакыт аралыгыннан соң бу төбәкнең фольклорында, телендә-сөйләмендә, халык музыка сәнгатенең яшәешендә, археографик, ташъязма һәм этнографик мирас сакланышында һ.б. нинди яңалыклар, үсеш-үзгәрешләр, табышлар һәм югалтулар булуын ачыклау ихтыяҗы Институттан бер төркем галимне янә Самара өлкәсенә китерде.

Биредәге Похвистнево, Келәүле, Камышлы кебек районнарда хәзер 130 меңләп татар яшәве мәгълүм. Фольклорчыларны, археограф, текстолог, диалектолог, сәнгать белгечләрен берләштергән комплекслы фәнни экспедиция бу юлы өлкәнең шушы районнарында эшләде. Эш барышында һәр белгеч үз юнәлешенә муафыйк максатларны тормышка ашыруны күздә тотты. «Юлы уңның – эше уң», – ди халкыбыз. Безнең дә юлыбыз уң булып, эшебез гаять җайлы барды. Экспедиция барышында Самара татарларының рухи һәм матди мәдәнияте төрле яклап өйрәнелде. Элекке дәверләрдән туплана килгән тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл, тапкыр фикерләр, тәрбия алымнары, әхлак нормалары, күңел дөньясының, матурлыкның үзенчәлекле чагылышы, хәерле гамәлләрне аңлау-тоемлау рәвеше, дин, фәлсәфә, хәтер – болар бар да халыкта яши торган тиңсез хәзинәләр. Халык бар икән, димәк, аның күңел байлыгы да исән-сау, ул байлык, тарихның үзе кебек, һаман үсеш-үзгәрештә.

Фольклорчы буларак, төп игътибарымны, әлбәттә, халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлауга юнәлттем. Халык белән әңгәмә корулар нәтиҗәсендә бик күп берәмлек тел-авыз иҗаты үрнәкләре язып алынды, шушы төбәккә генә хас булган тарихи, топонимик һәм мифологик риваятьләр, авыл тарихлары, уеннар, җырлар, йола фольклоры, төрле ышануларга бәйле барлыкка килгән яисә халык китаптан укып сөйләгән хикәятләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәзәкләр, мәзәк хәлләр архивыбызны баетты. Ачык йөзле, сүзгә оста информантлары, куллары шифалау үзлегенә ия халык табиблары, оста гармунчылары, гармун ясаучылары, тәмле сулары, татлы бавырсаклары, исламны

хөрмәт итеп яши белә торган халкы белән күңелгә керде бу төбәк. Ни дисәң дә, Самарадагы татарларда – ата-бабаларыбыз каны, тамырларыбыз бер, гадәтләребез уртак. Һәр мәсьәләгә үз карашы булган тырыш, гаярь, җор телле, ушлы Самара татарлары – асылда милләтебезнең тулылыгын, бөтенлеген тәэмин итеп торучы шактый эре катлам. Биредә очраган һәм язып алынган фольклор әсәрләре – татар халык иҗатының бүгенге торышы, халкыбыз яшәешенә, аның бүгенге сулышына тере мисал.

Үзеңнеке һәрвакыт үз була. «Без – татарлар!» – дип горурланып әйтерлек милләтеңнең булуы шул милләт кешесендә канәгатьлек хисләре тудыра. Бу әйбәт хис татарларның бай тарихка, үзенчәлекле мәдәнияткә ия халык булуын аңлаудан килә, әлбәттә. Самара татарлары белән аралашу, авыллары тарихы, күренекле шәхесләренең эш-гамәлләре, гореф-гадәт, йолалары турында үз авызларыннан ишетү, күңел сандыкларын ачтырып, анда саклаган хәзинәләр белән танышу шушы хиснең яңаруына, ныгуына сәбәп булды. Бөек Тукай әйткәнчә, «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул».

2010 елдан бирле даими чыгып килә торган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дип аталган сериядә дөнья күргән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Самара өлкәсе татарлары» җыентыгында *(Казан, 2015; 360 б.)* 2014 елда Самара өлкәсенә Институтыбыз оештырган экспедиция материаллары һәм шушы чараның барышы тулысы белән яктыртыла. Биредә исә шушы экспедиция составында Самара өлкәсенең Похвистнево районы Гали, Нугай, Красный мост, Яңа Мансур, Иске Мәчәләй, Яңа Мәчәләй, Келәүле районында Назаровка, Камышлы районында Камышлы авылында, Иске Ярмәктә, Яңа Ярмәктә, Иске Балыклыда һәм Дәүләткол авылларындагы татарлардан шәхсән үзем туплаган кайбер үрнәкләрне журнал укучыларына тәкъдим итәм.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре докторы*

## Борынгы курган

Тарихи риваять

Гали авылы янында биеклеге 70 метрлы курган бар. Аны Чыңгыз хан явыннан калган курган, диләр. Моннан Чыңгыз хан үзенең гаскәре белән узган. Бер ише Идел ягыннан килгән, икенчесе – Оренбург тарафыннан. Шушы тирәдә Чыңгызның бер атаклы генералы үлеп калган. Аны шунда җирләп, биек курган корганнар. Ул курган Гали авылы белән Ырсай авылы чигендә.

**Әхмәдиев Рәфхат Алтынхуҗа улыннан,**
*1957 елгы, Похвистнево районы Гали авылы*

## Морат бабкай чишмәсе

Тарихи риваять

Морат бабкай Гали авылында моннан 210 еллар элек яшәгән. Ул мулла булган, соңыннан – авыл старостасы. Аны, каты куллы, кырыс кеше булганга, янсыз *(җансыз, кансыз. – Л.М.)*, дигәннәр. Халыкны тәртипкә күндереп, авылны тотып торган.

Патша хөкүмәтеннән, авылны чукындырырга дип, арбалы ат белән 18 солдат килә. 18 обоз *(ат йөге. – Л.М.)*, тәреләр төяп, тау өсләп киләләр. Киләләр болар, хәзерге турбаза янында авылның ике йөзләп ир-аты боларны саф-саф булып тезелеп каршы ала. Кайберәүләр чукындыручылардан куркып та кала. Авылның Дәмин исемле кешесе бабкайга: «Әллә болар киткәнче генә булса да чукынган булып кыланыйк микән?» – ди икән. Морат бабкай әйткән:

– Беркем дә чукынмый! Ничек йөрдек моңа кадәр мөселман булып, шулай калабыз.

Патша солдатлары һавага атарга тотына. Сугыш китә. 18 солдатның 11ен үтереп, тау тишегенә күмеп куялар, алып килгән йөкләрен калдырып, калган 7се кайтып китә.

«Барыгыз, кайтып сөйләгез», – дип озаталар аларын. Алардан калган тәреләрне соңрак күрше чуваш авылларына барып сатып йөрүчеләр дә булган әле.

Шушы хәлдән соң бу эшне оештырган Морат бабкайны җәзалыйлар. Бабкайның ике күзен чокып чыгаралар да үзен таллыкка ыргыталар. Бабкай өч көн дога кылып, Аллаһка ялварып шунда ята.

– Әй Аллам, без бит дин өчен сугыштык. Су бир. Бу урында чишмә тибеп чыкса иде! Үтүчеләр шунда үзләрен чистартып китә алса иде. Бу җирләр ризыклы булсын.

Бабкай әнә шулай теләп ята, өч көннән үлә. Аны шунда җирлиләр. Ул үлгәч, бу урында чишмә бәреп чыга. Чишмә Морат бабкай кабере янында, шуңа күрә бу чишмәне халык Морат бабкай чишмәсе дип йөртә башлый. Сазлыкка әйләнеп бетте, дип, чишмәне Совет заманында таш бастырып каплап куйганнар иде. Ташны бәреп, ургылып кабат чыкты ул. Морат бабкайны халык бик зурлый. Чишмәне авыл байлары карап тора.

**Әхмәдиева Асия Хәлимулла кызыннан,**
*1958 елгы, Похвистнево районы Гали авылы*

## Кемнең җен күргәне бар?

### Мифологик хикәят

Миңа җен ияләште бервакыт. Ахшам укыдым. Караңгы. Дисбе тартып утырам. Карасам, дисбем төймәләре арасыннан ике ялтыр күзле кап-кара нәрсә килеп чыкты. Бәләкәй генә үзе. Кит, дим, «Лә хәүлә вә лә куәтә»не укып, күзенә төкерәм. Китми дә, күзен дә йоммый. Шуннан кызымны чакырдым. «Инәкәй, әйдә сызыйк», – ди кызым. «Аятелкөрси»не укып, икәүләп пычак белән стенаны өй эче буйлап сызып чыктык. Икенче көнне двухстволка мылтыктан аттырдык, куркытыр өчен. Шуннан бетте теге җен.

**Моратханова Наилә Закир кызыннан,**
*1936 елгы, Похвистнево районы Гали авылы*

## Хат

### Фольклорда эпистоляр жанр үрнәге

Бер ирне солдатка алалар. Башкаларга карамасын, дип, хатынына болай дип хат язып җибәрә бу:

*Алтын балдак кадакта*
*Барысына да кояш булма,*
*Калырсың бит азакка.*

**Зарипова Фәимә Әхмәтшәриф кызыннан,**
*1957 елгы, Похвистнево районы Гали авылы*

## Йорт анасы

### Мифологик хикәят

Бәләкәй чакта ишеткәннәрем бар иде. Иртән торуга лапаска чыксаң, мал-туарлар тирләп-пешеп беткән. Йорт анасының эше бу. Ачуы килгән булса, шулай итә. Йорт анасы, яратмаганга, төне буе малларны куып йөрткән, диләр иде. Мунчасына да, йортына да, лапасына да хуҗа ул. Шуны йорт анасы, диләр инде. Күченсәң: «Әйдә, калма бездән, ияр», – дип әйтергә кирәк. Йорт анасы үзеңнән калмый күченсә әйбәт. Саклаучы ул. Аллаһ шулай яралткан бит аны. Өйдә орчык эрләгән тавышлар чыгара ул, әле генә кул астында булган әйбереңне яшереп куеп шаяра, аннары кире урынына китереп куя, төнлә лапастагы атның ялларын үрә. Нишләп хатын-кыз затыннан? Соң, хатын-кыз бит бөтен нәрсәне күреп, нечкәлекләрен белеп тора йортта. Йорт анасы да шулай.

**Кәлимуллина Мөхлисә Кәлимулла кызыннан,**
*1939 елгы, Похвистнево районы Нугай авылы*

## Нугай авылы атамасының килеп чыгышы

Тарихи-топонимик риваять

Монда тоташ урман булган элек. Нагайка – кыска камчы. Байлар, шул камчы белән кыйнап, кешеләрдән урман кистергән. Шуннан бу авыл атамасы Нагайка дип калган. Чын исеме шулай. Әле тагын болай дип тә сөйлиләр: татарлар Үзбәкстанга киткән. Анда боларны «нугай» дип йөрткәннәр. Шуннан монда кайтып, Нугай авылы булып яши башлаганнар. Татарны үзбәкләрнең нугай диюе авылга исем булып киткән.

**Алтынбаев Габделкави Габделхак улыннан,**
*1940 елгы, Похвистнево районы Нугай авылы*

## Кодагый, хәзер таң ата

Мәзәк

Базарга барган да бер хатын, кайтышлый кодагыена кагылган. Кунарга калган. Кунакны ашарга бик кыстыйсы килми икән хуҗабикәнең.

– Хәзер таң ата, кодагый, хәзер таң ата, – дип, кунагын көттерә икән.

– Атар, кодагый, атар, атканчы бер ипине тартыр, – ди икән карыны ачкан кодагые моңа каршы.

## Кемне сөйсә дә барыбер

Мәзәк

Бер килен кияве *(ире. – Л.М.)* белән яхшы тормаган. Киңәш сорарга муллага килгән.

– Татулык юк. Ирем сөйми башлады. Гел талаша. Балаларны ятим итәсем килми. Нишләргә? – ди икән.

– Мин сиңа бер дога язып бирермен. Ачма, укыма. Ирең талаша башласа, шул дога язылган кәгазеңне ал да тышка чыгып тор. Бераздан кер, – дигән моңа мулла, язу язып кулына тоттырган.

Ярар. Кайтып киткән хатын муллага рәхмәт укып, сәдакасын биреп. Өенә кайткач, мулла әйткәнчә эшләгән. Яхшы тора башлаган болар. Өйдә татулык икән. Башка хатыннарның да моның серен беләсе килгән. Теге хатын үзенең муллага баруы, аның дога язып бирүе турында сөйләп биргән. Укыйк әле, ни язган икән соң, дип, теге язуны ачып укыганнар.

*Аны сөйсәни миңа,*
*Моны сөйсәни миңа,*
*Биш тиен акчасын биргәч,*
*Кемне сөйсәни миңа, –*

дип язылган булган ди мулла биргән кәгазьдә.

**Вакказова Хатимә Шәяхмәт кызыннан,**
*1941 елгы, Похвистнево районы Красный мост авылы*

## «Кач-кач»

Уен, балалар фольклоры

Йөз чыбык чәчтереп җибәрәсең. Көтүче чәчелгән чыбыкларны җыеп бетергәнче качып өлгерергә кирәк. Көтүче, чыбыкларның җыелганнарын берәрсе йөгереп килеп чәчмәсен дип саклый-саклый, йөз чыбыкны да җыеп бетерә. Чәчтерсә, кабат җыя башлый. Җыеп бетергәч, качкан кешеләрне эзләү башлана. Көтүчене болай саный идек:

*Әтекәмә-сүтекәмә,*
*Әбел-фәбел думина,*
*Ике-пике раматака,*
*Зәйнеспис.*

Кемгә «Зәйнеспис» сүзе чыга, шул көтүче була.

**Йосыпова Рәйсә Гариф кызыннан,**
*1932 елгы, Похвистнево районы Красный мост авылы*

## Юктан бар итүче Аллаһ

Мөнәҗәт

*Үлем-яшәеш, тормышны Аллаһы юктан бар итте,*
*Җиде кат күк, сигез җәннәтне, Җир йөзен бүләк итте.*
*Аллаһы – безне ярлыкаучы, яманлыктан саклаучы,*
*Аллаһ кушканнарны үтик, тар гүрләргә ятканчы.*
*Аллаһыдан – иң олуг әҗер, гөнаһлардан сакланыйк,*
*Җәннәт насыйп итәр безгә, гамәл кылсак мактанмый.*
*Көндәлек кылган эшебез үлчәү мизаннарында,*
*Игелекле савап басар яман эш кылынганда.*
*Җәһәннәм уты һәвия насыйп итмә һичкемгә.*
*Сират күперен үткән чакта, зинһар, тайдыра күрмә.*
*Аллаһы хуплар юмартны, хәер-сәдака бирик.*
*Аллаһ бөек, тәсбих әйтик, өскә бурычлар җыймыйк.*
*Игелек кылып, тәүбә итсәк, кабуллыкка ирешер,*
*Кыямәт көнне бар мөселман хисаплашыр, күрешер.*

**Морзаханова Саимә Әхмәдулла кызыннан,**
*1947 елгы, Похвистнево районы Гали авылы*

## Акыллы хатын

Хикәят

Бер бай матур җирдә бакча ясаган. Җире ярлы бер хатынныкы икән. Җәберләп, җирен тартып алган булган моның бай. Беркөнне бай бакчада йөргәндә, бу хатын бай янына килә дә:

– Шул бакчадан бер капчык туфрак алыйм, рөхсәт бирсәнә, – дип сорый. Ник бирмәскә, дип, бай риза була. Бай рөхсәте белән хатын бакчадан бер капчык туфрак тутыра да җилкәсенә күтәреп алып китмәкче була, байга әйтә:

– Шул капчык туфракны җилкәмә күтәртеп кенә җибәрсәнә, – ди. Байның гомерендә дә авыр әйбер күтәргәне булмаган инде. Алай да, мәрхәмәте килеп, күтәртеп җибәрим булмаса, дип, капчыкка тотына. Капчык авыр, селкетә дә алмый, хәленнән килми.

– Юк, булмый, мин моны күтәрә алмыйм, авыр икән, – ди бай. Шуннан хатын әйтә моңа:

– Ә-ә, шулаймы? Минем хакым булган шушы бакчадан бер капчык туфракны да күтәрә алмадыңмы? Бу бакчада әллә ничә мең капчык туфрак бардыр. Кыямәт көнендә аларын күтәреп, Аллаһ каршына ничек барырсың соң? – ди.

Моны ишеткән бай:

– Мин гаепле, ал бакчаңны, – дигән, гөнаһыннан тәүбә иткән.

(«Моны мин бер китаптан укыган идем. Иске китаптан. Гарәпчәне укырга әбием, Нәфисә апа, Шәмсекамәр апаларым өйрәтте. Кайсы китаптан бу сөйләгәннәрем – әйтә алмыйм». *Хикәятне кемнән ишетүен сорагач, информант шулай дип җавап бирде. – Л.М.).*

**Булатова Шәмсегаят Миргаз кызыннан,**
*1930 елгы, Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылы*

## Бавырсагың таралмасын!

Туй йоласы

Кыз ягында никах укытыла. Никахтан соң туйгача кияү кеше кыз йортында ята, монда аңа кияү мунчасы ягыла, кияү коймагы пешерелә. Туй көнне килен төшерү була. Туйга кыз бавырсагы пешерәләр. Килен төп йортка төшкәнче, башта бавырсагын алып китәләр, аннары – үзен. Бавырсакны кыз ягындагы туганнары пешерә. Оста чакырып та пешертәләр бавырсакны. Аны пешерүнең үз тәртибе, кагыйдәләре бар. Пешереп, ширбәттә болгатып өеп куйганнан соң, ике сәгать үткәч, бавырсак оешмаса, таралып төшсә, гаилә дә нык булмый. Бавырсак тулысынча таркалып бетсә, бу хәл гаиләнең дә таркалачагына ишарә итә. «Бавырсагы таралган», – диләр аннары.

## Каз өмәсендә бәлеш урлау

Йола элементы

Каз өмәсеннән соң кызлар җыелыштык. Бәлеш салынган. Егетләр килде. Такмак әйтеп җырлыйлар. Икесе яңа такмак өйрәнгән:

– Пешә төшә, – ди берсе. Аңа каршы икенчесе әйтә:

– Пешә төшсә, бөгелә төш.

– Бөгелә төшсәң, суы чыга.

– Суы чыкса, шу да чык.

Карасак, бәлешне чәлгәннәр. Бәлеш турында әйтешәләр икән болар үзара. Без такмак әйтәләр дип авыз ачып тыңлап торабыз. Урланган бәлешне кире бирәләр иде. Бәясе – йә түләгез акчагызны, диләр инде, йә җырлаталар.

**Әмирова Асия Әхмәтгали кызыннан,**
*1956 елгы, Похвистнево районы Яңа Мәчәләй авылы*

## Иске Ярмәктә Юкәле тау

Топонимик риваять

Юкәле тавын Әүлия турысы дип йөртәләр. Ул тау Изгеләр тавы санала. Изге тауда әүлия күмелгән дип сөйлиләр иде, шуңа «изге», диләр ул урыннарны. Тауның итәгендә элек карт ак каен үсеп утыра иде. Хәзер ул каен юк инде, картаеп, корып ауды. Шундый карт каен иде ул. Егетләр солдатка киткәндә, әле патша вакытында ук, каен кәүсәсен чокып, исемнәрен язып калдыра торган булганнар, Юкәле тау исемен кушып җырлар җырлаганнар:

*Сау бул, Ярмәк, сау бул, Ярмәк*
*Юкәле тауларың белән.*
*Сау бул, Ярмәк, рәхәт яшә лә*
*Калган яшьләрең белән.*
*Каршыбызда – Юкәле тау,*
*Тагын яшәрер әле.*
*Ходай гомерләрне бирсә,*
*Бергә яшәрбез әле.*

Монда элек Ярмөхәммәд исемле кешенең биләмәләре булган. Авылның исемен шуңа Ярмәк дип атаганнар. 1737 елда авылга рәсми нигез салынган, диелә. Әмма чынлыкта авыл борынгырак, 500 еллап тирәсе бар аның оешуына.

**Галимуллин Наил Нәбиулла улыннан,**
*1957 елгы, Камышлы районы Иске Ярмәк авылы*

# БУ – МИНЕМ ТАРИХИ КЫЙММӘТЕМ!

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

## Татарларны күккә күтәрдең син...

*Татарстан Республикасының*
*Беренче Президенты*
*Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә*

Без патшалар күреп үскәнмени?!.
Хан, солтан ни безгә, патша ни...
Без өйрәнеп беткән идек инде:
Урыс ни дә безгә, башка ни...

Бер халык та ләкин була алмый
Ходай Тәгаләнең кашкасы.
Һәр кешенең була үз Алласы,
Һәр халыкның була патшасы...

Син дә менә туган халкыбызның
Президенты булдың, илбашы.
Ни күрсә дә халкы белән күрә,
Иле белән күрә ир башы...

Ә татарга кайчан җиңел булган? –
Заманалар һаман болгавыр.
Шул болгавыр чорда дәүләт тоту
Бигрәкләр дә авыр, мең авыр.

Башың белән җавап бирәсең бит
Милләт өчен, дәүләт өчен дә...
Иң авыры һәм иң катлаулысы –
Дәүләт тоту дәүләт эчендә.

Үз халкыңа синең игелекләр
Тау кадәрле!.. Күбрәк булмаса?..
Ул эшләрне эшли алмас идең,
Күкрәгеңдә кодрәт булмаса.

Син һәрвакыт халкың белән булдың,
Тора белдең әйткән сүзеңдә.
Татарларны күккә күтәрдең син,
Күтәрелдең бергә үзең дә.

Ә зәңгәр күк очсыз-кырыйсыз ул,
Биек әле күге татарның...
Иң мөһиме, татарларга син бит
Татарлыгын кире кайтардың.

Син күтәрдең татар катламнарын,
Син киңәйттең татар чикләрен...
Хак бәяне сиңа тарих бирер...
Бозмасалар тарих битләрен.

Моннан соң да булалырмы татар
Милләтләрнең данлы, санлысы?!.
Син сүзеңне әйттең! Татарларның
Үзләреннән тора анысы.

**Айдар ХӘЛИМ**

## Туган тел

Әгәр бөек телдә язган булсаң,
Тәрҗемәче көтеп, бәсәрми,
Ахры, күптән син зур шагыйрь булып
Яңгырар идең, дисең, Рәсәйдә...

Шулай дисең.
Соң әйт, туган тел ул
Сайлап ала торган ярмыни?
Шагыйрь өчен җирдә аннан хисле,
Аннан да көчле тел бармыни?

Башка телдә җиңел аңлашсам да,
Җырлый алмам күкрәк киереп, –
Рәхмәт, халкым, хак язмышым итеп,
Үз телемне бирдең иң элек!

Аһ, ерактан килгән җан бүләгем,
Аһ, еракка китәр саф өнем!
Тугач, тәү кат биләнгән биләвем,
Җаным чыккач, төрелер кәфенем!

Чын дусларга телем балдан татлы,
Үткен кылыч – яусыз дошманга.
Корыч үлми. Кирәксә, мин үләм
Аның өчен – намус кушканга!

...Сиңа багам, авыр уйга калам:
Карашларың төссез никадәр!
Гүя, син бер керсез оҗмах кошы,
Ә мин – канга тузган пәйгамбәр...

Кан коелды, әйе! Сездән микән,
Күрдең микән безнең урамнан –
Уртабыздан үтте –
Сүзләреннән
Җаны тетрәп, миллион туганнар –
Атылганнар, асылганнар үтте,
Сөрелгәннәр, кимсетелгәннәр,
Патшалыкның бозлы карбаз сымак

Империясендә сүнгәннәр,
Октябрьның ал комиссарлары,
Корбаннары соңгы сулышның
Үтте горур!
Гүя, туры үтте
Капкасы аша Бранденбургның!..

Син – фәрештә, мин – пәйгамбәр түгел,
Хакыйкать бар, кайда каерма, –
Син – ватансыз,
Мин – ватанлы булып,
Илне сөям – шунда аерма!

Коралны һәм малны энәгәчә
Тартып алса дошман әсирдән –
Телгә көче җитми. Көче җитсә,
Булыр иде микән Җәлилләр?

Үз халкымны әгәр бер кат сөйсәм,
Киң илемнең барлык милләтен
Биш сөям – ул халкымны сөйгәнгә –
Бу минем тарихи кыйммәтем!

Телем белән мин дә уйный калсам,
Шагыйрьме мин, рухи сукырмы? –
Әйт инде, әйт, балам шигыремне
Суык тәрҗемәдән укырмы?

Әгәр илем шагыйрь итеп тапса,
Маңгаемны борып кояшка,
Күрсәтер ул ерак Вологдага,
Күрсәтер ул күршем – чувашка...

**Равил РАХМАНИ**

## Изге китап эчендә сакланган бабам васыяте

Тарих хәтере безне яттан белә, –
Аттан төшеп,
ишәкләргә атланмагыз!
Тик Алыплар үтәп чыгар бурыч алда –
Вакланмагыз!

Ходай йөрәк, куәт, акыл биргән:
«Булдырдык!» дип, ярты юлда мактанмагыз...
Бер-берегезнең алдын бүлеп тапталмагыз –
Вакланмагыз!
Ир ир булсын,
хатын – һәрчак хатын!
Кыбырсык дип замананы акланмагыз;
Сиблеп, чәчлеп... зур вазифа төшми өстән –
Вакланмагыз!

Үр менәргә ныклы иман кирәк,
Тәти күреп, тизрәк барып капланмагыз...
Тәңре бер ул!
Җирдә кырык Алла табып
Вакланмагыз...

Милләт яши – җиңеп алга барса,
Бер урында тора – авыру,
Таптанмагыз...
Мескен халык хатасына көн дә баса...
Вакланмагыз!

**Нәҗибә САФИНА**

## Кыч-кы-ра-а-а-ам!

Берәү килде: «Син тагын да сүгенмә инде», – диде.
Ә мин аңа: «Син тагын да чигенмә инде», – дидем.

«Кычкыруда хикмәт юк», – ди, юк, мине ышандырмый.
Реклама ясаучылар кычкырмый һич эш кырмый.

Милләтем, кая барасың?! Ай-һай, ерагайгансың...
Кычкырам: «Аера бел, – дип, – кибәк белән ярмасын!»

Кычкырамын, пышылдамыйм, әнә, җил пышылдасын.
Милләтен, дәүләтен саткан еланнар ысылдасын.

Кычкырып дәшәм туган тел, асылын сатмаганга,
Туган тел, үткән, бүгеннең рухын саклаганга.

Иң олы бүләк тиешле, аңа лаек андыйлар.
Нигә миңа: «Дәшми генә янсаң, әйдә, ян», – диләр.

Дәшми янган ай, кояштыр, мин алар булалмыйм бит.
Җирне ташлап, илне ташлап, җиһанга тулалмыйм бит.

Миңа тел биргән табигать: «Сөйлә, җырла, кычкыр, – дип. –
Чарасын тап һәм ишеттер, киләчәккә эш кыр!» – дип.

Тиргәнүдә хикмәт юктыр, хикмәт – ишеттерүдә.
Бүген дә яшәргә кирәк, нигә кичектерергә?!

Анда җәннәт булыр, диеп, гамәл кылмаганнарга,
Ходай бирер әле, диеп, һич эш кырмаганнарга

Берни әзерләп тормыйлар, сәбәп ит, булыр насыйп.
Кычкырам, әгәр дә шулай җаннарны булса ачып.

Бикләнгән җаннарга дәшәм: кайтыгыз үзегезгә! –
Киләчәгебез мохтаҗ бит туган телдәге сүзгә!

Карганмыйм да, тиргәнмим дә, оран салам, тыңлагыз:
Дәүләткә лаек халык без, исбатламый тынмагыз!!!

Рашат НИЗАМИ

## Идел-йорт

Төнге Идел.
Аның киңлекләрен
Күзләр өчен оешып-җыйналып,
Күктән йолдыз мәрҗәннәре карый...
Дулкын ярга бәрә, кыйналып.

Нигә шулай кыйналмасын икән
Татар язмышына «Аһ!» итеп, –
Күбекләнә. Һәм язмакчы була
тарих ялганнарын
Дөрес итеп, сөттәй ак итеп.

Төн пәрдәсен ертып, сурәт калка:
(Хәтер кайчак бездән көчлерәк!)
Аркан асып, Идел бурлаклары
Теплоходны бара өстерәп...

Мәҗүси җил дәшә безгә бүген:
Тәкъдиреңә, туган, түз, диптер.
Бүгенгене бурлак сыман тартып,
Сөйрәп бару – бәхетсезлектер.

Ватылмаган өмет. Өмет исән!
Барыр юллар – ташлы, бормалы.
Ил тәкъдирен мин дә тартып барам –
Гап-гади бер татар бурлагы.

Казансуга – һаман ямансудыр,
Тарихларда халкым кыйналган.
Идел шаулый...
Диңгез төенедәй
Татар рухы монда төйнәлгән...

Рәниф ШӘРИПОВ

## Бу – безнең җир!

*«Бу – безнең җир!» – Байрак тоткан Кырым татарының күсәк тоткан ОМОНчыларга әйткән сүзләре. «ТВ»*

Намаз укып, сәҗдә кылып,
Мунча кереп, уйнап-көлеп,
Иген игеп без көн иткән,
Бу – безнең җир иде элек!
Тау астыннан яу керәсен
Булмый икән алдан белеп.
Алла диеп без яшәгән,
Бу – безнең җир иде элек!
Илләр, җирләр, халыкларны
Асып, кисеп, турап, телеп,
Башка илдән патша килгән,
Бу – безнең җир иде элек!
Күпер бауда, Казан тауда,
Түгелде кан, кипте җелек.
Бау өзелде, яу тезелде,
Бу – безнең җир иде элек!
Катлам-катлам кан укмашкан,
Тимер кебек утта эреп.
Кызыл елга булып аккан,
Бу – безнең җир иде элек!
Катлам-катлам казылган җир –
Гасырларның өнсез теле.
Көл астында канлы кала,
Бу – безнең җир иде элек!
Кара катлам – бусы каны,
Соры катлам – бусы көле.
Яшел үлән – бусы җаны,
Бу – безнең җир иде элек!
Ник бастыгыз? Ник бастыгыз!
Юлбасардай бәреп кереп.
Шаулап-гөрләп дәүләт корган,
Бу – безнең җир иде элек!
Янды кала, кырды патша
Мөслимнәрне суеп, сөреп.
Без куылган, без сөрелгән,
Бу – безнең җир иде элек!
Иле дә юк, теле дә юк,
Бетә инде татар череп.
Ник бастыгыз! Ник бастыгыз!
Бу – безнең җир иде элек!
Җавап булмас. Урам буйлап
Читләр йөри уйнап-көлеп.
Өзелде көн, тезелде төн,
Бу – безнең җир иде элек!

Тел яшереп йөргән халкым
Куйсын муенына элеп –
Дога кебек изге сүзләр:
Бу – безнең җир иде элек!
Көн дә безне кимсеткәннәр,
Ирек бирми җанны телеп, –

Монда безнең Дәүләт булыр,
Бу – безнең җир иде элек!
Үч итмәбез, кимсетмәбез,
Тик, йөрегез шуны белеп:
Без беркайчан онытмабыз!
Бу – безнең җир иде элек!

**Ленар ШӘЕХ**

* * *

*Кара юрга бирегез...*
Кыргыз җырыннан

Кара юрга бирегез,
Сикереп кенә менәем,
Дилбегәмне тартаем,
Камчымны кизәнәем.

Ата-бабам җирләрен
Юртып урап киләем,
Карурманны гизәем,
Дала буйлап җиләем.

Идел буйлап йөзәем,
Агыйделне кичәем,
Күңелгә дәрт өстәрдәй
Чишмәдән су эчәем.

Чиксез офыкка карап,
Ук-җәямне тартаем,
Күктә очкан киекне
Мең чакрымнан атаем.

Туктап учак ягаем,
Ак тирмәмне кораем.
Монда туган биләмәм,
Ватан дигән сараем.

Шарт-шорт янган учакта
Киекне кыздыраем,
Урал тау итәгендә,
Думбырам сыздыраем:

«Җирләрем кисәк-кисәк,
Бергә тупларга исәп –
Уңга да ун мең чакрым,
Сулга да ун мең чакрым.

Аткаемны чаптырам...
Офыклар да яктыра...
Дәүләтем телем-телем,
Уйлап киләм, юллап киләм
Берләшү мөмкинлеген.

Урал тавы башында
Кояш минем каршымда...
Себер тарафка узам,
Юлларымда уйнап кала
Җанга утырган тузан...»

Айлы күккә багаем,
Кураемны тартаем.
Бу җирләрне мирас иткән
Бабам белән атаем.

Азия чүлләрендә
Кубызымны чиртәем,
Илемнең чиген эзләп,
Җир читенә җитәем.

Чал гасырлар калдырган
Кысаларга сыймаем,
Уңга-сулга сибелгән
Мәмләкәтне җыйнаем.

Татар диеп аталган
Милләтемне хуплаем,
Төрки диеп аталган
Кавememне туплаем.


Кара юрга бирегез,
Сикереп кенә менәем,
Төрки дигән халыкны
Бердәм итеп күрәем,
Бер гамь итеп күрәем!

# ЮКСЫНУ

*Уйлану рәвешендәге бу хатирә-истәлек моннан ун елга якын элек, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе Ринат Закировның юбилее уңае белән язылган иде. Аерым өлешләре газета кысаларында кыскартылып басылып та чыкты. «Казан утлары» (минем өчен газиз басма!) җитәкчелеге Шамил Закиров турында берәр кәлимә сүз әйтүне сорагач, әлеге язма искә төште. Бәй, мин бит анда Шамил Зиннур улы Закиров турында да беркадәр язып үткән идем бит. Архивымнан табып, ул мәкаләне яңадән укып чыктым. Әйе, чыннан да шулай. Бернинди төзәтмә кертмичә, ул вакытта ничек язылган, шул килеш журнал укучыларына тәкъдим итәм.*

## Казанның иң бай егетләре

*Иртән тор да чиста-пакь күлмәк ки,*
*һәм дусларны арттыр дөньяда!*



Язмамның исем итеп куелган сүзләрен укыгач, долларлы миллионнарга ия кайберәүләр сискәнеп, сәерсенеп тә куярлар: кемнәр икән ул байлар? (Хәер, юкка борчылам: татар фамилиясе йөрткән замана байларының абсолют күпчелеге, вакланып, әби-бабалары, әти-әниләре сөйләшкән телдә газета-мазар укып маташмас...) Сискәнмәсеннәр дә, гаҗәпләнмәсеннәр дә, сүз алар аңлаган байлык турында бармый. Байлык – адәм балаларының акылын саташтыра торган нәрсә, катлаулы төшенчә. Бу очракта үзем аңлаган байлык, рухи дөньяга бәйле кыйммәтләр, аларга турыдан-туры мөнәсәбәте булган шәхесләр турында.

Башкалабыз үзәгендә ике зур мәһабәт бина бар. Бездә башка күркәм биналар да җитәрлек. Әмма бу икесе халкыбыз тарихында миссиясе һәм әһәмияте ягыннан аерым статуска ия. Аларның берсе – Г.Камал театры, икенчесе – «Казан» милли мәдәният үзәге. Бу биналарның хуҗалары, ягъни директорлары – бертуган Закировлар (бу юлларны язганда, Дәрдемәнднең чын исеме Закир, ә Н.Исәнбәтнең чын фамилиясе Закиров булуы искә төшеп алды). Шамил Зиннур улы Закиров Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасы төзелгәннән башлап, ягъни 1985 елдан бирле эшли, ә Ринат Зиннур улы Закиров – 1988 елдан башлап «Казан» милли мәдәният үзәге (1984-1990 елларда В.И.Ленин Үзәк музееның Казан филиалы) бинасында директор.

Закировлар хуҗа булган бу биналар безнең өчен үзенчә изге (бигрәк тә Камал театры); бирегә күңел кушуы белән килеп, җанга «азык алып», шатлыктан сөенеп, аяныч хәлләрдән көенеп, әмма рухи яктан яңарып һәм тураеп чыга торган мәккәи урыннар. Укып-ишетеп беләбез: үткән гасыр башында Казан татарларының мәдәни

учагы булып «Шәрекъ клубы» эшләп алган. Анда Тукай заманы зыялылары җыелган, спектакльләр куелган, китапханәләр эшләгән, «Сәйяр» труппасы җыйналган... Кыскасы, клуб ул чорда яңа яралып килүче милли сәнгатьнең үзенә күрә бер бишеге булган. Бүгенге Камал театрын һәм Милли мәдәни үзәкне «Шәрекъ клубы»ның дәвамчылары санап, аналогия үткәреп буламы? Була кебек. Чөнки тарихи максат шул ук: халыкны милләт буларак саклап калу, рухи үсешен тәэмин итәргә тырышу. Масштаблар гына бүтән, тәрбия ысуллары гына үзгәрәк. Әйтик, «Шәрекъ клубы»на илле-алтмыш кеше йөрсә, Закировлар идарә иткән биналарда, көн саен яки көнаралаш дигәндәй, уртача бишәр йөз кеше тамаша кыла. Кемнәр йөри соң бу залларга? Монда бит мал бүлмиләр! Асылда, Үткән белән Киләчәкне өзеклексез әхлакый тоташтыру зарурлыгын аңлаганнар йөри бу залларга. Рухыбыз сау булсын өчен, телебез бетмәсен өчен, көй-моңнарыбыз саклансын өчен. Шундый мәркәзи биналарны (бу сиңа ярым криминаль казино-мазино йортлары түгел!) үз кулларында тоткан, хуҗа була белгән егетләрне ничек итеп иң-иң байлар дип атамыйсың!

Закировлар – тумышлары белән Чистай ягы кешеләре. (Чистай ягы Гаяз Исхакый, Әмирхановлар ягы инде ул.) Төгәлрәк әйткәндә, Нарат-Елга авылында ишле гаиләдә туып-үскән егетләр. Мәктәпне тәмамлагач, Казанның химия-технология институтына юл тотканнар, кергәннәр, укыганнар (бу очракта шуны да искәртеп үтәсем килә: беренчедән, башлы булган егетләр! Татар мәктәбен бетергәннәргә техник вузларга керү бик авыр иде; сәләтле күпме татар егет-кызлары рус теленнән сочинение аркасында киселеп калдылар! Икенчедән, техник белем алсалар да, милли мәсьәләләрне нечкә аңлауда, аларны чишү өчен тырышуда, гуманитар белем алган байтак мөтәтатарлардан Закировлар күп башка өстеннәр!). Институтны бетергәч, табигый, һәр кешенең индивидуаль, үзгә хезмәт юлы башлана. Тәртип-холыклар белән бер-берсеннән шактый аерылсалар да, Шамил белән Ринатның тормыш елъязмаларында охшаш яклар да байтак, һәр икесе дә вуз бетергәннән соң да укуларын дәвам итәләр. Шамил Ленинградта аспирантура (техник өлкәдә түгел, культура институтында!) тәмамлый, Ринат – күптән инде фәннәр кандидаты. Икесе дә комсомол-партия мәктәбен үтәләр, ягъни район һәм өлкә комитетларында эшлиләр. Икесе дә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре... һәм, ниһаять, алда әйтелгәнчә, икесе дә директорлар.

Бертуган Закировларны мин кырык еллап беләм. Өлкәне Шамил белән, табигый, алданрак таныш. Ныклабрак танышу 1968 елны булды. Шамил – КХТИ студенты, активист, сәхнәпәрвәр. Институтның актлар залында татарның яшь әдәбият-сәнгать вәкилләре белән очрашу оештырды ул. Без дүртәү чыгыш ясадык: җырчы Илһам Шакиров, композитор Ренат Еникеев, язучы Роберт (ул вакытта әле Рабит түгел) Батулла, яшь шагыйрь сыйфатында – мин. Ул кичә мәңге онытылмаслык тамаша булды. Халык залга, коридорларга сыймады. Милициягә дә эш табылган ул кичне, урамда калган яшьләр ишекләрне каерып, тәрәзәләрне ватып залга үтмәкче булган. Торгынлык чорының башлангыч еллары булса да, сәяси «җепшеклек» кайтавазы көчле булган әле ул вакытта. Шамил инициативасы белән оешкан бу кичә төрле вариантларда Казанның байтак вузларында шаулап узды. (Ул еллар турында олуг әдибебез Рабит Батулла тәфсилләп язып чыгарга да ниятли дип беләм. Батулла ул чорда «Ядкарь» иҗади яшьләр хәрәкәтен җитәкләде.) Оештыру сәләте студент елларында ук булган инде Шамилнең. Закировларга бер нәрсә хас: әгәр үзләре инанган максат өчен кирәк булса (беренче чиратта, милли мәнфәгать), алар вазифаи кысаларга гына сыя торган затлар түгел. Бер карасаң, студент-химикка ул кичәне оештыру мәҗбүри ихтыяҗ түгел бит. Ә бит оештырган! Димәк, аның бу гамәле күңел таләбе, җан таләбе булган. Мондый мантыйк белән фикер йөртсәң, Шамил әфәнденең гомере буе кылган бар хезмәтләре күңел таләбе белән башкарылды шикелле. Эшне җаны-тәне белән бирелеп үтәү – бу аның тормыш кодексы, кредосы. Чирек гасырга якын театрда директор булып торганда, бихисап эшләрнең байтагын, бәлки әле яртылабындыр, эшләмәскә дә булыр иде. Беркем дә бәйләнмәс иде. Дөньяда инструкция-устав буенча төп-төгәл үз вазифасын гына башкарып, тыныч кына бәргәләнмичә яшәп, карьера яулаган җитәкчеләр буа буарлык. Соңгы дистә еллар эчендә Шамил Зиннурович инициативасы һәм турыдан-туры катнашы булган театрдагы зур башлангычларның кайберләрен

генә санап үтим: өлкән яшьтәге ветеран артистларның «Инсаният» труппасын төзү, яшьләр өчен «Балачак» студиясе оештыру, «Яңа татар пьесасы» конкурсын үткәрү, театр һәм артистлар турында китап-альбомнар бастыру, шактый озак еллар өзеклектән соң ерак өлкәләргә һәм чит илләргә янәдән гастрольләргә чыга башлау. Театр эчендәге иге-чиге, очы-кырые булмаган хуҗалык һәм ремонт эшләре... Ярый, бу гамәлләр театр эшчәнлегенә, директор вазифасына карый, диик. Ә менә соңгы елларда Кызыл Байракта (Югары Ослан районы) гөрләп уза торган «Сәйдәшне искә алу» тантанасын, Яуширмәдә (Чистай районы) үткәрелүче «Исхакый укулары»н, театр мәйданында «Туган тел» бәйрәмнәрен оештыруга алынуын ничек аңлатасың? Кушып эшләтә торган гамәлләр түгел болар. Сәйдәшкә багышланган бәйрәмне Сабантуй шикелле үк зарыгып, сагынып көтеп алалар хәзер. Бу бәйрәм елдан-ел масштаблы төс ала. Безнең күз алдында республикакүләм яңа бәйрәм туды. Әлбәттә, әлеге чараларда Мәдәният министрлыгы, театр, иҗади оешмалар, җәмәгатьчелек тә актив катнаша. Әмма, ни генә дисәк тә, бу очрашу-тантаналарны Шамил Закировсыз күз алдына китерү кыен. Күп нәрсә аның фидакярлегеннән, тынгысыз тырышлыгыннан тора. «Байлык тынгы бирми ул!» дигәннәре әллә дөрес микән? Әллә рухи байлык иясенә дә карый микән бу тәгъбир?

Шамил Закиров. Кемнәрдер аны «изге җандыр ул», диләр. (Төрле телләрдә йөзәрләгән Коръән тупланмасын булдыру да нәрсәдер аңлата шикелле.) Мин үзем, мәсәлән, аның байтак язучыларга ярдәм кулы сузганын беләм. Ул шулай ук халкыбызның төп журналы булган «Казан утлары»ның да якын дусты, аны таратуда булышып тора. Кайчак уйлап та куям: бу кешенең дошманнары, һич югы, көнләшүчеләре бар микән? Бардыр. Озак еллар җитәкче булган кешене өнәмәүчеләр булырга тиеш. Шулай да андыйларның дәлилләре аздыр. Үлчәү тәлинкәсенең яхшырак ягы дигәне шапылдап аска тартадыр... Мәшһүр артист Ринат Таҗетдинов әле быел гына узган үзенең юбилей кичәсендә болай дигән иде: «Шамил Зиннурович исән-имин эшләгән чакта җирләнергә насыйп булсын иде!» Артистларча, бераз эффектны да онытмыйча әйтелгән булса да, бик тә гыйбрәтле, моңсу сүзләр!



*Шамил Закиров һәм Марсель Сәлимҗанов*

Шамилне кайчак арыган, алҗыган кыяфәттә дә күрергә туры килә. Кеше тимер түгел, көне-төне чабып, янып эшләгәч, арырсың да... Алсу йөзле, тук кыяфәтле, вәкарь белән генә сөйләшүче, кәнәфиендә канәгать оеп утырган Шамил Зиннур улын күрергә насыйп булмады инде. Һәм булмас та. Ул шулай – Үзе булып яратылган.

Шамилнең туганы Ринат турында берничә сүз. Хәер, бу шәхес турында берничә сүз белән генә булмый: ул башкарган эшләр аерым тикшерүләргә, аерым хезмәтләргә лаек. Ринат Зиннурович белән дә күптәннән таныш. 90 нчы еллардагы милли күтәрелеш елларында бигрәк тә еш очраша идек. Аңарчы да, партия өлкә комитетында иҗат оешмалары белән кураторлык иткән елларында да шактый күрешелде, кайбер уртак эшләр дә башкарылды. Хәзер дә аралар өзелмәде. Әмма һәрберебез өчен Вакыт дигән нәрсә цейтнотның синонимына әверелеп бара хәзер...

Ринат Зиннурович – конкрет, стратегик эшләр кешесе. Ахыр максатлар абыйсыныкы кебек булса да, максатка бару, аңа ирешү юллары шактый ук аерыла да. Шамилнең гомерлек хезмәте эмоциональ иҗат кешеләре – артистлар, язучылар, композиторлар

белән үтсә, Ринат тормышының байтак өлеше рәсми кешеләр – төрле рангтагы җитәкчеләр, чиновниклар даирәсе белән бәйле. Бу хәл, әлбәттә, аның эш стилендә дә чагылыш таба. Ул бүгенге җәмгыятьтәге үсеш динамикасының нечкәлекләрен яхшы белә, киләчәкне конкретрак күзаллап яши. Кыскасы, заманының гыйлемле зирәк улы, актив хадиме. Үз вакытында байтак еллар комсомол-партия структураларында эшләү, чарлану, шул чор идарә итү мәктәбен үтү аңа файдага киткән дип уйлыйм. Нинди генә шигарьләр астында яшәмик, дөньяда яшәү рәвеше кисәк кенә үзгәрә алмый, асылы аның, нигездә, шул ук кала.

Ринат Закиров – хәзерге татар дөньясында иң билгеле шәхесләрнең берсе. Аның хезмәти вазифасы белән дә бәйле бу хәл. Ул – Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе. Мөгаен, бөтен дөньяга сибелгән татарларның яшәешен иң яхшы белгән кешедер ул бүген. Татар дөньясы – бик катлаулы, четерекле, күп катламлы дөнья. Аны бербөтен милләт итеп сакларга тырышу – ифрат авыр миссия. Миңа калса, милләтне берләштерү процессы әлегә уңышлы бара. Бу тарихи хәрәкәттә, һичшиксез, Р.Закировның роле зур. Ринат Зиннурович Конгресс җитәкчесе буларак та, халык депутаты буларак та абруйлы шәхес. Бер генә мисал: моннан өч ел элек Казанга Россия Президенты Владимир Путин килгән иде. Ул республика җитәкчелеге һәм татар җәмәгатьчелеге белән Казан Кремлендә очрашты. Бик югары дәрәҗәдәге очрашу. Анда күрше республика президентлары да бар иде. Татар халкының рухи үсешендәге борчыган мәсьәләләрне күтәреп, Ринат Закиров кыю чыгыш ясады. Нотык, аңлавымча, Республика исеменнән, татар халкы исеменнән иде. Кайчак зур җитәкчеләргә күтәрергә кыен мәсьәләләрне җәмәгатьчелек вәкилләре әйтсә, кулайрак була...

Нинди генә дәрәҗәле постлар булмасын, беркөн алар бетә: рәислекләр дә, депутатлыклар да... Тормышның аяусыз, гадел кануны. Сайланып куелу белән бәйле вазифалардан тыш, кешенең, әгәр ул шәхес булса, күңел куеп, җегәр салып тудырган хезмәт-ядкарьләре дә калырга тиештер. Бу уңайдан Ринат Закировның әлегәчә алыштыргысыз директор буларак, «Казан» милли мәдәният үзәгенең эшчәнлеге турында да әйтеп китү дөрес булыр. Үткән гасырның 80 нче еллар уртасында шәһәр үзәгенең Казансу буенда корылган бу бина, шул заман хакимнәре уенча, Ленин тәгълиматларын пропагандалау үзәкләренең берсе булырга тиеш иде. Дөнья куласа, заманалар үзгәреп, коммунистик идеяләр тарату урынына бу мәһабәт бина Милли үзәккә, милли мәдәният, милли идеяләр үзәгенә әверелде. Моннан ике ел элек «Казан» милли мәдәният үзәгенең унбиш еллык юбилее да уздырылды. Шул вакытта фәнни-гамәли конференция дә узды. Конференциянең исеме үк күп нәрсә аңлата: «Милли мәдәният үсешендә һәм иҗтимагый аң формалаштыруда «Казан» милли мәдәният үзәгенең роле». Төп фикер шул булды: ифрат зур! Күпләребез үзәкне иң әүвәл концертлар, төрле кичәләр, күргәзмәләр, конференцияләр, симпозиумнар үткәрү урыны дип белә. Ул шулай да. Әмма Үзәкнең төп байлыгы – аның Милли мәдәният музее икәнен күпләр белеп җиткермәскә дә мөмкин. Берничә сан китереп узыйк: музей тупланмаларында археология, этнография, нумизматика, картография һәм театр, музыка, рәсем, декоратив-гамәли сәнгать төрләренә караган утыз алты меңгә якын экспонат бар! Шуларның унике мең чамасы төрле тарихи документлар һәм сирәк очрый торган китаплар. Кыска гына вакыт эчендә никадәр байлык тупланган!

Үзәкнең шәһәр филармония составына кергән сәнгать коллективлары аерым игътибарга лаек. Алар – «Казан нуры» халык уен кораллары һәм «La Primavera» камера оркестрлары, «Казан» бию ансамбле. Бу коллективларны дөньяның күп илләрендә яхшы беләләр. «La Primavera» турында күп язылды, ә «Казан» бию ансамбле турында аерым әйтәсе килә: Татарстанның җыр һәм бию ансамбленә көндәш коллектив ул. Җитәкчесе Чулпан Закирова (Р.Закиров һәм актриса Р.Мотыйгуллиналарның кызы) куйган биюләр тамашачы күңеленә бик хуш килә. Мескенлек юк аларда! Биючеләрнең нәфис пластик хәрәкәтләре матур эстетик тойгылар, горурлык хисләре уята. Сәхнәдә түбәтәй киеп, кәҗә бәтиләре кебек сикергәләп йөрү заманнары узды. Чулпан куйган биюләрне күргәч, «Браво! Афәрин!» дип оран саласы килә.

Ринат Закиров җитәкләгән Үзәк үзе бер мәдәни дәүләт ул. Коллективта

эшләүчеләрнең саны гына да ике йөз утыздан артык, ә кылган зур гамәлләр саны – меңләгән!

...Бертуган Закировларның эшчәнлеге сокландыра да, уйландыра да. Бер максатны кыйбла итеп алып эш иткән бертуганнар элек тә булган. Әйтик, Рәмиевләр, Шәрәфләр... Хәзер дә булырга тиеш, һәм беркадәр бар да алар. Күңел күбрәк булуларын тели. Әгәр халкыбызның һәр улы-кызы бертуган Закировлар эшләгән эшләрнең бик аз өлешен генә башкарсалар да, милләтебез тормышы шактый камил булыр иде.

Шамил һәм Ринат Закировлар турында бер-ике кәлимә сүз әйтергә күптән кыҗрап йөри идем. Язмам башындагы берничә җөмлә моннан ике ел элек язып та куелган иде. Ниһаять, теләгемә ирештем шикелле. Ничек килеп чыккандыр, анысы икенче мәсьәлә. Үзем өчен иң мөһиме – күңел тынычланып калды. Язарга форсаты да чыкты шул: бу көннәрдә Ринат Зиннур улы Закировка 60 яшь тула. Исәнлек-саулык, олуг эшләрендә уңышлар телибез аңа. Шундый ук теләкләр Шамил Зиннур улы Закировка да ирешсен.

*2008 ел*

***Өстәмә.***


*Дөресен генә әйткәндә, өстәмә сүз язып та тормас идем, тугыз ел элек язылган текстка бүген дә кул куям; әмма Вакыт дигәннәре яшәешебезгә үз өстәмәләрен гел кертеп тора шул. Торган саен Дөнья үзгәрә, үзебез дә күпмедер үзгәрәбез. Язмабызга нисбәтән, бу еллар эчендә иң зур өстәмәләрнең берсе – 2012 елның февралендә Шамил Зиннур улы Закировның вафаты – бакыйлыкка күчүе булды. Нишлисең, дөнья шулай яратылган: берәүләр килә, берәүләр китә. Кояш астындагы Җир өслегендә тереклек гел алышынып тора. «Кеше китә, җыры кала» диярга генә кала. Җыр димәктән, байтак еллар төп җитәкчеләрнең берсе Ш.Закиров булган Камал театры үз җырын әле дә уңышлы дәвам итә, традицияләрне дә онытмыйча, яңа дәвер таләпләренә лаек җавап бирергә тырышып иҗат итә бирә. Бәлки, элеккеге җитәкчелек вакытындагы кайбер үзенчәлекләр үзгәргән яки кими төшкәндер, ә бит театрда моңарчы булмаган күркәм яңа башлангычлар да җитәрлек. Күрә белергә, аңлый белергә генә кирәк. Иҗат кешеләре өчен бик уңай замана димәс идем безнең бу глобальләштерүгә юнәлтелгән елларны. (Хәер, чын иҗатчыларга кайсы заманда җиңел булган соң?) Теләмәсәң дә, уйланырлык хәлләр җитәрлек. Театр, эстрада коллективларында – тамашачыларның залларны тутыру проблемасы, язучыларда – укучыларың булу зарурлыгы, рәссамнарда – картина-сыннарны урнаштыру мәсьәләсе... Ә театрга килгәндә, тамашачы белән тулы залларны күргәндә (яшьләр дә бик күп була анда хәзер), коллективның әледән-әле дөньяның төрле илләрендә гастрольләре турында хәбәрләрне ишеткәндә, безнекеләр инициативасы белән төрле дәрәҗәдәге фестивальләрнең уңышлы үтүенә шаһит булганда, күренекле артистларыбызга багышланган матур-матур китап-альбомнарны укыганда, үзебезнең Камал театры өчен чиксез горурлык хисләре кичерәм мин. Шул чакларда еш кына Шамил Зиннур улы хәтергә килә. Бу күркәм башлангычларда аның өлеше дә бик зур булды дип куанасың.*

*Әле бу көннәрдә генә Шамил Зиннур улы белән, дөресрәге портреты белән янәдән очрашырга туры килде. Сөекле җырчыбыз Әлфия апа Авзалова белән хушлашу көне (17 июнь, 2017) иде. Мәрхүмәнең җәсәден җиргә иңдерү мәрасименә килгән йөзләгән кешене, Яңа Бистәдәге зират капкасыннан керүгә, Шамил кабере каршы алды. Чардуган эчендәге мәрмәр ташта – рәсеме. Уйчан, акыллы, моңлы күзләр... Күпләр аңа дога иңдереп, баш иеп киттеләр. Бирегә килгәннәрнең һәммәсе диярлек аның дуслары яки танышлары. Ул көнне Шамил Зиннур улының рухы шат булгандыр дип уйлыйм.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*18 июнь, 2017 ел*

# ТАРИХТАГЫ ТАТАР СУРӘТЕ ТУРЫНДА ЯЗМАЛАР



Европа һәм дөнья тарихында гаять әһәмиятле урын тоткан шәхес – хун хөкемдары Аттила безнең эраның 453 елында үлгән. Аның нинди телдә сөйләшкәнлеге фән дөньясы өчен хәзерге көнгә кадәр сер булып кала бирә. Аттила борынгы грек, герман, гот, итальян һәм венгр риваятьләрендә бик зур урын тотса да, хуннарның яки бу бөек хөкемдарның теленә караган мәгълүмат бик аз *(Nemeth, 1962: 141-142, 215-224).* Рим һәм Европа тарихында бик көчле варвар сурәте белән характерлана торган Аттиладан соң, Урта гасырлар һәм яңа дәвер буенча Европага төньяктан яисә көнчыгыштан килгән Азия кавемнәре һәм хөкемдарларының һәммәсенең дә тарихта шундый ук сурәт белән урын биләп торулары билгеле.

Аттиланың Рим империясенә ясаган һөҗүмнәре һәм йогынтысы турында француз тюркологы Jean Paul Roux шул фикерләрне әйтә: «Көнбатыштагы ике явы белән Аттила «Тәңре җибәргән газап»ка әверелә һәм өстенлекләр белән тулы бөтен гомере буенча казанганнарыннан да артыграк дан казана. Инде хәзер ул – «үтеп киткән җирендә үлән үсми торган» кешегә, ул вакытларга кадәр һич игътибар җәлеп итми торган гаскәре – хуннар исә кешелектән насыйбын ала алмаган мәхлукларга әйләнә. Аттиланың ысуллары Чыңгыз хан, Тимерлан кебек әлегә билгесез кайбер бик ерактагы хәлифләрнең кулланачак ысулларына охшаган. Атом бомбасы кадәр үк чигенергә мәҗбүр итә торган корал һәм террорга таянган ысуллар – тоташ юк итү белән шартсыз-нисез дошманга бирелүдән кала бер генә башка ысул да калмый. Бу яшендәй йөгерек яуларның максаты да басып алудан бигрәк талау була» *(Roux, 2007: 72).*

Л.Гумилёвның Аттиланы тасвир иткән түбәндәге юлларында исә аның күркәмлеге, затлылыгы чагыла: «Ярсуы куркыныч, дошманнарына карата аяусыз, тик коралдашларына, юлдашларына карата ул гаҗәеп дәрәҗәдә шәфкатьле була. Хуннар аның сәләтенә һәм кыюлыгына ышаналар. Шул сәбәптән булса кирәк, Иделдән Рейнга кадәр бөтен кабиләләр аның байрагы астында берләшәләр. Хуннардан башка остроготлар, гепидләр, түрингиләр, херуллар, турҗилиңнәр, ругиләр, болгарлар һәм акассирләр (акатирләр) аның байрагы астында сугыша. Болардан тыш, чыгышлары белән Рим һәм Грек илләреннән булган бик күп кеше, аңа хезмәт итәргә теләп, гаскәренә килеп кушыла» *(Гумилёв, 2005: 584).*

Император Теодосиус II тарафыннан Аттилага җибәрелгән һәм башында Максиминус дигән кеше торган илчеләр төркемендәге Фракия кешесе Прискосның сәяхәт язмалары булган грек телендәге «фрагмент» тупламы – V гасыр хуннар тарихына караган иң кыйммәтле чыганак. Тарихчылар өчен бик әһәмиятле бу язмаларда курку катыш хөрмәт тудырган риваятьләр түгел, хун өлкәсенең географик һәм этнографик тасвирлары, хуннарның көнкүреш рәвеше, телләре, гореф-гадәтләре, кунакчыллыклары, хуҗалык итү, җитештерү, ризык төрләре белән бәйле объектив мәгълүматлар теркәлгән *(Ahmetbeyoğlu, 1995: 77).*

Антик дәвердә Искит мәгълүматын теркәп калдырган борынгы грек җәмгыятеннән,

иртә чор Византия чыганакларыннан башлап бүгенге көнгә кадәр дәвам итеп килгән тарих язучылыгы (историография), варвар сурәтен гасырдан гасырга тапшыра килгән. Аттиладан соң алты гасыр үткәч, XIII гасырда, Чыңгыз хан һәм дәвамчыларының да шул ук сурәт эченә утыртылуын нәкъ менә бу гасырдан гасырга күчү белән аңлатырга мөмкин. Рус тарих китапларындагы Алтын Урдага карата булган күралмаучанлыкның да борынгы греклардан калган варвар хыялый сурәтенә барып тоташуы ачык аңлашыла.

Византиянең Анатолия дип йөртелгән өлкәсенең тора-бара Төркиягә әйләнү хәрәкәте белән бәйле рәвештә, XI гасырдан башлап тарих сәхнәсенә инде бер гасыр элек Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән күпсанлы угыз кабиләләре чыга. Бу көнбатыш төркиләренең Сәлҗуклы һәм аннан соңгы Госманлы дәверендәге яулау һәм сәясәт йөртү өлкәсендәге уңышлары да Европадагы мең еллык варвар сурәте эчендә тарихи елъязмаларда чагылыш тапкан. Аттиланың үлеменә төп-төгәл 1000 ел тулганда, Истанбулны яулап алган Фатих Солтан Мәхмәд, чорыннан күпкә өстен уку-язу осталыгына ия зыялы шәхес булса да, Көнбатыштагы әлеге дә баягы шул варвар сурәтеннән котыла алмаган. Атаклы немец язучысы Stefan Zweigның 1927 елда иҗат иткән «Sternstunden der Menschheit – Кешелекнең йолдызы ялтыраган мизгелләр» исемле язмаларында урын алган Мәхмәт II хакындагы хикәясе инде классиклашкан ике мең еллык хикәяләрнең бер үрнәге булып тора.

Урта гасырларның тарихи елъязмаларында варварларны атауда кулланылган *татар* этнонимы бик борынгы исем булганга, борынгы чор тарихи язмаларда ук теркәлгән. Кытайлар Чыңгыз ханга кадәр монгол даласында яшәгән халыкларга *татар (тата)* исемен биргәннәр. Шул ук вакытта, бүгенге татар халкының милләт булып оешуы *(этногенез)* X гасырда Ислам динен кабул иткән Идел-Кама болгарлары һәм алардан соңрак бу җирләргә баш булган күпсанлы кыпчак кабиләләренең берләшеп кушылуы белән бәйле.

Безнең эраның 482 елыннан башлап исемнәре Византия чыганакларында күренә башлаган һәм VII гасыр уртасында Идел буенда тупланган болгарлар (Утригур / Отуз огур болгарлары), вакытлар үтеп, X гасырда (922 ел) Ислам динен кабул итәчәк төрки кавемнәрнең борынгы бабалары була. Аларның иң якын кардәшләре – Дунай болгарлары (Кутригур / Докуз огур болгарлары) исә, Византия йогынтысы астында IX гасырда (864 ел) христиан динен кабул итеп, славянлашканнар *(Rasonyi, 1993: 89; Yüce, 1992: 390)*. Югары дәрәҗәдәге мәдәнилек тудырган болгарларның көньякта һәм төньякта ярты гасыр аралык белән ике аерым дингә керүләре дөнья тарихында аннан соңгы ике мең елга турыдан-туры йогынты ясаган гаять әһәмиятле вакыйга була.

Безнең эраның V-X гасырларында яшәгән Дунай болгарларының туган теле булган болгар төрки теленең эзләре бик аз сакланган. Болар кайбер чыганакларда очраган кеше исемнәреннән, чин атамаларыннан, төрле әйберләр өстенә язылган сүзләрдән гыйбарәт. Алтаистика һәм төрки телләрне чагыштырма өйрәнү өлкәсендә [з] фонемасының – [р] белән, [ш] фонемасының исә [л] белән алыштырылуы күзәтелгән гомумтөрки сүзләр белән чикле Дунай болгар төрки теле хәзинәсе З.Гомбоц, Г.Фехер, Дж.Дени, Дж.Бенцинг, К.Х.Менгес, Т.Текин кебек галимнәр тарафыннан тикшерелгән *(Tekin, 1987)*.

Идел болгарларының тел хәзинәсе исә XIII-XIV гасырларга караган кабер ташларындагы язулардан гыйбарәт. Боларны фән дөньясына ачуда Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Г.Әхмәрев кебек татар галимнәре зур өлеш керткән. XIX гасырда Н.Ильминский бу болгар төрки теленең чуваш теленең нигезендә ятуы турында фикер әйтә. Соңыннан фикер рус һәм европа тарихчылары тарафыннан да бик үз ителә, ә Н.Ашмарин тарафыннан тагын да алга җибәрелә *(Tekin, 1988: 2-3)*. Бөек мәдәни үзәк булган Болгарның бердәнбер мирасчысы итеп чуваш халкын күрсәткән бу фикерне Үзбәк Байчура (1980), Фәрит Хәкимҗанов (1987) һәм Мирфатыйх Зәкиев *(2008: 294-370)* кебек татар галимнәре тәнкыйть итеп чыкты.

Төрки тамырлы борынгы катлам тәшкил иткән болгарлар белән алар артыннан бу җирләргә җәелгән кыпчаклар – [латин.: *Cuman;* рус.: *Половцы;* поляк.-латин.: *Plauci, Plawci;* чех.-латин.: *Plavci;* латин.: *Pallidi, Flavi;* немец.: *Valwen, Falwen, Falones;*

герман.-латин.: *Valani* – «ачык төстә, алтын сарысы, тонык сары, кызгылт сары»] бүгенге татарларның бабалары.

VIII гасыр башларында Орхон-Енисей буйларында хакимлек иткән Төрки каганлыкта беренче тапкыр язу теле буларак барлыкка килгән борынгы төрки тел кебек үк, көнчыгышта туган кыпчак теле дә бүгенге көндә татар теле дә кергән бөтен хәзерге төрки-кыпчак әдәби телләре өчен XI гасырда теркәлгән нигез тел булып тора. Бу тарихи диалект турында җентекле мәгълүматны беренче булып Мәхмүд Кашгарый биргән. «Диване лөгать эт-төрк» (1074) дип аталган беренче төрки сүзлектә ул XI гасырның төрки диалектларын тасвир иткән һәм бу гасырның иң көчле төрки кавемнәре булган угызларга һәм кыпчакларга зур урын биргән. Әлеге хезмәттә угыз һәм кыпчак телләреннән башка тагын карлук, йагма, чигил, йемек, ограк, тухси, уйгыр, болгар, сувар, аргу, кәнчәк, басмыл, чөмүл, кай, татар, йабаку, хотан, согд, түбүт, баласагун, барсган, кашгар, куча, сайрам, уч кебек егермедән артык кавем һәм кабиләнең тел үзенчәлекләре күрсәтелгән *(Karahan, 2008: 42).*

Кыпчак теле тарихи шартларга бәйле рәвештә бары тик XIII гасырда гына әдәби тел буларак кулланыла башлый һәм XIII-XVI гасырларда дәүләт теле, әдәбият һәм фән теле булып формалаша. Бу дәвердә Алтын Урданың, аның артыннан Казан һәм Кырым ханлыкларының һәм XIII гасырда, Әйүбиләр заманында, үзәге Мисыр булган Урта Көнчыгышта барлыкка килгән Мәмлүк дәүләтенең дә теле – кыпчак теле була.

XI гасырда кыпчаклар җәелеп яшәгән җирләр – Кара диңгезнең төньягында Кавказ тауларыннан алып Карпат тауларына кадәрге далалар, фарсы телендәге чыганакларда искә алынганча, Дәшт-е Кыпчак иде. Бирегә урнашкан һәм борынгы ватаннарыннан язма мәдәният йогынтысы килеп ирешмәгән кыпчаклар яки, Европада танылган исемнәре белән әйтсәк, команнар, алдагы чорларда венгрлар һәм болгарлар белән булган кебек, христиан миссионерларының тәэсиренә дучар ителә. Бу миссионерлыкның бер нәтиҗәсе – итальян һәм немец монахлары төзегән «Codex Cumanicus» исеме белән танылган дәфтәрләр. Әлеге миссионерлыкның ни дәрәҗәдә уңышка ирешкәнлеге, христианлашканнан соң никадәр команның румын, болгар һәм венгр милләтләре эчендә эреп юкка чыкканлыгы турында мәгълүматыбыз юк. Бары тик шуны әйтергә мөмкин: XIV гасыр башларында язылган һәм христианлык белән бәйле догалардан, дини җырлардан, латинча, фарсыча һәм команча сүзлектән торган «Codex Cumanicus», кыпчак сөйләм теленең кыйммәтле истәлеге буларак тюркологиядә инде ике гасыр буе филологик эзләнүләр темасы булып тора *(Árpád, 1998: 158-165; Golden, 2014: 183-202; Grønbech, 1942).*

Башында Византия торган ул чор хаким дәүләтләре боерыгы астында бихисап күп сугышчы гаскәре хәлендә гасыр арты гасыр гомер сөргән кыпчакларның теле (яки коман теле, polevest теле) Мисырда мәмлүк (хакимлек яулаган коллар) солтаннарының, яңа әфәнделәрнең дә теле була. Шул ук кыпчак теле Чыңгыз хан ыруыннан килгән, тик тора-бара төркиләшкән Алтын Урда *(татар)* ханнарының ярлыкларында да әфәнде катламының, дәүләт ияләренең теле буларак мәгълүм. Бу ханнарның Госманлы дәүләтенә язган ярлык һәм битикләре (хатлары), кыпчак төрки теленең истәлекләре буларак, Истанбул Топкапы сарае музеенда саклана. Мәсәлән, Алтын Урда хөкемдары Олуг Мөхәммәд ханның Госманлы солтаны Морад IIгә 1428 елда язган «битиг»ендә аның кыпчакча сөйләме игътибарны җәлеп итә. Бүгенге Румыниянең төньягында урнашкан җирләрдә, Госманлы дәүләте белән үз дәүләте арасында калган «кяфер улак»ны бергәләп алып ташларга тәкъдим иткән Олуг Мөхәммәд хан, үзара сәүдә мөнәсәбәтләрендә булуны таләп итә; бигрәк тә «кичәр бой калур мәнгү ат» дип, югалмый торган дуслык мөнәсәбәтләренә чакыра *(Kun, 1949: 603-644).* Бу ярлык һәм битикләрдән, Алтын Урда, Казан һәм Кырым ханнарының, XV гасырда Византияне уртадан алып ташлап, үзе бер дөнья дәүләте хәленә килгән Госманлы дәүләте солтаннары белән югары дәрәҗәдә аралашулары аңлашыла.

Алтын Урдада, аеруча XIV гасырда, Ислам дине халык арасына үтеп керә барган саен, монгол булуларын оныта башлаган аксөяк әфәнделәр төркиләшә. Җирле телләрне, бигрәк тә болгар телен артта калдырып, кыпчак теле җәелә бара *(Roux, 2007: 286).*

Ислам географиясе белән бәйле борынгы әсәрләрдә *татар* атамасы бик сирәк

очрый: «Безнең эраның 982-983 елында язылган «Худуд-и галәм»дә татарларның докуз огузлар (тогуз гуз), ягъни уйгырлар белән бер үк ырудан булулары искә алына. Бу хәл татарлар арасындагы кайбер төркемнәрнең уйгырлар идарәсе астында булулары белән бәйле. Гәрдизи, X гасырда яшәгән география язучысы Җәйхани биргән мәгълүматларга таянып, төрки халык – кимәкләрнең бер нәселе чыгышы буенча татар дип белдерә. XI гасыр әсәрләрендә татарлар турында беркадәр күбрәк мәгълүмат бар. Җүрҗан Мәлики Кәйкавус бине Искәндәр үзенең «Кабуснамә» исемле әсәрендә татарлар – төрки кавемнәр арасында кыенлыкларга иң күп түзгән кавем, дип яза. Газнәле һәм Сәлҗуклы дәвере шагыйрьләренең шигырьләрендә дә татар атамасы күренгәли. Монголлар турында сүз алып барган фарсыча язылган әсәрләрдә монголлар хакында *монгол* һәм *татар,* гарәпчә язылган чыганакларда исә күбесенчә *татар* атамасы очрый, бик сирәк кенә монгол атамасы кулланыла. Мәмлүк тарихчылары үз дәүләтләренең иң төп дошманы булган илханлыларга *татар* диләр һәм Тимерланга карата да шул ук атаманы кулланалар, монголларны алар мәмлүк төркиләренең кардәшләре дип саныйлар. Ислам чыганакларында *татар* атамасы күбесенчә монголларга карата кулланыла. Монголларның Чыңгыз хан заманыннан башлап көнбатышка таба хәрәкәт итүләре, җәелүләре, Ислам дине таралган җирләрне яулап алып җимерүләре, 1258 елда Багдад шәһәренә кереп Аббаси мәмләкәтен юк итүләре, 1260 елда Мәмлүкләрнең җиңүе белән тәмамланган Айниҗалут сугышы нәтиҗәсендә яуларының туктатылуы турындагы вакыйгалар чыганакларда әһәмиятле урын били» *(Sümer, Tatarlar: İA C.40, s.168).*

Шул рәвешле, профессор Фарук Сүмәрнең әйтүе буенча, Урта гасырларда *татар* атамасы, нигездә, монголларга карата кулланылган. Төркия тарихында да *татар* исеме һәм аңа бәйле рәвештә монголларны хәтерләү элекке вакытларда һич кенә дә уңай түгел иде. «Латин чыганакларында *татарлар* дип искә алынган монголлар, шул ук чыганаклардан күренгәнчә, 1256 елда Анатолияне (төрекчә – Анадолу) буйсындырганнан соң, Урта Анатолиядәге күчмә тормышка яраклы бөтен җирләрне басып алалар. Кызылырмак елгасына коя торган кечерәк елгаларның саны бик күплектән «Инеш-елгалар төбәге» дип аталган һәм үзәннәр белән капланган бу җирләр күчмә халык өчен кышны үткәрергә бик уңайлы, язын исә мул үләнле көтүлекләргә бик бай була. Шул сәбәпле, монгол кабиләләренең бер өлеше киң җәйләүләрдә һәм кышлакларда иркенләп тормыш корып җибәрә. Монгол кабиләләре Кайсери, Сивас, Чорум, Йозгаттан Искешәһәр төбәгенә кадәрге бөтен җирләрне үз илләре иткәннәр. Нәкъ шул чорда, 1245-1248 еллар арасында, Анатолиядә миссионерлык белән шөгыльләнгән монах Доминикен Simon de Saint-Quentin үзенең латин телендә язылган «Historia Tartarorum» исемле әсәрендә монголларның гореф-гадәтләре, ышанулары һәм көндәлек тормышлары турында бик кызыклы мәгълүматлар бирә» *(Cambridge, Türkiye Tarihi, 1071-1453, Cilt I: 432).*

Анатолиягә монголлар килгән юлдан XV гасыр башында Әмир Тимер дә килә, Балканнарда хәрби һәм сәяси уңышларга ирешкән Госманлы дәүләтен Әнкара сугышында (1402) җиңеп, Солтан Баязитны әсир ала. Алты гасырдан артык дәвам иткән Госманлы тарихында бу иң җитди авыр вакыйга XIII гасырдагы җимергеч монгол яуларының хатирәсен яңарта.

«Бөек әмир» Тимернең ярдәме белән Алтын Урда дәүләтен терелткән Туктамыш хан, бөтен дошманнарын җиңеп, рус тарихи елъязмаларында «татар хакимияте» дип аталган чорны тагын бер гасырга озайткан. Масаеп китеп, Туктамыш хан 1387 елда үзен улы кебек якын күргән һәм ярдәм итеп торган Тимернең Кавказдагы, Мавәраэннәһердәге көчләренә һөҗүм итә. Тимерлан айлар, елларга сузылган бу бәрелеш өчен 1395 елда бик катгый һәм кырыс итеп җавап кайтара. Шул рәвешле, *татар* исемен дөньяга ишеттергән Алтын Урда Тимернең җимергеч һөҗүменнән соң бетә, юкка чыга дип әйтергә мөмкин *(Roux, 2007: 315-316).*

Татар атамасы, аеруча Алтын Урда заманында, күрше халыкларның карашлары нигезендә объектив атама буларак тарала. Ләкин тарихта татар атамасының Алтын Урда варислары булган Кырым-Идел-Урал мөселман төркиләре өчен субъектив милли үзатама хәленә килүен XIX гасырның ахырларына кадәр көтәргә кирәк иде әле.

Яңарышның Госманлы төрекләрендә, татарларда һәм Кавказда башланып, бөтен төрки дөньяга җәелүе күзәтелгән XIX гасырда, *татар* атамасы башта милли үзаңга ирешкән җәдитче зыялылар, бераздан уку-язу өйрәнеп агарган халык тарафыннан үзатама буларак кабул ителгәннән соң, хәзерге, уңай татар сурәте барлыкка килә.

Алтын Урдадан соң оешкан ханлыкларда да өстен тотылган шәхсият – татарлык түгел, мөселманлык була. Көнбатышта да, көнчыгышта да милли түгел, дини шәхсият өстен тотылган Урта гасырларда бу – гаять табигый хәл. Русия дәүләте иң җитди көндәшләре булган әлеге ханлыкларны бер-бер артлы үзенә буйсындыргач, 1552 елдан соң башланып киткән көчле христианлаштыру хәрәкәте барганда, бүгенге татарларның ул чордагы бабаларының үзләрен *татар* дип түгел, *мөселман* дип атаулары бу тарих яссылыгында шактый аңлаешлы булып күренә.

Хәзерге мәгънәдәге татар шәхсиятенең барлыкка килүе, һичшиксез, XIX гасырда алга киткән яңарыш агымы белән бәйле. Stanford университеты профессоры Азадә-Айшә Рорлих, халыкның баштагырак чорларда үзен һәрвакыт *мөселман* дип танытуы, шуның белән бергә *татар, казанлы, болгар* һәм *мишәр* кебек этнонимнарны да кулланыуы турында яза. XIII гасырда мәшһүр булган *монгол татарлары* белән буталмас өчен барлыкка килгән бу реакция XIX гасырда үзенең урынын татар милли горурлыгына тапшыра. «Ләһҗә-и татари»не язган галим Каюм Насыйри һәм бөек тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани кебек шәхесләрнең эшчәнлеге, фикерләре, татар атамасының милли шәхсият буларак үз ителешендә реабилитация ролен башкарган *(Rorlich, 2000: 27-28).*

Татарчада *мәгърифәтчелек* дип аталган агару, белем туплау агымы, Русиядә Пётр I реформалары белән бер гасыр элек башланган яңарыш, үсеш процессына мөселман җәмгыятен дә тартырга тырышулар бөтен төрки дөнья өчен әйдәп баручы булачак һәм йогынтысы көчле ренессанска әверелә.

Исламдагы дини күрсәтмәләрне үзгәртү, бозу очракларын тәнкыйтьләү белән башланган реформалар динне яңача аңлап кабул итү күренешен барлыкка китерә. Мәктәп-мәдрәсәләр белән бергә рус мәктәпләрендә дә белем алу башлаган XIX гасыр ахырында, формалашуга йөз тоткан ысулы җәдит буыны, цензура астында булса да, тора-бара байый барган татар матбугатыннан алып сәхнә әсәрләренә кадәр барлык өлкәдә дә яңарыш кичергән җәмгыятьтә хөр фикерле яшьләр барлыкка килүгә юл ача. Патша хөкүмәтенең соңгы унике елы (1905-1917) – бүгенге көндә интеллектуаль мәдәниятнең һәр өлкәсендә һәрбере бер татар маркасы хәленә килеп классиклашкан Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Кәрими, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди кебек шәхесләр якты эшчәнлекләре белән танылган дәвер иде.

Урта гасырларда уңай булмаган татар сурәте, шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX йөз башлары арасында заманадан артта калмас өчен балаларын укыткан, халкын агарткан, хатын-кызлары да иҗтимагый тормышка катнаша башлаган яңа мөселман җәмгыятенең алдынгы үрнәгенә әверелә. Русиядә, аеруча Екатерина II патша хакимиятеннән соң, көнчыгышка капка ачкан алдынгы муллаларны Урта Азиядә, хәтта Кытай Төркестанында да бүген дә хәтерлиләр. Сәүдә итү аркасында икътисадый һәм шулай ук мәдәни яктан баеган, телләр өйрәнгән, кешелек бәйләнеш төрләре арткан татарлар, Балтыйк ярларыннан казакъ далаларына кадәр уңай исемнәрен җәелдергәннәр.

XX гасырның беренче егерме елында Казан, Бакчасарай, Оренбург, Уфа кебек шәһәрләр, киң төрки дөньяның иң көнбатышындагы мәдәни үзәкләр булып калкып чыга. Шул рәвешле, Госманлы Төркиясендәге реформаларның йогынтысы җәелгән Кавказ төбәгендәге Тифлис (Тбилиси) һәм Бакуны да кертсәк, төрки җәмгыятьләр соңга калыбрак катнашкан яңарыш ярышы барган үзәкләрнең һәммәсен дә искә алган булып чыгабыз. Шуның белән бергә, Тимерлан һәм аның дәвамчылары дәверендә чәчәк ату чорын кичереп, яңа гасырларда тукталып калган һәм хәтта артка чигенгән Төркестанның Бохара, Сәмәрканд кебек классик мәдәни үзәкләренең XIX гасыр ахырында, дини схоластик йогынтыдан котылып, белем алу, агару юлында артта калганлыгын әйтеп үтәргә кирәк. Хәзерге казакъ әдәбиятына нигез салган Абай Кунанбаевның тормышы һәм иҗаты буенча күләмле гыйльми хезмәт булып саналган

«Абай энциклопедиясе»ндә (1995) *татар* темасы шул рәвешле чагылыш тапкан: «Татар һәм казакъ бәйләнешләре шактый элекке заманнарда ук башланган. Татарлар көнчыгыштан көнбатышка, Русиядән Урал тауларының аръягына үтеп, далаларга кадәр килеп җиткәннәр, сәүдә иткәннәр, аеруча яңарыш чорында мәктәп һәм мәдрәсәләр ачып, казакълар арасында Ислам динен таратканнар. Татарлар Казакъстан җирләренә, аеруча Семи, Вернай, Капал, Җидесу төбәкләренә күпләп килеп урнашканнар. Казакъ әдәбиятының нигезен салган Абай Кунанбаевның шигырьләрендә татарча сүзләр бик еш очрый. Реформачы казакъ шагыйренең халкын агарту максаты белән язган фәлсәфи-дини әсәрләре «Кара сүзләр» (кыска ак шигырьләр) яки «Гаклияләр» буларак танылган. Боларның икенчесендә акын *ногай* атамасын кулланса да, чынбарлыкта *татар* сурәтен чагылдырган» *(Barakulı, 1995: 538).*

Бөек казакъ акыны Абайның татар сурәтен чагылдырган шигырь юллары түбәндәгеләр: «Ногайга карасам: гаскәрлеккә дә түзә, юксыллыкка да түзә; бәла-казага да түзә, чыдый; мулланы, мәдрәсәне, динне саклый. Хезмәт куеп, табыш алуның да юлын алар белә, хакимлек, күркәмлек тә аларда. Аларның байлары янында, беребез – туймас тамагыбыз хакына хезмәтче, беребез мәҗлесендә утырабыз» *(Абай, 1986: 96).*

Татар әдәбиятының Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов кебек бөек язучыларының тормыш хикәяләрен укыганнан соң, бу акыл һәм талант ияләренең берара далага китеп, казакъ халкы арасында бик теләп көн иткәннәре аңлашыла. Казан университетында укыр өчен акча эшләргә дип казакълар арасында укытучылык белән шөгыльләнгән Г.Ибраһимовның, бераз вакыт үткәч, 1909 елда Уралда яза башлаган «Казакъ кызы» романы аның бу чордагы тормыш тәҗрибәсенең җимеше булып тора.

Татар язучысы Мәгъсүм Насыйбуллин, татар-казакъ әдәби бәйләнешләрен тикшергәндә, Жакан Сыздыков (1901-1977) исемле казакъ әдибенең истәлекләрендә урын алган шул юлларны китереп үтә: «Казакъ язма әдәбиятын тудырган беренче буын язучыларыбыз турыдан-туры татар әдәбияты осталыгы астында тәрбияләнделәр, татар мәдрәсәләрендә белем алдылар, татар матбугатында үзләрен күрсәттеләр, татар нәшриятында китапларын бастырдылар» *(Насыйбуллин, 1992: 15).*

«Кыргыз совет энциклопедиясе» дә, татар әдәбияты турында мәгълүмат биргәндә, кыргыз язучыларының Г.Тукай шигырьләре белән совет чорына кадәр үк таныш булганлыгын билгеләп үтә. Тукай шигырьләре Молдо Кылыч һәм Тоголок Молдо кебек кыргыз шагыйрьләренең шигъри әсәрләренең профессиональ дәрәҗәгә күтәрелүләренә җитди йогынты ясаган *(Kırgız Sovyet Entsiklopediyası – 5, 550).*

Татар китабының тарихы буенча зур белгеч профессор Әбрар Кәримуллин билгеләп үткәнчә, казакъ, кыргыз кебек дала халкының беренче китаплары Казан һәм аның якын-тирәсендәге татар мәдәни үзәкләрендә басылган *(Кәримуллин, 1979: 102-129).*

XX гасыр башларындагы татар буржуазия вәкилләре, байлыкларыннан өлеш чыгарып, милли матбугатка, милли әдәбиятка һәм белем бирү эшләренә акчаларын сарыф иткәннәр, милләтне алга җибәрүдә ярдәм күрсәтеп, үзләреннән соң якты истәлекләр калдырганнар. Советлар Берлеге артыннан Евразия киңлекләрендә яңа сәхифә ачып җибәргән төрки дөнья өчен бу татар буржуазиясе һәм татар яңарышы бүгенге көндә матур үрнәк булуын дәвам итә. Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Бигиев, Каюм Насыйри кебек татар фикер дөньясының реформачылары иске җәмгыятьләрен схоластикадан коткарган. Яңарыш белән дустанә яши торган дини тойгы барлыкка китерергә тырышучы шәрекъ дөньясы исә, әлеге алдынгы фикер ияләренең мирасына бүген дә мохтаҗ. Финляндиядән Америкага кадәр дөньяның бөтен почмагында оешкан татар җәмгыятьләре үзләренең эшчәнлекләре белән, диаспора вәкилләре исә һәр төрле тирәлектә яшәргә, чит телләр өйрәнергә, яңалыкларны үз итәргә хәзер торучанлыклары белән уңай татар сурәтен яшәтә киләләр. Күптелле һәм күпмилләтле тирәлектә яшәүче Татарстан Җөмһүрияте исә бу уңай татар сурәтенең ватаны булып мәңгегә калачак.

**Чыганаклар**

Абай. Эки томдык шыгармалар жыйнагы. 2 том. Авдармалар мен Кара Сөздәр. – Алматы: «Жазувшы», 1986.

Абай энциклопедиясе. Редакторы Р.Н.Нургалиев. – Алматы, 1995. – 720 б.

Ahmetbeyoğlu A. Grek Seyyahı Priskos'a Göre Avrupa Hunları. – İstanbul: «Türk Dünyası Araştırmaları Vakfı», 1995. – 84 s.

Árpád B. Middle Kipchak: The Turkic Languages (Edit. L. Johanson, E.A.Csato). – 1998. – s.158-165.

Baichura U. Tataro-Bulgarica I: On the Bulgar Origin of the Qazan Tatars According to Some Linguistic Data: Studia et Acta Orientalia 10. – Bucarest, 1980. – s.15-26.

Barakulı T. Tatar: Abay Entsiklopediyası (Red. R.N.Nurgaliyev). – Almatı, 1995. – 720 s.

Cambridge Türkiye Tarihi, 1071-1453, Bizans'tan Türkiye'ye Cilt I (Edit. Kate Fleet; çeviri Ali Özdamar). – İstanbul: Kitap Yayınevi, 2012. – C.1. – 600 s.

Golden P. Qıpçaq: Turcology and Lingusitics, Évá Ágnes Csató Festschrift (Edit. N.Demir, B.Karakoç, A.Menz). – Ankara: «Hacettepe Yayınları», 2014. – s.183-202.

Grønbech K. Komanisches Wörterbuch, Türkischer Worlindex zu Codex Cumanicus. – Copenhagen: Monumenta Linguarum Asiae Maioris, 1942. – Subsidia 1.

Gumilyev L.N. Hunlar (çev. Ahsen Batur), 4. – Baskı, İstanbul: «Selenge», 2005. – 665 s.

Зәкиев М.З. Татар халкы тарихы (Этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге). – Казан, 2008. – 543 б.

Karahan A. Dîvânü Lugâti't-Türk'e Göre Oğuzca: Oğuzlar: Dilleri, Tarihleri ve Kültürleri, 5. Uluslararası Türkiyat Araştırmaları Sempozyumu Bildirileri. – Ankara: «Hacettepe Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü», 2015. – s.41-60.

Кыргыз совет энциклопедиясе. 5. – Редакторы – Б.Орузбаева. – Фрунзе, 1980. – 656 б.

Kun T.H. Philologica III, Kazan Türkçesine Ait Dil Yadigârları, AÜ DTCF Dergisi C. VII (S.4.), 1949. – 603-644 s.

Nasıbullin M. Tatar-Kazak Edebî İlişkileri, Dostluk Büyük Zenginlik («Kazan Utları», 1989, Sayı 12; den aktaran. M.Öner) // Kardeş Edebiyatlar, Erzurum, Sayı 21, yıl 1992. – s.15-20.

Németh Gy. Attila ve Hunları (terc. Şerif Baştav). – Ankara: «DTCF yay 106», 1962. – 326+XX s.

Rasonyi L. Tarihte Türklük (3. Baskı). – Ankara: «TKAE», 1993. – 420 s.

Rorlich A. Volga Tatarları. – İstanbul: «İletişim», 2000. – 392 s.

Roux J.P. Türklerin Tarihi, Pasifik'ten Akdeniz'e 2000 Yıl. – İstanbul: «Kabalcı», 2007.

Sümer F. Tatar: İslam Ansiklopedisi (MEB), 1979. – C.12-1. – s.56-61.

Tekin T. Tuna Bulgarları ve Dilleri. – Ankara: TDK 530, 1987. – 70 s.

Tekin T. Volga Bulgar Kitabeleri ve Volga Bulgarcası. – Ankara: TDK 531, 1988. – 212+91 s.

Yüce N. Bulgar: İslam Ansiklopedisi (TDV) cilt: 6 – 1992, s.390-391.

Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. – М.: «Наука», 1987.

**Мостафа ӨНӘР,**

*Эге университеты профессоры, Төркия.*

*Төрекчәдән* **Асия РӘХИМОВА** *тәрҗемәсе*

*5-9 июнь көннәрендә Казан шәһәрендә унөченче тапкыр Халыкара «Нәүрүз» театрлар фестивале узды. Әлеге фестиваль, матур традициягә әйләнеп, тамашачыларга – төрки театрларның иҗаты белән якыннан танышу, ә театрларга исә үзара тәҗрибә уртаклашу, иҗади осталык алмашу мөмкинлеге бирә. Башлангычында торган Шамил Закиров, Марсель Сәлимҗанов кебек легендар шәхесләрнең исемнәре белән бәйле булуы «Нәүрүз» фестиваленең абруен тагын да арттыра.*


*Төрки театрларның үзара «бил алышында» катнашкан «Ай тотылган төндә» (Мостай Кәрим, Фаил Ибраһимов) спектакленә нисбәтле язма укучыларыбыз күңеленә дә хуш килер.*

**Редакция**

# ТУЛГАНАЙ ТОТЫЛГАНДА

Кызганыч ки, бүген трагедия жанры татар сәхнәсендә сирәк күренә. Әмма Чаллы драма театры бу «Түрк халыклары җыены»на нәкъ менә трагедия алып килгән иде. Театрның баш режиссёры Фаил Ибраһимов куелышында Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» спектакле фестивальнең аерым бер бизәге булды. Әлеге тамаша Чаллы театрының иҗади йөзен күрсәтте, бу иҗади йөз сәламәт, гүзәл һәм талантлы йөз икәненә ачык дәлил булды.

Милләттәшебез Мостай аганың «Ай тотылган төндә» пьесасын йөзләп театр сәхнәләштерде, шулар арасында Туймазы татар театры, Татар Дәүләт академия театрлары да бар иде. Бөтен Советлар Союзы театрларында гөрләп бара торган бу пьеса Татар Дәүләт академия театрында уңышсызлыкка очрады (1963). Режиссёр Ширияздан Сарымсаков куелышындагы әлеге спектакльнең сәхнәдә озак бармавының



*«Ай тотылган төндә» (Мостай Кәрим) спектакленнән бер күренеш. Режиссёры – Фаил Ибраһимов.*

сере, минемчә, әсәргә салынган фаҗиганең режиссёр тарафыннан артык купайтылуында иде: караңгы сәхнә җиһазлары, алама-сәләмә киемнәр, кургашын болытлар, авыр-трагик музыка, актёрларның алдан ук «трагедия» уйнаулары спектакльне бармас дәрәҗәгә китергән иде.



*«Ай тотылган төндә» (Мостай Кәрим) спектакленнән бер күренеш. Режиссёры – Фаил Ибраһимов.*

Ә менә Башкорт академия театры артистлары бу спектакльне якты-гүзәл декорацияләрдә, Җыр-бию ансамбленә тегелгән киемнәр кебек матур киемнәр киеп уйнадылар. Тамашаны сәхнәләштерүче сәнгатькәрләр гүя фаҗигаләр бай йортларда, матур табигатьтә ешрак була, дип әйтәдер кебек. Башкортларның бу тамашасы бик зур уңыш казанган иде. Алар спектакльне хәтта Кремль театрында да уйнап, Мәскәү тамашачысын сокландырган иде.

Чаллы театрының «Ай тотылган төндә» спектакле бөтенләй башка, үзгә ысул белән бизәлгән саран сәхнә җиһазлары, риваять чорына якын киемнәр мохитендә уйналды. Һәм актёрларның сәхнәдәге яшәеше шушы саран детальләрне баетты. Күчмә тормыш шартлары үзе шартлы җиһазлар ясарга мәҗбүр итә. Йөк машинасына декорация тутырып йөрү заманнары узды-китте.

Сәхнәне аркылыга урталай бүлеп, «киптерергә» дип тарттырылган зур бер җылкы тиресе эленгән. Ул тире Дәшти-Кыпчак даласының харитасы кебек күренә. Як-яктагы керү-чыгу урыннары да кибәргә эленгән куй тиреләре белән капланган, тиреләр ишек вазифасын үти, җиргә (идәнгә) җанвар тиреләре җәелгән. Вакыйгада катнашучылар шул җәелгән тиреләр өстенә утырып ризык җыялар, киңәшмәләр уздыралар, яратышалар. Югарыда, вакыйгалар өстендә тотылачак тулган ай балкый. (Рәссам – Валерий Яшкулов.) Фаҗига менә шушы мохиттә булачак.

Финалда әлеге җылкы тиресе, дала харитасы урталай аерылып-ертылып китә. Бу да – символ. Тиренең ертылып китүе – ул фикерләрнең урталай бүленүе, Бөек Даланың урталай бүленүе, йолаларның урталай ертылуы һәм, ниһаять, милләтнең урталай ертылуы турыда сөйләмиме икән? Бу – зур фаҗига.

Фаҗиганең шаукымы сәхнәгә Дәрвиш (Илфат Әскәров) кыяфәтендә килеп керә. Әсәрнең төйнәлеше шуннан башлана. Серле, шомлы Дәрвиш сөяк кимерүче Диванаһың җәйләү патшабикәсе Тәңкәбикәнең никахсыз туган үз баласы икәнен белә. Һәм мәкерле Дәрвиш, шушы хәлдән файдаланып, Тәңкәбикәне шантажлый башлый. Ул Шәфәкъка өйләнергә мәкер кора. Салмак кына башланган тамаша әкренләп кыза бара, актёрлар бирелеп уйный. Әүвәлге камерный-сабыр тавышлар көчәйгәннән-көчәя. Күрәсең, режиссёр актёрларының тавышын башта саклый, ул тавышлар фикерләр, ихтыярлар (ирадәләр) бәрелешендә, ягъни кульминациядә кирәк булачак. Әсәрнең төп фикере: йолаларны хөрмәт итегез, йолага каршы барганны алда фаҗига көтә, ди автор.

Ярашкан спектакльдә сәләте чамалы артист – сәләтле булып, сәләтле артист талантлы булып күренә. Чаллы театрының «Ай тотылган төндә»се – ярашкан тамаша (ансамблевый спектакль). Пластика (Нурбәк Батуллин), музыка (Юрий Чаплин), рәссам (Валерий Яшкулов), режиссураларның (Фаил Ибраһимов) үзара ярашып иҗат итүе актёрлар составын да ярашканлыкка тарта. Театрның корифейлары Инсаф

Фәхретдинов (Беренче аксакал), Булат Сәлахов (Икенче аксакал), Рафил Сәгъдуллин (Өченче аксакал) янына талантлы яшьләрнең (Руслан Әюпов, Зөлфия Гыйльметдинова, Энҗе Шиһапова, Фәнис Сәхәбетдинов, Зөлфия Галиуллина) туплануы шушы ярашканлыкны барлыкка китерә.

Иң олы йөк Энҗе Шиһапова (Тәңкәбикә), Зөлфия Гильметдинова (Зөбәрҗәт), Фәнис Сәхәбетдинов (Дивана) белән Руслан Әюповның (Акъегет) иҗади җилкәсенә төшә. Һәм алар бу йөкне башыннан азагынача уңышлы тартып бара. Актёрлар гади пьеса уйнамый, ә риваять уйный, шуңа күрә романтик риваятьләргә хас мохиттә хәрәкәт итәләр, алар кайвакыт балет хәрәкәтләре белән сәхнәдә йөри, Дивананың Дәрвишне эт булып талау күренеше – үзе бер уңышлы эпизод. Монда актёрның акробатлыгы да, эт рәвешен алуы да, физик әзерлек тә, актёрлык гайрәте дә таләп ителә.

Мәхәббәт каһарманы Руслан Әюпов белән мәхәббәт гүзәле Зөлфия Гыйльметдинованың дуэты әсәрнең төп уңышын тәшкил итә. Егетнең актёрлык гайрәте, кирәк чакта пышылдавы, кирәк чакта югары-каты тавыш белән сөйләве, дикциясенең шәплеге һәм, гомумән, Чаллы театрында ачык-чиста Ана теленең яңгыравы да тамашачының күңеленә хуш килде.

Форсаттан файдаланып, режиссёр Фаил Ибраһимовның иҗаты турында кыскача гына мәгълүмат биреп узам.

Утыз өч ел дәвамында Фаил Ибраһимов – дистәләрчә (80) спектакль куйган һәм мул уңыш яулаган режиссёр, Минзәлә һәм Чаллы театрларында баш режиссёр булып озак еллар эшләгән җитәкче, Камал һәм Әлмәт театрларында пьесалар сәхнәләштергән шәхес.

Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр... Театр өлкәсендә дә, әдәбиятта да профессиональ тәнкыйть үшәнләнде. Юкса тәнкыйть талантлы кешенең иҗатын хупларга, үстерергә бурычлы яки аның иҗатын инкарь итәргә тиеш. Соңгы елларда җирлексез мактау, җирлексез хурлау мәкаләләре еш күренә башлады. Андый гамәл әдәбиятны да, сәнгатьне дә үстерми, халыкның зәвыкын боза гына. Әле анысы бер хәл, талантлы кешенең игътибарга лаек әсәрләрен, сыйфатлы спектакльләрен мактамау да, сүкмәү дә эчне пошыра торган нәрсә. Бу да – инкарьнең бер шәкеле, әлбәттә. Битарафлык, күрмәмешкә салышу, талантлы кешенең талантлы икәненә шик белән багу, талантлы кешенең уңышлы әсәрен салып таптау, югары кимәлдәге эшен күрмәгәнгә салышу куркыныч мохит тудыра. Әлеге тенденция – әдәбиятның, сәнгатьнең башка өлкәләренә дә хас күренеш. Сәнгатьнең дә «үз рэкэты, үз мафиясе» бар, күрәсең. Сәнгать булмаганга тәнкыйть юкмы, әллә тәнкыйть юкка сәнгать юкмы? Әлбәттә, алар тыгыз бәйләнгән, тик сәнгатьтә дә, әдәбиятта да, тарих фәне мәйданында да уңышлар бар. Кызганыч ки, ул уңышларның байтагы тәнкыйтьнең эзлекле игътибарыннан төшеп кала. Галимнәрнең гафу ителмәс хәбәрдарсызлыгымы бу? Әллә субъективлыкмы? Әллә театр белгечләре арасындагы гап-гади «күрә карау» галәмәтеме?

Фаил Ибраһимовның катлаулы, бай иҗаты да шулай шау-шусыз гына, мактау таләп итмичә генә өлкәнәйде. Кызганыч, бөтен татарына җиде-сигез генә режиссёр булып та, аларның кайберләре тәнкыйть, матбугат игътибарыннан читтә кала. Юкса, биш-алты спектакль куюга ук, яшь режиссёрның иҗат атналыгын уздырып, аның тоткан юлы, өслүбе, иҗат алымнары турында тәфсилле сөйләшүләрне оештыру Театр әһелләре җәмгыятенең, Актёрлар йортының, Фәннәр академиясенең даими планында булырга тиеш. Гәзитләр, журналлар һәр режиссёрның иҗаты, яңа куйган спектакльләре турында махсус заказ белән мәкаләләр яздырырга, бастырырга тиештер бит инде. Төрле уку йортларында белем алучы шәкертләргә курс, диплом эшләре яздырып, киләчәктә диссертациягә кадәр барып җитәрлек итеп, максатлы рәвештә театр тәнкыйтьчеләре, театр белгечләре әзерләү бер тәртипкә салынырга тиештер. Профессиональ театр тәнкыйтьчеләре, кызганыч ки, бик аз.

Үзенең озын иҗат гомерендә (33 ел) Фаил Ибраһимовның хезмәте турында язылган мәкаләләр күп түгел, унлап булыр. 80 спектакль куйган режиссёр өчен бу – сиксәнннән бер өлеш кенә. Ни өчендер җитди тәнкыйтьчеләр Фаилнең иҗатын күрми, күрергә теләми? Очраклымы бу? Әллә монда нindидер сәламәт булмаган мөнәсәбәтләрнең чагылышы бармы?

Әйдәгез, югары кимәлдәге театр тәнкыйтьчеләрен, театр әһелләрен тыңлап багыйк. Менә, ул чагында (моннан 13 ел әүвәл) Фаил Ибраһимов җитәкләгән Чаллы театрының Казандагы гастрольләреннән соң театр белгечләре оештырган конференциядә телдән әйтелгән, ләкин матбугатка чыкмаган сүзләр (1994).

*Сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илтани Илялова:*

*– Әлеге театр белән мин моннан дүрт ел элек танышкан идем. Бу юлы мин аптырап калдым. Каршымда – яңа театр, сез яхшы якка үзгәргәнсез. «Курку» спектакле шәп. «Күбәләк булып җаны кайтыр» спектаклен мин моннан дүрт ел элек караган идем. Әсәр үзгәргән. Бу – югары дәрәҗәдәге спектакль. Актёрлар ышандырып уйный. Бу – олы, җитди эш.*

*Татарстанның халык артисткасы Гөлсем Исәнгулова:*

*– Чаллы театры – ялтырап торган профессиональ театр! Бу – бәхәссез! Профессионализм – актёрларның яхшы уенында. Әлеге театрда мәһабәт егетләр күп, яшь артисткаларны үз артларыннан ияртә алырдай тәҗрибәле Гөлүсә ханым, Әлфия Рәхмәтуллина кебек артисткалар бар.*

*Драматург Юныс Сафиуллин:*

*– Шәп театр! Хикмәт режиссурада!*

*Камал театры директоры Шамил Закиров:*

*– Зәвыклы театр! Хикмәт репертуар сайлый белүдә. Фаил символлар белән эш итә!*

*Сәнгать фәннәре докторы Гали Арсланов:*

*– Бик кызыклы театр. Югары дәрәҗәдәге профессиональ коллектив. Режиссура көчле. Сәхнәне җиһазлау, бизәү эшләре – сценографиянең образлы булуы – Чаллы театрының йөзе.*

*Камал театры музее мөдире Луара Шакирҗанова:*

*– Театрда зәвык сизелә. Яшь театрның юл башы зәвыктан башлана икән, бу инде бик тә куанычлы күренеш. Театр озын гомерле булсын.*

*Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфи:*

*– Әйбәт, әйбәт, бик һәйбәт театр Фаил Ибраһимов театры.*

*Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Наил Дәүләтшин:*

*– Кыска гына әйткәндә, егетләр булдыра!*

Бу сүзләрне профессиональ актёрлар һәм театр белгечләре әйткән иде. Ләкин ни өчендер профессиональ тәнкыйтьчеләр шушы фикерләрен матбугатта җәеп салмады. Ә абруйлы матбугат ни өчендер дәшми.

Миңа калса, сәхнәдә символлар куллану, образлы детальләр иҗат итү, мизансценалар аша көтелмәгән мәгънә әйтү – режиссёр Фаил Ибраһимовның иҗат алымнарының берсе.

Татар театры, без белә-белгәннән бирле, «ике такта, бер басма – уртасында мәхәббәт» ысулы белән иҗат итә килде. Бигрәк тә күчмә шартлардагы театрлар спектакльләрне гел бер төрле җиһазлый иде. Арткы диварга каенлык (башка очракта: наратлык, урман, болын) күренеше ясап эләләр дә ян-яктан – өй баскычы (болдыр яки тәрәзә), икенче якта тактага ясалган капкамы, мунчамы төртеп куялар, сәхнә уртасына калку урын ясыйлар да, ике егет – бер кыз артыннан, бер егет ике кыз артыннан куыша башлый, көлә-көлә, елый-җырлый мәхәббәт уйныйлар. Һәрвакыт безнекеләр җиңә иде. Өлкән буын артистлары, режиссёрлары, зинһар, миңа үпкәләмәсен, әлбәттә, театр тарихында бик уңышлы спектакльләр дә күп булды, мин монда фәкать гомум «өслүб» турында әйтәм. Ягъни, режиссёрлар спектакльнең образлылыгы, күчмә шартларда шартлы детальләр белән генә кыен хәлләрдән чыгу турында башларына да китерми, чынбарлыкка якын авыр декорацияләр ясата торганнар иде. Бу күренеш татар театрының торгынлык елларында булды. Шөкер, яңа режиссёрлар, яңа актёрлар, яңа драматурглар килде. Татар сәхнәсендә образлылык, читләтеп әйтү алымнары да пәйда булды.

Фаил Ибраһимов – театрның миссиясен тирән аңлап эш итүче режиссёр. Ул пьесаның «орлыгын» тапмыйча, спектакль куярга тотынмый. Аның өчен пьесаның рухына тәңгәл килә торган сәхнә җиһазы кирәк. Образлы ул җиһазны табу өчен,

атналар, айлар уйларга, хыял дөньясында фикер йөртергә кирәк. Фаилнең символлар, абстракция образлары белән эш итүе, иҗат өслүбе беренче спектакленнән үк ялтырап күренә иде инде.



*Чаллы Татар дәүләт драма театрының баш режиссёры Фаил Ибраһимов.*

Фаил Ибраһимовның режиссёр буларак тагын бер асыл сыйфаты бар. Ул – тәрбияче-режиссёр. Шәһәрнең стационар театрлары, гадәттә, әзер актёрлар белән, сыналган, танылган артистлар белән эш итә. Күчмә шартлардагы театрларда актёрларга кытлык була, шуңа күрә артистларны читтән, һәвәскәрләр арасыннан алырга туры килә. Алар актёрлык осталыгы дәресләре узмаган. Менә шулардан режиссёр актёр ясарга тиеш. Спектакль куясы урында режиссёр актёрлык осталыгы дәресләре уздырырга мәҗбүр. Фаил – бу эшнең остасы. Ул – театр мәктәбе эшләп бетермәгән җитешсезлекләрне төзәтергә алынган режиссёр. Ул – уртача сәләтле актёрдан – яхшы актёр, яхшы актёрдан шәп актёр ясый ала торган тәрбияче.

Фаил Ираһимов сәләтенең тагын бер гүзәл ягы бар: ул спектакльдә ярашканлык (ансамбль) хасил итә ала. Товстоногов әйткәнчә: бөек актёрларның берсе – агаракка, икенчесе тагаракка тартып, спектакль уйнауга караганда, урта сәләтлеләрнең берләшеп, ярашып уйнавы кадерлерәк. Ачылып бетмәгән актёрны талантлы актёрга якынлаштыра алу сәләте һәр режиссёрга да тәтеми.

Фаил Ибраһимовның тәҗрибәсе бай, куйган спектакльләре күп, ул Татарстан актёрларының нәрсәгә сәләтле икәнен биш бармагы кебек белә. Кайсы театрга барып спектакль куйса да, Фаил Ибраһимовның хезмәте заяга китмәс. Алда планнары бар аның, ул кече күләмле әсәрләргә мөрәҗәгать итмәкче була. Әлбәттә, театр җитәкчеләре, пьесаны куярга алганда, бу пьеса безгә күпме керем бирер, дип уйлый. Ләкин Фаил Ибраһимов, иҗат кешесе буларак, җитди пьесалар сәхнәләштерергә хыяллана. Актёр үссен өчен, комедия белән рәттән, трагедиясен дә, кыска шәкелдәге пьесаларны да уйнарга кирәк.

Фаил – озын иҗат юлында шактый кыен ашаган кеше. Ләкин ул кыенлыкларны җиңә килде, алга таба да режиссёр Фаил Ибраһимов алган юлыннан тайпылмас, сәнгатькә тугры хезмәт итәр, иншалла!

Быелгы Төрки халыклар фестивалендә Мостай Кәримнең пьесасы нигезендә Фаил Ибраһимов куйган «Ай тотылган төндә» тамашасы театрның ныклы һәм ышанычлы адымнар белән алга баруы турында сөйли.

Иҗат итү шартларының никадәр кыен булуына карамастан (театрның профессиональ коллективы яшәрлек үз бинасы юк), театрны, зур коллективны тиешле формада тотканнары өчен, театрның баш режиссёры Фаил Ибраһимов белән директоры Рашат Фәйзерахмановларның батырлыгы һәм иҗади каһарманлыгын аеруча билгеләп үтәргә кирәктер.

Чаллы театрының киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешерлек иҗади гайрәте бар.

**Рабит БАТУЛЛА**

# ЮЛЛАР ҺӘМ ҖЫРЛАР

Рифат Әхмәт улы Фәттаховны гомер буе беләм кебек. Минем күз алдында ул Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исемен алды... Инде менә хәбәр иреште: Рифат Фәттаховның татар халкы алдындагы хезмәтләре «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бәяләнгән икән. Ләкин бәяләрнең иң зурысы әле бу түгел. Аны туган ягы бәяләгән! Ул хәзер Түбән Новгород өлкәсе Кызыл Октябрь районының шәрәфле гражданины! Журналист һәм җәмәгать эшлеклесе сыйфатында хезмәт юлын узган кешегә хөрмәтләүләр исән чагында сирәк эләгә. Ә ул бу хөрмәтләүләргә нәкъ менә исән чагында тиешле зурлау күрмәгән якташларын таныту юлында куйган эшләре белән ирешге. «Рәшит Ваһапов. Заман. Иҗат. Шәхес» китабы өчен «Бәллүр каләм» премиясе белән бүләкләнүе юлның башы гына булган икән әле. Бай тарихлы, талантлы шәхесләрне мул биргән төбәк дөньяга Рифат Фәттахов дигән кеше килүен көтеп яшәгән диярсең. Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев кынамы соң әле монда?! Кави Нәҗмиләр генә дә түгел татар халкы яңадан ачасы шәхесләр... Аның үзен белүчеләр дә хәзер бер Татарстан белән генә чикләнми. Алай да беркадәр чигенеп, аның тәрҗемәи хәленә экскурс ясау зыян итмәс.

### Җәяүле кеше сукмагы

1966 елның 17 ноябрендә Нижгар төбәгендәге Актук авылында туган егет кечкенәдән үзен егет буларак танытып үсә. Барысы да каләм тибрәтергә яратудан бигрәк, каләмнең кодрәтен аңлаудан башлана бугай. Чү, ашыкмыйк әле. Барысы да биш баланың уртанчысын журналист итеп тәрбияли алган әти белән әнигә тоташмый микән? Нәни генә әңгәмә корып, үткәннәргә сәяхәт кылып алыйк әле. Әйдә, башлап үзе сөйләсен:

*«Әти инде исән түгел. 50 яшем уңаеннан туган якка быелгы кайтуым әтием Әхмәт белән яу кырында ятып калган бабам Фәттах рухын яд итеп, корбан чалдырып, Коръән укытып китәр өчен иде. Ниятем бик матур итеп үтәлде – шуңа мең шөкер. Әтием Әхмәт гомер буе машина йөртте. Әнием Нурсанә, Актуктан Уразавылга көн дә җәяү йөреп, типографиядә хәреф җыючы булып эшләде. Ул әле газета битләрен – полосаларны салучы да иде. Безнең өйгә Казанда чыккан газета-журналлар – «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Ялкын», «Яшь ленинчы», «Азат хатын» килеп торды. Мин бишенче сыйныфтан яшь хәбәрче булдым. Әй шуңа горурлануларым! Авылда абруй күтәрелде – миңа Юнкор дигән кушамат тагылды. Авылның үзхәбәрчесе булгач, вакыйгалар үзәгендә кайныйм инде мин. Берзаман Актукны Уразавыл белән кушмакчы булдылар. Фетнә уртасына кереп киткәнемне сизми дә калганмын. Тәмам идеолог сыйфатында әтәчләнеп йөргәнем һаман да истә».*

Димәк, егетнең абруе, «әтәчләнү» өчен сәбәп тә булган...

*«Бар инде, бар... Бер елны мине колхоз рәисе сарык йоны кыркучыларга баш итеп куйды. Мин хатын-кызлар кыркыган йонны үлчәп торам. Хәрәмләшергә бер дә ирек бирмим. «Энем, киткәндә дәфтәреңне калдырып тор әле», – дип юмалап та карыйлар. Катылыгымны күреп, август аенда бухгалтерлык җәһәтеннән тагын да күтәрделәр. Инде ындыр табагына кайткан ашлыкны үлчәп торам. Остарып та җиттем: исемлекне күчергеч кәгазь аша тутырам. Яңа һөнәремне әти дә хуплады. Бу инде учыңа*



Легендар җырчыбыз Илһам Шакиров белән.
Сулдан уңга: Рифат Фәттахов, Гөлсирин Абдуллина, Азат Абитов, Ранис Габбазов.

*каләм кыстырып йөрү генә түгел. Булды бу. Совхоз-техникумга бухгалтерлар курсына китәм! Шуны тәмамлагач, колхоз рәисе булам дип йөрим. Татар теле укытучым Әнвәр абый Ташбулатовка бу хыялым бер дә ошамады. Шуннан ул мине үзе белән Казанга алып китте. Габдулла Тукай, Рәшит Ваһапов каберләрен күрсәтте. Бу сәяхәт минем тормышта борылыш ясады».*

Димәк, алда – Казан! Казанга Рифат Фәттахов пар атта түгел, җәяүләп чыгып киткән икән. Урыным – Казан дәүләт университетының журналистика факультетында, дип ышанган, алтын медальле аттестат алган егетне хәрби комиссариат хәрби-сәяси мәктәпкә димләп торуга карамастан, ул Казанны сайлый. Казан студентлары арасына Рифат Фәттахов дигән егет килеп керүен бик тиз ишетеп алган идек без. Чөнки рус телендә генә чыгып килгән «Ленинец» газетасы Нижгар төбәгеннән хөр фикерле, таза сынлы егет килүгә татарча сөйләшә «башлаган».

Ул Казанга килүгә үк, бөтен газеталарга язарга керешә. «Социалистик Татарстан» газетасы ишеге төбеннән тиз боралар аны. Миргалим Харисов дигән җитди журналист: «Энем, профессияне дөрес сайламагансың», – ди. Башка газеталар да бетмәгән. Өченче курста укыганда ук, факультет диварында «Рифат Фәттахов иҗаты» дигән стенд эленеп тора. «Ленинчы»га тотынганда, ул аспирант иде инде. Урамда, мәйданнарда милли хәрәкәт активлаша. Рифат та рухы белән милләтче. Нидидер файдалы эшләр майтарасы килә. Ул бит, гомумән, кул кушырып утыручылардан түгел. Аны бераз мактандырып алганда да ярар иде. Булдыклы кешегә мактану килешә ул.

*«Студентлык чорында ике ел гына авылдан ярдәм алдым. Аннан үзем продюсерлык итә, ягъни концертлар оештыра башладым. Авылдашларымны ул вакыттагы мәшһүр артистлар белән күрештерәм, үземә дә азмы-күпме әҗере кала. Казанга килүгә, иң беренче продюсерлыгымны Хәйдәр Бигичевларга кунакка килүдән башладым. Зөһрә ханым сыйлаган шулпаның тәме әле дә теш төбендә. Бик җылы кабул иттеләр. Менә шуннан соң, мин аларның концертын оештырып, авылыбызга алып кайттым».*

Бу хакта Рифат Фәттахов белән әле иркенләбрәк сөйләшербез. Хәзергә «Ленинчы» белән эшне бетереп куйыйк. Остазы Флорид Әгъзәмовны сагынып искә алу өчен дә җай чыгып тора.

*«Әйе, мин аңа бик рәхмәтлемен. Ул мине кулымнан җитәкләп йөртте. Идеяләр бирә, юл күрсәтә торды. Мин йөгерә-йөгерә үти тордым. Нинди ишекләргә шакыйсын да ул өйрәтте. Әле шулай да җиңел генә булмады ул эш. Иң нык ярдәм итәргә тиешле кешеләр сыната иде. Бер генә мисал: университетның русча чыга торган газетасының бүлмәсе бар, ә татарчасыныкы юк. Бүлмә таләп итеп кергәч, ул вакыттагы проректор Миркасыйм Госманов мине «әрсезләнеп» йөргәнем өчен кыздырып чыгарды».*

Үткән эшкә салават. Ул бит барыбер «Ленинчы» белән генә чикләнеп калмый. Юрганын тарсынып, «Мәгърифәт» газетасы дип җенләнеп йөри башлый.

Монда да алар Флорид абый белән бергәләп йөриләр. Чыннан да, уку йортларының һәркайсында студентлар өчен газеталар чыга. Нигә дип әле барысына уртак вузара

газета чыгарып карамаска ди? Исемен генә матурны сайламаганнар. Үзенә дә шулай дип әйтәм.

«Исемнән бигрәк акча табу проблемасы борчыгандыр инде», – ди Рифат. Вузларның һәркайсы уртак эшкә мая кертергә ризалаша. Мәдәният университеты проректоры Рәис Беляев аеруча теләктәшлек күрсәтә. Ә менә ул вакытта үзе депутат, тел һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе, үзе педагогика институты ректоры Рүзәл Юсупов бик озак тарткалаша. Җае чыккач, студент-яшьләр газетасының финанс чатырын кору өчен матур хәйлә дә табыла. Моның өчен ул вакыттагы мәгариф министры Васил Гайфуллинга рәхмәтле Рифат Фәттахов. «И егетләр, мин сезгә бик ярдәм итәр идем. Вузлар Россия карамагында. Әйдәгез, газетаны укучы яшьләр һәм студентларныкы дип атыйк. Шул чагында мин сезгә акча табармын», – ди ул. «Мәгърифәт» зур тиражлар җыя, вузлар буйлап китә алды. Менә шул газетаны оештырган чагында яшь журналист зур чыныгу үтә дә инде, психологик тетрәнүләр дә кичерә. Һәркайда җидешәр ел эшләгәнен исәпләп чыгардым.

*«Татарстан» журналында озаграк эшләдем анысы. Ул журналга республика дәүләт учреждениесе статусы алуга ирешеп киттем мин. «Татарстан» журналын мавыктыргыч басмадан бигрәк, мәгълүмати журнал итеп күрергә теләгән идем. Җитәкчелеккә минем инициативаларым ошап бетмәде. Тышына «Татарстан» дип язылган журналның милли концепциясе булырга тиеш иде ләбаса. Милли концепция тарафдары мин. Һәр эштә! Аларча эшләргә күнгән булсам, бәлки, китмәгән дә булыр идем. Журнал хәзер реклама ягына авышып бара кебек. Хәзер инде киткәнемә үкенмим. Аннан соң «Идел» журналын да өч елга якын җитәкләдем бит әле. Менә тагын җиде ел ук түгел...»*

«Идел»дән соң Рифат Фәттахов Рәшит Ваһапов исемендәге Фондка «чумды». Менә хәзер аның продюсерлык эшчәнлеге турында сөйләшсәк тә ярыйдыр. Тик аңа кадәр...

Фондка «чумуы» 2004 елда ук булган дип исәплик. Чөнки шул елны Рәшит Ваһапов исемендәге Беренче Халыкара татар җыры фестивале уздырыла. Фәттахов ялгызы түгел. Түбән Новгород якташлар җәмгыяте, Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә!

## Җырны җигеп, җилдереп

Кем әйтмешли, продюсерлык турында сөйләшүне дә шушы төштән башлыйк әле. Һәр сүзен, һәр эшен «якташлар» дип башлый ул. Хәер, хәзер ул «якташларның», Якташлыкның башында да үзе тора түгелме соң?

*«Әйе, шулай. Казанга барырга җыенуымны белгәч, әбием мине өйрәтеп җибәрде: «Улым, безнекеләр ярдәмчел. Менә Кыяметдин абызыңның улы – «Татарстан» дигән кунакханәнең иң зур кешесе. Кыен хәлдә калдыңмы, аңа бар. Ташламас», – диде. Бардым, таптым, ташламады. Безнекеләр бөтен җирдә бар. Мәскәүдә дә. Андагылар да ташламады. Егылам дигәндә, якамнан күтәреп торгызган чаклары да булды. Әле дә бар эшемдә аларга таянам».*

Шулай итеп, Рифатның Хәйдәр Бигичев белән Зөһрә Сәхәбиевага продюсерлык итеп башлаган «нәни шаярулары» татар җырын дөнья буйлап йөртерлек зур бер гамәлнең башы булган икән. Зур юлга төшү авыр булдымы, дип сорамыйм. Тәвәккәл таш яра, диләр, әмма кайчагында таштан алда баш та ярылучан...

*«Мин Актукка башка җырчыларны да алып кайттым. Шул җырчылардан тормыш сабагын да өйрәндем. Иң кызыгы Әлфия Авзалова белән эшләү булгандыр. Уйнап кына йөрсә дә, Әлфия апаның математикасы бик шәп иде. Клубка барып керүгә, иң әүвәл урындыкларны саный. Аннан, башын юләргә салып, миннән сораган була: «Бу клубта ничә урын, энем?» «300ләп», – дисәң: «Юк, энекәш, 400 урын монда», – дияр иде».*

Хәйдәр Бигичев истәлеген мәңгеләштереп, китап итеп төпләп куйганнан соң тотынган иде Фәттахов мәшһүр якташы Рәшит Ваһаповка. Дөресрәге, аның бай җыр мирасын барлау эшенә.

Бу кеше егетнең йөрәгендә бала чагыннан ук яши. Тавышы тәлинкәләргә язылып куелып, әбисе сандыгында саклана торган әлеге җырчының үз авылларыннан

икәнлеген аңлау өчен бәләкәй малайның хыялы җитми. Күк гөмбәзенең чиксезлеген аңлый алмый йөдәгән кебек. Рәшит Ваһапов! Актукныкы! Әбисе, сандыгын ачып, тәлинкәне иске патефонга куеп җибәргәндә, өй эчен әллә нинди могҗизаи моң биләп ала. «Казанга килгәч, авылдашымның иҗаты һәм тормыш юлы белән якыннанрак кызыксындым. Ләкин тапканым бик аз булды. Менә шуннан инде мин бу эшне үземә бурыч, авылдашым васыяте итеп кабул иттем», – ди Рифат.

Ул бу бурычны бише белән генә түгел, йөзе белән үти. Хәзер инде «Ваһапов кем соң ул?» дигән сорау беркайчан да куелмас. Беренче Фестивальдә үк килгән кунакларга аның тавышы язылган 600 кассета биреп җибәрелде. Югыйсә, ул кассетаның «XX гасырның бөек җырчылары» сериясеннән чыгарылуы үзе генә дә зур казаныш иде! Бу тема Рифат Фәттаховны кыздырып җибәрә.

*«Бөек Җырчылары бар татарның. Әнә, Зур концерт залында Бах, Бетховен кебек композиторларның бюстлары тезелеп тора. Ни өчен соң анда үзебезнекеләр – Булатова, Даутов, Насретдинов, Ваһапов юк?! Казанның 1000 еллыгын форсат итеп, бөек татарларга һәйкәлләр тезеп чыга ала идек. Инде аннан соң да уникe ел үтте. Казан урамнарында Кол Галидән башка берәр бөек шагыйрьгә һәйкәл куелдымы? Урам исемнәре татарча сөйләшәме? Бервакыт Финляндиядән дуслар килеп төште. Вокзал ягыннан Азинога таба үткәнче, миннән урам исемнәрен сораштыра бардылар. Саныйм: Чернышевский, Толстой, Бутлеров... Һәйкәлләрне күрсәтәм: Ленин, Горький, Шаляпин... Өйгә кайтып җиткәндәрәк: «Теге юл аэропортка илтә», – дигән идем, кунакларым миңа: «Безне шунда илт. Син безгә татар шәһәрен күрсәтәм дип алдалагансың. Без андый шәһәр күрмәдек, кайтып китәбез», – диделәр».*

Аның каруы, бөек якташларын һәйкәлле итүгә ирешә. Авылы Актукта Рәшит Ваһаповка бюст куйдыра. Инде быел Хәйдәр Бигичев белән Рәшит Ваһапов һәйкәлләре Нижгар төбәгендәге Уразавылда – Кызыл Октябрь районы үзәгендә мәгъруранә басып тора. Моның өчен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка, Түбән Новгород губернаторы Валерий Шанцевка, Бөтендөнья татар конгрессына, якташларына чиксез рәхмәтле ул. «Бер мин генә йөрсәм, әллә ни майтара алмас идем», – ди.

Сөйләшүебездә һәрдаим чагылып киткән «Финляндия» сүзенә игътибар итәм. Ул анда да үз егет бугай...

*«Мин анда туасы булганмын бит, – ди Рифат, – бабайның әнисе Айниҗиһан әбием шунда күмелгән. Ерак бабам белән ул әбием гаиләсе – инкыйлабның тагын бер корбаны. Айниҗиһан әбием, барып урнаша торырга дип Финляндиягә киткәч кенә, чикләр ябылган. Болар икесе ике якта каңгырып яшәргә калганнар. Бабай кулында яшь бала да калган бит әле. Минем Фәттах бабам ул. Айниҗиһан әбиемнең каберен күреп кайттым».*

Авыл белән Финляндия арасында хатлар йөреп торган. Аннары моңа чик куелган. Бервакыт Финляндиядән килгән посылканы да кире борып җибәргәннәр әле. Янәсе: «Кирәк түгел подачкаларыгыз!» Чөнки тиешле җиргә чакыртып, нык кына өркетеп алганнар. Әмма теге якта калганнар өчен дә кадерле нәрсәләр булган. Хәмидә Чайдам ханымның шундый истәлеге бар: «Минем әти дипломат иде. Кая гына юлга кузгалса да, чемоданына татарча җырлар язылган тәлинкәләр тутыра иде», – дип сөйләде ул. Әлеге дә баягы, Рәшит Ваһапов җырлары инде болар. Менә шуның өчен Ваһапов исемендәге фестиваль дөнья буйлап сәфәренең беренче адымнарын иң элек Түбән Новгородта, аннан Хельсинкида башлый да инде. Беренче елны ук төбәкара фестиваль сыйфатында ул Санкт-Петербургка, Төмәнгә, Екатеринбургка, Башкортстанга юл ала.

Икенче елны Удмуртия,Чувашстан,Ульяновск өлкәсе, Пермь крае, Самара... Өченче елны Мәскәү, Украина, Марий Эл, Кытай, Германия... Һәм янәдән – Актук, һәм янәдән – Казан. Җыр, дөньяны әйләнеп, туган ягына, башкалабызга кайта тора... Кайта һәм яңа исемнәр ияртеп кайта. Татар яшәгән һәр төбәктә кызып киткән җыр бәйгеләре Ваһапов исемен әләм итеп күтәрә. Шул бәйгеләрдә җиңүчеләр Рәшит Ваһапов исемендәге яшь башкаручылар конкурсында катнашырга атлыгып тора. Конкурсларның жюри рәисе дә Илһам Шакиров үзе бит әле. Татар эстрадасына яңадан-яңа исемнәр килә. Яңа якты йолдызлар балкый тора. Менә кайчан башланган икән ул татар эстрадасындагы бүген генә исеме табылган Үзгәреш җиле! Миллиард сумнар түкмичә генә! Фәкать




Жыр атлы аргамакта җилдереп кенә. Ни өчен шулай дәррәү күтәрелде соң жырлы халык? Татар җырын зурлап, татар фамилияле җырчыларның – кемнең Латвиядән (Эллина Шиһабетдинова), кемнең Прагадан (Галия Ибраһимова), кемнең Алматыдан (Бибигөл Түләгәнова), кемнең Берлиннан (Айдар Гайнуллин) килүләренең дә роле зур булгандыр. Альбина Шаһиморатова Америкада стажировкада иде, ул да кайтты. Хәтта Зураб Соткилава кебек грузин, Алаар Хаак кебек эстон, Фёдор Тарасов кебек рус җырчылары да читтә кала алмады.

*«Әлбәттә, аларны кайтару, китерү өчен шактый тырышырга кирәк була торган иде. Беренчесеннән үк Фестивальнең милли премиясен тапшыруны гадәт иттек. Беренчесе – Фәридә Кудашева! Планканы шул югарылыктан төшерергә ярамый иде, төшермәдек тә!»*

Фестивальләрнең лауреатлары да бу мәртәбәле исемне горурланып йөртә булыр. Рөстәм Асаев, Филүс Каһиров, Айгөл Хәйри, Илүсә Хуҗина, Марсель Вагыйзов, Айгөл Сагынбаева, Сиринә Зәйнетдинова, Ришат Төхвәтуллин, Гөлсирин Абдуллина, Ранис Габбазов, Азат Абитов, Азат Фазлыев... Фестиваль кабызган йолдызларның саны хисапсыз. «Тырышмый гына балык та капмый», ди рус мәкале. Татар җырына лаек заллар юллап йөрүләр, юл чыгымнарын каплардай иганәчеләр табулар да җиңел булмагандыр. Китерелгән җырчыларга юл чыгымнарын, тору хакын, гонорарын каплыйсы да бар бит әле аның.

*«Рәшит Ваһапов исемендәге Фонд рәсми төстә оешканнан бирле, хәлләр җиңеләйде. Татарстан хөкүмәте Фондны бюджетка алды, безне теләнеп йөрергә калдырмады. Фондның бюджеты хәзер 10 миллион белән исәпләнә. Штатта да унлап кеше эшли. Чыгымнарга сыеша алмаганда, Президентыбыз һәрвакыт хәлебезгә керә. Рәхмәт аңа».*

Унөченче фестивальгә һәм үзенең 50 яшьлек юбилеена дөньяның 11 илендә, Россиянең 56 төбәгендә эз калдырып килә Рифат Фәттахов. Мактанырлык гамәлләре тагын да бар аның...

*«Эстрададагы башбаштаклыкны җиңеп, фестиваль кысаларында фонограмманы гамәлдән чыгаруда, сәхнәгә профессионализм алып килүдә ролем зур булды дип саныйм. Исемнәре ни кызыккыч булса да, фонограммасыз сәхнәгә чыкмыйм мин, дигән җырчыларны чакырудан баш тарттык. Халык җырларын оркестр белән яңгыратуга ирештек. Иң яхшы оркестрлар белән килешү төзергә тырыштык. Мәшһүр Фуат Мансуров безнең теләктәш, фикердәш, сәхнәдәш булды. Казаныш түгелмени бу! Татар җырын Мәскәүдәге Чайковский исемендәге 1800 кешелек залда, Союзлар йортының*



Фестивальнең мәртәбәле кунаклары белән. Зураб Соткилава һәм Бибигөл Түләгәнова.

*1200 кешелек колонналы залында яңгыраттык. Зур заллар бу!*

*Ә иң кечкенә зал – Америкада. Сан-Францискода залы 20 генә кешелек Татар йорты бар икән. Анда мин, Филүс Каһиров, баянчы Рөстәм Рәхмәтуллин барган идек. Андагыдан да кечкенә аудитория Лос-Анджелеста булды. Бер татар бае гаиләсендә. Филүс аларга «Туган тел»не җырлады. Фәйзелхак әфәнде елый, хатыны елый, мин елыйм, Филүс елый, Рөстәм елый... Япония, Кытай, Төркия аша Америкага барып төпләнгән татар нәселен елатып кайттык. Туган илне сагыну, җирсү буыннар аша да басылмый икән. Юк, мин кечкенә заллар турында хыялланмыйм. Казанда эстрада концертларын куеп булырлык бер затлы зал, музыкаль театр турында хыялланам. Профессиональ эстрада кирәк. Шунда ук тавыш яздыру студиясе дә булсын иде ул. Безнең эстрада бригадалары чегән таборы рәвешендә болганалар лабаса. Ә теге музыкаль театр турында моннан дүрт ел элек үк Президентка хат керткән идек. Ул «добро»сын биреп, тәкъдимнәр әзерләргә кушып, виза да салган иде. Нилектәндер йөк кузгалмый».*

Алган белеме җәһәтеннән җырдан ерак торырга тиеш кеше дә бит инде ул үзе... Бу ниткән шаукым була соң? Язмыштыр, күрәсең. 13 яшендә «Артек»ка җибәрәләр аны. Татар малае булганына күрәме, татар вожатые аны үз отрядына ала. Ә бу отряд «Артек» музыкантларының – быргычы-барабанчыларның җыелма отряды булып чыга. Музыкаль белеме булмагач, аңа, беләгең таза, дип, «Артек» байрагын йөртергә кушалар. Шулай итеп, 45 көн дәвамында лагерь байрагын тотып, иң алдан йөри, музыкантлар башында! Кызыклы хикәятләре күп аның.

*«Бер елны чиргә уралдым. Ашап булмый, йоклап булмый, ябыгып беттем. Актукка кайтып киттем, бәхилләшергә дип. Рабига әбием кайтуыма картоф яккан (бәрәңге боламыгы яккан зур пәрәмәч) пешергән. Шуны ашап бетергәнемне сизми дә калдым. Терелеп тә киттем. Мин әле дә гел шулай итәм: дөнья ямен югалта башладыммы – авылга кайтам. Сарсаз күле, Ишмәт тавы тирәсендә бер әйләнсәм, бүтән кеше булам. 360 кына чакрым бит, дөньяны әйләнгәнне, авылга гына кайтам инде мин!»*

Күпме генә урап йөрсәм дә, аның татар сәнгать дөньясына продюсер дигән термин алып керүе турында әйтми кала алмыйм. Үзе исә бу турыда:

*«Минем чиләнүләрем шундый да матур, шундый да яңа сүзгә сыеп бетсә икән ул! Бер исемсез, билгесез, хәтта ки берәүгә дә кирәкмәгән талантны табып алып, аны җырларга гына түгел, бәлки киенергә дә өйрәтеп, юл сызып биреп, аудитория ясап, репертуар сайлап, алай гына да түгел, фатирлы, машиналы итеп – кыскасы аңа атасын, анасын алыштырып, гомереңнең бер өлешен бирү була инде ул продюсерлык итү. Бездә продюсерлык институты эшләнмәгән. Бу гамәлне, хәтта ки хәйриячелек кебек аңлау да бар. Зур дөньяга юл яра алган, хәзер инде аңа мин кирәкмим дип уйлаган бер «талантым» белән сөйләшәбез: «Син нидән канәгать түгел? Сиңа акча җитмиме?» – дип сорыйм. «Җитә. Сиңа күп кала. Шуңа ачуым килә», – ди бу. Нәрсә әйтим? Хәзер ул егет үзбаш эшли. Эшләсен! Минем эшемнең нидән гыйбарәт икәнен үзем генә беләм. Атаклы продюсер Айзеншпис бар иде. Ул менә көлдән көмәч «пешерә» белә торган остаз иде. Аның «күмәчләре» инде пешеп җиттек дип уйлап, үзбаш яши башлаудан соң, өч-дүрт ай узуга ишелеп төшә торганнар иде. Чөнки «үзбаш» булган төркемне яки аерым бер җырчыны популяр итү юлында ничәмә-ничә кылыч сынганын, сәхнә арты көрәшенең аяусыз икәнлеген алар белми дә кала. Кирәкле кешеләрне табуга, алар белән сөйләшүләр алып баруга*

*киткән вакыт һәм акча чыгымнарын гына санасаң да... Аннары бит әле кабатланмас стильне табу, репертуар туплау кадәресе дә бар. Продюсер менә шул эшләр белән дә шөгыльләнә. Яңа исемнәр, яңа йолдызлар фестивальләр булып торганга кабына дип уйлау дөрес түгел ул. Җырчы Халыкара фестивальләрдә бишәр Гран-при алып та популяр булмаска мөмкин. Җырчы – продюсерына, продюсер талантка ышанганда гына Йолдыз кабына! Минем үзләренә продюсер булуымны, ризалашуымны көтеп торучылар байтак. Шөкер, Ваһапов исемендәге яшь башкаручылар конкурслары аша байтак талантлар калкып чыкты. Сайлап алырга да мөмкин. Бу юнәлештә эш дәвам итәчәк. Ә инде кайбер низаглар чыгып тору – бу кадәресе тормыш кануны. Ачынулар да бар. Әйтик, Филүс Каһировны дөнья йолдызы итү мөмкинлеге бар иде. Италиядәге Бельканто академиясе җитәкчесе Мирелли Френи белән сөйләшүләр уңышлы төгәлләнгән иде.Тавышы ошады, үсеш мөмкинлекләрен күрделәр. Филүс үзе теләмәде. Кызганыч. «Үзгәреш җиле» дигән проект та татар җырына шундый үсеш тели ләбаса.*

Әмма бу «Үзгәреш җиле» татар җырын дөньяга танытуның иң үтемле юлы, җырны яңа өслүбтә башкарып, заманча сәхнә бизәлешенә төреп бирү була инде ул, дип уйладылар, ахры. Шулай итеп, Опера театры бинасында сынап каралган «Үзгәреш җиле» Мәскәү залындагы концертка тамашачы җыя алмады, диделәр...

*«...Чөнки татар бәгырендә яңгырап торган газиз җырларның эчке моңы әллә кая киткән булып чыкты. Бу фикер иске булса да, кабатлыйм инде – татар җырының фишкасы – моң! Үзгәртсәң дә, концертларның структурасын үзгәртү җәһәтеннән генә уйланырга кирәк. Йөрәгеннән моңын алсаң, татар үзе дә юк ул. Җырында аның тарихы, язмышы...»*

...Димәк, продюсер талантлы җырчыга икенче дәрәҗәдәге космик тизләнешне бирә, ә менә өченче тизләнешкә чыгу-чыкмау аның үзеннән тора. Ә бит Ходай биргән талантны татар исеменә хезмәт иттермәү үзе гөнаһ.

Шушы урында сөйләшүгә нокта куеп, Рәшит Ваһапов исемендәге 13 нче фестивальнең йомгаклау концертына киттем. Бүген анда Фестивальнең узаманы Рифат Фәттаховны зурларга тиешләр. 50 яшьлек юбилее егетнең!

Концерт шәп, котлаулар мул булды. Рифат Фәттаховның түшенә медальләр дә кадалды, бүләкләр дә бирелде. 50 нче сан белән бирелгән «Тынычлык Розасы» дигән орден аеруча кызыксыну уятты. Ул орден ни-нәрсә һәм нинди казанышлар өчен бирелә икән, дип әсәрләнеп торганда, Грузиядән килгән СССРның халык артисты Зураб Соткилава үз халкының җырларын җырлап, юбилярның йөрәген яулады. «Минем халкым җырчысын зурлап килеп, үз халкыңның моңнарын бүләк иттең. Моннан да зуррак бүләк булырмы? – диде Рифат Фәттахов. Аннары өстәп куйды: Мин, гомумән, милли җанлы кеше. Һәр милли нәрсә минем өчен кадерле». Ышанабыз, Рифат!

**Асия ЮНЫСОВА,**
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

# АЛТЫННАН ДА АСЫЛ ТЕЛЕМ

## Яшә, «Казан утлары»!

*«Казан утлары» журналына*

Яшәсәк тә чит илләрдә,
Сибелеп без чит җирләрдә,
Юлдаш булдың һәр җирдә,
Сердәш булдың син безгә,
Яшә, «Казан утлары»!

Гореф-гадәт, телне дә,
Әдәбият, динне дә,
Милләтебез язмышын,
Аңлаталдың син безгә,
Яшә, «Казан утлары»!

Милләт өчен көрәштең
Гасыр буе, арымый,
Ышанамын мин сиңа,
Барырсың һич туктамый,
Яшә, «Казан утлары»!

Сайлап менеп толпарны,
Саклап таза каннарны,
Милләт өчен тырышып,
Яшәртәсең Казанны,
Яшә, «Казан утлары»!

## Тукай кабере алдында

Казанга кайтам да
Барам мин кабергә.
Догамны багышлыйм
Тез чүгеп кабердә.

Сүзләрең күңелдә,
Ятлана бары да.
Сагынып искә алам
Кабереӊ алдында.

Сагынам һәр таңда,
Чын тарих алдымда.
Баш ия һәр татар
Кабереӊ алдында.

Саклandың һәр җирдә
Күңелнең түрендә.
Өзелмәс җыр булып
Җырландың күңелдә.

Яшисең мәңгегә,
Татар бар һәр җирдә.
«Туган тел» шигырең
Әйләнде гимнга.

Халкымның газизе,
Мин синнән нур алам.
Тукайлы халык, дип,
Һәр җирдә мактанам.

## Гармун моңнары

Гармунның моңнары,
Ул – йөрәк сагышы.
Йөрәкне тибрәтә
Шул моңсу тавышы.

Тыңлыйсың җырларны,
Җырлар бит бик моңлы.
Моңында халкымның
Сагышлы язмышы.

Туйларда уйнасын,
Гармун һич тынмасын.
Буыннан-буынга
Туктамый җырласын.

## Газиз халкым

Өйрәтте әнкәм туган телен,
Татар телен шуннан белдем.
Телем ачтым – сөйләгәнем –
Минем туган татар телем.
И, сөекле туган телем!
Туган илнең кадерен белдем
Асыл туган телем белән.
Бар дөньяны шуннан белдем,
Минем газиз татар халкым,
Минем асыл туган телем,
Алтынга да алмаштырмам,
Алтыннан да асыл халкым,
Алтыннан да асыл телем.

## Сөю булса

Сөю – дару,
Сөю – шифа,
Сөю булса арада.

Сөю – саулык,
Сөю – шатлык,
Сөю булса һәркемдә.

Сөю – рәхәт,
Сөю – җәннәт,
Сөю булса чын-чыннан.

Сөю – байлык,
Сөю – барлык,
Сөя белгән кешегә.

## Шагыйрь

Шагыйрь күңеле чиксез диңгез,
Сыя аңа барысы.
Шагыйрь тормышы тынгысыз,
Кайгырта ул чынлыкны.
Шагыйрь яза, шагыйрь сөйли
Һәм уйлый чынбарлыкны.

**Гыйззәтулла ХӘСӘН,**
*Кытай республикасы Шенҗаң-Уйгыр автоном районы,Элә өлкәсе*

## Йөрәк аша үткәреп

Мин «Казан утлары» журналының 3нче санында басылып чыккан «Сагынган чакларымда» исемле драманы бер тында зур кызыксыну белән укып чыктым. Автор Айгөл Әхмәтгалиева тарихи вакыйгаларны шундый зур осталык белән тасвирлап ачып бирә алган: колхозлаштыру чорының фаҗигасе, авыл активисты булып йөрүче намуссызларның әрсезлеге, оятсызлыгы, сугыш вакытындагы коточкыч авырлыкларны күтәргән ач хатын-кызның тормышы, сугыш чоры балаларының ачы язмышы – мин боларны үз җилкәмдә татыган кеше кебек, йөрәгем аша үткәргәндәй булдым. Шаһидә образын әйтерсең лә автор минем әнкәемнән күчереп алган, шундый итеп сурәтләгән, күзләремнән яшьләр килде: авыр балачак хатирәләре, ялгыз калуы, сиерыннан аерылу, шундый ук борчулары... Әйе, күпләргә хас авыл тормышын бөтен нечкәлекләре белән бирә белгән автор. Драмадагы геройларының характеры, нәкъ авылча сөйләме, миһербанлы гадилеге күңелнең иң нечкә кылларына кагыла, хәзерге яшьләргә үткәндәге авыр тормышны бар нечкәлеге белән күзалларга ярдәм итә. Без, язучы Айгөл Әхмәтгалиеваның кыска, фәһемле хикәяләрен, эчтәлекле повестьларын яратып укучылар, бу күпкырлы талант иясенә яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез, шундый әдәби хәзинә булырлык әсәрләрен көтеп калабыз.

**Ралия КӘРИМОВА,**
*«Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең җаваплы сәркатибе.*
*Түбән Кама шәһәре*

## Якты әсәр

Төзеләчәк дәрес планнарын, бетмәс-төкәнмәс кәгазьләрне читкә куеп, «Казан утлары» журналының 5 нче санын кулыма алдым. 95 ел буе укучыны сөендереп, рухи яктан туендырып торган басманың юбилей саны бит бу.

Гадәттә, газета-журналларны «Баш мөхәррир сүзе» рубрикасы белән бирелгән язмаларны укудан башлыйм, аннан күңелемә иң якын тоелган әдәби әсәргә тотынам. Берочтан шуны да әйтим: бу санда «Сәфәрләр, очрашулар, тәэсирләр» дигән баш астында бирелгән фоторәсемнәр Актаныш ягы укучыларының күңеленә хуш килгәндер, «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре белән булган очрашу мизгелләре күңелләрендә яңаргандыр.

«Мәһдиев һәм...» бәян-хатирәсе игътибарымны җәлеп итте. (Авторы – Вакыйф Нуриев.) Мәһдиев шәхесе, аның әсәрләре безнең өчен бик якын. Классик язучы булганы өчен генә түгел. Әнием КДУда укыганда, Мөхәммәт Сөнгать улы аның диплом җитәкчесе булган. Әдипнең никадәрле гыйлемле, таләпчән, гадел булуы хакында бүген дә якын итеп искә ала. Әниебез бездә дә язучы иҗатына мәхәббәт тәрбияләгәндер, шулай булмаса, апам да, үзем дә М.Мәһдиев әсәрләре буенча диплом эше язмас идек.

«Мәһдиев һәм...» бәянын журналның иң якты, иң җылы әсәре дип атар идем. Үзенең язылу формасы ягыннан да аерылып тора. Бәян өч кеше исеменнән язылган кебек. Иң әүвәл Мөхәммәт Мәһдиев язган юлларны укыйбыз. Аның кебек, авылны, яшьлек елларын, кешеләрнең хис-кичерешләрен бөтен нечкәлекләре белән бирүче янәдән табылырмы? Мәһдиевнең уй-фикерләрен әсәрнең «Әни сөйли» өлеше дәвам иттерә. «Хәтерем дәфтәреннән»дә В.Нуриев үз истәлекләре белән уртаклаша. Нәтиҗәдә, янәшәдәгеләргә һәрвакыт игътибарлы, ярдәмчел, юл яручы, юл күрсәтүче М.Мәһдиев безнең яныбызда гына, әсәрдә язылган күренеш-вакыйгалар күз алдында кебек тоела башлый.

Шулкадәр мавыктыргыч, матур бу әсәрне бер тында укып чыктым да гадәттә соңгы юллардан соң языла торган «дәвамы бар» дигән сүзләрне эзләдем. Кызганыч ки, тапмадым. Бәлки, язарга гына онытканнардыр...

**Сөмбел ХӘБИБУЛЛИНА,**
*Актаныш районы Әтәс мәктәбенең тарих укытучысы*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Зәки ВӘЛИДИ ТУГАН**
*хатирәләренең алдагы саннарда чыгачак*
*бүлекләреннән кайбер өземтәләр*

***

Мәдрәсәдә шәкертләргә галәм гыйлеменнән (астрономия) дәрес бирә башладым. Атам бу дәресләремне хупламый, чөнки алда сөйләгәнем кеби, Җирнең әйләнүенә ул ышанмый. Мин глобусның тагын да зуррагын ясадым. Караңгылыкта Кояш (лампа) әтрафында Җирнең әйләнешен шәкертләргә күрсәттем. Җир шарын (глобусны) ясаганда, җилем урынына камыр кулландым. Җир шарын җәйгелеккә мәдрәсәдәге бүлмәмдә калдырдым. Җир шарымны тычканнар, күселәр ашап бетергән, бөтен тырышлыгым юкка чыкты. Атам исә бик канәгать калды:

– Җирнең әйләнешенә хәтта тычканнар да ышанмыйлар! – диде.

***

Авылда бөтенесе дә бал шәрабы (әчебал) ясый. Ислам тыймаган бу шәрабне кайбер башкорт имамнары да эчә торган иде. Безгә туган тиешле бер имам бар иде, Әһил мулла исемле иде ул. Халыктан «гошер сәдакасы» дип әчебал ала, барысын да эчеп бетерә. Аңа оеган җәмәгать тә үзенә охшаган була, алар Әһил мулланы минем әтиемә караганда да нык яраталар иде. Имам әфәндебезнең бу гамәле Галишер Нәвоиның, казакъ шагыйре Абайның фикере һәм дөньяга карашларына да туры килә иде. Ул заманда да сугым көннәрендә бал шәрабе күп эчелә иде. Галишер әйтәдер ки:

– Кояш батып, шәфәкъ кызарганга чаклы, шәраб белән мәҗлесеңә балкыш бир, чөнки Алла кәримдер, иртәгә сине гафу итәр.

***

Малларыбыз кар катламы калынайганчы авылга, араннарга кайтмый. Алар, тибенеп, кар катламын тояклары белән ачып, кар астында калган үләнне рәхәтләнеп ашыйлар. Без килә башласак, качалар. Бу кыргый-буйсынмас атларны тирәнәйгән кар каплаган урманнардан эзләп табар өчен, чаңгы киеп барабыз. Кар артык калынайса, алар урмандагы кибән янына җыела. Шул кибән янында аларны тотабыз. Качарга теләгән, чыгымчы атларны кыйныйбыз, игә китерәбез. Безнең башкортлар да сөекле хатыннарын шулай кыйный, игә китерә.

***

Җае туры килде, миңа сәясәт белән җитди шөгыльләнергә форсат бирүче бер эш чыкты. Патша сайлау кануннарын үзгәртте. Казанлыларга Думага биш депутат, азәрбайҗаннарга бер депутат юлларга мөмкинлек ачылды. Башка төркләр, Төркестанда яшәүчеләр Думага вәкил юллаудан мәхрүм ителде.

***

Татар әдибе Муса Җарулла Бигиевнең, рус вә Гареб галимнәреннән башка, борынгы Андалусия галимнәреннән Әбү Бәкер Гарәби (үлеме – 1148 ел) вә Ибраһим Шатиби (үлеме – 1388 ел) вә Һиндстан фәйләсүфләреннән Нигъмәтулла Дәһләви (үлеме – 1774 ел) кебек шәхесләрнең тәэсирендә иҗат иткәне турында Горький башына да китермәгән икән. Ул бары тик:

– Татарларның бу кадәр ерак өлкәләр белән дә культура багланышлары булганын мин белмәгәнмен! – диде.

***

Абзам Шәяхмәт өенә киттем. Аның углы – минем элеккеге яшьлек дустым – Нурмөхәммәд тә коры печән әзерләргә киткән булып чыкты. Өйдә хатыннар гына калган. Алары да өй артында, «ындыр» дип аталган җирдә, ашлык сугуда икән. Алар янына киттем. Ни күрәм? Ындырда Мәхүб, Махия апаларым белән Ләйлибәдәр – яшьлегемдәге кызлар – ашлык суктыралар. Аларның барысы да кияүдә икән. Махия Шәяхмәт абзамның кызы иде. Авылыбыздагы башкорт, мишәрләрнең гадәтләре бераз аерыла иде. Башкорт нәселле кызларның йөзләре ачык, алар атка атланып чаба, хәрәкәтләре ирләрнеке кебек. Махия дә шундыйлардан, ул хәтта иярсез атка атланып ыргып чаба, кияүгә чыкканда, аның бу кылмышын гаеп итеп күрсәттеләр. Мәхүб исә, ир-егетләр белән көрәшеп, үзенә ир сайлады. Ул бары тик үзен көрәштә җиңгән егеткә генә кияүгә чыгачак. Калгасау авылының бер куәтле иренә ул хатын булды. Ләйлибәдәр исә безгә күрше мишәрнең кызы иде. Сабыйлыгыбызда анам янында бергә белем алган идек. Мишәр таифәсенең *(төркем, кабилә)* кызлары ирләрдән кача һәм атка атланмый. Шулай итеп, бу юлы Махия аңа миннән качарга юл куймады. Мин дә иген сугуга килеп катнаштым. Бераздан мин салам өстенә сузылып яттым. Махия шунда чүмәлә итеп куелган көлтәләрне «һоп» итеп минем өскә өя башлады да мине көлтәләр белән күмеп тә куйды. Көлтә чүмәләсе астында калгач, миңа кычкырдылар:

– Нигә өйләнмисең? Нигә дуадак ата каз кебек тулганасың? Өйләнергә сүз бирмәенчә, көлтә астыннан чыгармыйбыз! – дип шаярттылар.

***

Урман эченнән, юлсыз юлдан, тирән-юеш карга бата-чума, алга барабыз, атлавы кыен, тирләп-пештек. Кулына балта тоткан бер башкортны очраттык. Агач аударыр өчен килгән икән.

– Авыл еракмы? – дип сорадык.

– Мынау шул түбәнең аркаһында, яп-якын гына! – диде балтачы.

Ләкин сәгатьләрчә барсак та, калкулык күренмәде. Тарихта кыйтгадан кыйтгага җиңел күчеп йөрергә күнеккән төрк кавемнәрендә ераклык үзләренчә үлчәнә, аларга ерак аралар да якын сыман тоела. Казан татары:

– Чүгүчәк шәһәре кайда? – дип сораса, казакъ кешесе, ияге белән ишарә ясап, Кытай ягына күрсәтер дә әйтер: – Ана ул Чүгүчәк! – дияр.

Казан татары соңыннан әйтер:

– Казакъ ымлап күрсәткән якка өч ай йөредем! – дияр.

Төрек-сәлҗуклар заманасында Анатолиядә дә шулай булган, имеш. Җәләлетдин Руми язып калдырган: «Барасы җир еракмы?» дип сораганга төрк: «Монда гына», дип җавап бирер. Бу җавапның асылы нәрсә булыр, беләсезме? Аның асылы: Тәңре синә куәт һәм батырлык биргән, ул ара бик ерактыр, Алла сиңа ярдәм итсен, дигәнне аңлата».

***

Мәскәү урамнарында кышын бик күп кар көртләре өелгән була. Автомобильләр йөри алмый. Сталин мотоциклга утырып йөри ала. Беркөн, мотоциклның бишегенә утырып, Сталин белән бергә каядыр китеп барабыз. Яз килгән чак, урамнарда тау кадәрле кар өемнәре эреп ята. Мотоциклдан төшеп, җәяү бармый хәлең юк. Биек кар тауларына күрсәтеп, Сталин:

– Безнең Совет таулары! (Наши Советские горы!) – дип шаяртып алды.

Икенче көнне ул мине тагын матайга утыртып каядыр алып китте. Биек өйләрнең югаргы катыннан сап-сары кәгазьгә төрелгән нindидер бер нәрсә ыргыттылар.

– Боларны төнлә генә ата торганнар иде! – диде Сталин. – Хәзер бер Халык комиссары вә Көнчыгышның мөхтәрәм бер вәкиле узып китәсен белеп, шуның шәрәфенә ташладылар! – дип төрттереп куйды.

Мәгәр кышын җылыткыч батареялар һәм бәдрәфләр эшләми икән, кешеләр гәзитә кәгазенә төреп, өске кат тәрәзәләрдән нәҗесләрен урамга ташлыйлар ди.

**Рабит БАТУЛЛА** *тәрҗемәсе.*

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республика җәмәгатьчелеге бик зур югалту кичерде. 2017 елның 15 июнендә 85 нче яшендә күренекле җырчы, РСФСР һәм ТАССРның атказанган артисткасы, ТАССРның халык артисткасы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Әлфия Авзал кызы Авзалова** вафат булды.

Ә.А.Авзалова 1933 елның 15 гыйнварында ТАССРның Актаныш районы Актаныш авылында туа. Кызга биш яшь чагында Әлфиянең әнисе үлеп китә, әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак була. Ә.А.Авзалованы әнисенең сеңлесе тәрбияләп үстерә.

Тумыштан ук гаҗәп талант иясе, җырларны тел-теш тидергесез итеп халыкчан башкаручы Әлфия Авзалова сәхнәдәге беренче чыгышларыннан ук тамашачыларның һәм сәхнә осталарының игътибарын җәлеп итә. 1951 елда ул Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшкә чакырыла. Һөнәри иҗади эшчәнлек юлына аяк басканнан соң, җырчы тиз арада ансамбльнең әйдәп баручы солисткаларыннан берсенә әверелә. Ул, оста итеп, борынгы һәм заманча халык җырларын, С.Габәши, А.Ключарёв, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин, Н.Җиһанов, Р.Яхин һәм башка күп кенә композиторларның әсәрләрен башкара. Ул татар халык җырларының һәм авторлар әсәрләренең тирәнлеген, матурлыгын күрсәтеп бирүгә ирешә.

Озак еллар буе Ә.А.Авзалова үзенең концерт төркеме белән Советлар Союзы буйлап гастрольләрдә йөри, Урта Азиядә һәм Балтыйк буенда, Мәскәүдә һәм Ленинградта, Татарстан һәм Башкортстан нефтьчеләре, КамАЗ төзүчеләр, авыл хезмәтчәннәре алдында чыгышлар ясый. Аның концертлары һәрвакыт аншлаг белән уза, тамашачылар җырчыны аягүрә басып каршылый һәм озата.

Ә.А.Авзалова Мәскәүдә, элеккеге Советлар Союзы республикаларында, шулай ук чит илләрдә: Кытайда, Чехословакиядә, Венгриядә һ.б. Әдәбият һәм сәнгать көннәрендә даими катнашып килә. Ә.А.Авзалованың репертуарында 500дән артык әсәр бар, җырларының язмалары аның талантын саклап калачак һәм яшь буыннарга тапшырачак. Әлфия Авзалова – легендар җырчы, төрле буын вәкилләре тарафыннан яратып тыңлана торган, матурлыгы буенча сирәк очрый торган тембрга ия иде. Ә.А.Авзалова татарның вокаль башкару сәнгатен саклауга һәм үстерүгә бәяләп бетермәслек өлеш кертте.

Ә.А.Авзалованың югары дәрәҗәдәге осталыгы һәм фидакарь хезмәте күп кенә мактаулы исемнәр һәм дәүләт бүләкләре белән билгеләп үтелде. Алар арасында «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте бар.

Татарстанның музыка сәнгатенә тугры һәм данлыклы хезмәт итү үрнәге күрсәтеп, Ә.А.Авзалова халыкның чиксез мәхәббәтен яулады, республикабызның музыка җәмәгатьчелеге арасында гаять зур абруй казанды.

Бөтен халыкның яраткан җырчысы, талантлы кеше турындагы якты истәлек безнең йөрәкләрдә озак сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, А.М.Сибагатуллин, И.Р.Метшин, Р.И.Вәлиев, Ф.М.Камаев, И.Г.Шакиров, К.Н.Нуруллин**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## КАЗАНДА КЫРГЫЗСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Казанда Кыргызстан Республикасы мәдәнияте көннәре булып узды. Бу уңайдан башкалабызга КР Президенты Алмазбәк Атамбаев килде. Казан аэропортында аны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов каршы алды. Кыргызстан Республикасы мәдәнияте көннәрен ачу тантанасында Алмазбәк Атамбаев җәмәгате Рәйсә ханым, Рөстәм Миңнеханов җәмәгате Гөлсинә ханым белән катнашты. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Әсәнхан Җомәхмәтов исемендәге дәүләт симфоник оркестры, җирле опера, филармония солистлары концерты булды. Казанлыларга һәм башкалабыз кунакларына  Кыргызстанда соңгы елларда төшерелгән иң яхшы фильмнар күрсәтелде, сынлы һәм гамәли-декоратив сәнгать әсәрләре тәкъдим ителде.

## ПУШКИННЫҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ

А.С.Пушкинның туган көне уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев шагыйрьнең Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Чәчәк салу тантанасында ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Дәүләт Советы депутатлары, хакимият әгъзалары, әдәбият, сәнгать әһелләре, фән эшлекләләре һ.б. катнашты.

Һәйкәл алдындагы мәйданчыкта шигъри митинг  булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, шагыйрьләр Наилә Ахунова, Эдуард Угаров, Алексей Остудин, Алёна Кәримова, Альбина Әпсәләмова, Айрат Бикбулатов, прозаик, автор-башкаручы Рөстәм Сабиров һ.б. чыгыш ясады. Шигъри митинг М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында А.С.Пушкинның тууына 218 ел тулу һәм Рус теле көне уңаеннан зур бәйрәм буларак дәвам итте. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. «Телләрнең, традицияләрнең һәм мәдәниятләрнең күп төрлелеге – безнең бәһасез байлыгыбыз. Аларны рус теле берләштерә», – диде ул. Президент үзенең чыгышында рус телен саклауда һәм үстерүдә республикабыздагы рус милли-мәдәни берләшмәсенең зур роль уйнавын билгеләп үтте.

## КОНФЕРЕНЦИЯ ҺӘМ ТАНТАНА

Бөек татар шагыйре Г.Тукайның Уфага килүенә 105 ел тулды. Шул уңайдан Башкортстан Республикасының башкаласында, М.Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогика университетында «Тугандаш халыклар әдәбиятларында традицияләрнең саклануы» дигән темага фәнни-гамәли конференция һәм тантаналы кичә булып узды. Конференциядә катнашучыларны Башкортстан дәүләт педагогика университеты ректоры Раил Асадуллаев, БР Дәүләт Җыен-корылтаеның комитет  рәисе урынбасары, БР татарларының милли-мәдәни автономия советы рәисе  Римма Үтәшева, Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Зәки Алибаев, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов сәламләде. Конференциядә Уфа һәм Казан галимнәре докладлар белән чыкты, чыгышлар ясады. Шул ук көнне «Габдулла Тукай. Энциклопедия» китабын тәкъдим итү дә булды. Бу чараларда Казаннан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, галимнәр Зөфәр Рәмиев, Рауза Солтанова, Эльмира Галимова, Әлфәт Закирҗанов, Таһир Гыйләҗев, Илһам Гомәров катнашты һәм чыгыш ясады. Кичен университетның концерт залында «Син сазыңны уйнадың» дип аталган кичә булды. Анда Марат Кәримов, Кадим Аралбай, Хәсән Назар, Риф Мифтахов кебек җирле шагыйрьләр белән бергә Казаннан Роберт Миңнуллин, Мөхәммәт Мирза чыгыш ясады. Кичә Идрис Газиев, Марат Шәрипов, Айгөл Сагынбаева һ.б. җырчыларның чыгышлары белән үрелеп барды.

## «НӘҮРҮЗ» ФЕСТИВАЛЕ

Казанда «Нәүрүз» халыкара театр фестивале булып узды. Быел ул Саха (Якутия) Республикасы сәнгатенә багышланды. Анда Алтай, Башкортстан, Кабарда-Балкар, Казакъстан, Хакасия, Тыва, Чувашстан театрлары катнашты. Эстониядән «R.A.A.M.»

театры махсус кунак буларак чакырылды. Фестивальнең ачылу тантанасында ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин чыгыш ясады. Ул ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлавын ирештерде. Спектакльләр Камал театрының зур һәм кече залларында, Тинчурин, Әкият, Яшь тамашачы театрларында барды.

«Нәүрүз»дә якутлар сәхнә тотты. Аларның төрле жанрда иҗат ителгән, традиция һәм заман яңалыгы бергә кушылган спектакльләре югары бәяләнде.

Киләсе фестиваль 2019 елда узачак һәм Башкортстан театрларына багышланачак.

## МИЛЛИ МӘГАРИФ – ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Чаллыда милли мәгарифне үстерү мәсьәләләренә багышланган «түгәрәк өстәл» булды. Анда ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Чаллы шәһәре мэры Наил Мәһдиев катнашты. Бу сөйләшү алдыннан Э.Фәттахов шәһәрнең мәгариф системасында эшләүче җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашты, Чаллыда мәгариф системасында тупланган уңай тәҗрибәне күрше-тирә районнардан да өйрәнергә килүләрен әйтте. «Түгәрәк өстәл» сөйләшүендә сүз укучыларга төпле белем бирү максатында матди-техник базаны яхшырту, кадрлар әзерләү, методик кулланмалар белән тәэмин итү мәсьәләләренә игътибарны көчәйтү турында барды. Министр Мулланур Вахитов исемендәге 2нче гимназияне үрнәк татар гимназиясе дәрәҗәсенә күтәрү, милли мәктәпләр өчен һәр елны Чаллы дәүләт педагогика университетына 200 кеше кабул итү һәм әзерләп чыгару бурычын куйды.

## ХАЛЫКАРА БИЕННАЛЕ

Казакъстанның башкаласы Алматыда «Җәмгыятьнең рухи тормышына язучыларның тәэсире. Дөньяның тотрыклы үсеше» дип аталган халыкара әдәби биеннале булып узды. Анда Англия, Финляндия, Австрия, Кытай, Корея, Һиндстан, Иран, Үзбәкстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Таҗикстан һ.б. республикалар вәкилләре катнашты. Язучыларның иҗади потенциалын файдаланып, җәмгыятьне рухи тазарту максатында үткәрелгән бу чара кысаларында халыкара конференция, «түгәрәк өстәл» сөйләшүләре, китапханәләрдә очрашулар уздырылды. Халыкара биенналедә Казаннан Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин катнашты. Ул бу чарага Россиядән килгән бердәнбер шагыйрь иде. Р.Миңнуллин Алматының Абай исемендәге опера һәм балет театрында Казакъстан язучылар берлеге рәисе, җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь, драматург Нурлан Оразалинның 70 яшьлек юбилее уңаеннан уздырылган тантаналы кичәдә дә катнашты һәм чыгыш ясады. Бәйрәмдарга ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлавын ирештерде. Аны Татарстан Язучылар берлеге исеменнән дә тәбрикләде.

## БИШЕНЧЕ ТОМ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

Татарстан Фәннәр академиясенең Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты «Татар энциклопедиясе»нең 5нче томын дөньяга чыгарды. Бу томда «Р», «С», «Т» хәрефләренә багышланган 3824 мәкалә урын алган. Аларның 1500е шәхесләргә багышланган, 950дән артык иллюстрация бар. Бу басма рус телендә чыккан энциклопедиянең тәрҗемәсе генә түгел. Аңа 100дән артык яңа мәкалә өстәлгән, күбесе яңартылган, төзәтелгән, яңа статистик мәгълүматлар белән тулыландырылган. Әлеге том тулысы белән «татарлар», «Татарстан» төшенчәләре белән бәйле, шуңа күрә татар халкы, Татарстанның тарихы, сәнгате, әдәбияты, сәнәгате, авыл хуҗалыгы һ.б. өлкәләренең үсешен күрсәткән мәгълүматка бай мәкаләләр шушы томда тупланган. «Татарстан Республикасы» мәкаләсе үзе генә дә 54 бит урын алган. Анда республикабызның Конституциясе, хокукый статусы, административ-территориаль бүленеше, дәүләт органнары, символлары, дәүләт бүләкләре һ.б. турында аерым мәкаләләр бирелгән.

Том ахырындагы кушымталар да игътибарга лаек. Анда Социалистик Хезмәт Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Татарстанның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреатлары, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларының тулы исемлекләре бар. Татарстан Республикасының физик, административ, геологик карталары, шулай ук татарларның Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә күпләп таралып урнашкан төбәкләрен күрсәткән карталар тәкъдим ителгән.

## МУЗЕЙДА – ӘДӘБИ КИЧӘ

ТР Милли музеенда шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Зөлфәтнең тууына 70 ел тулу уңаеннан әдәби кичә булды. Анда әдәбият галиме Фоат Галимуллин әдипнең иҗаты һәм тормыш юлы турында сөйләде. Шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Розалина Шаһиева, Асия Юнысова, язучы-прозаик Камил Кәримов Зөлфәт турында истәлек-хатирәләре белән уртаклаштылар. Татарстанның халык артистлары Илдус Әхмәтҗанов, Хәлим Җәләй шагыйрьнең шигырьләрен укыды. Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов башкаруында Зөлфәт сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Кичәне әдәби салон хуҗабикәсе Флёра Дәминова алып барды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Интервью И.ИБРАГИМОВА с председателем Исполнительного комитета Всемирного конгресса татар Р.ЗАКИРОВЫМ.*
*«Проза и поэзия»: исторический роман Ф.БАЙРАМОВОЙ «Хидржа»; Д.ГИСМУТДИН. «Драгоценный камень»; стихи Л.ШАГИРЬЗЯН, Р.ИДИЯТУЛЛИНА, И.САБИРОВА .*
*«100-я страница»: И.САБИРОВ. «Словарь родного языка».*
*«Воспоминания»: И.ТАГИРОВ. «На пути свободы»; Г.КАРИМОВА. «Вот такая я Зайнаб».*
*«Вопрос от редактора»: Р.ХАННАНОВ. «Здоров ли дух твой, моя нация?»*
*«Литературное наследие»: З.ВАЛИДИ. «Воспоминания»;*
*Л.МУХАМЕТЗЯНОВА. «Самарские татары и современный фольклор».*
*«Наши знатные лица»: Р.ФАЙЗУЛЛИН. «Тоска».*
*«История»: М.ОНАР. «Заметки об исторических изображениях татар».*
*«Искусство»: статья Р.БАТУЛЛЫ о деятельности Челнинского татарского драматического театра; А.ЮНУСОВА. «Дороги и песни».*
*«Творчество читателей»: стихи Г.ХАСАНОВА.*
*«Страницы юмора»: отрывки из произведения З.ВАЛИДИ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Сабантуй». Картина художника Усмана Абдулова.*
*Делегаты Форума татарской молодёжи в Булгарах. 2014 год.*

## IN THIS ISSUE:

*Interview of I.IBRAHIMOV with the Chairman of the Executive Committee of the World Congress of Tatars R.Zakirov.*
*«Prose and poetry»: historical novel by F.BAIRAMOVA «Hegira»; D.GISMUTDIN. «Precious stone»; Poems by L.SHAGIRZYAN, R.IDIYATULLIN, I.SABIROV.*
*«100th page»: I.SABIROV. «Dictionary of the native language».*
*«Memoirs»: I.TAGIROV. «Towards freedom»; G.KARIMOVA. «This is what I'm like, Zainab».*
*«Question from the editor»: R.KHANNANOV. «How healthy is your spirit, my nation?»*
*«Literary heritage»: Z.VALIDI. «Memories»;*
*L.MUKHAMETZYANOVA. «Samara Tatars and Modern Folklore».*
*«Our notable persons»: R.FAIZULLIN. «Yearning».*
*«History»: M.ONAR. «Notes on the historical images of the Tatars».*
*«Art»: article by R.BATULLA on the activities of the Naberezhnye Chelny Tatar Drama Theater; A.YUNUSOVA. «Roads and songs».*
*«Creativity of readers»: poems by G.KHASANOV.*
*«Pages of humor»: fragments from the work by Z.VALIDI.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social-cultural life.*
*On our covers: «Sabantuy». Painting by the artist Usman Abdulov.*
*Delegates of the Forum of Tatar youth in Bulgary. 2014.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Сабан туе». *Госман Абдулов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Татар яшьләре форумы делегатлары Болгарда. 2014 ел.